# КАЗАН УТЛАРЫ

4.1995



# Нури Арсланов

## Шагыйрьгә

Булса синдә Әфләтунның акылы,
Садәлеге керсез сабыйның,
Дәрвишлеге Хуҗа Насретдинның,
Исәрлеге Мәшрәп сафиның,
Телгә оста булсаң Чичән кебек,
Уйга — йөгерек, дала атыдай,
Гаделлеккә Нәүширваннан гадел,
Юмартлыкка булсаң Хатом-Тай...
Анда да син камил түгел, шагыйрь!
Җитми әле Хәйям касәсе,
Һәрдәм тулы шатлык шәрабына!
Бар әле, бар күкрәп-яшьнәсе,
Салават күпере салып күңелләргә
Коясың бар хисләр ләйсәнен,
Кирәк сиңа Мәҗнүн мәхәббәте
Һәм илһамы гүзәл Ләйләнең!..

Син кәрванбаш нар дөягә охшаш —
Күпме йөкләр сиңа артыла!
Тик истә тот: иң мөкатдәс йөгең —
Тугрылыклы булу халкыңа.



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**4**

**(870)**

**1995**

КАЗАН

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Т. МӨБАРӘКОВ. Хәтер аланы. *Повесть-кыйсса* ..... 3
Ә. ГАФФАР. Дәрья башы. *Повесть* ..... 95
РАФАИЛ. Сандугачлар. *Шигырьләр* ..... 120
К. СӘГАДӘТ. Нигез. *Шигырьләр* ..... 130

РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНГА 60 ЯШЬ

Н. ГАМБӘР. Җәяүле күбәләк ..... 87
Роберт ӘХМӘТҖАН. Төрле еллар дәфтәреннән. *Шигырьләр* ..... 88

ОСТАХАНӘ

Г. ӘСӘН. Бала чакта... *Шигырьләр* ..... 125

ЕЛЛАР КАЙТАВАЗЫ

Б. СОЛТАНБӘК. Сталинның Бакудагы дусты ..... 133

МӘДӘНИ МИРАС

Г. БАТТАЛ. Казан төркиләре ..... 140

М. БӘДӘЙЛИНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Рухы сынмаган көрәшче ..... 168
М. БӘДӘЙЛИ. Тормыш төпчекләре ..... 169

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Л. ӘХМӘДИЕВА. Язмыш һәм иҗат ..... 175

Безнең календарь ..... 181, 182

ҮТКӘН МӘСЬӘЛӘ

Т. ӘЙДИ. Инкыйраз көзгесе ..... 184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*
**Гариф Ахунов**
**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**
**Тәлгат Галиуллин**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Зиннур Мансуров**
**Рөстәм Мингалимов**
**Минтаһир Минһаҗев**
**Мөхәммәт Мәһдиев**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Индус Таһиров**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Тәүфикъ Әйди**
*(бүлек мөхәррире)*
**Марсель Әхмәтҗанов**

Б е з н е ң  а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: повести Т. МУБАРАКОВА «Поляна памяти», А. ГАФФАРОВА «Исток». Стихи Р. ГАЗИЗОВА, К. САГАДАТА, Г. АСАНА.
«К 60-летию Роб. Ахметзянова»: стихи Роб. АХМЕТЗЯНОВА.
«Эхо прошлых лет»: статья Б. СУЛТАНБЕКОВА «Друг Сталина из Баку».
«Культурное наследие»: статья Г. БАТТАЛА «Казанские тюрки».
«К 100-летию М. Будайли: миниатюры М. БУДАЙЛИ.
«Литературная критика»: статья Л. АХМАДИЕВОЙ «Судьба и творчество».
«Острая проблема»: статья Т. АЙДИ о проблемах татарской периодической печати.
Наш календарь.
На наших обложках: «Энергия» — картина художника И. Ханова, известный переводчик, ученый Р. Даутов.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: the narratives of T. Mubarakov «Memory Glade», A. Gaphpharov «Source». The verses of R. Gazizov, K. Sagadat, G. Asan.
«To the 60 th Anniversary of Robert Akhmetzyanov»: the verses of R. Akhmetzyanov.
«Echo of the Past Years»: B. Sultanbekov's article «Stalin's Friend from Baku».
«Cultural Heritage»: G. Battal's article «Kazan Turki».
«To the 100 Anniversary of M. Budaili»: M. Budaili's miniature.
«Literary Critique»: L. Akhmadieva's article «Fortune and Creation».
«Sharp Problem»: T. Aidi's article about the problems of Tatar periodical press.
«Our Calendar».
In our corvers: I. Khanov's picture «Energy», well-known translator, scientist R. Dautov.

- Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.
- Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
- Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Марсель Галиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Гөлназ Хөснетдинова.

Производствога бирелде 1.02.95 ел. Басарга кул куелды 14.04.95 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 10 975. Заказ Д-139.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1995 ел.

# Чәчмә әсәрләр



**Тәбриз Мөбарәков**

# ХӘТЕР АЛАНЫ

ПОВЕСТЬ-КЫЙССА

Төш вакыты. Эссе, бөркү. Дөньяның мәлҗерәп, оеп калган чагы. Рәшәле тоныкк күктә июль кояшы үзе дә үр менеп әлсерәгән, бер мәлгә туктап, зенитта хәл җыеп утыра сыман.

Урман аланында шылт иткән аваз юк. Исәрләнеп берөзлексез скрипка сызган чикерткәләрнең дә тәнәфес вакыты. Армас, эшсөяр бал кортлары гына, чәчәктән-чәчәккә кунып, ширбәт эчеп туймыйлар. Ләкин аларның да очулары сүлпән, безелдәүләре зәгыйфь шикелле...

Урман хуҗалыгы директоры кызы Шура, киртәгә менеп атланган да, шалаш янында чабата ясап утырган каравылчы малайны үчекли: «Тофик — Сунгатның малаеның малае... Тофик — Сунгатның малаеның малае...»

Тәүфыйк атлы малай леспромхозның яшелчә бакчаларын саклый. Кәҗәләр бик йөдәтмәгән араларда чабата ясый. Малайның эше тыгыз. Ул, чабатасының сыңарын тәпәчләп калыптан төшерә дә, икенчесенә керешә.

Унике яшьлек малайга чабата ясау — авыр эш, бигрәк тә сыдырып юкә йомшартуы. «Чабатаңны тыгыз кайтарма, тезәр юкәләреңне югарак яса», — дип өйрәтә өйрәтүен чабата остасы Начти түти, әмма Тәүфыйк ул өйрәткәнчә үк булдыра алмый әле. Начти түти әртиле, сагыз чәйнәгән шикелле, бер дә кечәнмичә генә кеше башына көненә биш-алты кием чабата ясый. Ә Тәүфыйк, бик тырышса да, ике көнгә өч кием генә ясый ала. Әле шуларына да бармаклары, шешеп тоткан уч төбе төннәр буе сулык-сулык сызлап чыга. Чабата ясау газаплары төшләренә керә малайның...

Леспромхозда эшләгән бабасы янына беренче мәртәбә килүендә барак малайлары: «Сөнгать бабай, бу кемең?» — дип сорагач, «Малаем түгел, малаемның малае», — дигән иде бабасы. Шул җитә калды инде

---

Тәбриз МӨБАРӘКОВ — физика-математика фәннәр кандидаты. Арча районында туган. Проза әсәре белән журналда беренче тапкыр катнаша. Уфада яши.

Әсәр кыскартылып басыла.

малайларга. Күзләренә Тәүфыйк чалындымы, әйдә такмакларга: «Сөнгатьнең малаеның малае! Сөнгатьнең малаеның малае!»

Менә әле дә Шураның тавышы яңгырады:

— Сунгатның малаеның малае...

— Ну, кызый, бетердең бөтен нервыларымны!

Тәүфыйк, тезендәге чабатасын бер якка атып бәрә дә, киртәдән төшеп кача башлаган кызны өч сикерүдә куып җитеп, аркасыннан түбәнрәк җиренә чабата юкәсе белән суга.

«Ма-ма!..» Шура артын уа-уа бии, үрсәләнә, инде зәһәрләнеп такмаклый башлый:

— Малай, малай, күптән калай! Мин синең бөтен кыярларыңны, кишерләреңне утап бетерәм төннә белән! Мин синең шалашыңны җимереп ташлыйм!

Тәүфыйк, икенче сыңарын да ясап бетереп, чабаталарын парлап бәйли. Су бөркеп, шалаш эченә ыргыта: күләгәдә ятсыннар, чабата мастеры Начти карчык шулай өйрәтә.

Шураның ачуы тиз үтүчән, кинә саклый торган кыз түгел. Ул тагы шалаш янына килеп чүгәли. Тыз-быз килеп юкә мунчалаларын җыештырып йөргән Тәүфыйкның эше беткәнен сабыр гына көтеп тора.

Шул чакта бараклар ягыннан Шураның әнисе Ирина Васильевнаның тавышы ишетелде:

— Шура, Шурочка, где ты? Иди домой, доченька, будем обедать!

— Я здесь, мама, бегу-у!.. Тофик, после обеда мин опять синен янына килермен, ярый?

Шура Тәүфыйкка чыршы күркәсе томырды да өйләренә таба йөгерде.

Шура болай әйбәт кыз үзе, тик менә эшсезлектән гаҗиз. Аның яшендәге кызлар поселокта аз, булганнарының да трай тибеп йөрергә вакытлары юк — кайсы бала карый, кайсылары аналарына ияреп яшелчә бакчасына чүп утарга, печән кабартырга йөри. Нишләмәк кирәк, дөньясы шулай корылган инде — нәчәльник балалары гына рәхәт яши бу дөньяда...

«Тәүфыйк улым, син кайда? Өйгә кайт, улым, ашарга!» — Тәүфыйкны да әнисе шулай чакырып алыр әле, сентябрь генә килеп җитсен. Әлегә Тәүфыйкны ашарга чакырып алучы кеше юк. Урман кисүче хатын-кызларның пычкы, балталарын кайрап, төзәтеп торган бабасы да моннан биш-алты чакрым җирдә шалашта яшәп ята. Ул көн дә кайтып йөри алмый, аның аяклары авыру, буыннарына тоз утырган.

Тәүфыйкның тормышы болай ару гына. Шалаш куенында тастымалга төрелгән ипи кыерчыгы бар, ә кишер, кыяр бакчада үсеп утыра. Каравылчы кешегә аларны туйганчы ашарга рөхсәт.

Ипиен никадәр кечкенә кабып ашарга тырышмасын, әбәдкә дигән нормасы ике кыяр ашарга да җитмәде. Ярар, җитми калган җирен Тәүфыйк кишер ашап утырыр. Әбәтен малай котелоктан су эчеп тәмамлады. Су җылына төшкән, коедан салкын су алып киләсе булыр... Аннары шигырь көйләде:

> — Амин, амин алманды,
> Авыз-борын ялманды.
> Күз күрде — тамак туймады,
> Әзрәк йөрәк ялганды...

Сугышка кадәр Тәүфыйк бер-ике җәй колхозның балалар бакчасына йөргән иде. Малайлар ашагач, әнә шулай итеп «әпәр» итәләр иде.

Тәүфыйк, шалаштан чыгып, бакчаларга күз салды. Чүп утаучы хатын-кызлар да әбәдкә кайтып киткәннәр. Бакчалар тирәсендә караклашу мәкере белән йөрүче кәҗәләр дә күренми. Кәҗә халкы үз кадерен үзе белеп яши шул — нигә аларга бу эсседә караклашып йөрергә, рәхәтләнеп күләгәдә ятуга ни җитә?..

Ярар, Тәүфыйкка да бераз черем итеп алырга була. Малай, шалашына кереп, йомшак печән өстенә сузылды...

* * *

Шура белән Тәүфыйкның танышулары кызыклы гына булды. Җәйге каникуллар вакытында малай, бабасы янына килгәч, җәйгә бирәр төрле эш табылмасмы дип, леспромхоз конторына бардылар. Сонгать бабай, онытына күтәп торырга кушып, директор янына кереп китте. Тәүфыйк урамда торып калды.

— Эй, малай, син кем янына килдең?

Тәүфыйк тавыш килгән якка караса, бер малай чирәмдә биштәш уйнап утыра. Малай аның янына килде.

— Ну, исемең ничек синең?

— Тәүфыйк.

— Толик, значит?

— Нишләп Түлик булыйм ди тагы? Тәүфыйк.

— Ну, Тофик так Тофик...

Малай торып басты, бер учыннан икенче учына авыштыргалап, ташларын чалбар кесәсенә салып куйды. Күзләренә төшкән җиткү чәчләрен башын чөеп кенә артка ташлады да сорау алуын дәвам итте:

— Ну, кем янына килдең син?

— Ә син кем янына килдең?— Тәүфыйкның махы бирергә исәбе юк.

— Минме? Мин беркем янына да түгел. Без монда торабыз, ике ел, биш ел, егерме биш ел, беләсең килсә!

«Бу малайга әзрәк житеп бетми, ахры»,— дип уйлап куйды Тәүфыйк.

— Ә син йөзә беләсеңме, әгәр белсәң, мин сине бер җиргә алып барам, син миңа камышлар алып бирерсең!

Һи, Тәүфыйкмы йөзә белмиме! Ничек кирәк, шулай йөзә ала Тәүфыйк: колач бирәп тә, чалкан ятып та, кызлар шикелле арт сикертеп тә. Алар авылында малайлар тәпи йөри башлаганчы йөзәргә өйрәнәләр, чукмарбашлар шикелле, суда, яр буенда үсә Мирас малайлары.

«Айда минем арттан!»— дип, сарычәч поселок кырыендагы урманга таба йөгерде.

Малай Тәүфыйкны поселок белән урман арасында агып яткан мул сулы елга ярына алып килде. Бу төштә елга борылышы шактый киң, тирән түгай да бар икән.

— Әнә, күрәсеңме камышларны, вот алып чык шуларны!— ди сарыбаш, камышларга таба ымлап.— Мин карыйм синең ничек йөзгәнеңне.

Тәүфыйк күлмәк-ыштаннарын салып ташлый да, йөгереп килеп, бөтен нәмәстәкәйләрен ялтыратып, суга сикерә.

Авызына бер төп камыш кабып йөзеп чыкса — ярда малай юк, малай елый-елый кире кайтып бара. Тиз-тиз киенеп, Тәүфыйк аның артыннан йөгерә, контор янында куып җитә малайны:

— Син нәрсә, нигә елыйсың? Мә сиңа камыш, тамыры-ние белән йолкып алдым, мә!

— Ты бессовестный малайка, кирәкми синең камышларың, бессовестный!..

Шулчак контордан Тәүфыйкның бабасы белән бер озын абый килеп чыктылар.

— Доченька, что с тобой, отчего ты плачешь? Кто тебя обидел?— ди озын абый, үзенә килеп сыенган сарыбашның чәчләреннән сыйпап.

— Вот этот мальчишка! Он нехороший, он бессовестный!.. Я просила сорвать мне камыши, а он... а он...

«Доченька"! Кыз бала! Менә сиңа мә!» Тәүфыйк баскан җирендә мәтәлеп китә язды.

— Чү, улым, чү, син ни эшләдең, нишләп рәнҗеттең кыз баланы?— Куркып, каушап калган бабасы Тәүфыйкны шелтәли башлады.— Җә, ни начарлык кылдың, җә димен?

— Әнә теге елгадан, йөзеп кереп, камыш алып чыктым, ул үзе сорады. Мин... мин аны малай кеше дип белдем ич...— Тәүфыйк,колакларына кадәр кызарып, башын түбән иде.

Эшнең нәрсәдә икәнен тиз чамалап алды Сөнгать карт:

— Ә, ни, теге... Фидыриваныч, теге, ни... безнең авыл жирендә малайлар суга, теге, ни... бич шәрә калып чишенеп керәләр бит инде. Малай зур хата җибәргән, Фидыриваныч, гафу итегез инде, Фидыриваныч, ул икенче алай эшләмәс. Шулаймы, улым?

— Ах, вот в чем дело!— Озын абыйның чыраенда елмаю галәмәте чагылып китә.— Егетнең монда гаебе юк шикелле, хаталык малайда түгел... Но, что, доченька, успокоилась? Вот и хорошо! Ә камышны, Шура, алырга кирәк, үзең заказ биргәнсең ич. Бар, ал!

Шура, матур зәңгәр күзләренә нәфрәт, зәһәрлек билгеләре чыгарырга тырышып, Тәүфыйкның кулындагы камышны тартып алды да йөгереп китеп барды. Фидыриваныч, конторага кереп барышлый, Тәүфыйкның бабасына борылып әйтте:

— Шулай, Сунгат абзый, сөйләшкәнчә, укулары башланганчы егет яшелчә бакчаларын саклар. Шәп итеп шалаш ясап куй үзенә...

— Бабай, бабай, кем ул монда Фидыриваныч абый?

— Фидыриванычмы? Фидыриваныч шушы леспромхозга баш кеше була инде, нәчәльник кеше! Бик миһербанлы кеше, кешегә гел игелек эшләргә тырыша, кече күңелле кеше.

— Ә Шура кем?

— Фидыриванычның кызы, димәк. Их син, кавалер!— Бабай кеткелдәп көлә.— Чут кенә эшне бозмадың.

Менә шулай кечкенә генә җәнҗал белән башланды кыз белән малайның беренче очрашу-танышулары.

* * *

Урман хуҗалыгы директоры Купцов — озын, килешле гәүдәле кеше. Һәрчак зәңгәр гимнастеркадан, галифе чалбардан йөри. Билендә ике телле яссы каеш, аягында җаннары чыкканчы чистартылган кирза итекләр. Шуның өстенә, гимнастерка якасына эчтән ак каурый кәгазь тегеп, борын астында гына бер чеметем мыек калдырып, һәр көн бик чиста кырынып йөрүе аны кавалерия әфисәренә охшата.

Тәүфыйкка Купцов — укытучы Габдрахман абыйларын хәтерләтә. Ул да озын буйлы, какча гәүдәле кеше иде. Дулкынланыбрак торган кара чәчле, борын астында гына мыек йөртә. Сабыр холыклы, укучыларына беркайчан да тавышын күтәрмәс, ләкин класста тынлык, тәртип булыр. Авыру булдымы икән ул, бер дә җылыга туймас иде, кыш көннәрендә аркасын мичкә терәп торырга ярата. Шуңа күрә аның аркасы гел моржа агына буялган булыр иде.

Әле дә күз алдында Тәүфыйкның: менә җыр дәресе бара, кулларын пинжәк җиңенә кушырып, аркасы белән мичкә сөялгән Габдрахман абый җыр башлый:

Ленинград — Мәскәвә,
Урамнары таш кына...

Класс дәррәү күтәреп ала:

Яшь йөрәгем фашистларны
Бетерергә ашкына!..

Җырны Әхмәдиев Миңнулла, бүтәннәр тынып калгач та, тагын әллә никадәр сузып тора ала. «Синең тының киң, тавышың да матур гына, синнән киләчәктә җырчы әртис чыгып куюы бар»,— ди Габдрахман абый, Миңнулланы аркасыннан сөеп.

Авыл уртасына, дөресрәге, янган мәчет урынына салынган бина ике катлы. Мәктәп икенче катта. Аста — клуб белән колхоз кәнсәләре, өстә ике класс бүлмәсе, китапханә. Бер класста беренчеләр белән өченчеләр утыра. Аларны Мәрзия апа укыта. Икенче белән дүртенчеләр — Габдрахман абый класслары. Озын тәнәфес вакытында, гадәтенчә, Габдрахман абый кәнсәләргә тәмәке тартырга төшеп китә. Мәрзия апа өйләренә йөгерә, аның имчәк баласы бар.

Мәктәптә егерме минутка «аулак өй». Менә шул чакта башлана инде «Бөек ватан сугышы!» Көзге байлыкта малайларның кесәсе тулы борчак, һәр малайда борчак мылтыгы. «Атаканы» дүртенче класс малайлары башлый. Командирлары — Тити колгасы Габдуллажан. Һәр классында икешәр ел утырган. Мәктәптәге бүтән малайлар аның тезеннән генә. Өченче класс малайлары оборона тота: ишеккә аркылы парта куялар да коридордан һөҗүм итүче дүртенчеләргә борчак мылтыкларыннан ут ачалар. Һәр ике як каһарманнарча сугыша. Һәр ике якка ярдәмгә икенчеләр белән беренчеләр ашыга. Сугыш кызганнан-кыза бара. Хәзер инде яклар бер-берсенә борчакны учлап-учлап бәрәләр. «Патроннар» беткәч, кул сугышлы башлана. Кулга «трофей төшерү», «плен алу» китә. Һәр малай, күзе төшебрәк йөргән кызга килеп ябыша да, үз классына өстери башлый. Тегеләре партага тотынып карышалар, чинашалар, бәргәләшәләр...

Дүртенчеләр зур тантана белән үз классларына кайталар. Трофейлар да мул: биш борчак мылтыгы кулга төшерелгән, өч кыз пленга алынган. Уңышлардан башлары әйләнгән җиңүчеләр сизгерлекләрен югалтканнар: һич көтмәгәндә көчләрен туплап алган өченчеләр һөҗүм итә. Алар, ишектә каршылык очратмыйча, туп-туры класска бәреп керәләр. Максатлары бер — плен төшкән кызларны коткару. Яңадан кыямәт көне куба класста!

«Сугыш»ның иң кызган чагында Габдрахман абый килеп керә. Ни күрсен: класста парталарның асты өскә әйләнгән, идән тулы ап-ак борчак, боз явып үткән диярсең. Малайларның, чабыштан килгән атларныкы шикелле, ярсудан борын тишекләре киңәйгән, кызларның яулыклары сыдырылып муеннарына төшкән, чәчләре тузгыган. Класста балта элеп куярлык тузан...

— Тынычланабыз,— ди Габдрахман абый, өстәл артына килеп утырып.— Парталарны рәтләп куябыз, форточкаларны ачып җибәрәбез...

Ауган парталар рәтләнә, форточкалар ачыла.

— Хәзер урыннарыбызга утырабыз, борчак мылтыкларын парталар өстенә куябыз...

Мылтыклар парталар өстенә куела.

— Ә синә, Хафизә, аерым әйтергә кирәкме? Чыгар, чыгарып куй мылтыгыңны, синдә мылтык булмый калмас.

Кан җирән чәчле иржәнкә кыз Хафизә, кайсы төшеннәндер чыгарып, парта өстенә бәрәңге тукмагыдай иләмсез бер нәрсә куя.

— Үзең ясадыңмы?

— Үзем.

— Маладис. Ә син, Габдуллажан? Синдә алар икәү бит, куй икенчесен дә...

Габдуллажан, кесәсеннән чыгарып, парта өстенә тагын бер мылтык куя.

— Староста һәм дежурлар, мылтыкларны җыеп мичкә ташлыйсыз.

Мылтыклар мичкә ташлана.

— Зөлфия, Сара, идәндәге борчакларны себереп җыеп алыгыз. Мич артында себерке, чиләк булыр. Бибинур тәтә алып кайтып, казларына сибәр, ичмасам. (Бибинур тәтә — мәктәп җыештыручы, кыңгырау шалтыратып торучы).

Бу әмер-шелтәләрен Габдрахман абый тавышын күтәрмичә генә, өстәл артында класс журналларына нәрсәдер язган көйгә биреп утыра. Йөзе-чырае тыныч, мөлаем.

Укытучы урыныннан тора, сәгатенә карап ала: «Никадәр вакыт бушка сарыф ителгән!»

— Син нишләп әле монда?— ди Габдрахман абый, арткы рәттә, Габдуллаҗан белән янәшә шыңшып утырган өченче класс укучысы Әлфияне күреп алып (Әлфия — мәктәптә иң матур кыз).

— Мин... мине Габдуллаҗан плен төшерде...

— Бар, бар, сеңлем, үз классыңа чыгып утыр. Мәрзия апаң яңа дәрес бирә торгандыр.

— Мин чыга алмыйм, мине... мине Габдуллаҗан кадаклап куйды...

Әлфия елап җибәрә. Чынлап та, юньсез Габдуллаҗан Әлфиянең күлмәк итәген эскәмиягә кадаклап куйган икән. Бар икән залимлек бу малайда!

Икенче класста матур язу дәресе. Габдрахман абый кара тактага «Без алга барабыз көн саен!»— дип язып куя да, янә дәвам итә:

— Икенче класс! Зур дикъкать белән тыңлыйбыз: тактадагы җөмләне бик матур итеп дәфтәрләребезгә күчереп язып куябыз, биш мәртәбә. Тавыш-тын чыгармыйча гына.

— Җә, кем өйгә бирелгән мәсьәләне чишә алмады? Кемегез тотынып та карамады?— Габдрахман абый инде дүртенчеләр каршына килеп басан.— Кулларыбызны күтәрәбез, бармы андыйлар, җәгез?

...Мирас мәктәбенә килгәндә Габдрахман әле егет кеше иде. Башта үзләренең авылы мулласыннан сабак алган, аннары ике кыш Кышкар мәдрәсәсендә укып калган ярлы мәзин малае, унҗиде яшьлек үсмер, үз көнен үзе күрергә, ил гизәргә чыгып китте. Өч-дүрт ел каңгырап йөргәч, тагын туган якларына әйләнеп кайтты. Ул елларда татар авылларында яңа мәктәпләр ачылып яткан чак иде.

Мәдрәсәдә бергә укыган сабакташының киңәшен тотып, татар мәктәпләренә укытучылар әзерләүче курсларны тәмамлагач, Габдрахманны Ташлык волостена җибәрделәр. Ташлык аны Мирас мәктәбенә тәгаенләде. Мәктәп дигәч тә, мәктәп дигәннәре — элек Ташлыкта кибет тоткан Хөсни бай амбары иде. Түр стенасына куш тәрәзә тишеп, галанка мич чыгарып җибәргәч, күңелгә мамыклы хәйран гына бер бинага әйләнгән мәктәп, яңа укытучы килгәч, авылның бала-чагасы, яшьләре өчен җан тартып торган урынга әверелде.

Мирас авылы — һөнәрле, кәсепле авыл. Мирас агайлары итек баса, тегү тегә, арба-чана ясый. Балта осталары, морҗа чыгаручылар да бар авылда. Җәен-кышын урманда дегет куып, дегет кайнатып, күмер яндырып көн күргән Зарифныкылар хәтта тирә-юньгә билгеле. Бердәнбер сөннәтче бабай да — Мирас кешесе.

Мираслылар читкә чыгып та кәсеп итәләр. Моны «өязгә чыгу» диләр. Өязгә чыгып йөргән кеше ил-дөнья күрә, урыс белән аралаша, үткерләнә, шомара. Шуңа күрәдер, Мирас халкы чи надан, дөм сукыр кешеләр түгел. Укуга, мәдәнияткә тартылу татарның канында булса да, Мирас кешеләрендә бу омтылыш кирәклеген аңлап эшләнә. Урысча сөйләшә белүнең зарурлыгын да алар җилкәләрендә татыган бәндәләр: урысча бер-ике авыз сүз белмәсәң, Ташлык базарында шалкан сатуы да кыен эш. Авылның иң томана, мокыт агае да үзенең Галиулласын, Сафиулласын мәктәпкә китерә: «Мә, мөгаллим абзый, каты тот, ите — сиңа, сөяге — миңа. Бездән булмады инде, бәлки, малайдан кеше чыгар...»

Габдрахманга чаклы балаларны сыйныфларга бүлеп укыту булмаган. Мәктәп бусагасын беренче мәртәбә атлап кергәне дә, аны инде икенче, өченче ел таптаганы да, бергә укмашып утырып диярлек сабак тыңлаган. Габдрахман исә балаларны сыйныфларга аерып укыта башлады. Бер рәттә беренче сыйныф утыра. Аларга укытучылары хәреф таныта, санарга өйрәтә. Икенче рәттә ижекләп булса да укый белгәннәр — икенче сыйныф балалары. Иң арткы рәттә өченчеләр утыра. Габдрахманга балалар укыту бик тә ошый. Әнә ничә пар риясыз күзләр аңа текәлгән.

Әмма Габдрахман берүзе, ялгыз. Тәҗрибәсе житенкерәми. Балалар укыту шикелле нечкә, четерекле эштә киңәшер, фикер алышыр кешесе юк аның.

Шулай шатлыклы газаплар эчендә бер ел үтеп тә киткән. Киләсе уку елында инде мәктәптә дүрт сыйныф булачак. Җәен авыл агайлары, амбар янтыгына терттереп, тагын бер бина ясап куйдылар. Тәрәзәләрен зәңгәргә буяп, тирәли рәшәткә тотып алгач, мәктәп тагы да күркәмләнеп, ямьләнеп китте. Әйдә, Габдрахман!..

* * *

Сиражи карт йорты Аргы як урамда, су буенда. Караңгы, аулак урында утыра. Картайды инде Сиражи. Бар иде аның дөньяны якасыннан селкеп яшәгән чаклары! Хәзер Сиражиның мүкләнеп беткән капкасын каккан, капка эченә үткән кеше юк. Бала-чагалар да Сиражи йорты турыннан, бичуралы йорт янынан узган шикелле, шүрли-шүрли, үзләреннән кечерәкләрне житәкләп-күтәреп үтәләр.

Мортазаныкыларны Мирас халкы өнәми. «Мортазаныкыларның күзендә ат тоягы эзләре бар» — алар ат карагы. Ат карагы дигән исемне авылда караклыкны кәсеп итеп алган, бу эштә маһирлыкка ирешкән абруйлы каракларга гына тагалар. Сиражи хәтта Бибигайшәнә дә өязгә чыккан жиреннән урлап алып кайткан иде. Күзгә караңгы кичтә, комган тотып тышка чыгып барган чагында чәлдергән ул аны. Ишек алдында тәгәрәп комганы гына калган Бибигайшәнең...

Һөнәр белү ат карагына да комачауламый. Сиражетдин итек баса белә. Аны бу эшкә атасы Мортаза өйрәтте. Бүре, гадәттә, сарыкны оясыннан ерактарак жирдә буа, диләр. Ат караклары да шул бүре гадәте буенча эш итәләр — туган авылларыннан ерактарак, өязгә чыгып... Яшь чаклары иде. Солыдагы әшнәсе Мирза белән Сиражи көзен өязгә итек басарга чыгып китәләр.

Һай, көзге төннәрнең матурлыгы! Караңгы көзге төнгә ни житә! Көзне Аллаһы Тәгалә ат караклары өчен яраткандыр! Кыш көне, дерес-рәге, кышкы төндә, ишек алдында тояк эзләре калдырмас өчен, тәжрибәле караклар атның аякларына киез ката, башмак чабаталар бәйләп алып чыга. Көз көне чабата-каталарның кирәге юк. Көзен агайлар, мужиклар атларын абзар курасында тота. Солы, печән ашап туеп, йокымсырап торган хайван янына акрын гына якынлашасың. Ят кеше исен сизеп борчыла башлаган, колакларын шомартып читкә тайпылган хайванны ялыннан эләктереп, муенын чәбәкләп сөеп, ял төпләрен кашып юмалыйсың, тынычландырасың, иплэп кенә, кабаланмый гына, башына йөгән кидерәсең. Аннан, абзардан алып чыгып, сыртына сикереп атланасың да — бигайбә, хуҗа абзый!

Ат урлауның рәтен белгән тәҗрибәле карак теләсә нинди дүрт аяклы мәхлукның ялына килеп ябышмас. Атның ниндие юк аның: олау аты, тарантас аты, чабыш аты, елкы аты. Аннан соң, ат урлауның тәмен белгән каракларны халыкта даны чыккан, исеме халык теленә кергән хайван гына җилкендерә, төн йокыларын качыра.

Бу көздә Сиражилар Чаллы якларында йөрделәр. Итек басу эше пычрак эш, дигән сылтау белән итекчеләр өй хуҗаларының мунчасында торып эшләүне кулайрак күрделәр. Мунчада үзең хуҗа — жиде төн уртасында чыгып кит тә җәһәннәмнәреңне айкып йөр!

Итек бастырырга дип йон күтәреп килгән агайларны һөнәрчеләр якты чырай белән каршы алалар:

— Әйдүк, җонлы капчыкларыгыз белән түрдән үтегез!

Бер көнне итекчеләргә бик тә сүзгә әвәс бер агай эш китерде.

— Әссәламегаләйкем, Алла ярдәм бирсен сезгә. Иншалла, исәнлек-саулыктыр?

— Аллага шөкер, саулыктан зарланган юк, беләктә куәт, кулда тәпәч, казанда әтәч!..

Агайдан йорт-илнең, мал-туарның аман-иминлеген сорашкач, итекчеләр сүзне акрын-акрын кирәк якка бора:

— Җәйләр матур килдеме быел сезнең якларда?

— Җәйләр бик матур килде, Аллага шөкер. Вакытында яңгыры булды, вакытында җылысы, дигәндәй.

— Сабан туйлары да шәп булгандыр инде алайса, көрәшләре, чүлмәк ватышлары, ат чабышлары белән, дигәндәй, ә, абзый?

— Булмаган кая ул! Булды, бик тә булды, көрәше дә, ат чабышлары да, булды, бик булды...

— Ат чабышлары димәктән, кемнәр-кемнәр аты баш килде соң?

— Акъяр мулласы Әбүзәр хәзрәтнең Туры айгырына чыкканы булмады. Чаллы сабан туенда баш арты килгән атны җир буе җир калдырып килде. Акъярда да баш килгән дип ишеттек. Бу тирәдә аңа чыгар чабыш аты юк, дип сөйлиләр.

Моңарчы итекчеләр агайны бер дә исләре китмәгән кыяфәт белән, итекләрен тәпәчләгән көйгә генә тыңласалар, аның соңгы сүзләрен тәпәчләрен ташлап, колакларын торгызып тыңлап тордылар.

— Әбүзәр хәзрәтне әйтәм, ул данлы малын кеше күзенә дә күрсәтмидер инде?— Сиражи җеп очын ычкындырмыйча, акрын-акрын гына тарткалап, агайның сүз җомгагын сүтә бара.

— Нигә күрсәтмәсен ди! Якшәмбе саен Әбүзәр хәзрәт Чаллыга ат базарына килә, тарантасына сабан туе батырын җигеп. Акъяр белән Чаллы арасы кырык чакырым җир, шуны хәзрәтнең Туры айгыры ике сәгатьтә уза икән, диләр. Чабышкының аяклары языла торгандыр, нибуч!

Бер атнадан итекләрең әзер булыр дип, сүзгә һәвәс агайны озаткач, әшнәләрнең телендә бер генә сүз булды: Туры айгыр, Туры айгыр!.. Әкиятләрдәге Алтын кош сыман, бөтен күңелләрен, бөтен җисемнәрен биләп алды ул «итекчеләр»нең. Бүген шимбә көнме? Иртәгә иртүк Чаллыга, Ат базарына китәргә карар кылынды...

Бирим дигән колына чыгарып куяр юлына, ди. Итекчеләр базарны иңләп-буйлап озак та йөрмәде, алар игътибарын базар читендәге йорт капкасына бәйләп куелган ат, ат-арба тирәсенә җыелган кешеләр җәлеп итте. Якын килделәр. Киң күкрәкле, озын торыклы дүрт-биш яшьлек айгыр, баскан урынында тора алмый, бии, бер чигенә, бер алга тартыла, өзлексез башын чайкый, колакларын шомартып уйнаштыра. Бертуктаусыз авызлык чәйнәүдән чыккан селәгәйле ак күбек, авыз кырыйларыннан тамып, җилгә оча. Атның зур акай күзләре усал, тәкәббер ялтырый...

Агайлар сүз куерта:

— Вәт ичмасам мал!

— Моңа ун ат акчасы да жәл түгел, билләһи!

— Бу кем дөлдөле икән?

— Нәрсә, күзең чыкканмы әллә? Чаллы сабан туенда баш килгән ат, Акъяр мулласының чабышкысы бит...

Сиражи белән Мирзаның тыннары кысылды: каршыларында кыланып, масаеп, биеп аларның Алтын кошы — Туры айгыр тора лабаса! Агайлар гапләрен дәвам итәләр:

— Мулла абзый кайда тота икән бу чибәр егетен?

— Бу бахбайны чәлдергән карак Гани байга әйләнә инде!

«Һи-и, килеп карасыннар! Айгырның абзары — таш пулат, пулат ишекләре тимердән, аларда ат башы кадәр йозаклар, килеп кенә карасыннар!..»

Итекчеләр абайламый да торалар икән: бишмәтен кызыл пута белән буган, мескен бүрек кигән ир уртасы бер кеше тарантаска кырын ятып тора, шул кеше сөйли икән бу сүзләрне.

«Килеп кенә карасыннар! Өстәвенә мин әле төнгә айгырның аякларына богау салып куям, богауларның зынҗыры абзарның идән такталарына береккән. Ә абзарның, богауларның ачкычлары минә кайда йөриләр!— түгәрәк бүрек иясе бишмәтенең кесәләренә суккалап ала.— Һи, килеп карасын караклар!»

Бу ачык авыз — мулла абзыйның хезмәтчесеме, ат караучысымы,— сүзен бетергәч, итекчеләр бер-беренә мәгънәле генә карап алалар да, бер-берсен сүзсез дә аңлап, вакытларын бушка уздырмыйча, үзләре эшкә төшкән авылга юл тоталар. «Алтын кош»ны күрделәр, оясын да белделәр, хәзер аны нибары кулга төшерәсе калды...

... Бер атнадан мунчага, итекләрен алырга дип, теге сүзгә һәвәс агай килеп керә. Керүенә, сөенеч алган шикелле, әсәрләнеп әйтеп сала:

— Ишеттегезме?! Мулла абзыйның туры айгыры — тү-тү! Теге, мин сөйләгән, мәйдан тоткан чабышкы, тү-тү! Чәлгәннәр!

— Китсәнә!— Сиражи бот чабып, хәйран кала.— Без монда, караңгы мунчада, берни ишетми ятабыз! Нәрсә? Ничек? Кайчан?!

— Атна кичкә каршы төндә. Әбүзәр мулла иртән торып тышка чыкса, ат абзары йозаксыз, ди. Абзарда, күзләрен акайтып, мулланың хезмәтчесе ята, ди. Авызына караклар дыңгычлап бүреген тыкканнар, аяк-кулларын ат богауларына богаулап идәнгә ташлаганнар, ди.

— Нәрсә, авылда ни сөйлиләр соң?!

— Авыл халкы телендә гел шул Әбүзәр хәзрәтнең урланган чабышкысы инде.

— Хезмәтче, алай-болай... төсмерләп калмаганмы соң, каракларны, дип әйтүем?— Сиражи сүзне кирәкле юнәлешкә бора.

— Кая ди инде ул төсмерләү, күзгә төртсәң күрмәслек кара төндә!

— Алай икән, алай икән... Ни, итекләрең, агай, әзер. Мә, җылы аякларыңда өстерәргә язсын.

— Рәхмәт, шулай була күрсен. Теге, иптәшең, Мирза, күренми, дигәндәй?— Агай кеше инде ишек сабын тоткан, чыгып кына китми бит.

— Ул ни... авылларына кайтып китте...

— Нәрсә, андый-мондый хәл килеп чыкмагандыр ич?

— Хатынының баласы аркылы килгән!

— Сөбханалла, әстәгъфирулла! Чыгасы юлларын киң кылсын инде.

— Шулай кылсын, киң кылсын...

Бу лыгырдык агайдан котылган гына иде Сиражи, мунчага хуҗа кешенең буй җиткән тилемсә малае килеп керә. Бусагадан ук:

— Ә Милза абзый кайда, кая китте Милза абзый?

— Анаңның түбән авызына теш куярга! Тай, тай моннан, сыпырт мәхлук!..

... Узган төн үк кайтырга тиеш иде инде Мирза. Чабышкыны урнаштыру — аларны урлауга караганда да авыррак эш. Туры айгыр әле яшәргә тиеш, сабан туйларында баш килеп, яңа хуҗасына шөһрәт, дан яуларга тиеш. Шуңа күрә аны ераграк, бүтән өязләргә чыгарып «сеңдерергә» кирәк. Мирзаның бу эшкә маһирлыгы җитәрлек. Тик менә: «Мирза кайда?» «Милза абзый кайда?» Әллә авылда берәр төрле сүз йөриме? Әллә бер-бер эз калганмы «эш» урынында?

Ә нигә Мирза озаклады соң әле? Сиражиның эче пошулы, күзенә йокы керми Сиражиның. Инде әллә ничә тапкыр тышка да чыгып керде — төн караңгы, болытлы, явымсыз. Менә дигән караклар төне. Сукыр лампаны төтәтә-төтәтә тагын итек тәпәчләп алды Сиражи. Эш белән вакыт үткәне сизелми ичмасам, эч пошканы да басыла төшә...

Төн урталары узгач, ниһаять, Мирза кайтып керде. Арыган, йончыган.

— Йә, ничек, ник озак йөрдең?— Сиражи түземсезләнеп, пышылдап кына сораулар яудыра башлый.

— Ал да гөл!..

— Кая чумдырдың?

— Танышка. Хәзергә бахбай аның абзарында торып торыр. Боз каткач, ул атны Агыйделнең аръягына шудырырга тиеш. Башкорт инде бәһасеннән тормас андый малның! Башкорт ат малын таный белә!

— Ә мәһәре? Танышың күп тамыздымы соң мәһәрен? Арзанга ычкынмадымы айгырыбыз?

— Ун атлык булмаса да, дүрт-биш атлык булыр мәһәре.

— Китсәнә?!

— Малына күрә бәһасе инде.

... Утны сүндереп, итекчеләр озак кына план корып яттылар. Бу яклардан тизрәк таярга кирәк, дип хәл кылынды. Алган эшләрне әпен-төпен эшләп бетерергә дә — ычкынырга! Алла, саклаганны сакларман, дигән...

Иртәгесен әшнәләр, «мәһәр»не уртаклап янчыкларына яшергәч, Мирза әйтеп куйды:

— Әллә тагын өйләнеп ташлыйсыңмы, Сиражетдин? Хәзер акчаң бер букча, ә?

— Акчасы бар барын, тик кызы юк. Үзең беләсең бит, безнең капка «кыңгыраулы». Мирас кызлары гына түгел, тирә-юнь авыл кызлары да безнең өйнең бусагасын атлап керәселәре юк.

— Кайгырма, дус кеше! Сиңа дигән кызны урлыйбыз аны, ерактан, белмәгән, ишетмәгән җирдән.

— Кайдан, кемне?

— Безнең хуҗаның күршесе Бибисаҗидә карчык кызын!

— Бибигайшәнеме?! Ул бит мине...

— Тыңлап тор! Син сизенденме — без хуҗа өенә әбәт ашарга кердекме, йә иләк, йә чиләк сораган булып Бибигайшә кереп җитә, үзе кып-кызыл булып кызара. Мине күрәсе килеп керә дисеңме әллә син аны, минем инде өч балам барын белә бит ул. Юк, юкка гына кереп йөрми ул Бибигайшә! Үзең менә дигән ат карагы, ә кызлар күңелен аңламыйсың. Йә, әйт, ошыймы сиңа Бибигайшә?

— Ошавын ошый да... Тик менә...

... Мирзаның планы буенча, итекчеләр Чаллы базарыннан бер яхшы гына ат-арба сатып алдылар. Авылга кайтып, арбаларына печән түшәп, эш коралларын, киемнәрен чыгарып салдылар да, өй хуҗаларын бәхилләтеп, кичкә таба авылдан чыгып киттеләр. Алар Бибисаҗидә карчык йорты турыннан узганда, тәрәзәдә Бибигайшә шәүләсе күзгә чалынып калды...

Тәмам караңгы төшкәч, безнең мөсафирлар авылга янә кайтып, атларын бер аулак тыкрыкка куйдылар. Мирза арба янында калды. Сиражи исә Бибисаҗидә карчык йортының чоланы артына посып көтә башлады: йокларга ятар алдыннан Бибигайшә тышка чыкмый калмас, чыгар...

Нәкъ шулай булды да: тамак кыра-кыра комган тоткан Бибигайшәнең ишек алдына атлавы кая, — Сиражи үзенең кирәк кадәр кулы белән кызның авызын томалады. «Курыкма, Бибигайшә, мин Сиражи... син курыкма гына... Мин сине үзебезнең авылга алып китәм... мин күп акча таба торган егет...»

Бу сүзләрне Сиражи, сарык бәрәнен эләктереп чапкан бүредәй, куркуыннан һушын җуеп мәлҗерәп төшкән Бибигайшәне күтәреп абына-сөртенә арбага таба йөгергәндә пышылдады.

* * *

Мортазаныкылар йортына Бибигайшә бер дә ияләнә алмады. Кырыс, караңгы чырайлы кайнатасы һәм гомер буе иреннән кыйналып яшәгән, кыен ашый-ашый чукракланган эт кояшы

шикелле өнсез генә йөргән кайнанасы Хәдичә ана чит-ят кешеләр иде.

Берсе артыннан берсе көннәр үтте. Нинди йортка килеп эләккәнен, ире Сиражиның ни белән «кәсеп» иткәнен Бибигайшә инде сизенә башлады. Бу йортка җан төн житкәч керә: шыпырт кына чыгып, кемгәдер капка ачалар, кемдер нәрсәдер китерә, нәрсәдер алып китә...

Сиражи белән дә гаҗәп хәлләр булгалый. Шулай, гадәттәгечә, сәкегә урын җәеп кичтән бергә йокларга яталар. Бибигайшә төнлә уянып китсә — янында ире юк. Шул юктан өч-дүрт көн, бер атна югалып торгач, көтмәгәндә, төнлә белән арып-талып кайтып керә. «Кайларда йөрисең син шулай?» — дип соравына, Сиражи, көчле куллары белән хатынын күрәп алып күкрәгенә кыса да, усал күзләре белән бер мизгел карап торгач: «Гайшә биби, күпне белсәң, тилгән алып китәр үзеңне»,— дип, уены-чыны белән хатынының маңгаена чиертә. Ат типте мени — Бибигайшәнең башы әйләнеп китә, маңгае күбеп чыга.

Авыл хатыннары да үзләрен ничектер сәер тоталар. Бибигайшә чишмәгә суга килсә, чишмә янында шау-гөр килеп сөйләшеп торган хатын-кыз тынып кала, сәламенә дә бик тыйнак җавап кайтаралар. Беркөн шулай, су алып киткәч, артыннан бер миһербансызы, юри Бибигайшә ишетерлек итеп: «И-и бичара, кемгә башын бәйләгәнен белмичә килгәндер инде»,— дип әйтә калды.

Бөтен йорт эшләре, мал-туар карау килен җилкәсендә. Бибигайшә көне буе өй белән каралты-кура арасында чуала. Мортазаныкыларның атлары икәү генә. Бер иртәдә шулай мал карарга чыкса — ат абзарында өч ат. Өйгә кереп Сиражидан өченче ат турында сорарга кергән иде, башлаган сүзен әйтеп бетерергә ирек бирмәде Сиражи, сугып егып, эт итеп кыйнап ташлады хатынын. Такмаклый-такмаклый, котырып кыйнады: «Ишетмә, күрмә, сорашма!..»

Кара-каршы өйнең икенче яртысында торган кайната белән кайнана, тавышсыз-тынсыз гына кереп, уларының кыланышын карап тордылар да тавыш-тынсыз гына үз якларына чыгып киттеләр.

Икенче көнне чишмә янында, күршеләре Гамилә җиңги бөтен йөзе кара көйгән Бибигайшәне күреп, елап җибәрде: «И-и балакаем, инде сине дә мени? Аларга кеше ярый аламы соң. Ат караклары бит алар, йортларын җит йоткыры! Сиңа хәтле дә ике бәхетсез килеп китте инде бу йортка. Кем икәннәрен белгәч, артларына борылып карамыйча чыгып качтылар, бахыркайлар. Кит, балакаем, кач бу Алла каргаган йорттан. Урлаганнарын сендереп тормасаң, сиңа да көн яктысы күрсәтмәсләр, китә күр, кач, балакаем, кач!»

... Бибигайшә иртәдән кичкә кадәр аяк өстендә, көнозын бетмәс-төкәнмәс йорт эшләреннән иза чигә. Авыр хезмәттән аның әле нык житмәгән гәүдәсенә көч килә, яткач төне буе нәзек беләкләре сулкылдап сызлап чыга, аяклары ут яна.

Сиражиның тагын юкка чыгып торган чагы. Төн. Бибигайшәнең күзенә йокы керми, уйланып ята Бибигайшә: миңа кадәр дә Сиражи ике хатын алган булган... китә күр, кач, балакаем, сиңа да көн яктысы күрсәтмәсләр... Алла каргаган йорт... Китәргә? Кая?.. Гайшәнең инде буенда бар... Китмәсәң, ат карагы хатыны исемен күтәреп ничек дөньяда яшәргә, ничек кеше күзенә күренмәк кирәк... И әни җаным, нигә үзең белән алып кайтып китмәдең теге чакта, инде миңа нишләргә соң, әни җаным?..

Бибигайшә урыныннан торды, тәһарәт алды, җәймәсен намазлык итеп җәеп тезләнде дә, бар белгәннәрен укырга тотынды. Намазын башкарып бетергәч, елый-елый ялвара башлады: «И Аллам, минем хәлләрем сиңа мәгълүм, мин синең бер ятимең, мин бер ялгызым чит илләрдә, ят кешеләр кулында. Сиңа мәгълүмдер, минем ирем ат карагы булып чыкты, ул мине үзебезнең авылдан урлап алып китте, мин аның карак икәнен белмәдем бит, үзең шаһит, мин аның урлаган малларын

сеңдереп үз өстемә гөнаһ җыеп яши алмыйм, әмма минем аннан көмәнем бар, инде миңа нишләргә икән, Ходаем. Коткар мине мортазаныкылар-ның каһәреннән, инде бер дә чарасын тапмасаң да, ал минем газиз җанымны, ал, ал, Раббым, кара кан йотып, кеше алдында хур-рисвай булып яшәгәнче, җанымны ал, Ходаем...»

Бибигайшәнең теләкләре фәрештәнең амин дигән чагына туры кил-гәндер шул. Тәүлеккә якын тулгаклап, зур газаплар белән Бибигайшә малай китерде. Каны бик күп китте тудырганнан соң. «Хәле бик начар, сине чакыра шикелле, әйтәсе сүзе бардыр»,— дип, кендек әбисе ишек алдында арлы-бирле йөргән Сиражины чакырып кертте. Бибигайшә чыбылдык эчендә ята. Йөзендә кан әсәре калмаган, юка иреннәре күгәр-гән, күз төпләре кара көйгән.

«Бибигайшә, ни хәлләрең бар?» дип, тетрәнгән, каушап калган Сира-җи хатынының өстенә иелде. «Сиражетдин абзый... мин үләм инде... балабызны тәүфыйклы итеп үстерә күр... зинһар...» Бу — күзләрен ачар-лык та хәле калмаган Бибигайшәнең соңгы сүзләре иде. Кояшлы, җылы, матур җәйнең соңгы аенда әле унсигез яше дә тулмаган Бибигайшә гүр иясе булды.

Малайга Фәтхулла дип исем куштылар.

* * *

Тирә-юнь авылларда мәктәпләр күбесенчә манаралары вәйран ителгән мәчет биналарына урнашкан. Мирас авылының мәчете юк. Коточкыч янгында, бөтен авыл белән бергә, мәчет тә янып көл булган. Аның тарихы болайрак...

Мирасның Мөхетдин дигән бер агай урман аланындагы дисәтинәсе-нең бер почмагына шалкан чәчә торган булган. Урман туфрагында шалкан бик уңа икән. Көзен Мөхетдин комган-комган шалкан җыя. Бервакыт шулай шалкан җирен карарга дип барса — кемдер сайлап кына, эреләрен генә җыеп киткән, җир өстендә ат-арба эзләре калдырып. Узган атна якшәмбесендә Ташлык базарында шалкан сатып торучы Фәтхине күреп кайтканнар. Арба әрҗәсе тулы шалкан ди. Мөхетдин шалкан чәчкән урман Ташлык юлы өстендә. «Шул йөзе караның эше, бер дә бүтәннеке түгел, каккан казыгы да юк зимагурга каян килсен ди шалкан. Менә күрсәтим әле мин аңа шалканның ни икәнен». Төпчек малае Сәхәбетдинне ияртеп, якшәмбегә каршы төндә Мөхетдин агай шалкан сакларга китә. Ни ялына, ни ялвара хатыны Шәмсекәмәр: «Бармагыз, йөрмәгез, хараплар гына булырсыз, ул бит ата карак! Кеше башына җитү аңа бер тиен тормый, тыңлагыз зинһар сүзләремне!» Юк, кеше сүзе керә торган кеше түгел Мөхетдин. Дуамал, гайрәтле кеше, махы бирә торган-нардан да түгел.

Барып җитәләр болар шалкан җиренә, куак астына яшеренеп көтә башлыйлар. Төн аяз, айлы.

Төн урталары узгач аты-арбасы белән килеп керә берәү туп-туры шалкан җиренә, ашыкмыйча гына, сайлап кына йолкый башлый. Үзе чәчеп үстергәнмени!

Мөхетдин агай малайга урынында гына калырга ишарә ясый да, куак артыннан сикереп чыгып, каракны якасыннан элеп тә ала.

Фәтхи ычкынмакчы булып ыргылып карый. Юк. Бу куллардан ыч-кына торган түгел. Кул түгел — тимер келәшчәләр. Күпне күргән Фәтхи моны тиз чамалап ала.

— Җибәр, Мөхетдин абзый, яхшылык белән...

— Һе, җибәрми, җибәрде ди! Менә мин сине атың белән янәшә мичәүләп, чыбыркылап авылга алып кайтам әле! Халык алдында хур-рисвай итәм әле мин сине! Тапкансың әзергә бәзер!

— Җибәр, Мөхетдин абзый, нужәли шалкан бәясе дә тормый синең җаның?— Фәтхи ычкынмакчы булып тагын тартынып, йолкынып карый.

— Янама, янама! Теге нәрсәм дә селкенми синең янавыңнан!— Мөхетдин Фәтхине арбасына таба этләли-төрткәли өстери, муен тамырына берне кундырып та ала.

— Җибәрәсенме?!

— Ю-у-ук, Фәтхи, әле мин сине...

— Мә алайса!— Фәтхи кискен хәрәкәт белән Мөхетдиннең эченә пычак тыгып чыгара,— ал кирәгенне, инде икенче кулыңны озайтмассың...

— Аһ!— Мөхетдин сыгылып төшә, эчен тотып җирдә ауный, тәгәри башлый.

Поскан җиреннән әтисе белән Фәтхинең әвәрәләнүләрен коты чыгып күзәтеп торган малай тумырылып куак артыннан чыга:

— Әти, әти! Нишләтте ул сине?!

— Кач... улым... кач!..

— А-а! Әле син монда көчегең белән мени! Көчегеңне дә бетерәм!— Фәтхи урманга таба чапкан малай артыннан ташлана.— Тукта, көчек, бетерәм, барыбер бетерәм сине дә!

Сәхәбетдин агачлар арасыннан борыла-сарыла элдертә. Аның артыннан Фәтхи чаба. Агач ботаклары малайның битен, муенын тырный. «Сөртенеп егылмасам гына ярарие».— Уйлавы була — нәрсәгәдер абынып мәтәлеп барып төшүе була кычытканлык-куралык эченә. «Беттем!»— Малай куркуыннан күзләрен чытырдатып йома, тынсыз калып җиргә сеңә. Якыннан гына чаштыр-чоштыр агач ботакларына, куакларга бәрелә-сугыла Фәтхи чабып уза. Туктый, тыңлап тора: «Шушы тирәдә генә юкка чыкты, әдәм актыгы. Котыла алмассың! Сине исән калдырсам — миңа хана!»

Аяк астында чытыр-чатыр сынган ботак тавышлары ерагая. «Китте?» Юк, Сәхәбетдин яткан чытырманлык янына Фәтхи тагы әйләнеп килә: «Шушы тирәдә генә юкка чыкты, көчек, кыларга кирәк аны да, юкса...»

Әрле-бирле тугланып эзләп йөреп тә малайны эләктерә алмагач, Фәтхи өч катлы итеп сүгенеп, канлы пычагын юлында очраган кырмыска түмгәгенә батыра да, аты янына китә:

«Таярга кирәк! Ташлыкка! Ташлыктан шәһәргә дачный поездлар йөреп тора. Анда инде эзләсеннәр Фәтхине!»

... Ташлык ягына чаптырып киткән ат-арба тавышы ерагайгач, Сәхәбетдин үзен коткарып калган куралыктан чыгып әтисе янына килә. «Әти! Әти!..»— Әтисе дәшми дә, селкенми дә. Ике кулы белән эчен кысып тоткан көе бөгәрләнеп ята. Күзләрен чытырдатып йомган. Малай калтыранган куллары белән инде суынып беткән атасының битен, маңгаен капшап карый да, коты алынып авылга таба чаба...

Юл буе елый-елый йөгереп кайтып хәлдән тайган Сәхәбетдин урман очында яшәгән олы абыйсы Низаметдинга кереп егыла: «Әтине... Фәтхи... Ташлыкка таба...»

Таң атып килгәндә Мөхетдиннең канлы гәүдәсен өенә алып кайтып салалар.

Өйләнеп башка чыгып яшәгән Низаметдин, инде буйга җиткән егет булып килгән Бәдретдин — аталары шикелле үк гайрәтле ирләр, ат атланып Ташлыкка чабалар — турыга, болын буйлап, җәяүле сукмак буйлап...

* * *

Фәтхинең авылда атасы Сиражи карт йортында «эз суытып» яткан вакыты иде. Юк, ул ат карагы түгел, ат урлау — пычрак эш. Шәкүр карак шайкасында «кызыл мал» белән «эш» итә Фәтхи. Бер Мәскәү баеның кибетен «алганда» аларның шайкасы «янды». Полиция фургонына утыртканда, ике беләгеннән кысып тоткан полицейскийларны чөеп ташлап, Фәтхи качып котыла алды, бүтәннәр каптылар. Шәкүр каракның Мәскәү полициясендә дә әшнәләре юк түгел. Әшне

җайлаганчы, шау-шу тынганчы, Шәкүр абзый Фәтхигә күздән югалып торырга әмер биргән. Менә икенче ай инде Фәтхи Мираста, «атпускыда» ята. Авылдашлары өчен ул — Казанның дары заводында рабучи. Бик хәтәр эштә, шуңа күрә атпускысы да мулдан икән.

Узган ел да кайтып, Мирас кешеләренең һушын китәреп йөргән иде Фәтхи. Өстендә шакмаклы пинжәк, пүттәшкәле чалбар, башында чуклы кызыл фәс, аягында ялтырап торган штиблетлар; ефәк күлмәге өстеннән муенына чуар чүпрәктән муенчак бәйләгән. (Ул җәйдә Фәтхи Мәкәрҗә ярминкәсендә бер төрек сәүдәгәрен чишендергән иде.) Авыл халкын шаккатырганы — коерыклы кызыл кәләпүш белән пүттәшкәле чалбар булды. Авыл җирендә күтендә ыштаны тормаган малайларның гына ыштаннарын пүттәшкәгә асалар.

Эшсез яту ялыктырды Фәтхине. Ул түземсезлек белән хәбәр көтә. Ташлык базарына «Чулак» килеп чыгарга тиеш. Фәтхи узган якшәмбедә дә аны базар таралганчы көтте, күз буяр өчен, арба әрҗәсеннән шалкан сатып торган булды. «Чулак» килмәде.

Теге якшәмбедә, Ташлыкка барышлый юл өстендә очраган шалкан түтәленнән арбасына ун-унбиш төп шалкан йолкып салган иде Фәтхи. Бу юлы да шулай эшләмәкче булып, узышлый шалкан җиренә кергән иде, менә ничек булып чыкты... Их, Мөхетдин абзый, Мөхетдин абзый!.. Җибәрсәң ни булган инде? Һич югында, сукмасаң да исән калган булыр идең әле. Дуамаллыгың җитте башыңа...

Ташлыкка җитәрәк яктыра башлады. Фәтхи атын алып юлдан болынга борды. Юлсыз-нисез чыклы курпы өстеннән бер кавым баргач, атын беренче очраган печән кибәненә кушып, арбасыннан төште, гәүдәсен, оеган аякларын язгалап киерелә-сузылды, үз алдына мыскыллы елмаеп, уйлап куйды: «Кемнең башына килер икән Фәтхине Ташлык болынынннан эзләргә?»

Чуен юл станцасына кадәр ике чакрымлап җир булыр. Беренче дачный поезд китәргә әле өч сәгатьләп вакыт бар. Бераз черем итеп алырга да була. Фәтхи кибән астына оя сыман нәрсә ясап кереп ятуга, гырлап йокыга китте. Каракларның нервлары нык була торгандыр шул...

Төшләнә-төшләнә йоклый Фәтхи. Ул үзенең шәһәрдәге уйнашчы марҗасы өстендә азаплана, имеш. Инде булдырам гына дигәндә аны марҗасы өстеннән өстерәп төшерәләр, имеш...

... Шашынган, ярсыган Низаметдин Фәтхине аягыннан өстерәп кибән астыннан суырып чыгарды да, сабан туенда батыр калып алган сарык тәкәсе шикелле, баш очына күтәреп, җиргә орды...

Төш җитеп килгәндә Низаметдин белән Бәдретдин яртылаш үлек Фәтхине авылның каравыл өенә алып кайтып ташладылар. Измәсен изгәннәр, кеше дип әйтер җирен калдырмаганнар. Фәтхи ярым ачык күзләрен гарешкә терәгән. Эчендә җаны бармы-юкмы, белерлек түгел.

Халык җыелды. Мөхетдиннең энеләре, кияүләре тагын өстиләр Фәтхигә. Дисәтник Гәптери генә араларга тырышты: «Җәмәгать, җәмәгать, ипләбрәк кыланыгыз, самасут килеп чыкмасын, ахыры хәерле булмас!»

Кич булгач халык таралды. Фәтхинең җаны бар икән әле — сирәкмирәк ыңгырашкалый.

Чыкмаган җаны гына калган Фәтхине саклауны, дисәтник Гәптери, бөтен гомере каравыл өендә үтеп, каравыл өендә картайган Бөкере Заһирга тапшырды:

— Иртәгә Ташлыктан урәтник килгәнче күз-колак булып тор, Заһир абзый.

— Ай-һай, Габдеррәүф, айнып китеп, алай-болай... төннә белән дип әйтүем... алай-болай... аяк-кулларын бәйләп салмыйсыңмы, диюем.

— Шайтаныма китсен мени, күрмисең мәллә хәлен, иртәгә кадәр аягын сузмаса ярый әле. Ярар мин киттем.

Төн җитә. Каравыл өендә — Заһир карт та үлеп ятучы Фәтхи.

Заһир тышка чыгып йомышын йомышлап керә. «Ай-һай, бик ямьсез жил күтәрелгән, хәерлегә генә була күрсен, ут-күздән Алла сакласын!» Заһир карт идәндә һаман шул кыяфәтсез рәвештә көйшәнеп яткан Фәтхигә күз ташлап ала. Тәрәзә төбендә пыскып утырган шахта фонарен кыса төшә, сәләмә чикмәненә төренеп, Фәтхидән ераграк почмакка килеп чүмәшә дә үзенең күнелсез уйларына чума...

Шулай оеп күпме вакыт утыргандыр, кемнеңдер кармалавын тоеп, сискәнеп айнып китсә, ни күрсен — Фәтхи! Заһир карт чүмәшкән почмакка шуышып килгән дә, аның кәләпүшенә үрелеп азаплана.

— А-а-а! Үтермә мине Фәтхулла!— дип коты алынган карт бөрешеп почмакка инә.

— Син... кәкере шайтан... мин барысын да ишетеп яттым... аяккулларын бәйлә, имеш... бир кәләпүшеңне салып... бөкере тәре... йә... кемгә әйтәләр!..

Фәтхи аркасын стенага сөяп утырып, Заһир картның кәләпүшенә сия дә, кәләпүш тулы канлы сидеген эчеп, тагын идәнгә сузыла: «ух... ых...»

Күпмедер вакыт шулай ухылдап аунап яткач Фәтхи тернәкләнә, чайкала-чайкала торып баса, куркуыннан үлә башлаган картка, тәрәзә төбендә пыскып янган фонарьга карап уйланып тора да, ниндидер катгый карарга килә. «Мин әйләнеп кергәнче урыныңнан кузгаласы булма, кәкре шайтан!»— дип, тәрәзә төбендәге фонарьны алып тышка атлый.

...Низаметдин курасына салынган ут жил уңаена бөтен авылны диярлек сыпырып чыга. Бер-берсенә тоташ киртә-коймалы, урыс капкалы, житү-төзек йортлардан ике-өч сәгать эчендә ыржаеп утырган моржалар гына кала.

Ил белән килгән бәла жиңелрәк була торгандыр. Йорт-жирләре, каралты-куралары янып көлгә әйләнгән агайлар авыл уртасына, мәчет янганны тамаша кылырга жыелган. Авылның урамнарын, кешеләрнең иманнарын бергә төйнәп торган мәчет ут эчендә. Тирәли үскән карт тупыллар, өянкеләр, үзләренең гомерләре бәрабәренә ут өермәсен тоткарлап торып, үз вазифаларын ахыр чиккә кадәр үтәп шәһит булгач кына мәчеткә ут каба — бер юлы манарасыннан, түбәсеннән яна башлый.

— Сүрәнерәк яна түгелме соң, жәмәгать!— дигән була әфьюнчы Һидият, мәчеткә ураза, корбан бәйрәмнәрендә генә, анда да тәһарәтсез йөргән кеше.

Аннан күрмәкче Зәйни солдат теленә салына:

— Ходай тәгаләнең пожарный фирештәләре юк микәнни, менә дигән Алла курасы вәйран була ласа!

— Жәмәгать, көфер сүзләр сөйләп гөнаһланмагыз бу дәһшәтле вә фажигале сәгатьләрдә!

Галиулла хәзрәтне жәмәгать шәйләми дә тора икән: бер читтәрәк кама бүрек, яшел жөббә кигән мулла абзый, вак ташлар жыеп, шуларга ниндидер әфсен укып төкергәли дә, янган мәчет өстенә ыргыта: «Йә, Алла, кодрәтең киңдер — сүңдер! Кодрәтең киңдер — сүңдер!..»

«Хәзрәт, синең әфсеннәреңнән ут тагы да шәбәеп китте шикелле»,— дигән була һаман да шул әфьюнчы Һидият.

Авыл жирендә иң зур, биек бина — мәчет. Менә ул тоташ ут эчендә. Чылтырап тәрәзә пыялалары коела, нәрсәләрдер шартлап сына, ишелеп төшә: берөзлексез гүләү, сызгыру, чинау авазлары. Моңарчы мәчетләре янып күрсәтмәгән Мирас кешеләренә бу — зур тәэсирле тамаша.

Менә мәчетнең манарасы гөрселдәп жиргә ава. Тамаша кылып торган халыкның яше-карты, кәефе, тәкъвә-диндары берьюлы, жан ачысы белән ыңгырашып куя. Күбесе, күз яшьләрен йотып, тавышсыз гына елый. Гүя алар бу һәлакәт-тәкъдирнең шомлы ишарәсе икәнен күңелләре белән сизә: Мирас инде беркайчан да мантымас, инде беркайчан да янган мәчет урынына яңа мәчет калкып чыкмас. Тиздән ил өстенә революция дигән афәт инеп, илдән иман, бәрәкәт качар, авыл агайларын колхозга куып кертеп, аларны жирдә иген игү ләззәтеннән мәхрүм итәрләр, йортларында ашар ипиләре калмас.

«Җәмәгать! Күрәсе казаларыбыз булгандыр инде, бер Алланың үзенә тапшырдык, Аллага сыгынийк — күңелләребезгә сабырлык бирсен! Ходайның рәхмәте киңдер, безне үзенең шәфкатеннән калдырмас, иншалла!»

Галиуллa хәзрәтнең ошбу вәгазь-нәсихәтен тыңлап бераз тынычланган халык үзләренең вәйран булган йорт-кураларына тарала гына башлаган иде, җәмәгать алдында Бөкре Заһир пәйда булды. Ул халыкка каравыл өендәниләр булганын, Фәтхинең утлы фонарь белән төнгә чыгып киткәнен бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Халык тагы ярсып китеп, котырынып, сүгенеп Сираҗи йортына ташланды:

— Ерак китмәгәндер, тотып утка салырга кирәк, мәлгуньне!

— Утка атарга, утка! Эзләп табарга да утка атарга нәгъләтне!

Сираҗиның йорты бердәнбер янмый калган Аргы як урамда.

Фәтхине эзләп, Сираҗиның йортын астын-өскә әйләндерделәр. Чормасын-идән астын, келәтен-мунчасын айкап чыктылар, абзар-курасын актардылар, ындырдагы арыш кибәнен сүтеп ташладылар — юк, юк Фәтхи!

Кайсыныңдыр башына килде: төтен салырга кирәк Сираҗи йортына, төтен! Качып яткан җиреннән төтәп чыгарырга кирәк, кабахәтне!

Малайлар йөгереп алып килгән кисәүләрдән Низаметдин, тагын берничә агай, Сираҗиның абзар-курасына, келәт-мунчасына ут үрләтеп җибәрделәр...

* * *

Җәй башы. Тегүче Солтан әкә Өфе белән Казан арасында йөрүче пароходта Башкорт ягыннан өяздән кайтып килә. Быел эш күп булды. Кыш буе авылдан-авылга йөреп, башкортның баена тышлы тун, бишмәт, камзул, ярлысына каеры тун тегеп, ару гына акча сугып алды Солтан. Ярата ул Башкорт ягында йөрергә! Башкорт — җырчы, кунакчыл, юмарт халык. Тегүче Солтанның ашаганы ит тә май, эчкәне кымыз да бал булды.

Килүен дә пароходта килгән иде Солтан. Аста, өченче класста. Өченче класс базы капчыклы, биштәрле авыл агайлары, мужиклары белән дыңгычланган. Тынчу, бөркү. Ул әледән-әле һава суларга пароход коерыгына чыгып йөрде. Өстә — беренче класста затлы, күркәм кешеләр килә. Аларның кайберләре чыбык урындыкларга утырып Агыйделгә, Агыйдел өстендә уйнашып очкан акчарлакларга карап хозурланып бара, бәгъзеләре палубада ялкау гына арлы-бирле йөри. Бер-берсенә тиң көяз парлар, купшы киенгән сылу гәүдәле кызлар Солтанга бөтән, икенче дөнья кешеләре булып тоела. Бар икән рәхәт дөнья, бар икән рәхәттә яшәүче бәндәләр!

Солтанның шул өске катка менеп, бер генә мәртәбә булса да шул тәтәй кешеләр йөргән палубаны буеннан-буена әйләнеп чыгасы килә, дөньяга, аста мәж килгән кешеләргә өстән карап торасы килә аның.

Караңгы төшеп, инде өске палубада йөрүчеләр азайгач, Аллага тапшырып, тегүче агай үзенең хыялын гамәлгә ашырырга булды. Өске катка алып менә торган баскычның беренче басмасына аягын куюы булды, артында: «Э, тубетейка, куда лезешь, не положено туда!» — дип җикеренгән тавыш ишетте. Идән юып йөрүче матрос кычкыра икән. Бик гарьләнде шул чакта Солтан, «Түбәтәй» генә булса да, ул идән себерүче түгел, шөкер, тегү тегүче ул, аның «Зингер» дигән германски аяк машинасы бар; тегүче Солтанны бөтен тирә-юнь белә Ташлык ягында!..

Тегүче, Өфе кибетләрендә йөреп, хатыны Нурлыбанатка, бала-чагаларына бүләкләр, күчтәнәчләр, үзенә гомере буена кияргә кызыгып йөргән нәрсәләрен — куныччы сыдырыла торган йомшак читек белән фетр эшләпә сатып алды.

Кайту ягына Солтан билетны пароходның өске катына — икенче класска алды. Ничу анда өченче класста сөрсеп кайтырга, бигрәк тә кесә

тулы акча барында! Билетны беренче класска алырга да исәбе юк түгел иде әле, әмма касса тишегендә маржа: «Нету!» дип кырт кисте, ә үзе Солтаннан соң беренче класска әллә ничә билет сатты.

Солтан — ир уртасы кеше. Буйга-сынга да, тәскә-биткә дә Ходай ким-хур итмәгән. Аның өстендә үзе тегеп кигән әр-яңа җилән, башында фетр эшләпә, аякларында куныччлары гармунландырып сыдырылган читекләр. Уң аягындагысы баскан саен, мунча сыерчыгы шикелле, чыгырт-чыгырт итеп куя (читекчеләр аны юри шулай итеп тегәләр икән).

Бу юлы өскә менсә дә, аска төшсә дә Солтанга җикергән, чабуыннан тоткан кеше булмады. Өске палубаларда, чыннан да, икенче дөнья икән: саф һава, чисталык, пөхтәлек. Ашыкмый, кабаланмый, вәкарь белән генә, чиста киенгән кешеләр йөреп тора. Аскы палубадагы кешеләр бераз сәер күренәләр — гүя барсы да карсаклар, аларның түбәләре белән җилкәләрен генә күреп була икән бит.

Салмак кына, саллы гына, үз дәрәҗәсен белеп кенә йөри бирә Солтан өске палубаларда — вчутәки өстендә яңа җилән, башында фетр эшләпә, аякларында чыгырдый торган читекләр! Чуар йөрәкле, һавалы, үзенә муафыйк баскычтан бер генә басмага булса да югарырак торуны дәгъва итә торган кеше инде Мирасның тегүче Солтаны!..

Нинди генә кешеләр бармый пароходның өске катында! Әнә, кәкре аяклы, гел карадан киенгән әрмән сәүдәгәре. Чабата калыбы тикле иләмсез зур борын, ике якка тырпайган мыеклары аның кыяфәтенә кабырга капкан эт рәвеше биргән. Әнә, көчкә селкенеп, як-ягына аватүнә, ак мунча миче шикелле тәбәнәк-юан бер хатын муенчак бавыннан күсе кадәр генә кәрлә көчекне җитәкләп килә. Көчегенең сыйраклары җан шикелле нәзекләр, үзе коточкыч ябык. Хуҗабикәсе аны ач тота микән, әллә бар булганы шул микән? Үзенә күрә түгел тагы: унга-сулга чәң-чәң килеп өргән була. Тьфү! Солтаннарның ата мәчесе бу хәшәрәтне бер утыруда койрыгын да калдырмыйча ашап бетерер иде, җирәнмәсә...

Солтан янынан култыклашып бер-беренә бик тә пар килгән ир белән хатын узып бара. Хатынының башында дөге саламыннан үргән, кызыл чәчәк кадалган киң кырыйлы эшләпә, гәүдәсе ак челтәр күбегенә баткан. Ирнең өстендә юка йон кәчтүн-чалбар, шулкадәр шома тегелгән — таракан таеп егылыр! Ә җөйләре бөтенләй күренми дә, сизелми дә диярлек. Солтан да шулай шома тегә алыр иде микән? Нигә текмәсен! Аның «Зингер»ендәме? Һи, аннан да шәбрәк итеп тегәр Солтан, кисеп бирүчесе генә булсын!

Ике кулын аркасына куеп, ашыкмыйча гына палубаның урта бер җиреннән ярып йөри Солтан. Ул инде палуба халкы өчен үз кешегә әйләнеп бара. Бер культурный гына маржа, кояшка карап алып: «Как вы думаете, сколько сейчас время?» — дип, Солтанга сүз кушты. «А чурт ява знает», — дип кенә җибәрде Солтан, юлын дәвам иткән көйгә.

Йөри торгач безнең тегүче буфетка юлыкты: «Кереп чыгарга кирәк, тимбүле кесә тулы акча». Ишектә аңа бер-беренә тагылышкан ике бөдрә чәчле хатын каршы булды. Туп-туры Солтанның күзенә карап киләләр. Сул яктагысы хәтта сизелер-сизелмәс кенә күз кысып, орынып ук узды. Тәмам азганнар, аналарын эт еккыры кәнтәйләр...

Буфетта кеше күп түгел. Солтан аулаграк урын сайлап, почмакка кереп утырды. Янына килеп баскан юан ботлы официант маржага аяк астына чиртеп кенә заказ биргәч, тирә-ягына күз салды. Каршы өстәл артында Солтанга аркасы белән утырган ир кеше папирос тарта. Аның каршындагы чибәр хатын, ризыгын иннек сылаган иреннәренә тидермәскә тырышып кына, ашаган төсле кыланып утыра. Әйтерсең, аның чәнечке очында ит кисәге түгел, ә шартлаткыч матдә, анасын эт еккыры!

Маржа Солтан алдына бер шкалик аракы белән закуска китереп куйды. Клиенты: «Я свинҗә ни кушайт!» — дип нәзберекләнгәч, официант хатын колбаса телемнәрен тавык ботына алыштырды.

Эчми эчкән тегүче абзый тиз кызды — җиләнен чишеп җибәрде, эшләпәсен салып ташлап, түбәтәйдән генә калды. «Тагын алыргамы-юкмы? Алырга! — тимбүлә кесә тулы акча! Көн дә парахут буфетында типтерергә туры килми...»

«Эй, марҗа! — дип кычкырды Солтан, учын-учка сугып, — ишшо один малинки бутилкә аракы!»

Күрше өстәл артындагы хатын елмаеп куйды, аркасы белән утырган ир дә борылып, тузына башлаган агай ягына карап алды. Аларның күзләре бер генә секундка очраштылар: Фәтхи!!!

Ир кеше, берни булмагандай, каршында утырган хатын белән иха-хай-михахай сөйләшүен дәвам итте, бокалларына тагын аракы салып куйды.

Фәтхи!.. Мәлҗери башлаган Солтан айнып китте. Ярый әле танымады. Моннан тизрәк ычкынуың хәерле. Юан ботлы марҗаның «малинки бутилкә» аракы китергәнен дә көтеп тормыйча, Солтан буфеттан чыгып ычкынды — бәладән баш-аяк!

Мирас халкы Фәтхине, кайда да булса дөмектергәннәрдер, дип уйлаган иде. Шайтаным да булмаган Фәтхигә, пароходның беренче классында марҗалар белән аракы эчеп, типтереп килә Фәтхи!

Аның авылны көлгә очырып качканына инде өченче ел китте. Фәтхи турында авыл халкы ләм-мим бер хәбәр дә ишетмәде. Атасы Сиражи картны да кысып карадылар. Ташлыктан килгән тикшерүче түрәләр, әмма «белмим»нән бүтән сүз ишетмәделәр.

Фәтхулланың анасы Бибигайшәдән соң, Сиражига тагын ике-өч хатын килеп китте. Соңгы елларда карт ялгызы гына яшәде. Бибигайшәсен бик еш искә ала торган булды: «Тарантас тае булган икән аның Бибигайшәсе, кадерен генә белмәгән Сиражи...»

Көтелмәгән очрашудан шүрләп калган, кәефе сүрелгән Солтан аска, үзләренең каютасына төшеп, өйрәнчеккә алып чыккан үсмер малай Галимҗанны бераз һава сулап йөрергә чыгарып җибәрде дә, нарга сузылып ятып күзләрен йомды... Фәтхи! Бер тәүлек эчендә кеше үтергән, бөтен бер авылны көлгә әйләндергән кеше иректә! Нишләргә икән? Әллә капитанга әйтеп, тоттырыргамы: «Фәтхи бандит — Мухутдинны ризал, диривне бальшой пожар делал». Ә нигә тыкшынырга? Үлгәнне терелтеп, янганны яңартып булмый бит инде. Йөрсен, йөри бирсен, берәр җирдә берәрсе бәреп үтергәнче. Ярый әле мине танымады, таныса...»

Менә шундый уйлар уйлап, Солтан йокыга куерып барганда каютага... сәрхүш Фәтхи килеп керде.

— Син нәрсә, авылдаш, авырып киттеңме әллә? — Фәтхи әле исенә-акылына килеп өлгермәгән Солтанны якасыннан алып күтәрде. — Заказ биргән аракыңны да эчмичә чыгып шылдың. Алай килешми эшләпә киеп йөргән кешегә, килешми-и-и! — Фәтхинең йөзендә мыскыллы елмаю, ә күзләре! — атныкы шикелле акай, исерек күзләрендә җан өшетерлек салкынлык, усаллык.

— Ә-ә, Фәтхи... Фәтхулла! — Солтан алай куркаклардан түгел, әмма исерек Фәтхинең тиктомалга шулай катышлы кыланышы аны каушатып җибәрде, — менә очрашу диген, ә! Бу елларда авылга да кайтканың булмады шикелле?..

— Син теленә салынма, Солтан, әйт — син монда үзең генәме? — Фәтхи каютаны айкап карап алды, ишек ягына күз ташлады.

— Үзем генә, ә юк, үзем генә түгел икән, өйрәнчек малаем Галимҗан белән, күршегез Әхмәтханның олы малае, әнә, үзе дә, гомере озын булгыры.

Ишектән килеп кергән Галимҗан, Фәтхине күргәч телсез калып, артка таба чигенеп куйды.

— Ну, күрше, егет булып буламы? — Фәтхи Галимҗанны ике кулы белән якасыннан алып үзенә тартып китерде. Малайның куркуыннан агарынган йөзенә аракы пары белән сулап, озак тәрәләп карап торды —

Что-то мина соңгы елларда менә синең шикелле маңкач егетләр мешать итәләр әле...

Аннан соң — шарт! — Галимжанның маңгаена чиртте дә, үзеннән читкә этеп җибәрде. Малайның ике күзеннән яшь атылып чыкты, күзгә күренеп маңгае күбеп чыкты.

— Ярар инде, яшә, Солтан абзый, но — май кап! Син малай — тоже! Сез мине очратмадыгыз да, күрмәдегез дә, а то...— Фәтхи ишеккә таба атлады.— Да, тегә чакта мине, идиотлар, әти йортыннан эзләп йөргәннәр икән. Нинди дуракка санаганнардыр инде. Ә мин, беләсегез килсә, Галиулла хәзрәтнең ак мунчасында өч атна тавык шулпасы чөмереп яттым, әтәч булып кычкыра башлаганчы, ха-ха-ха! Галиулла хәзрәтнең йортыжире Аргы як урамда әле дә исән-сау торадыр, шәт. Мин бит тоже үзе изгелек эшләгән кешегә начарлык эшләмим. Ә менә Низаметдин белән исәп-хисапны өзәсе бар әле...

Ишекне тибеп ачып, Фәтхи каютадан чыгып китте.

Казан пристанендә Солтан белән Галимжан Фәтхинең лихачка утырып чапканын күргәч кенә пароходтан төшәргә җөрьәт иттеләр.

Бу вакыйгалардан соң бер ел үткәч, Мирас кешеләре Фәтхинең дөмеккәнен ишеттеләр,— уйнаш итә торган марҗасының яңа дуслары аны трамвай астына салганнар.

Ат карагы Сиражетдин малае Фәтхуллага Мөхетдин малае Низаметдин белән исәп-хисабын теге дөньяда гына өзәргә калды инде...

* * *

Яңа уку елын Габдрахман Исрафил исемле яңа укытучы егет белән башлап җибәрде. Исрафил — җәдит Эстәрлебаш мәдрәсәсе шәкердәме. Җиңел сөякле, житеш кеше булып чыкты яңа мөгаллим. Тапшлыкка, атна аралаш шәһәргә барып, әллә ни кадәр уку-язу әсбаплары, кулланмалар, күрсәтмәләр җыеп алып кайтты. Укучы балаларның исен-һушын китергәне «шар харита» — глобус булды.

Исрафил Чистайда туып үскән. Килеш-кыяфәте күркәм, чибәр егет. Өс-башы, киенүе дә шәһәрчә — кәчтүн-чалбардан, галстук тагып, чәч җиткереп, кәләпүшсез йөри. Урысчасы да чәчрәп тора.

Егетләрнең яше бер чама. Холыклары белән төрле булсалар да, тиз арада уртак тел таптылар, алар арасында дустанә мөнәсәбәт урнашты.

Укытучы Габдрахманның урысчасы йомшаграк. Исрафил аңа урыс теленнән дәрес бирергә тәкъдим иткәч, ул шатланып риза булды.

Дәресләр бетеп, укучылар өйләренә таралышкач, аларның урынына Габдрахман мөгаллим утырып, Исрафилдан урысча дәрес ала башлады. Беренче мәртәбә чамасын тартып карау өчен, дүрт-биш минут урысча сөйләштереп азаплап, Габдрахманның урысчасы «нам татарам вчырауна, одна талон, два каша» дәрәҗәсендә икәнен ачыклагач, учитель Исрафил кистереп әйтте: «Будем заниматься систематически два раза в неделю в течение всего учебного года!»

Кичен мәктәптән кайтырга алар һәр көн диярлек бергә чыгалар.

Бүген көн аеруча әйбәт — кояшлы, җылы, җилсез. Алар авылдан чыгып ук китеп, инде болын буйлап баралар икән. Исрафил илһамланып Хафиз газәлләрен, гомер буе хәмер вә хатын-кызга мәдхия җырлаган Гомәр Хәйям робагыйларын яттан укый. Исрафил фикеренчә, мәхәббәт җырчысы буларак, татар шагыйрьләреннән Габделҗаббар Кандалыйга җиткәне юк:

«И, беләмсең, Сәхипҗамал,
Гыйшыклык хәл икән яман.
Сагынып бергә һәр заман
Торамын бимәҗәл, алла.
Билең нечкә, буең һәм төз.

Тәнең сай гүяки акбүз.
Әгәр дисәң дә син бер сүз,
Укыр идем йөз аяти...»

— Бу хисләр ташкынын Кандалый үзенең мәгъшукасы Сәхипҗамалга күндергән,— ди Исрафил. Ә менә безнең Тукаебыз андый шәүкъ тойгыларын үзенең Зәйтүнәсенә шәрран яра әйтеп бирә алмаган. Холкы, табигате икенче. Әчтән яна торган зат, артык тыйнак, оялчан. Аның бу халәтен русча бик төгәл әйтеп була: застенчивость, доходящая до неприличия! Белмим, моңа, бәлки, шагыйрь үзе генә белгән сәбәпләр дә булгандыр. Ә Зәйтүнә безнең Чистай кызы булган икән...

Габдрахман юлдашын сүзен бүлдермичә генә тыңлап бара. Юк, ишеткәне юк аның Хафизлар, Хәйямнар, Кандалыйлар турында. Тукайның Зәйтүнә исемле сөйгән кызы булганын да беренче тапкыр ишетә Габдрахман. Аз шул Габдрахманның мәгълүматы, аз. Аның шулай икәне менә бу сүзгә оста, чибәр егет янәшәсендә тагы да җетерәк тоела...

Тагын бераз баргач, егетләр кайтыр якка борылдылар.

* * *

Мирас авылына нигезне Му дигән авылдан күченеп утырган Мирас исемле кеше салган. Сайлый да белгән инде урынны Мирас бабай! Авыл — урман астында, өч елга үзәнендә. Яшел печәнгә кадалган өч аерчалы зәңгәр сәнәк шикелле, Сорна, Янык, Кесмәс инешләре урманнан агып чыгалар да, Мирас утырган уйсулыкта бергә кушылып, көнгә карап агып китәләр. Сорна белән Яныкның мөстәкыйль гомерләре биш-алты чакрым гына. Инешләрнең өлкәне — Кесмәс. Ул Ташлы Кичү, Солы, Мирас тегермәннәрен әйләндереп аргач кына сеңлесе Сорна, энесе Янык белән күрешә. Аннан соң алар күмәкләшеп, юлларында очраган Сикертән, Казаклар, Му, әллә ничә Масра авылларында он тартып, тагы да ишәеп, егерләнеп Касан-Суга кушылалар да, Бөек Иделгә барып җитеп, юкка чыгалар...

Мирас авылы иңкүлектә утыра. Аңа килүчеләр һәр уңайдан үр төшәргә мәҗбүр — авылга атлы-арбалылар күңелле шалтырап-чабып барып керәләр. Кунакка килгәннәр исә хуҗаларына:

Сезгә килүләре бик күңелле,
Әмма китүләре бик яман...—

дип тә җырлап бирәләр.

Читтән килгән яшь киленнәр дә авылга бик тиз ияләшә. Менә шундый хикмәтле, күркәм авыл Мирас авылы.

Әмма Мирасның үзенә генә хас тагы ике мөһере-тамгасы бар әле. Аның берсе — авылга чекерәеп карап торган, бөтен авыл кешеләрен үзенә мөкиббән иткән Галия тавы, икенчесе — авыл кызларының, яшь киленнәрнең күңелен җилкетә торган, шул тау итәгеннән агып чыккан салкын сулы Галия чишмәсе. Тауга да, чишмәгә дә кайчандыр шушы мәшһүр тау астында гомер итеп үлгән бер бик мөхтәрәм Галия карчыкның исеме ябышып калган.

Галия тавы Мирас кешеләренең күңеленә бала чактан ук кереп урнаша. Кыш көне бала-чага Галия тавыннан чана, чаңгы шуа. Язларын, тауның көнгә каралган битеннән кар киткәч тә, күлмәкчән, яланаяк малайлар анда шайтан куа башлыйлар — мәтәлчек аталар, узыштан йөгерешәләр, көрәшкән булып әверенәләр.

Җәй башында тау итәгендә какы, кузгалак күренә башлый, урыны-урыны белән каен җиләге, җир җиләге пешә, юа үсә.

Иртән торып тышка чыгуга, теләсә-теләмәсә дә, Мирас кешесенең күзе Галия тавына төшә. Аны һәр даим үз урынында, елның һәр дүрт

фасылына муафыйк киемдә күреп, авыл халкының күңеле тынычлана, кәефе хушлана.

Авылдан чыгып китеп зимагурлыкта йөргәннәр дә онытa алмыйлар Галия тавын — чит җирләрдә каңгырап йөргән бәхетсезләрнең төшенә кереп, ул аларны ямансулата, күңелләрен нечкәртә. Якын-тирәдәге шәһәрләргә китеп урнашкан мираслар да аны сагынып кайталар. Ләкин Галия тавы инде, ничектер чулыгып, тәбәнәгерәеп калган шикелле күренә.

Кичкырын, көтү кайтыр алдыннан, авыл кызлары көязләнеп, җилкәләренә бизәкле көянтә-чиләкләрен асып, авылның бөтен очыннан су алырга Галия чишмәсенә килә. Бүтән чишмәләрнең дә суы кипмәгән югыйсә, әмма бу элек-электән килгән йола инде. Бу мәлдә авыл урамнарына кызлар хуҗа. Кайсылары бара, кайсылары, вак-вак кына атлап, тулы чиләкләрен җай гына чалпайтып килә. Өсләрендә ал, кызыл, яшел, зәңгәр тәстәге куштанлы күлмәк, шлапырлы чиккән алъяпкыч, башларында колак артына гына бәйләгән ак бәс яулык, җилкәләрендә бизәкле көянтә-чиләк — гел болын күбәләкләре инде! Көтү каршыларга капка төбендәге бүрәнәгә чыгып утырган картларның да күңелләре җилкенеп ала:

— Бусысы кем чәчәге булды тагы?

— Һай, әттәгенәсе!..

Кызларның Галия чишмәсенә йөрүенең тагы бер сере — аның аулак урында булуы. Чишмә янына егетләр җыела. Чишмә яны кыз күзләү, сөешкәннәрнең очрашып бер-берсенә иң кадерле бер-ике сүз әйтеп калу урыны.

Менә бүген дә чишмә тамагында, сукмакның ике ягына егетләр тезелешеп утырган. Кызларга бу төшне узу — сират күпере кичү белән бер. Алла сакласын, капылт аякларыңның җегәре китеп, тигез урында егылуың бар. Адәм рисвае булырсың!..

Кайтыр юлга кызлар ялгыз чыкмый. Иптәш булганда сулы чиләкләр белән дә сират күперен кичү җиңелрәк. Аннан бигрәк, форсат табып, егетләр кунаклаган якка да керфек сирпеп алырга була. Анда синең күптән бәгыреңә кереп урнашкан, дөньяда иң чибәр, иң күркәм, төнлә төшләреңә кереп газаплый торган егетең утыра. Юк, юк, ул үзе әле бернәрсә дә сизенми... Сизенсә?! Аллам сакласын! Оятыңнан җир тишегенә керерсең!..

Егетләр арасында хәбәр йөри: имеш, йортта су салырга урын калмагач, кайбер кызлар, алып кайткан суларын капка баганасы төбенә түгеп, тагы чишмәгә йөгерәләр икән.

— Сәрби, капка баганагыз чәчәк атмадымы әле? — дигән була Карсак Садрый, күңеленең кәгъбәсе булган Сәрбиҗамалга.

— Атты гына түгел, инде очында җимешләре өлгерде,— бар, барып җый, буең җитсә!...

— Һай, маладис, Сәрбиҗамал! Икенче авызын ачарлык итмәдең!

— Үтерде, бетерде, инде дөньяда йөрер җирен калдырмады Садрыйның!

Уен-көлке арасында яшьләр болын яктан кайтып килгән кешеләрне абайламый да калганнар. Чишмә тирәсендә үскән тал-тирәк артыннан көтмәгәндә пәйда булган Исрафил белән Габдрахманны күргәч, егетләр урыннарыннан сикерешеп тордылар.

— Әссәламегаләйкем, егетләр-кызлар! Хозурыгыз күркәм булсын!

— Вәгаләйкемәссәлам, сезнең белән бергә-бергә булсын, мөгаллим абзыйлар, хуш килдегез, әйдә түрдән узыгыз! — егетләр, тәгъзыйм-лек кылып, үзләре утырган җирдән урын күрсәттеләр.

— Без мосафирларны сыйласагыз икән, ә, туташлар? Йә, кайсыгызныкы кәүсәр суы? — ди Исрафил, каушабрак калган, тулы чиләкләрен тиз-тиз көянтәләренә элә башлаган кызларга.— Кайсыгызныкы ширбәт кебек татлы да, салкын да?

— Минеке, абзый, минеке! Минеке иң тәмлесе, минем суым салкын ширбәт! — Исрафил каршына чүмеч тулы су белән бер кыз чәчрәп чыгып басты:

— Эч, мөгаллим абзый, салкын да, татлы да минем суым, эч, эчә күр, зинһар!..

Исрафил алдында әле кичә генә балалыктан чыккан кыз басып тора: зифа гәүдәле, алсу-ак йөзле, кашлары — карлыгач канаты, ә күзләре! — чем кара зур күзләре Исрафилга төбәп карыйлар... Юк, юк, гөнаһсыз сабый карашы гына түгел инде бу чая күзләрдә! «Сөбханалла! Чын болгар пәрие!» — дип уйлап куйды Исрафил су эчкәндә, чүмеч өстеннән сөзеп кенә кызга карап.

— Рәхмәт, сеңлем, суың чынлап та бик тәмле икән. Инде миңа шундый тәмле салкын суны кем эчертте дип искә алырмын икән — ни атлы син, исемең ничек синең, сеңлекәш?

— Фатыйма... Фатыйма исемле мин. Син Нәгыймә әбиләрдә торасың бит, иеме, мөгаллим абзый. Ә без бер йорт аркылы гына торабыз. Мин көн саен синең мәктәпкә киткәнеңне карап калам, кайтканыңны да...

Фатыйма зур кара күзләре белән тагын бер яшьнәп алды да, аптырабрак калган Исрафилның кулыннан чүмечен тартып алып, иптәш кызлары янына йөгереп китеп барды.

Габдрахман белән Исрафил, инде тагы Аргы як урам буйлап, юлларын дәвам иттеләр. Байтак сүзсез баргач Исрафил шигырь әйтеп куйды:

Буе зифа, йөзе күркәм, үзе яшь
Күзе кара, озын керпек, каләм каш...

— Кем ул, кем баласы булды ул миңа су эчерткән кыз — Фатыйма?

— Фатыймамы? Фатыйма ул сезнең күршегез Сөннәтче бабай, Шәрифулла карт оныгы була. Әбисе белән бабасына күз өстендә каш инде, дөньяда бердәнбер шатлыклары, өметләре...

— Әйе, Сөннәтче бабайның тере хәзинәсе бар икән. Ә нәрсә, Фатыйманың әти-әнисе?..

— Әтисе, Шәрифулла абзыйның бердәнбер улы, Герман сугышында үлеп калган. Фатыймага биш-алты яшь чагында әнисе дә үлеп киткән. Кыз бала ятимлеген сизеп үсми шикелле, шулай да...

— Мөгаллим абзыйның мәгълүматы зур гына икән. Күрәсең, аның бөтен гаме-гамәле авыл балаларына хәреф таныту гына булмагандыр.— Исрафил ак тешләрен ялтыратып елмайды, киная белән Габдрахманга карады.

— Юк, ни... юк, Фатыйма миндә сабак укыган кыз.— Габдрахман колакларына кадәр кызарды.— Быел дүртенче сыйныфта утырырга тиеш иде, әмма бабасы җибәрмәде мәктәпкә, буй җиткән кыз балага малайлар арасында ихахай-михахай килеп йөрү мөрәүвәт түгел, имеш.

— Бәлки тагы үгетләп карарга кирәктер бабайны?

— Файдасы булмас, бик кире, үзсүзле кеше Шәрифулла карт...

* * *

Беркөнне шулай, Габдрахманның урыс теле дәресеннән соң, егетләр гадәтләренчә Аргы як урамны арлы-бирле йөреп, урап, сөйләшеп йөрделәр. Юл уңаенда Исрафил Габдрахманны үз фатирына чакырды: «Әйдә, минем ничек тереклек итеп ятканымны күреп чыгарсың, бездә булганың юк бит әле синең».

Исрафил хуҗаларының ак өендә берүзе генә тора икән. Бусагадан атлап керүгә шәһәрчәлек, пөхтәлек күзгә ташлана: идәндә затлы палас, түрдә келәм белән ябылган кәнәфи; ян тәрәзә каршында тартмалы язу өстәле, өстәл өстендә, киштәләрдә рәт-рәт итеп тезелгән китаплар. Тәрәзәләр арасындагы стенага, пыялалы рамнарда, берничә фоторәсем эленгән. Идәндә тагы ике чыбык урындык, чаршау артында тимер карават.

«Минем походный мебельләр,— ди Исрафил, өй җиһазларын күздән кичереп торган Габдрахманга.— Иң хаҗәт, иләшкән әйберләр. Кайда яшәргә туры килсә, шунда өстерәп йөрим үзләрен».

Габдрахман кысалардагы рәсемнәрне карый. Берсендә башына каләпүш кигән, казакиеның түш кесәсеннән сәгать чылбырлары асылындырган, мыек очларын бөтереп божраландырган гаярь ир басып тора. Ул уң кулын биек аркалы урындыкта утырган чибәр ханымның җилкәсенә куйган. Ханым калфак өстеннән чуклы ак шәл ябынган, озын итәкле күлмәк өстеннән чигүле камзул кигән, аякларында биек үкчәле озын куныччы ботинкалар, йөзендә бәхетле елмаю.

— Әтием белән әнием,— ди Исрафил.— ә монысында сеңелем белән мин булам, ике һәм биш яшьлек чагыбыз.

Кәнәфидә үзеннән аз гына кечкенә курчак тотып, бит урталары батып торган бөдрә чәчле кызчык белән чиккән түбәтәйле бер юантык малай утыра. Икесе дә, түземсезлек белән, тылсымлы тартмадан очып чыгачак кошны көтәләр — кыяфәтләрендә кызыксыну, сабырсызлык.

— Әтиегез, рәсеменә караганда, кырысрак кешегә охшый.

— Азрак бар. Әмма ул туры сүзле, бик гадел кеше. Әйткән сүзендә, биргән вәгъдәсендә торуны ирлеккә саный торган, ихтирамга лаек зат.

— Шөгыле ни әтиеңнең, Исрафил?

— Революциягә кадәр әти Чистайда китап кибете тота иде. Мәскәүдән, Казаннан китапларны үзе барып алып кайта, үзе сата. Әти өйдә югында кибеттә әни сату итә, аңа сеңелем Сәрвиназ булыша иде.

Әтием дә, әнием дә китапны бик яраталар, күп укыйлар, татарча да, урысча да. Сеңелем белән миңа да бик яшьләй китапка мәхәббәт тәрбияләделәр. Мин инде биш-алты яшемдә татарча балалар китабы укый идем. Аннан соң, җиде-сигез яшьләремдә әнием мине урысча да укырга өйрәтте. Шулай итеп, сигез-тугыз яшемдә мин һәр ике телдә дә бер үк дәрәҗәдә сөйләшә, укый идем инде. Әти шәһәрнең гимназия укытучылары, директорлары белән дустанә мөгамәләдә иде. Алар әти кибетендә даими сатып алучылар, заказ бирүчеләр. Шуңа күрәдер, тугыз яшем тулгач әти мине гимназиягә урнаштыра алды.

— Сүзеңне бүлеп сорыйм, Исрафил, ничек соң әле син Эстәрлебаш мәдрәсәсенә килеп эләктең?

— Сабыр ит, Габдрахман, тыңлап бетер. Аның үзенә күрә бер тарихы бар...

Исрафил, идән буйлап ишекле-түрле йөреп, сөйләвен дәвам итә:

— 1913 елның июнь ахырлары иде. Тукай үлгән ел, шуңа күңелгә уелып калган. Әти Казанга товар алырга бара. Үзе белән мине дә алырга булды. Миңа инде унөч яшь, мин инде гимназиянең дүртенче классын бетергән кеше. Күрәсең, әти миңа ил-дөнья күрсәтергә уйлагандыр.

Иделгә пароход төшкәч, әти Казаннан китапларны гадәттә пароходта алып кайта торган иде. Бу юлы Казанга ат җигеп барырга булды. Ике олау, бер тарантас яллап, әти белән без Казанга чыгып киттек. Әнием белән сеңелем Сәрвиназ изге теләкләр теләп озатып калдылар.

Әти белән без тарантаста барабыз. Минем гимназист булуым белән ул горурлана иде булса кирәк, Казанга да гимназист формасында баруымны теләде. Минем башымда кокардалы фуражка, өстемдә жиз төймәле китель, аякларда ялтырап торган ботинкалар. Әтинең кәефе күтәренке, минеке инде әйтеп торасы юк. Яңа илләр, яңа җирләр! Юлның һәр ике ягында алмашынып торган манзара. Миңа, моңарчы беркая да чыкмаган шәһәр малаена, юл тәэссораты зур вә бик гыйбрәтле булды. Татар, урыс авылларын уза-уза, әллә ничә елга-инешләрне кичеп, болыннар-урманнар аша үтеп, өч тәүлектән артык бардык шәһри Казанга.

Яшеллеккә чумып утырган татар авыллары безне тәрәзәләрендәге шау чәчәк гөлләре белән елмаеп каршы алалар. Урам башларында кергәндә-чыкканда үз артыңнан ябарга тиешле басу капкасы дигән чыгырлы җил капка. Әмма синең ат-арбаңнан төшеп мәшәкатьләнәсең юк

икән — авыл башында яшәүче өлгер, житез малайлар, кыңгырау тавышына өйләреннән йөгереп чыгалар да, капканы төбенә кадәр ачып куяр, ябып куялар. Бу савапны эш санала икән. Әгәр инде юлаучы агай капка ачучыларга бер-ике тиен акча, яисә прәнник-конфет тоттырса, малайларның башы күккә тия.

Татар авылының йортлары кечкенә, фәкыйрь булсалар да, кош оясы кебек жыйнак, төзекләр. Йорт-жир, киртә-кура, капка-койма белән әйләндереп алынган. Кыйшаеп торган бер казык та күрмәссең. Тирәли шомырт, миләш агачлары, чия, балан, кәнәфер куаклары. Яшел чирәмле киң ишек алларында, урамнарында сизгер, уяу әнкәләре сагы астында гамьсез тавык чебиләре, каз бибиләре чемченеп йөри.

Урыс авыллары бөтенләй икенче. Авылга керүгә, борынга авыр ис бәрә. Кубесе биш стеналы, такта түбәле йортлар, ләкин киртә-куралары йә бөтенләй юк, йә жимерек, авыш-кыеш. Тәрәзәләре гөлсез, ә пыяласы ватык, өлгеләренә мендәр тыгып куелган. Урамнарын, киртәсез бакчаларын дуңгыз ермачлаган. Юл читендә, саз пычрагында коенып жен төсенә кергән дуңгыз балалары мыркылдашып яталар.

Татар агайлары иләнә-жиренә теше-тырнагы белән ябышып, юктан бар кылып, балта белән төймә төеп яшәсә, урыс мужигы артык казганырга яратмый. Шуңа күрәдер инде — урыс авыллары таркау, ярым жимерек хәлдә, яшеллектән мәхрүм урамнары караңгы, күңелсез.

Без төн кунарга татар авылларында, әтинең таныш агайларына тукталабыз. Беренче кичтә Шомыртлы авылының Рәхимулла абзыйларга төштек. Олаучы абыйлар, әти, ишек алдында атларын тугарып, урнаштырып йөргән арада, мин урамга чыгам. Авылдагы яңалыкны иң беренче булып белүче малайлар инде капка төбендә. Киртә-казыкларга менеп кунаклаганнар да, зур кызыксыну белән Рәхимулла бабайның ишек алдындагы ыгы-зыгыны күзәтәләр. Мине күреп алгач: «Урыс малае, урыс малае!» — дип пышылдашалар, яннарына килә башлагач, чыпчык көтүе шикелле дәррәү урыннарыннан күтәрелеп, бераз йөгереп китәләр дә, тагын туктыйлар, инде батырланып: «Әй, урыс малае, урыс малае, кяфер, имансыз!» — дип, мине үртәп көлешәләр.

— Нишләп мин урыс малае булыйм, мин татар малае! — дим, бөтен жаным белән рәнжеп, — мин кяфер дә түгел, имансыз да түгел!

— Ә нигә суң урыс малае булып киендең?

Шунда гына искәреп алам: минем өстемдә гимназист формасы лабаса!

— Мин гимназия дигән мәктәптә укыйм, анда укучы малайлар шулай киенеп йөриләр.

— Ә син бисмилла әйтә беләсеңме суң? — дип сорый араларында иң зурысы булган малай.

— Бисмиллах иррахман иррахим...

— «Лә илаһыны» да әйтеп күрсәт! — Һаман да шул малай төпчена.

— Ля илаһе илляллаһы мөхәммәден рәсүллаһы...

«Имтиханым» уңышлы тоткач, инде малайлар куанышып көлешәләр, яныма килеп, мине чорнап алалар, минем киемнәремә сокланып карыйлар, кыяр-кыймас кына кителемнең төймәләренә, фуражкамдагы кокардага бармакларын тиереп алалар:

— Нәрсә ул картузыңдагы нәмәстәкәй?

— И-и, нинди матур, име...

Аннан соң китә сорашу, төпчену:

— Син ни атлы?

— Сиңа ничә яшь?

— Син Рәхмәтулла бабайларның кеме?

— Син әкият сөйли беләсеңме?

— Тыңлыйсыгыз килә соң, сөйлим, — дим мин.

— Әйдә сөйлә, сөйлә! — малайлар мине үзләре белән бергә урам читендәге чирәмгә утырталар да, түземсезлек белән әкият тыңларга әзерләнәләр.

Гимназиядә малайларның тышкы кыяфәтенә, киемнәренең пөхтәлегенә зур игътибар ителә. Шунда күнегелгән гадәт буенча, мин каршымда түгәрәкләнеп утырган малайларга күз йөртеп чыгам: барысы да яланаяк, барысы да түбәтәйдән; күлмәк-ыштаннары ямаулы булса да пакь, чисталар; изүләрендә өзелгән бер сәдәп тә юк; чәч-тырнаклары китәрелгән. Малайларның олыраклары миңа яшьтәш булыр. Алар янында көне буе янәшә чабып арган, борын аслары ялтыравыклы дүрт-биш яшьлек энекәшләре утыра.

Мин күңелемнән үзем белгән әкиятләрне барлап алам. Габдулла Тукайның берсеннән-берсе матур әкият-хикәяләренең мин күбесен яттан беләм икән.

«Борын-заман бер ир белән хатын торган,
Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган;
Асраганнар бер кәҗә берлә бер сарык,—
Болар булган берсеннән дә берсе арык...»

Тыңлаучыларым әкияттәге мажараларны күңелләреннән кичереп утыралар. Мактанчык кәҗәнең гайрәт чәчүе бигрәк тә борын аслары ялтыравык малайларга кызык — алар чирәмдә тәгәри-тәгәри көлешәләр. Бүреләр, хәйлә корып, берсе артыннан берсе качып беткәч, ут янында тәмләп кенә бутка ашап, төннәрен дә шунда кунган батыр кәҗә белән зирәк сарык турындагы әкиятне тәмам итәм.

Малайлар, әле генә матур төш күреп уянган сабый шикелле, елмаешып, бер аук тынсыз яталар, алар әле әкият тылсымы астында...

— Чынлап та беттемени? — дип сорыйлар, ниһаять, айнышып.

— Бетте,— дим.

— Тагы, тагы сөйлә! — дип таләп итә, билендә ыштаны тормаган бере карапуз.— Давай, тагын сөйлә!

— Бүгенгә җитеп торсын,— дим мин, чирәмнән торып басып.— Ә сез беләсезме мин сөйләгән әкиятне кем чыгарганын?

— Юк.

— Юк, белмибез...

— Габдулла Тукай дигән исемне ишеткәнегез бармы сезнең? — дип сорыйм, малайларның өлкәнрәкләренә карап. Кайсыгыз китап укый белә?

Тынлык, малайлар дәшмиләр.

— Тукай ул әүлия, минем әби намаздан соң дога багышлаганда аны да телгә ала,— ди, арткы рәттән бер малай.

— Менә сез әле генә ишеткәнегез шикелле матур-матур әкиятләр, шигырьләр язган олуг шагыйрь иде Габдулла Тукай абзагыз,— дип, әти малайлар янына килә.— Күрәсең, ул да мине тыңлап торган.— Ләкин, оланнар, моннан ике ай гына элек Тукай абзыегыз вафат булды...

Тыйнакланып, юашланып калган малайларга әти Тукай рухына багышлап сәдака өләшә — барчасына биш тиенлек бакыр, берәр конфет тоттыра.

Инде кич. Без әти белән өйгә кереп киткәч, малайлар да таралышалар.

Ашап-эчкәч, хуҗалар миңа өйалдына урын җәеп бирделәр. Әллә инде ят урын булганга, әллә юл тәэссоратларым зурга, көне буе юлда, саф һавада булуыбызга карамастан, мине йокы алмый. Елдай озын көндә күргәннәремне баштан кичереп, озак уяу ята торгач, ниһаять, йоклап киткәнмен... Сүзем озынга китте бугай, сине ялыктырмадыммы? — Исрафил йөрүеннән туктап, кәнәфигә утырган Габдрахман каршына килеп баса.

— Юк, юк, бик рәхәтләнеп тыңлап утырам, сөйли күр, дәвам ит.

— Менә шул җылы июнь төнендә, Рәхмәтулла абзыйның өйалдында мин гаҗәеп матур вә бик сәер төш күрдем. Имеш, мин оҗмах бакчасы

кебек матур ялан уртасында утырам. Тирә-ягым шау чәчәк. Ак, ал, сары, кызыл, зәңгәр чәчәкләргә куныл-китеп төрле төстәге күбәләкләр оча, энже, зәбәрҗәт, ахак, якут, фирүзә төсле Ходайның бихисап бөҗәкләре бизәлди. Куктә, куакларда яшел, кызыл, зәңгәр канатлы оҗмах кошлары сайрыйлар, имеш...

Игътибар ит: мин төсле төш күреп ятам! Мондый хикмәтле төшне минем үз гомеремдә беренче мәртәбә күрүем!

Шулчак яланга бер көтү кыр казлары төшеп кунаклый. Юк, алар кыр казлары түгел, кичә кичен миннән әкият тыңлап утырган малайлар, имеш. Барысы да шаһзадә кебек бай вә матур киенгән: башларында алтынука белән чигелгән яшел, кызыл, зәңгәр бәрхет кәләпүшләр, өсләрендә ак, ал, сары төстәге күлмәк өстеннән киелгән чигүле җилән, барысы да яланаяк, имеш. Алар, нәкъ кичәгечә, аякларын бөкләп минем каршыма килеп утыралар, мин аларга әкият сөйлим, имеш.

«...Бер заманны әйләнеп баккан идем артка таба,—
Аһ, харап эш!—Су анасы да минем арттан чаба...»

Ул арада булмый—мин хәлфәгә әверелән: минем өстемдә яшел җилән, аякларымда читек-кәвеш, башымда бәрхет кәләпүш, имеш. Һәр малайның алдында әлифба китабы. Китаптагы хәрефләр дә, гөл тармаклары шикелле яшел, кызыл, зәңгәр, ал, шәмәхә төстә икән.

Яшел үләнгә сибелешеп утырган малайлар башта миңа ияреп яттан «әлип» укыйлар: әлиф-би, ти-си, җим-чи, хи-ха, дәл-зәл, ра-зи... Аннан соң мин аларга бу авазларга тәңгәл хәрефләрне кулларындагы әлифбаларыннан күрсәтеп чыгам. Минем шәкертләрем зирәкләр—әйткәнкүрсәткәннәремне шундук күңелләренә сеңдерә баралар.

Аннан соң без күмәкләшеп, көйгә салып, илһамланып тәкбир әйтәбез, имеш:

Ля илаһе иллялаһенең карамагыз азына,
Ля илаһе иллялаһе—мәңге бетмәс хәзинә!..

Шул чакта: «Балалар-чагалар, кайтыгыз!»—дигән аваз ишетелә, имеш. Малайлар янә, алар белән мин дә, кыр казларына әверелеп, дәррәү күккә күтәреләбез дә, Шомыртлы ягына очып китәбез. Тезелешеп, почмак ясап очабыз, мин—юлбашчы.

Җирдән безне санаган авазлар ишетелә: «Берәү, икәү, өчәү...» Мин: «Санамагыз ла безне, зинһар, санарга ярамый безләрне!»—дип ялварам, имеш...

Менә без инде таралыша, адаша да башлыйбыз...

Мин, иптәшләремнән аерылып, берүзем төнгә карап очам да очам, имеш. Мин кычкырам—алар мине ишетмиләр. Шулай, оча-оча торгач, мин иптәшләремне инде күздән югалтам, үзем дә караңгыга кереп югалам... Мин тагы: «Исрафил!»—дигән аваз ишетәм, җавап бирергә тырышам, ләкин тавышым чыкмый...

Уянып китеп, күзләремне ачсам,—баш очымда елмаеп әти басып тора: «Хәерле иртә, улым! Әйдә, битеңне-күзеңне юып ал да, чәй эчәргә кер, аннан сәфәребезне дәвам итәрбез, Алла боерса».

..Кичәге малайлар безне басу капкасына кадәр килеп, капка ачып озатып калалар. Алар миңа бүген тагы да якынрак, кадерлерәк тоела: минем әле күргән төшемнән әсәрләнүем үтмәгән,—алар минем зирәк шәкертләрем, дусларым лабаса! «Кайтышлый тагын сезнең авылда кунарбыз әле»,—дим мин малайларга, аерылышкан чакта.

Без тагы урман-кырлар, болыннар, елгалар аша, фәкыйрь татар, урыс авыллары аркылы юлыбызны дәвам итәбез. Тирә-якта бай, хозур табигать, ә Алланың иң камил мәхлугы—акыл көченә ия булган кеше-се—фәкыйрьлектә яши. Нигә шулай корылган бу дөнья? Мин бу хакта әтидән сорыйм—нигә шулай? «И улым, улым!—ди әти, авыр сулап.—

Сиңа моны аңлатып бирергә минем башым-акылым җитмәс. Бу турыда уйланырга әле сиңа да иртәрәк, балам, балигъ булмаган акылыңа көч килер. Һәр нәрсәнең үз вакыты бар, һәр җимеш үз вакытында өлгерә. Әмма минем шуңа иманым камил — татарның да, урысның да шулай фәкыйрьлектә тереклек итеп ятулары адәми зат өчен хурлыктыр. Мәгәр бу да миңа мәгълүм — инсанга лаек мәгыйшәт кылып яшәр өчен авыл кешеләренә мәдәният җитешми. Алар томана,— акылларына, зиһеннәренә яктылык сирпүче илаһи мәгърифәт нурына мохтаҗлар. Әнә, үзең дә күрдең ич — авыл балалары, димәк аларның ата-аналары да, мәшһүр шагыйребез Тукай барлыгын белмичә яшиләр икән. Үз кулларында тотып бөек Тукаебызны уку гына да аларның гаҗизәнә тормышына мәгънә бирер, ямь өстәр, күңелләренә нур сибәр иде!»

Шушы шактый ук күтәренке рух белән әйтелгән сүзләреннән соң, әти күзләрен йомып, тынып кала. Без тарантаста җай гына тирбәлеп, беравык сүзсез барабыз. Ниһаять, мин кичәгедән бирле күңелемә кереп урнашкан, инде тынгы бирми башлаган теләгемне әйтеп бирергә җөрьәт итәм: «Әти, әти, дим, минем хәлфә буласым килә!..» Әти әллә ишетмәде, әллә инде ишетеп тә, сафсатага санап, минем бу сүзләремә әһәмият бирмәде,— тарантас аркасына терәлеп утырып, йокымсыраган кыяфәттә килә бирде. Мин тагы кабатлыйм: «Әти дим, әти! Минем хәлфәлеккә укыйсым килә, минем шул авыл балаларына сабак укытасым килә, мин аларга Тукайның үзем белгән бөтен шигырьләрен күңелдән ятлатыр идем, мин аларны урысча сөйләшергә өйрәтер идем!..»

Әти инде күзләрен ачкан, минем дулкынланып сөйләгән нотыгымны бераз гаҗәпләнеп тыңлап бара. Мин аңа бу теләгемнең кичә малайларга әкият сөйләп утырганда килүен, ниһаять, төнлә күргән төшемне сөйләп бирәм. Төшем әтигә көчле тәэсир итте, бигрәк тә аның төсле булуы. «Гаҗәп, гаҗәп! Чәчәкле төш!.. Һәр чәчәк үз төсендә!.. Кыр казлары булып очу... Җирдән торып санадылар, димсең?.. Таралыша, адаша башладыгыз, димсең?.. Бик хикмәтле, бик хикмәтле төш күргәнсең, балам!..»

Минем ишеткәнем бар: төсле төшне хәерлегә юрамыйлар. Белмим, әтием нәрсәгә юрагандыр, аның чырае сүрелде. Ул минем күзләремә текәлеп карап торды да уйга калды...

«Менә нәрсә, улым,— диде әти бераз сүзсез баргач,— син балигъ булганчы тәрбия кылу, дөрес юлга кую миңа фарыз эштер. Мәгәр синең хәлфә булырга дәртең фани, минутлык күңел җилкенүе генә түгелме? Син минем бердәнберем, мин синең теләгеңә каршы килмәм, телисең икән — мәдрәсәгә бирермен. Әмма миңа башта уйларга, дусларым белән киңәштабыш итәргә кирәк, кем әйтмешли, җиде кат үлчә — бер кис».

Казанның китап кибетләреннән, нәшрият складларыннан сайлап алынган китапларны олау арбаларына төяп Чистайга озаткач, без әти белән тагын бер-ике көнгә шәһәрдә калырга булдык. Минем Казанда беренче мәртәбә булуым иде. Әти миңа шәһәр күрсәтеп йөрде, мине дә ияртеп, үзенең таныш, дус нәширләренә, мөхәррирләренә визит ясады. Шәһәрнең зыялылары Тукайның вакытсыз вафаты шаукымында. Һәр җирдә, күрешеп исәнлек-саулык, хәл-әхвәл сорашкач, мәрхүм шагыйрь турында сүз кузгалмый калмый: «Менә бит кемебезне югалттык!..» «Милләтебезнең җәүһәр ташы, йөзек кашы булган икән, исән чакта кадерен белмәгәнбез...»

Шагыйрьнең ямьсез, шыксыз, фәкыйрьлектә үткән тормышында, үлемендә татарның өшбу хәяллы зыялылары күпмедер дәрәҗәдә үзләренең дә гаепле булуын таныйлар, шуңа уфтаналар иде шикелле...

Нәшир Галиәкбәр әфәнде безне якты чырай белән каршы алды. Кәләпүштән, тырпай мыеклы, гаярь кыяфәтле бу ачык кеше миңа беренче күрүемдә үк ошады. «Ә-ә, менә нинди икән яшь социалист!» — дип елмаеп, минем белән ике куллап күреште. Күрәсең, аның белән әти арасында минем хакта элегрәк тә сүз булгандыр.

Без Галиәкбәр әфәндене язу-сызу өстәле артында сөйләшә-сөйләшә, клиндер белән чәй эчтек. Галиәкбәр абзый әтинең сәүдә эшләре ничек барганын сорашты, татар китапларының ниндие, кайсы язучыларның китабы күбрәк таралуы, Чистайда гыйлемле татарларның ни чама булуы белән кызыксынды.

— Инде бу егет мәсьәләсенә килгәндә, мин аның теләген хуплыйм, аны мәдрәсәгә бирүне мәслихәт күрәм,— диде Галиәкбәр абзый.— Гомер башында һәр яшь кеше үзенә муафыйк шөгыль табып, шул эшендә иҗтиһат итеп яшәгәндә генә матди вә рухи байлыкка ирешер, илгә дә бәрәкәт иңәр... Аннан тагы бу ягы да бар — классында бердәнбер татар малае булгач, ул анда һәрдаим рухи ятимлек, ялгызлык кичерәдер. Ә бу хәл баланың аңына, рухына зыян китерүе ихтимал.

— Рәхмәт, Галиәкбәр әфәнде, инде икеләнүләрем бетте, карарым анықланды. Тик менә кайсы мәдрәсәгә бирү мәслихәтрәк булыр икән?— ди әти.

— Дөресен әйтим, Мөхәммәт абзый, шәһәр җирендә яшь кешегә агъва зур, күңел сайларлык нәрсәләр күп. Баруди шәкертләренең дә кирәкмәс урыннарында шалтай-балтай йөргәннәрен күреп йөрәк әрни. Эстәрлебаш, Кышкар, Иж-бубый кебек шөһрәтле авыл мәдрәсәләре бар. Минем үземә Эстәрлебаш мәдрәсәсендә уку насыйп булды. Ул чын мәгънәсендә мәгърифәт учагы! Анда зур мәгълүматлы, киң мәсләкле хәлфә-мөдәррисләр гыйлем бирә, намуслы, вөҗданлы, пакъ кешеләр әхлак тәрбияли. Авылының мохите, кешеләре матур. Ерак димәсәгез, мин егетне шул Эстәрлебаш мәдрәсәсенә урнаштыруны мәгъкуль күрер идем.

Без хушлашабыз. Галиәкбәр абзый, өстәл артыннан чыгып, безне ишеккә кадәр озата килә:

— Йә, энекәш,— ди, минем аркамнан сөеп, хәер-фатыйхам сиңа! Иҗтиһат ит, мәгърифәтебез күгендә якты йолдыз булып кабын!

Менә шулай итеп, Габдрахман, минем язмышымда яңа борылыш булды.

Исрафил тагы сөйләп китә:

— Әти белән кибетләрдә йөреп, миңа кәләпүш, җилән, камзул, читек-кәвеш, шәкерт тормышы өчен хаҗәте булган башка вак-төяк әсбапны, әни белән Сәрвиназга күчтәнәчләр сатып алдык та, кайтыр юлга чыктык. Мин үземнең яңа дусларымны — Шомыртлы малайларын да онытмадым, аларга дип әлифба, юка-юка әкият китаплары, шул җөмләдән Тукайның шигырь китапларын да сатып алдым.

Кайтышлый кунарга тагы Шомыртлыга тукталдык. Рәхимулла бабай йорты янына тагын малайлар җыелды. Мин инде алар янына бу юлы кәләпүштән, камзулдан чыктым. Теге көндәгечә, урам читенә — чирәмгә утырып малайларга Тукайның «Шүрәле»сен укыдым. Аннан соң рәвешен китерергә тырышып, шәкерт, казый булып кыланып, яттан «Таз» шигырен сөйләдем. Малайларга кызык, малайлар тагын чирәмгә тәгәрәшеп көлешәләр. Әкиятне беренче тапкыр ишетүләре, ә гыйбрәтле тәкъбирләрен бер дә ялгышмыйча отып алалар. Әйтеп кара син авыл балаларын томана дип!

Иртәгесен малайлар, гадәтләренчә, безне озатырга килделәр. Мин дә басу капкасына кадәр алар белән җәяү бардым. «Исрафил, тагын килеп чык, икенче килүеңдә инде сине без Тукай абый әкиятләрен укып көлдерербез»,— диделәр малайлар, юл борылышына кереп без күздән югалганчы түбәтәйләрен болгап тордылар.

Әти мине гимназиядән алып, мәдрәсәгә бирергә карар кылганын әйткәч, әни башта ышанмады, шаярып сөйләшә дип уйлагандыр, күрәсең. Әти үзенең бу нияте инде хәл ителгән, бәхәссез икәнен (безнең өйдә әти сүзе сүз!), минем үземнең дә теләгем шулай икәнен әйткәч, әни бик гаҗәпләнде, елап та алды. Әти югында мине кирегә үгетләп тә карады: «Син анда берүзең ничек яшәрсең, ашарына-эчәренә кем әзерләр, күлмәк-ыштаннарыңны кем юып торыр? И-и балам, балам!..»

Сентябрь урталарында без әти белән юлга чыгып киттек. Өфегә кадәр пароходта килдек, аннан ат яллап, өйдән чыкканга бер атна була дигәндә, сәфәребезнең максаты булган мәдрәсәләр мәркәзе Эстәрлебаш авылына килеп җиттек.

Ул вакытта Эстәрлебашның унбишме-уналтымы мәдрәсәсендә алты йөзләп шәкерт укый иде. Мәдрәсәдә, чынлап та, алдынгы карашлы мөхтәрәм хәлфә-мөдәррисләр дәрес бирәләр икән. Дин гыйлеменнән башка шәкертләр татар, гарәп, фарсы, урыс теле, тарих һәм башка дөньяви, акыл фәннәреннән дә сабак алалар.

Диндар әтиемнең теләген үтәп, мин Чистай мәчете имамыннан дин сабагы да укып йөргән идем. Чамамны тартып карагач, мине мәдрәсәнең урта сыйныфына утырттылар.

Укуымның соңгы елларында минем күңелемне көфер фикерләр талый башлаган иде. Мин хәлфә-мөдәррисләрнең гыйльми мәҗлесләрендә катнашкалый идем. Бервакыт шулай Мәрҗани фәлсәфәсе буенча бәхәс оештырдылар. Мәрҗани фәлсәфәсе — ислам фәлсәфәсе. Хәзрәте Мәрҗәни халкыбызның тарихын шәригать кануннарыннан чыгып, аларга таянып бәян итә. Мин аның бу ысулы-мантыйгы белән килешеп бетә алмыйм, әмма зиһенемне, җанымны газаплаган көфер, низаглы сорауларымны мөхтәрәм мәҗлес әгъзаларына бирергә җөрьәт итмим,— тыйнаксыз, дәһри булып күренүдән куркам. Шагыйрь әйтмешли:

Берсе — динне, берсе — фәнне хуплый торган
Ике аваз арасында басып торам.
Куркып куям: «Тегесе дә һәм бусы да —
Дөрес түгел!» — дигән аваз килерсыман...

Шулай да, миңа һәр чакта игелекле булган хәялы зат Таһир әфәндегә җанымны газиз иткән икеләнүләремне сөйләп бирдем. Ул мине зур игътибар белән тыңлады. Мин аның арган, акыллы күзләрендә кызыксыну, гаҗәпләнү, шул ук вакытта ни беләндер разый булмау чаткылары да күреп тордым.

«Әйе, әйе,— диде Таһир абзый үз алдына, шактый вакыт сүзсез торгач, дөньялар үзгәрә — фикерләр үзгәрә. Бу инсаният, җәмгыять тәрәккыйсының асылыдыр...»

Таһир әфәнде, халыкның юкка чыгарылган мәдәниятен, тарихын аның тереклек иткән төбәгендә калдырган эзләре буенча барларга, өйрәнергә кирәк дигән фикереннән чыгып, миңа укуымны шәркый шәһәрләрдә түгел, ә нәкъ Казан университетында, шөһрәтле Казан университетында дәвам итү мәслихәт булыр, диде.

Аның киңәшен тотып, мин Казанда Учительская школаны тәмамладым, ике елда. Аннан соң университетка имтихан тотарга әзерләнә башладым, һәм аны дәвам итәм,— Исрафил өстәлдәге, киштәдәге китапларга ишарә итеп алды.

Шул арада Нәгыймә карчык өстәлгә шаулап кайнап торган самавыр кертеп утырта. «И-и, әллә кайчан кайнап чыкканые, сүзегезне бүлдермим дип кертми тордым, и-и, менә төче коймак пешереп алдым, кунак хөрмәтенә, чәй эчегез, рәхәтләнеп эчегез, и-и...»

Егетләр әбине, әбинең коймагын мактый-мактый чәй эчтеләр.

— Димәк, син Мирас мәктәбендә вакытлыча гына? — ди Габдрахман, сизелерлек күңелсезләнеп.

— Ничек дип әйтергә инде... Киләсе ел август аенда университетка экзаменнар тотып карарга исәп, уңышлы барып чыкса, әлбәттә, мин укырга китәрмен, барып чыкмаса...

Исрафил инде чәй өстәле артыннан торып, тагын ишекле-түрле йөреп сөйли башлый. Дулкынланудан аның йөзеннән каны качкан, аз гына кылычрак борыны тагы да тараеп, очланып калган, ә чем-кара күзләре әсәрләнеп ялтырыйлар...

Габдрахман сокланып карап утырды: тагы да матурлана икән болай да чибәр Исрафил илһамланган, рухы ярсыган минутларында!

— Эстәрлебаш мәдрәсәсендә миңа тагы бер хакыйкать ачылды,— дип сүзен дәвам итә Исрафил, инде бераз тынычланып, яңадан өстәл артына кереп утыргач.— Яшүсмергә фән нигезләрен ана телендә үзләштерү фарыз. Сабыйга ана сөте ничек табигый вә шифалы булса, ана телендә гыйлем эстәү дә шул дәрәҗәдә табигый вә шифалыдыр. Ана телендә укып белем алганда бала рухи ләззәт тоя, җан шатлыгы, тән шатлыгы кичерә. Укуын урысча башлаган татар баласы буларак әйтәм: баланың чит телне белүе шул телдә уйларлык дәрәҗәдә булмаса, фән төшенчәләре, тәгъбирләре аның миендә тоткарланып, зәгыйфьләнәләр, имгәнәләр, хәтта асылын җуялар икән. Адәм баласы беренче мәртәбә ачы хәсрәтен әнисе имчәктән аергач кичерә, диләр. Ана теленнән аерылу аның гомерендә икенче ачы хәсрәтедер. Мин шул фикердә...

Исрафил Габдрахманны озата чыкты. Тышта айсыз аяз октябрь төне. Егетләр, бер мәлгә сүзсез калып, күккә текәлделәр. Төнге учак, баш очында янган йолдызлар адәм балаларының игътибарын җәлеп итми калмыйлар. Бу табигый омтылыш аларның ерак бабаларыннан килә торгандыр инде.

Күктә йолдызлар тантанасы! Бәйрәмчә балкып кабынган купшы кызлар-йолдызлар ни турындадыр серләшәләр, елмаешалар, бер-берсенә күз кысышалар. Кайбер артык шаяннары атылып, берсен-берсе куышып китәләр дә, кире кайтыр юлларын табалмыйчы, адашып, зәмһәрир суыгында һәлак булалар.

Күк гөмбәзен урталай бүлеп, мәшрикътән мәгърипкәчә космос пәрәвезе, Галәм картның ак көрфия билбавы — Киек каз юлы сузылган...

— Әгәр атылган йолдыз тизлеге белән гел бер юнәлештә ун, йөз, мең ел очсаң дөньяның читенә җитү мөмкин түгелдер,— ди Исрафил, ниһаять, телгә килеп.— Очасың, очасың, очасың — ә дөньяның барыбер иге-чиге юк... Бу минем башыма да, акылыма да сыймый, мин чиксезлекне күз алдыма китерә алмыйм, ул мине куркыта... Менә шулай төнге күккә карап язгандыр инде Гомәр Хәйям дә үзенең хикмәтле шигырьләрен:

Түгәрәк бер божра булган бу дөньяның
Башы да юк, ахыры да юктыр аның.
Һичбер кемнең әйткәне юк, адәм, сиңа:
Кайдан килдең, кая илтә китәр ягың?

Ә менә адәми затка нинди урын билгеләгән мәгъруур шагыйрь:

Бу дөньяның чын баласы — без ул, без ул,
Бу җиһанның күз карасы — без ул, без ул.
Бу җиһанның күз карасы — без ул, без ул.
Әгәр дә бу божра — Галәм — йөзек булса,
Ул йөзекнең гәүһәр кашы — без ул, без ул!..

Әсәрләнеп тыңлап торган Габдрахман, ниндидер бер җан ашкынуы белән, кинәт Исрафилны кочаклап алды:

— Рәхмәт сиңа, Исрафил туганым, бүген мин синнән бик тә гыйбрәтле сабак тыңладым. Син минем күңел күгемне күтәрдең! Инде мин кайтып китим, күп вакытыңны алдым шикелле.

— Зыян юк, төн минеке...

Егетләр хушлаштылар.

Габдрахман фатирына очынып, яхшы кәеф белән кайтып керде. Менә нинди кеше икән аның әшнәсе Исрафил! Хөсни бай амбарыннан әмәлләгән мәктәптә Мирас балаларына менә нинди мөгаллим сабак бирә икән!..

Бу кичтә Габдрахман гомерендә беренче мәртәбә диярлек җан шатлыгы сизде: әйе, бу дөньяда ул ялгызы гына түгел, аның нечкә зәвыклы,

әтрафлы мәгълүматлы Исрафил исемле дусты бар, аннан соң... әле исемен атарга да кыймаган, әлегә сурәтен йөрәгенең иң изге, иң яшерен почмагында саклап йөрткән тагын бер кешесе бар аның бу дөньяда, ул кеше...

Моңарчы беркайчан да булмаган хәл — Габдрахман иртәгесе көннен тизрәк тууын теләде, урынына сузылып ятты да, күзләрен йомды: «Бу җиһанның күз карасы — без ул, без ул... ул йөзекнең гәүһәр кашы — без ул, без ул...» Нинди матур, нинди гүзәл сүзләр!

Күңел хушлыгы, җан рәхәте тоеп, үзалдына елмаеп, мөгаллим егет йокыга китеп барды.

Ә Нәгыймә кортканың ак өендә, караңгы урамга тәрәзәләреннән якты нур көлтәләре ташлап, ут әле бик озак янып торды.

* * *

Гадәти мәшәкатьләр белән кыш, яз үтеп, җәй килде. Керү имтиханнарын уңышлы биргән Исрафил август азакларында Казанга укырга китеп барды.

Габдрахман ат җигеп, дустын Ташлыкка кадәр үзе озата килде.

Юлчылар Сөннәтче бабай йорты турыннан узып барганда, каршыларына йөгереп Фатыйма килеп чыкты.

— Нәрсә, мөгаллим абзый, китәсеңдәмени инде бездән? — Ул туптуры Исрафилга карап килде. — Инде бөтенләйгә китүеңмени?

Фатыйма каушаган кыяфәтле: күзләре зур ачылган, иреннәре калтырый, ул менә-менә елап җибәрер төсле.

— Бөтенләйгә булса хәерлерәк булыр иде, Фатыйма сеңлекәш, йә, сау бул инде, ил чәчәге, — Исрафил һәр вакыттагыча ак тешләрен күрсәтеп елмайды. — Хәерле юл телә миңа, Фатыйма, ә мин сиңа ак бәхетләр теләп, юл буе дога укып барырмын.

— Хәерле юл, хәерле юл сиңа, мөгаллим абзый... Исрафил абый...

Фатыйма тагы нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачты — әйтә алмады, ике кулы белән йөзен каплап, елап өйләренә йөгереп кереп китте...

Ташлык станциясында егетләр кочаклашып аерылыштылар.

Габдрахман атын кайтыр юлга борып, үз иркенә куйды да, тарантасына кырын ятып, юл буендагы инде җителегән җуя башлаган манзараларны күзәтеп кайта башлады.

Габдрахманга ямансу булып китте. Шулай бит ул кешенең табигате — бергә чакта бергә булуның кадерен белмисең, аерылышкач, ул көннәрне сагына башлыйсың...

Дөресен әйтергә кирәк: соңгы вакытларда ул, Габдрахман, ниндидер җан тынычсызлыгы сизеп яши башлаган иде. Моңа сәбәпче — Фатыйма булды. Исрафил белән кайчан гына, кайда гына йөрергә чыкмасыннар, һәр чакта диярлек алар Фатыймага юлыктылар. Бу чая, җилбәзәк кызның чиләк-көянтәләрен асып йә суга барышы була, йә кайтышы, йә тагын нәрсәдер йомышлап йөрүе. Очраган саен кыю гына: «Исәннәрмесез, мөгаллим абзыйлар!» — дип исәнләшер, очраган саен Исрафил аңа мактау сүзләре, — ничек әле? — комплиментлар, — әйтми калмас: ил нуры, гөләндәм, җир гүзәле...

Габдрахман акылы белән аңлый — шәһәр тәрбиясе алган укымышлы егетнең кызларга мактау сүзләре әйтүе гадәти хәлдер, ә менә йөрәге белән...

Хикмәт шунда ки — Габдрахман... Фатыймага гашыйк. Инде күптән, әле Мираска Исрафил килеп чыкканчы ук. Фатыйма — Габдрахманның беренче мәхәббәте!

...Габдрахман ул кызыйны өченче сыйныфка утырткан иде. Укыта башлавының беренче көннәрендә үк бу наян кыз үзенең чибәрлеге, өстебашының бөтенлеге, пөхтәлеге белән мөгаллим егетнең игътибарын җәлеп итте. Үзен иркен тотуы, кыюлыгы белән дә ул сабакташ

кызларыннан аерылып тора иде. Бераз һавалы, бераз дуамал, бераз иркә Фатыйма, күзен әле баласыман күренсә дә, язга таба үзгәрде, тамчы гөлдәй, кинәт чәчәк атты, җаны сизгерләнде. Ул мөгаллим абзыйсының күз карашыннан, үзенә төбәп әйткән бер авыз сүзеннән дә кызара, хисабында бутала, язуында ялгышлар җибәрә башлады. Аның элеккеге кыюлыгы кимеде, дуамаллыгы сүрелде шикелле. Мөгаллим егет түбән сыйныфларга дәрес биргәндә, Фатыйма аны астыртын гына күзәтеп утыра, еш кына өстәленә капланып, бер сәбәпсез-нисез елаштырып ала торган булды.

Фатыйманың бу кыланышларын мөгаллим егет үзенчә юрады: «Бу баланың күңелен кузгаттым, ахры»,— дип уйлады ул, дәресләрдә аннан сорамаска, аның ягына карамаска тырышты. Ләкин — ни хикмәттер! — Габдрахман үзе дә сизмәстән Фатыйма ягына элеккегә караганда да ешрак күз салганын, бу кыз аны магнит кебек үзенә тартканын сизде. Сизде дә, үзенә-үзе әмер бирде: «Азынма, мөгаллим абзый, языктан курык!..»

Шулай да бер көнне, мәктәптә ялгызы калгач, өченче сыйныф журналын ачып, Фатыйманың туган елына күз төшерде. Сөбханалла! Үндүрт яшен тутырып, унбишенче белән бара икән инде кызый!..

Менә уку елының соңгы көне дә килеп җитте. Укучы балалар, инде көзгә кадәр мөгаллим абзыйлары белән саубуллашып, өйләренә таралыштылар. Габдрахман бераз ямансылап, уку-укыту әсбапларын шкафларга урнаштырып йөргәндә, мәктәпкә Фатыйма килеп керде, бераз ыңкысыңкы торгач: «Ни, Габдрахман абзый... мин инде бүтән мәктәпкә йөрмәм, бабай кушмый... Сау бул инде, мөгаллим абый, мин...»

Бер генә мизгелгә укучы кыз һәм мөгаллим егетнең күзләре очраштылар. Аһ, бу күзләр!.. Фатыйманың яшь мөлдерәп торган күзләрендә каушау катыш тәвәккәллек тә, ялвару да, ни өчендер рәнҗү дә бар иде кебек...

Укучысының бу чаялыгыннан гаҗәпләнеп, аптырап калган мөгаллим телгә килгәнче, Фатыйма капыл борылды да йөгереп чыгып та китте.

Җәйге ялын Габдрахман туган авылында үткәрде. Атасына, башка чыккан абыйларына печән чабышты, урак урышты, кышлыкка утын әзерләргә булышты. Кайда гына булмасын — болындамы, иген басуындамы, урмандамы,— ничек кенә мавыгып эшләмәсен, Габдрахманның күңелендә Фатыйма булды. «Габдрахман абзый... мин инде бүтән мәктәпкә йөрмәм, ...сау бул инде, мөгаллим абый, мин...» Тагы нәрсә әйтергә теләде икән ул кыз? Бәлки: «Мин... сине ярата идем»,— дияргә теләгәндер, гыйшык тоткандыр? Җүләр, җүләр син, Габдрахман мөгаллим! Аның яшендә укучы кызларның күбесе укытучы абыйларына бераз гашыйк була. Аларның җилкенгән чагы, ә син... Карт тиле! Хыялый! Күңелеңне аздырма, ул кыз әле унбишенче яше белән генә барса, син хәзер егерме өчне тутырып киләсең, Алладан курык!

Үзен-үзе менә шулай тиргәп, күңелен тынычландырырга тырышты Габдрахман, атасы йортында чоланда яки печәнлектә, озак йокыга китә алмыйчы газапланып уздырган төннәрендә...

Юк, акылына буйсынмады Габдрахманның күңеле — Габдрахман гашыйк иде... Сөннәтче бабай оныгына, Фатыймага!

Мөгаллим егет, ялы беткәнче түзәргә дә тәкате калмыйча, ашкынып Мираска кайтты. Кайткан көнне үк көздән мәктәпкә йөрергә тиешле балаларны барлау сылтавы белән, йорттан-йортка йөреп, авылны әйләнеп чыгарга булды. Шәп уйланган план! Ул Сөннәтче бабай йортына да кагылачак, әлбәттә. Анда аның Фатыймасы яши!.. Фатыйма, Фатыйма... Нинди матур исем! Ничектер элегрәк игътибар итмәгән Габдрахман бу исемнең ягымлы, нәфис булуына!

Шәрифулла карт йортына якынлашканда Габдрахман үзенең тез буыннарының йомшарганын сизде. Койма аркылы Фатыйманың көмеш

кыңгырау чыңы шикелле риясыз көлгән тавышын ишеткәч, йөзенә, чигәләренә кайнар кан бәргәнен тойды.

Ишек алдында кәҗә бәтиләре белән мәш килеп, куышып уйнап йөргән ялан аяклы Фатыйма, көтмәгәндә капкадан мөгаллим абзыйсы килеп кергәч, каушап калды, комачтай кызарды, оялып кына: «Исәнмесез, Габдрахман абзый...» — дип әйтте дә, йөзен учлары белән каплап, йөгереп өйләренә кереп качты.

Бабасы белән мөгаллим абзыйсы бер-берсеннән хәл-әхвәл сорашып болдыр алдында торган арада, инде өс-башын алыштырырга өлгергән Фатыйма көянтә-чиләк асып чишмәгә китеп барды. Бабайга сиздермәскә тырышып кына аның артыннан карап калган Габдрахманга күз сирпеп, аның йөрәген өтеп алырга да җаен тапты, наян кыз!

— Жук-жук, кем, Габдрахман, укыганы бик җиткән! — дип, кырт кисте Шәрифулла абзый, мөгаллим егет Фатыймага тагын бер ел мәктәпкә йөрү фарыз икәнен әйткәч.— Белгән хәтлесе бик җиткән балакаебызга! Әнә, әбисенә шаулатып хикәятләр укый, җазу җаза — хат җаза. Аллага шөкер, әйе, укыганы бик җиткән, сиңа да зур рәхмәт, кем, Габдрахман. Аннан суң,— Сөннәтче бабай як-ягына каранып алды, бармагы белән якынырак килергә ишарәләп, мөгаллим егетнең колагына диярлек, пышылдады: — Аннан суң, кем, Габдрахман, кызыбызның күзе урыныннан купкан чагы. Аңа инде ир-ат, малай-шалай арасында ихахай-михахай йөрү мәрәвәт түгел. Хәерниса түтиең белән дөньяда гамебез. Ходайга гозеребез бер генә — үзебез исән чакта, насыйбы чыкса икән дә, тезгә утыртып, тупылдатып беренче балаларын сөяргә насыйп итсә икән. Аннан суң күзебезне йомсак та үкенечебез калмасые, әйе, шулай, кем, Габдрахман мөгаллим.

— Әле иртәрәк түгелме, Фатыйманың насыйбы турында уйларга? — диде, мөгаллим егет, карап торырга кырыс, йомыкый бу картның телгә маһир кеше булып чыгуына гаҗәпсенеп.

— Һич тә түгел. Ул йөземнең сурты шундый. «Өлгергән җимешне вакытында өзү хәерле»,— диләр, хе-хе-хе! Менә ике-өч елдан синең шикелле инсафлы, тәүфыйклы егет яучы җибәрсә... Әлегә балакаебызның бер генә моңы бар,— җилбәзәгрәк шул әз генә. Әмма ул кызамыгы да, иншалла, үтәр, бетәр, шаукымы да калмас.

Шәрифулла картның соңгы сүзләре Габдрахманга ниндидер бер мәгънә белән, киназләп әйтелгән кебек тоелды. Бәлки, бу дөнья күргән, нечкә һөнәр иясе бабай, егетнең йөрәгендә ниләр барын сизгәндер, аңа хәер-фатыйха бирәчәген алдан ук белдерүе булгандыр? Әгәр шулай икән — мең яшә, Сөннәтче бабай!

Шәрифулла абзый капкасыннан Габдрахман канатланып чыккан иде ул чакта: «...Ике-өч елдан синең шикелле инсафлы, тәүфыйклы егет яучы җибәрсә...» Җибәрер, җибәрер Габдрахман, ә көтәргә икән — өч, дүрт, биш ел көтәргә әзер ул! «Балакаебызның бер генә моңы бар — җилбәзәгрәк шул әз генә». Шулаерак шул, Сөннәтче бабай. Әнә, ни кыланды бит оныгың Исрафил мөгаллим китеп барганда! Әлбәттә, күңеленең күбәләк чагы, чәчәктән-чәчәккә куныш уйнар вакыты. Бу сабыйлык чире үтәр, Фатыйманың да күңеле утырыр. Ә Габдрахман көтәр, көтәр... Сабырлыгы җитәрлек мөгаллим егетнең.

...Рәхәт уйларга чумып кайта-кайта, юл сизелми дә калган. Мираска алып төшүче Сөзәк үргә җиткәч, Габдрахман атына чөңгереп, дилбегәсен каккалап алды. Туры бия юыртып китте. Авыз тутырып кычкырып җырлаганны җене сөймәгән мөгаллим егет, үз гомерендә беренче тапкыр, өрән салып, илһамланып, кайчандыр Тау ягында ишеткән җырны сузып җибәрде:

Каен ауган, карлар яуган
Барасы юлларыма;

Әйләнерсен-тулганырсың —
Керерсен кулларыма...

* * *

...Еллар арты еллар үтте. Сөннәтче бабай кызы Фатыймага өйләнгән Габдрахман Мираста төпләнеп калды. Башта алар Габдрахманның фатирында, Гөлбикә карчыкта яшәп тордылар. Фатыйманың әбисе-бабасы үзләрендә торырга ни чакырмасыннар — кияү кеше риза булмады. Авыл жирендә егет кешенең йортка керүен өнәмиләр. Беренче кызлары Алия дөньяга килгәч кенә, карт белән карчыкның гозерен искә алып, Шәрифулла йортына кайттылар.

Әби белән бабай морадына иреште: аларның йөрәк парәсенә Ходай Тәгалә инсафлы, тәүфыйклы кияү насыйп итте. Фатыйманың беренче баласы Алияне генә түгел, ике елдан соң дөньяга килгән уллары Хәнәфине дә тезләренә утыртып, тупылдатып, сөяргә насыйп булды аларга.

Әмма дөнья дигәннәре фани. Сөннәтче бабай белән карчыгы Хәерниса әбинең каберләре өстендә тәүфыйклы кияүләре үз кулы белән утырткан каеннар да тәртә юанлыгы булып киләләр инде. Хәнәфиләренә өч яшь тулган җәйдә алар берсе артыннан берсе гүр иясе булдылар. Пар күгәрченнәр шикелле гөрләшеп кенә яшәгән бу бәндәләр, Аллага шөкрана итеп, дөньяга бик разый булып, җан газабы күрмичә, җиңел үлем белән генә дөнья куйдылар. Изге җаннардан булганнардыр шул...

Риясыз, игелекле Габдрахман тиз арада Мирас халкына үз кешегә әйләнде. Киңәш-табыш итәргә килгән агайларга якты чырай күрсәтеп, хәленнән килгән кадәресе ярдәм итәргә тырышты: һәртөрле сәвитләргә гаризалар язды, Донбасс шахталарында күмер чапкан Сәләхетдин, Хисаметдиннәргә чук-чук сәлам хатлары юллады.

Җәмәгать эшләреннән дә читләшмәде Габдрахман. Утызынчы еллар башында авыл җиренә колхозлашу хәрәкәте килгәч: «Сез бәхетле көнегезгә бары тик күмәкләшеп яшәгәндә генә ирешәчәксез», — дип, авыл агайларын колхозга керергә агитлады. Кичләрен мәктәптә, крәчин лампалары яктысында, авыл наданнарын укытты. Габдрахман мөгаллим элегрәк иске мәктәпне, аннары янган мәчет урынына салынган клуб бинасын шыплап тутырган апайларга-агайларга, һәр елның 23 февралендә, данлыклы Кызыл Армиябезнең Пыскуф белән Нарва тирәсендә күрсәткән тиңдәшсез батырлыклары турында сөйли, 1 Май гарәфәсендә тоткан нотыгын ул гадәттә: «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» — дигән өндәмә белән тәгәлли иде. Ходайның бирмеш 7 ноябрь көнендә кызыл әләмнәр күтәреп, һәр урам чатына туктап революцион азаннар кычкырып йөргән колонна башында да укытучы Габдрахман була иде. Авылны әйләнеп клуб янына кайткач, яшел ылыс, кызыл комачлар белән бизәлгән трибунага менеп, Бөек Үктәбер шәрәфенә ялкынлы лозунглар әйтеп төшүне дә үзенең вазыйфасы дип саный иде мәктәп мөдире.

Күндәм, итагатьле холкы белән Габдрахман сәвит, колхоз башлыкларына да ярау булды. Аның укытучы, мәктәп мөдире буларак та, үзен-үзе аямыйча, яхшы нәтиҗәләр күрсәтеп эшләгәнен Ташлыкның мәгариф әһелләре дә беләләр, хөрмәт итәләр иде.

Мираста укыту дәверендә аңа ике мәртәбә хәреф алыштыру әкәмәтен дә кичерергә туры килде. Башта гарәп хәрефеннән латин хәрефенә, латиннан — урысныкына күчтеләр. Болай кеше башын бутау нәрсәгә кирәк булганын укытучы үзе дә аңлый алмады, моны аңлатучы кеше дә табылмады...

Шулай да бәхетле, ниһаять — бәхетле кеше иде, Габдрахман! Сөннәтче бабайдан мираска калган йорт-җир, каралты-кура бөтен, төзек. Беренче мәхәббәте, сөеп-яратып өйләнгән, аның өчен дөньяда иң чибәр

иң сылу булган Фатыймасы ана ике малай, ике кыз китерде. Фатыйманың элеккеге җилбәзәклеген дә инде күптән җилләр алды. Эшкә уңган, пөхтә, пакъ яшь хатын дәртен, җанкөчен балаларына, балаларының әтисенә багышлады.

Сәләтле генә булган Фатыйма тиз арада латин хәрефләре белән укырга-язарга өйрәнде. Колхоз авылда балалар бакчасы ачкач, шунда тәрбияче булып эшли башлады.

Тумыштан зәвыклы булган укытучы хатыны, өстенә ни кисә шул килешеп торса да, киемгә талымлы булды, хәленнән килгән кадәр шәһәрчәрәк киенергә тырышты. Аның таләбе буенча ире Габдрахман да, Исрафил мөгаллим шикелле, үз иңенә-буена таман кибет кәчтүн-чалбары, эшләпә киеп, муенына галстук тагып йөри башлады.

Исрафил мөгаллим димәктән, ул шәһәргә укырга киткәч хәбәрләшеп тормасалар да, тормышы юлында Хозыр-Ильяс булган егетне Габдрахман бик еш исенә төшерә иде. Байтак еллар узгач, алар тагын бер мәртәбә очраштылар. Казанда, тимер юл вокзалында. Габдрахман дачный поездлан төшеп, вокзалга кереп барганда, җыйнак кына чемодан тотып, ашыгып вокзалдан чыгып баручы Исрафил белән капма-каршы булды.

— Исрафил!!!

— Габдрахман?!

Иске дуслар кочаклашып күрештеләр. Исрафил утырасы поезд янына бара-бара, аның вагоны янында туктап ике-өч минут кына сөйләшеп алдылар. Күбрәк Габдрахман сорашты. Исрафилнең Ленинградка барышы икән, шәһәрнең борынгы татар тарихы, әдәбияты, мәдәнияте буенча чыганакларга бай китапханәләрендә казынырга икән исәбе... Әйе, моннан өч ел элек кандидатлык диссертациясе яклаган. Юк, өйләнмәгән әле, вакыты җитми икән ул нәрсә турында уйларга.

Габдрахман каршында инде яшь, чибәр, романтик егет түгел, басынкы, арган кыяфәтле галим ир тора иде. Ул сулыга төшкән, күз карашлары да җитди, уйчан. Поезд кузгалгач, Исрафил тамбурга менеп басты, нәкъ Мирастагыча итеп, матур ак тешләрен күрсәтеп елмайды да, дустанә кул изәп вагонга кереп китте.

Теге чакта — Ташлык станциясында шикелле, — аларны тагы поезд аерды. Бу юлы инде мәңгегә...

* * *

Икътисади яктан еллар авыр булса да, укытучы гаиләсе мохтаҗлык күрмиче, ярыйсы гына яшәде. Тырыш, эшкә өлгер Фатыйма йорт җанлы әбисенең калган мал-туарны бетермәскә тырышты, сыер, сарыклар, тавык, каз-үрдәкләр асрады.

Шәрифулла бабасы нигезендә, Габдрахманның берсеннән-берсе матур, сәламәт балалары тәгәрәшеп үстеләр. Мәктәптән кайтып керүгә, кечерәкләре йөгерешеп килеп, әтиләренең ботларыннан кочып алып, берсен-берсе бүлеп чөкердәшергә тотыналар. Кухня яктан, елмаеп, яшь, чибәр хатыны чыгып, өстәлгә аш хәзерли башлый.

Авыл җирендә үзенне бәхетле сизәр өчен тагын нәрсә кирәк? Бәхетле иделәр Габдрахман белән Фатыйма!

Әмма...

Хәвефле, фаҗигале 1937—38 еллар килеп җитте. Үз халкыннан шүрләп, Мәскәү хөҗрәсендә бикләнеп утырган Чулак Зәнки, Бөек Империясендә кодрәте йомшара барганын сизеп, ил өстенә үзенең опричникларын өсләтте. Надан булса да, Олуг Залимгә шул нәрсә мәгълүм иде: бу киң күңелле, чыдам, күндәм халык, азамат ирләрен әледән-әле чүпләп аттырып, астырып, зинданга ташлатып, җанына курку салып торганда гына килмешәк Хакимне санлаячак, Тәңрегә санап, аның һәр кылган золымын «Афәрин!», «Ләббәйкә!» — дип кабул итеп торачак.

Илне иңләгән кара афәт, район үзәге Башлыкны өтеп, имгәтеп узып, урман артында посып утырган Гөберчәк, Мирас тирәләренә дә килеп җитте. Авыл сәвите һәм колхоз рәисләрен, укытучыларны, әлегә исән-имин калган муллаларны утырта башладылар. Алар арасында Габдрахманның иске танышлары да бар иде. Кайчандыр бергә курсларда укып йөргән Ташлы Кичү мөгаллиме Хафизны, игелекле, дөньяви вәгазьләре белән үз мәхәлләсендә генә түгел, бөтен тирә якта абруйлы Гөберчәк мулласын алдылар. Зур укымышлы, мәгърифәтле, күп төрле һөнәр иясе, муллалыгын ташларга мәҗбүр булгач, үзенең ишле гаиләсен инде күп еллар хәләл крәстиян хезмәте белән туендырып яшәгән бу мөхтәрәм кеше белән Габдрахман әле шәкертлек елларыннан ук таныш иделәр.

...Габдрахманны турыдан-туры мәктәбендә алдылар. Декабрь азагы иде. Гадәте буенча, ул дәрестән соң класста калып, дүртенчеләрнең арифметикадан контроль эшләрен тикшереп утыра иде. Укытучыларның мәшәкатьле чагы — чирек йомгаклар вакыт җитеп килә иде.

Ишектән йолдызлы бүрек, кыска тун кигән, бил каешларына наган аскан ике ГПУ кешесе килеп керде. Алар артыннан авыл сәвите рәисе Бүтәкә Әхәт тә пәйда булды.

— Шагиахметов Габдрахман сез буласызмы? — дип сорады ГПУ кешеләренең өлкәнрәк күренгәне.

Каушап калган Габдрахман телгә килгәнче, аның өчен, наганлы кешеләр алдында ялагайланып, Бүтәкә Әхәт җавап бирде:

— Әйе, әйе, Шәяхмәтеф Гаптрахман шушы кеше, шушы кеше була...

«Шушы кеше!..» Әйтерсең лә алар орынып торган күршеләр түгел, әйтерсең лә карсак Әхәтнең вак бәрәнге шикелле вактан-вак алтымы-җидеме баласын укытып чыгарган, унбиш ел буена бөтен Мирас кешеләре алдында йөзе ак булган мөгтабәр мөгаллим Габдрахман түгел, бары: «Шушы кеше» генә...

Әхәт абзый, бичара бәндә, нәкъ ике атнадан соң наганлы егетләр аның үзен дә алып китәселәрен, шул китүдән балаларын, аларның әниләре Хәмдениса хәләлен дә инде яңадан беркайчан да күрмәсен башына да китермәгәндер шул ул чакта...

Фәкыйрьлектә үскән, Ташлыктан да ары дөнья барлыгын белмичә илле биш яшенә җиткән, ишле балаларына якты, мул тормыш вәгъдә иткән өчен генә сәвиткә ялагайланып йөргән бу көчсез, зәгыйфь кеше, үзенең гаебе нәрсәдә булганын да белмичә, Җирән Мәлгунь зинданнарында череп юкка чыккан миллионнарның иң мәхлукларыннан берсе булгандыр.

...Габдрахманны Ташлыктан Казанга озаттылар. Ике наганлы кеше уртасында утырып поездда барганда Исрафилдан ишеткән шигырь исенә төште:

Башйортарның әллә туйдым дигәне бар? —
Бу язмышны кемнең әле җиңгәне бар?
Йотылмадым бит әле дип тынычланма:
Сиңа бары нәүбәт кенә җитәсе бар!..

Юк, Габдрахманның башын йотмадылар. Алып киткәннәренә өч атна дигәндә ул өенә әйләнеп кайтты.

Өч атна ут йотып яшәгән Фатыйма ишек ачкач ирен танымый торды: йончыган, суырылган, картайган Габдрахман карты, озак авырудан соң яңа гына торып аягына баскан кешене хәтерләтә иде. Әтиләре кайтканга шатланган балалары да, аның кыяфәтен күреп, нәүмизләнеп калдылар.

Мунчада иренең кан сауган кул башларын, тезгә кадәр шешкән аякларын күреп, Фатыйма тетрәнеп китте:

— Нәрсә... анда сине... кыйнадылармы әллә?

— Син сорама, мин әйтмим... Зинһар, шулай килешик, Фатыйма...

Бер-ике атнадан Габдрахманга хәл керде. Ләкин ул өйдәгеләр белән аз сөйләшә, еш кына күзләрен бер ноктага төбәп утыра, йә берөзлексез ишекле-түрле йөреп гажизләнә торган булды.

Беркөн Фатыйма иренең шулай җан газабы чигеп йөргәнен күреп, түзә алмыйча елап:

— Габдрахман җаным, сиңа ниләр булды? Нигә син сөйләшмисен? Нишләттеләр сине анда? Нәрсә талый синең җаныңны? Нинди ауруларың бар синең? — дип өзгәләнде.

— Юк, Фатыймам, мин инде сәламәт кеше диярлек, тик менә үземә урын табалмыйчы, җаным ургый минем.— Габдрахман килеп хатынының җилкәләреннән кочып алды.— Ә син елавыңнан тукта, әнисе, югыйсә минем күңелем йомшак, парлап елап җибәрербез дә, аннан безне кем юатыр? — дигән булып шаяртты.

Шул арада төпчекләре Хәлим, әтисенең ботын кочаклап, чалбар балакларыннан тарткалап: «Абдрахан, Абдрахан, тәстә булды сиа. Абдрахан?» — дип тинтерәтә башлагач, «Абдрахан» елмаеп, улын түшәмгә кадәр чөеп «үчтеки-үчтеки» иттерә башлады. Сабыйның бәхетле чыркылдавы әти кешене газаплы уйларыннан арындырып җибәрде. Кайтканнан бирле беренче мәртәбә әтиләренең күтәренке күңеле гаиләсенә дә шатлык китерде.

Ташлыкка барып кайткач, Габдрахман яңадан үз классларында укыта башлады. Айдан артык юкка чыгып торган, ябыккан, чырае качкан укытучыларын балалар сагаеп, сәерсенеп каршы алдылар.

Авыл агайлары да «тегендә» булып кайткан мөгаллимнең шактый үзгәргәнен сизми калмадылар — картаебрак киткән шикелле, кешеләрдән читләшергә тырыша сыман. Элек алай түгел иде кебек. Кәефсез йөри Габдрахман мөгаллим, кәефсез. Әллә авыру инде...

Әйе, авырый укытучы Габдрахман, бик каты авырый. Ул «тегеннән» гомерлек җан чире эләктереп кайтты...

Вөҗдан газабы дигән чир иде ул.

* * *

Кырык икенче елның октябрь урталары булдымы икән, Габдрахман абый соңгы дәрес беткәч кенә әйтеп куйды: «Ни... балалар, мин иртәгә сугышка китәм... Яңа укытучы килгәнче сезне Мәрзия апагыз укытып торыр инде... Хәзер өйләрегезгә кайтыгыз, мин иртәгә иртән кереп чыгырмын әле класска...»

Икенче көнне иртән Габдрахман абый өстәле артына кереп утырды. Чиста итеп кырынган, өстендә бераз кыршылган көзге пальто, аягында күн итекләр. Ул ничектер кечерәеп, бетешеп калган шикелле...

Класста тынлык. Укучыларның хәсрәт мөлдерәгән күзләре укытучыларына төбәлгән. Габдрахман абыйлары аларны берәм-берәм йөрәгеннән үткәреп утыра: Габдрахман... Хафизә... Җәгъфәр... Зөлфия... Касыйм... Ясәви... Фирдәүсә... Миннулла... Гәрәй... Хөрмәт... Шушы минутларда тагы да кадерле, газиз булып күренгән укучыларының җанлы сурәтләрен күңеленә уеп калдырасы килә аның. Урынсыз каты бәрелеп, бу гөнаһсыз бәндәләрнең хәтерен калдырмадыммы, рәнҗетмәдемме икән? Юктыр, ахры...

«Йә, балалар, сау булып торыгыз. Тәртипле булыгыз, яхшы укырга тырышыгыз. Син, Габдуллаҗан, артык юньсезләнмә инде. Хафизә син дә... Сез, балалар, анда урамга төшеп йөрмәгез инде. Йә, ярар, әлегә сау булып торыгыз!..» — Габдрахман абыйның тавышы калтырап куйды. Ишеккә килеп җиткәч, тагы нәрсәдер әйтәсе сүзе калган шикелле, бераз тоткарланып, тагын укучыларын, класс бүлмәсен күзеннән кичерде дә, чыгып китте. Кызлар парталарына капланып елый башладылар. Каушап, юашланып калган малайлар, рөхсәт булмаса да, урамга чыгып, яраткан укытучыларын басу капкасына кадәр озата бардылар...

Габдрахман абыйлары киткәч, икенче, дүртенче классларны атна-ун көн тирәсе Мәрзия апа укытып азапланды. Дүрт класска бер үзе, ике ишек арасында йөгереп йөрде, кая ди инде ул юньле дәрес бирү, кая ди ул укучыларны санлату! Берәзлексез чыр-чыр кычкырып торгач, сүзенең дә базарлыгы калмады. Иң гаҗәбе шул булды — Габдуллаҗан юньсезләнмәде генә түгел, класста тәртип саклауда Мәрзия апаның ярдәмчесенә әверелде. Класста Габдуллаҗаннан шурлиләр, хәтта кара-каршы тотып сугышырга күп сорамаган ирҗәнкә Хафизә дә коерыгын кысты.

Бер көн иртән мәктәпкә килсәләр, класста, өстәл артында тәмәке тартып, шинель кигән бер кеше утыра. Дәрес башланыр алдыннан Мәрзия апа кереп: «Укучылар, менә бу абыегыз сезнең яңа укытучыгыз була инде», — дип әйтеп чыгып китте.

Абый кеше торып басты, папирос төпчеген бик оста чиртеп, мич авызына очыртты да шинелен чишеп җибәрде, галифе чалбар кесәсеннән, коедан чиләк алган шикелле чылбырыннан өстерәп, өстәлгә куян савыты кадәрле кесә сәгате чыгарып салды. Коридорда Бибинур тәтә дәрескә кыңгырау шалтыратты. Шинельле абый дәрес башларга ашыкмады, ул нидер көтә иде. Инде һәрвакыттагыча беренче дәрескә соңарып килә торган Гәрәй дә, рөхсәт сорап, урынына кереп утырды (ул атлар караучы әнисе кәнүшнидә бер кат эш бетереп кайтканчы өйдә бәбиләр карап тора); инде коридорда тәмәкесен тартып бетереп, Тити колгасы Габдуллаҗан да, гадәтчә рөхсәт-мазар сорап тормыйчы, класска кереп урынына — арткы рәткә узды...

«Да-а-а, сездә дистиплина аксаган! — Яңа укытучы, ниһаять, телгә килде. — Сез, понимаешь, без десяти восемь как штык казармада — отставить! — класста булырга тиеш! Нет дистиплины — нет армии! Бу мәктәптә дә шулай булырга тиеш, понимаешь! Беренче чиратта — дисциплина! Ну, ладно, давайте танышып алыйк. Минем фамилиям — Адгамов, сезгә күрше Солы авылы гражданы. Диствительныйда — помписаря штаббата, сугышта отделком, тоест отделение командиры булган кеше. Фашист пулясы аяктан екмаган булса, минем урыным, канишны, фронтта булырга тиеш иде...»

Отделком абый, дулкынланып китеп, класс буйлап арлы-бирле йөренә башлады. Чынлап та, сул аягына аксый, кәкре башлы таякка таянып йөри икән. Класс авызын ачып, хәйран калып тыңлап утыра. Колак ишетмәгән сүзләр: помписаря... штаббата... Бар икән күрәселәр!

— Йә, нинди вопросларыгыз бар лично миңа карата? — ди Адгамов абый.

— Абый, «помписары», «штаббата» — ниткән сүзләр алар? — Бу арткы рәттән, Габдуллаҗан тавышы.

— Вот маладис! Шулай кирәк, штобы аңлашылмаган бер нәрсә дә калмасын безнең арада! Малай, синең фамилияң ничек?

— Әхмәтҗанов...

— Помписаря, укучы Ахметҗанов, ул помощник писаря батальонного штаба дигән сүз була, тоест штабта язу-сызу эшләрен алып баручының ярдәмчесе. Писарь, вопшем, командирдан кала батальонда икенче кеше.

— Алайса, абый, сез батальонда өченче кеше булгансыз икән...

— Так точно! Маладис! Кем әле синең фамилияң? Ахметҗанов? Маладис, Ахметҗанов, соображаешь, понимаешь! Ну, хәзер личный состав белән танышып алыйк, так сказать...

Адгамов, өстәл артына утырып, класс журналларын ача. Беренче фамилияне дә әйтергә өлгерми:

— А-а-а! Абый!!!

Кем булсын инде, шул ирҗәнкә Хафизә кычкыра.

— Эй, син, кызыл чәчле кыз, нәрсә акырасың, ананны суялармы әллә?! — Адгамов абый урындыктан сикереп тора. — Минем нервыларның болай да рәте калмаган, понимаешь, нигә акырасың?

— Ә нәрсә Тити колгасы чәчне умыра!..

Адгамов класс буйлап титаклап йөрен башлый.

— Сез яхшы булсагыз, дистиплиналы булсагыз — мин ун мәртәбә яхшы! Сез начар икән — мин ул мәртәбә начар!

«Помписаря», кызып китеп, таянып йөргән таягы белән өстәлгә китереп суга. Өстәлдәге кара савыты, һавада мәтәлчек атып, янадан өстәлгә төшеп утыра (ярый әле карасы түгелә торган савыт түгел). Класс үлеп кала. Икенче класс отличнигы Хәмитова астыннан «чишмә» саркып чыгып, челтерәп идәнгә ага. Дүртенче класс укучысы Җиһаншин авызын ачып, тораташ булып каткан, йөзендә кан, тәнендә җан әсәре калмаган. Форсаттан файдаланып, рәхәтләнә бер әрсез чебен малайның колакларындагы, борын асларындагы мул азыкка!

— Анда кемнең нәрсәсе түгелде? — Класстагы үлем тынлыгын беренче булып яңа укытучы үзе боза. — Ничего, тәнәфестә сөртеп алырсың. Ә син малай — бас! — Адгамов таягын инде Җиһанга төбәгән, таяк башындагы резина уймак малайның ачык авызына терәлгән диярлек. — Бас, малай! Фамилияң ничек синең?

Җиһаншинның торып басарлык та, җавап бирерлек тә хәле калмаган, Җиһаншин — җанлы мәет...

— Дүртенче класс укучысы Җиһаншин, укуы — «өчкә», дистиплинасы — «биш»кә! — Үлә башлаган Җиһаншин өчен класста берләнбер исән калган Габдуллаҗан җавап бирә.

— За дистиплированные укучы Зиганшинга объявляю благодарныс! Биш минут карап тордым — талый малайны бер нахальный чебен, издивается итә малайдан, панимаешь, а Зиганшин — нуль внимания! Патамушто ул дәрестә утыра, патамушты дистиплиналы укучы!

Отделком абый агитлавын дәвам итә:

— Сездән тимер дистиплина и яхшы уку сорала! Сез фронтта кан койган әтиләрегезгә, абыйларыгызга ничек ярдәм итә аласыз? Яхшы укуыгыз белән! Сезнең һәр «биш»легез — Гитлер йөрәгенә пуля!

— Ә һәр «бер»лебез — Сталин йөрәгенә пуля! Шулаймы Адгамов абый?

— Так точно, Ахметҗанов, һәр берлегез иптәш Сталин йөрәгенә... Отставить!!! Син, Ахметҗанов, мине провокацияләмә, понимаешь, сүзеңнең кая барганын чамалап сөйләш, понимаешь. А то, понимаешь!...

Адгамов абыйның каһәреннән Ахметҗановны Бибинур тәтәнең кынгыравы коткарды.

— Бу нинди звонок тагы? Ә, дәрес бетте мени? Минем бит план үтәлми калды. Ну, черт с ним, политбеседа тоже кирәк нәрсә...

Адгамов абый әллә ни арада авызына папиросын кабып өлгергән, кесәләренә суккалап шырпысын эзли.

— Абый, син азапланып кәнсәләргә төшеп йөрмә, рәхәтләнеп мич авызына утырып тарт, мин хәзер моржа юшкәсен ачып төшәм.

— Отставить! Синең, малай, фамилияң ничек?

— Гайфиев, абый... Җәгъфәр исемле...

— Ничәнче класста укыйсың?

— Икенчедә, абый...

— Менә нәрсә, укучы Гайфиев, син совет мәктәбендә икенче ел белем аласың, да бит? Нужели сине өйрәтмәделәр — совет мәктәбе укучылары үзләренең укытучыларына кем дип обрашаться итәргә тиеш?

— «Сез» дип, абый... «Син» дип мин сине... юк, сезне, якын итеп кенә әйтүем ие, абый...

Җәгъфәр — тиен баласыдай йомыры күзле, хәрәкәтчән, сөйкемле малай, киң күңелле, шәфкатьле, игелекле җан. Укуын, укытучыларын, классташларын, укыган мәктәбен яратып укый. Бөтен фәннәргә караганда бигрәк тә арифметиканы ярата Җәгъфәр. Көн саен, дәрес саен гел арифметиканы гына укытсалар да бер сүз әйтмәс иде. Ул инде өченчедә укыган Җәүдәт абыйсына да чыкмый азаплаган мәсьәләләрен чишеп бирә торган терчә малай.

Менә хәзер дә Җәгъфәр укытучы Адгамов абыйсы тирәсендә бөтерелә, урындыгын мич алдына китереп куя: «Тартыгыз, абый, рәхәтләнеп, мич алдына утырып».

Мич алдында утырган Адгамовны малайлар чолгап алган.

— Абый, сугышка кадәр сез кайсы авылда укыткан идегез?

— Мин, укучы малайлар, вопше-то полныстый укытучы түгел. Диствительныйга киткәнче мин калхузда ветфельшер булып эшләгән кеше, мал врачы, значит. Минем образование дә җиде класс кына бит. Но минем почерк, тоест язу, бик шәп. Шуңа күрә дә мин действительныйда помписаря булып служить иттем инде.— Адгамов абый күбрәк Габдуллаҗанга карап сөйли. Габдуллаҗан — лилипутлар арасында Гулливер, инде борын астында мыек тибә башлаган егет малай.

— Действительныйда вакытта Ташлык роносында секретарь булып эшләүче бер мәткә белән хат алышып торадырыем...— Бу урында Адгамов абый бик мәгънәле итеп Габдуллаҗанга күз кысып ала.— Ранный булып кайткач, менә шул мәткә агитировать итте инде мәктәпкә. Давай, ди, язуың да матур синең, ди, мәктәпләрдә хәзер ир заты калмады, мәктәпләргә җен иялнә башлады, ди, давай, ди Мирас мәктәбенә, анда бер укытучы хатынга берүзенә дүрт класс, ди.— Адгамов папирос төпчеген мичкә ыргытып, яңасын кабыза.— Ну, тагы нинди вопросларыгыз бар, укучы малайлар?

— Абый, сугышта гел урысча гына сөйләшеп сугышалармы?

— Асновном русча, канишне, кайчакларда кайбер сүзләрне татарча да ычкындыргалыйсың... Вопше, биш елга якын чи урыс арасында йөреп, татарчамны да онытып бетерә язганмын, понимаешь, ярый әле Казанда госпитальдә ятканда бер медсестра кыз татарчамны деңгә кертте, ул кыз үзе татар авылыннан булып чыкты.

— Абый, сез ничек яраландыгыз?

Адгамов, тәмәкесен тирән итеп суырып, бер мәлгә тынып кала да сөйләп китә:

— Отделениемне атакага алып барганда булды ул хәл. Илле метр да йөгереп үтмәгәнмендер отделением башында, нәрсәдер бот төбенә китереп бәрде. Егылдым. Тормакчы булып талпынып карыйм — кая ул! Ә минем башта кара уй — отделением командирсыз калды! Ә командирсыз солдатлар — көтүчесез калган сарык көтүе инде ул. Ятам. Чалбар эче тулы кан. Санитарлар тиз килеп җитмәсәләр, эшләр начар иде. Полевой лазаретта, аннан Казанда госпитальда дүрт ай яттым. Ярый әле пуля азрак кына читкәрәк эләккән, а то...

— Нәрсә абый, а то — кыхх!..— Габдуллаҗан чалбар изүе тирәсендә бармаклары белән, чакма чаккандагы шикелле, кискен хәрәкәт ясап күрсәтә.

— Вот именно!.. Минем рана, малайлар, бик хитрый төштә. Кызлар югында бер ачып күрсәтермен әле, дистиплинагыз яхшы булса...

Әңгәмәне бозып, кыңгырау шалтырый.

— По местам, укучы малайлар и кызлар!..

Малайлар: «Яңа укытучы абый алай түзә алмаслык начар кеше түгел, ахрысы»,— дигән фикергә килеп, парталарына таралыштылар...

Икенче көнне дә дәресне Адгамов абый «личный состав»ны тикшерүдән башлады:

— Ахметжанов?.

— Так точно!

— Бадыйгов?..

— Монда...

— Гарифуллин? Гарифуллин Гәрәй?..

Нәкъ шул чакта ишектән Гәрәй атылып килеп керә:

— Мин, абый!.. Тактага чыгаргамы, абый? Хәзер абый...— Каты йөгерүдән Гәрәйнең сулуы кабынган.— Хәзер, абый... Әзерәк кенә аяк-

ларыма җан керсен...— Гәрәй букчасын партасы өстенә ташлап, трык-трык сикерә, бии башлый, иржәнкә Хафизә «чабата» көенә такмак әйтеп тора:

Тәлә-ли-ли-тә-тә,
Тәлә-ли-ли-тә-тә...

Класс моңа күнеккән инде. Адгамов абый гына бу әкәмәткә исе китеп карап тора...

Гәрәй өчен ел фасыллары юк. Җәен, кышын, яңгыр булсын, буран булсын — Гәрәй мәктәпкә яланаяк, күлмәкчән генә йөри. Шартлаган суык көннәрдә генә дәрес калдыра.

— Син нәрсә, Гарифуллин, якты дөньядан туйдыңмы әллә? Яланаяк, ялан өс, понимаешь! — Адгамов абый төсенә-кыяфәтенә кырыслык чыгарып, Гәрәйне шелтәли башлый:— Атаң-анаң нәрсә карый, понимаешь!

— Без, абый, бер әнигә аяксыздан-күтсез җиде бала, мәктәптә һәр класс саен бер малай утыра, тагын өйдә өч малай акырышып кала әле, безгә ничек барыбызга да чабата, бишмәт тѳткәрмәк кирәк. Мин олы малай, мин түзәргә тиеш инде...

Гәрәйнең күгәрчен тәпие шикелле кызарган аякларына инде җылы кергән, ул инде парта артында утыра, букчасыннан дәфтәр, каләмнәрен алып, дәрескә әзерләнә.

— Значит, син олы малай семьяда, Гарифуллин?

— Шулай булып чыга инде абый, дүртенчедә булгач...

— Атаң сугыштамы?

— Сугышта булмый кайда булсын инде...

— Син мәктәпкә ерактан йөрисеңме, Гарифуллин? — Адгамов абыйга Гәрәйнең фидакарьлеге нык тәэсир итте бугай, ул инде җикеренми, тавышы да мәрхәмәтле, йомшак.

— Югары очтан. Һи, абый, бер өйрәнгәч бернәрсәсе дә юк аның: өйдән чыгуга элдертәсең дә, шул хут белән мәктәпкә дә барып керәсең. Бер кызып алгач аяк карны да, салкынны да тоймый ул.

— Малай чакта мин үзем дә, Гарифуллин, кыш көннәрендә баскыч башыннан чаптырырга яланаяк кына чыга торган идем анысы. Бу, канишне, башка эпизод. Но югары очтан мәктәпкә кадәр, кардан яланаяк — бр-р! Ладно, Гарифуллин, моның бер-бер чарасын табарбыз. Совет мәктәбе укучысына мәктәпкә кыш көне яланаяк йөрү не допустимо, понимаешь. Ә атаң синең, Гарифуллин, прямо ворошиловский стрелок, аткан берсен уңга тиергән, молодец, ха-ха-ха!...

Журнал буенча икенчеләрне дә барлап чыккач, Адгамов, ниһаять, дәрес бирә башлый.

«Икенче класс, внимание! Дәреснең темасы — «Астылы-өстеле язу ысулы белән ике урынлы саннар эчендә кушу гамәле». Дәреснең темасын укытучы тактага да язып куя. Адгамовның почеркы чынлап та «шәп» икән: һәр хәрефе мөгез, колак чыгарып, янсә койрык тагып бизәлгән хәрефле түгел, гел шайтан малайлары!

Укытучы, тактада бер-ике мисал өстендә янача кушу ысулын аңлаткач, икенчеләргә мөстәкыйль эш биреп, дүртенчеләргә күчә:

«Дүртенчеләр, внимание! Китабыгыздан СССРда ташкүмер ятмаларының байлыгы турында эчтән генә укырга, берегез кычкырып сөйләп бирер».

Все!... Авыр эш башкарып чыккач, Адгамов папироска сузыла, ләкин авызына капкач кире пачкасына салып куя: тәнәфескә кадәр как-нибудь түзәргә кирәк...

— Абый, абый! Ике ике урынлы сан кушканыем, өч урынлы сан килде дә чыкты!

— Ә нигә аңа шаккаттың? Фамилияң ничек әле синең, малай?.. Гайнетдинов? Ә нигә аңа исең китте, Гайнетдинов?

— Дөрес ике урынлы саннар эчендә генә кушу булгач әйтүем...

— Куша бир, Гайнетдинов, куша бир! Өч урынлы сан чыкмагае, биш урынлы сан чыксын, результат кына дөрес булсын!

— Абый, абый дим! — Җәгъфәр, укытучы абыйсының игътибарын җәлеп итәр өчен, урыныннан бер сикереп тора, бер утыра, түземсезләнеп күтәргән кулын болгый.

— Йә, нигә кыбырсыйсың, Гайфиев, ни әйтер сүзең бар?

— Абый, абый дим! Әгәр дә кушасы саннар икесе дә илледән ким булса, кушкач та ике урынлы сан килеп чыга...

— Ну баш синдә, Гайфиев, ну ба-а-аш! — ди, укытучы Адгамов, үзе бераз уйланып торганнан соң.— Бик тырышып укысаң, синнән арифметика профессоры чыгып куюы бар.

— Адгамов абый! Әгәр астагысын өскә, өстәгесен аска әйләндереп кушсаң, барыберме?

— Ну надан син, Хисматов, чи надан! Буең үскән, акылың үсмәгән, панимаешь. Нишләп барыбер булсын ди инде. Например, синең атаң белән анаң, панимаеш... Отставить! Бу удачный пример булмады... Вопшем, юк белән катырма минем башны, Хисматов, халачникта ничек язылган, шулай куша бир!

Дәрес ахырында укытучы абый икенчеләргә өй эше бирә: «Тактага язылган нумерларны эшләп килергә. Бу военный приказ, эшләми килгәннәрне строго наказайт итәрмен!»

Адгамов абыйга өйгә биргәннәрне эшләми килүчеләрне «строго наказайт» итәргә дә, кызлар югында малайларга теге «хитрый» урындагы ранасын күрсәтергә дә насыйп булмаган икән. Солыга кайтышлый ул таеп егылган да, ярасы ачылган. Аны янадан Казан госпиталенә салганнар. Бу хәбәрне Солыдан Мәрзия апа алып кайтты. Мәрзия апа тагы дүртенче класс укучысы Гарифуллин Гәрәйгә бер төенчек тапшырды. Төенчектән олтан салынган киез итек, бераз киелгән бишмәт, бүрек килеп чыкты. Бишмәт кесәсендә язу да бар икән: «Укучы Гарифуллин! Ташла дуракавалять итүеңне, понимаешь. Сиңа үземнең малай чактагы зимний обмундированиемне җибәрәм. Киеп йөр на здоровье. Адгамов».

Тагын Мәрзия апаның берүзенә дүрт класс калды. Ике атнадан соң яңа укытучы китерделәр. Ул Тащлык педагогия техникумында укучы Габдрахман абый кызы Алия булып чыкты. Район мәгариф бүлеге аны, өченче курс студенткасын, вакытлыча укуын бүлдереп, туган авылы Мираска укытучы итеп җибәргән. Инде уку елы беткәнче, икенче-дүртенче классларны Алия апалары укытты...

* * *

Габдрахман Сталинград фронтына эләкте. Тарихта тиңе булмаган оборона сугышлары алып барган Сталинград шәһәренең нәкъ үзенә. Бер атна-ун көн өйрәткәннән соң красноармеец Шагиахметовны пулемет расчетына икенче номер итеп билгеләделәр.

Ноябрь башлары иде. Габдрахман үзенең командиры, 18-19 яшьлек Василий Кузнецов атлы егет белән иң беренче мәртәбә позициягә чыкты. Алар төнлә белән ике урам чатындагы бер җимерек таш йортның ярым подвалында урнашып-ныгып алдылар. Пулеметчыларның сугышчан бурычы — алдагы мәйдан аркылы, Волгага таба төшә торган урамга дошманның тере көчләрен үткәрмәү. Приказ — үлгәнче торырга!

Иртән фашистлар беренче атакаларына ташландылар. Алдан танклар килә, алар артыннан — пехота. Танкларны уздырып җибәреп, пулеметчылар, аны-моны абайламый, бөтен буйларына басып йөгергән фрицларга ут яудыра башладылар. Каршы яктагы йорт подвалы тәрәзәсеннән дә пулемет сиптерә иде. Ут кайчысына эләккән фашист пехотасы ике дистәгә якын үлекләрен калдырып, җимерек йортлар арасына кереп яшеренде.

Алга узган немец танклары да үзләренең һәлакәтен таптылар. Дошманның бу атакасы ярты юлда тончыкты.

— Ну, как мы их, ... мать, дядя Гриша, а! Пусть попробуют еще сунуться, мы им не то покажем! — Ярсыган Вася Кузнецов үзен инде бөтенләй җиңүче итеп хис итә. — Ну, дядя Гриша, они еще полезут?

— Полезут, но уже не таким образом, — ди Габдрахман үзенең командиры малаена. Ул моны хәрби тактиканы белеп түгел, тормыш тәҗрибәсеннән чыгып әйтә. — Бер авызыңны пешергәч, икенче мәртәбә өреп кабасың...

Ярты сәгать тә үтмәгәндер, күктә самолетлар гүләгән аваз ишетелде. «Немец бомбардировщиклары, безне бомбага тотарга киләләр, — диде Вася Кузнецов, белдеклеген күрсәтеп. — Ничего, дядя Гриша, безнең өс калын, безнең өстә, җимерек булса да, дүрт этажлы таш йорт!»..

Командир Вася сүзен әйтеп тә бетермәде, кинәт коточкыч көчле шартлау, зилзилә, гарасат, җир белән күкне бутады, һәм пулеметчылар өчен дөнья тынып калды...

...Күпме вакыт узгандыр, Габдрахман һушына килде, күзләрен ачты... Дөм караңгы... «Исән калганмын икән», — дигән уй үтте аның башыннан. Ул подвал идәнендә чалкан ята иде. Солдат кымшанып карады — селкенә алмады. Аның аяк-куллары, күкрәгенә кадәр бөтен гәүдәсе, нигезенә кадәр җимерелгән йорт хәрабәләренә басылып калган иде. Ул тагы бер мәртәбә ыргып, йолкынып карады — юк, ычкынырлык түгел! «Вася!.. Василий!.. Кузнецов!?» Аңа җавап бирүче булмады.

Габдрахман, җан ачысы белән тагы бер мәртәбә талпынып-ыргылып карады — файдасыз... Тиздән ул кул-аякларын да тоймый башлады, алар оеганнар иде инде... Менә нинди үлем белән үләргә язган икән тәкъдиренә Габдрахманның — аек акыл белән әҗәлен көтәргә!... Үзенең бу уеннан коты алынып, ул кычкырмакчы булды: «Коткарыгыз! Помогите!..» Ләкин инде тавышы чыкмады — аның күкрәге кысылган иде. Тәкъдиргә буйсынып, укытучы елый-елый, үзенең дөньяда иң газиз, кадерле кешеләре белән бәхилләшә башлады: балаларым Алия, Хәнәфи, Асия, Хәлил... хушыгыз, бәгырь кисәкләрем, игелекле булып үсегез... Хуш, Фатыймам... рәхмәт сиңа... син миңа зур бәхет бирдең, бәхил бул... Аннары ул мәктәбен, моннан бер ай гына элек хушлашкан укучыларын күз алдына китерде... Хушыгыз, балалар... Ә син, Исрафил, мине гафу ит... Алла хакына... Анда, Казанда... мин кыйнауларына, җәзалауларына түзә алмадым... үзләре алдан язган кәгазьләренә кул куйдым... Гафу гозерләнәм синнән, Исрафил...

Габдрахман тагын балаларын, хатынын күз алдына китерде. Алар инде ерагаеп, караңгыга кереп китә башладылар... Хушыгыз, бәгырь кисәкләрем...

Укытучы аңы томалана башлаганын, үзенең соңгы минутлары килгәнен сизде һәм үзенә-үзе ясин чыга башлады: «Йасинн... вәл көрьәнел хәким... иннә ләмил мөрсәлим...»

...Аның соңгы, авыр, салкын яшь бөртекләре күз төпләрендә мөлдерәп калдылар... Укытучы Габдрахманның изге җаны, җирдә булмаган киңлек, җиңеллек, рәхәтлек сизеп, серле, якты, чиксез бушлыкка очты.

* * *

Кышкы шыксыз төндә, бөтен илгә сибелгән лагерьларның иң ерагында, иң салкынында, тиз үтерә торган чахоткадан бер тоткын үлеп ята. Төрмә больницасында җәһәннәм суыгы булса да, авыруның тәне кызыша, эчәсе килә, ләкин аның су сорарлык та хәле калмаган инде. Хәер, ул яткан палатада аннан башка кеше дә юк, ул өметсез авырулар палатасында берүзе генә...

Авыру кипшергән иреннәрен коры, кайнар теле белән яламак була, ләкин теле аңа буйсынмый. Сырхау бер мәлгә өнсез кала, аннан янә саташа башлый. Менә ул ерак Мирас авылында, авылның данлыклы Галия чишмәсе янында, имеш. Бер яшь чибәр аңа мөлдерәмә чүмеч су бирә «Минем суым салкын ширбәт, эч, мөгаллим абзый, салкын да, татлы да минем суым, эчә күр, зинһар!..» Мөгаллим егет эчә, эчә, эчә, ләкин аның сусавы һич кенә дә басылмый... «Исемең кем синең, сеңлекәш?» — дип сорый сусаган мосафир. «Фатыйма, Фатыйма исемле мин, мөгаллим абзый!» — ди мәрхәмәтле кыз...

«Фатыйма... Фатыйма... Мин Фатыйма исемле...»

...Мәетнең ачык калган, пыялаланган шомырт кара күзләрендә, бөтен кыяфәтендә газап чигү һәм... елмаю чаткылары катып калган...

Икенче көнне иртән носилка күтәреп кергән санитарларның берсе әйтеп куйды: «Кажись, профессор умирал весело».

Бу мәет — буржуаз милләтчелектә, Россия тарихын ревизияләп маташуда, Советларның милли мәгариф политикасына яла ягуларына гаепләнеп ун елга иреgеннән мәхрүм ителгән, аннан соң тагы биш ел буена сөрген сөрергә мәҗбүр булган профессор Исрафил Мөхәммәт улы Туктамышев мәете иде...

* * *

Шәрдән леспромхозын сугыш башланган елның көзендә оештыра башладылар. Башта егерме биш-утыз кеше шалашларда яшәп урман кисә башлады. Урман авызларында, тирә-юнь авыллардан килгән юллар чатында баганаларга: «Осторожно, валка леса!» — дигән язулы такталар кадаклап куйдылар. Бу язулы такталар урманга җиләккә, печәнгә йөргән бала-чага, хатын-кызның игътибарын җәлеп итми калмады, әлбәттә. Урысчасы шәп Хөрмәт (ул ике җәй Ивановта көтү көткән кеше) шартлатып: «Бүредән, төлкедән сакланыгыз!» — дип тәрҗемә кылгач, яшен тизлеге белән якын-тирә авылларда шомлы хәбәр таралды: Шәрдән урманында мыж аю, бүре, төлке, ди, урманга кермәскә кушып багана башларына язу язып элгәннәр, ди.

Бу хәвефле хәбәр бигрәк тә Мирас хатыннарын хафага салды: авыл өстенә егылып торган урман Шәрдән урманына барып тоташа. Алла сакласын, бер төнне өерләре белән килеп... Әстәгъфируллла тәүбә, тәүбә!

«Алар памаему, Белорус урманыннан килгән бүреләр, шугыштан кашып», — дип фараз кыла Барый, Мираста әле бердәнбер сугыштан ранин булып кайткан кеше (штык сугышында нимес аның теш казнасын җимергән, шуңа күрә аның сөйләшүе шулайрак). — Шәрдән урманында алар, памаему, ожак задержатша итмәшләр: Шәрдән урманы урман мени белоруш бүрешенә — башын урманга тыкша, койрыгы кырда кала. Алар Шәрдән урманына привалга гына тукталган булыр. Тайга урманнарына үтеп барышлый. Ял итеп алалар да — әйдә тимер юл буйлап Шебер тайгашына туп-туры! Юл да шорашып торашы юк!»

Барыйның бу сүзләре (сугыштан кайткан кешенең сүзе абруйлы) аны сырып алган бала-чага, хатын-кыз йөрәгенә бераз җылы кертә: шулай гына булса ярарие, җитмәгән сугыш афәте, тагын урмансыз да кал...

Әмма Барыйның сүзе бетмәгән икән әле:

— Ну, привалда бер-ике малайны тотып ашап, бер кыж бала белән жакушывать итәләр инде, привал — привал буламени, тамак ялгап алмагаш!

— Йа аллам, утырмасанчы бала-чаганың котын алып, — ди Барыйның хатыны Гөлфия, йөгереп килеп сыенган кызы белән малаен кочаклап. — Гомереңүтте инде тоссыз сүз сөйләп!..»

Авыл халкы урмансыз яши алмый. Авыл халкының ярты тормышы урман белән — утыны, печәне, җиләге — барсы да урман хәзинәсе. Ләкин хәзер урманга ялгыз бару, урманда ялгыз йөрү бетте. Печәнгә, җиләккә

хатын-кыз, бала-чага жыйнаулашып кына йөриләр. Урманга чиләк, кәчтрүл кагып, улап, яшелле-зәңгәрле авазлар белән чинап, сызгырып кергән «Чыңгызхан чирүе»ннән өркеп аю-бүреләрнең генә түгел, шүрәле, җен убырларың чыгып качар!

Бер көнне шулай урманда леспромхозга директор булып килгән Федор Иванович Купцовны очратмасалар, бу хәл күпме дәвам иткән булыр иде икән?

Купцов, урман мастерлары белән, леспромхозның даими базасына уңайлырак урын эзли торгач, Мирас урманына барып чыккан иде. Менә шунда инде алар акырып-бакырып, савыт-саба шалтыратып килгән кыргый кавемгә юлыктылар.

«Ни булды, нигә болай шаулашасыз?— Купцов юлларына аркылы төшеп, бу шашкан өерне туктата.— Йә, нигә кычкырасыз, шаулашасыз, ни булды, ни бар?»

Өзлексез кычкырудан, сызгырудан, чинаудан ярсыган малайларның борын тишекләренә әрлән кереп китәрлек, кызларның исә чәчләре тузгыган. Көтмәгәндә ят ир-атка тап булып, уңайсыз хәлдә калган хатыннар тиз-тиз чәчләрен яулык астына яшерәләр, терсәккә кадәр сызганган җиңнәрен сыдырып төшерәләр.

— Йә, нигә шаулашасыз? Ни булды?— Купцов соравын тагын кабатлый.

— Бүре куабыз!— ди арада иң әтчәенни малай Габдуллажан.— Белорус бүреләрен! Шәрдән урманына сугыштан качып бер көтү белорус бүресе килгән, ди. Безнең урманга да килеп житүләре бар.

Купцов: «Бер ни аңламыйм!»— дигән кыяфәт белән мастерларына карый, мастерлар иңбашларын сикертеп, кулларын гына як-якка җәяләр...

— Хөрмәт Шәрдән урманына җиләккә барганда күреп кайткан, багана башларына язу язып кадаклаганнар, ди, урманга кермәскә-йөрмәскә кушып, аю-бүре дачурта дип. Әнә үзе сөйләсен. Хөрмәт! — Габдуллажан сүзне Хөрмәткә бирә.

— Ну, егет нинди язу укыдың син баганада?— дип сорый Купцов, инде нидер сизенә, төшенә башлап.— Нәрсә дип язганнар иде баганадагы такталарга?

— Астарожно дип, волык, лиса дип...

Мастерларның яшьрәге яшен суккандай капылт җиргә егылып ауный-тәгәри көлә башлый, икенчесе эчен тотып хихылдый: алар бит баганаларга язулы такталар беркетеп йөргән кешеләр!

Купцов та кәефләнеп елмая:

— Эх, син, грамотей! Егет тәрҗемәдә бераз тогәлсезлек җибәргән,— ди ул, баганадагы язуларның мәгънәсен аңлатып бирә.— Урманда курыкмыйча, шау-шу куптармыйча гына йөри аласыз, бернинди дә бүре көтүе юк урманда.

Ирләр үз юллары белән китеп баралар.

— Их син, грамотей!— Габдуллажан Хөрмәтнең иңи шүрлегенә менеп төшә.

— Ну, күрсәтәм әле мин аңа кайткач «белоруш бүреләрен!— дип чәпчи Барый хатыны Гөлфия.— Янавыч белән тәя-тәя менә дигән мәлүрәүни кәчтрүлемне эштән чыгарганмын, җанымны суырыйм!...

* * *

Леспромхоз базасын ике-бус берәр чакрым булган урман аланында кора башладылар. Аланның бер читеннән мул сулы Сарысу дигән елга агып үтә, биш-алты чакрым җирдә тимер юл станциясе Шәрдән. Икенче уңайда, өч-дүрт чакрымлап булыр — больницалы, почталы, пекарнялы Ключи дигән зур урыс авылы. Тирә-якларда тагын эреле-ваклы татар, чуаш, удмурт авыллары. Эш сөючән, һөнәрле халык яши бу якларда.

Башта леспромхоз базасын Шәрдән станциясендә урнаштырырга планлаштырганнар иде. Ләкин жирле властьлар производство максатларына электр энергиясе бирә алмауларын белдергәч, аерым бер хуҗалык булып урман аланына урнашырга карар кылынды.

Леспромхозның бөтен эшләп чыгарганы сугыш ихтыяҗлары өчен булачак. Беренче чиратта — тимер юл паровозларын утын белән тәэмин итү күздә тотыла. Шәрдән — узел станциясе. Анда паровозларга «ашханә» — алар Шәрдәндә утын ала, су ала (Донбасс немецлар кулына эләккәч, тылда йөргән паровозларны утын ягуга көйләделәр). Аннан кала цех-мастерскойларда арба, чана ясау, хәтта камыт агачы, көрәк, балта сабы юну да — хәрби заказ, барсы да фронт өчен эшләнәчәк.

Купцов эшче кадрлар туплау, йөк атлары булдыру нужасы белән район үзәгендә булды, тирә-юнь авылларны йөреп чыкты. Район башлыклары эшнең мөһимлеген аңлап, Купцовны «всячески поддерживать» итәргә вәгъдә бирделәр. Шыксыз колхоз кәнсәләрендә персидәтел булып утырган картлар, «ат аунаган җирдә төк кала» дигән тәкъбирне искә алып, урман хуҗаларына колхозның да гозере төшәчәген белеп, леспромхозга бер-ике ат сатарга, урман кисәргә ике-өч таза хатын-кыз җибәрергә ризалык белдерделәр.

База урнашачак урман аланында көзен төзелеш эшләре башланды. Төрле авыллардан җыелып, сезонник булып ялланган балта осталары, такта яручылар артеле өч-дүрт ай эчендә бер рәткә тезеп контора йорты, кадровый эшчеләр өчен куш буралы җиде барак җиткереп куйды. Аннары, каршы якта, Сарысу буенда, утыз-кырык баш атлык абзар, мастерскойлар, мунча, ниһаять, шул ике рәт корылмаларның урта бер җиренә ашханә, кибет-келәт салынып, урман аланында ике рәтле, бер урамлы эшчеләр поселогы калкып чыкты.

Контора ишеге өстенә эленгән «Шарданский леспромхоз» дигән язу поселокның исеменә әйләнде. Ләкин халык аны алан яткан квартал номеры белән «Кырык алты» дип кенә йөртә,— татары да, урысы да, удмурты да — һәрберсе үз телендә, шулай гадирәк, җиңелрәк: «Кырык алтыга барышым», «Кырык алтыдан кайтып килешем әле...»

Кушбуралы контора бинасының бер яртысында директор Федор Иванович Купцов кабинеты; шунда ук, такта бүлмә аркылы, экономист-бухгалтер Спиридоныч утыра — үз эшен фанатикларча яраткан кеше, шул ук дәрәҗәдә пөхтә, вакчыл, намуслы, вөҗданлы карт хезмәткәр. Бинаның икенче яртысында — прораб Дәминов, мастерлар, хисапчы, завхоз Шәмәк утыра. Леспромхоз бюрократиясе шушы кешеләрдән гыйбарәт. Купцов әйтмешли, бу команда — «достаточный минимум».

Төзелеш эшләре беткәч, балта осталарының күпчелеге мастерскойларга күчте, калганнары кайсы урман кисә, кайсы ат җигеп Шәрдәнгә урман чыгара башлады.

«Кырык алты»ның даны тирә-юньгә тиз таралды. Әле көчендә булган түбәтәйле, чикмәнле, чабата-ыштырлы карт-коры агайлар, мужиклар, эшкә яраклы гарип-гораба, сугышка алынырга әле елы кермәгән яшүсмерләр «Кырык алты»га агыла: аларга да бирәр эш табылмасмы? Дирихтыр дигәннәре әйбәт кеше дип әйтәләр...

Мәңгелеккә колхозга беркетелеп, болай да коры «хезмәт көненә» эшләргә дучар ителгән авыл халкы, хөкүмәткә ит, сөт, йон, йомырка, бәрәңге йөкләмәсе түләү өстенә, сугыш башлангач йорт башыннан хәрби заем — унсигез яшенә җиткәннәрдән башлап сугыш ясагы түләргә мәҗбүр. Тәмам бөлгән, ярым ач, ярым ялангач, томана, хайвани затларга әйләндерелгән бу мескен, бичара дәүләт коллары шул салымнарны түләргә кайдан да булса акча юнәтергә тиеш, югыйсә — төрмә.

Купцов завхоз Шәмәккә килгәннәрнең хәленә керергә, һәркайсына үзе булдыра алырлык эш табарга кушты. Тәҗрибәле, эшлекле Шәмәк һәркемгә үзенә муафыйкъ шөгыль таба. Ун-унбиш кеше сугыш чыгу сәбәпле печәне чабылмый калган аланны чабарга куела. Печәне тиздән,

көннәр коры тора. Атна эчендә абзыйлар киптереп җыеп, сигез-тугыз кибән куялар. Кикерә-пошкыра ашасыннар кышын леспромхоз атлары арзанга төшкән печәнне!

Тазарак җиде-сигез агай подвал казырга алына. Шәмәк аңа ашханә өчен кышлык бәрәңге, кәбестә, чөгендер салдырып куяр.

Тагын берничә карт-коры, урманнан киртәлек кисеп ташып, аланның бер-ике гектар җирен киртәләп алырга тотына. Киләсе җәйгә леспромхозның яшелчә бакчасы булырга тиеш. Ничу колхозлардан теләнеп, капчыклап кишер-кәбестә җыеп йөрергә.

Печәнче абзыйларга тагын эш табыла: алар әле генә үзләре печәнен чабып җыйган урыннарда чирәм сукалый башласыннар. Язга чыккач ул җирләргә Шәмәк солы чәчәргә, бәрәңге утыртырга исәпли.

Бөкере чуваш картына да кулай эш табыла: ул конторга күз-колак булып, аның идәннәрен себерештергәләп торыр.

Леспромхоз кышны инде тәмам җайланган-көйләнгән механизм булып каршылады. Утыз биш-кырык кеше урман кисә; бүе берәр метрлы утынга туралган юкә, каен, усак, өчбуй чыршы-наратны утыз-утызбиш атлы Шәрдәнгә чыгарып тора, көнгә икешәр мәртәбә урап. Мастерскойларда егерме биш-утыз кеше тәгәрмәч, арба ясый, чана табаны, дуга бөгә, камыт агачы, көрәк, балта сабы юна.

Ниһаять, беренче чана юлы белән леспромхоз Шәрдән станцасына берничә олау әле эшләнеп бетмәгән арба, чаналар озатты. Поездга төяп аларны каядыр, почта ящигы гына күрсәтелгән заводка җибәрәчәкләр. Ул заводтан алар тимергә киенеп, тимер хуллы арбага, чанага әверелеп, сугыш эшенә китеп барачак.

Дөнья мәшәкатьләре белән кыш, яз үтте, җәй килде. Бу яклар элек-электән игенгә начар як. Шәмәк әйтмешли, җирләренә шайтан коерык астын ышкыган — чәчкәнең уммый, сипкәнең булмый. Авыл халкы өчен май азагы, июнь иң авыр вакытлар — искенең беткән, яңаның җитмәгән чагы. Яшелчә бакчасын сукалатып, түтәлләр ярдырасы бар. Ә менә әбиләргә нинди эш табарга?

Беркөн шулай ашханә мөдире Әнисә, оныгын җитәкләп әрле-бирле ашханә тирәсендә чуалган бер карчыкны чакырып кертеп, икесен дә ашатып чыгарган иде. Аның бу изгелеген ни арада ишетеп белгәннәрдер, икенче көнне — ни күзе белән күрсен — ашханәне дистәләгән карчыккари, бала-чага сырып алган. Иртүк! Кайчан торып юлга чыкканнардыр. Бер кечкенә малай елый: «Әби, әби, тамагым ачты, безне кайчан ашатырлар инде?»

Йомшак күңелле Әнисә, елап конторага, директор янына килә, хәлне сөйләп бирә: «Купцов абый җаным, пешләргә инде, ачлар бит алар, бигрәк тә балаларына карарга кызганыч! Әйдәгез, чыгып күрегез әле, Купцов абый җаным!»

Күренеш Федор Ивановичның йөрәген чалып ала: аның алдында инде күптән ачлык авыруыннан йөдәгән, җыерчыклы йөзләренә ачлык сарысы төшкән карчыклар, ачлыктан күзләренең нуры сүнгән, битләре бөрешеп, авызлары зураеп калган бала-чага. Карындык шикелле үтә күренмәле тире астында йөзгән колак сөякләре, бүртеп чыккан күгелҗем чигә тамырлары, авыз тирәсендәге вак җыерчыклары белән алты-җиде яшьлек малайлар лилипут картларына охшап калганнар...

— Кайсы авыллардан килдегез сез, әбиләр?

Купцовның бу соравына арадан бер терерәк карчык җавап бирә:

— Ташлы Кичүдән... Ташлы Кичү авылыннан булабыз без... Без монда ни дип инде...

— Ташлы Кичүдән! Моннан сигез чакрым җирдән, шушы вак балачагалар белән!.. Йә, хода!.. Әнисә, ашат, тизрәк ашата күр бу бәндәләрне, нәрсә булса да әмәлләп, ипиен-чәен бардыр бит? Көндезге ашыңны мулырак итеп сал, мин Спиридоновнчка әйтермен...

Ачлык... Ачлык хәле Купцовка таныш, һай, бик таныш хәл. Әле моннан ел ярым элек кенә, төрмәдә ятканда... Юк, искә төшерәсе килми, авыр...

Ярар, бүген бу карчыкларны, бала-чагаларны ашатып озаттык, ди. Иртәгә Ташлы Кичүнең инде бөтен карчык-корыуы, бала-чагасы «Кырык алтыда» булачак, һәм бер Ташлы Кичүдән генә җыелмаслар әле. Килгәннәрне көн дә шулай бушлай ашату мөмкин түгел. Өметләнеп көтеп торган бала-чаганы нәүмизләндереп, ач көе кире борып кайтару — юк, юк, бу бөтенләй рәхимсезлек булачак. Менә Купцов бара алмый. Карчыкларга тамак ялына гына булса да берәр төрле эш табарга кирәк...

Өендә, кичке аш вакытында Федор Иванович башына төшкән нужаны хатыны Ирина Васильевнага сөйләп бирә (Ирина Васильевна врач-терапевт, Ключи больницасында эшли).

— Ой, Федя, миңа бирсә икән синең хәстәрләреңне, диләрме әле, тыңлап тор: май ахырында — июнь урталарында юкә чәчәк ата; июль башында мәтрүшкә, җарабай (зверобой) җыяр чак җитә; бөтен җәй буе бака яфрагы, алма үләне, ромашка үсеп тора,— аларны җыюның вакыты чикләнмәгән. Болар бит бәясе алтын дәва үләннәре! Аннан килеп — кипкән кура җиләге, кипкән шомырт, гөлҗимеш җиләге, ниһаять, киптерелгән яки тозланган гөмбә! Боларны җыю-хәстәрләү нәкъ карчыклар эше ләбаса!

— Умница ты моя Ириша! Болар минем башыма һич киләчәк нәрсәләр түгел икән, рәхмәт сиңа, күгәрченем! Син мине шактый уңайсыз хәлдән йолып алдың.

— Сүз уңаеннан, минем иртәгә эштән буш көнем, мин синең карчыкларыңа нәрсәне ничек, кайчан җыярга, ничек эшкәртергә икәнен сөйләп лекция укый алам,— ди Ирина Васильевна,— ә хәзер, Федя, даруларыңны эч тә — постельгә! Бүген бик йончу күренәсең...

* * *

Төн. Салкыннан урманда агачлар шартлап сына. Ачлык аталы-аналы бүреләрне урманнан куып чыгарды. Суыктан йоннарын кабарткан ач бүреләр коерыкларын бот араларына кыстырып бер урында таптандылар, төнгә карап улап алдылар. Авыл ягыннан искән җил аларга абзар исе китерде. Ана бүре җилгә каршы басып озак кына иснәнде дә Мирас авылына барып чыга торган Коры елга буйлап чабып китте. Ата бүре аның артыннан иярде.

Елга авызына чыккач, артыш куагына ышыкланып, бүреләр күптән йокыга талган авылны, авыл тирәсен күзәтә-тыңлый башладылар. Күп тә үтмәде, чана шыгырдаган, ат пошкырган авазлар ишетелде. Бүреләр колакларын торгыздылар. Тау астында, юлда, авылга таба юртып килүче чаналы ат күренде. Борыннарына килеп бәрелгән әче тир исе бүреләрне укшытты, селәгәйләрен агызды. Түземсезләнеп, бөтен гәүдәсе белән калтырый башлаган ата бүре алдарак торган ана бүренең бойрыгын көтә. Ә анысы, җиргә тияр-тимәс коерык очын селкеп, сабыр итәргә куша.

Юл бүреләр посып торган урыннан бер җир буе читтән уза. Әлегә бернинди хәвеф-хәтәр сизмәгән ат (җил бүреләр ягына исә) бер көйгә юыртып бара бирә.

Ниһаять, вакыт җитте. Бүреләр куак артыннан чыгып һөҗүмгә ташландылар. Ана бүре алдан, ата бүре арттан аркылы төшеп, атның юлын кисәргә тиешләр. Бу тактиканы бүреләр ана сөте белән үзләштерә.

Соңгы минутларда гына бүреләрне күреп алган ат, пошкыра-пошкыра, кушаяклап җан-фәрманга алга чаба. Аз гына соңга калган ана бүре томырылып чана артыннан куа башлады. Толыбына төренеп, йокымсырап кайтучы юлчы чананың кинәт тартылуыннан айнып китте. Арттан куып килгән бүреләрне күреп каушабрак калган кеше тиз арада үзен

кулга алды, аркасын чана түренә терәп утырды да бияләйләрен салды, толып итәкләрен ачып куйды...

Менә-менә куып житәм, чанадагы кеше өстенә сикерәм, дигәндә генә чанадан ут бөркелде. Ана бүре чинап жибәрде, ут көлтәсен сикереп үтәргә теләгәндәй югарыга — күккә ыргылды да, һавада мәтәлчек атып, юлга тәгәрәде.

Чанадагы кеше тагын атты. Ургылып чабып килгән ата бүре, кискен борылып, юлдан читкә сикерде. Бу аның гомерен саклап калды.

Атлы кеше күздән югалгач, ата бүре үзенең егылып калган батыр жанкисәге янына әйләнеп килде. Телен аркылы тешләп хәрәкәтсез яткан ана бүренең текә маңгаеннан акрын гына куе кан саркып, юл карына тамып тора. Ата бүре жан дустының сыртыннан тешләп йолыккалады, өстерәп карады. Үле икәнен сизгәч, аның гәүдәсе тирәсендә төне буе әйләнеп-тулганып йөрде, күккә карап шыңшып елады. Шулай да жан саклау инстинкты жиңде — яктыра башлагач, ата бүре тугры дустының үле гәүдәсен калдырып, урманга таба юыртып китеп барды...

Шушы төннән соң Мирас авылына афәт инде — авыл кешеләре атна аралаш бәла-каза күрә башлады. Бер төндә бүреләр, абзарның тишек түбәсеннән төшеп, Гайнижамал карчыкның бердәнбер кәжәсен ашап киттеләр. Тагын бер атнадан күпер төбе Сәгъдинең жылы абзарына кереп буаз танасын ботарладылар.

Авылда мылтык заты юк, мылтык тотарлык ир-ат юк. Бүреләрнең азынуы хәттин ашты. Алар инде көпә-көндез урман очындагы урамнарга кереп, бәйдә торган этләрне бугазлап китә башладылар.

Бүреләр өер булып йөри, өер башында — үзенең жанкисәген югалткан ата бүре.

Жәй житеп, маллар көтүдә йөри башлагач, бүре өере, котлары алынган көтүчеләрнең кычкыруына-сызгыруына исе дә китмичә, сарык көтүенең уртасына ярып кереп, юлына тап булган мәхлукларны унгасулга буып ташлап, канлы тамаша ясап йөрде.

Жәй көне бүре ач булмый. Бүреләрнең бу ерткычлыклары Мирас кешеләреннән үч алулары иде. Узган кыш Мирас басуында ата бүренең жанкисәрен атып үтергән кеше Ташлыктан кайтып баручы Ключи урысы, тирә-якта дан тоткан аучы Дуболазов карт булганын алар кайдан белсен...

Ерткычларның авыл халкына кылган жәбер-золымнарының иге-чиге булмас кебек. Караңгы көзге төндә алар тышкы абзарда кунарга калдырылган ферма сарыкларын тар-мар итеп киттеләр. Йөз башка якын малның берсе генә дә исән калмаган.

Бу коточкыч фажигане иртән беренче булып көтүчеләр күрде. Кан сазына әйләнгән киртә эчендә бугазланган, эчләре актарылган, тереләй туналган сарыклар аунап ята. Жирдә, хәтта киртә-казыкларга эленгән сарык эчәгесе. Жан бирә алмыйча газапланып яткан мәхлуклар өстеннән пар күтәрелә. Күңел болгаткыч авыр ис — үлем исе килә.

Бәлагә тарган ферма янына халык жыелды. Кешеләр жан тетрәткеч һәлакәтне күреп, телсез калып карап тордылар. Дөньяда үзләренең иң явыз дошманы — кешедән аласы үчләрен, канга исергән вәхшиләр камарланып, шашып, Алланың гөнаһсыз мәхлукларыннан алганнар...

Өске нигрә киртәләрдә калган канлы эзләрне санагач, көтүчеләр абзарга дистәгә якын бүре кергән, дигән нәтижә чыгардылар.

«Бу — котырган бүреләр эшедер,— диде мал брачы Гафият,— акылында булган збир бу тиклем кансыз булалмас».

Шул ук Гафият күрсәтмәсе буенча куллпрына күн бияләй кигән көтүчеләр, үлә алмыйча ятканнарын чалып, ферма атына төяп, ике көн үләт базына сарык үләксәсе ташыдылар.

Икенче көнне Ташлыктан милиция килеп «пратакул» төзеде. Ул төнне дә, гадәтенчә, ферма каравылчысы йоклап калган булып чыкты.

«Сине милиция чакыра»,— дип кәнсәләрдән кеше килгәч, каравылчы карт — сиксән яшьлек Гатиятулла абзый, куркуыннан мич башыннан егылып төшеп, җан тәслим кылды.

Ферма мөдирен сутка бирделәр. Судта район прокуроры: «Корткычлык эшләү максаты белән, ферма мөдире гражданин Галиахметов абзар киртәләрен бүреләр кererлек итеп юри тәбәнәк эшләткән»,— дигән гаепләү белән чыгыш ясады, мөдирнең хатыны Себергә сөрелгән кулак кызы булуын да искә алып үтте.

Чулак Сабирҗанга биш ел бирделәр...

* * *

Ферма сарыклары белән булган казадан соң авыл халкы куркуга төште: котырган бүре өер$^{е}$ ни кыланмас! Хуҗалык малын көтүчеләр көтүне болынга, кырга алып чыгарга курка башладылар. Нинди дә булса бер чара күрергә кирәк иде.

Авыл Сәвите рәисе Гыйлаҗиев, тирә-як урыс авылларына чыгып, тәҗрибәле карт сунарчылар белән сөйләшеп-киңәшеп йөреп кайтты. Бүре холкын белгән аучылар бүре өерен күз күнә эзәрлекләү нәтиҗәсез булачагын әйттеләр.

Сүз куешкан буенча, беренче кар төшү белән Ключидан Дуболазов карт, Урыс Бимәреннән тагы ике аучы, аннан соң Гөберчәкнең өйрәнчек аучысы, әле сугышка китәргә чираты җитмәгән Вәлихан, Мирас урманының яманаты чыккан, халык «Бүре түкмәсе» дип йөрткән почмагын кызыл чуклы баулар белән камап алдылар. Кеше аяк басарга курыккан бу чокыр-чытырманлык элек-электән бүреләрнең туй ясый, бала үстерә торган урыны иде.

Ау арканын күчергәләп торырга авылдан карт-коры, малайлар ярдәмгә килде. Камау урынын сайлауда Дуболазов ялгышмаган. Табыш мул булды — аучылар җиде бүре атып ектылар. Җиңел яраланган сигезенче бүре качып котылды. Ул Вәлихан мылтыгыннан иңбашына җәрәхәт алган ата бүре иде. Аны вакытында эзәрлекләүче булмады. Икенче көнне, яшь кар эреп киткәч, бүренең канлы эзе юкка чыкты.

Туган, тереклек иткән төбәгеннән өркетелгән, гарипләнгән бүре Шәрдән урманына качты. Хәзер Аксак бүре куян, төлке куып тота алмый. Ул үлгән кош-корт, бүтәннәрнең мул табыныннан калган сөякләрне кимереп җан асрады. Шулай да февраль аенда каны уйнап китеп, кавемдәшләренең туена барып чыккан иде, ике яшь ата бүре килмешәк гарип җанварны чак кына ботарлап ташламадылар. Чакырылмаган кунак көчкә генә оясына кайтып егылды һәм туйда алган җәрәхәтләрен озак көннәр буе ялап ятты. Шушы җәнҗалдан соң буйдак бүре ялгызы гына, үз көнен үзе күреп яши башлады.

Ул үзенең гариплеген соңгы чиккә җиткән, башын бетерерлек кыюлыгы, рәхимсезлеге белән кайтарды.

Аксак бүре урыс авылларын ерактан әйләнеп үтеп, татар авылларын кыдырып йөрде. Авылларны ул исеннән аера. Урман тирәсендәге урыс авылларында аучы булмый калмый. Сугышка киткән Иван бәлки инде күптән батырларча һәлак булгандыр, әмма аның чөйгә элеп калдырган мылтыгыннан әле һаман да дары исе аңкып тора, хуҗасының кайтуын түземсезләнеп көткән тугры Полканы әле сизгерлеген җуймаган. Каршы искән җил урыс авылыннан дары исе, чучка исе алып килә. Чакрым ярым, бер чакрымнан сизеп алган этләр гауга күтәрәләр. Ата бүре, юлын үзгәртеп күрше татар авылына титаклый — татар авылларында мылтык булмый, татар агайлары эт асрамый диярлек, булган этләре дә юашлар, ялкаулар.

...Авылда ут алына. Кичен ыгы-зыгы килеп мал-туар карап йөргән агайлар, апа-җиңгәләр бер кат эшләрен бетереп, ашарга-эчәргә утыралар. Абзар-кура әле төнгә бикләнмәгән. Менә нәкъ шул вакытта якын

урман авызында гына посып яткан аксак бүре, ындыр артлатып килеп, каза күрәсе йортның бакчасыннан ишек алдына сикерә дә ачык калган абзар курасына чума. Хуҗаның кәҗәсен, асрамага калдырган сарыгын бугазлап, шунда — абзарында ук, ашап чыгып китә. Яисә, буран көннәрендә, көпә-көндез авыл читендәге кетәклеккә кереп, колхоз тавыкларын пыран туздыра-ботарлый башлый. Тавыкларның чыр-чу иткән, кыраклаган тавышына кетәклеккә килеп кергән ферма кызының өстенә сикереп котын алып, тышта котырган буран өермәсендә юкка чыга...

Тирә-юнь авыл кешеләре бу тәвәккәл, рәхимсез ерткыч турында ничектер курку катыш ихтирам белән сөйлиләр: аксак бүре фәлән авылның фәләннең сарыгын ашаган, ди, фәләннәрнең абзарына кереп сыерын... Сөйләгәннәрнең барысы да чын булса, аксак бүре көн саен бер сарык ашаган, аның өстенә тагын көн аралаш сыер малы бугазлаган булып чыга. Аксак бүрене күрүчеләр, очратучылар да бихисап. Әйтерсең, кешеләргә шулкадәр җәбер-золым кылган ерткычны күрү — үзе бер зур мәртәбә. Тик менә аның алгымы яисә арткымы аягына аксаганын тәгаен әйтеп бирүче генә юк...

Теге чакта, эзәрлекләүләрдән, кызыл тасмалардан иза чиккән, ярсудан кан сауган күзләренә үзенә аткан кешенең шәүләсе генә чалынып калган. Камаудан ычкынып, өстенә ыжгырып килгән бүрегә Гөберчәк малае, куркуыннан акырып, тәземи-нитми атып җибәрде дә, мылтыгыннан ташлап качты — бүре бер якка, аучы малай икенче якка чаптылар.

Аксак бүренең бу явыз дошманы хәзер якты дөньяда юк инде. Яше кергәч, яз көне, Гөберчәкнең Вәлихан абыйлары артыннан сугышка китеп барды. Арыш урагына төшәр алдыннан, ялгыз калган карт белән карчыкка төпчекләренең дә үлгән хәбәрен китерделәр...

* * *

Тәүфыйк дигән егетебез бабасы торган баракта, аның урынында йоклый. Баракта алар дүртәү — авылдашы Газиз абзый, арба ясаучы Гафур бабай, такта яручы чуаш карты Михай. Агайлар берберсенә юл куешып, тату гына яшәп яталар. Арада өлкәннәре — Гафур абзый, дөньяда күпне күргән, сабыр холыклы, мөлаем карт. Баракта ул абруйлы кеше. Аның сөйләгәне — төпле сүз. Газиз абзый шикелле, тузга язмаганны сипмәс. Тәүфыйкка да иртән, кичен бер-ике авыз җылы сүз әйтми калмас: «Нихәл, егет, әйбәт йоклап булдымы? Кандалалар бик каныкмадыларамы?» Яки: «Ну, энекәш, кишер-кыярлар, кәбестә-суганнар шәп үсәме, кәҗәләр бик йөдәтмиме?»

«Кәҗәләр бик йөдәтмиме?» — дип сорый Гафур абзый. Кәҗәләргә түзеп була, кандалага чыдар хәле юк малайның, бигрәк тә беренче төннәрдә үзәгенә үттеләр. Бөтен стена ярыкларына, топчан җекләренә шыплап тулган кандала чирүе, Тәүфыйк кичен кайтып ятуга, посып яткан җирләреннән чыгып, һөҗүмгә ташлана тегеләр.

Яктыра башлагач кына, ике яктан да бик күп кан коелгач, дошман чирүе, сугыш кырында берничә йөз мәет калдырып, үзләренең элеккеге позицияләренә чигенә. Тәмам алҗыган малай да батырлар йокысы белән йоклап китә.

Бер көнне Тәүфыйкның шалашы тирәсенә бер көчек килеп чыкты. Эт малаеның кыланышлары бик сәер күренә — нәкъ тычкан аулаган мәче шикелле, ул үләнгә чумып, посып ята да кинәт кенә сикереп нәрсәнедер эләктермәкче була. Шулай бер сикерүендә тычкан чиелдәгән тавыш чыккач, каравылчы малай, ясап утырган чабатасын куеп, көчек янына килсә — ни күрсен! — эт сабыеның тәпие астында имгәнгән тычкан баласы! Көчек аны нишләтергә дә белми: җирдә әвәли, иснәп карый, җирәнеп, төчкергәндәй итә — «фчык, фчык!..»

Тәүфыйк эт баласына Муйнак дип исем кушты. Бакча тирәсеннән кәҗәләрне куарга өйрәтте. Начти карчыкның кәҗәсе генә санламаган

булып маташканые, сиздерми генә килеп арт аягыннан тешләп алгач, коты алынды карт марҗаның! Хәзер «тәф-тәф!» итеп өреп килгән Муйнакны күргә, беренче булып ул кача башлый.

Шура апасы да бик яратты Муйнакны. Ул миски белән көчеккә калган аш, ипи катылары китерә — теленне йотарсың! Ә кай чакларда савытта хәтта сеңерле сөякләр дә булгалый! Ашап туйгач, Муйнак Шура апасы белән аланда бер-берсен куышып уйныйлар, үләндә ауныйлар. Шалаш янында чабата ясап утырган Тәүфыйк аларга көнләшеп карамый микән? Дөресен генә әйткәндә, Муйнак Шура апасын күбрәк ярата — ул тәмле ашлар ашата, ул күңелле уеннар уйната, баштан-аркадан сыйпап иркәли. Бу дөньяда тагы нәрсә кирәк ике-өч айлык ятим эт баласына!..

Гомумән, Муйнак әйбәт көчек, әрсез, комагай түгел. Аның әти-әниләре дә юньле этләр булганнардыр, мөгаен...

Күп тырыша торгач, Тәүфыйк көчеген кишер ашарга да өйрәтте. Башта үзе бик тәмле итеп кимерде. Муйнак карап кына торды. Аннары чәйнәп, кишерне этнең авызына тыгып, көчләп йотарга мәҗбүр итте, тешләре арасына бөтен кишер кыстырып, чәйнәтеп азаплады. Абыйсының тырышканы бушка китмәде — хәзер Муйнак биргән кишерне кетертәтеп кенә куя. Әмма ул нәзберек көчек булып чыкты — син аңа кишерне юып бир!

Бервакыт каравылчы малай көчеген үзләренең авылына кунакка да алып кайтты. Бер бөртек тә армады Муйнак, әле алга чыгып, әле артка калып, юл буе бертуктаусыз йөгереп, дөнья белән танышып барды.

Мираска кайтып җиткәндә генә зур, караңгы Солы зираты янынан узасы бар. Ялгызы гына кичкә калып кайткан чакларда шул шомлы зират турыннан үткәндә Тәүфыйкның аркасыннан салкын тир бәреп чыга торган иде. Соңга калсалар да, бу юлы малай шүрләмәде, чөнки аның белән янәшә курку белмәс Муйнагы йөгереп кайта!

Караңгыга калган ялгыз юлчыларга Солы зиратыннан өрәк чыккалый, диләр. Әле сугыш алдыннан гына, Солының Мохтар исемле ата коммунисты клубта Мирас кешеләренә: «Алла да юк, җен-шайтан, өрәк-убыр дигән нәрсәләр дә юк, оҗмах белән җәһәннәм дигәннәрен дә муллалар уйлап чыгарган»,— дип, тагын әллә нинди көфер сүзләр сөйләгәч, көзге айлы төндә үзләренең авылына кайтырга чыккан. Юл өстендәге зиратның нәкъ уртасына җиткәч, аның каршына елаган аваз белән, ак кәфенгә төренгән өрәк килеп чыкмасынмы! Коммунист абзый артына борылып йөгерим дисә — аның каршында шундый ук икенче өрәк! Җан-фәрман кырга чапкан Мохтарны өрәкләр икәүләшеп куа башлаганнар. Авыл башына килеп җитәрәк кенә шаркылдап көлеп, кире китеп барганнар...

Мохтар телсез-авызсыз калып, өенә кайтып егылган. Хатынына: «Минем арттан... зираттан чыгып... ике өрәк»...— дип кенә әйткән дә җан тәслим кылган.

Дөрес, «өрәкләр» — ак җәймәгә төренгән Мирас егетләре булган икән, коммунист абзыйны сынар өчен алар, алданрак юлга чыгып, зиратта качып, кайтканын саклап торганнар икән, дип сөйләүләр булды булуын. Шулай да зират шүрләтә, янынан узганда күңелгә шом сала.

Муйнак өйдәгеләрнең барсына да бик ошады. Карт ата мәче генә сыртын, мыекларын тырпайтып мырылдаган иде, ул да тора-бара ияләште. Тәүфыйк: «Әни, Муйнакны көз көне бөтенләй үзебезгә алып кайтыйм?» — дип сораган иде дә, әнисе: «Улым, җаным, сез болай да миңа дүрт көчек»,— дип кырт кисте.

Хәзер Тәүфыйк авылларына гел көчеге белән кайтып йөри башлады. «Кайта торгач сиңа әни дә ияләнер әле, бәлки көз көне дә куып чыгармас,— дип юмалады малай көчеген,— безнең әни әйбәт кеше ул, Муйнак!»...

* * *

Кырык өченче ел җәе коры килде. Май ахырыннан бирле кинәндереп яуган яңгыр булмады. Сирәк-мирәк кенә Мирас күгендә юка, кысыр болытлар күренгәләде күренгәләвен: алар, кайсы якка китәргә белмәгән шикелле, гаҗизләнеп, авыл өстендә асылынып тордылар да, җиргә өч-дүрт бөртек тамчы ташлагач, эреп юкка чыктылар.

Иң әүвәле, авыл халкы күңеленә шом салып, Галия тавында үлән көйде. Аннан соң кырда сабан ашлык, бакчаларда чәчәккә бөреләнеп килгән бәрәңгеләр көеп калды. «Тагын бер атна яумый торса, барсы да бетте дигән сүз,— ди тәҗрибәсе зур Хисаметдин карт,— бәрәңге дә, сабан ашлык та...»

Яңгырсыз җәйдә алабута бетли, кычытканга көя төшә. Чабарга дип, иләгендәге кычытканны кунага аударса — ни күрсен! — яфраклар арасыннан куна читенә мыж килеп, буй-буй яшел-кара йөнтәс көяләр үрмәләп чыга башлады. «Аба-а-у!» — Шәмсениса, җирәнеп-куркып, кычыткан яфракларын кунасы-ние белән тышка чыгарып ыргытты. «И-и Аллам! Инде кычыткannарыңа да корт җибәргәнсең. Кычкырып ачка катсыннар диюеңдер инде! Әйтче, Хода вәндәм, әгәренки булсаң — ни ачуың бар минем ятим сабыйларымда?! Ни гөнаһлары бар аларның синең каршыңда?! Нигә каһәрлисең, ник яңгырлар бирмисе-е-ең?!» — Шәмсениса боегып торган Мисбахын кочаклап, сәке кырыена килеп утырды да улының башыннан сыйпый-сыйпый елый башлады — ач балаларын кызганып, үзен кызганып... «Әни, елама, син елагас, минем дә елыйсым килә, елама, әни!»

Төпчегенең бу ихлас сүзләре ана күңелен тагы да нечкәртеп җибәрде. Шулай да ул елавыннан туктады — елаудан файда юклыгын каһәрләнеп, эт көне күреп яшәгән Шәмсениса яхшы белә. Бүген аның бөтен зары, бөтен үпкәсе тышка чыга. Чыгырыннан чыккан чакта теләнә ни кылса шуны ычкындыра торган хатын Шәмсениса. «Син әле нигә миңа каныгасың, кидере-нифини кәнсә-кәнис! Иремне зинданга салдың, сугыш чыгарып, улымны солдатка алдың, менә инде ике ай Зөлфәтемнең хатыхәбәре юк, башлары вәйран булды микән балакаемның, әллә җәрәхәтләнеп, хат язарлык та хәле юк микән? — Шәмсениса тагы елап алды.— Инде хәзер калган сабыйларымны да ачка катырыйм дисең мени? Кодрәтеңнән килсә — яудыр яңгырларыңны, килми икән — төш! Ничу анда шакмакларыңны асылындырып утырырга, хәлеңнән килмәгәч. Беләм, беләм мин синең мәкерле планнарыңны! — дип зәһәрләнә Шәмсениса,— яңгыр юк икән — илдә ачлык, ач кызылармиес нимескә каршы тора алмый, Гитлер Сталинны җиңә. Ден дошманың Сталин белми торгандыр әле синең кем икәнеңне, белсә әллә кайчан Себергә олактырган булырие, әллә кайчан! Утырыр иең себер өтермәсендә күзеңне акайтып!» — Әйтерсең лә Шәмсениса үзләренең ферма мөдире Чулак Сабирҗан белән кычкырыша — итагатьлек кая да, кая тәкәллефлек...

Стенадагы сыңар герле сәгать бер тулып килгәнне күрсәтә, балаларының мәктәптән кайтыр вакыты җитә икән. Шәмсениса иләген тотып тагы бакчага чыгып китә. Бу юлы инде бәрәңге яфрагы кыркырга. «И ходаем, Фәрзәнәмә тагы ниләр юнәтеп бирермен икән, ашамый гына бит үлән ашын, хәерсез бала»,— дип үзалдына сукрана иза чиккән ана...

Алла бар икән, бөтенләй үк мәрхәмәтсез дә түгел икән. Бер көнне шулай, төштән соң, еракта-еракта гөлдерәп күк күкрәгән авазлар ишетелә башлады, салкынча-дымлы яңгыр җиле исеп куйды. Озакламый көнбатыш якта, офык артыннан кабарынкы болытлар килеп чыкты. Алар бүсеп, җәелеп, бергә укмашып инде күкне тоташ иңләп алып, туп-туры Мирас өстенә агылдылар.

Менә инде кояш та болыт астына кереп югалды.

Болытның язгы ташкын шикелле пычрак-соры кайма булып, ишелеп-тәгәрәп килгән алгы чите артыннан тигез, караңгы-көрән яңгыр җәймәсе сузылды.

Инде якында гына пыяла күк гөмбәзен чәлпәрәмә китереп, яшен яшьнәде. Җәен кеше күзенә чалынмыйча, каядыр такыр басуларда җим табып тереклек иткән кара карга көтүе, хәвефле кычкырышып, авыл өстеннән урманга таба очып үтте.

Яшенле яңгыр юлдашы давыл, узып барышлый гына каралты түбәләреннән йолкыган саламнарны тузан белән бутап, урамнарда өермә ясап уйнап алды да авылдан чыгып китте.

Өйдә шомлы тантана урнашты. Шәмсениса, бисмилла әйтеп, морҗа юшкәләрен япты, өстәл өстендәге самавырны идәнгә алып куеп, аны җәймә белән каплады. Мисбаһының башына түбәтәй киертте, бисмилла әйтеп, култык асларын сыйпаштыргалап торырга кушты: янәсе, яшеннән куркып, Иблис кеше култыгы астына кереп кача икән, Иблисне сугам дип, яшеннең кешене дә сугып куюы бар икән.

Ниһаять, «дөп-дөп!» — яңгырның беренче эре бөртекләре өй түбәләренә бәрде. «Шоп-шоп!» — урам туфрагына төшеп, кечкенә-кечкенә тузан болытлары күтәрде, әйтерсең лә күктән бәләкәй-бәләкәй бомбалар төшеп ярылды.

Күк, бөтенләй ишелеп төшкәндәй, тәрәзә пыялаларын зеңгелдәтеп тагын бер мәртәбә чытырдап алгач, яңгыр кинәт шәбәеп китеп чиләкләп ора башлады. «Бир, Раббым, бир хәерең-рәхмәтең белән, ятим сабыйларның хакына, гарип-горабалар хакына, сиңа сыгынырга теле-авызы булмаган, суга зарыккан үлән-куакларыңны, мәхлук җанвар-хайваннарыңны, кош-кортларыңны кинәндереп бир, газиз Аллам! — Сәке кырыена утырган Шәмсениса иелә-бөгелә Тәгаләсенә ялвара: — Сабан ашлыкларга да җитәрлек итеп, бәрәңге төбенә дә үтәрлек итеп бир, рәхмәтле Ходам!..»

Шәмсениса түр тәрәзәдән урамга карады. Каршы яктагы Гарифулла абзыйларның йортын да күрерлек түгел — ора гына яңгыр!

«Кәрәхтерем начар икәнне үзең дә беләсең, көфер сүзләремне гафу кыйл инде, Ходаем. Бик ачуымны китергән вакытларда сиңа да тәмсез сүзләр ычкындыргалыйм шул, ярлыка инде бер юлга гөнаһлы бәндәңне, Тәгаләм!»

Ә тышта әле яңгырның тыйлыгырга исәбе юк, инде чирек, ярты сәгать булыр — коепмы коя!

«Җә, җә, җитәр, күпкә җибәрдең бугай, бәрәңгеләрне агызуың бар, арттырып җибәрдең, җитеп торсын хәзергә, җә, Ходаем!..»

Ходай Тәгаләнең Шәмсениса белән арасын бозасы килмәде, ахрысы. Бераздан яңгыр бөтенләй диярлек туктады. Инде хәлсезләнеп, сыегаеп калган ертык болытлардан ишек алды чирәменә сибәләгән вак яңгыр астына кыз-кыркын чүлмәк-чүлмәк гөл чыгарып тезәләр — шифалы яңгырга алар да коенсын!

Чалбар балакларын сызганган малайлар урамны иңләп аккан яңгыр суында чабышып рәхәтләнәләр. Алар бүген дуңгыз булып кайтсалар да сүз әйтүче булмас.

Авылга сарык көтүе кайтып керде. Көтү артыннан, култык асларына күшеген хәлдән тайган сарык бәтиләрен кыстырган, өсләрендә коры җепләре дә калмаган көтүчеләр кайтты. Чыланган, арган булсалар да, аларның кәефләре шәп — алар бит авылга зарыгып көткән яңгыр алып кайттылар.

Урман өстендә, Сорна белән Кесмәсне тоташтырып, салават күпере эленде...

* * *

Ирина Васильевнаның таләбе буенча Федор Иванович, форсат табып, һәр көн бер-ике сәгать урман һавасын сулып йөрергә тырыша. Үткән язда авыруы тагын көчәеп китеп, ул кан төкерә башлаган иде. Җәйгә кереп, көннәр җылынгач, үтте тагы. Менә елдан артык инде, аның төкерегә «коры», тьфү, тьфү.

Менә бүген дә, ял көне көнозын урманда булырга, делянкада агач тамгалап йөрергә планлаштырды Купцов: кыр сумкасына хатыны хәстәрләп биргән әбәтен салып, клеймә балтасын кыстырып, иртүк урманга чыгып китте.

Төшкә кадәр Федор Иванович, тиздән урманчылар кисәргә тиешле ерак делянкада, киселми калырга тиешле орлык наратларын тамгалап йөрде. Ул бу эшне үзе теләп башкара. Аның бестолковый мастерларына, татар әйтмешли — «үгез үлсә ит, арба ватылса утын». Аларга көнлек план гына үтәлсен, ә ул план нинди агач кисеп тутырыла, житмеш-сиксән елдан соң делянкада нинди урман калкып чыгар — аларның анда гаме юк. Элек колхозда бригадирсымак нәрсә булып йөргән, көн дә сәрхүш Ивановка ике дөнья бер, уртасы камыр, — ә урман техникумының икенче курсын ташлап киткән унжиде яшьлек Харисовка житмеш-сиксән елдан соң булачак дөнья — ахырзамандай ерак, акылга-хыялга сыймый торган, күз алдына китерүе авыр булган бер нәмәстәкәй генә әле. Ни хәл итмәк кирәк, леспромхоз директорына менә шундый кадрлар белән эш итәргә кала, махсус белеме булган чын урман мастерларын каян аласың.

Делянкада усак, каен, юкә арасында берән-сәрән, ниндидер могжиза белән янгыннан исән калган, очлары белән күккә терәлеп, бераз һавалanып утырган наратларга сокланмаска мөмкин түгел! Моннан туксан еллар элек булган янгында ниндидер могжиза белән исән калган йөзәр яшьлек агачлар, тирә-якка орлык очырып, ел саен меңнәрчә яшь үсентеләргә җан биреп, әле ким дигәндә тагы кырык-илле ел яшәргә тиешләр.

«Яшә, яшә! Син дә яшә әле!» — Купцов наратларның кәүсәсенә, кайрыларын өстән генә юнаштырып, бөжра ясап йөрде, шул ук вакытта ул аларның санын, чама белән генә булса да, юанлыкларын да, кенәгәгә теркәп барды.

Иртән иртүк көн янгыр вәгъдә иткән төсле иде: яфрак селкетерлек тә жил юк. Кыздыра. Төш вакыты җиткәнче үк урманда кош-кортлар тынып калды. Сирәк-мирәк кенә, күңелгә шом салып, кайдадыр ябалак кына кычкыргалап куя: «Чи-и-як... чи-и-як...»

Күк күкрәгән авазлар ишетелү белән, Купцов кайту ягына борылды. Аңа, үпкә авырулы кешегә, һич кенә дә чыланырга ярамый, — үзеннән бигрәк хатыны Иринаны хафаландырасы килми аның. Ашыгып, турыдан-туры квартал юлына чамалап чыга барганда куып житкән янгырдан ышыкланып, Купцов юлында очраган беренче чыршы астына кереп утырды! Инде ничә дистә еллар янгыр тамчысы төшмәгән биек, куе ботаклы чыршы төбендә сары ылыс келәме. Келәм өстенә, саргаеп калган көзге үләннәрне утлап йөргән сарык бәрәннәре кебек, узган елгы, эреле-ваклы чыршы күркәләре сибелгән.

Купцовның чыршы астына кереп яшеренгәнен генә көтеп торган диярсең, — янгыр чиләкләп коя башлады.

Колак тондыргыч шартлау янгыраді, жир тетрәнеп куйды. Көек исе, әче ылыс янган ис чыкты — якында гына ак чыршыны сукты булса кирәк. Тоташ янгыр пәрдәсе аша биш метрдан да бернәрсә күрерлек түгел. Ләкин Купцов төтене исеннән нинди чыршы янганын һич тә ялгышмыйча аера ала. Яшенле янгыр вакытында чыршы астында торырга ярамаганы да яхшы мәгълүм аңа. Ул үзенең ни дәрәҗәдә хәвефсез икәнен, малайларча шуклык белән, ихтималлык теориясе буенча исәпләп утырды: геометрик метод кулланып хисаплагач, яшеннең нәкъ менә ул качып утырган чыршыны сугу ихтималы юк дәрәҗәдә аз булып чыкты.

...Ихтималлык теориясе димәктән, Купцовның фәнни эшендә бу теория бик мөһим иде. ВАСХНИЛда фәнни хезмәткәр булып эшли башлагач, бу өлкәдә белемен камилләштерү максаты белән, ул бер семестр Мәскәү университетына мәшһүр математик Хинчинның лекцияләрен тыңларга йөрде. Бөтен игы килгән профессорның бу үзенчәлекле теориягә жан өреп, тыңлаучыларга аңлаешлы, мавыктыргыч итеп менә дигән лекцияләр укыганы Купцовның әле дә булса хәтерендә...

Яңгыр бер көчәеп китеп, бер тыйлыгып калып, әйләнеп йөреп ява. Әле кеше аягы-кулы тимәгән урман, яшенле-күкрәүле яңгыр! Йә Хода, никадәрле матурлык, хозурлык табигатьнең бу стихиясендә!..

...Кемерово тирәсендә ул яткан лагерь тоткыннарын яңа төзеләчәк ТЭЦның нигез чокырын казырга йөрттеләр. Җәй көне. Кояш мәрхәмәтсез кыздыра. Өч-дүрт ярус белән казыла торган чокырда мунчадагы шикелле бөркү. Җитмәсә тагы әледән-әле капыл исеп торган җил чокырда кайнашкан бәндәләр өстенә кырдан эссе тузан, ком китереп сибә. Менә шул газаплы сәгатьләрдә яңгыр явып торган җәйге урман күз алдына килә торган иде. Юк, хәзерге шикелле яңгырдан качып, чыршы астында утырган чак түгел, киресенчә — җылы яңгырга чыланып, яланаяк юеш үләннәрне таптап йөргән рәхәт чаклары исенә төшә иде Купцовның.

...Ирина белән өйләнешкән елның августында беренче мәртәбә алар Федорның туган иленә кайттылар — Кама буена. Кама урманнарына алып кайтты Федор үзенең яшь, чибәр хатынын. Кайтканның икенче көнендә үк алар урманга җиләккә бардылар. Мәскәүдә туып-үскән чын шәһәр кызы Иринага урман җәннәт бакчасы булып күренде. Хуш ис аңкытып торган нарат-чыршылар, чәчәккә күмелгән аланнар, кып-кызыл кура җиләге пешкән төплекләр — аңа барысы да яңа, мондый могҗизаларны аның беренче мәртәбә күрүе. Аның йөзендә бәхетле елмаю.

Ул әле курадан җиләкләр өзә, тирә-юнендәге ал, сары, зәңгәр чәчәкләр аның игътибарын җәлеп итәләр. Ул Федясыннан аларның исемнәрен сорый, үзенә иң ошаганын өзеп түшенә кадап куя. Йә, сабыйлар шикелле, чәчәктән-чәчәккә кунып очкан күбәләкләрне куып йөгереп йөри, йә куакта сайраган кошларны күрәсе килеп куаклар арасына кереп китә дә, ялангач балтырларын кычыткан ага әтәләтеп чыгып, үрсәләнеп елый башлый...

Федор Иринасының кыланышларын күзәтеп, төп башында утыра. Чәчәкле урман аланында чикылдап көлә-көлә күбәләкләр куып йөргән, кычыткан га өтәләнеп, үрсәләнеп елаган сары бөдрә чәчле, ак батист кофталы кыз аның — Федорның — хатыны! Ха-тын!... Юк, бу сүз бик гади, хәтта аның Иринасы өчен тупасрак та яңгырый кебек. Федор үзенең Иринасына, назлырак, мөлаемрак исем табар: әйтик — Сөеклем, Бәхетем, Иркәм...

Кунакка гына кайткан бу Мәскәү кызына табигать урманның тагы бер матур чагын күрсәтеп калырга ашыкты, ахрысы. Абайламый да калганнар — ни арада болыт килеп җиткән дә, ни арада ява башлаган! Федор, Иринасын җитәкләп, якындагы чыршы астына йөгермәкче иде — кая ул! Ирина коеп яуган яңгыр астында калып, такмаклый-такмаклый, бии-бии башта берүзе генә юләрләнде, аннан соң, чыршы астында ышыкланып торган Федясын да өстерәп чыгарды. Парлап биеп тилерделәр...

Ничек ява башласа, шулай көтмәгәндә яңгыр туктады, кояш чыкты. Менә шул чакта биючеләр бер-берсенең кыяфәте мөшкел икәнен күреп, көлештеләр: Иринаның тураеп калган юеш чәчләре маңгаена, битләренә ябышкан, ә кофтасы!.. Чыланган батист кофтасы үтә күренмәлегә әйләнеп тәненә сыланган, бөтен җире... Гомумән, бу рәвешле аңа өйдәгеләргә кайтып күренү килешмәс.

Федор аулаграк урынга кереп ут якты. Ярый әле, үзе тәмәке тартмаса да, кесәсендә шырпы йөртү гадәтенә кергән. Мәрхүм доцент Василевский әйтә торган иде: «Чын ир кешенең кесәсендә ким дигәндә өч нәрсә — шырпы, пычак, бау булырга тиеш, шушы әйберләр булганда күп бәлаләрдән котылып була».

Киемнәрен киптереп алгач, Федор белән Ирина яланаяклап, балачага шикелле, җылы күлләвекләрне ера-ера, йөгерешә-йөгерешә өйләренә кайтып киткәннәр иде...

Яңгыр ява, ява... Тиз генә туктарга исәбе юк шикелле.

Аркасын чыршы кәүсәсенә терәп утырган Купцов якында гына яткан күркәне алып, әйләндерә-әйләндерә карый башлады. Күркә тышкы формасы белән гел чыршы агачын хәтерләтә: төптән очка таба нәзегәеп бара, орлык әрҗәләре дә, чыршы ботаклары шикелле, сулдан уңга, төптән очка таба бөтерелгән спираль ясап урнашканнар. Әйе, табигать биргәнен-булганын сак тотучы, хәстәрле хуҗабикә кебек, бар нәрсәсен бәрәкәт белән сарыф итә: чыршы ботакларының спираль ясап урнашуы аларга кояш нурларының тигез төшүе өчен кирәк булса, күркәләрен шулай ясап, аларга орлык әрҗәләрен күбрәк урнаштыруны «кайгырткан» табигать. Ярар, шулай да булсын ди. Нарат күркәләре дә чыршыныкына охшаган, ә ботаклары кәүсәсенә боҗра ясап урнашалар. Ә нигә алай?

Купцов кәефләнеп, үзалдына елмаеп куйды: яңгырдан качып, ялгызы гына агач төбендә, эшсезлеккә дучар булып утырган бәндә башына нинди генә уйлар килмәс!

Уйлар, уйлар...

Институтта укыганда Федор, үзләренә урман биологиясе буенча лекцияләр укыган доцент Аркадий Михайлович Василевский оештырган фәнни экспедицияләрдә катнашты. Яшьләре арасында аерма әллә ни зур булмаган доцент белән икенче курс студенты арасында ничектер тиз арада дусларча мөгамәлә урнашты. Себердә, гади урман каравылчысы семьясында туып үскән Аркадий һәм урманчы малае Федор — икесе дә мәктәпкә кергәнче үк урман әлифбасын үзләштергән, табигатьнең урман дигән могҗизасына гашыйк кешеләр булып чыктылар. Урманга булган мәхәббәт аларны төрле елларда төрле сукмаклар белән институтның Урманчылык факультетына алып килгән икән.

Өченче курсны тәмамлагач, Аркадий Михайлович белән Федор, Кама урманнарын айкап йөргәннәр иде. Кечкенә генә салда елганың иң югары очыннан Алабуга шәһәренә кадәр агып, Каманың һәр ике ярында туктала-туктала, бер ай буена үзенә күрә бер төрле экспедиция ясаган иде алар. Бу кызыклы да, гыйбрәтле дә сәяхәт бөтен ваклыклары белән исендә Купцовның.

...Яр Чаллыдан түбәнрәк бер борылыштан соң, кетмәгәндә каршыда Алабуга шәһәре пәйда булды. Каманың уң як ярыннан бераз читтәрәк, тау итәгендәге иңкүлеккә сыенып утырган бу бай сәүдәгәрләр мәркәзе үзенең туры, төзек урамнары, яшәргә уңайлы җыйнак йортлары, мәһабәт чиркәүләре, айлы манаралы агач мәчетләре белән сәяхәтчеләрдә матур тәэсир калдырган иде.

Василевскийның максаты Кама буендагы Шишкин наратларына сокланып кына йөрү түгел иде, әлбәттә. Рәсәйнең эчке урманнары һәртөрле чикләүче нормалардан тыш киселеп, урман ресурсларының елдан-ел азая баруы аңа мәгълүм иде. Кама буйларында йөргәндә ул тагы бер башбаштаклыкка шаһит булды: НЭП чорында тернәкләнгән сәүдәгәрләр, патша заманындагы шикелле үк, дәүләттән урманны тамырында көе сатып алып, берниндн плансыз-нисез, иң уңайлы, суга якын урыннарда гына кистереп, делянкаларны варварларча таптатып — изләреп, җәрәхәтләп, агачның каймагын гына җыеп, сал белән илнең үзәк өлкәләренә чыгарып сатуларын дәвам итәләр икән.

Кама буйлап бер-бер артлы агып торган, буйлары берәр чакрымлы салларга күрсәтеп, Василевский: «Кара, Федор, ул салларда бүрәнәләр түгел, ә башлары чабылып суга ташланган нарат, чыршы, каен гәүдәләре ага,— дигән иде, тәэсирләнеп.— Әгәр дә бу хәл шулай дәвам итсә, тагы бер унбиш-егерме елдан Кама ярларының гел шәрә калу ихтималы бик зур»...

Акрыная төшкән яңгыр, нәзек-көмеш таякчыклар белән миллион яшел барабан-яфракларны кагып, оркестр уйный. Аңа үзенең салмак борылмалары белән төбендә Купцов утырган чыршы-виолончель кушыла...

Яңгыр музыкасын тыңлап утыра торгач, Федор Иванович чыршы кәүсәсенә аркасын терәгән көе йокыга китте...

Кешеләрнең котын алып йөргән батыр аксак бүре дә, яшенле яңгырдан качып, үзенең яңа оясына — ботак өеме астына кереп ятты. Урман кисүчеләр якыная башлагач, ул Сары елга үзәнендәге оясын ташлап киткән иде. Тук чакларында кереп йоклардай аулак урынны гарип бүре озак эзләде. Коры, тирән елга буендагы иске ботак өеме аны канәгатьләндерде. Өем алдында кечкенә генә ачыклык. Бүре башын шул ачыклыкка куеп ята. Әгәр анда аның иң явыз дошманы — мылтыклы кеше күренсә, ерткычның ботак астында, елга ярына чыккан качар юлы бар.

Узган кыш, бер агайның биек коймасы аша сикереп качкан чакта, аксак бүре егылып, иске җәрәхәтен яңартты. Ул ботак астында Гөберчәк малаеның ядрәсе утырып калган иңбашы сөягенең сулкылдап сызлаганын тоеп ята.

Урманда яңгыр коя бирә. Яшен чатырдаган саен бүре сискәнеп китә, ботак астыннан чыгып чабасы килә җанварның. Бераздан яшьнәү-күкрәү авазлары ерагая төште. Акрынайа барган яңгырның тигез-тоньк тавышына йокымсырап, аксак бүре күзләрен йомды...

Болытлар таралып, көн аязгач, аксак бүре качып яткан оясыннан чыкты да ауга китте — бер-ике гамьсез куян баласын эләктереп, тамак ялгап алырга кирәк.

Күп җир дә китмәде, кинәт исеп куйган җил җәнлек борынына кеше исе китерде. Ул, куак артына посып, тирә-якны күзәтә-тыңлый башлады, һәм ерак та түгел, чыршы төбендә хәрәкәтсез утырган кешене күреп алды. Кешедән дары исе түгел, инде бүрегә күптән таныш булган сасы кләймә буявы исе килә иде. Ерткыч тагы да якынрак килде, чыршыдан ун адымнар гына булган зелпе куагы артыннан карап тора башлады. Аксак бүрегә бу кеше таныш, аның бу кешене урманда әллә ничә тапкыр очратканы бар, күзенә күренмичә генә артыннан йөргәне бар. Бу кеше беркайчан да мылтык тотып йөрми, бүреләр өчен ул куркыныч кеше түгел...

Кеше күзләрен ачты, җаны белән үзенең монда ялгыз түгеллеген сизде. Куак артыннан аңа туп-туры карап торган зур этне күреп алгач, ул ачы итеп сызгырып җибәрде. «Эт», алгы аягына авыр аксап, куаклар арасына сикереп күздән югалды.

«Э-э, менә син кем икәнсең! — диде аксак бүренең «егетлекләре» турында күп ишеткән Купцов. — Синең эшләрең бик мөшкел күренә, братец, җәен җәйләрсең дә бит, кышны ничек кышларсың икән бу кадәр гарип аягың белән...»

* * *

Печән өсте җитәрәк Тәүфыйкның башына бик шәп фикер килде. Аяк астында гына, тирә-якта, киртә буйларында — тездән үлән. Нигә аны чабып, киптереп, шалаш өстенә яба бармаска! Һәм малай шулай эшләде дә. Урман эчендәге кечкенә-кечкенә аланнарның да печәнен чабып шалашы өстенә өя башлады. Көз көне улы өйләренә ике ат йөге печән белән кайтып керсә, әнисенең шатлыгы түбәсеннән ашыр!

...Яңгырга Тәүфыйк печән хәстәре белән йөргәндә эләкте. Менә алар яңгырдан качып шалаш астында яталар. Яшен яшьнәп, күк шартлаган саен көчек сискәнеп китә, хуҗасына карый: «Абый, әллә баракка, абзыйлар янына элдерәбезме?» Якында гына яман каты чытырдаганнан соң каравылчы малай шалашыннан ничек атылып чыкканын үзе дә сизми калды. Муйнагын култык астына кыстырып, чиләкләп орган яңгыр астында поселокка таба чапты...

Барак чоланына җыелган агайлар, мужиклар тансык яңгырга көч биреп, куәт өстәп торалар:

— Әйдә, бик сагындырганиең, из инде измәсең!

— Так-так-так, давай-давай! — ди күрше барактан мичкә ясаучы урыс, яшен чытырдаганда.

Гафур абзый белән Михай дәдәй дә монда. Күк шатырдаган саен чуаш карты иманен китә, татарлардан күрептер инде, «писмилла, писмилла» дип яңакларын сыпыргалый.

...Ниһаять, дөнья җимерердәй булып дөбердәтеп, гөрелдәп яшеннәп килгән болыт, алан өстендә тонып явып торгач, бушанып, шинеп, хәлсезләнеп, сүлпән генә Шәрдән урманы артына китеп барды...

— Бу безнең авылда да яуды микән, Гафур абзый? — Тәүфыйкның баракка кергәч беренче соравы шул булды.

— Кайсы якта соң сезнең авылыгыз, энекәш?

— Болыт килгән якта иде...

— Алай булгач яугандыр, биргән булса, яугандыр, инләп килде бит, яумый калмагандыр сезнең авылда да, энекәш, бу бик тә кирәкле яңгыр булды. Бәлки, бүген монда кунарсың, энекәш?

— Юк, Гафур абзый, кандалалардан куркам, алар миңа тагы йокы бирмәсләр. «Әйе, әйе, абый, үз өебезгә кайтып йоклау хәерлерәк булыр, монда һава да бик шәптән түгел шикелле».

Көчек белән малай шалашларына кайтып киттеләр.

Икенче көнне иртән иртүк Тәүфыйк шалашка таба йомырылып йөгереп килгән Шураны күрде. Ул кулларын болгый-болгый кычкыра: «Тофик, Тофик, беләсеңме?!.»

«Дөньяның кайсы почмагы җимерелде икән инде? — дип уйлый малай, — нәрсә булды икән дөньяда?»

Ниһаять, Шура шалаш итәгенә килеп егылды. Кызыйның чәчләре тузган, сулуы капкан.

«Тофик... Тофик!.. Кичә урманда... яңгырдан качып чыршы астында утырганда... папаны чуть кенә аксак бүре ашап үтермәгән!... Ну прямо өч метрдан гына папага ун минут карап торган. Папа сызгырып җибәргәч кенә өч аягында сикергәләп качып киткән...»

* * *

Тәүфыйкның хәтерендә әле — Ташлыкта алар ике бүлмәле фатирда яшәгәннәр иде. Бервакыт шулай кич булгач, олы як бүлмәнең идәненә тезелешеп йокларга яткан балалары янына әтиләре кереп утырды. Ул, гадәттә, кәефе күтәренке вакытларында шулай эшли торган иде.

Бу юлы кәефе яхшы булмаса да, ул аны балаларына сиздермәскә тырышты. Мәликнең балалары янына керүенең максаты да икенчерәк иде инде — ул алар белән бергә озаграк булырга, күбрәк аларны тыңларга, һәрберсенең йөзен, әйткән сүзен, холкы-фигылен күңеленә сеңдереп калырга тели иде. Бюро әгъзаларыннан алар өчәү генә калдылар. Райземотдел мөдире Мәлик Гариповка да чират җитәчәк, бүген булмаса — иртәгә...

— Әти, әйдә, «кем-кем булыр»ны уйныйбыз, — диде Тәүфыйк әтиләр бүлмәгә килеп керүгә. — Әйдә, Зөлфәт абыйдан башлыйбыз!

Үз авыллары мулласыннан сабак тыңлаган, аннан соң Ташлыкта ике-өч ел урыс школасында укып калган Мәликнең хыялында аның балалары инде кемнәр генә булып бетмәделәр — укытучылар, инженерлар, врачлар, очучылар, артистлар...

— Әйдә алайса, башладык, — ди әтиләре.

— Стена кырыенда, сиздермәскә тырышып, йокларга яткач та китап укып ятучы олы улым, зирәк Зөлфәтем зур галим булыр, моңарчы кешеләрнең башы җитмәгән ачышлар ясап дөньяны таң калдырыр;

— Аның белән янәшә яткан уртанчы улым — тәүфыйклы Тәүфыйгым ерак диңгезләрне айкап йөрүче кораб капитаны булыр, яңа җирләр,

яңа илләр ачып Ватаныбызга дан китерер, үзе шөһрәт казанып, аның исеме китапларга язылыр.

— Әти, әти, минем капитан буласым килми, минем очучы буласым килә,— дип карышкан була алты яшьлек Тәүфыйк.— Юк, юк, әти, мин юри генә әйтәм, минем икесе дә буласым килә!

— Уртанчы улым кырында яткан җырчы кызым Фәрзәнә мәшһүр артистка булыр,— дип сүзен дәвам итә әтиләре,— ул бөтен илне гизеп йөрер, матур тавышы, моңы белән кешеләрнең күңелләрен дәртләндерер, хушландырыр;

— Синлесе Фәрзәнәне кочаклап яткан олы кызым миһербанлы доктор булыр, шифалы кулы, йомшак сүзе белән җирдәге барлык авыруларны сихәтләндереп, сәламәтләндереп йөрер...

Балалар куанышып, елмаешып тыңлап яталар.

— Әти, әти, а Мисбах кем булыр? — биш айлык энесенең дә кем булачагын беләсе килә Тәүфыйкның.

— Аның үзе белән киңәшмичә тәгаен бернәрсә дә әйтә алмыйм, әнә үзең дә икеләнеп тордың бит әле,— дигән була әтисе.

Менә шулай Мәлик Гарипов балалары белән, уртанчы улы Тәүфыйк яраткан, исемен дә үзе уйлап тапкан «кем-кем булыр» уены уйнап, хәвефле уйларыннан арынырга тырышып утырган иде ул кичтә. Бу уйнаулары соңгы мәртәбә булган икән...

Бер шимбәдә Мәлик эшеннән әйләнеп кайтмады. Хафаланып эзләргә чыгып киткән әниләре елап кайтып керде.

Атна-ун көн узгач, райисполком коменданты Колаксыз Афзал кереп, кәҗүнни фатирны ослобонить итәргә кушып чыгып китте: «Иртәгә үк штубы, враг народаның духы да калмасын, штубы!»

Олы улы Зөлфәт белән киңәшләшкәч, янадан Мираска кайтырга булдылар. Шәмсениса, ат-мазар юнәтеп булмасмы дип, иренең эшләгән җиренә барган иде дә, аңа борылып караучы да булмады. Инде базар көнгә кадәр көтеп торыйк, бәлки Мирастан Ташлыкка ат җигеп килгән кешеләр булыр, дип торганда, булачак яңа хуҗаларны ияртеп, фатирга тагын комендант Афзал килеп керде: «Ослобони фатираны, штубы»...

Шәмсениса чәпчеп китеп, Колаксызга кирәген ишеттерде дә, күрше марҗадан үрәчәле чана алып, аңа юрган, одеал, мендәр, кайбер савыт-сабаларны төяп, сабыен күтәреп, калган балаларын ияртеп, көн уртасында Ташлыктан чыгып китте. Барлы-юклы өй җиһазларын ат белән килеп алырлар.

Юл әйбәт кенә. Зөлфәт чананы алдан өстери, олы кызы таяк белән арттан этә. Алар артыннан Мисбахны күтәреп Шәмсениса, әниләре артыннан Фәрзәнә атлый.

Тәүфыйкка башта бу сәфәр бик ошады. Ул бер алга чыгып, бер артка калып уйнаклап барган иде дә, бара торгач арды, артка кала, елый башлады. Чанага аны да утыртырга туры килде.

Аршын буе гына гыйнвар көне караңгылана да башлады. «Хәерчегә җил каршы»,— дигән әйтем Шәмсениса, аның балалары шикелле бәхетсезләр юл җәфасы чиккәндә тугандыр,— кинәт әче җил чыгып, юл аркылы җәяүле буран себерә башлады. Мосафирларга баруы авырлашты. Чүп өстенә чүмәлә, дигәндәй, разбой салып сабый акырырга тотынды. Туктап аның чүпрәген алыштырдылар.

Ниһаять, караңгы төште. Җилнең, буранның туктарга исәпләре юк шикелле. Җилгә ян биреп бара торгач, ул бераз мәрхәмәтләнде, арттан исә башлады сыман.

Балалар тәмам гаҗизләнделәр. «Аякларым өшеп бетте инде»,— дип чанада Тәүфыйк елап бара, «Битем туңды, бармакларым өшеде»,— дип, әнисенең янәшәсендә Фәрзәнә шыңшып килә. Зөлфәт белән Һомаюнәнең генә тавышы-тыны юк, алар үҗәтләнеп чана өстерәүләрен беләләр.

«Хәзер, балакайларым, хәзер кайтып җитәбез,— дип юмалый Шәмсениса балаларын,— түзегез инде әз генә, түзегез!»

Чынлап та, алда карамчыкланып нәрсәдер күренә башлады. Барып житсәләр — башланган салам эскерте булып чыкты. Алдан чана тартып барган Зөлфәт, ялгышып, саламга бара торган юлга кереп киткән, күрәсең. Менә ни өчен жил аркага исә башлаган икән! Юл эскертләрдән ары китми, тупик...

«Инде нишләргә! Кире кайтып, җуйган юлны эзләп карарга мы? Таба алмасаң кырда адашып, бөтен балаларың белән укмашып катып үләрсең, тьфү, тьфү, әстәгъфирулла! И Ходаем, үземнең кәрәхтерем начар шул, фатирдан кусалар да, Ташлыктан куган кеше булмады бит аларны, пырдымсызланып Шәмсениса үзе чыгып китте бит! Йә, Аллам, бар икән күрсәтәселәрең! Бу сабыйларыннын ни гөнаһлары бар соң синең алдында?!»

— Улым, инде нишлик икән, кире чыгып карыйбызмы әллә? — ди Шәмсениса, үзенең ямьсез уйларыннан айнып.

Анын иң олы баласы, унбиш яшьлек акыллы малай Зөлфәт хәлләренең соң дәрәҗәдә мөшкел икәнен аңлый:

— Кире чыкмыйбыз, әни, жил каршы, балаларны өшетербез. Хәзер сез эскерт артына качып җилдән ышыкланып торыгыз, ә мин эскерттән салам йолкыйм.

Эшлекле Зөлфәт әнисе, энекәшләре-сеңлекәшләре янына кочак-кочак салам китереп куя:

— Хәзер менә җылынырбыз! Әни, шырпы кай тирәдә икән безнең?

— Һай, балам-җаным, мин шырпы алмадым бугай, — ди Шәмсениса өзгәләнеп. — Кемнәр уйлаган бит мондый бәлагә тарырбыз дип!

— Их, әни!... («Беттек болай булгач!» — дип тә өстәмәкче иде Зөлфәт, тыелып калды).

Җил бераз басылды шикелле басылуын, әмма салкын. Әчкә суык төшүдән котылу чарасы бер генә — эскерттән салам йолкып җылыну. Имезгәч тагы йоклап киткән Мисбахын инде күптән мәлҗерәгән Тәуфыйкгы янына чанага салып, аларны кат-кат юрганга төргәч, өлкән балалары белән рәткә басып, Шәмсениса үзе дә салам йолкый башлады.

Чирек сәгатьтән эскерт сутүчеләрнең эченә җылы керде, күңелләре күтәрелде. Юлга дип алган ипи кыерыгын сындыргалап ашап алгач, тагын тотындылар.

— Яшибез болай булгач! Тик артык тырышмаска, тәндә җылы тотарлык кына селкенергә, тән озын әле, — дип кисәтә Зөлфәт.

— Әни, әни, карале, монда таба нәрсәдер килә, — ди Һомаюнә, коты алынып әнисенә елышты.

— Һай, Аллам! Бүре, бүреләр!.. Берәү генә түгел, икәү! — Шәмсениса йоклап яткан балалары янына ташланды.

Чынлап та, алар кергән уңайдан эскәртә таба ике карамчык нәрсә якынлашып килә икән.

— Әни, алыгыз тизрәк чанадан савыт-сабаларны, пычак-чәнечкеләрне, — дип боера Зөлфәт, үзе авызына дүрт бармагын кабып, боргалапсыргалып сызгырырга тотына. Аңа ярсып таба, тәлинкә, кастрюльләрдә уйнаучылар оркестры кушыла. Шәмсениса пычак сырты белән таба кага-кага Алласына ялвара: «И Ходаем, булсаң, белгерт барлыгыңны, рәхмәтеңнән ташлама, коткар сабыйларымны ерткычларыннан, синең кодрәтең киңдер бит, газиз Аллам!»

— Туктагыз, туктагыз, монда таба килгән нәрсәләр бүре түгел! — ди Зөлфәт, — ник дисәң — беренчедән алар безнең шау-шуга колак салып, туктап торырга тиешләр иде, ә болар килә бирәләр. Икенчедән — бүреләр үзләренең корбаннарына җил уңаеннан якынлашмыйлар, минем бу турыда китаптан укыганым бар, өченчедән...

Өченчедән... аермачык булып ат пошкырганы, «На-а, әйдәле-е!» — дип ат куган авазлар ишетелде.

Персидәтелдән сорарга кыймыйча гына колхоз саламына килгән Шәйхелислам белән Фәтхелисламның кара төн уртасында, эскерт янында бер көтү бала-чагага юлыгырбыз дип башларына да килмәгәндер. Ат хуҗалары бик тә гаҗәпләнделәр.

— Сез кемнәр? Нишләп монда бу вакытта? Каян килеп чыктыгыз?

— И рәхмәтле Аллам! Бар икәнсең, бар бу дөньяда! Шәйхелислам абзый, җаным, сезне Алла үзе җибәргәндер!..

— Шәмсениса килен?!! Күрше?! Бәрә-ә-әч! Ни булды? Нишләп монда?

— Шәйхелислам абзый, тизрәк, тизрәк, зинһар өчен... балаларымны!..

Үлем куркынычы шулай кинәт юкка чыккач, бәхетсез хатын мәлҗерәп, елап, карга сыгылып төште...

Уңмаган юлга чыккан мәрхәмәтле салам караклары, чаналарына күшегеп бәткән бичара мосафирларны төяп, Мираска чаптылар.

* * *

Шәмсениса балалары белән тагы кайнатасы Сөнгатулла карт йортына кайтып сыенды. Үзе колхозның сыер фермасында эшли башлады,— коры хезмәт көненә эшләү булса да — даими эш, икмәге булмаса, саламы мул тияр, ичмасам.

Инде Мираска кайтып тора башлагач, бер көнне кич, тәрәзә кагып чыгарып, нindидер кеше Шәмсенисага папирос кәгазенә карандаш белән язылган кош теле хәтле генә хат биреп китте.

«Мин крипыч астында ятам, иртәгә язмышымны хәл итәчәкләр, әгәр алай-болай була калса — бәхил булыгыз. Шәмсениса, сиңа бер генә үтенечем бар — ничек кенә булса да балаларны укытырга тырыш. Мәлигең».

Бу хат Мәлик Гариповның беренче һәм соңгы хәбәре булды...

Шәмсениса балалары белән Мираска мәктәптә кышкы каникуллар вакытында кайтып егылган иде. Балаларының укуында өзеклек булмады. Каникуллар бетүгә, Һомаюнәсе Солы мәктәбенә йөри башлады, Фәрзәнәсе авыл мәктәбенең икенче классына утырды. Ә Зөлфәт Ташлыкта укуын дәвам итәргә тиеш, дип карар кылынды.

Бер якшәмбе базарын да калдырмаска гадәтләнгән, Ташлыкта әшнәләре, знакумнары күп булган Сөнгатулла карт, яраткан оныгына фатирны укыган мәктәбеннән якын гына җирдә үзе эзләп тапты.

Ятимлектә, фәкыйрьлектә яшәсәләр дә, Мәликнең балалары яхшы укыдылар, класстан-класска мактау кәгазе белән күчеп килделәр. Математикага аеруча сәләтле булган Зөлфәт Ташлык урта мәктәбен бик яхшыга тәмамлагач, Мирастан ерак булмаган күрше район үзәгендәге мәктәптә түбән классларда арифметика укыта башлады. Әнисенең үзе ашасын балаларына ашатып, үзе киясен балаларына киертеп, көн-төн алар өчен кызганганын күреп үскән акыллы, игелекле малай энекәшләресеңлекәшләре бераз аякка басканчы эшләп торырга булды. Ике-өч ел укытырга да, аннан Казан университетына укырга керергә,— физикаматематика факультетына, әлбәттә.

Әле түбән классларда укыган чагында ук Казан университеты Зөлфәтнең күңеленә кереп урнашты. Мәлик Сөнгатович шәһәргә барганда кайчакта үзе белән олы малаен да ала торган иде. Әтисе үз эшләрен майтарып йөргәндә малай университет янына китә. Каршы яктагы агач бакчадан кояш шикелле ике канатын җәеп тау өстендә утырган мәһабәт бинага карап, ыгы-зыгы кереп-чыгып йөргән бәхетле студентлардан көнләшеп, сәгатьләр буе бер урында басып тора иде ул. Һәр килүендә: «Мин дә монда укырга тиеш!» — дип үз-үзенә сүз бирә иде үҗәт малай...

* * *

Шәмәкнең мулла кушкан исеме Шаһимәрдән. Шәмәк — леспромхоз директоры Купцовның уң кулы. Кешеләргә ашарга юнәтү, атларга азык табу дисеңме, язын яшелчә бакчасын, солы басуын сукалату, чәчтерү, җәен атларга кыш чыгарга җитәрлек печән әзерләү, бараклар салдыру, подваллар казыту да, тагын әллә ниткән, көн саен чыгып торган вак-төяк хуҗалык эшләре — һәммәсе Шәмәк өстендә. Көн дими, төн дими, яңгыр дими, кар дими, арбага яки чанага җигелгән Акбәкәле белән йомышын үти тирә-юнь авылларга чаба, көн аралаш Шәрдән станцасында була, район үзәкләренә барып чыккалый.

Мәскәү яны сугышларында яраланып, сул аягы тездән бөгелмәс булып кайткач, Шәмәк колхоздан ычкына алды. Бу якты дөньяда азмыкүпме бәхетле булу өчен аңа ике генә нәрсә җитмәгән икән — азатлык һәм... ат!

Һәр эшеннән ләззәт тапкан Шәмәк бигрәк тә базарга йөрергә ярата. Иртәнге саф һавада үзенең дөлдәленә Балтач яисә Чепья базарларына җилдерткәндә ул чын мәгънәсендә җан вә тән рәхәте тоя. Базар кешеләре дә инде Шәмәкне, үзеннән бигрәк аның холыксыз айгыры Акбәләкне таныйлар. Ат хуҗасының базары югары, чөнки ит алса, ул түшкәләп ала, он, ярма алса — капчыклап. Тере малны да таный тәҗрибәле завхоз — сатулаша торгач, сораган бәядән шактый арзанга килешеп, хуҗа кеше белән кул сугыша.

Шәмәкне базарга тагы чабата хаҗәте китерә. Эшчеләргә чабата төткәрер хәл юк. Базар саен ат сыртыннан төяп алып кайта — атна ахырында складта ике-өч пар чабата кала. Товарлары үтемлегә әйләнгәнен сизгәч, керәшен карчыклары чабата хакын өч тәңкәгә күтәреп куймасыннармы!

— Юк инде, алай булмый, иптәш-товарищ әби карчыклар, — ди Шәмәк, — мин бит уптым илаһи алып, сезнең кадерле минутларыгызны саклап калам, ваклап сатып утырганда сезнең өегезгә кайтып тагы ничә кием чабата ясап ташларлык вакытыгыз сарыф була, сөекле әбиләрем, уйлап кына багыгыз әле!

— Жук, жук, Шәмәк, юкәсен урлавы да кыенлашты, урманга яңа каравылчы куйдылар, әгәренки тотсам сутка бирәм, дип куркыта, — ди, карчыкларның Начти исемле үткенрәге.

— Әйе, әби карчыклар, никадәр яшь юкә харап ителәдер урманда, бу тамашага каравылчының да түзәр хәле калмас шул, — ди Шәмәк, — аның бит сезнең чабаталарыгызны прәме базарда арестовать итәргә дә правасы бар, әйе-әйе!

— Кит инде!...

— Кодай күрсәтмәсен диген!...

Карчыкларның күңеленә пошаман төшә.

Шунда Шәмәкнең башына менә дигән фикер килә: нигә бу карчыклардан «Кырык алты»да чабата әртиле оештырмаска!

— Әби карчыклар! Сез чолан күләгәсендә генә утырып, каравылчыдан-нидән курыкмыйча, әзер юкә-мунчаладан гына, иртәдән кичкә кадәр чабата үреп утырырга риза булырыегызмы? Өстәвенә тагы... ашау — байдан, үлем — ходайдан, дигәндәй.

— И кодаем, кайда инде ул безгә андый өчтомак? — ди Начти түти, уфтанып.

— Килегез «Кырык алты»га, барысы да шулай булыр. Әле әйтергә оныткамын икән — көнаралаш иртәдән кичкә кадәр ягулы мунча булыр, җәй көннәрендә баш очыгызда тирәктә сандугач торыр — полный булмаса да — ярты оҗмах инде! Йә, карчыклар, ни диярсез?

...Бер көнне урман поселогына, бөтен житиясен кечкенә арбага салган, арба артына сыңар кәҗәсен таккан, озын юлда арган, әлсерәгән Начти карчык килеп керде. Ул үзе белән өч ахирәтен дә ияркткән.

Шәмәк аларның дүртесен дә бергә нәкъ урман кырыендагы баракка урнаштырды. Карчыклар икенче көнне үк эшкә тотындылар.

Тора-бара чабата әртилендәге әбиләр саны җидегә җитте. Алар хезмәттә алдынгы метод кулланып эшлиләр: ике карчык юкә ясап тора, икесе кайтара, икесе тезә, берсе киндерә ишә. Эш кайный гына!

Тәуфыйк еш кына әртилче карчыкларның эшләгәнен карап торырга килә. Әбиләрнең барсы да черт-черт чертләтеп сагыз чәйни, кайтарганда тезләрендәге чабаталарын, бәйләү бәйләгән шикелле, карамыйчы гына үрәләр. Кая әле Тәуфыйкка андый осталыкка ирешү!

Малай үзе ясаган чабаталарын Начти әбигә китереп күрсәтә. Мастер карчык чабаталарны бөгеп-сыгып карагач, мактый...

* * *

Тәуфыйк авылларына кайтып килергә булды. Бүген аның капчыгында дөнья байлыгы — ике кирпеч ипи, бер кило тары ярмасы, ике стаканлап булыр шикәр комы, өч кием чабата. Апаларына дигәннәренең башларын матур итеп Начти түти ясап бирде. Аның өстенә тагын Галимә апа әбисенә ярты кирпеч ипи, аз гына ярма, шикәр комы тыкты. «Энем-җаным, зинһар, ала күр. Үзем бу якшәмбедә кайта алмыйм, киләсендә кайтырмын, дип әйтте, диген әбигә». Бүтән кеше булса алмас иде, ә Галимә апаның сүзен тыңламыйча буламы соң? Җитмәсә тагы бакчаларыңны үзем карап торырмын, диде бит. Галимә апалар авылы Күкчә юл өстеннән ярты гына чакрым читтә кала.

Кайтыр юлга Мөнәвир белән бергә чыктылар. Ул да Мирас малае. Авызы бүрәнкәләнеп торганга авылда малайлар аны Бүрәнкә дип йөртәләр. Бүрәнкәнең дә капчыгында кирпеч ярым ипи, бер кило тары ярмасы икән.

Күкчә турысына җиткәч, Тәуфыйк Мөнәвиргә: «Син монда көтеп тор, мин тиз генә авылга кереп чыгам»,— дип китеп барды.

Галимә апаның әбисе мунча тикле генә ике тәрәзәле өйдә берүзе яшәп ята икән. Җил капка, алабута, әрекмән, кычыткан күкрәп үсеп утырган ишек алдында мәче сукмагы шикелле генә тар сукмак. Малай, әкияттәге ялмавыз карчык янына килгәндәй, шүрләп кенә өйгә керде. Ярым караңгы өйдә, сәке йөзлегендә калкынып бер карчык утыра. Яулык өстеннән башына карга оясы шикелле түгәрәк, сәләмә бүрек, күлмәк өстеннән җиңсез сырма кигән, үзе авыз эченнән генә мыгыр-мыгыр нәрсәдәр укына. Бичура дип уйлап, Тәуфыйк кире чыгып шылмакчы булган иде, «бичура» телгә килде:

— Курыкма, улым, миннән, курыкма, мин шундый ямьсез карчык инде. Салып тор биштәреңне, олан, җилкәләрең ял итсен, менә шулай. Кем дип әйтим инде сиңа, олан, син кем баласы буласың соң?

— Минем, әби, «Кырык алты»дан кайтып килешем. Галимә апа сиңа күчтәнәч җибәргәние,— дип, Тәуфыйк капчыгын чишә башлады.

— И-и-и балакаем-җан кисәгем, йөрәк парәм. Бу кадәр дә игелекле бала булыр икән, бәгырькәем. Көн дә күрәсеңме Галимә апаңны, улым, авырмыймы? Бик тә сагындым инде йөрәк парәмне, үзем кайтам димәдеме суң, улым?

— Киләсе якшәмбегә кайтам диде.

— Самавыр куеп җибәримме, улым?

— Юк, юк, әби, минем кайтып житәсем бар,— ди Тәуфыйк.

— Алайса бераз ял итеп утырып тор, олан.— Әби өйдәге берданбер артсыз урындыкка киез салды.

Әби карчык арлы-бирле йөргән арада малай өй эчен караштырып утырды. Түрдә тоташ сәке. Аның бер кырыена бик похтә итеп урын-җир җыеп куелган: кызыл тышлы түшәк, аның өстендә корама юрган, юрган өстендә чуар тышлы, бик һәйбәт итеп кабартып куелган мамык мендәр.

Стенадагы киштәдә китаплар.

— Галимә апаңның китаплары,— ди әби,— өч ел Солыда укып йөреп, жиде класс бетерде. Укуы би-ик шәп дип мактадылар укытучылары. Ә инде җыруга, биюгә дисәң — гел тамаша. Мәктәп белән барып авылларга кәнсиртләр күрсәтеп йөрделәр.

— Әби, Галимә апаның әтисе-әнисе бармы, алар кайда соң?

— Галимә апаңнар Донбаста торалары, олан. Сугыш башланырдан бер ел алда әтисе, әнисе белән кунакка кайтканнары. Улым минем шәхтедә күмер чыгара, өй салырлык акча юнәтеп булмасмы дип язылып киткәние, балакаем. Галимәгә би-и-ик тә ошады инде авыл. Тиз арада үзе шикелле күрше кызлары белән дуслашып алды, бергәләп урманга җиләккә йөрделәр, су коеныргa. Миңа бик тиз ияләште. Китәр вакытлары житкәч, мин монда калам, мин бабүшкәемне ялгыз калдырмыйм, дип жылый гына бит, жан кисәгем! Ярар инде алайса, диде Минхәерем, калса калып торсын әни синең янда, тагы бер срук — өч ел эшләгәч, без дә кайтырбыз, әни, диде, матур итеп, иркен итеп өй салып җибәрербез диде. Шулай итеп китеп бардылар. Башта хатлары, акчалары килеп торды. Сугыш башлангач та әле бер хатлары килгәние. Менә ике елдан артты инде хатлары юкка, немеч астында калып вәйран булдылар микән, балакайларым...

Сәке йөзлегенә утырган әби тавышсыз гына елый, әледән-әле яулыгы почмагына күз яшьләрен сөртә...

— Ярар, әби, мин китим инде, минем кайтасы юлым да байтак.— Тәүфыйк биштәрен киеп, ишек сабына тотынды.

— Тукта, тукта, олан, мә, бер пешкән күкәй бирим әле.

Әби, таягына таянып, Тәүфыйкны озата чыкты.

—Олан, Галимә апаңа әйт, киләсе елында кайта күрсен, би-ик сагындым. Дүрт күзем белән көтеп торырмын...

Малай олы юлга чыккач күрә — Бүрәнкә Мөнәвирдән җилләр искән.

...Мираска кайтып җитеп, үзләренең тыкрыкларына борылуга, Тәүфыйкның каршына энесе Мисбах томырылып «тәгәри» — аяклары җиргә тими бахырның. Килеп җитүе була, кочагын ачып торган абыйсының муенына асылына, аны үпкәндәй итә.

— Кайттың, кайттың! Мин белдем синең кайтасыңны, абый, мин сине сагындым!..

Тәүфыйк энесен җиргә төшереп, аңа бер кесәсеннән алдан ук әзерләп куйган бер сынык ипи, икенче кесәсеннән кишер чыгарып тоттыра.

Туганнар янәшә кайтып киләләр. Мисбах авызына ипи белән кишер дөнгечли, шунда ук дөнья хәлләре турында сөйләргә дә өлгерә:

— Касыйм абый кичә тегермән артында чеәүчәнгә ике бәртәс тотты, иң зурысы төшеп калды... Хәлимнәрнең Кәрләсе алты көчек китерде... Фәритнең әтисенең үлгән хәбәре килгән...

Тыкырык башында Мөнәвирнең сеңлесе очрады.

— Безнең абый да кайтмадымы, Тәүфыйк абый?

— Әле кайтып житмәде мени? Тешләрегезне кайрап торыгыз, бер капчык ипи күтәреп кайта абыегыз.

Тәүфыйк өйдәгеләргә бүләк өләште. Апалары Һомаюнә белән Дәрзәнә чабаталарын шунда ук киеп карадылар: һай да матурлар инде, икесенең дә аякларына тап-таман, үлчәп ясаган диярсең! Әнисе дә куанды: «Рәхмәт, улым, аягым чабатага туйды ичмасам син «Кырык алты»да эшли башлаганнан бирле». Әбисенә иң кадерле күчтәнәчне — бабасы җибәргән бер шырпы тартмасы чын бөртек чәй бирде.

Кич булгач, бөтенесе өстәл артында түгәрәкләнеп чәй эчәргә җыелдылар. Шәмсениса улын үзе белән янәшә түр башына утыртты. Ай-һай, аңа ипине дә калынрак кисеп куймады микән.

— Быел көзгә кайтырсың инде, улым, укуың кала, ачка үлмәбез әле,— ди әнисе Тәүфыйкка,— иллә ни булса безгә шул булыр...

— Күз күрер әле,— дип кенә җибәрә малае, өченче чынаяк чәенә чокырын сузып.

Чәй эчеп кенә бетергәннәр иде, ишегалдына бер кулында ярты кило ипи йомарлыгы тотып, икенче кулы белән малаен җитәкләп Мөнәвирнең анасы Сәгыйдә апа килеп керде.

— Тәүфыйк энем, чык әле, күпме ипие бар ие Мөнәвирнең капчыгында,— ди Сәгыйдә апа,— түлке дөресен әйт!

— Төп-төгәл кирпеч ярым ие, ә ни булган, Сәгыйдә апа?

— Менә бөтен булганы,— ди Бүрәнкәнең әнисе, кулындагы ипи йомарлыгын сузып.— Капчык төбеннән шушы килеп чыкты, тагы янчыкта әзрәк тары ярмасы.— Кая куйдың, улым, шулкадәр ипине? Таладылармы әллә юлда?

Бүрәнкә эндәшми, башын түбән игән дә лыш-лыш борынын тартып тик тора.

— Кая куйдың дим? Җавап бир ичмасам!— Сәгыйдә апа Мөнәвирнең колагын борып ала:— Кая куйдың димен?

— Ашадым...

— Ничек ашап бетермәк кирәк кирпечтән артык ипине коры көйгә, балам җаным, әллә берәр җиргә яшереп куйдыңмы?— дип өзгәләнә әнисе.

— Нигә коры көйгә булсын, суга манып ашадым. Янык чишмәсе буена утырып ашадым,— ди Бүрәнкә,— аннан соң Солы чишмәсе буенда, аннан соң Галия чишмәсеннән су эчтем...

— Шулкадәр ипи ничек эчләреңә сыеп бетте, балам-җаным?— Сәгыйдә апа малаеның башына чүкеп ала.— Сыер да ашап бетерә алмас шуның кадәр ипине.

— Ничек инде шыймашын ди, коршак бит ул режинка шикелле киңәя торган матриалдан эшләнгән,— ди, әллә каян килеп чыккан Барый,— күрмишенмени,— малаеның коршагы борынына тиеп тора...

— Һай, Барый, Барый, таптың тагы көләр мәзәк. Үз пычрагым үземә сасы түгел, әйдә, улым, кайтыйк.

Сәгыйдә, килгәндәге шикелле үк җилтерәтеп, малаен өйләренә алып кайтып китә.

* * *

Леспромхозда Тәүфыйк өчен иң күңелле урын — мастерскойлар. Елдан-ел киңәеп, берсенә-берсе төрттереп салынган, эчтән ишекләр, һәртөрле тәрәзә-тишекләр белән тоташкан цехларда нәрсә генә ясамыйлар! Аларда яңа гына стружкаланган йомычка, усак каерысы, буяу, кыздырган тимер, тәмәке төтене, тагы әллә нәрсә исләре, чүкелдәгән, гөрелтәгән, тукылдаган, зырылдаган, тагы әллә ниткән тавышлар. Бер цехта арба тәгәрмәчләре ясыйлар. Монда Мирасның балта остасы Газиз патшалык итә. Ул үзе әмәлләгән станокта тәгәрмәч бүкәннәре кыра. Бу эшне аннан башка бүтән булдыра алган кеше юк, һәрхәлдә, Газиз үзе шул фикердә. Калган осталар әзер бүкәннәрне тишеп кигн кагалар, тугым тарттыралар, кыршаулыйлар. Икенче бер цехта мичкә ясыйлар. Монда — гел урыслар.

Өченче цехта камыт агачы, балта, көрәк сабы, тагы әллә нәрсәләр юналар. Иң авыр эш арба-чана ясаган цехта башкарыла. Ул биналар тезмәсенең иң читтәгесенә, урман кырыендагысына, Сарысу буена урнашкан. Монда һава һәрвакытта парлы-дымлы, әчкелтем-төчкелтем, татлы-баллы исләр аңкып тора. Чөнки монда парда пешереп элмәдән, карамадан дуга, тәгәрмәч тугымы, чана табаны бөгәләр. Тыштан ягыла торган пар казаны авызы цех эченә ачыла. Осталар тәүлегенә өч-дүрт мәртәбә, казанны шыплап тутырып, баллы «агач боткасы» пешереп алалар.

Бөтен мастерскойларны гизеп, бөтенесенә хуҗа булып йөргән бер кеше бар — ул Санька-Немой. Бу уналты-унҗиде яшьлек телсез малай, көннәр буе бер цехтан икенчесенә йөгереп, идәндәге йомычкаларны вакытында җыеп, янып торган мичләргә ташлый, иң кирәкле чакта гына ул тегесенә дә, бусына да ярдәмгә килеп җитә. Йә тегермән куласасы шикелле зур, килбәтсез тәгәрмәчне әйләндереп, Газизнең кыру станогын зырлатып торыр, йә ул әле генә пар казанынннан чыгарган яркаларны бөгеп ятучыларга ярдәмгә ашыгыр. Малай көчен кызганмыйча, ихлас күңелдән тырыша. Әллә сыгылып килгән имән яркасы шыгырдый, әллә инде артык көчәнүдән Санькаің тешләре, умырткалары шыгырдыйлар...

Малайның тәгаенләнгән эше юк — ул цехларны җыештыручы да, мич ягучы да, ярдәмче эшче дә, аның өстенә тагын кочегар, су ташучы да, чөнки пар казанына — «парилкага» да ул яга, су җиткереп тора. Малайның фидакарь хезмәтен искә алып, Спиридонычның сукрануына карамастан, директор Купцов кушуы буенча, ана хезмәт хакын ике исемлек буенча — ярдәмче эшче һәм кочегар вазыйфалары өчен түлиләр.

Тәүфыйк леспромхозга килүгә, Саня аның белән дә дуслашып алды. Көндезге әбәт вакытларында ул каравылчы малайның шалашы янына йөгереп килеп китәргә дә вакыт таба. Тәүфыйк бармак ишарәләрен аңлап бетермәсә дә, аның йөрәген яхшы аңлый, ә телсез малайның күңеле гел изгелектә.

Санькага инде җегәр кергән. Аның аркасындагы, беләкләрендәге мускуллары кабарып, уйнаклап тора. Кичләрен аның яшендәге үсмерләр тимерче алачыгы янында аунап яткан ике потлы герне чөеп уйныйлар. Санька-Немой барсын да уздыра — ул сыңар кулы белән герне рәттән егерме мәртәбә баш өстенә чөя. Аннан соң егет-малайларның тагын бер көчсынаш уены бар — беләкләренә тегәрҗеп бәйлиләр дә, мускулларын кинәт катыралар. Шулай итеп кем ничә кат җепне өзә ала? Ярышучыларның күбесе бер катны да алдыра алмый. Бик чирәшә торгач, Мәче борын гына бер кат җепне җиңә, ике каты аңа да бирешми. Ә Санька бер дә көчәнми-нитми беләгенә ике кат ураган тегәрҗепне шартлатып өзеп ташлый.

Санька-Немойның башы да яхшы эшли икән. Сарысу ярыннан казан өстенә түгәрәк агачка чокып ясалган улаклар сузылган, яр буена чыгыр көйләнгән. Ике чиләкле бадья белән тугайдан чумырып алынган су «ә» дигәнче, улак өстендәге яңы тишек тимер кисмәккә аударыла, аннан улаклар буйлап казанга. Шатлыгының иге-чиге булмаган малай Тәүфыйкка бу корылмаларга ишарәләп, имән бармагы белән күкрәгенә, аннары маңгаена төртеп күрсәтә — мин боларны үзем уйлап таптым, янәсе...

* * *

Яшелчә бакчаларында эш беткәч, завхоз Шәмәк, Тәүфыйкны Габделхәй урынына конюшняга, ат караучы Хәсбулатка ярдәмче итеп куйды. Торырга да малай Габделхәй урынына, абзар эчендәге диннеккә күчте.

Диннекнең хуҗасы — шорник дәдә Василий. Йон гөнҗәләсе шикелле сакал-мыеклы йөзе, бөкере аркасы, карлыккан калын тавышы белән ул карт аюга охшый. Күз күргән кеше булмаса, бәлки, Тәүфыйк аның янында ялгызы гына төн кунарга шүрләгән дә булыр иде. Юк, дәдә Вася тыштан гына шулай куркыныч күренә, аны тормыш, картлык шулай эшләгән. Яхшы күңелле, миһербанлы кеше ул дәдә Василий.

Диннектә өрөзлексез диярлек тимер мич янып тора, җылы, рәхәт, кичен, атларны карап кергәч, бераз арган-талчыккан малай үзенең печән түшәлгән тапчанына сузылып ятып, шорник картның ат дирбияләрен төзәткәләп, ялгаштырып, ямаштырып утырганын күзәтергә ярата. Бабай

өстәленә тезеп салган эш кораллары арасыннан озак кына үзенә кирәген эзли, таба, ни өчендер аны әйләндерә-әйләндерә бик җентекләп карый, аннан соң гына эшкә тотына. Малайны гаҗәпләндергәне — дәдә Васяның күзләре. Алар кыйшайган, җимерелгән салам түбәле өйнең өр-яңа зәңгәр тәрәзәләре шикелле. Алар әле бик шәп күрәләр. Менә шорник ертылган камыт бөятен тегәргә җыена. Озак эзли торгач, каршында гына торган тегәрҗеп йомгагын таба, аңа кадап куелган чирмеш энәсен ала да, беренче омтылуда ук тегәрҗепкә саплап та куя! Кулыннан идәнгә төшеп киткән әйберен эзләп иелгәндә Василий бабайның сөякләре шыгырдый. Тәүфыйк тапчаныннан сикереп төшеп йә безен, йә уймагын табып биргәч, шорник карт, рәхмәт йөзеннән тагын бер мәртәбә малайның исемне сорыйсы итә:

— Ни атлы әле син, малай?

— Тәүфыйк исемле,— ди малай, инде ничәнче тапкырдыр.

— Туфяк... Туфяк... Ну и ну!...— Карт кәефләнеп башын чайкый,— татарны да әйтер идем инде — баласын таба, ә путевый исем таба белми, чудно!..

Озын, шыксыз кышкы төннәрдә шорник картка Тәүфыйк бер иптәш булды. Барсы белән дә кызыксынучан малайка, сораштырырга ярата, сөйләгәннәрне йотылып тыңлап утыра.

— Дәдә Вася, син татарча кайда өйрәндең? — дип сорый малай.

— Кайда булсын, беркайда да түгел... Гомер буе татар белән бергә яшәп, иңгә-иң куеп эшлә дә, аның телен белмә! Эштә татар урысча, ә рус татарча өйрәнә,— да-а-а... Мин әле чуточку удмурдча да, чуашча да сукалыйм,— да-а-а... а как же!...

— Ә Купцов абый кайдан татарча белә?

— Вот те на! Купцовның аның, Федор Ивановичның, әнисе татарка иде, да-да-а! Как ее — Рая, Рая... Разич!.. Да-да! Татарча исеме Разия иде... Ну и красавица была!.. Жаль только, бик яшьли үлеп китте. Федяга ул чакта унбер-унике яшьләр генә булгандыр... Әниләрнең бик кирәк чагы...

Купцов абыйның әнисе татар хатыны булган! Разия исемле! Менә кайдан белә икән ул татарча! Димәк, Купцов абый үзе дә яртылаш татар булып чыга! Бу — Тәүфыйк өчен зур ачыш иде.

— Син боларны, дәдә Вася, кайдан беләсең?

— Ничек инде белмәскә? Мин ведь ул чакларда «Круглая поляна» лесхозында конюх булып эшләдем... Кучер булып, Федяның атасын, Иван Степановичны, ничә еллар атта йөрттем, да-а-а... Ул лесхозда десятник булып йөргән чакта. Иван Степанович озын буйлы, имән яркасыдай таза кеше иде, да-а-а...

— Бик көчле идеме Купцов абыйның әтисе?

— О-о! Зверь! Һәр йодрыгы — бала башы! Киерелеп агачка балта чапса — балта түтәсенә кадәр чума, үзеннән башка берәү дә кире суырып чыгара алмый балтаны! Да-а-а... Бик туры сүзле, намуслы, вөҗданлы кеше иде Иван Степанович, туфрагы җиңел булгыры. Урманны ярата иде. Ә инде җырларга дисәң, Ө-ө! Эчәргә дә булдыра иде, мәрхүм. Бер утырганда бер шешә аракыны каплап куя пүчтәк кенә иде...

Шорник бабай тимер кружкасына яфрак чәй салып, кайнар су агыза, янә плитәгә пешерергә куя. Тумбочкасыннан ипи чыгарып, бер телем ипи кисеп ала да, ипине кире тумбочкага тыгып куя. Ипи телеменә мул итеп тоз сибә, аннан кружкасына өрә-өрә, ашыкмыйча гына, тәмләп кенә чәй эчә. Кичке ашын ашагандай иткәч, дәдә Вася чукынып ала, урыныннан тора, бераздан тагы килеп утыра.

Өстәлдән ипи валчыкларын учына себереп авызына каба. Курж-касына чәйнектән тагы су агыза, бер-ике йотым ясагач, кыяр-кыймас кына тумбочкасыннан тагы калган ипине ала, гаепле эш эшләгән сыман, нарда яткан малайкага карап ала, ипинең авырлыгын чамалагандай, учында селкетеп, әйләндерә-әйләндерә карый да, кире тумбочкасына

тыгып куя, ухылдый: «Ох-хо-хо!..» Кружкасындагы чәен эчеп бетереп, тагы эшенә тотына...

— Ә Федор Иванович абыйның туганнары бармы соң?— Тәүфыйк, өзелгән сүзне ялгарга тырышып, шул сорауны бирә.

— Да-а, Иван Степановичның яшь хатыны тагын бер малай тапкаые. Юк, Николай непутевый булып үсте. Татар әйтә ведь, аттан ала да туа, кола да туа, дип. Манка башыннан атка атланып чыгып, урманда хатын-кызларга бәйләнеп йөри башлады, укырга хирысы булмады. Ә Федор укыды, шәп укыды! Школны укып бетергәч, Мәскәүгә барды, урман буенча укырга, да-а-а... Укып чыкты, и шунда калды. У-у! Федор Иванович бик зур укыган кеше, да-а-а...

— Ә Федор Иванович белән тагы ничек очраштыгыз соң?

— А-а-а... Картайгач кешене туган иленә тарта, диләр. Мин дә үземнең туган авылым Ключига кайтып егыласы иттем, ата-бабалар белән бер зиратка ятырга дип, да-а-а...

Утырам шулай, җәй көне, өй янындагы лавкада... күрше карты белән дөньяга зарланып... Шунда берәү килә дә: «Исәнме, дядя Вася, Василий Никифорович»,— дип авызын ерып тора каршымда. Ә мин танымыйм, да-а-а... «Мин Федя, Федор Купцов, десятник Иван Купцов малае!»— дигәч ышандым инде. Мәскәүгә киткәндә нәзек-озын үсмер иде, ә каршымда — мыеклы ир уртасы кеше тора... да-а-а. Ә ведь күпме гомер үткән, күрешмәгәнгә дип әйтүем... Мин син, Василий Никифорович, тавышыңнан таныдым, ди. Тормыш хәлләрен сорашты. Эшләр мөшкел, минәйтәм, Федор Иванович... Ул әйтә, иртәгә үк, Василий Никифорович, леспромхозга кил, ди. Көчеңнән килердәй эш табарга тырышырбыз, ди... Менә шулай итеп, мин монда инде, да-а-а...

Тагын бер серне ачасы килә малайның:

— Дәдә Василий, ә нигә икесе генә калганда тимерче Григорий Купцов абыйга Федя дип кенә эндәшә, ә кеше барында — «Федор Иваныч»?

— А-а-а... Син смышленый малайка!.. Гришка белән Федя ведь бергә уйнап үстеләр, алар яшьтәшләр дә. Гришка лесхоз тимерчесе малае иде... Ә менә язмышлары... Григорийны Федор Иванович Шәрдән вокзалында исереп аунап яткан җиреннән алып кайткан... Эчмәгән чакта ул менә дигән тимерче, тимердән гөлләр коярга может, ә инде эчеп алса — диңгез тубыктан... өч көн, бер атна запоем эчеп йөри, да-а-а...

Тәүфыйкның сораулары табылып кына тора:

— Дәдә Василий, ә кем шәбрәк эшли урманда — татармы, удмуртмы, чуашмы?

Шорник карт, гадәтенчә, җавап биргәнче, бераз эше белән маташа, көттерә малайканы.

— Татар бүрәнәнең юан башыннан күтәрергә тырыша, да-а-а... ... честный халык татарлар...

— Ә удмуртлар?

— Удмурт урман эшенә бик гайрәтле халык, у-у, җен кебек удмурт урман эшенә...

— Ә чуашлар нинди эшкә оста?

— Чуаш бура бурарга, такта ярырга мастер, менә дигән итеп өй сала, итек баса чуаш.

— Ә керәшеннәр?

— Кряшен... кряшен чабата ясарга оста.

— Нишләп аларны «керәшен» дигәннәр, дәдә Вася?

— Кряшен ул — иманын алыштырган татар... Татардан киткән, урыска барып җитмәгән... җир белән күк арасында асылынып калган кряшен, да-а-а... Иван Грозный дигән патша татарны чукындырып бик зур гөнаһ эшләгән... Кагылма кешенең верасына!.. Һәркемнең үз верасы булырга тиеш... Кеше дөньяда верасыз яши алмый, да-а-а...

— Дәдә Вася, ә дядя Вася, сиңа ничә яшь инде?

— Миңамы?.. Ленин бабаеңа ничә яшь икәнен беләсеңме?

— Беләм!

— Белсәң вот шул — Ленин бабаң туганда мин инде каз күтәрлек малай булганмын. Ну, ничә яшь була миңа? Вот чутлап кара!..— Дядя Вася хәйләкәр елмая.

Тәүфыйк бу табышмакка җавап эзләп баш ваткан арада, шорник карт бүгенгә эшләрен бетереп, иске тунын ябынып нарына сузылды: «Охо-хо-о-о!»..

Күп, бик күп нәрсәләр белде бүгенге кичтә Тәүфыйк. Бөтен ишеткәннәрен яңадан бер мәртәбә башыннан уздырып, ул озак йокламый ятты. Малай бүтән чакларда Василий бабайдан алдарак йокыга китә торган иде, бүген киресенчә булды.

* * *

Салкын, шыксыз февраль төнендә диннек тәрәзәсен шакыдылар. Дәдә Вася ахылдап-ахылдап урыныннан торды, фонарның утын күтәрде, мыркылдый-мыркылдый чыгып, ишекне ачты.

— Ни шайтаным йөри анда, кара төн уртасында?

— Бу мин, дядя Вася, Габделхәй, Абдулка,— диде ике култык таягына таянып, ишек авызында торган шинельле кеше.

— Абдулка?! Тавышың ошаган. Кер соң, кер, да-а-а!..

... Кайнар чәй эчеп, азрак эченә җылы кергәч Габделхәй сөйләп китте:

Ул поездда юл буе уйлап-уйлап кайткан да, төшәсе станцасына килеп җиткәнче Шәрдәндә төшеп калырга булган. Авылдан хат язганнар, әбиең үлде, дип. Анда аяксыз кайтып керердәй бүтән туган-тумачалары юк икән. Шулай итеп, элек эшләгән җиренә — леспромхозга кайтырга булган, яхшы күңелле кешеләр эшләгән җиргә. Берәр төрле эш табылыр әле, дип уйлаган, аннан тагы киләчәктә күз күрер, дип Шәрдәннән монда кадәр биш чакрым араны өч-дүрт сәгать кайткан. Атлаган саен култык таяклары карга кереп батканнар, һәм адымын мең газап белән ясаган...

— Да-а-а... Кай арада әле немец, синең аягыңны дим, болай бик аккуратный итеп оттяпал? — Вася дәдә сыкранып башын чайкады.— Киткәнеңә әле бит синең...

— Наступлениегә күчәргә торганда гына фашист безнең өскә мина яудырырга тотынды. Кыямәт көне ясады нимес! Бик күп кеше кырылды. Шунда мина кыйпылчыгы белән минем аякны да харап итте, тездән түбән...

Йокларга Габделхәй Тәүфыйк тапчанына, аның белән янәшә ятты.

— Йә ни хәлләр, ни яңалыклар бар леспромхозда, энекәш? — дип пышылдады Габделхәй.

— Синнән соң тагы дүрт-биш кешене сугышка алдылар. Урман чыгаручы Әхмәтнең инде үлгән хәбәре килде, кисмәк ясаучы Сергей хәбәрсез югалган.

— Тагы, тагы!..

— Тагын, ни... Мәче борын Галимә апаның артыннан бик каты чабып караганые да, барып чыкмады. Нишләп аңа карасын соң Галимә апа?! Шулай бит, Габделхәй абый?

Малайның бу хәбәре егетнең йөрәгенә сары май булып ятты...

Икенче көнне Габделхәй конторга китте, үзенең хәл-әхвәлен Шәмәккә сөйләп бирде: «Менә шундый-шундый хәлләр, Шаһимәрдән абый».

Шәмәк солдатка бер атна-ун көн ял итәргә кушты, аннан соң конюшнядә атларга фураж биреп торырсың, диде. Спиридонычтан ун көн ашханәдә түләүсез ашарга талон яздырып алып бирде, Купцовтан ике кило ипилек талон алып чыгып тоттырды...

Шулай итеп, Габделхәйнең тормышы җайланды шикелле. Ләкин, ләкин... Аның яңадан Шәрдән леспромхозына кайтып төшүенең төп сәбәбе — Галимә иде. Теге вакытларда йөрәгендәгесен әйтеп бирергә

егетнең кыюлыгы житмәде. Аннан соң көтмәгәндә каралырга барган жиреннән «Годен»,— дип, туп-туры сугышка алып куйдылар үзен.

Кайтканына инде айдан артык булса да, Габделхәйнең Галимәне күргәне юк. Ул авырып яткан әбисен карап торырга авылларына кайтып киткән икән. Бу хәбәрне «разведчик» Тәүфыйк китерде.

Гарипләнеп кайткан егет кыз белән очрашудан курка да иде. Галимә аның агач аягын күреп өркер, күнеле кайтыр һәм үксез егет Габделхәй бу дөньяда бердәнбер кадерле, жаны тарткан кешесен югалтыр.

Бер көнне шулай алачык яныннан узып барганда Габделхәйне Гәргәри чакырып алды: «Кер әле монда!»

Габделхәй керде, сәлам бирде. Алачыкта, тимерчедән башка, арбачана цехында эшләүче Кузьма атлы керәшен дә бар иде. «Кәефләнеп» утыралар икән.

Сандалына атланып утырган тимерче бервакыт Габделхәйнең агач аягына карап торды, сүнгән төрепкәсен кабызып, рәхәтләнеп, үпкәләрен тутырып төтен суыргач, ниһаять, телгә килде:

— Не годится синдәй жегеткә чурбан өстерәп жөрү!..

Кузьма-Кузна да сугышта тездән түбән сул аягын өздереп кайткан кеше. Бер ел инде ул фабричный протез киеп йөри, аек йөргәндә аның аксаганы сизелми дә диярлек.

Кузна зур мәшәкатьләр белән, мышный-мышный беркетеп бәйләгән каешларын чишеп, протезын салды, тыгызлап киерткән кирза итегеннән арындырды.

Гәргәри, фабричный аякны күтәреп, тәрәзә яктысына килде. Әйләндерә-әйләндерә карады, бөкте, сыкты, балтырына, табанына чирткәләде, сандалына терәп бастырып куеп, уйланып торды.

— Булдырам, жасыйм! Сиңа фабричный аяк жасыйм, Габдулхай! Миңа кысалык ике буй дүрәл генә кирәк булыр, калган материалны үзем жүнәтермен. Син, Габдулхай, үлчәү бирергә кереп жерерсең, ә син, Кузна, тоже утырмага килерсең. Миңа аягыңны салып бирәсең дә, бүкәненә кунаклап аракы чөмереп утырасың, хы-хы-хы!..

Иртүк килеп, кичләрен эштән соң алып калып Гәргәри алачыкта протез ясау белән мәшгуль булды. Шәмәк юнәткән дүрәл таяклардан башта аның кысасын әмәлләде, аңа табан ясап беркетеп куйды. Кузьма салып куйган протездан үрнәк ала-ала, булачак аякның тимер, агач, фанер, күн, киез өлгеләрен Габделхәйдән алган үлчәүләргә туры китереп кисте, тиште, игәде, чүкеде, яньчеде, шомартты, текте, ябыштырды. Булачак хужасына киертеп карый-карый тимерче инде әзер әгъзаны кат-кат көйләде, кайсы төшен тарайтты, кайсы жирен киңәйтә төште.

Шулай бер атна азаплангач, аяк һәр ике якны канәгатьләндерерлек камиллеккә иреште.

— Носи на здаровье! — диде Гәргәри.

Габделхәй өчен газаплы көннәр, атналар башланды. Беренче көннәрне аның бигрәк тә жәзалы булды. Иртән торуга, ул, бәби биләгән шикелле, аягын биләүгә урап протезын кия дә, сыңар таякка таянып диннектә йөренә башлый. Биш адым, ун, егерме, йөз... Аннан соң бер очтан бер-очка конюшнә коридорын таптый: кара тиргә төшкәнче, бөтен әрнүләренә тешен кысып түзеп...

Габделхәйгә протезда йөрергә генә түгел, аңа таяксыз һәм аксамыйча йөрергә өйрәнергә кирәк! Үзен-үзе каһәрли, жәберли торгач, үжәт егет максатына ирешә — бер айдан ул «Кырык алты» алачыгында керәшен Гәргәри ясап биргән протез аягында никадәр кирәк, шул араны таяксызнисез йөри башлады. Ул Тәүфыйкка үзе артыннан карап торырга куша. «Ура-а, Габделхәй абый! Аксаганың бер бөртек тә сизелми ичмасам! — дип кычкыра малай,— кайткач Галимә апа да бер нәрсә дә сизмәс!»

* * *

Аксак бүре ботак өеме астындагы җылы куышыннан чыкты. Ул бүген начар йоклады. Ач карынга бүреләрнең дә йокысы йокы түгел. Тирә-як авылларын кыдырып, кешеләрнең котын алып йөргән мәшһүр ерткычның рәвеше кызганыч иде. Курку белмәс җанвар йолкыш мәхлукка әйләнгән. Быелгы салкын килгән кышта кыш буе аксак бүренең кайнар аш җыйганы булмады. Ул әҗәле җитеп үлгән кошкортларны ботарлап, бүтәннәрнең мул табынынннан калган сөякләрне кимереп җан асрады.

Ачлыктан аңы томалана башлаган, җан саклау инстинкты тупыйкланган аксак бүре, караңгы төшкәнне дә көтмичә көпә-көндез кешеләр, хайваннар яшәгән алан ягына титаклады...

Башында Начты түти Марфасы торган кәҗә көтүе, конюшнә тирәсендә җиргә коелган печән-мазар чемченеп йөри. Әле яңа гына дөньяга килгән, исәеп, беренче мәртәбә генә тышка чыккан кәҗә бәтиләре дә әнкәләре тирәсендә сикерешеп уйнаклый. Аларның әле берсе, әле икенчесе үз әниләренең корсак астына кереп, тезләнеп, төймә кадәр генә койрыгын болгый-болгый, мул сөтле имчәкне бер-ике мәртәбә суырып ала да, торып-китеп, тагы уйнаклый, сикергәли башлый. Алар моны имәсе килгәннән эшләми, юк, юк! Бәхетле сабыйлар: «Бу минем әнием, ә бусы минеке!» — дип, бер-берсенә үзләренең сөекле әниләрен күрсәтер өчен генә үзләренчә кыланган булалар.

Коры печән кетердәтеп кыш чыккан, инде сусыл азык тансыклаган кәҗә халкын командир Маня ат абзары артындагы таллыкка алып китте. Март кояшы астында инде тернәкләнеп, бөреләре бүртеп килгән талтуйра бәбәген кыркып кинәнделәр генә кәҗәләр!

Ләкин карт юлбашчының күңеле нигәдер тыныч түгел иде, аның җаны нәрсәдер сизенде. Ах, әнә ул дошман! Бүре!!! Әле дус белән дошманны аерырга өйрәнмәгән, зурлардан күрмәкче, тездән карга батып, тырышатырыша тал чыбыгы кимерергә азапланган гамьсез бәтигә таба куаклар артына поса-поса йөзе кара бүре якынлашып килә. Алты адым, биш адым...

Карт кәҗә, хәвефле тавыш белән бакырып, залимнең юлына аркылы төште. Башка кәҗәләр, бәтиләрен ияртеп, җан-фәрман поселокка таба чаптылар. Начти түтинең кәҗәсе башын иеп, кыршылган, кителгән мөгезләрен бүрегә таба төбәде. Алышу күз ачып йомганчы тәмам булды: тәҗрибәле аксак бүре, кинәт яннан сикереп бичара кәҗәнең бугазына тешләрен батырды. Ач ерткыч, ниһаять, авызында җылы, куе кан тоеп, рәхәтлектән исереп, бер мәлгә мәлҗерәп китте. Ләкин җан тәслим кылган корбанын урман куелыгына өстерәп китәргә кирәк иде. Ачлыктан хәлсезләнгән, гарип ерткыч үле кәҗә гәүдәсен өстерәп карады. Урыныннан да кузгата алмагач, яткан җирендә ботарларга булды, ләкин тешләрен кәҗәнең бугазыннан ала алмады — кинәт көзән җыерудан бүренең яңак мускуллары тартылып калган иде...

Шәрдәнгә утын чыгарып кайтып килүче Мәче борын, абзар артындагы вак таллыкта, нинди дер соры этнең урманга таба нәрсәнедер өстерәп азапланганын күрде. Сызгыргач та эт качмады, әйберсен тагы да ярсыбрак өстерәргә тотынды. Сәерсенгән малай атын туктатты, кулына чана башына кыстырган балтасын алып, эт янына килсә — ни күрсен! — эт дигәне бүре булып чыкты! Аксак бүре! Ул аны әллә ничә тапкыр очратты Шәрдән урманында. Аксак бүре Начти карчыкның кәҗәсен буган! Мәче борын куркаклардан түгел иде. Кәҗәсеннән ычкына алмаган бүренең түбәсенә балта түтәсе белән — раз берне, аннан соң тагы, тагы!...

Шулай итеп, кешеләргә бихисап золымлык эшләгән батыр аксак бүренең кара каны белән гөнаһсыз батыр кәҗә каны бергә буталып, бер үк җиргә актылар...

* * *

Купцов инде күптән үзе туып-үскән «Түгәрәк алан» лесхозына барып кайтырга уйлап йөри иде. Ниһаять, ул тәвәккәлләп юлга чыкты. Моңа Мәскәүдән алган хат та сәбәпче булды.

Федор Иванович әле февраль аенда ук элек эшләгән институтының директор урынбасарына — чын галим, намуслы кеше профессор Гусевның өенә — үзенең хәзерге хәл-әхвәлен сөйләп, башкала, институт хәлләрен сораштырып, хат язып салган иде. Җавап булмады. Бәлки, Борис Михайлович инде күптән бу фани дөньяда юктыр.

Көтмәгәндә, инде өмет өзгәч, Гусевтан хат килеп төште. Борис Михайлович ел башында хатыны белән Чистайдан эвакуациядән кайтканын, Мәскәүдә тормышның көннән-көн тернәкләнә баруын язган. Җавап белән тоткарлануының сәбәбе — институтларының язмышы тулысынча ачыклануын көткән икән. «Шатланып хәбәр итәм, — дип язган Борис Михайлович, — 1944 елның көзеннән безнең институт тагын эшли башлаячак, һәм мин, гыйльми эшләр буенча директор урынбасары буларак, сезне — гаепсезлеге расланган кешене, югары квалификацияле белгечне, институтка эшкә чакырам, лаеклы эш урыны гарантиялим, уңай җавап бирерсез дип ышанам, тиз көннәрдә күрешергә өметләнәм...»

Федор Иванович Гусевның хатын Иринасына бирде дә, каршысына утырып, аның укыганын күзәтә башлады...

Зур кызыксыну белән укыган, эчендәге кичерешләре йөзендә чагылып торган Ирина, хатның Мәскәүгә кайтырга чакырган төшенә килеп житкәч, урыныннан сикереп торып, иренең муеныннан кочаклап алды: «Федя, Феденька, дорогой, наконец-то! — дип Феденькасын күз яшьләренә чылатып, битләреннән үбәргә тотынды. — Наконец-то! Син, әлбәттә, уңай җавап бирергә тиешсең».

Әйе, әйе, ул Гусевка уңай җавап бирәчәк. Бу бичара хатын иренең бәхетсез язмышын уртаклашып менә алтынчы ел инде михнәт күрә, җәфа чигә түгелме соң? Башкалада туып-үскән кыз, меломан, театрал, өченче ел инде электрсыз урман поселогында, тупас урман эшчеләре арасында яши, кирза итектән язгы-көзге пычракны ерып, зарлану, зарыгу, уфтану галәмәтләре күрсәтмичә, дүрт чакрым җиргә җәяүләп эшкә йөри. Моның өчен бик акыллы, тугрылыклы, түземле булырга кирәктер. Бу сыйфатларның иң тотрыксызы — соңгысы. Аның шулай икәнен хатынының күз яшьләре раслый — түземлекнең дә чиге бар.

— Мин әлбәттә Гусевка институтка эшкә кайтырга ризалык биреп хат язачакмын, — диде Федор Иванович, үзенә елышкан хатынының җилкәләреннән кочып. — Ләкин бу инде Мәскәүгә кайтып киттек дигән сүз түгел әле, әллә нинди көтелмәгән хәлләр, низаглар килеп чыгуы бар. Вакытыннан алда леспромхозда имеш-мимеш хәбәрләр таралуның һич тә кирәге юк, — диде аннары, җитдиләнеп.

— Мин дә шулай уйлыйм, Федя. — Бу фикердә хатыны ире белән ризалашты. Ә Мәскәүгә кайтып киткәнче ул, әлбәттә, әнисе һәм әтисенең каберләрен зыярәт кылырга тиеш.

* * *

Лесхоз урнашкан аланга җиткәч, Купцов икеләнеп туктап калды. «Ялгыштым, ахрысы...» Аның каршында ул белгән, әкияттәгедәй матур төзек Урман патшалыгы урынында биш-алты искергән йорт, тузып кыйшайган, вәйран булган хуҗалык корылмалары пәйда булды. Лесхоз биләмәсен уратып алган, чыпчык очып керә алмаслык коймалар юкка чыккан. Триумфаль арка кебек мәһабәт, җәй көннәрендә, гадәттә, түбәнә кадәр ачык була торган Олы капканың ялангач калган имән баганалары гына тырпаеп калган.

Федор Иванович, бераз кайсы якка барырга белми торганнан соң, элек үзләре яшәгән йортка таба атлады. Кое янындагы сулы тагаракта каз бәбкәләре йөздереп азапланган күлмәк-ыштансыз малайлар, бермәлгә шөгыльләрен ташлап, үзләренә таба килгән ят кешегә шүрләбрәк карап тордылар да, ул узып киткәч, чыр-чу килеп, яңадан игелекле эшләренә тотындылар.

Йорт өстендә кояшта кызынып яткан карт эт, иренеп кенә, ялкау гына селкенеп, икенче тәшкә барып бәргәләнде.

Купцов йорт янындагы эскәмиядә утырган карт белән карчык алдына килеп туктады:

— Исәннәрмесез!

Икесе өчен дә карт җавап бирде:

— Тәндә җан бар әле...

— Нишләп алай бик күңелсез генә, дядя Сережа?

Карт каршыларында елмаеп басып торган кешегә сынап карады, танымаганын белдереп, як-якка башын чайкады, көн дә ят кешеләр күрергә өйрәнгәнгә, исе китмичә генә үзе яныннан урын күрсәтте:

— Утырып тор, әмма уңмаган юлга чыккансың, бүген начальстводан берәү дә юк,— диде.

— Тетя Маша, син дә танымыйсыңмы? — Купцов һаман да картлар каршында басып тора бирде.

Хәтеренә төшереп, саквояжлы озын кешенең йөзенә текәлеп карый торгач, карчыкның чырае яктырып китте:

— Батюшки! Федя... Федор Купцов никак! Как же так, танымый да торабыз икән ич, картлачлар! — әби кулларын җәеп бот чабып алды.

Картлар җанланып киттеләр.

— Сколько лет, сколько зим, танымассың да шул! Әле кайлардан килеп чыктың? Әйдә, әйдә өйгә керик, Федя... Федор Иванович!

Кадерле кунак хөрмәтенә хәстәрләнгән өстәл артында гомере буе янгынчы булып эшләгән дядя Сережа лесхоз хәлләрен сөйләде.

— Шалагиннан соң мантымады лесхоз, сүнде, бетүгә йөз тотты. Май чүлмәге тышыннан билгеле, ди татар. Ишек алдындагы йортларны, каралтыларны күргәнсеңдер инде, май чүлмәге түгел, чүп чүлмәкләре. Шундый хәлдә идемени алар Алексей Петрович заманында! Гөрләп торалары, гөрләп! Ул үлгәч әллә ничә лесничий алмашынды инде, әмма берсеннән дә уңмадык. Кайсы эчкече булып чыкты, кайсы урман сатарга гаярь булды. Юк! Шалагинга житү кая ул! Алексей Петрович гел урман өчен туган изге җан булган икән. Ул исән чакта урманда сандугачлар да җәй буе сайрый торганнарые, билләһи! Аннан соң менә бу сугыш афәте... Ир затыннан сау-сәламәт кеше калмады инде лесхозда — җыен аксак, чулак, карт-коры да хатын-кыз...

Федор Иванович, форсаттан файдаланып, үзенең монда кайтуының максаты — әнисе белән әтисенең каберләрен зыярат кылу икәнен, вакыты аз булганын, мөмкин булса бүген үк әтисенең каберенә барасы килгәнен әйтте.

— Хуплыйм изге максатыңны, бик хуплыйм, Федор Иванович, әйдә, хәзер үк барып киләбез мәрхүмнең каберенә.

Карт Федор Ивановичны лесхоз утарыннан бер километр-километр ярым җирдәге Торналар күленә алып китте.

Күл буена чыккач, пожарник карт Купцовны текә, биек яр өстендә үсеп утырган ике нарат янына алып килде.

— Менә бусының астында Шалагин йоклый, Алексей Петрович... Үзе шушында күмәргә васыять әйтте. Ул монда бик еш килеп, табигатькә хозурланып утыра торган иде. Каберен нәкъ аның утырып тора торган эскәмиясе янына казыдык. Ә менә бу яшь нарат Иван Степанович өстендә үсеп утыра инде...

Федор Иванович, юан нарат бүрәнәләрдән бурап салынган уртак чардуганга таянып, тынып калды...

Федор Иванович, авыр сулап, урыныннан кузгалды, башын иеп атасының, лесничийның каберләре белән хушлашты да, урман хуҗалыгы утарына таба кайтып китте. Юл уңаенда аның тагын бер аланга кереп чыгасы бар иде әле.

Менә ул «Түгәрәк алан»! Ул бөтенләй диярлек үзгәрмәгән. Һәр җайдә печәнен чабып торгангадыр, агач та басып китмәгән үзен. Күче-күче белән утырган балан куаклары, җир җиләге үсә торган сөзәк калкулык, алдан уртасында җәелеп утырган ялгыз наратлар да үз урыннарында...

Кояшлы матур җәй көннәрендә, өйләренә якын бу ачыклыкка әнисе кечкенә Федя-Фәритне бик еш алып килә торган иде. Монда алар татарча гына сөйләшәләр. Әнисе Фәриткә чәчәк исемнәрен, төсләрен аңлата: «Бу — ак чәчәк, бусы — зәңгәр, бусы — кызыл, бусы — сары чәчәк. Агач яфрагы — яшел төстә». Бераздан әнисе Фәриттән имтихан ала башлый.

— Бу нинди чәчәк, улым, әйт әле? — ди кызыл чәчәккә күрсәтеп.

— Яшел чәчәк! — ди малай. — Юк, юк, әни, мин юри генә әйттем, кызыл чәчәк! — Әнисе белән улы рәхәтләнеп көлешәләр.

Дөньяда иң-иң матур, шәфкатьле әнисе белән бу чәчәкле, җиләкле аланда йөрү Фәриткә күңелле, рәхәт. Менә ул күбәләкләр куып йөгерә, сөртенеп егыла, ләкин еламый, чыркылдап көлә генә... Менә алар качышып уйныйлар, әнисе күзен йомып, читкә карап торган арада, улы якындагы куак астына поса. Әнисе эзли-эзли бөтенләй икенче якка киткән булып кылана: «Кайларга гына качты минем улым, минем Фәритем?»

Йә бөтенләй тапмас дип куркып, Фәрит качкан җиреннән чыга, «Әни, әни, мин монда гына бит!» — дип кычкыра.

Җиләк-чәчәкләр җыйгач кайтырга әзерләнәләр. Әнисе, яланга чыккач, сүтеп ирекә җибәргән озын чәч толымнарын яңадан баш түбәсенә урап куя.

— Әни, әни! — ди зирәк бала, — урманда мин Фәрит исемле, син әни исемле, ә өйгә кайткач мин — Федя булам, син мама буласың, нигә алай?

— Шулай кирәк, улым — күз нурым, — ди әнисе, көрсенеп...

Үсеп, мәктәп яшенә җиткәч, урман-аланнарга Федя үзенең яшьтәшләре белән йөри башлаган иде. Дүртенче классны бетерәсе җәйдә әнисе аны үзе Түгәрәк аланга чакырды. Ул бу юлы күңелсез иде — элеккеге чаклардагы шикелле урманны яңгыратып көлмәде, утыргач, әнисе, беренче мәртәбә күргәндәй, Фәритенә бик озак карап торды, йомшак куллары белән аның чәчләрен, битләрен сыйпады. Аннан күкрәгенә кысып, озын, моңлы көйгә җырлады да, улының битен яшькә чылатып, үксеп елый башлады: «Улым, Фәрит, син минем бердәнберем, син мине оныттма, синең күңелеңдә никадәр яшәсәм дә, бу дөньяда мин шулкадәр яшәрмен. Аннан соң минем чын исемемне дә хәтерләп кал — минем татарча исемем Разыя. Мин синең атаңны яраттым, син дә аны ярат»...

— Син нәрсә, әни? — Фәрит, сәерсенеп, әнисенең яшь тулы күзләренә, йөзенә карады да куркып китте. Әле кайчан гына алсуланып торган битләре, кырау суккан чәчәк шикелле шинеп, саргаеп калганнар, наз, шәфкать сирпеп торган зур кара күзләре тоныкланган, эчкә кереп батканнар. Балалык гамьсезлеге белән генә күрмәгәндер Фәрит әнисендәге бу үзгәрешләрне.

— Син нәрсә? — дип кабатлады Фәрит әнисен кочаклап.

— Берни дә юк, улым, мин болай гына... — Әнисе елмайган булды. — Мин болай гына... Әйдә, улым, хәзер инде өйгә кайтыйк...

Разыя ятып ук авырый башлады. Уку елының соңгы көннәре иде. Күрше авыл мәктәбенә Федяны алырга килделәр: «Әниеңнең хәле авыр, аның сине күрәсе килә».

Фәрит, әнисе янына кереп, аның баш очына тезләнде. Авыру ана хәлсез куллары белән улының чәченнән, битләреннән сыйпады, нидер әйтергә теләп иреннәрен кыймылдатты, ләкин тавышы чыкмады. Ул үзенә мөлдерәтеп карап торган йөрәк пәрәсенә елмайгандай итте, аның кулын учына алып сизелер-сизелмәс кенә кысты да, күзләрен йомды...

Бер сәгать тә үтмәгәндер, утар кешеләре десятник Иван Купцовның хатыны «красавица Рая»ның үлүе турында ишетеп еладылар. Бу утыз яшьлек хатынны кабергә тамагыннан аш үтмәү зәхмәте алып китте...

Икенче көнне иртән Федор Иванович, кунакчыл хуҗалары белән саубуллашып, әнисенең туган авылы Чыршылыга юл тотты. Бу зур авылда татары, удмурты фани дөньяда тату гына яшәсәләр дә, теге дөньяда һәркайсысы үз өммәте белән бер аймакта булуын кулайрак күргән.

Татар зираты авылдан ярты чакрымлап бире, барган унайга сул якта булырга тиеш. Фәрит-Федя әнисенең кабере янында соңгы мәртәбә ул үлгән елның кара көзендә булган иде. Малай әнисенең баш очына аның яраткан чаукасы — балан куагы утыртып кайтты. Кабере зират киртәсе буенда гына иде.

Купцов җил капканы ачып зиратка керде. Әнисенең кабере эчтәрәк калган булырга тиеш. Урманда юл табу тәҗрибәсенә таянып, Федор Иванович кабер өстендә үсеп утырган балан куагын эзләп, зиратның эченә кереп китте. Һәм үзенең сабыйларча беркатлылыгын аңлагач, ирексездән елмаеп куйды: зиратның кояш төшкән һәр ачык җирендә күкрәп балан куаклары үсеп утыра иде!

«Авылда, бәлки, белгән кешеләр бардыр». Федор Иванович зираттан чыгып барганда, бер яңа кабер янында тезләнеп дога кылып утыручы картны күреп алды. Агай, догасын укый бетереп аягына баскач, таягына таянып инде китәргә җыенгач кына, Купцов аңа сүз кушты:

— Әссаламәгаләйкем, исәнмесез, абзый!

Кинәт кенә каршында пәйда булган, — киеме-кыяфәте белән урыска охшаган кешедән шүрләп, каушап калды карт. Шулай да:

— Вәгаләйкемәссәлам...— дип сәлам кайтарды.

— Абзый,— диде Федор Иванович,— син моннан кырык еллар элек үлгән Разыя исемле хатынның каберен белмисеңме, лесхоз десятнигына, урыска кияүгә чыккан хатынның.

— Кемнең, кемнең дисең? Урыска кияүгә чыккан Разыяның кабере дисеңме?— Карт, әсәрләнеп, Купцовка карап алды.— Нигә белмәскә, беләм. Әйе, бик яшьли гүр иясе булгание, мәрхүмә... Ә син аның кеме буласың соң?

— Мин аның улы...

— Син — Разыяның улы? — Гаҗәпләнүеннән карт телсез калды.

— Әйе, абзый, мин аның улы... Фәрит булам.

— Алай, алай икән... Алай булгач, син Иванның да улы булып чыгасың инде... Әйдә, күрсәтим, Разыя мәрхүмәнең кабере әнә теге төштәрәк...

Федор Иванович, таякка таянып, авыр аксап барган картка иярде.

— Менә, Разыя мәрхүмәнең кабере шушы инде,— диде абзый кеше, каенга, каеннан аз гына читтә учарланып җәелгән балан куагына ымлап күрсәтеп.— Каенын үзем утыртканыем. Икенче җәйдә килсәм, ходайның рәхмәте, анаңның кабере өстендә ике тармаклы балан үсеп утыра.

Фәрит-Федор әнисенең каберенә башын иеп озак сүзсез торды. Аннан соң, кесәсеннән пәке чыгарып, инде картаеп килгән балан куагының корыган ботакларын кисте, бөтенләй диярлек җир белән тигезләнгән кабер өстен, кабер тирәләрен чистартты.

— Разыя белән минем карчыгым Мәхмүзә ахириләр ие, без икебез дә аны догадан калдырганыбыз юк,— дип, абзый, кабер итәгенә утырып, дога укый башлады.

Федор Иванович бу мохиттә беренче мәртәбә иде. Чәчәккә күмелеп утырган, каберләре-чардуганнары тәрбия күреп торган татар зираты, анасының кабере өстендә көйләп дога укып утырган татар карты — боларның барысы аның күңелендә моңарчы кичерелмәгән каршылыклы хисләр уятты. Шулай да ул бу минутларда үзен дөнья мәшәкатьләреннән

бөтенләй арынган итеп тойды, янында, тәнендә ниндидер тынгылык, рәхәтлек сизде. «Улым Фәрит, син мине онытма!» Юк, онытмады аны Фәрите. Баласын үнике яшенә кадәр татар баласы итеп тәрбияләгән ана, улының күңел түрендә үз милләтенең серле тамгалы, тылсымлы бөтиен калдырып киткән иде. Дөрес, тормыш сикәлтәләрендә Федор ул бөтине югалткалады, ләкин бөтенләйгә түгел икән. Менә бүген, шушы мизгелләрдә, Федор Иванович үзенең янында әле дә татар рухы барлыгын хис итте. Ана сөте белән кергән бу рух табигый һәм ихлас иде.

Догасын укып бетергәч, Разыя улы бабайга мул итеп сәдака бирде, әнисенең каберенә чардуган корып китәргә теләге барын да әйтте.

— Корырбыз, Алла теләсә, корырбыз, бик матур итеп корырбыз! Минем карчыгым белән үземә багышлап ясап, буяп куйган чардуганнарым бар. Теләсәң бүген үк ат юнәтеп алып киләбез дә, корып та куябыз! — дип, Купцовка проблема булып күренгән мәсьәләне бик җиңел чишеп ташлады.— Ә хәзер, Фәрит, авылга, безгә кайтабыз. Мәхмүзә түти ахирәтенең улын күреп куансын, җыласын әле.

Федор Иванович белән Әхмәди абзый, акрын гына атлап, Чыршылыкка кайтып киттеләр. Әхмәди абзый юл буе кунак өчен «интирисны» булган хәлләр турында сөйләп кайтты. Ул күп еллар Фәритнең атасы Иван кулы астында эшләгән — урман кискән, Камага сал төшергән. Аягын да шунда бүрәнәгә кыстырып имгәткән икән.

Әхмәди карт: «Менә без кайтып та життек!» — дип, урам очындагы бер кечерәк кенә, әмма җыйнак-житеш йортның капкасын ачты: «Карчык, мин кунак алып кайттым, якты чырай белән каршы ал!» — диде Әхмәди, тавык-чебешләр арасында мәш килеп йөргән хатынына.

Федор Иванович үзенең кем икәнен әйткәч, Мәхмүзә карчык елап алды: «И-и-и, дөньялар диген, исән кеше бер әйләнеп кайта шул... Бәләкәй генә Фәрит менә нинди дәү кеше булган, сөбханалла!»

Чәй эчкәндә Мәхмүзә Фәрит-Федорга әнисе Разыя белән Чыршылыкка бик еш килеп йөргәннәрен сөйләп утырды. «Сиңа ике-өч яшьләр булгандыр ул чакларда,— Разыя туп-туры ахирәте Мәхмүзәгә килеп йөри. Ул чакта качып урыска кияүгә чыгу бик зур гөнаһ ие. Разыяның атасы бердәнбер баласына бәддога укыган. Мәрзия түтине — синең әбиең була инде ул,— эт итеп кыйнап ташлаган, син күз-колак булмагансың, диеп, ул хәзер миңа бала түгел, бусагамнан атлап керәсе булмасын, дигән. Менә шулай сез килериегез дә, килүегезгә мин ындыр артлатып Мәрзия түтиләргә чабарием. И-и-и! Ана күңеле ярлыкамыймы соң? Бичаракаем, бөтен эшләрен ташлап, мәтәлә-казала килеп житәрие. Ул Разыя белән кочаклашып елашулары, ул сине сөюләре! Атна-ун көн саен шундый хәл булырые. Әмма Мәрзия түти бер җәйне тиктомалга үлеп китте, син кечкенә идең әле. И елады, и елады инде Разыя, ятып каберләрен кочаклап елады анасының, гафу ит, әнием, мин генә гаепле синең вакытсыз салкын гүрләргә керүеңә, дип өзгәләнде, бичаракаем...

Безнең бөтен серләребез уртак ие. Иван белән вәгъдәләшкән көннең кичендә ахирәтем белән урман юлына чыгып, билгеле урында куак артында качып тордык. Атка атланган Иван сәгате-минуты белән безнең янга килеп тә житте, алдына Раечкасын утыртты да — әйдә! Ахирәтемнең үзе белән аласы төенчеген көчкә биреп өлгердем. Менә шулай өйләнештеләр анаң белән атаң, Фәрит. Гыйшыклары бик көчле булды. Разыяның да бик тиле чагы ие, уңжидене генә тотырганыек әле без аның белән...

— Ә Иванга, минем әтигә, ничә яшь булды икән ул чакта? — дип сорап куйды, үзенә моңарчы билгесез булган сәхифәләрне тетрәнеп тыңлап утырган Федор Иванович.

— Егерме биш, егерме алтылар булгандыр.— Моңарчы сүзгә кушылмаган Әхмәди карт карчыгы өчен җавап бирде.— Егетнең нәкъ азау теше ярган чагы инде. Разыя карчыга тырнагына эләккән чебеш кенә булган шул ул чакларда...

Кунак кеше хуҗа абзыйның соңгы сүзләрендә десятник Иванның ул чактагы гамәлләрен өнәмәгәнен абайлады. Хәзер Федорга үп нәрсәләр аңлашылды. Иң мөһиме — аның әнисе, унҗиде яшьлек гөнаһсыз авыл чибәре,— беренче мәхәббәт корбаны булган, төн күбәләге шикелле, канатларын гыйшык утында көйдергән икән...

Чәйдән соң хуҗа кеше ат эзләргә чыгып китте. Ул арада Федор Иванович йорт тирәсеннән саллы гына кыр ташы табып, аны чистартты һәм шома, ясмак кырына зәңгәр агач буявы белән язып куйды:

Әхмәди абзый юнәтеп китергән ат арбасына чардуган утыртып, ирләр тагын зиратка киттеләр. Язулы таш, зәңгәр рәшәткә чардуган куйгач, Разыяның кабере ямьләнеп китте.

Чардуган янында Фәрит-Федор тагын бер мәртәбә үзенең кыска, ләкин бәхетле бала чагын күңеленнән кичерде. Тамак төбендә каты төер укмашканын тойды. «Хуш, әни, прощай, мама»,— дип пышылдады ул. Һәм акрын гына зират капкасына таба юнәлде.

«Аллага шөкер, бик тә матур, бик тә күркәм булды!» — кылган изге эшләреннән Әхмәди карт та бик канәгать иде.

— Әйтсәм әйтеп бетерим инде, Фәрит,— диде Әхмәди абзый, зираттан чыгып атка утыргач.— Сине тагын кайчан күрәм инде мин. Синең атаң Иван шаяргалады шул. Аздырдылар аны. Аңа күз атучы хатын-кызлар бик күп булды — таза, чибәр, көчле ир. Иван да атказ бирә торганнардан түгел иде. Мәрхүмнең яманын сатуым түгел, син дөреслекне белеп китәргә тиеш, мин сөйләмәсәм кем сөйләр сиңа. Минем сал төшерүдә эшләгән чагым. Безнең янда Иван Купцов та көн саен диярлек буладырые. Менә шул чакларда пристанда буфетта сату итүче Кәтерина дигән марҗа үзенә иясләштерде атаңны. Разыя мәрхүмә бик тә горур хатыные шул. Авызындагы кара канны төкермиче, эченә җыеп баргандыр, бичара. Китәрие — барып сыеныр кешесе юк, әнисе Мәрзия җиңги исән булса бер хәл. Менә шул эчендәге кара каны, кара чиргә әйләнеп, вакытсыз гүр иясе итте инде анаңны. Синең миңа, Фәрит, хәтерең калмасын, мин сиңа сөйләргә тиеш булганын гына сөйлим, мин сөйләмәсәм тагын кем сөйләр...

Юк, Федор Ивановичның Әхмәдигә хәтере калмады, киресенчә, монарчы үзенә билгеле булмаган күп нәрсәләрне белде ул бүген, күп нәрсәләрне аңлады.

...Федяга дүрт-биш яшьләр булгандыр. Җәй көне иде. Малай тышка чыгарга кысталып уянды да, әниләренең йокы бүлмәсенә керде. Ни күрсен! Әнисе озын эчке күлмәктән, чәчләре таралып иңнәренә төшкән, кулында зур чыра пычагы. Әтисенең каршына баскан да, ана каз шикелле зәһәрләнеп ысылый: «Иван, якыныма килеп, мине пычратасы булма, шушы вакытка кадәр кайда йөрсәң — шунда олак!» Әтисе тәки өйдән чыгып киткән иде шул вакытта, ә әнисе Федяны үз янына яткырып, аны кочаклап бик озак елап яткан иде.

Өйдә зиратчыларны Мәхмүзә әби куанып каршы алды. «Рәхмәтләр яусын сиңа Фәрит, картым, сиңа да рәхмәт, бик тә игелекле эш эшләдегез, каберен улы зыярәт калганга ахирәтем Разыяның да рухы шатлангандыр инде. Алланың рәхмәте киң савaплы гамәлеңнең әҗерен күрми калмассың, Фәрит, күрерсең, күрми калмассың боерган булса. Атаң урыс булса да, татар җанлы икәнсең, рәхмәт инде».

Июнь көне сүнде, кич булды. Федор Иванович кунарга калды. Хуҗалар аңа урынны чоланга җәйделәр. Көнозын аяк өстендә булу арыткан булса да, кунак йокыга китә алмады. Башта ул урам авазларына колак салып ятты: күрше йортның капкасын шыгырдатып ачып яптылар, өй турыннан көлешә-көлешә сөйләшеп яшьләр үтеп китте, кайдандыр ерактан зәгыйфь кенә гармун тавышы ишетелде, кемнеңдер сабые үрсәләнеп елап алды, аннары авыл акрынлап тынып калды.

Федор Иванович әле бик озак уяу ятты. Бүгенге көннең тәэсирияты зур иде: яңадан татар мохитенә кайту, татар зираты, ничә еллардан соң тагын әнисенең каберенә килү, ярдәмчел, рыясыз Әхмәди карт, ниһаять,

әнисенең иң яшерен йөрәк серләрен белгән яшьлек дусты Мәхмүзә карчык...

...Федяның әтисе Иван диннәргә битараф, эшкуар кеше иде. Бала тугач, авылдан килгән Степан бабасы малайны чукындыру турында теш агартып караган иде, кая ул! — килене Разыя карчыкка булып ташланды кайнатасына. Сабыен күкрәгенә кысып өйдән үк чыгып йөгерде.

...Әнисе үлгән көзне Федяны әтисе укырга Сарапул гимназиясенә урнаштырды. «Ну, Федор, әйбәт йөр, тырышып укы! — диде өлкән Купцов, улының җилкәсенә кулын салып,— мин синең янына килгәләп йөрермен, так что не скучай, сынок!»

...Әнисенең татар хатыны булганын Федор Ивановичның бу дөньяда иң якын кешесе Ирина да белми бит әле. Кайтуга Иринага барсын да сөйләп бирергә кирәк. Шурага да...

* * *

Тәүфыйк, каяндыр тапкан иске арканның ике очын ботакларына бәйләп, таган асып куйды. Ярты метрлы тактаның баш-башларын нәкъ урта бер җиреннән уймырлап, таганга утыргыч та ясады. Хәзер Шура белән Муйнак көнозын таганда атыналар. Муйнак кыз артыннан әле бер якка, әле икенче якка чаба-чаба тәмам арый, әлсери, миңгерәүләнә, аннан соң Шура аны алдына утыртып атына башлый. Ничек элегрәк килмәгән бу хәйлә Тәүфыйкның башына — хәзер аңа чабата ясарга мишәйт итүче юк.

Кайбер кичләрдә монда килеп Галимә белән Габделхәй дә таган атынып китәләр. Ничек кадерләп, сөеп таганда атындыра Галимәсен Габделхәй! Бу аның дөньяда иң бәхетле минутларыдыр...

Менә бүген дә алар, атынып туйгач, аланны бер әйләнеп чыктылар да, шалаш янына килеп, төп башына утырдылар. Габделхәй кыймыйча гына, оялып кына кызның иңнәренә кулын салды, акрын гына, ләкин бик дәртләнеп нәрсәдер сөйли башлады. Тыз-быз килеп үз эше белән йөргән Тәүфыйк Габделхәйнең кайбер сүз өзекләрен генә ишеткәләп калды.

— ...Шәрдәнгә барып урнашырыек... сугыш беткәч...

— Һай, Габделхәй абый, мин бик яшь бит әле, сугыш булмаса, мин быел көз унынчы класска гына йөргән булыр идем...

Шул вакытта әллә кайдан — җир астыннанмы Мәче борын килеп чыкты, чыкты да, оча-куна Габделхәйгә бәйләнә башлады.

— Нигә карасын ул сиңа, сәп-сәламәт унҗиде яшьлек кыз! Бар, бар, әнә үз тиңнәрең тирәсендә титакла!

Габделхәй колакларына кадәр кызарды, урыныннан сикереп торды. «Менә хәзер сугып егып таптый инде шул җирәнгеч Мәче борынны»,— дип уйлады Тәүфыйк. Юк, Габделхәй сукмады: «И-их, энем, энем! Ник син шушы кадәр юньсез! Каян килә сиңа бу кадәр әшәкелек, миһербансызлык?!» — диде.

Галимә сүзгә катнашмыйча гына, горур кыяфәт белән басып торды да:

— Әйдә, Габделхәй, кайтыйк, безнең кайтыр вакытыбыз житте,— дип, егетне җәһәт кенә култыклап алды да баракларга таба китеп бардылар.

Мескен Галихужа, баганадай, баскан урынында катып калды.

«Һай, нинди акыллы да, хәйләкәр дә кыз Галимә апа,— дип уйлады каравылчы малай.— Әнә ничек Галихужаның мәче борынына чиертте!»

* * *

Узган төндә Тәүфыйк начар йоклады. Шунарданмы, иртән аның кәефе булмады. Нәрсәгәдер эче пошты, җанына урын таба алмады малай. Чабата ясарга тотынып караган иде — ташлады, эшкә кулы бармады.

Эленке-салынкы йөри торгач, ничек кирәк алай төш вакыты житте. Тәүфыйк шалашына кереп барганда гына җан-фәрман йөгереп килүче Шураны күреп алды.
«Тофик, Тофик! Стой! Тукта!...»
— Тофик!.. там в лесу... Галиму задавило... Галиманы агач баскан!..
— Син нәрсә сөйлисең, кызый!?
— Правда, правда... бар кеше делянкага йөгерә, папа тоже ускакал на лошади...
Тәүфыйк йөгереп килеп җиткәндә поселок халкының яртысы шунда иде инде. Кисеп егылган юан, кәкре каенны кешеләр әйләндереп алган. Хатын-кыз, бала-чагалар елаша. Уртада, җирдә яткан Галимәнең башын алдына салып Хәбирә утыра: «Син басылганчы үзем басылган булсамчы, и сеңелем җаным, балам җаным! — дип өзгәләнеп елый Хәбирә.— Никләр дип бирдем пычкымны, никләр дип кенә бирдем икән!?»
Леспромхоз директоры Купцовның чырае качкан, аның күз кабагы берөзлексез тартыша. Федор Иванович әле киселгән каен төбенә бара, әле Галимә мәете өстенә килеп иелә. Галимәнең чигәсендә кечкенә генә яра, аннан әле дә кан саркып тора. Кызның йөзендә каушау-курку әсәре язылып калган.
— Бу хәл ничек булды, вакыйганы үз күзе белән күргән кешеләр бармы? — дип сорый, ниһаять, Купцов, җыелган кешеләргә карап.
— Купцов абый җаным,— ди Нәфисә елый-елый.— Галимә безнең янга су эчәргә дип килгәние. Хәбирә белән мин шушы каенны кисеп ятадырыек. Кая кайсыгызны алыштырыйм, диде Галимә. Хәбирә апай бераз хәл ал, бик арган төсле күренәсең, диде. Без Галимә белән кисә башладык. Кисеп чыгар-чыкмас агач шатор-шотыр ава башлагачтын, коты алынган Галимә, мескенкәем, пычкысын-ниен ташлап кычкырып күзе күргән якка йөгерде. Купцов абый җаным, каен аварга тиешле булган ягына аумыйча, тере нәстә шикелле төбендә бөтерелде дә, Галимә йөгергән якка ауды шул. Иң кырый ботагы белән генә чигәсенә суккан шул. Аварга тиеш ягына гына ауса иде, Купцов абый җаным! Нишләпләр алай булды икән, Купцов абый җаным?..
Каенның нигә «бөтерелгәнен», авасы якка аумаганын Купцов аңлады, әлбәттә: кәкре агачның авырлык үзәге кәүсәсеннән читтә булырга мөмкин, андый агачның ауган чакта кисүчеләр исәпләгән юнәлештән тайпылу ихтималы зур. Бу хакта урман мастерлары кисүчеләргә алар әле урманга аяк басмас борын аңлатырга тиешләр иде, бигрәк тә хатын-кызларга...
— Кем участогы бу? — Купцов, күзе белән кешеләр арасыннан мастерларын эзләде.
— М..минем участок, Федор Иванович.— Мастер Иванов, шүрләп кенә, леспромхоз директоры янына килде.
— Йә, ничек аңлатасың, мастер Иванов, ботак яндырырга гына рөхсәт ителгән, яше җитмәгән кызның урман кисәргә алынуын, аның агачка басылып һәлак булуын? Бу трагедиядә үзеңнең дә гаебең барын сизәсеңме?
— Случайность, Федор Иванович, аннан соң... кәкре агач, центр тяжести...
Ивановтан бүген дә аракы исе аңкый иде. Купцов аңа әйтеп бетерергә бирмәде:
— Случайность!.. Центр тяжести!..
Теш арасыннан чыккан шушы өч сүзгә леспромхоз директоры мастерга булган бөтен нәфрәтен сыйдырган иде.
Купцов сулыгып елап утырган Хәбирә янына килде.
Бәхетсез хатынның альяпкычы, куллары Галимәнең ал канына буялган. Каен яфракларына, үләннәргә, чәчәкләргә Галимәнең ал каны чәчрәгән...
«Купсуф абый җаным, мин генә гаепле аның үлеменә, мин генә гаепле! — дип елый Хәбирә.— Оят булса да әйтим — вакытсыз чагым ие,

Купцов абый җаным, бик хәлем беткәние шул, кая, Хәбирә апа, син әзрәк хәл алып тор, дигәч, пычкымны биргәнием шул, Купсуф абый җаным!..

Галимәне үз куллары белән арбага салып, поселокка озаткач, Федор Иванович, ялгызы гына каласы килеп, әйләнгечтән, икенче юлдан кайтырга булды. Кызның мәгънәсез, фаҗигале үлеме аның җанын тетрәндергән иде. Ялгызы гына калгач, ул хисләренә ирек бирде: «Ләгънәт төшкән сугыш! Парта артында утырасы балалар урман эшендә җәфа чигә. Ләгънәт сиңа, рәхимсез дөнья! Ләгънәт сезгә, дөньяны болгатучы фюрерлар! Ләгънәт! Ләгънәт!! Ләгънәт!!»

Купцов кинәт үзен начар хис итте. Үз ирегенә куелган хуҗасын ат инде Озын аланга алып чыккан икән. Федор Иванович атын юлдан читкә борып, ялгыз каен янына китерде, ияреннән төште, каен кәүсәсенә сөялеп укшый, буыла-буыла йөткерә, кан төкерә башлады...

Икенче көнне «Кырык алты» кешеләре урман авылы тарихында беренче мәетне озатырга килделәр. Ир-ат, хатын-кыз, бала-чага Хәбирәләр барагы алдына җыелды. Яшел үлән түшәлгән арбада чәчәккә күмелеп Галимә ята. Хәзер аның агарып калган йөзендә тәкъдиргә буйсыну, күндәмлек төсмерләре чалымлана иде.

Поселок кешеләре Галимә белән хушлаша башладылар. Галимәне туган авылына алып кайтып җирләргә булдылар. Хәбирә белән Нәфисә Габделхәй арбасына утырдылар. Җеназа, мәет күмүнең рәтен белгән Гафур картны Шәмәк үз арбасына алды. Бүтән атларга Галимәнең дус кызлары утырышкач, хәсрәт олавы Күкчә авылына юл тотты.

Юл буе Хәбирә белән Нәфисә телләреннән Галимәне төшермичә Габделхәйнең бәгырен телгәләп бардылар. Каен янында яткан Галимәнең баштарак аңы булган икән әле. Йөгереп килеп кочагына алган Хәбирәгә ул: «Әби ничек яшәр инде, мескенкәем»,— дип соңгы сүзләрен пышылдаган, бичаракай. Тәүфыйк күмәргә китүчеләрнең кайтканын түземсезләнеп көтеп торды. Малайның исәбе буенча, алар әле көн яктысында ук кайтып җитәргә тиешләр иде. Күкчәгә ике-өч сәгать алданрак кабер казырга киткән Галихуҗа, Миша, Петя, Хәйләрнең дә кайтканы күренмәде.

Шалашына кереп йоклаган малай, Муйнакның чәң-чәң өргән тавышына уянып, тышка чыкты. Ул җәйге төн энгерендә юртып кына килүче атларны шәйләде һәм алар каршына йөгерде.

Тәүфыйк иң ахыргы атта ялгызы гына кайтучы Габделхәй арбасына сикереп менеп утырды. Габделхәй:

— Ә, синмени әле бу?..— диде дә, күңелсез генә кайта бирде.

— Галимә апайның әбисе бик елагандыр инде, Габделхәй абый?

Габделхәй байтак вакыт җавап бирми торды, авыр сулап алды, аннан соң сөйләп китте: әбисе, Галимәнең мәетен күргәч, акылга җиңеләеп киткән, бер елаган, бер көлгән. Галимәне юып, кәфенләп, җеназа кабыгына чыгарып салгач, бичара карчык «Әһ!» дигән аваз чыгарган да җан тәслим кылган. Икенче ягына да ләхет уеп, әбине Галимә белән бер кабергә күмгәннәр. Мулла абзый да, авыл халкы да бу гамәлне мәгъкуль күргәннәр.

Фаҗигадән соң өч-дүрт көн узгач кына, леспромхозга тикшерүче килеп төште. Делянкага барып, егылып яткан кәкре каенның инен, буен, юанлыгын, Галимә егылып яткан төптән агач кәүсәсенә, агач төбенә кадәр араны эшлекле кыяфәт белән үлчәгәннән соң, «Так, так, значит»,— дия-дия, төпкә утырып беркетмә язды, конторга чакырып Нәфисәне, Хәбирәне дупрысладе, леспромхоз директорына да сораулары күп булды тикшерүченең.

Район үзәгендә мастер Ивановка суд булды. Шаһит булып барган Хәбирә белән Нәфисә: «Без гаепле»,— дип торсалар да, прокурор Ивановны 5 елга ирегеннән мәхрүм итүне таләп итте. Шулчакта судка леспромхоз директоры Купцов килеп керде дә, Ивановның эше буенча сүз бирүләрен үтенде. Судтагыларны авызына каратып торып, ярты

сәгать сөйләде Ивановның начальнигы. Бик күп дәлилләр китереп, фаҗигагә урман мастеры гына гаепле булмаганын исбатларга тырыштым. Нәтиҗәдә, Ивановны ике елга гына утырттылар.

Галимә үлгәннән соң урман поселогы сүнеп калды. Кичләрен яшьләр мастерскойлар артындагы такырга чыкмый башладылар. Моңа гармунчы Галихуҗаның да юкка чыгуы сәбәп булгандыр. Беркөнне Шәрдән станцасыннан Чукрак Фазыл арбасы артына Мәче Борынның атын тагып кайтты. Фазыл абзый сөйләвенчә, станцада Галихуҗа йөген бушата, аннан ары култык астына үзе белән алып килгән гармунын кыстырып, хәрби эшелоннар янына китеп бара. Ярты юлда туктап, ул Фазылга нәрсәдер кычкыра, кулын болгый. Сәерсенгән Фазыл поезд юлына чыгып караса, күрә — Галихуҗа ышалун янында гармун уйный, солдатлар җырлыйлар, бииләр, гармунчының аркасыннан сөяләр. Ышалун кузгала башлагач, Мәче борын шау-гөр килгән солдатлар белән поезд янына китә. Әрҗә вагондагы солдатлар ике кулыннан тартып, җирдәгеләре артыннан этеп, гармунчы малайны очыртып кына поездга мендереп утырталар. Вагон аның турысыннан узып барганда Фазыл күреп кала: Галихуҗаның авызында пипируз, үзе иелә-бөгелә гармун уйный, сугышка китеп баручы солдатлар исә җырлыйлар.

Галимәне җирләгәннән соң атна-ун көн үткәч, леспромхоздан Габделхәй дә китеп барды. Юл уңаеннан ул, саубуллашырга дип, Тәүфыйк янында озак кына боегып басып торды.

— Ярар, Тәүфыйк энем, сау булып тор! — Габделхәй малайга кулын бирде.

— Габделхәй абый, инде кая китеп баруың?

— Туган авылыма, үзебезнең авылга кайтырга исәп, энекәш. Дус егетемнән хат алдым, көздән ымтыеста тракторчылар курсы ачыла, дип язган. Кайтып карыйм әле...

Каравылчы малай, аркасына кечкенә генә солдат кәтүмкәсе аскан, авыр аксап барган Габделхәйне урманга кереп югалганчы карап калды. Элек аның аксаганы бөтенләй диярлек сизелми иде...

Хәбирә белән Нәфисә дә авылларына кайтып киттеләр. Ике елдан артык кара-каршы пычкы тарткан, бер баракта яшәгән ике тол хатын юл чатында елашып аерылыштылар. Аркаларына биштәр аскан, кулларына берсе самавыр, икенчесе мәче тоткан ахириләр берсен-берсе күздән югалтканчы бер-беренә кул изәшеп бардылар.

Галимә үлгән көннән запой белән эчә башлаган Гөргөри ике атна буена «кибә» алмый газапланды. Тимер алачыгында Петя һәм аңа ярдәм итүче малайлар чүкеч җырын дәвам иттеләр.

* * *

Август башларында Купцов Мәскәүдән хат алды. Гусевтан. Борис Михайлович институт Советында Федор Иванович Купцовны, заочно, кафедра мөдирлегенә тәкъдим иткәнен язган. Штат расписаниесе расланган вакытта, ягъни 20 августтан да соңга калмыйча, Купцовның Мәскәүгә кайтып җитүе хәерле булачагын искәрткән.

Купцовлар якшәмбе көнне киттеләр. Көченә күрә эш биреп, семьяларын ачлык газабыннан йолып калган мәрхәмәтле начальникларын озатырга дип аның өе янына рәхмәтле поселок кешеләре җыелды. Дулкынланган Федор Иванович леспромхоз ветераннары белән кул биреп хушлашты. Балавыз сыгып торган Әнисә белән Әлфиягә җылы сүзләр әйтте, борыны йомшарып киткән Спиридонычка төгәл службасы өчен рәхмәт белдерде. Читтәрәк басып торган дәдә Вася янына килеп, озак кына картның кулын кысып торды.

Чират тимерче Григорийга җитте. «Я сопьюсь, Федор, без тебя, мин син киткәч эчеп үләрмен инде», — дип, еламсырап пышылдады яшьлек дустына тимерче. Федор Иванович Григорийны, малае Петя белән бераз

читкәрәк алып китеп, бик житди, кырыс тон белән, бер атасына, бер улына карап ниләрдер әйтте. «Син, Гриша, эчүеннән тыел, наконец, ә син, Петя, инде егет булып киләсең, атаңны ныграк тот!» — дигән булса кирәк.

Тәуфыйк күчеп китү мәшәкате белән мәш килгән Ирина Васильевна, Шура тирәсендә кайнашты, барлы-юклы өй әйберләре салынган әржәләрне арбалар янына чыгарып торды.

Леспромхоз директоры урынына калган прораб Дәминов, завхоз Шәмәк Купцовларны станцага кадәр озата барачаклар икән. Ирина Васильевна белән Шура тәмам эшләрен бетергәч, Акбәкәл жигелгән арбага менеп утырып, хужаларны көтә башладылар. Бер читтәрәк Муйнагын житәкләп торган Тәуфыйкны Ирина Васильевна үзләре янына чакырып китерде: «Әйбәт егет булып үс, Тәуфыйк, ярыймы,» — дип, матур апа малайның битеннән үпте. Еларга житешкән Шура исә Муйнакны иркәләгән булып кыланды: «Сау бул инде, акыллы көчегем-Муйнагым, мин сине беркайчан да онытмам!..»

Ниһаять, атлар янына «Кырык алты»да бөтен эшләрен бетергән Купцов, аның белән Шәмәк килде. Әдәпле Шәмәк Дәминов атына утырды.

— Ә сиңа, егетем, авылыгызга кайтырга, укуыңны дәвам итәргә кирәк,— диде Федор Иванович, Тәуфыйкның иңенә кулын салып.— Укырга, укырга кирәк, энекәш!

Атлар кузгалып киткәч, алар артыннан Муйнак та тартылды, борылып Тәуфыйкка карады: «Шура апа китә бит!» янәсе.

Шәрдән станцасына китүчеләрне Тәуфыйк белән Муйнак урман авылына кадәр озата бардылар. Тар урман юлыннан барган атлар киң юлга чыгып, борылышта күздән югала башлады. Менә иң артта барган Купцовлар аты да юк булды. Каравылчы малай, нәүмизләнеп, бер урында байтак басып торды. Шул чакта юл борылышына Шура йөгереп килеп чыкты: «Эй син, Сунгатның малаеның малае!» — дип, ачыргаланып кычкырды да елый-елый кире йөгерде...

Август ахырларында Тәуфыйк та авылларына кайтып китәргә жыенды. Әле һаман делянкада яшәп яткан бабасы янына барып кайтты, үз урынына Шәмәккә ышанычлы малай табып бирде.

Дуслары Петя, Санька-Немой белән хушлашты, динннеккә дәдә Вася янына кереп чыкты, мастерскойларга барып, Гафур абзый белән күрешеп китте.

Кайтуын-кайту, ә менә Муйнак белән нишләргә? Тегe кайтканда Тәуфыйк әнисенең кылын тартып караган иде дә: «Сез, улым, миңа болай да дүрт көчек» — диде түгелме? Ә бит Муйнак шундый акыллы эт, барсын да аңлый, әйтергә теле генә юк. Менә хәзер дә Тәуфыйк абыйсы аның турында ни уйлаганын аңлап тора ул, шулкадәр ялварып күзгә карый: «Абый, жаным, Шура апай да китеп барды, инде син дә ташлама мине, зинһар!» «Юк, Муйнак, монда сиңа яхшырак булыр, акмаса да тама, дигәндәй, ашханә тирәсендә дә сөяк-мазарлар эләккәли...»

Тәуфыйк, Петя белән сөйләшеп, Муйнагын аңа биреп калдырырга булды. Муенсасын алачык янындагы казыкка бәйләп куйгач: «Муйнак, мин авылга гына кайтып киләм, шуңарчы син Петя абыең белән яшәп тор!» — дип алдашты аңа дөньядагы иң яраткан кешесе...

Тәуфыйк Галимә судан чыгып, кояшта кибеп-кызынып торган төшкә барып килде: «Хуш инде, Галимә апа!» Соңгы мәртәбә шалашына кереп чыкты: «Сау бул, шалаш!»

Малай тамагында каты төер тойды, елый-елый биштәрен киде.

Аркасындагы йөге авыр иде бу юлы Тәуфыйкның — аның бөтенләйгә бөтен житиясен күтәреп кайтып китүе бит бу. Ул юл буе урман поселогында бер ел буе бергә яшәгән, үзенә якын кешеләр турында уйлап кайтты: Галимә, Хәбирә, Нәфисә апалары, Гафур абзый, дәдә Вася, Габделхәй, Санька-Немой, мактанчык булса да Газиз абзый, беркатлы,

яхшы күңелле чуаш карты Михай... Нинди яхшы кешеләр! Мәче борын Галихуҗаның да кешегә бөртек зыяны тигәне юк, сүгенүе бар-барын, ага-җиңгә кулында үскән бала, диләр ич, үскәндә йомшак кулы белән башыннан сыйпаучы әнисе булмагач, күңеле чиләнгәндер шул...

Ә директор Купцов абый, аның хатыны Ирина Васильевна! Нинди ягымлы, игелекле кешеләр иде! Ә аларның кызлары Шура... Шурадан да якын кешесе булмагандыр аның леспромхозда...

Әле быел гына, май урталарында бугай, Шура иртә белән Тәүфыйк янына килде дә: «Тофик, давай мине урман чыкканчы озатып куй, мин мәктәпкә барам»,— диде. Озата китте Тәүфыйк теге май иртәсендә Шураны. Урман юлында бер сазлык урын бар. Менә шул сазлыктан Тәүфыйк кызыйны арка кочтырып алып чыккан иде, чөнки Шураның аякларында чүәкләр, ә ул — яланаяк.

Сазлыкны үткәч тә Шура, төшим инде, димәде, Тәүфыйк та төш димәде, шулай бардылар да бардылар. Шура бер кулына портфелен тотып, бер кулы белән Тәүфыйкның муеныннан кочаклап барды, ә Тәүфыйк — аның тез асларыннан...

Урманны чыккач кына Шура Тәүфыйкның аркасыннан төште, чәчләрен, кофтасын рәтләде. Шушында гына, беренче мәртәбә, Тәүфыйкның күзе төште — кызыйның ак батист кофтасы астында пионер галстугының ике ягында, кетеки генә ике шалкан калкып тора икән. Аларның күзләре очрашты, нишләптер икесе дә берьюлы кызарындылар... Шулай беравык сүзсез басып торгач, Шура: «Спасибо, Тофик!» — диде дә йөгереп китеп барды...

...Галимә белән Шура — Тәүфыйкның иң кадерле кешеләре булганнар икән. Ул моны хәзер генә аңлады. Малайның күңеле тулды. Ул биштәрен салып куеп, җиргә утырды. Туган авылына, әнисе туганнары янына кайтып килүе дә куандырмады аны, ул үзен ялгыз, ятим итеп сизде бу минутларда. Ичмасам Муйнагы да юк янында, юкка гына ул аны Петяга биреп калдыргандыр...

Шулай байтак утыргач, Тәүфыйк торды, көрсенеп, биштәрен кия башлады. Шул чакта аның күзенә томырылып-тәгәрәп килгән бер нәрсә чалынды. Йомгак якынайганнан-якыная барды, инде, ниһаять, танырлык булды: нindидер көчек чаба икән. Муйнак? Муйнак! Муйнак!!

Куанычыннан исәрләнгән көчек дустына ташланды. Ул шыңшыйчиный, күз яшьләре белән елый, дустының өстенә сикерә-сикерә битен, борынын ялый: «Ташлап китсәң дә мин сине таптым бит, абый, артыннан куып җиттем бит!» — дия төсле.

Бәхетле көчек алдан чабып әллә никадәр җир китә дә яңадан кире әйләнеп килә, юл чатларында туктап көтеп тора: «Кайсы якка китәргә инде безнең авылга, абый?»

Муйнак Тәүфыйк белән янәшә йөгерә башлады. «Кайтуын кайтабыз да, абый, Шәмсениса апай ничек каршы алыр икән мине?» «Кайгырма, Муйнак, безнең әни әйбәт хатын ул, куып чыгармас, ничек тә яшәрбез әле...»

Юлчылар Солы үренә җиттеләр, үр төшә башладылар. Алда, иңкүлектә утырган Мирасның тирәк очлары күренде.

— Алга, Муйнак! — дип фәрман бирде Тәүфыйк.— Әнә алдагы тирәкләр — безнең авыл тирәкләре инде!

*1991—93 еллар.*



## РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВКА
### 60 яшь

# ҖӘЯҮЛЕ КҮБӘЛӘК

Шигырь ялкыны кайчак очраклы бер очкыннан кабынып киткән кебек, шагыйрь җанын аңлау өчен дә ул тудырган берәр образның мәгънәсенә төшенү җитә икән. Роберт Әхмәтҗанов турында бер-ике кәлимә сүз әйтим дип кулыма каләм алгач та, дөресрәге сүземне нидән башлыйм дип аптырап утырганда, кылт итеп исемә килеп төште: «Җәяүле күбәләк» — «Шигырь китапханәсе» сериясендә басылып чыккан китабына шулай дип исем кушкан иде бит ул!

Җәяүле күбәләк!..

Роберт Әхмәтҗановның күңел дөньясын, аның иҗади принципларын, рухи эзләнүләрен, эстетик карашларын, ахыр чиктә, поэтик идеалларын шушы метафорик образдан да төгәлрәк әйтеп бирергә мөмкинме соң? Дөрес, аны күпләр җилбәзәклектә гаепләргә ашыктылар, әмма бу тыштан караганда гына «дөрес» бәяләмә. Асылда исә ул бөтен җаны, омтылыш-ышанычлары, бөтен вөҗүде белән шагыйрь; әрфия күбәләктәй самими, сабый җанны нишләтәсең инде аны... Ләкин онытмыйк: көндәлек ваклык-интригалар бәрелешендә баштан ук җиңелергә дучар ителгән шушы күбәләк җанга — Җәяүле күбәләккә — Табигать үзе үк туләем сыя ала, чөнки аның җаны шигырьдән тора. Ул — үзе бер шигъри дәүләт!

Ятам ярда. Тыныч дәүләт сыман.
Баш очымда шаулый тупыллар.
Баш очымда Идел әкият сөйли.
Йөрәгемне юа дулкыннар.

Якты. Тыныч. Иркен. Әйтерсең лә
Дөньяның бу кыл бер уртасы.
Кочагыңа ал да эрет мине,
Җил һәм Кояш Республикасы.

Кеше — Җәяүле Күбәләк!..

Бу хакта ул үзе болай ди:

**— Эзләнүләр — Иҗатның гомерлек юлдашы. Мин әлеге шигырьләр китабын «Җәяүле күбәләк» дип исемләдем. Ни эзли соң ул җәяүле күбәләк? Нәрсә хакында сөйли ул безгә?**

**Туган җирне, газиз табигатьне кошлар юлыннан карасаң, тагын да якынрак, сагынулар яңа мәгънә ала: туган җирнең гади күбәләге дә бөек киңлекләр аша, җил-давылларны җиңеп, туган төбәкләргә ашкынып, җилфердәп кайта икән.**

**Бервакытны миңа яшел киңлекләр, Идел өстеннән җилфер-җилфер очкан күбәләкләрне иллюминатор аша күрергә туры килде. Кайларга оча, кайларга кайта ул шулай? Беркадәр мистик Җәяүле Күбәләк образы Мәхәббәт, Табигатькә һәм кешеләр язмышына багышланган шигырьләрдә безнең уртак юлдашыбыз булса икән!**

Шикләнмичә әйтергә мөмкин: Роберт Әхмәтҗановның шигырьләре күпләр өчен юлдаш булды. Чөнки ул гомере буе Матурлык турында җырлап килде. Ә Матурлык кешелекнең аерылмас юлдашы инде ул. Йә, уйлап карасаң, исәннәрдән күпме татар шагыйре үзенең иҗатында, Туган як турында («Каенстан! Урман башыннан ук күренәсең — йөрәгемә матур утырган! Әнә синең яңгыр басмаларың, урамнарың — минем Нотр-Дам»), «дөрләп янган усаклар» «күгәрчен очып туймас көн», «орчык җыры», киңлек буйлап очучы пәрәвезләр («шундый көз бу, шундый киңлек бүген, — пәрәвезләр оча Әдрәнгә») хакында, гомумән безне чолгап алган тирәлек, Туган җир, Табигать хакында Роберт Әхмәтҗанов кебек үзенчәлекле итеп, дәртләнеп, очынып, талпынып, ихлас күңелдән, күтәренке рух белән җырлый алды икән?

Андыйлар бармак белән генә санарлык.

Ул — күбәләк, ә без җир кешеләре. Биектәнрәк оча шул ул. Бәлки шуңа да аны «күреп», зурлыгын бәһаләп житкерә алмыйбыздыр? Шагыйрьгә бүген 60 түгел, 6 гына яшь тулгандыр кебек. Мөгаен, нәкъ менә шушы холык-фигыле, сабыйлыгы өчен дә санлап бетермибездер. Шигырьдә шоңкар булып та, тормышта Җәяүле күбәләк булганы өчен...

Шулай дидем дә, «Вокруг света» журналында бер натуралистның (фәнни телдә күбәләкләрне өйрәнүче белгеч башкача аталадыр, бу очракта анысы әһәмиятле түгел) язмасын искә төшердем. «Моннан күп еллар элек Амазонка бассейнына сирәк очрый торган экзотик күбәләк эзләп (ә ул фәндә бик кыйммәт бәяләнә икән) сәяхәткә чыккан идем, дип яза ул. Баксаң, ул безнең урта полосаларда да очрый икән. Берничә ел элек мин шуңа тап булдым».

Әдәбиятта да шушыңа охшашрак вакыйга-хәлләр була. Еш кына «экзотик күбәләкләр» эзләп ерак-чит киң киңлекләргә күз атабыз түгелме без? Бәлкем бу бер яктан дөрестер дә, офыкларны киңәйтү ягыннан. Ләкин икенче яктан, шундый сорау туа: үзебезнең җирлектәге сирәк очрый торган «күбәләкләрне» вакытында танып алып, «исемле гербарийларга» теркәп куя беләбезме? Яки фән өчен кыйммәте шәкли булган бер көнлек күбәләкләрне, яза белгәннәре өчен түгел, яши белгәннәре өчен, алтын тартмаларда сакламыйбызмы? Сораулар күп, әлбәттә.

Ә шагыйрь Роберт Әхмәтҗанов — татар шигъриятенең сәер холыклы Җәяүле Күбәләге — әдәбият киңлекләренә дә бернигә дә карамыйча җилфер-җилфер оча да оча бирә. Очсын гына. Бәлкем дөнья агышын «иллюминатордан» күзәтеп торучы «натуралистларның» берәрсе аның да барлыгын күреп алыр әле. Татар акылы төштән соң дигәндәй, тик соңга калмаска иде.

**Наис ГАМБӘР.**

---

# Роберт Әхмәтҗан

## ТӨРЛЕ ЕЛЛАР ДӘФТӘРЕННӘН

### Җәяүле күбәләк

Безнең сагыну шундый —
ашкынабыз җир үзәге булган төбәккә,
йөрәгебез
болытларга тигәләп!
Ә түбәндә
таулар, урманнар артына
чакрымнар аша
җилне җиңеп, җилфер-җилфер килеп,
кайта
бер күбәләк!
Кайта! Болытлар арасыннан,
давыл сукмагыннан,
каршысына урманнардан
сибелә сары яфрак,—
сары күбәләкләр күч-күч
ятып кала кырда.
Ә бу — кайта! —
җанлы сары яфрак төсле

жил-жил килеп,
калтырап!
Колакларда саубуллашу жыры.
Әллә инде кыска җәен эзләп,
ашыккан кешедәй, очына-талпына
кайта!

Җәйге болыннарның җаны —
Җәяүле Күбәләк.

## Саумы, Кояш!

Таралды инде болытлар,
аязды һавалар.
Иделдә зәңгәр дулкыннар
ярларга кагалар:
«Саумы, кояш,
саумы, иртә,
исәнме!» — диләр.
Иркәли, иркәли җанны
ягымлы көйләр.
Күтәрдем ак пәрдәләрне,
карыйм ерак, ерак...
Яшь көннәрем, мәхәббәтем
кайтты миңа урап:
«Саумы, кояш,
саумы, иртә,
исәнме!» — диләр...
Иркәли, иркәли җанны
ягымлы көйләр.
Күзләрем карап туялмый
ямь-яшел кырларга.
Ак пароход гудоклары
чакыра юлларга
«Саумы, кояш,
саумы, иртә,
исәнме!» — диләр...
Иркәли, иркәли җанны
ягымлы көйләр.

*1964*

* * *

Авылым —
Арышым,
син минем Парижым!
Үрләр аша миңа үреләсең,
солы кырларыннан карыйсың.
Карабодай тулы төклетура,
бәбәкләре зеңли ясмыкның.

Шул уйларда ничә көзгә кердем,
шул хис белән ничә яз чыктым!

Каенстан!
Урман башыннан ук күренәсең —
йөрәгемә матур утырган!
Әнә синең яңгыр басмаларың,
урамнарың —
минем Нотр-Дам!

Әнә зәңгәр инешең, шатлыгыннан,
ташларына чаклы яктырган!
Авылым,
күтәреп куй хәтер пәрдәләрен,—
сагыну җиле иссен урләрдән...
Алып китә мине еллар синнән,
суларында кала күләгәм...

Инешеңә иелеп, кояш белән
чәчен юа синең талларың
Еллар аша күренә: шундый биек
күтәрелер икән таңнарың!..
Еллар аша күрәм кояшыңның
камылларда чәчрәп янганын.

...Тау артыннан ишетәм туган якта
әрекмәнгә
тамчы
тамганын!

*1966*

## Карлы тәрәзәләр

### 1

Тәрәзәмдә кардан ап-ак челтәр,
яшел гөлләр кая үрмәләр?
Тәрәзәмдә ап-ак тропиклар,
тәрәзәмдә ап-ак хөрмәләр!

А, тойгылар! Җылы дулкын булып,
йөрәгемдә кабат терелгән.
Чирек гасыр шушы тәрәзәдән
алтын кояш миңа күренгән.

Рәсемнәрне карыйм: таныш йөзләр,
истәлекләр җанны җилкетә.
Мәхәббәтем, якты еллар язы,
килерсеңме, йә, кил, мин көтәм!..

Йә, кил инде! Мөлдерәмә күзләр,
җиңел чәчең йөзгә кагылсын.
Күрсәт әле миңа язлар ямен,
бокалларда шәфәкъ чагылсын!

Суыта алмас кышлар: синең хакта
тирән итеп уйдым хисемне.

Карлы тәрәзәләр... Салкын карга
бармак белән яздым исемеңне!

2

Әйтерсең без әле кавышу таңын
тау артында көткән ике кош:
Арабызда безнең ике яз бар,
иң кимендә әле — ике кыш...

Карлы тәрәзәләр гомермени —
кояш агызыр салкын яшьләрен.
Өй түремдә, ике теләк сыман,
ике тирәк торыр яшәреп!

Икебездә безнең ике ут бар,
ике сагыну, ләкин — бер бәхет.
Без мәңгелекмени? Тынса йөрәк,
икебезгә булсын — бер ләхет!

*1961*

## Иделдә җәй

Ятам ярда. Тыныч дәүләт сыман.
Баш очымда шаулый тупыллар.
Баш очымда Идел әкият сөйли.
Йөрәгемне юа дулкыннар!

Якты. Тыныч. Иркен! Әйтерсең лә
дөньяның бу кыл бер уртасы.
Кочагыңа ал да эрет мине,
Җил һәм Кояш Республикасы!

Киңлекләрдә җәй патшалык итә,
Иделемдә — җәйге аккордлар.
Гомерем җәе. Тугыз баллы кояш
жирнең йөзен ничек балкыткан!..

Шырпы сызам, ярда учак ягам,
көнгә кушам учак яктысын.
ә ут бии алтын елан кебек,
офыкларга сузыла чаткысы.

Чикерткәләр һәм бөҗәкләр шыла
үләннәргә. Дөрли җир уты!..
Кабатланмас мизгел. Гасырның бу
бер күз ачып йомган минуты.

Истәлектән сары һуннар калка,
урә тора Чыңгыз атлары...
Кояш шаһит! Өзәңгесен тартып,
Ишетелә кешнәп чапканы...

Китә бар да учак уты белән,
кайта бар да иске урынына.

Кояш карый, тугыз баллы белән,
Идел җиле йөзгә борыла.

Учакны мин кыйныйм таяк белән
һәм чик куям шунда мин утка!
Чалкан төшеп җирнең җилкәсенә,
тынычланып йөзәм офыкка.

Мин үземә-үзем тыныч дәүләт:
сугыш ачмыйм, утлар гүләтмим.
һәр пунктка ашыгып имза куймыйм
һәм танымыйм һәрбер дәүләтне!

Җир өстендә тора изге сәгать,
күкләр тып-тын. Гадел минутлар!
һәм, кыйбласын онытып, офыгында
тугарылып ята болытлар...

Әйтерсең лә җирдә тәмуглар юк,
кыерсытмый кешене кешеләр:
сагыш та юк, кара кайгы та юк,
бар кешеләр бер үк төсләләр...

Син дә мине күптән кичергәнсең,
онытылган бөтен ваклыклар...
Иделдә җәй.
Җирнең яртысында —
Җәй патшалык иткән вакытлар!

*1966*

* * *

Каеннарны үт тә, сугыл миңа.
Күңелем әле утсыз йорт сыман.
Анда бар да синең җыр шикелле
исемеңне күтә, юксына.
Син кер анда. Калдыр бусагада
икеләнү тулы уйларны.
Син кер анда. Ут ал күзләремә,
уз, тәртипкә китер дөньямны!
Анда бар да синең кулны көтә.
Үз итеп йөр. Үз ит, тарсынма.
Утлар кабыз. Чыгар гөлләреңне
коеп яуган яңгыр астына.
Бар да синең якты эзне саклый,
син кагылган әйбер — кузгалмый!
Ак мендәрдә синең җылың тора,
гөлләреңнең төсен көз алмый.
Бусагада синең адымнарың,
тоткаларда — җиңел кул эзе.
Шәүләң йөри. Саклый пыялалар
еллар җуймас ике йолдызны!..
Күңелем бер йорт. Калдырып кер, йөртмә
икеләнү тулы уйларны.
Син йөр анда, ут ал күзләремә,
уз, тәртипкә китер дөньямны!

*1966*

## Көзге бакча

Көзге бакча туен ача, җилләр — маэстро!
Кемнең эзен күмә көзләр, кемне кавыштыра.
...Әйтерсең лә яфрак түгел, йолдызларга басып,
инне ингә куеп уза ике фантаст-гашыйк.
— Күрче, ничек тармакларга энҗеләрен тезгән!
Китмәс идем бер дә көздән, ул китмәсә бездән.
— Безгә яфрак асты да — йорт! Менә... кышлар гына...
Иннәренә әйләнгәләп сары кошлар куна.
Күкрәк тутырып эчелә татлы, рәхәт һава!
Ак каенлы юлларына якты бәхет ява...
Аяк астында тулгана күләгәдәй бер эт.
(Кайчандыр ул капка астыннан калган иде өреп.)
Сырпаланып йөри бүген, «коткар,— диме,— кыштан»,—
Һәр кешенең күзенә карый, койрыгын кыскан!
Соңгы яфрак — гүя кылда эленеп тора йөрәк —
өзелер дә янып бетәр кара җирдә дөрләп...
Җилли дөнья, туза тузлар! Җирдә — эзләр, эзләр...
Кемне эзләп елына бер кайтып китәр көзләр?
Шаулый бакча, яфраклары җирдә — бакыр акча.
Көзләр килә-китә, шаулап җирдә кала бакча.
Кала көйләр, кала аваз кылдай тармакларда,
аңа җилләр кагылу җитә моңны кабатларга!
Яфрак шавы аша килә кем тавышы, әкрен:
«Белдекме соң без, бәгырем, мәхәббәтнең кадерен?»
Тавыш калган әнә шулай тармакларга сарылып:
«...исемеңне яздан көзгә кабатлармын сагынып!»
Көзге моңнар гизгән чакта шаулап бар дөньяны,
сукмаклардан тып-тын гына уза Шагыйрь җаны...

*1970*

## Солдатлар

Озатып, вокзаллар каршында
маңгайдан үптеләр аналар.
Тузанлы юллардан үттеләр
дөньяны күрмәгән балалар.

Балалар керделәр утларга,
балалар сүз бирде тупларга.
Күпләре, төренеп шинельгә,
калдылар еракта йокларга...

«Балалар, торыгыз, балалар,
ашыгыз суына табында!..»
Ничә ел тормыйлар балалар
Иделдә һәм Дунай ярында...

Уятма, йокласын, син, ана,
айларны, елларны санап бар.
Йөрәктә һаман яшь, гел бала —
кайтмаган солдатлар, солдатлар...

Ана ул йокламый, сабые
юрганын ачса да уяна.
Аналар йөрәге шикелле,
Мәйданда Мәңгелек ут яна.

Аналар йөрәге шикелле
ут яна, уйлана, талпына.
Аналар хәтере шикелле,
җил йөри курганнар артында...

*1965*

* * *


Мәхәббәтсез, утсыз һәм сөюсез
үткән көннәр — кысыр хыяллар...
Салам белән суга язган антлар,
китек бәхет — бәллүр-пыяла;

зәңгәр мираж, алтын пәрәвезләр,
чибәр гарип,
җәннәт төрмәсе,
татлы сагыз,
канатсыз җир, өмет...
Тормыш-туйның чүпрәк бирнәсе...

Ком өстенә салган идеал-сарай,
шәрә табын,
көләч дивана,
муляж алма,
йолдыз күләгәсе...
Үрелеп кара, яле, син аңа!..

Барына да бүген хисап бирәм,
гомернең нәкъ исәп вакыты.
Сөю китер миңа! Кызыктырмый
фиргавеннең алтын табуты!

*1985*



**Әхәт Гаффар**[1]

# ДӘРЬЯ БАШЫ

ПОВЕСТЬ

Ак кар яткан дала дәрьядай киң, очсыз-кырыйсыз булып тоела иде. Күк йөзе аяз, кояш тарау яктылык белән өретелеп кенә күренә. Ак моңсулыкта салмак кына кыңгырау чыңлавы, чана табаннары чыжылдавы, кар шыгырдавы, ара-тирә ат пошкырганы, кешеләрнең өзек-өзек сөйләшкән, көлеп куйган тавышлары ишетелә.

Читендә сирәк-мирәк шәрә куаклар тырпаешкан, ялгыз агачлар басып торган кышкы ат юлы буенча дистә чамасы җигүле ат олавы көнчыгышка таба бара иде. Тәбәнәк кар көртләре кашында җәяүле буран көдрәләре бөтерелә, сыртлары бәсләнгән атларның танауларыннан пар бөркелеп чыга, җил атларның ялларын тузгытып җибәргәли, чана чыбылдыкларына, йөкләргә учлап кар сипкәли. Уң яктан искән җилгә каршы, канатларын авыр кагына-кагына, олауга аркылы юнәлештә ялгыз козгын очып үтә, аның коңгылдавы ишетелеп кала.

Олауның урта бер өлешендә туры ат җигелгән чыбылдыклы чана бара. Ул чана артына тагын бер затлы чана тагылган. Аңа төенчекләр, тулы капчыклар, әрҗәләр төяп бәйләнгән, аларны кар сарган. Башына колакчыны бәйләнгән бүрек, кулына тире бияләй кигән, якасы һәм җиңе камалы төлке туны өстеннән толып бөркәнгән, сакалы-мыегы бәсләнеп каткан, дилбегә тоткан Сафиулла — «казанчы Алты-биш Сапый» — козгынны карашы белән озатып калганнан соң:

— Һи, үләт кыргыры! Кем башына каркылдый бу, ә? — дип куйды. Аңа каршы бер хатын-кыз салкында карлыкканрак тавыш белән:

— Алла сакласын! — дип авыз салды.

Сафиулла, толып якасын кайтара төшеп, артка каерылып карады. Чыбылдык астында — әрҗә һәм төенчекләр белән уратылган яшел печәнне чокырлап ясаган урынга яртылаш күмелеп, аның хатыны Фатыйма

[1] Әхәт ГАФФАР (1949) — прозаик, драматург, публицист. Дистәдән артык китап авторы, күп кенә әсәрләре чит телләргә тәрҗемә ителде. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.

утырган. Ул да толып бөркәнгән, бүреге өстеннән бәсләнгән, чуклы йон шәл япкан. Аның куены турысында башына сырган бүрек кигән бер баланың зур, кара күзе елтырап тора иде.

Ат пошкырып җибәрде. Чана кинәт тартылып китте. Дуга кыңгыравы чыңлады. Бер генә мәлгә әйләнә-тирәне тынлык басты. Ләкин шундук җанлану сизелде, тавыш күтәрелде. Сафиулла юлчылар өстенә егылудан дилбегәгә генә тотынып калды. Аты, колагын шәңкәйтеп, янга каерылып карады. Аның сулышы тирәнәеп, танавыннан чыккан тыны киңәеп киткән. Сафиулла, чыбылдык астыннан сузылып, аты каерылган тарафка караш ташлады.

Ул якта — утыз сажиннар ераклыктагы үр кашында бүре утырып тора иде. Ялгызы гына ул танавын күккә чөеп, кыска гына итеп улап куйды. Алда, аннары артта каударланып ике эт өрергә тотынды.

— Бүре бар! — диде Сафиулла.

— Ләхәүлә вә лә куәтә,— дип укынды хатын.— Үзең сакла, Ходаем!..

Аларның туры аты алдындагы чанада утырган көрәк сакаллы урыс чукынып куйды.

Сафиулла ятып диярлек үрелеп, чана алдындагы печән арасыннан авыр чылбырлы чукмар суырып чыгарды да, бияләен салып, аның тимер сабын җайлап тотты. Ул арада елтыр күзле малай ни торырга, ни посарга белмәгән хатынның куеныннан шуып чыкты да, үрәчәгә ябышып, якты кар өстенә күләгә салып торган бүрене карашы белән эзләп тапты.

Олау башындагы пар атка җигелгән яхшы кошевкада ике хәрби утырып бара иде.

— Попридержи коней! — дип кычкырды аларның сакал-мыегы бозланып каткан өлкәнрәге кучер солдатка.

Атларны тыйгач, олау туктап калды.

Ул арада хәрбиләрнең яшьрәге — нечкә генә мыегына фәкать юка бәс кенә кунарлыгы — елгыр гына сикереп төште дә шундук винтовкасының затворын коргач, җәһәт кенә бүрегә төбәде.

Ату тавышы яңгырады. Өлкән офицер янәшәсендәге хатын-кыз, күзен йомып, колагын томалады. Тик, аткан чакта әллә шинель бөркәнчеге, әллә шул мәлдә йөзенә сибелгән учма кар комачауладымы, яшь хәрби бүрегә тидерә алмады.

Янәшәдәге куаклыктан бер көтү кызылтүш пырылдап күтәрелде дә, түбәнтен генә очып, әрәмәлектә күздән югалды. Ә бүре, акрын гына аякларына күтәрелде дә, ашыкмый гына үр артына төшеп китте. Анда аны тагын икесе көтеп тора иде.

— Ах, черт! Промазал! — диде яшь офицер җилгә кырын төкереп.

— Растяпа ты, однако, Михаил Семеныч!

— Поземка,— диде яшь офицер һәм, җилдән ышыкланып, папирос кабызды.— Уж не обессудьте.

— Смотри, милостивый государь! Как бы супруге так же не промазал по приезде,— диде өлкән офицер гөлдерек тавыш белән көлеп. Аннары, кучер солдатның иңенә кагылып:— Трогай, голубчик! — дип боерды.

Тук пар атлар, пар бөркеп, гаярь генә кузгалып киттеләр. Алардан соң берәм-берәм арттагылары да купты. Яшь офицер, папиросын соңгы тапкыр суырып алгач, читкә атты да, барган шәпкә винтовкасын урнаштырып, кошевкага сикереп менде.

— Вожак был, ваше благородие,— диде ул үкенечле тавыш белән һәм тагын бүре күренгән якка борылып карады.

— Думаешь, со своей стаей пожаловал?

— Непременно-с.

— Вожак, да не наш!..

— Мәми авыз,— диде Сафиулла.— Тигезә алмады.

Аларның алдындагы йөк хуҗасы аңа таба борылып сүз катты:
— Коленки, кажись, задрожали, а, Сафи!
— Да уж! — диде Сафиулла аңа чукмарын күрсәтеп, һәм, аны печәнгә яшергәч: — Я шесть волк бил, Кузьмич,— дип өстәде.
Кузгалырга аларга да чират җитте.
— Слыш-ка сюда, Сафи! — диде рус йөкчесе.
— Чава ышшы?
— Что-то стало холодать.
— Скуры думa будем, Алла бирсә.
— Вот именно. Поди, пересядь сюды.
— Зачем?
— Дак ведь промазал, будь он неладен! А нам бы малость и мазнуть не грешно...
Сафиулла бер хатынына, бер малайга карап алды.
— Мәле, Габдуллаҗан, шәкерт булсаң да, ат тота беләсеңдер?
— Белми ди, бар! — диде малай һәм, куанычын яшерә алмыйча, дилбегәне тизрәк кулына алды.
— Ни диюең, тозсыз? — диде хатын канәгатьсез төстә.— Баланы туңдырасың ич! Җизнәсенә ничек җавап тотарсың?.. Урынына кереп утыр, Габдуллаҗан!
— Әй лә! Анда аяк ойый. Минем тышта, җәяүләп йөгерәсем дә килә әле.
— Йөгерер чагың алда әле бала, алда,— диде хатын моңсу тавыш белән һәм печәнгә чума төшеп утырды.
Сафиулла толыбын иңеннән төшерде дә, малайга җайлап япкач, үрәчәгә тотынып тышка сикерде һәм урыс чанасын куып китте.
— На, малкай! — диде малай көр тавыш белән дилбегәне кагып.
Дөнья, әйләнгән кебек, акрын һәм тын гына артка таба шуа бирде. Җил кешеләр тавышын өзеп-өзеп, бер калкулыкта тибрәлгән кылганнар арасыннан шудырып чыгаргач, җәяүле кар белән бергә далага тарата иде. Малай, шул кылганнарны карап бара торгач, үзен шулар арасында күлмәкчән, чалбардан гына яланаяк каядыр йөгерә дә йөгерә, тыны бетеп егыла, аннан тагын йөгереп китә, ауный, торып, аларны бәләкәй кулы белән иркәли, нәрсәгәдер сөенгән сыман көлә, аннан ары, тезен кочаклаган килеш, шулар арасында тын гына уйланып утыра, күзеннән бите буйлап яшь тәгәри итеп күрде. Күрәсең, очсыз-кырыйсыз тоелган офыксыз карлы даладагы әлеге кылганнар уентыгы, әледән-әле учма-учма кар тузанының йөзенә сирпелеп, күзеннән яшь китергәне шундый хис кичерткәндер. Чыннан да, чана башында печәнгә һәм толыпка төренеп утырган бу малай үзе дә җилгә һәм кар себерүенә һәркайсы үзенә аерым каршы торучы әлеге кылганнарны хәтерләтә иде.
«Казанчы» Сафиулла белән олаучы Кузьмич салмак кына агылган олауның уртасында барган чанада стаканнан бер-бер артлы «ачы су» эчеп куйдылар. Сафиулла урыс олаучысы сузган дуңгыз маен капмады.
— Ат ите харуша,— диде ул куенына тыгылып.— Казылык!
— Бля-ям! — дип сузды Кузьмич.— Отведал. В русско-турецкую войну. Впрямь яхши. С кониной холод нипочем.
Шулай гәпләшеп, аларның һәркайсы үз ризыгын чәйнәде.
— А малайка яхши,— диде Кузьмич Габдуллага ымлап.— Дай Бог ему здоровья.
— Рәхмәт, Сабилий Кузьмич.
Сафиулла артсыз чанадан ашыкмый гына төште дә, атын уздырып җибәргәч, тәртәләреннән артка тагылган затлы чанадагы төенчекләрне ураган бауны тарткалап карады һәм үз чанасына менеп утырды.
— Бүре куркытмадымы соң? — дип сорады ул малайдан дилбегәне алып.
— Әй лә! — диде Габдулла.— Бүре күргәнем бар инде минем.
— Кайда?

— Әтнәдә.
— Нишләп йөридер ие соң ул анда? Бүрене әйтәм.
— Базарда ие ул.
Сафиулла көр тавыш белән көлеп җибәрде:
— Берәр сарык сатып алырга килгән мәллә?
— Аның үзен сатарга апкилгәннәр ие. Бер урыс.
— Нигә алмадыгыз соң? Сиңа бүрек тектергән булыр идегез.
— Сәгъдетдин әти миңа анда бүрек алып биргән иде инде. Аннары — бишмәт. Киез ката да.
Сафиулла үз-үзенә сөйләнеп:
— Сәгъдетдин әти, Сәгъдетдин әти,— дип кабатлады.— Мөхәммәтгариф әти, Мөхәммәтвәли әти... Күрсә дә күрер икән ятим башы. Инде менә — Галиәсгар... Нишләр анда? Бусы — җизнәсе генә...
Тын гына барган Фатыйма толыбын ачты да:
— Җәле, карт! Баланың башын катырма әле! — дип үрелде дә малайны үз алдына тартты.
— Карап барасым килә,— диде малай аңа карышып.
— Туңарсың,— диде Фатыйма кырыс кына.— Җизнәң Галиәсгар туңдырмаска кушты.
— Монда шулай бүреләр күпмени? — дип сорады малай.— Казаннан чыкканнан бирле... дүрт тапкыр юлга төштеләр ич инде.
— Әй, Габдуллаҗан! Дөньяда бүре бетә димени? Аның ике аяклылары күбрәк. Шуларыннан саклан син, шуларыннан...
Малайны Фатыйма үз алдына төреп утыртты. Ул арыган, талчыккан иде, ахрысы. Җай гына барган шәпкә, кыңгырау чыңлавына, кешеләрнең тоныкк кына булып ишетелгән сөйләшүләренә, кар шыгырдавы авазына изрәп йоклап китте.
Каршы килгән атлылар күренмәс булды: олау юл тоткан урынга — Җаекка якынлашты.
Олау башында барган хәрбиләрнең пар аты тояклары астыннан кар чәчә-чәчә юыртып ук китте. Сафиулланың туры аты бер мәлгә колагын шәңкәйтеп алды да, адымнарын кызулаткан башка атлардан калышмаска теләгәндәй, елгыррак атлап китте.
Алда шәһәр чалымнары күренде. Әле шактый ерак булса да, чиркәү һәм мәчет манаралары төсмерләнә иде инде. Бер үргә күтәрелгәч, аның эреле-ваклы йортлары да ачык күренә башлады.
— Ай җанкай! — диде Сафиулла атны тыеп.— Кайтып җиткәнне сизә, малкай... Сиңа әйтәм, Габдулланы да уятсаң ярар.
— Йоклаган баланы уяталар димени?
— Йә, хатынланма. Кая җиткәнен карап калсын.
Малай уянып китте, тире бияләе белән күзен угалаганда, шәһәр урамына җиткәннәр иде инде. Олау берәм-берәм аркылы урамнарга, тыкрыкларга тарала башлады. Малай каршыга якынлашкан һәм артка чигенгән катлы-катлы агач һәм таш йортларга, урысча, гарәпчә хәрефле кибет язуларына, морҗалардан чыккан төтеннәргә, урамдагы халыкка, җигүле атларга, биек манаралы мәчеткә карап барды.
Олы капкасы шәрран ачык (ни ачылмас, ни ябылмас хәлдә карга күмелгән), асты — таш, өсте агач булган бер йорт янынннан узып баралар иде. Аларның юлын бүлеп, әлеге капкадан бер төркем малай-шалай йөгерешеп чыкты. Сафиулла атын туктатып торырга мәҗбүр булды. Кайсы кай тарафка чәчелгән малайларны карашы белән озатып калгач, малай Сафиулладан:
— Болар кем була? — дип сорады.
— Танымадыңмыни? Шәкертләр ләбаса!
— Ә бу — мәдрәсәмени?
— Мәдрәсә шул. «Мотыйгия» мәдрәсәсе, диләр аны.
— Син әйткән хәзрәтнекеме? Кем әле...
— Шуныкы шул. Мотыйгулла хәзрәтнеке.

— Мине шунда бирәләрмени?
— Белмим тагы. Җизнәң шулай дип әйткәние-әйтүен.
Кузгалып киттеләр. Бераз баргач, бер йортка камчы сабы белән төртеп күрсәтеп, Сафиулла:
— Ә менә бусы Галиәсгар җизнәң белән Газизә апаңнар йорты булыр,— диде.
— Мине шушында илтәсеңмени инде син, Сафиулла абзый?
— Башта үзебезгә төшәбез әле. Аннары, аннары...
Ниһаять, туры ат чаттан бер тыкрыкка борылды да, җыйнак агач йортның капка төбенә җитеп туктады.
— Әлхәмделилла! — диде Сафиулла һәм, авыр гына кузгалып, чанадан төште, бияләйләре белән шап-шоп иттереп, өс-башын какты.
Аның сүзен Фатыйма:
— Аллага шөкер,— дип куәтләде.
Башта малай, аннары хатын чыбылдык астыннан иелеп чыгып, карга аяк бастылар. Аларның аяк астында кар шыгырдады.
Малай кар сарган утыртма куак читәнне, аның буена көрәп өелгән кар көртен, түбәсез, кыйшайганрак капканы, аның нәкышлы келәсен, бер тәрәзә төбендәге яран гөлен күзеннән кичерде.
— Ай Алла, күрче, бар дип тә белмиләр,— дип сөйләнде Сафиулла:— Кая олактыгыз? — дип кычкырды.— Ачыгыз җәтрәк! — Ул кече капканы шыгырдатып ачты һәм тагын риза булмыйча:— Җүннәп карын да көрәп куймаганнар,— дип сукранды.
Ачык капкадан бер эт йөгереп чыкты да аяк астында буталырга тотынды, чананы иснәштергәләде дә, малайга карап, юаш кына өреп куйды. Малай, ятсынып кына аның сыртыннан сыйпады.
Тәрәзәдә хатын-кыз йөзе чалынды. Шундук ишек ачылган, кар шыгырдаган авазлар, хатын-кыз, ир-ат тавышы ишетелде:
— И-и...
— Кайттылар!
— Сөбханалла!
— Көтә-көтә көтек булдык инде...
Кече капкадан иң әүвәл ялан-өсле, башына шакмаклы чуклы шәл генә бөркәнгән бер хатын килеп чыкты да:
— Нихәл кайттыгыз соң? — дип эндәште.
Сафиулла аңа кырыс кына:
— Ару гына әле,— дип җавап бирде.
— Иншалла, иншалла,— дип сөйләнде әлеге хатын һәм, малайны абайлап, Фатыймага:— Шәкерт малай шушымыни инде? — дип сорады.
— Кем булсын тагын? — диде Фатыйма аны баштанаяк күзәтеп.— Берәр биләмгә җыендың мәллә — чулпы чыңлатып йөрисең?
— Ә-э, биләм кайгысые! Йортны кем тоткан дип беләсең?
— Әйдә, Габдуллаҗан,— диде Фатыйма һәм малайны ишегалдына, аннан өйгә әйдәп кереп китте.
Башына камалы бүрек, өстенә җилбәгәй җибәреп кайры тун кигән бер ир-ат, авыр гына күтәреп, олы капканы ачып куйды да, йөгәненнән тотып, Туры атны эчкә әйдәде.
— Ну, Гатаулла, бу карны көрәп куйсаң, кулың тартышыр идеме? — диде Сафиулла.
— Көрәгән инде аны, әти. Тагын салган ич.
— Сала инде ул, салмый ни!
Сафиулла әлеге хатынга:
— Нәрсә син яланөс йөрисең монда? Суык тисә, синең җәфаң кирәк ди! — дип эндәште дә кулыннан салган бияләе белән аның артына шапылдатып алды.— Бар, чәеңне куя тор. Аннан ары кара аны: ахшамнан соңга мунча әлгергән булсын! — дигәч, толыбын салып, кулын әледән-әле тыны белән җылыткалый-җылыткалый йөк бауларын чишәргә керешә.

Арттагы чананы чишеп, янга урнаштыргач, Гатаулла олы капканы эшереп япты да, аннары атны тугарып, абзарга кертеп чыкты.

— Турыга солыны кызганма,— диде аңа Сафиулла.— Туенгач, көрпә туглап сугарырсың. Тоз салырга онытма. Аннары өстенә чыпта яптырләде.

— Япкан. Ярар инде, әти. Шуларны да белмәскә бала-чага мәллә мин?— диде Гатаулла һәм яңа чанага ымлап:— Кыйммәткә төштеме соң?— дип сорады.— Хутлы күренә.

— Кеше малын чутлама, яме. Казаннан хәтле сөйрәтеп кайткач, очсыз булыр димени? Галиәсгар кесәсе генә күтәрмәслек түгел,— дип, Сафиулла болдырның тәбәнәк баскычыннан өйгә кереп китте.

Йөкләр тирәсендә Гатаулладан кала бишмәт кигән яшь кенә хатын (йөкле күренә) һәм бер кыз белән бер малай кайнаша калды.

— Күпме әйтергә сиңа авыр күтәрмә дип?— диде Гатаулла яшь хатынга.— Көчәндермәстәйләренә генә тотын. Арттан кумыйлар ич— өлгерелер.

Фатыйма чишенеп өлгергән иде һәм хәзер малайның билбавын чишеп, бишмәтен, аннары киез каталарын салдыра иде инде. Сафиулла да чишенеп, киемнәрен чөйгә элде, сакал-мыегына каткан бозны йолыккалагач, башындагы түбәтәен салып, башкасын киеп куйды.

Ишекне әледән-әле киң итеп ачып, өйне буга күмә-күмә әрҗә, төенчекләр ташылып беткәч, барчасы өйгә җыелып торган бер арада Сафиулла сандыкка утырды да:

— Дога кылыйк,—диде.

Утырышып, дога кылып алдылар.

— Әгүзе биллаһи минәшәйтан ирражим...

— Йа аллаһы иллалаһы...

— Өй суынды,— диде Сафиулла кузгалып.— Син, килен, мичкә ягып җибәр... Кызым, син яңа оекбаш китер, ә син, такырбаш, читек китер,— диде ул һәм, шуларны кигән арада, самавыр куеп йөргән яшь хатынын астан гына күзәтә-күзәтә:— Чәйгә Казан ризыкларын да куегыз,— диде.— Чәйдән соң Габдуллаҗанны җизнәләренә илтәсе булыр. Бераз күчтәнәч җыеп төйнәрсез... Син бар, кызым, Газизә апаңнарга хәбәр итеп куй...

— Кайсысына — әнинең абыйсы Галиәсгар абыйдагы Бибигазизәгәме? Әллә хезмәтче Габдрахман абыйның хатыны Газизәгәме? Ә?

— Минем әни ниме дип монда килсен икән, аңгыра? Габдуллаҗанны шуларга үзебез илтеп бирергә булгач,— диде Фатыйма.

— Минем кызым аңгыра икән, үзегезнең чатаныгызны йомышлагыз алайса,— диде Җәмилә.

— Сез нәрсә?— диде Сафиулла ярсып.— Инде балалар бүлешәсезмени? Әйткәнне эшлә!— дип кычкырды ул кызына. Һәм тегесе, тиз тотып, чыгып та китте.

— Ә син, Җәмилә,— диде ул, мич аралыгыннан коры утын алып, тамызлыкка чыра телгән яшь хатынына,— чабынырга яңа себерке куй. Рәтләп (тамагын кыра) чабынмаганга айдан артык... Юл газабы — гүр газабы ул.

— Бар, мунчага коедан су китерә тор,— диде Җәмилә киленнәренә. Һәм Сафиуллага:— Аның каравы бер михнәттә, бер рәхәттә, диләр,— диде. Ул мичкә утын тыгып, бер-бер артлы сызса да, шырпысын кабыза алмый тора иде.

Фатыйма аның кулыннан шырпы кабын тартып алды да, кабызып, чырага элде.

— Рәхәткә тәкатең калмагандыр шул,— диде ул төксе генә.

Бу арада Гатаулла ишек төбендәге тәпәнгә агач кисмәктән су салып, он, тоз өстәп туглады да атны эчертергә чыгып китте. Ә Габдулла, түрдә өйдә нишләргә белмәстән, тын гына өй җиһазларын күзәтеп тора иде.

Мичкә ягып җибәргәч, түрге өйдә Фатыйма бер төенчекне чишәргә керешкән Җәмиләгә иелеп:

— Рәхәткә тиенәсең килгәч, Казан юлын таптыйлар аны,— диде һәм төенчекне үзе чишә башлады.— Әйтмәгәние димә, мунчаның беренчесенә үзебез керәбез.

— И-и, исем бик китә инде,— диде Җәмилә, тыенкы гына көлеп һәм, күлмәген төзәткән булып, билен сыпырып-сыпырып куйды.— Икенчесе... күпкә кайнаррак аны пәрәми!

— Кайберәүләргә кеше калдыгы да тансык шул,— диде ана Фатыйма, зәһәр пышылдап.

— Ай-һай! Кайберәүләрне калдырасы итмәсә, Сафиулла яңаларын башларые микән дип торадырыем әле мин!

Эчтән ярсый башлап, Фатыйма төенчектән урындыкка исле сабыннар алып тезде.

— Аң бул,— диде әл.— Бу Гөлҗиһан сабыннарын үз кулларым белән сезгә дип җыймаган! Гөбердәтеп, үзебез юынабыз, Аллаһы теләсә!

— Сафиулла бая гына бер дә алай юыну кайгысында булмады шикелле. Безнең икебезгә ике себерке дә хәйран таман! Биргәненә шөкер, бүген бер-беребезне әлсерәшеп бетенгәнче чабындырасыбыз бар әле дип көтеп алганнарым рас килмәгәе!

Ике өй арасындагы ишектән, кулында сөлге ишә-ишә, Сафиулла килеп кергәнен күргәч, алар басынкыланып калдылар һәм икесе берьюлы төенчеккә иелделәр.

— Ни бүләсез? — дип сорады Сафиулла.

Шундук йомшап, Фатыйма үз төенчеген чишеп, түрдәге сәкегә берсе кызыл, икенчесе яшел юрган таратып салды.

— Менә, карт,— диде ул.— Җәмиләгә юрганнарны күрсәтмәкчием әле.

— Күрсәт соң.

— Алган чакта монау сатинына пар булмады ич, хәерсез. Ничек дисең, Сафиулла, безгә монау кызыл атласы гына да ярап тормасмы?

— Анысын мин белмим инде аның, үзегез карагыз тагын. Минем үземә чиратлаштырып та ярый,— дип, Сафиулла ишкән сөлгесен тарата-тарата артка чигенде.— Кайчан кайный инде бу самавыр?

— Ә менә мин... Ә менә мин...— диде Фатыйма Җәмиләгә тотлыга-тотлыга.— Мунча себеркесе генә чиратлап була ул. Безгә атласы да ярап торыр,— дип, юрганны күтәреп, такта белән бүленгән бүлмәгә кереп китте.

— Әй, сезгә әйтәм! — дип кычкырды Сафиулла.— Суынышыгыз. Самавырыгыз кайнап чыкты монда!

Хатыннар кече өйгә чыгып киттеләр.

Габдулла бу вакытта сәкедән аягын салындырып, тәрәзә янында утыра иде. Үзе генә калгач, ул, сабыннар төреп кайтылган бер гәҗит битен алып, караштыргаларга керешге. Аның каршысына ничектер чаталанлабрак атлап йөрүче теге малай килеп басты.

Габдулла аңардан:

— Син кем атлы? — дип сорады.

— Гаптерәүф.

— Ә мин — Габдуллаҗан.

— Беләм инде. Сине күп сөйләделәр монда.

— Минем хактагы сүз гел шулай инде ул: эт шикелле, бер алга чыга, бер артка төшә,— дип көлде Габдулла.— Син бу апаларның кайсысыныкы соң? Олысыныкы бугай, име?

— Әй! — диде Габдерәүф кул селтәп.— Шул — өлкәненеке булам.

— Атаның да Казанда чакта сүз арасында: «Мин өлкән кеше инде»,— дип куйгалаганы бар. «Өлкән» ни нәрсәне белдерә ул?

— И, шуны да белмәскә! «Олуг» дигән сүз!

— Алай икән-әң,— дип сузды Габдулла.

— Ә миңа икесе дә — ике тиен бер акча,— диде Габдерәүф өзелгән сүзгә кире кайтып.— Икесен дә «әни» дип йөртәм.

— Синең әниләрең әзрәк икән әле! — дип елмайды Габдулла.— Әминекеләрне бергә санасаң, өчкә тула. Үземнеке Бибимәмдүдә булган. Аннары соң — Кырлайдагысы Зөһрә әнкәм. Аннан соң — Казандагысы Газизә анам.

— Бер атаңа өчәүме?

— Аталарым да шул тиклем! Үземнеке — Мөхәммәтгариф, Кырлайдагысы — Сәгъди, Казандагысы — Мөхәммәтвәли.

— Бай икән син! — диде Габдерәүф, тел шартлатып.

— Ие шул,— диде Габдулла һәм, уйчанланып, тәрәзәгә борылды да: «Бие, бие, Гайнулла, биегән кеше бай була»,— дип көйләп куйды.— Бии торгач, хәзер монда килеп җиттем инде. Син минем Галиәсгар җизниләрне белмисеңме?

— Нигә белмим ди? Минем әни — шуның кызы ич инде. Әти — кияүләре була... Алар — б-ә-ә-әк байлар. Кыргызлардыр, урыслардыр — барчасы белән эш йөртә. Бә-әк шәп урынга төшәсеңне бел.

— Кайда да бер,— диде Габдулла уйчан гына һәм гәҗитне төргәкләр өстенә ыргытты.— Мин Кырлайны сагындым инде, мәдрәсәне. Фәтхерахман мөгаллимне...

— Мәдрәсәләр бездә дә күп ул, Габдулла малай. Дүртәү! Мин «Рәкыйбия»гә йөреп сабак алам.

— Бергә йөрмәбезме әле.

— Юк, сине бүтәнгә бирәләр. «Мотыйгия»гә. Шулай колагыма чалынганые. Минем бабай, ә синең җизнәң Галиәсгар бай Мотыйгулла хәзрәт белән әшнәлек йөртә.

Шунда аларның сүзен алгы өйдән Сафиулланың:

— Әй, малайлар! Табынга чыгыгыз! — дигәне бүлдерде.— Аннары хәерле сәгатьтә кузгаласы булыр.

— Ярар, бергә-бергә уйнаган чаклар булыр әле,— диде Габдерәүф.

— Мин уеннарга бик катнашмыйм,— диде Габдулла.

— Ник алай? — дип сорады Габдерәүф гаҗәпсенеп.

— Килешми дия торганнарые. Мулла баласы диптер инде.

Эшләрен бетереп, өйгә Гатаулла белән аның хатыны да керделәр. Сафиулланың кызы да кайтып җитте.

— Газизә апай бәбәй имезә, йоклатам да килеп җитәм, дип әйтте,— диде ул, кемгә дә атамастан.

Табын хәстәрләнгән иде инде. Бит-кул юып, сәкегә утырыштылар, «бисмилла» әйтеп, тын гына ашарга, чәй эчәргә керештеләр.

— Алай бик иркенлисе түгел,— диде Сафиулла.— Ахшамга хәтле оланны илтеп тапшырган яхшы.

— Бәлкем, шәкерт егетнең юлдан соң кунып китәсе киләдер? — диде яшь килен.— Мунчаны да тансыклагандыр.

— Синнән сорамаганнар! — дип бүлдерде аны Фатыйма.— Әниләргә атап алган Казан күчтәнәчләрем бар. Бүген үк тапшырганда саваплы булыр.

— Әле кайтып җитмәгәннәр, инде әниләр дип торган булалар,— диде Җәмилә һичкемгә карамастан.— Минем әниләргә бармаганга биш былтыр инде.

— Үзем генә тапшырганда да җарап торыр,— диде Сафиулла кырыс кына.

— Үземә хәләл доганы кешегә калдырасым юк әле,— диде Фатыйма катгый итеп.— Атап алганны тапшыруның үз йоласы аның. Анысы, шөкер, үз дәүләтләре дә җитәрлек, тик көтмәс төштән иңгән күчтәнәчне беркемнең язык иткәнен күргәнем юк әле моңарчы. Бер генә кадак как-төшкә бал, төшлесеннән дә, төшсезеннән дә тагын берәр кадак бөлеш җимеше илтүдән генә бөлмәбез. Шул как-төш өстенә эресеннән, вагыннан чәчәкле кәнфиттән дә бер кадак тирәсе өлеш чыгарганда да ярап

торыр. Узган юлы барганымда әни ит-аш арасында күнеленең болганып-фәлән итеп куйгалаганына зарланып торганые, ике-өч данә генә лимоннан да өлеш чыгармасаң, килешеп бетмәс...

Җәмилә түземсезләнеп:

— И-и-и!..— дип куйды.

Сафиулла тамагын кырып алды: әллә Фатыймага, әллә Җәмиләгә риза түгел иде, ахрысы.

— Моның белән генә бетмәде әле,— дип дәвам итте Фатыйма, өреп чәй эчә-эчә.— Аш артыннан тәмле суга дип, киптерелгән чиям дә бар, аннан да чирек кадагын тәгаенләп куйган идем, бер адарынганны кире уйлауның гөнаһысы бар аның. Шуннан ары шулай ук чирек кадак кадәрле генә кагын да бүлгән идем, биргән нәрсәләрем ишле күренсенгә анысын да куйсаң, таман булыр. Тагын...

— Җитеп торыр,— диде Сафиулла.— Монда әллә әндри казнасы бар дип белдеңме?

— Минем дә күнелемә шулай тоелган иде анысы, карт. Бәлкем как-төш өстенә дигән чәчәкле кәнфитне ярты кадакка калдырып, аның урынына сумсага, катламага дигән майдан бирәр кадак өстәмәскәме дип тора идем. Безнең дә төшеп калганнардан түгел икәнне белеп торсыннар дигәнне белгертеп, янына өч әфлисун да куйганда ярап торыр иде...

— «Ишле», имеш»! Әллә монда без бик ишсезме?— диде Сафиулла табындагыларга ымлап.

— Анысы үз нәфесең ние инде.

— Ние, ние? Телеңне тыйма әле монда, җәме?!

Килен:

— Ул тиклем нәрсә Җаек кибетләрендә дә бихисап ич, әни. Казан каласыннан шайлы...— дип башлаган иде, Фатыйма аны:

— Син тик кенә тор. Өйрәтеп торучың булмагач, әш җаен беләсенме соң син? Менә, карап карарбыз әле, мунчаны узган юлыдагы ише исфәләнле итеп якмадың микән...

— Әни, ул юлысында мин әниләргә барып калгач, син үзең томалаганыең ич аны...— диде яшь килен үпкәле тавыш белән.

Каршы сүз әйтере калмаганга күрә Фатыйма:

— Карале, карт, аннан ары болар, Казан хәтле Казаннан кайтып, буш кул белән килеп кергәннәр, димәсеннәр өчен теге өч ак сәрпинкә яулык янындагы зәңгәрсу сатин яулыкка төреп, бер-икене генә булса да Гөлҗиһан сабыны да куймасак, әллә ничегрәк чыкмас микән ул?— диде. Үзе Җәмиләгә каш астыннан гына карап куйды.

Габдулла, бу сөйләшүләрдән кызык табып, әллә кайчан көләсе килсә дә, үзен тыеп тора иде. Инде чыдамады, бөтен өйне тутырып көлеп җибәрде.

— Җыеныгыз!— дип боерды Сафиулла һәм, сүзне бетерергә кирәк табып, алгы өйгә узды да буфетның аскы өлешенә иелгәч, әллә кайдан «чүлли» аракысы чыгарып, куен кесәсенә яшерде, капшап, беленмәслеген чамалап торды.

Фатыйма исә үзалдына сөйләнгәндәй кыланса да, көндәше Җәмилә белән яшь киленне котыртасы килеп:

— Аллаһы тәгалә боерса, Казаннан үземә алган кырык итәккә житәрлек илле иңле уникe аршин кәшимир күлмәк тектергәч киеп барып, әнинең сөенчесен алып кайтасыларым да бар әле минем!— дип, җырлый башлады.

Җете кызарып, кояш баюга авышкан, баш очында ай да калыккан иде инде. Әле караңгы төшмәгән, энгер-менгер генә. Карга тавышы ишетелде, кайдадыр эт өреп алды, күгәрченнәр очып узды.

Шыгырдап ачылган ишектән Габдулла килеп чыкты. Ул бер кавым ишегалдындагы чаналарга, келәт диварына һәм баскычына куелган ат сбруйларына карап торды. Һәм, кая барырга белмәстән, кое янына килеп

басты, аннан капканы ачып, түбән текәлде. Кое төбеннән ана ай карап тора иде. Аймы соң? Нәрсә? Үз әнисе Бибимәмдүдә йөземе? Әллә икенчесе — Газизәме? Ә бәлки өченчесе — Зөһрә әнкәседер бу? Әнә шулай үз хәтерен барлап торганда кое төбендәге ай чагылышы Сафиулланың өлкән хатыны Фатыйма булды да куйды: тирләп-пешеп чәй эчә, үзе туктаусыз нидер сөйли дә сөйли. Габдулла артка чигенде дә кое капкачын шапылдатып ябып куйды. Ул ни капка ягына юнәлергә, ни өйдән чыгучыларны көтәргә белмичә, мунча почмагына елышты да, нигә икәнен үзе дә сизмәстән, әкертен-әкертен генә һәм тын гына, сабыр гына еларга кереште.

Болдырдан Сафиулла килеп чыкты. Бер әрҗә тоткан. Ул кече капканы барып ачты, капка төбен һәм урамны карашы белән барлады да ишегалдына борылды. Һәм ул, Габдулланы күреп, аның ни хәлдә икенлеген ачык тоеп алды.

Ул арада ишектән кулына төенчеген тоткан Фатыйма да күренде.

— Әйдә,— диде ул Сафиулла турысына җиткәч.

— Хәзер. Син бар, атлый тор.

— Бу малай кайда соң? — дип сорады Фатыйма, Габдулланы эзләп, як-якка каранды.

— Монда гына ул.

— Тышка чыгамыни? — дип, Фатыйма иплəп кенә атлап китте.

— Нишләп торасың монда? — дип сорады Сафиулла, малай янына килеп.

— Болай гына,— диде Габдулла, сулкылдавын тыя алмыйча.

— Әллә елыйсың инде шунда? И, юеш борын, юеш борын! Ни булды сиңа?

— Берни булмады ла...

— Әйдә алайса, кузгалыйк.

— Әйдә,— диде Габдулла һәм кинәт Сафиуллага сыенды.

— Җә, җә, борчылма. Бар да әйбәт булыр.

— Борчылмыйм мин.

— Курыкмыйсыңдыр ич?

— Курыкмыйм да. Уйлыйм. Нишләрмен инде, дим. Нигә гел болай йөртәләр мине, дим. Әле анда, әле монда. Әле авылдан авылга, әле каладан калага. Нигә мин бер генә җирдә тормыйм, дим. Нигә бер генә мәдрәсәдә гыйлем алмыйм, дим. Нигә мин гел юлда, дим. Нигә мин... дим...

Мунча почмагындагы куе ботаклы карт миләш агачыннан аларның өстенә саллы гына кар ишелеп төште. Габдулла моңа илтифат итәр дәрәҗәдә түгел иде — күрмәде, сизмәде. Ә Сафиулла әллә күтәлмәгән авырлыктан, әллә якасы астына эләккән карның эрү салкыныннан, әллә малайның бар җанын — үткәнен, хәзергесен, күрәчәген — ачып әйткән рәнҗүле, каргышлы сүзләреннәнме зиһенен җыя алмый торды. Аннары, гаярь җилкенеп, иңеннән карны кагып төшерде: авыр-авыр итеп сулады, әле аяк астына, әле күккә карады. Аның авызы судан чыгарылган балыкныкыдай зур ачылган, салынып төшкән ирене калтырана иде. Ул чыгарга юнәлде, малайның үзенә тын гына, кыймый гына:

— Сафиулла агай...— дип эндәшкәнен ишетмәде әле.

— Сафиулла агай,— диде малай тавышын көчәйтә төшеп һәм, аны кое турысында куып җитеп, сак кына тун җиңен тартып куйды.

— Әү,— диде Сафиулла. Тагын атлап китте, ләкин, коены узып, Габдуллага каршы басып туктады. Алар икесе ике якта калды.

— Сафиулла агай дим...

— Әү, Габдуллаҗан, әү.

— Безнең күрешкәнгә егерме көннән артык бит инде, әме?

— Җегерме ике көн... Өч көн шикелле дә тоелмый үтте дә китте.

— Миңа күбрәк тоелды.

— Күпме?

— Белмим инде.
— Төгәл егерме ике көн дим ич.
— Миңа үз әти-әниләремне белгән вакыт шикелле.
— Син аларны бик кыска арада гына белеп калдың шул.
— Түгел. Озак. Бик озак.
— И бала... Күргән-кичергәннәрең җаныңа сыешмый синең, шуңа озак тоелгандыр ул.
— Минем ул озакны тагын бик озак иттерәсем килә.
— Ничек итеп?
— Кемнәрнедер тагын «әти» дип, «әни» дип дәшеп.
— Алла рәхмәтеннән ташламады ич әле. Әйтерсең. Мәнә Галиәсгар җизнәннәргә илтеп куярмын да — әйтерсең.
Габдулла уйланып, йөзен читкә борды.
— Сафиулла агай...— диде ул, сүзен башлагандагычы сак кына итеп.
— Әү, әү.
— Илтмә син мине бүтән җиргә, Сафиулла агай.
— Илтмичә нишләтәсең белмим шул, улым.
— Мин беләм,— диде малай аның ягына килеп.
— Нәрсәне?
— Син мине анда илтмәсәң нишләсемне.
— Соң? Нишләрсең?
— Син миңа әле генә «улым» дигәнчә, мин дә сиңа «әти» диярмен.
— Миңа?!
— Ие,— диде малай, аңа таба борылып.— Озак диярмен. Бик озак. Бик!
Габдуллага карап-карап торды да, нишләргә, ни дияргә белмичә, җавап эзләгәндәй, Сафиулла кое капкачын ачты, иелеп түбән карады.
— Аларга да диярмен.
— Кемнәргә тагын?! — диде Сафиулла, коедан аерылып.
— Фатыйма белән Җәмилә апайларга. «Әни» диярмен. Үз итәрмен. Бәлки... яратырмын да әле.
Дөрләп янган җан учагының соңгы ялкыннарын, соңгы утлы күмерләрен таптап сүндерергә теләгән шикелле, Сафиулла баскан урынында таптанып алды да, иренен тешләп читкә атлады, бая малай поскан мунча почмагына сыенды һәм бүрәнәгә китереп сукты. Аркасына тагын — бу юлысында түбә кыегыннан — бөгелеп торган мул кар ишелеп төште. Ул, малай алдында тыелырга кирәклеген дә онытып, елый иде инде.
— Нигә елыйсың? — дип сорады малай, аның янына килеп.
— Еламыйм мин... Габдуллаҗан... Үзем еламыйм, җаным елый.
— Ә үзең нишлисең соң?
— Үзем уйлыйм. Нишләрсең инде, дим. Нигә гел шушылай йөртәбез без сине, дим. Авылдан авылга, каладан калага... Нигә сине бер генә җирдә тотарга, бер генә мәдрәсәдә сабак алдырырга җай җук икән, дим. Нигә син... дим...
Сафиулла кинәт борылды да, малай алдына тезләнеп, аны кочып алды.
— Уйлама, Сафиулла агай. Берни уйлама. Алайса, мин сиңа «әти» димәм. Әйдә, илт. Галиәсгар җизниләргә илт. Тик мин бик кыска вакытка да бүтән кешегә «әти» димәм инде.
— Нигә алай... Габдуллаҗан?
— Үз атаң сеңлесе иренә «әти» димиләр.
— Бусы нигә?
— Шәригать кушмый,— диде малай, зурларча, кырыс итеп. Һәм, тирән итеп тын алгач, Сафиулладан аерылды да ачык капкага таба атлап китте.
Авыр йөк тарткан атның башын чайкаганы кебек, Сафиулла үз иңендәге карны, үзенең күз яше белән бергә күңелен тутырган авыр

уйларны да кагып төшерердәй булып, башын әллә чайкап, әллә кая куярга белми айкап алды да малайга иярде. Хәзер инде ул малайны түгел, ә нәни Габдулла дәү Сафиулланы каядыр илтеп куярга алып китте кебек тоелды. Сафиулла кое яныннан узышлый аның капкачын ябып куйды: буласы эш булды, бүтән чарасы калмады. Ул, иелеп, әрҗәне күтәрде.

Капкадан чыккач, малай аңа:

— Әрҗәмне үземә бир,— диде.— Авыр түгел ул. Миңа инде бирни авыр түгел.

— Мә алайсаң,— диде Сафиулла, аңа әрҗәне сузып.— Ие, авыр түгел. Аның каравы... язмышың авыр... Җәле әйтеп бак: безгә кай тарафка барасы?

Габдулла, чаттан борыласына ишарәләп:

— Кайтканда күрсәттең ич,— диде.

— Карале, Габдуллаҗан, анда барганчы бераз гына сөйләшеп алсак ярармы?

— Нигә ярамасын икән, Сафиулла абзый?

— Ирләрчә сөйләшсәк, дигәнием.

— Белмим инде тагын. Мине мулла малае дип, шәкерт дигән булып, гелән күп сөйләштерәләр. Торган авылларда да, Казанда да.

— Анысы... Монда кайтышлый мин дә ким куймадым. Сөйләшергә, сөйләштерергә мин дә оста — Алты-биш Сапый! Җиңелчә кеше мин. Күп сөйләшәм. Һы — «Алты-биш Сапый», диң, ә? Кем беренче шулай дигән, кем таккан, ничек ияреп киткән — Алла белсен!.. Ярар, сүз бу хакта түгел,— дигәч, ул капка төбендәге такта утыргычның карын эшереп төшерде дә, тәмәке янчыгын алып, шунда утырды.— Туңмассыңмы?

— Рәхәт кенә ич әле.

— Утыр алайса,— диде Сафиулла, бераз уйланып торгач, тәмәке янчыгын кире кесәсенә тыгып куйды.

Габдулла, әрҗәсен кочаклап, аның янына утырды.

— Өйрәтә димәссең, җәме?

— Йә.

— Мин, шулай, «җ» дип сөйлим инде. Син, әнә, укыган булгач, бүтәнчә әйтәсең.

— Китапча ул.

— Китапча шул. Ә тормышның сабагы бүтәнчә аның, Габдуллаҗан. Сиңа шуна әйтмәкчием — тормыш сабагын,— дип, Сафиулла тукталып калды.

— Анысын да алмаган түгел инде...

— Ие. Күрмәгәнеңне күргәнсең анысы. Ә күрәселәрең алда әле.

— Син, Сафиулла абзый, әрләмә инде,— диде Габдулла, алда әйтәсенә алдан үзе көлеп.— Син алтыдан бишкә күчмә инде. Нәрсә аны — турысын әйтәм дигәч, әйт.

— Менә маладис, ә? Әйтәм җирле ишеттергәннәрие — син дә сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел икән шул... Хәер, ни әйтмәкчием әле мин?.. Ие... Менә, Габдуллаҗан, сиңа тагын чит-ят бер йортка аяк басарга туры килә инде. Чит-ят йортка гына, ә чит-ят кешеләр тарафына түгел, ие. Анда сине беләләр.

— Мин дә беләм лә инде,— дип уфтанып алды Габдулла.— Кырлай бик ерак калды бит. Кайтып китәм дисәң дә... Әллә ничә көн кирәк...

— Туган җирләр кемгә дә бәһасез кадерле инде ул. Тик нишләмәк кирәк: татар башын язмыш йөртә шул, язмыш... Шуңа күрә торган җир дә ул хәтле ачы тоелмый. Алла җүн кылса, шөкер итәсең... Син бер дә нитмә... бәгыреңне көйдермә. Болай да көйгәндер... Минем кайнага, синең җизнәң бик ипле кеше ул. Синең хакта яхшы хәбәрдар. Ни хәл итәсең: син анда каңгырап җөрисең, ул монда каңгырауда. Быел, җыл башында, алдан кызлары Мәрзия, аннары уллары Гобәйдулла вафат булдылар. Бер атна дигәндә, бер-бер артлы...

— Беләм. Бәдретдин абый сөйләде инде.

— Сине алдыруы да менә шуңа. Бәдретдин абыеңа сине җә бер килгәндә үзең ала кил, диде, җә бер бәрәү белән җибәрергә кушты. Ул «бәрәү» менә мин булып чыктым инде, рәхмәт төшкере! — дип, Сафиулла көлеп куйды.— Әгәр тиз генә ияләшеп китәргә авыр булса, ятсынмассың, үзебезгә килеп-китеп йөрерсең. Габдерәүф янына... Бар күк киңәшем менә шулые, Габдуллаҗан.

— Рәхмәт яусын, Сафиулла абый...

— Әйдә. Фатыйма апаң барып җитте инде. Көтәләрдер.

Алар икәүләп чатка таба атлап киттеләр.

Ул якта су мичкәсе салынган чана тартып узган ат күренде. Ә аларның каршысына, япкан яшел чапанын җил-җил китереп, чаттан кызларга тартым җыйнак кына яшь бер хатын килеп чыкты.

— Нихәлләрегез бар? — дип эндәште ул тыйнак кына. Ә игътибарын читтән үк малайга юнәлтеп якынайды.

— Аллага шөкер. Исән-сау кайтып җиттек, Газизә,— дип, Сафиулла Габдулланы аркасыннан алгарак этәрде.— Күреш, Габдуллаҗан. Бу — апаең Газизә була.

Габдулланың күңеле күтәрелеп китте. Аның көр тавыш белән:

— Таныдым, таныдым! Нихәл, апай? — дигән шат тавышы аңа иелгән һәм кочаклап алган, аркасыннан кагып сөйгән хатынның кочагында күмелеп калды.

— И наным... Үскәнсең, сөбханалла! — диде Газизә, аны үбә-үбә.— Сине соңгы күргәнемә күпме инде... ике ел,— дип, ул еламсырап алды.— Кырлай белән Казандагы туган-тумача ни хәлләрдә калды?

— Шөкер генә, апай, шөкер генә,— дип, малай Газизәнең кочагыннан тарсынып чыкты.— Бик күпләп сәлам әйтергә куштылар.

— И-и, наным...— дип сузды Газизә, аның саен ни елмаерга, ни еларга белмәстән. Шулай да куанычына караганда Габдулла энесенең дә, үзе кебек, чит-ят җирләргә китерелүенә ачынуы басарак төште, елыйсы килә иде.

Сафиулла аның аркасына сак кына кагылып:

— Куанырга кирәк, Газизә сеңел,— дип, юаткан булды, тик үзенең дә күңеле тулып бугай, башкача сүзе булмаганга:— Юл өстендә тормыйк инде,— дип өстәде.

Газизә малайның әрҗәсен үзенә алмакчы иде дә, Габдулла бирмәде, үзе күтәреп китте.

— Авыр түгелме соң? — дип сорады Газизә.

— Юк,— диде Габдулла.— Укырга гына авыр ул.

— Ни соң анда синең?

— Укыган вә укыр сабаклары,— диде Сафиулла.

Утыз адымнар атлагач, асты — таш, өсте агач булган ике катлы йортка килеп җиттеләр. Аның капкасына керер алдыннан малай, артка каерылып, анда-монда караштырып алды. Әйтерсең лә, билгесезлеккә таба тагын бер адым атлар алдыннан, нәрсәнедер барлап каласы килә иде.

Кече капканы ачып, ишегалдына уздылар. Чылбырлап куелган йөнтәс эт тынычсызланып өреп алды, арлы-бирле йөренергә кереште. Анда бишмәт кигән бер ир-ат баягы мичкәле чанага җиккән атны тугарып тора иде.

— Әссәламегаләйкүм, Гыймадетдин,— диде аңа Сафиулла.

— Вәгаләйкүм әссәлам! — дип, әлеге ир эткә кизәнде дә, олылап, Сафиулла белән күреште, аннары Газизәгә дә кул бирде.— Менә, кунак егет тә килеп җиткән икә-ән! — дип сузды ул. Тавышы көр, калын, йөзе елмаюлы иде. Башына сырма бүрек, өстенә кайры тун кигән, аңа ызәр салган.— Габдуллаҗан бит әле? Нихәл соң, Габдуллаҗан?

— Әйбәт әле,— диде малай.

Сафиулла тамагын кырып:

— Кунак булырга — ул өч көнгә төшмәгән лә! — дип елмайды.

— Шулай, Сафиулла абый, шулай. Төкле аягы белән үтсен инде,— дип, Гыймади атны түрдәге корылмаларга таба җитәкләп китте. Баскыч ишегендә алъяпкычлы, почмаклап яулык япкан бер яшь хатын күренеп алды, тик ул, исәнләшеп тормастан:

— Сөенче, сөенче! — дия-дия, баскычтан өскә менеп китте.

Өчәүләп шунда күтәрелгәндә ул хатынның эчтән тагын:

— Сөенче, байбикә! — дип кабатлаганы ишетелде.— Килеп җиттеләр!

Габдулла апасына күтәрелеп карады да:

— Көтәләр икән әле! — дип елмайды.

— Көтми ни! — диде Газизә, куанып.

— Нихәл, Гайниҗамал,— дип, Сафиулла әлеге хатын белән исәнләште дә өйгә узды һәм, ишек чаршавын кайтарып, Габдулла белән Газизәне эчкә уткәреп җибәрде.

Алар ян-якларда, түрдә берничә бүлмә ишекләре күренеп торган алгы бүлмәгә аяк бастылар. Шуннан соң булган хәлләрдә — күрешүләрдә, танышуларда, аңлашуларда, сөйләшүләрдә Габдулла игътибар үзәгендә булып, ул әле куанды, әле уңайсызлану, әле тарсыну, әле ятсыну, әле тагын көр күңеллеләнү хисләре кичерде.

Бу — Габдулланың атасы Мөхәммәтгарифның бертуган сеңлесен (ул да — Газизә атлы) алган, Уральскида уртача саналган сәүдәгәр Галиәсгар Госманов йорты иде.

Алданрак килеп өлгергән Фатыйманың хәбәре белән аларны биредә көтеп торалар иде инде. Ул үзе чишенеп тә куйган. Иң алда, затлы яулыгын төзәткәләп, Галиәсгар байның хатыны Газизә[1] Габдулланың атасының сеңлесе тора. Кичке ашка әзерләнүеме, әзерләнеп бетү вакытымы булганга, өйдәге хатын-кызның кайсысы савыт-саба, табак, чынаяктәлинкә, самавыр, чүлмәк, кайсысы сөлге-тастымал, кайсысы тагын нәрсә тоткан. Галиәсгарның ирдән аерылып кайткан өлкән кызы Зөһрә — озынча буйлы, туры кашлы, нечкә борынлы, тар иренле хатын да шунда: Габдуллага, бүлмәгә яңа килеп кергәннәргә артык исе китмәгән ише, ничектер, өстән, ят итеп караучан. Читтәрәк — йорт хуҗаларының тагын бер кызлары — ул да Фатыйма атлы — бар. Ә Гайниҗамал, кызыксынуын басып, ишек төбеннән узмады әле. Тере хатын булса да, хуҗалар сүзеннән чыгарга күнекмәгән.

Габдулла, килеп керү белән, бүреген салды да менә шундагы җиде хатын-кыз һәм Сафиулла арасында бәләкәй, ят, оялчан, куркынган, рәнҗегән бер малай булып калды.

Ботын чабып, иң әүвәл өлкән Газизә телгә килде:

— И-и!..— дип суызды да, күзенә яшь килеп, аны яулык очы белән сөртеп-сөртеп алды.

Бер кавым ирексез тынлыктан соң кыскача гына, мәгәр тиз-тиз — аннан башлап, моннан очлап дигәндәй — бүлмәдә сүз өстенә сүз, хәл-әхвәл белешү авазлары яңгыраттылар:

— Узыгыз, уз!..

— Нихәлләрегез бар соң?

— Аллага шөкер!

— Мактап йөрисез икән. Нәкъ аш-су өстенә туры килдегез...

— Хәзер, хәзер.

Сафиулла белән Газизә чишенеп, аларга ара-тирә булышкалап тордылар.

Өлкән Газизә, башкалар ишетмәслек итеп, Гайниҗамалга:

— Нәрсә уклау йоткандай торасың инде? Күрмисең мәллә — ишәйдек. Кунак самавырын да куеп җибәр, затлырак чәй әйберләрен чыгар.

---

[1] Ары таба — ике Газизә бергә туры килгән күренешләрдә Өлкән Газизә дип язылыр. Фатыйма да — шулай ук. (Автор искәрмәсе.)

Яңа аш-су ягын да кара! — дияргә онытмады.— Башта Гыймадига төшеп әйтеп мен: бездән бер чирек кымыз кертеп чыксын.

Гайнижамал түбән өйгә төшеп китте дә, бераздан күтәрелеп, аш-су әзерләү бүлмәсенә узды.

— Ничекләр кайтып життегез соң? — дип сорады Өлкән Газизә.

— Бер самавыр екмаенча торып, сөйләп бетермәле түгелләр. Дүрт көн Казан каласында кундык, бер көн — Чистайда, бер көн — Ырымбурда. Тагын әллә ниткән пучты стансыларында, авылларда... Җәмгысе — унсигез көн тоташлай юлда,— диде Өлкән Фатыйма.

— Сату-алулар уң булдымы соң?

— Бик уң, бик уң! Анысын тагын бер самавыр екмаенча торып...

— Синеке шул самавыр төбеннән узмас инде,— диде ана Сафиулла.— Менә кем ләбаса ул «самавыр», менә кем! — дип, ул арттан Габдулланың иненә кулын куйды да алгарак этәрде.

— И-и!..— дип сузды тагын Өлкән Газизә.— Каяле, энем-җанашым! Өс-башыңны сал әле. Нишләп торасың болай монайган шикелле? Зөһрә, Фатыйма! — дип эндәште ул кызларына.— Куегыз нәстәләрегезне. Ниме дип карап торасыз? Өс-башын салдырыгыз, урнаштырыгыз, аягына яңа оекбаш, ката кидерегез...

— Үз кулым да бар ла! — диде Габдулла.— Нигә мине һаман, һаман...

— Нитмәле, Габдуллаҗан...— дип, әйтер сүзен әйтеп бетермәстән, Сафиулла малайның шарфын, биленә салынган чуклы эзәрне, аннары бишмәт төймәләрен чиште.— Куеп тор инде шул әрҗәнне, җә!

Малай әрҗәсен аягы янәшәсенә куйды да әкрен генә, ләкин эчтән янганын сиздереп:

— Мин кайда да ирекле түгел инде,— диде.

Ничектер шундук бердәм төстә, зиратта хәер биргәндәй ымсынышып һәм шуның белән савaплы булырга теләгәндәй, аны чиратлашып чишендереп тә куйдылар.

Өлкән Газизә малайны баштанаяк күздән кичереп чыкты. Кызганып та куйды кебек, ошатмаган да сыман булды. Тик моны һичкемгә сиздермәде. Алай да, аның киемнәрен әйләндергәләп карагач, коштабак тотып чыккан Гайнижамалга:

— Аскы өйгә төшереп куй. Аруларсың,— диде.— Гыймадига житкер: мунчаны карасын, су җылытырга куйсын. Табыннан кузгалганнан соң, мунчалалап коендырып чыгарырсыз.— Аннары ул, малайның күңеле үсеп китсен дипме, әллә үзенең аңа карата илтифатлы булганын һәм буласын белдерәсе килепме: — Әй, канатым! Менә әйбәт. Килеп кергән сәгатең фәрештәләрнең амин дигәненә туры килсәче! Аллаһы Тәгалә җиде оҗмахның ишеген ачып керткәндәй итсен! — дип теләде.

Малайның күзенә нур керде. Тирән итеп тын алды да:

— Рәхмәт, тута. Сүзеңә каршы Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә йортыгызны бәрәкәтле, бәла-казадан имин итсен! — дип, җай гына алгарак узды, иркенәеп, рәхәтләнеп китте.

— Амин! — диештеләр.

Малайның җавабы ян ишекнең ачылган һәм анда чиккән түбәтәй, утыртма якалы яшел күлмәк өстеннән тире тән җылыткычы, аягына читек кигән Галиәсгар Госманов күренгән чакка туры килде. Малайга канәгать икәнлеген, әйткәнен хуплавын белдергән сыман, ул нохтә мыегын сыпырып куйды, тамагын кыр итеп кырып алды.

— Бәрәкалла! Нинди тавыш дисәм, кеше бар икән ләбаса! — дип, ул иң әүвәл Габдуллага ике кулын күрешергә сузды.— Нихәл соң, мосафир мелла кем... Габдуллаҗан? — дип күрешкәч: — Әйдүк, әйдүк, каениш! — дип, аркасыннан кагып, башыннан сыйпап алды. Галиәсгар шулай ук якты чырай, кәр кәеф күрсәтеп, Сафиулла белән дә исәнләште. Аннары соң: — Дога кылыйк! — диде.

Догадан соң Сафиулла:

— Аллаһы Тәгалә сезгә дәүләтегезне киң, бәрәкәтле итсен, кыямәт көнне иманыгызны, йөзегезне нурлы кылсын,— дип, битен сыпырды.

— Амин! — диештеләр.

— Сиңайтәм,— диде Галиәсгар хатынына,— кунакларны бусага төбендә аягөсли тотмыйк алайсаң. Аш-су белән мөшәррәф (кадер-хөрмәтле) булыйк.

— Озаклардыбыздыр,— диде Сафиулла, кыстаткан булып.

Хатыны да:

— Ие шул, ие,— дип, җөпләргә кирәк тапты.— Без табыннан яңа гына куптык. Төн кергәнче мунчада буласыбыз бар әле.

Кече Газизә дә:

— Ирем Габдрахман югалтыр,— дип куйды.

— И-и!.. Бер самавырлык кына урыныгыз калгандыр әле,— диде Өлкән Газизә.

— Ярый соң. Аштан олы булып булмас,— диешеп, җай гына, бербрсенә юл куеп, кул-битләрен юыштыргалап, кызыл башлы сөлгегә сөртенгәч, җанланып, сөйләшә-көлешә дигәндәй, берәм-берәм бүлмәләргә кереп киттеләр.

— Әйдә, монда узыйк,— дип, Галиәсгар Сафиулланы бая үзе чыккан бүлмәгә әйдәде. Хатын-кыз, Габдулланы ияртеп, каршы якка узып бетте. Фәкать ара-тирә Гайнижамал гына күренгәләп, ул әледән-әле ул-бу ризыкны, савыт-сабаны ташыштырып йөренде.

Галиәсгар байның бүлмәсе затлы мебель белән җиһазландырылган, асылмалы лампа белән яктыртылган иде. Иң әүвәл эш өстәле күзгә ташланып тора: анда — кәгазьләр, төрле кенәгәләр өеме, язу-сызу әсбаплары, тәсбих; бизәкле урындык турысындагы диварга кечерәк һәм чын зурлыктагы ике счет элеп куелган. Өстәлнең ике ягында китап тулы пыялалы шкафлар тора. Аяклы зур сәгатьнең ялтыратылган жиз теле һәм авыр герләрендә ут нурлары чагыла. Тирәсенә алты урындык тезелгән самавырлы аш өстәле әзер иде инде.

— Йә, сөйлә,— диде Галиәсгар, һәр икесе бисмилла әйткәннең соңында чынаякларга чәй ясап.

— Адәм сөйләр, тәкъдир көләр инде ул,— диде Сафиулла, ашыкмый гына чәй эчә башлап һәм кинәттән башлаудан читләшебрәк.— Ил белән киселгән бармактан кан чыкмый дигәндәй, түзәсең инде. Акчаң меңлек булса, хәл иминлек анысы.

— Ярар! Тәкә башы күрсәтеп, эт ите саткан ише итмә инде син. Алты-биш Сапый дигән атың Казан белән Җаек арасында койрык болгап чабулап йөри. Телең күздән күләгә алырлык. Ә монда Галиәсгар бай булып, Галиәсгар бай алдында тел яшермәк булып маташасың тагын!..

— Соң, жизни, табынга утырып җитмәстән телгә кан төшереп тә булмый инде ул.

— Алла бәндәсе! Ярар дим бит инде, ә! Һаман үз туксаны туксан... Мә, кымыз totып куй соң,— дип, Галиәсгар агач җамаякларга чүлмәктән кымыз салды.

Сафиулла җамаягын күтәреп:

— Менә бусы бүтәнчә! — дип, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

Эчеп куйгач, тамакларын кырып һәм мыекларын сыпырып алдылар.

— Тешкә килешә бу! — диде Сафиулла.

Галиәсгар тынычланып калды.

— Син, Сафиулла кияү, меңлеген миңа калдыр аның. Иминлегең шунда булыр.

— Менә рәхмәт! Дөнья — фани, хакыйкать — бакый. Дөрес әйтәсең. Сөттә коенгандай була алмасак та, болай, Аллага шөкер, кәсеп бәрәкәтле булды.

— Чана алып кайттыңмы?

— Әлбәттә. Әйтергә оялмыйм дисәң, кушканны кылмыйммы соң! Бик хутлысын, затлысын гына сайлап алдым.

— Ярар. Бәясеннән тормам. Хәер, эштәгесе дә ару гына иде әле. Тик ел башында далага — кыргызларга чыгып керәсем бар. Ә сәүдәдә, үзең беләсең, барлык яраштыра, юклык орыштыра ул.

— Бәясе димәктән... Эсселәтеп җибәрде әле,— дип, Сафиулла камзулын салды да урындык аркасына элеп куйды. Ишек ачылып, Гайнижамал аш, ит кертеп чыкканны көтеп алгач кына, кулын артка каерып, түш кесәсенә үрелде:

— Монда бер Казан кучтәнәче түземсезләнеп тора иде әле — бәләкәй генә «урыс малае»...

Хатын-кызлар утырган бүлмә дә зәвыклы, иплe иде. Төрле җирдә һәм тәрәзә төпләрендә гөлләр күп. Күренекле урынга шулай ук бер өем китап куелган. Алар өстендә ике тәсбих ята. (Бер-очтан шуны да әйтеп китәргә кирәк: һәр бүлмә ишеге турысына нәфис шәмаилләр эленгән һәм аларның кысалары кызыл башлы яисә чиккән сөлгеләр белән бизәлгән иде.) Бу як сәкеле булуы белән аерылып тора, урын-җир, мендәр-түшәккә, намазлыкларга бай.

Табын да шушы бүлмәгә әзерләнгән иде. Габдулла башта, ятсынганга күрә, аягын салындырган килеш сәкенең читенә генә утырган иде. Этәреп тә күтәреп дигәндәй, аны сәкенең түренә үк менгерделәр.

— Йә, Алла белән юллашкан ише, итәгенә карап утырма...

— Без сине монда тиклем читкә кагар өчен чакыртып китерттекмени?— диде Өлкән Газизә.

— Ие! Мулла баласы лабаса син. Үз урыныңны белеп, чамалап кына йөрисе, бел аны! — дип ярарга тырышты Өлкән Фатыйма.

— Карасана! Өебезгә бала яме кереп китте, күз тимәсен, тьфу, тьфу,— диде Өлкән Газизә, аягын бөкләп утырган малайга сокланып.— Аша әйдә, аша. Менә, каз ите.

Катнашуны кирәк һәм урынлы санап, шунда Зөһрә телгә килде:

— Бер дә ялындырып торыр сыман күренми әле,— дип куйды.— Тора-бара кеше өендә идән себерергә тотынмаса ярый тагын.

— Алдыбызда уйнап йөрсә, сабагын укыса, мәрхүм Гобәйдуллабыз кайгысын басмасмы, ходай кушып. Безгә артыгы кирәкми,— диде ана каршы анасы.

Малай, бу сүзләргә әлләни илтифат итмәгәндәй, тыйнак кына утырды-утырды да алдына куйган икмәк телеме белән иткә үрелде:

— Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим!

— Ай, рәхмәт, балам! Өй яктырып киткәндәй булды лабаса,— дип мактады аны Өлкән Газизә.

— Атабыз төсле булырлыгы теленнән саркып тора шул аның,— диде Кече Газизә.

— Бигрәк мәгълүматлы, инсафлы бала икән,— дип җөпләде Өлкән Фатыйма.

— Алай күп белгәч, әйтеп бирсен әле менәтерә: «Бисмилла»ны нигә гел әйтешле?— диде Зөһрә төксе итеп.

Габдулла ялындырып тормады:

— Кем дә кем «Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим»ны даими әйтеп, ашарга утырса, ул кеше белән бергә шәйтан ашый алмас. Шайтан «Бисмилла» әйткән кешеләрдән качар.

— И-и! Алай икән...— дип сузды Өлкән Газизә.

— Каян белеп бетердең моны?— дип сорады Кече Газизә.

— Сәгъди атам Мәңгәр базарыннан бер китап сатып алып биргән иде. Кулдан гына язылган. «Фазаилеш-шөһүр» дип атала. Ул китап тагын болай дип тә әйтә әле: «Кем дә кем «Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим» дип әйтеп йөрсә, ул кеше утта янмас суда батмас, аны елан чакмас вә агулар зарар бирмәс».

— Амин!— дип битен сыпырды Кече Газизә.— Каяле, наным, чәеңне яңартыйм.

— Шулпага да вакыттыр,— дип, Өлкән Газизә малайның алдына чүлмәктән аш салып бирде.— Ул «Бисмилла»ның хикмәте бихисап дип, беркөн ашта да сөйләп утырганнарые аны...

— Бихисап, бихисап! — диде малай.— Аллаһы Тәгалә вә Тәбарәкә әйткән: «Үземнең гыйзззәтем вә олылыгым белән ант итәмен ки: кем дә кем Мөхәммәт өммәтеннән берәү ихлас белән «Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим» дип әйтсә, аның ләүхе-л-мәхфүзенә җиде йөз еллык гыйбадәт савабын язармын»,— дигән.

Кече Фатыйма ашавын да онытып:

— Тагын, тагын,— дип сорады.

— Ярар. Аптыратмагыз. Тынычлап ашасын,— диде Зөһрә.

Күтәргән кашыгы өстеннән малай аңа туп-туры карап:

— Ашаудан вакытында туйсаң, савап була, «Бисмилла»дан тую гөнаһ,— диде. Һәм Кече Фатыйманы җавапсыз калдырмыйча:— «Бисмиллаһи-р-рахмани-рахим» унтугыз хәрефтер. Газап фәрештәләренең дә олылары унтугыздыр. Кем дә кем «Бисмиллаһи-р-рахмани-рахим» дип әйтсә, унтугыз газап фәрештәсеннән котыла, газап кылынмый,— дип өстәде.

Зөһрә малайның үзенә читләтеп әйткән җавабын ошатмады: үзалдына дигәндәй, әмма барчасы да илтифат итәрлек һәм ишетелерлек рәвештә:

— Бу килмешәк өч көн торса, бөтен йортны үзенеке саный башламагае әле,— диде.

— Авызыңнан җил алсын ла, Зөһрә апай,— диде Кече Газизә.— Әйтергә оялмаган кылырга оялмас дигән шикелле, бу ятим баланы кага-нитә калсаң...— дип, ул әйтеп бетерүне уңайсыз күрде.

Малай тыныч калды. Ул инде сүзен һичкемгә юнәлтмәстән:

— Кем дә кем ихлас белән «Бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим» дип әйтсә, Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә шул кешенең шушы егерме дүрт сәгатьтә булган гөнаһларын гафу итә.

— Кайлардан шулай бакыйлык сыман отып бетергән диген, ә?— диде Өлкән Фатыйма, ихлас гаҗәпсенеп.

— Безнекеләр шулай зиһенле булды ич инде, тута,— диде Кече Газизә, тыйнак кына мактанасы килеп.

Өлкән Газизә Габдулланың тәлинкәсенә бүтән ризык салып:

— Менә, бисмиллаһи-р-рахмани-р-рахим, каз аягы белән бүтәкәсеннән пешкән бәлешне ашап кара әле,— диде.

— Урыным калмады ич инде! — диде малай, җайлабрак утырып. Аңа кинәт рәхәт булып китте. Гыйлем иңдереп, савап калды. Үзенең дә чегән арбасыннан төшеп калмаганлыгын ипле төшендерде. Гел кагылырга да сугылырга димәгән!

Йомышы бар кебек, Зөһрә бүлмәдән чыгып китте һәм бу юлы инде фәкать үзалдына, чынлап ышанып, зәһәр итәргә тырышып:

— Ничек карыны ярылмыйдыр,— дип пышылдады. Ни әйткәненә үзе дә өркеп китеп, тиз генә:— Әстәгъфирулла! — дияргә тиеш тапты. Һәм ул көтмәгәндә:— Бисмиллаһи-р-рахмани-рахим,— дигәнен сизми дә калды.

— Тагын бер генә чынаяк чәй эчеп куй әле, наным,— дип, Өлкән Газизә Габдуллага тагын чәй ясап бирде.— Сөтләп, күрәгә белән! Әнә, әфлисуныннан да авыз ит. Җаныңа ял бирсен. Ә тәнеңә ял — мунча булыр. Гыймади абзаң юындырып чыгарыр да йокларга салырбыз. Ә без монда өс-башыңны яңартып көтәрбез...

— Яңартылган инде ул. Кырлайдагы Сәгъди атам белән Зөһрә әнкәм монда чыгып китәр алдыннан гына яңартып озаттылар. Кирәкми миңа берниегез дә!.. Әнә, сабакка йөрергә асылмалы киндер букчалы итсәгез, шул җиткән... Сезнең киндерегез дә юктыр әле. Байлар киндер сукмый ул...

— Җә, җә, киреләнмә,— дип кисәтте аны Өлкән Фатыйма. Ул ни көләргә, ни еларга белми торды.— Табарбыз, тапмыйни! Киндер генә тапмаска без әллә!...

Ишек чыбылдыгын киң ачып һәм бүлмәне чулпы чыңы белән тутырып, юантык кына бер хатын килеп керде. Бала итәкле күлмәген сыпыргалады, яулыгын төзәткәләде. Һәм, әлбәттә, сәке түрендәге чит-ят малайны шәйләми калмады.

— Бәрәкалла! Әллә бу теге — миңа кода тиешле шәкертме? Исән-сау килеп җиткәннәр дә мени, Ходаем? Шулай, тамак тәмугка җиткерер ди ул! Бу теләккә, тугыз корбан суйсаң да, ирештермәс! — диде ул, суык майның кайнар табага салынуы кебек чатыр-чотыр килеп.

Аның соңгы сүзләрен Өлкән Газизә көтеп кенә торган диярсең. Ул Габдулладан да яшереп торырга кирәк санамыйча:

— Кеше суйган мал ашы ашап кына теләккә ирешеп булмый шул! — диде.— Бик ирешер идең дә кана, бәдәл-хаҗга йөреп кенә кияү синең ни теләп тә тулмаган карыныңны тутыра алмас шул... Таныш соң, Габдуллаҗан: бусы — җизнәңнең сеңлесе Газизә җиңгән булыр. Бездә торалар.

— Аллага шөкер! — диде ана Газизә, түшен киереп.— Аштан ашка гына йөргән көннәребез әле! — Аннары ул Габдулладан дорфа сүзе өчен үкенгәнен белдереп:— Син шул Габдуллаҗан мыни инде, бәгырькәччәем? Әйттем исә кайттым, яме, наным, яме? — диде.

Малай сәкедән шуып төшеп, аптыравыннан күрешергә дә оныткан кыяфәттә өч Газизәгә дә карап алганнан соң:

— Монда башың адашырлык икән: берьюлы ике Фатыйма, өч Газизә! — дип көлде.— Әллә дөньяда бүтән исем беткәнме? Бер казанга ике тәкә башы да сыймый, диган булалар тагын!

— Кара, кара,— диде яңа кергән Газизә, аңа күзен тутырып карап һәм чигенә-чигенә.— Бусына тиклем артыксынып өлгергән инде әллә?

Хатын-кыз тынкы гына, ләкин кинәнешеп бердәм көлеп җибәрделәр.

— Гыйлемлегә өстенә җор телле дә икән әле үзе! — дип сөенде Өлкән Фатыйма.

Кече Газизә дә канәгать калып:

— Әйтәм ич, чат әти инде менәтерә! — дип өстәде.

— Башыңа төшсә, сыясың икән аны,— диде яңа кергән Газизә, кинәт мескенәеп калып.— Кырыгына — бер иман, утызына бер комган булса да, сыярга туры килә. Ни хәл итәсең: шундый тозлы су сипкән җир инде бу минем бертуган абыем Галиәсгар йорты. Үзенең генә бәхете булмады бәгырькәччәемнең: бер-бер артлы күз уңында тоткан углы белән кызы дөнья куйсын әле, ә?! Ярар, Габдуллаҗан бәгырькәччәем, шикләнмә: сине дә монда ни торган авылларыңа, ни Казан каласына сыймаган корбан тәкәсе итмәскә генә хәлебездән килер. Алла җүн кылса, ничек тә сыешырбыз,— дип, ул сәке читенә утырды да яулык очын күзенә тидерептидереп алды.

Өлкән Газизәнең дә күңеле тулышты бугай: ул самавыр битенә учын куеп карады да, аның суынып беткәненә тәгаен ышангач, Кече Фатыймага:

— Бар, кызым, Гайни апаңа чыгарып бир әле, яңартсын,— диде.

— Хәзер, әни. Бу самавыр бик тиз кайнап чыга ул. Аннары никтер тиз сүрелә тагын.

— Чат минем төсле инде! — диде яңа кергән Газизә, елмаерга тырышып.— Чат минем төсле...

Ә Габдулла ишек турысындагы шәмаилгә күтәрелеп карады һәм, аның пыяласында Кырлайдагы ата-анасы чагылып киткәндәге шикелле тоелгач, артка чигенде, китап өеменнән берсен алып актарырга, туктаптуктап укырга керешге.

Бу вакыт зал ишеге шәмаиле пыяласында Кече Фатыйманың чагылышы күренеп узды. Ә Галиәсгар Госманов бүлмәсендәге шәмаилдә аның үзенең һәм Сафиулланың тирләп-пешкән йөзләре кайтарыла иде. Зиннәтле идән сәгатенең зур теле салмак кына — көттереп диярлек — чайкала да чайкала. Тик почмактагы зур көзгедә тагын берәү башына

кара хәтфә көләпүш, өстенә казаки кигән, пөхтә генә сакал-мыеклы кеше күренеп тора иде. Күрәсең, ул салкыннан әле яңа гына кереп чишенгән, йөзе кызарынган, кулын әледән-әле мич йөзенә куеп-куеп ала. Күз читләре әллә күләгәдән, әллә сөрмә тартканга каралыбрак, тирәнәебрәк күренә.

Галиәсгар бай аңа кырын гына карап:

— Табынга уз, кияү,— дип эндәште.— Самавыр суынып бетмәгән әле. Хәер, сиңа тансык нәрсә башка инде башкасын...

— Тәкъдирдә шулай язган, күрәсең,— диде Фәтхетдин.— «Әл-әмер әмриллаһ», диләр аны. Ягъни, «әмер иясе Аллаһның әмере» дигәнне аңлата.

— Белмәгән эшең юк, кинәндергән төшең юк дисәм, ничек инде?. Аштан-ашка йөрисең дә, әллә кайда гына төшереп алырга да өлгер үзең. Каян килгән байгура!

— Алай димәле, җизни! Менә тагын җәренгә бәдәл-хаҗ килешеп кайттым. Кәсебе ташкүлчим булса да, тынчу мәдрәсәдән соңра, кеше хаҗы саналса да, бер җир гизеп, әзме-күпме савапка ирешеп кайту булыр. Дөнья гизүнең тәмен беләм мин.

— Анысы җае чыкканда тәмен белүләрне әйләнеп үтмисең инде үзең. Кая, Сафиулла, булмаса, пычак калынлыгы гына Казан күчтәнәчеңне салып бир шуңа. Бездән калмасын.

Өстәл аягы төбендәге яртылаш бушаган «чүлли» шешәсеннән җамаякка эчемлек салып, Сафиулла Фәтхетдингә таба этәреп куйды.

— Гаеп итмә, кияү. Безнең эш бетмәгән әле монда. Бар әнә, өлешеңә разый бул да яңа шәкертең белән күрешеп чык.

— Руза-намаз туклыкта, иман качар юклыкта,— дип, Фәтхетдин салып биргәнгә үрелде.— Иртәгә кайгы китерәсе бүгенге шатлыкның мәгънәсе юк-югын да...— дип, эчкәч һәм нидер кабып куйгач, ул сакалмыегын сыпыргалап чыгып китте.

— Менә шуңа ышанып, үз балаң урынына алдырган, мирасчың булуны күз алдында тоткан баланы сабакка бир инде, ә? — диде Галиәсгар ризасыз кыяфәттә.— Ярар, күз күрер тагын. Аннан башка да хәлфәләр бетмәгән. Бер-ике ел иялә шкәч, Габдуллаҗанны урыс сыйныфына бирми булмас, ахрысы... Булды, бусын калдырып торып, ары таба киттек,— диде ул һәм кулына алган каләмен тел очына тидереп юешләде дә алдындагы кәгазьгә язарга әзерләнде.— Югыйсә, бу минем күршем Ат барышник Бәдри байга бик үк ышанып та бетеп булмый. Товар бәяләре хакында әйткәннәре әллә хак, әллә ничек... Миңа карата зыянлы эш йөртмәсә дә, чабуы астыннан ут йөрткәли, диләр. Әнә, кызыл малчы Ишәк Хәсәнҗанның да көймәсен коры комга утыртып калдырган. Анысы ул Ишәккә типкәләп алуы да ярый-яравын... Бу атнада даладан олау белән Җомагул килеп төшәсе. Атлар куып, куй мае туңдырып. Миннән җурна булыр дип, килешенгән иде. Казаннарда поты күпме тора да, монда күпме — шуның аермасыннан берәр тиен отсаң да, чутлагач, хәйран гына җыела ул... Әйдә, Казанда кибет арышының хакы күпме дә, базарныкының хакы күпме? — дип сорады ул кибеп өлгергән каләмен тагын юешләп.

— Поты кырык җиде тиеннән,— диде Сафиулла алдындагы кәгазенә карап.— Оны — алтмыш бер тиеннән. Суккан арышның Чистайныкы белән аермасы — бер, йә ике тиен. Ырымбурда — поты кырык тугыз тиен.

— Базарда?

— Алтмыш. Мин булган дүрт көн арасында ике тиенгә күтәрелде.

— Солы?

— Яңа сукканы утыз җиде тиеннән бара. Әвеннеке — кырык. Базарда — утыз сигез-утыз тугыз. Шул дүрт көндә өч тиенгә артты.

— Җомагул белән карабодай ярмасы да әзерләп куярга килештем. Анысы күпме тора?

— Поты — бер сум да җегерме. Борайлысы — алтмыш биш тиеннән бер тәңкәгә хәтле.

— Хәзер май бәһасен әйт инде.

Тар гына ачылган ишектә Гыймадиның түбәтәйле башы пәйда булды. Филтәсе басыларак төшкән фонарь тоткан. Бүлдерергә кыймастан, ләкин үзенең барлыгын белдереп, ул учына йөткергәләп алды:

— Һым...

Ишеккә каршы утырганга, Сафиулла аны шәйләде-шәйләвен. Шуңа күрә Галиәсгарның соравына җавабыннан бүленебрәк калды.

— Май дим!

Гыймади тагын:

— Һым!...— дип йөткергән атлы кыланган булды.

— Ни кирәк? — диде Галиәсгар, аңа борылып тормастан.

— Ни ие, бай абзый. Теге шәкертне алмага меңгәнием. Аңарга мунча өлгерттем...

— Мунча! — дип кычкырды аны үртәп Галиәсгар, тирләгән битен сөлге белән сөртә-сөртә.— Мунча менә монда ул, кем... Гыймадетдин. Тегеләр ягында ул, тегеләр!... Майга җиттекме әле? Ие, май хакы күпме?

Сафиулла:

— Сөт мас унбер сум җегерме тиен тора...— дип башлагач, ишекне сак кына ябып, Гыймади әчтәгеләрнең сүзенә колак салып торды.— Идел буеныкы — унөч сум, двәрәнски дигәне — ундүрт, парижские — унбиш.

— Өем сездән читтә, ишегем чыпта,— дип, Гыймади каршы бүлмәгә юнәлде. Андагы ачылыбрак калган ишектән Габдулла тавышы ишетелә һәм үзе дә күренеп тора иде.

— «Иман шарты»н үткәч, «һәфтияк»кә күчтек инде,— дип, ул Фәтхетдингә җавап тота иде.— Аның соңында «Бәдавам»ны көйләдек. Шуннан ары «Кисекбаш»ка кереп калганыек.

— Хуп, хуп,— дип мактады аны Фәтхетдин.

— Болардан ары «Рисаләи Газизә»гә чыктым...

— И-и! — диде Өлкән Газизә, аларга кушылып.— Аның кияү, теге... карасана, оныттым да инде — ие! — «Фәзаилеш-шөкер»...

— ... «ш-шөһүр»,— дип төзәтте аны малай.

— Ие. Менә шул «шөкүр»дән әйтеп биргәннәрен ишетсән дә әле, кияү!

Фәтхетдин канәгать калганлыгын белдереп:

Болай булгач, кода шәкертне үз сыйныфыма алмый булмас,— диде.— Мин сине Мотыйгый хәзрәткә чисти хәлфә булуга җиткереп тоттырам.

— Хәлфә?! — диде Өлкән Газизә, ботын чабып.— Ниткән хәлфә ди ул тагын? Кара бу малны! Ишәйгәннән-ишәя, Аллага шөкер! Иншалла, сәүдәгәр булыр. Ниндие генә әле, әйеме, Габдуллаҗан?

— Җиткереп тоттырам, имеш,— диде Уртанчы Газизә, Фәтхетдинне мыскыллап.— Тоттырыр нәрсәләрең бигрәкләр дә кешнәп тора шул синең!

— Җәгез инде,— дип туктатты аны Кече Газизә.— Шәкерт алдында исәп-хисапларыгызны калдырып торыр идегез инде аны.

Гыймади, ниһаять,— бу юлы кыю рәвештә — бүлмәгә килеп керде.

— Менә кайда икән әле ул! — диде ул, Габдуллага карап.— Килеп җитмәгән көенчә малайдан мулла-сәүдәгәр ясамакчы булып тормасагыз соң... Әйдә, малай, җыен җәтрәк!

Малай Газизә апасына таба елышып, шикләнгән тестә:

— Тагын кая? — дип сорады.

— Мунчагадыр,— диде Кече Газизә аны юатып.

— Имынный! Килгән шәпкә кая булсын ди тагын? — диде Гыймади.— Ниме, бикә, алмашка кигезергә тегесе-бусы әзерләр ич? Сөлгене үзебезнекен куйдым.

Өлкән Газизә залга чыгып, калай бизәкле сандыкларның берсен ачып иелде дә, кием-салым арасыннан малайга ярардай күлмәк-ыштан эзләргә керешге. Элеге дә баягы вафат улыннан калган вак-төяк

булгандыр, күрәсең: соңгы тапкыр үзенә якын исен иснәп калырга теләгәндәй, аларны битенә тидереп-тидереп алгалады.

— Бар,— диде Кече Газизә, малайны алга этәреп.

— Мә, наным. Сау-сәламәт тәнендә туздырырга насыйп итмәде инде үзебезнең улыбызга. Сиңа язган икән,— дип, Өлкән Газизә киемсалымны Габдуллага тоттыргач, Гыймади аны җитәкләп алып чыгып китте. Артта әллә Галиәсгарның, әллә Сафиулланың:

— Куй җоны хакы...— дигәне ишетелеп калды.

Баскыч басмаларыннан төшеп, ишегалды карын шыгырдатып үткәч, мунча алачыгына килеп керделәр. Караңгы иде. Гыймади фонарь филтәсен күтәргәч, яктырып китте, эчтә булган нәрсәләр ачыгаеп калды.

— У-у, сезнең монда-а!— дип сузды малай баш турысындагы колгаларга эленгән каен, имән себеркеләренә күтәрелеп карап.— Кырлай урманы шикелле!

Тышкы киемнәрен салырга керешеп, Гыймади:

— Сездә әзрәк иемени?— дип сорады.

— Бездә җитәрлек итеп кенә бәйлиләр.

— Бездә дә артыгы җук аның.

— Кырлайдагы Сәгъди абзый да шушылай мул әзерли торганые, базарда сәүдә итәргә.

— Мунча себеркесе белән вакланып торырга Галиәсгар җизнәңнең өресе сыек дип белдең мәллә? Җаек байларындыр, казакъ, кыргыз байларындыр шушы себеркеләр белән өтәм инде мин. Пешеп беткәнче чабыналар, малай. Ишегалды себерерлек чыбыгын да калдырмыйлар... Чү, нигә чишенмисең? Шикләнмә, малайларны алай ук каезламыйм мин.

— Оялам мин,— диде малай тыенкы гына.

— Кит әле, булмаганны!— дип, бил тиңентен — шәрә, ә түбәнтен ак ыштаннан калган Гыймади малайның тышкы киемнәрен салдырып ташлады.— Болары җатсын шушында. Иртәнчәк Гайнижамал апаң җуып, киптереп, сырлы бәләк белән язып бирер... Ә боларын эчкә алып кер. Чыгышлый кияргә җылынып торсыннар,— дип, Гыймади фонарен кулына алды.

Пар көдрәләтеп, эчкәре уздылар. Мунча ак, чиста, пөхтә иде. Гыймади тәрәзә пәрдәләрен тартып куйды, фонарьны матчадагы чөйгә элде, себерке пешекләнеп яткан агач тагаракны, комганны ләүкәдән түбән төшерде, шунда ике чүмеч су йөгертте, мич капкачын ачып, ташка да чыжлатып җилпеде.

— Ләүкәгә менеп җат. Бер кавым тирләп ал.

— Эссе,— диде малай ләүкәгә йөзтүбән яткач.

— Булмаенча!.. Сине кем диләр әле?

— Габдуллаҗан...

— Кушаматың җукмыни?

— Булды ди сиңа! Мулла малае ич...

— Ә минем бар. Кырыкмыш Гыймади мин.

— Кырыкмыш тай гына була ул.

— Шул-шул менәтерә! Әллә миңа Алаша Гыймади дияр иеңме?

— Дигәнем юк ич әле. Ярый алайса, мин дә Кырыкмыш Гыймади диярмен.

— Диярмен мин сиңа!— дип көлде Гыймади.— Матри аны!

— Миңа «Апуш» диләр. Син дә шулай диген. Тик үчекләп түгел. Мулла малаен үчекләү — гөнаһ!

— Күптән шулай диләр аны, амакай!— дип, Гыймади пешекләнгән себеркене алып селеккәләде дә, мич авызына чүмечтән тагын су җибәреп, шуның кайнарында себеркесен корылата төшкәч, малайның аркасына тидермичә генә буйдан-буйга җилпеп узды.

— Габдулла эсселеккә чыдамыйча дугадай бөгелеп:

— Уй!— дип куйды.

— Абзарыңа симез куй! — дип көлде Гыймади һәм малайны калерләп, яратып, шуннан үзенә тәм табып, чабындырырга кереште.— Менә бусы әнкәң өчен...

— Уй! — диде малай тагын һәм үзенең: — Җитәр, Кырыкмыш! — дигәнен сизми дә калды.

Гыймади рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

— Ә! Син әле алаймы? Кем Кырыкмыш? Әле бер генә үткән, ә ул инде «кырык» дип мышкылдый!

— Җитәр, Гыймади абзый! Үтерәсең! Арыйсың да...

— Нигә арыйм ди?

— Минем әниләр — өчәү! Әтиләр дә! Бөтенесе өчен дә чабындырсаң, хәлдән таеп бетәрсең...

Гыймади әллә нишләп китте. Хәлсезләнгән кебек, себеркеле кулы түбән салынды. Аннары ул себеркесе белән маңгай тирен сөртеп алды.

— Алай икә-ән... Алайса, Апуш, өч әнкәң өчен менә бер, — дип үткәч, малайны аркасына әйләндереп салды.— Алайса өч атаң өчен менә тагын берне...

Малай карышмый иде инде. Аны пар, эсселек изрәтте, себерке иркәләде. Тәне шуңа тәмам күнекте. Аңа рәхәт иде.

— Ә менә бусы — үзең өчен, Апуш. Күңелең пакъ, жаның иманлы, тәнең сау-сәламәт булсын өчен, киләчәк бичәң чибәр, сөйкемле, балаларың тәүфыйклы булсын өчен!

Шуннан соң Гыймади ишек төбендәге агач кисмәктән чүмеч тутырып су алды да, малайның аркасына — шулай ук буеннан-буена — жилпеп җибәрде. Малай тагын:

— Уй! — дип куйды да исен җыеп торып утырды.— Салкын ич!

— Җылыга — салкын, салкынга җылы килешә ул, Апуш. Йә, төш,— дип, Гыймади комганга таманлап су салырга тотынды.— Булдымы соң?

— Шәп! — диде малай.

— Синеңчә, шәп нинди була инде ул?

— Каян белим?.. Шундый... очасы килгән күк.

— Очсаң, кая китәр иең соң?

— Шунда инде... Кырлайга.

— Шулай. Туйдырган җиргә караганда, тудырган җир тартарак шул... Мәле, себерке иснә. Мәтрүшкәле ул.

Малай утыргычка утырды да себеркене йөзенә каплады. Ул, йөзен аермыйча, тагын:

— Уй! Нинди тәмле! — диде.— Мәтрүшкә сездә дә үсәмени ул?

— Менә инде! Үсмичә ни!.. Татар бар җирдә мәтрүшкә булмый димени? Кәҗә сыртын сарган тигәнәк ише, мәтрүшкәнең орлыгы татар кешесе узган аланнарга уч-уч чәчелеп кала инде ул... Син бар, алачыкта хәл алып кер.

Шәрә килеш караңгы алачыкка чыгып баскач, Габдулла кинәнеп кулын җәеп җибәрде, киерелеп алганда колгадагы себеркеләргә орынды. Алар исә, күңелле генә итеп, кыштырдашып куйдылар. Малай, күзен йомган хәлдә, аларны тагын, тагын кыштырдатырга тотынды, хыялында үзен киң ябалдашлы бер ак каен астында итеп күрде. Агач көчле җилдә тирбәлә, ябалдашы тузгый, гүя очып китәргә җыена иде кебек.

— Җитәр инде, кер! — дигәнен ишеткәч, ул, уйларыннан айнып, эчкә узды.

Гыймади агач тәпәнгә башта — кайнар, аннары таманлый-таманлый салкын су тутырды да колгага эленгән урыннан яңа мунчала үрелеп алды.

— Кызлар чәчемени, ә? — диде ул.— Чаган елгасында үзем чылаткан юкә кабыкларыннан бу. Җәй көне шунда атлар коендырырга җөрербез әле, җәме?.. Каяле, «Гөлҗиһан» сабыны белән гөберләтеп, бер уындырып җибәрим әле үзеңне, Апуш!

— Үзем, үзем! Син аркамны гына у,— дип карышса да, Гыймади малайны көчле кулы белән уртага бастырды да, китәрелгән башын сабынлап югач, буйдан-буйга сабынлы мунчала белән ышкып чыкты, артыннан тәпәндәге су белән юды. Тәпәнне түкте, чайкады, кулына комганны алды.— Кая, коендырыйм инде дә — чыгарбыз.

Малай анын игелегенә тәмам ышанып бетеп, ни әйтсә дә үтәргә әзер иде инде. Комганнан су бетмәс-төкәнмәс булып акты да акты, акты да акты...

— Хәзер сөртеник,— дип, Гыймади колгадан сузылып чиккән сөлге алды, малайны сөртеп чыкты.— Киен, Апуш.

Малай эчке киемнәрен киеп куйды да нишләргә белми басып калды.

— Бар, тышкы киемнәреңне киенә тор. Мин хәзер,— дип, Гыймади комганга тагын су тутырды, малайның чыгып киткәненә ышангач, ыштанын салып, үзе дә коенды, сөртенде...

Кергәндәгечә үк ишегалды карын шыгырдатып, алар баскычтан югары күтәрелделәр. Алар кергәндә хатын-кыз чәйдән торган да савыт-саба җыештырып йөри иде инде. Берара малайга «Мунча сихәтле булсын!» — дип, Гыймадины мактап тордылар.

— Шәкертне кая салабыз соң? — дип сорады Гыймади.

— Әнә, әнә, урын-җире җәелгән дә инде,— дип, Өлкән Фатыйма сандыкларның киңенә ишарәләп күрсәтте.

— Һи! — дип куйды Гыймади, канәгатьсез төстә.— Кунакны шунда кундыралар димени инде аны?

— Алай димәле, Гыймадетдин. Бик җайлы урын ул! Бөтенесе чип-чиста, үтүкләнгән...

— Юк инде. Болай итик әле! — дип, Гыймади Галиәсгар бүлмәсен барып ачты.

Ә анда һаман саныйлар, чутлыйлар, язалар иде әле.

— Ат ите күпмедән? — дип сорады Галиәсгар.

— Бер сум да туксан...

Алар тәмам тирләгән, кызарышып чыкканнар иде инде.

— Бетмәдемени әле, бай абзый? — диде Гыймади һәм аларга һич исе китмәгән кыяфәттә, диванга урын-җир китереп салды, җайлап җәйде дә Габдуллаҗанны ияртеп керде.— Кая! — дип аваз салды ул ишектән күренеп торган хатын-кызга.— Чәй кертегез дә, йокласын әле шушында кинәнеп.

— Безнең эш бетмәгән ич әле, Гыймадетдин! — диде Галиәсгар килештермичә.

— Сезнең бетәрлек тә түгел инде ул.

— Җарар инде алайсаң... Әйдә соң, Сафиулла, залга чыгып дәвам итик булмаса,— дип, Галиәсгар алдындагы кәгазьләрне җыйнады, чутын култык астына кыстырды да, кымыз уртлап алгач, бүлмәдән чыгып китте.

— Гыймадетдин...— диде Сафиулла тын гына һәм, чокырга баягы чүлли шешәсендәге калган нәрсәне салып җибәргәч, ияген какты: тот, янәсе.— Китәсе булыр... Безне онытa күрмә тагын, Габдуллаҗан. Кил, җәме! — дигәч, алар малайны ялгызын гына калдырып, чыгып киттеләр.

Кече Газизә кереп, малайга чәй эчертте, сүзсез генә карап торгач, җайлап яткырды һәм эленгән лампаны сүндерде. Бүлмәдә малайның ачык күзе генә күренеп, сәгать тавышы гына ишетелеп калды.

Юка гына боз парчалары белән бизәлгән ике тәрәзә пыяласы ай нурында көмешләнеп, идәнгә, җиһазларга шуның зәңгәрсу яктысы сузылып яткан да көзгегә — әллә кайларга кереп киткән. Габдуллага йокы урынын җизнәсенең җыйнак эш бүлмәсендәге күн диванга җәеп бирделәр. Урыны йомшак, җылы булса да, анын күзе һаман ачык әле. Салмак кына итеп, сәгать йөри. Менә ул берне сугып куйды. Ничәнченеңдер яртысынадыр инде. Малай ничәнче икәнен белми. Үзен анын булачак

хәлфәсе дип таныштырган, нindидер кода абзый тиешле кеше, күрәсең, тонык кына булып, шуның гырылдавы ишетелә. Ул монарчы белешле булмаган Газизә җиңгәсенең аңадыр инде сукранып эндәшкәнен танып ала: «Сиңайтәм, борылып ят, борылып дим!» Гырылдау тынып кала. Ә кайдадыр ялгыз чикерткәнең тигез, күңелле зыңлавына малай рәхәтләнә үк: чикерткәләр кайда да бер икән.

Идәнгә сузылган яктылык кинәт тәрәзәгә таба шуышкандай була, аннан Габдулланың күңеле аша тышка чыгып китә һәм малайның күз алдында Җаектан Ырымбурга, аннан Чистайга, тагын, Казанны үтеп, Кырлайга тиклеп барып җитә. Ялгыз бүренең моңсу улавы ишетелгәндәй була, бу улау бераздан нindидер бер этнең шат өрүенә әйләнә сыман. Кемдер гөлдерек, тук тавыш белән көлә, нindидер бала авыл йортының ишегалды уртасына баскан килеш сабыр гына елый. Бу ул — Габдулланың үзе инде. Ялгыз берәүнең аяк астында кар шыгырдавын боз астында аккан су челтерәве баса. Әллә кайдагы — бик ерактагы нindидер өй эчендә сәкегә яткан икәүнең сулавына корама юрган тын гына калка да төшә, калка да төшә. Габдулланың иң соңгы ата-анасы Сәгъди белән Зөһрә һәркайсы үзалдына аны — Габдулланы уйлап, аның менә шушылай йомшакта, җылыда ятканын күз алларына китерәләр дә көрсенешәләр бугай... Җил исә, җәяүле буран йөгерә һәм Габдулланы шушы ят өйгә, таныш та, таныш та түгел кешеләр арасына китереп җиткергән очсыз-кырыйсыз юлга әкренләп кар сала, аны күмә, югалта. Габдулла аяк астында каты юл тоймый, әллә кая читкә кереп китә, башта кара ноктага, аннары югарыдагы бер йолдызчыкка әверелеп кала...

Габдулланың, ниһаять, күзе йомылганның соңында кысылып чыккан ике тамчы фирүзә яшьне һичкем күрми инде...

---

Әсәрне журнал өчен Шамил Маннап әзерләде.



**Рафаил**

## Сандугачлар

Сандугачлар көзен җылы якка
Китә микән башка кош кебек?
Кышның чилләсендә кирәк булды —
Былбыл эзлим дөнья бетереп.

Яшәп булмый икән сандугачсыз
Көзләрен дә, карлы кышта да;
Әллә йөрәгемне тапшырыйммы
Көйләтергә берәр остага?

Сандугачлар көзен китә икән,
Безне калдыралар кемнәргә?
Сандугачсыз йөрәк охшагандыр
Тышы салдырылган мендәргә.

Китә микәнни соң сандугачлар?
Бәлки, йөрәкләргә күчәдер?
Йә, тәрәзә төпләренә кунып,
Тамчы гөлләр булып үсәдер.

Китә микәнни соң сандугачлар?
Бишекләргә генә күчәдер,
Гашыйкларның сусау күңеленә
Күктән сөю булып төшәдер.

Сандугачлар сайрый башлыйлардыр,
Кеше күңеленә моң тулгач.
Күңел бакчасында адашкандыр,
Җылы якка китми сандугач.

## Шигырь укыйм

Рифкать Закировка шигырь укыйм,
Папиросын элә авызына,
Аннан папиросын әллә шырпы,
Әллә шигырь белән кабыза.

Минем ярсу төя стенаны,
Дуамаллык бәрә түшәмгә,
Кайчак сабырлыгым идәннәргә
Затлы келәм булып түшәлә.

Тәрәзәне бәреп вата сүзләр,
Саесканга барып кадала,
Яраланып, шул саескан сыман,
Иярә дә китә язларга.

Телем, син дә кунак чакыручы
Саескандай туган иленлә,
Баскак булып килгән килмешәк тел
Гүрдә түгел, түрдә бүген дә.

Рифкать Закировка шигырь укыйм,
Шук сакалы бетә агарып,
Йодрыгымда — тарих, җавап эзлим,
Кемгә кирәмәйләп ямарлык...

Бармак арасыннан кайнап чыга
Кара каннар, ачы күз яше,
Тарихымның хәтта зираты юк,
Китапларда ялган чүпрәсе.

Бармак арасыннан үлек ага,
Тәреләре ага чиркәүнен,
Эчүчелек, фәхишәлек, коллык —
«Изге» мираслары үткәннен.

Мәчетләрен җуйган туган җирем —
Корымлы мич — урыс мунчасы,
Күпме татар — безгә кафтан теккән
Тегү машинасы сосасы.

Ләббәйкә, дип тора күпме куштан
Халкыбызның тамырын кискәндә,
Сатлык җанга сынык-санык кала,
Акмаса да тама кесәгә.

Рифкать Закировка шигырь укыйм,
Шигырь микән, кара кан микән:
Тарих кыйбласыннан умырылган,
Телен өзеп алган чаң микән?

## Дөньяны кочам

Мин дөньяны кочам. Һималае
Кулларыма коя ак карын,
Һималайның чыңлы кыясына
Бәйләп куйдым шигырь тулпарын.
Мариан иңкүлеге төпләреннән
Алып менеп энҗе бөртеген,
Зөһрә кызның калфагына тездем,
Әйтте: «Төсең итеп йөртермен».
Сөйләп тормыйм сезгә Зөһрә белән
Булган гыйшык-гыйшрәт турында,
Тиешсезне сөйләп йөргәннәрне
Җир күп йотты тигез урында.
Мин дөньяны кочам, урманнары
Әти яңагыдай тырныйдыр,
Мин бит әтиемне хәтерләмим,
Миңа болай әйтеп булмыйдыр.
Мин дөньяны кочам. Океаннары
Кысылып-кысылып куя йөрәк күк.
Җир шары да сулый, яралана —
Кеше кебек икән, кирәк бит.
Мин дөньяны алам кочагыма,
Кемнәр белер аның кадерен,
Иркәләүгә беркем чыдый алмый,
Сулык-сулык елый, бәгырем.

## Белә торып

Кулга каләм алдым. Белә торып
Ул-бу булса башның очканын,
Тарихыбыз буе халык өчен
Шагыйрьләрнең каннар косканын.
Төрмәләрнең мәрхәмәтле бозын
Ялап, йөрәкләрне дәвалап,
Күпме хаклык, ак маңгаен ярган
Төрмә стенасын яралап.
Кулга каләм алдым. Белә торып
Кыска гомер сайлыйм үземә,
Сизәм урмандагы һәрбер төпнең
Килеп бәреләсен тезәмә.
Терсәгемне тетеп ташлаячак
Һәлакәтнең тимер өеме,
Тарих хәрабәсе арасыннан,
(Исән пыяланы эзләгәндә)
Мин эзләрмен Болгар-өемне.
Кулга каләм алдым. Тамак ягы
Такыр басу булыр элгәре,
Нихәл итим: бу фаҗигам минем
Һәм бәхетнең ходай биргәне.
Кулга каләм алдым. Белә торып
Һәр адымда хәвеф көткәнен,
Белеп шагыйрьләрнең бакыйлыгын,
Шагыйрьләрсез дөнья беткәнен.

## Булмады

*Яшьлеге сугыш чорына туры килгән апа һәм абыйларга.*

Янып көл булырлык сөя алмадык...
Йә кием, йә ашау җитмәде,
Көл буласы килде, чалбарымның
Ямаулыгы рөхсәт итмәде.

Янып көл булырлык сөя алмадык...
Кайчак учак булып янсак та,
Көл буласы килде, өзеләм дип
Тешен шыгырдатты чабата.

Сөя алмадык, табындагы ризык
Гәүдә йөртерлек тә булмады.
Көл буласы килде, эчебездә
Көтү-көтү бүре улады.

Янып көл булырлык сөя алмадык...
Бит йөрәктә теләк бар иде,
Йөрәкләргә сугыш камытының
Корыч кочагында тар иде.

Көл буласы килде, әтиләрнең
Үлемнәре керде арага,
Чирәм өзгәч мәтәлепләр киткән
Бәбкә сыман чыктык язларга.

Янып көл булырлык сөя алмадык...
Кайчак көч булмады еларлык,
Гомеребезне язмыш аягына
Якты ыштыр итеп урадык.

Ә үзебез чынлап сөя алмадык,
Сыйпамады баштан беркем дә.
Көл буласы килде, яшьлегебез
Калды фаҗигалэр иркендә.

Янып көл булырлык сөя алмадык,
Көчебез юк иде ул кадәр,
Хыялдагы ипи телемennән
Кайтышрак иде җилкәләр.

## Мең ел

Сырхауларга сабыштырдың инде,
Чамасы юк яну-көюемнең;
Кыйблалары бар да табынырга,
Чикләре юк минем сөюемнең.

Очрашканга мең ел вакыт үтте,
Өч гасыр бар әле җомгага,
Уйнап әйтмим, чынлап шулай икән,
Сөю офыкларсыз булганга.

Хат-хәбәр юк, телефон да «үлгән»,
Ныграк яратсын дип үртәвең,
Юк, белмисең, ахры, минем сине
Сөю офыкларсыз икәнен.

Җанның канатлары, каерылып,
Сәгать телләренә бәйләнгән,
Белдем инде: синең белән яшәү —
Офыкларсыз гына бәйрәмнәр.

Озак карап торам бер ноктага,
Тормыш нокталарга әйләнгән;
Сөюләрем офыкларсыз калды
Сиңа гашыйк булган җәйләрдән.

---

*Котлыйбыз!*

## *Әнәс Галиевкә 75 яшь*

Татар язучыларының язмышы һәрвакыт халык язмышы белән бергә булды. Бу хәл Алмания белән булган соңгы сугышта аеруча калку күренде. Татар язучылары фронтның алгы сызыгында корал белән дә, каләмнәре белән дә фашист илбасарларына каршы аяусыз сугыштылар, бик күбесе яу кырында газиз гомерләрен бирделәр. Кайберләренә җиңү шатлыгын күрү, туган илгә әйләнеп кайту да насыйп булды. Алар арасында Әнәс Галиев тә бар иде. Ләкин аның бу вакытларда сөенечләреннән көенечләре күбрәк булгандыр шул. Чөнки сугышның беренче көннәреннән үк эченә барып кергән Әнәс Галиев 1942 елның сентябрендә чолганышта кала һәм яраланган хәлдә дошман кулына эләгә. Яшь язучы шуннан соң 1945 елның апреленә кадәр әсирлекнең бөтен кимсетүле газапларын кичерә.

Алтмышынчы еллардан башлап Әнәс Галиев нигездә проза жанрында иҗат итә, үз язмышында күргән-кичергәннәрен нигез итеп алып, шактый хикәяләр, «Йолдызлар шаһит», «Намус кушканча», «Һәр солдатның үз язмышы» һ. б. повестьларын яза. Укучыларыбыз хәтерлидер, «Һәр солдатның үз язмышы» дигән ике кисәктән торган документаль бу повесть «Казан утлары»ның 1991 елгы 5 һәм 1994 елгы 7—8 саннарында басылып чыкты.

Инде Әнәс Касыйм улы Галиевнең гомер чишмәсе кайсы төбәктән башланганын да әйтеп китик. Ул 1920 елның 3 апрелендә Татарстанның Арча районы Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң, Казан финанс-экономика техникумында белем алган, берникадәр вакыт шушы һөнәре буенча эшләгән. Аннары — сугыш... Әсирлек газаплары...

Нинди кыен шартларда да чын Кеше булып кала алган, Ходай биргән талантын халкыбызга хезмәт итүгә багышлаган, әле хәзер дә җиң сызганып иҗат итүче каләмдәшебезне олуг юбилее белән ихлас котлыйбыз, сәламәтлек, озын гомер, яңа иҗат сөенечләре телибез.

**Татарстан Язучылар берлеге идарәсе,**
**«Казан утлары» журналы редакциясе коллективы.**
**1995, апрель.**



**Диңгездәй олы татар шигърияте яңа чишмәләр исәбенә гел тулыланып, яңарып, сафланып тора. Үзенә генә хас аһәңнәре, кабатланмас моңнары белән аңа яңа исемнәр килеп кушыла. Галим Әсән — әнә шундый авторларның берсе. Аның шигырьләр бәйләмен мин үземчә бер ачыш кебек кабул иттем.**

**...Бәйләшләр куйыймны кулны —**
**Гел каләм сорап тора...**

**Шигырьләреннән күренгәнчә, аны тынгысыз уйлары, дөньяга, кешеләргә, сөйгән ярга карата тирән мәхәббәте каләмгә үрелергә мәҗбүр итә. Каләм исә, шагыйрьнең эчке халәтен, кичерешләрен аңлап, аларны шигырь рәвешендә дөньяга түгә...**

**Галим Әсәннең фәлсәфи шигырьләре дә, мәхәббәт лирикасы да авторның инде шагыйрь буларак өлгереп житүе турында сөйли. Ул аларны уйлап чыгарып кына түгел, бәлки тормыштан чумырып алып, жаны аша үткәреп яза.**

**Галим Әсән... Шигъриятгә яңа исем. Әмма әдәбиятка аның бүген генә килүе түгел. Шаехзадә Бабич иҗаты буенча зур эзләнүләр алып барган галим, повесть һәм хикәяләре белән танылган прозаик, каләмдәшләре иҗатына объектив бәя биргән тәнкыйтьче Галимҗан Гыйльманов ул. Аңа шигърияттә дә хәерле юл телик.**

**Харрас ӘЮП**

# Галим Әсән

* * *

Бала чакта елгыр тулпарларның
Ялларына үстек уралып.
Дәртле яшьлек җилләр булып исте,
Яллар кебек киттек таралып.

Юллар дигән тулпар атлар безне
Язмыш буйлап алып киттеләр.
Яллар кисте кулны, ә егылсак...
Ә егылсак — атлар типтеләр!..

Юллар арды, еллар арды бездән,
Йөгән салдык тулпар атларга.

Дәрьяларга төшеп исән калдык,
Дөрли-дөрли яндык утларда...

Хыялларның очы — офыкларда,
Атлар янып калды, йөрәкләр...
Һаман бер төш: и үскәннәр, имеш,
Әнкәй буе калган тирәкләр!..

Егәрлек тә инде чамалырак,
Әткәйләр дә юк шул якларлык...
Дәртле яшьлегемнән килгән юлдан
Кабат кайтыр идем — атлар юк...

## Суык

Шулкадәр суык!..
Түзмичә
Яфрак кычкырыр кук...
Сөясе иде!
Бу көздә
Гомерем кыскарыр кук...

## Диңгездә

О, Диңгез!
Олы Диңгез, син —
Иң гүзәл дөнья икән!
Ул горурлык, ул җегәрлек!
Нык синең кыя-җилкәң!..

Әй, Диңгез,
Син очсыз-кырыйсыз,
Гүя, туган як далам...
Икегездә дә ак дулкын,
Икегездә дә калам!

И, Диңгез...
Кичер, даламның
Моңы китми күңелдән...
Нишлим, нишлим,— йөрәгемә
Кылган чыгы түгелгән...

## Бармы?

Тамакларда төер булып калган
Көйләре бар татар халкының.
«Туган теле», «Карурман»ы яши,
Гамен җыеп, күңел ялкынын —
Күпне күргән татар халкының...

Күнелләрдә газап булып калган
Тукае бер татар халкының;
Тормышына бар кайгысын җыйган,
Үпкәсенә барлык салкынын,
Тукае бар татар халкының...

Бу газапны иман итеп саклар
Күңеле саумы татар халкының?
«Туган тел»не, «Әллүки»не сузар
Моңы бармы татар халкының?
Күңеле саумы татар халкының?..

**Уйлану**

Туу — очраклылык!
Кем генә
Үлчәгән табигать елгасын?!
Очраклы туып та, яшәвең,
Үлемең очраклы булмасын!...

* * *

Урамнарда әле май биюе,
Урманнарга инде гөл кергән...
Карашларда бөреләнә генә,
Җанда инде сөю өлгергән!

* * *

Бүген синдә сер бар: җаның —
Ярым ачылган капка.
Кертмисең... Үткәннәреңне
Төбенә куеп сакка...

* * *

Кайчан гына әле таш идем мин.
Кышка кердем — карга әвереләдем.
Җыр башладың — гөлдәй чәчәк аттым,
Көлдең — сөйгән ярга әвереләдем...

* * *

Нидер үлә миндә, нидер туа,
Көн саен мин үлеп терелләм.
Үлгән саен дөнья дөртләп китә,
Ә бит җирдә мин тик бер үләм...

* * *

«Җаның бармы синең,
чыгар идең
Хет бер ярсып, чәчрәп!» димәгез.
Авылымның соңгы аты дулый,—
Ул минем җан — аңа тимәгез!..

* * *

Кара чаршау булып баскан хәтер,
Барган юлны ябарга тора,
Күңел исә аның җиленнән дә
Чалкан төшеп аварга тора...

* * *

Дөм караңгы!..
Тик барыбер
Күңелемә ут алмыйм...
Мин берәүне бөтенләйгә
Онытырга дим — онталмыйм...

* * *

Синнән көтмим сөю догалары,
Синнән көтмим назлау, юату.
Бар гомерем минем — сине эзләү,
Бар гомерем — сине югалту...

## Диңгез ярында

Диңгез суы — кеше түккән күз яшеме?
Уйга батып ята идем мин-нарасый,
Дертләп киттем: яр буенда чуар ташлар —
Бабамнарның төшеп калган күз карасы!..

## Тукай кабрендә

Менә тагын сиңа килдем әле,
Йомыш белән түгел, кунак булып.
Бар хисләрем ташып чыкты, гүя
Ярларыннан чыкты Болак тулып...

## Гомерем

Бар гомерем янып ята
Тимерче учагында:
Алсу күмерләр — түшәгем,
Кыскычлар — кочагында...

Янагымда — кызган чүкеч,
Күзгә керә ут теле:
Миннән — Тормыш станында
Айбалта йә ук телә...

Йә хәнҗәр әвәли ул, йә
Мылтык көпшәсе итә.
Тагын учакка ата да
Бөгелеп килгәнне көтә!..

Миннән кылыч түгел, беләм,
Сабан яхшырак чыга.
Һаман әнә корал сорый,
Сорый — заман карчыгы!

Ул чүки, чүки... яньчелгән
Чүкечен алыштыра.
Бар җиһанны шатландырып,
Чыныккан тавыш тора.

...Бар гомерем ята шулай
Тимерче учагында...
Әрнүле төш: мин бер сабан
Кара җир кочагында...

# ШИГЪРИЯТ



## Камил Сәгадәт

### Нигез

Күмерләрнең чем-дөм каралары,
Таралганнар нигез ташлары...
Түзсә түзә бит ул ир йөрәге,
Күрсә — күрә ир-ат башлары.
Кош оясын тилгән туздырганмы?
Давыл-афәт моннан узганмы?
Еллар аша өелеп җыелган да,
Хәтер бураннары тузганмы?
Кемгә кирәк булган бу нигезнең
Рухын сынау, җанын яралау?
Кемнәр безне таралудан тыяр,
Җан пакьлеген саклар, аралар?
Кая кайтып баш иярбез хәзер
Бик әрнегән чакта җаныбыз?
Бу нигезгә тамган күз яшебез,
Бу нигездә — кендек каныбыз.
Өзелмәсен туган якка сукмак
Таралмасын нигез ташлары!
Чыдый алмас моңа ир йөрәге,
Түзә алмас ир-ат башлары.
Таралмасын нигез ташлары...

* * *

Маңгайларга куна тора сырлар,
Җыерчыктан кала яңа эз.

---

Камил СӘГАДӘТ (Сәгъдәтшин) — 1952 елда туган, журналист; шигырьләре көндәлек матбугатта күренеп килә. Журналыбызда беренче кабат басыла.

Әле генә килгән идегез бит,
Нигә китү якта күзегез?

Тормыш сынаулары шушыдыр ла,
Җил-давылы, тайгак юллары...
Үзгәртүе кыен икән, әгәр
Кысып алса язмыш кулларны.

Гөрләвеккә кунган күбәләктәй,
Бөтереп алгач язмыш, ни чара.
Асыл түгел, мескен дөньясында
Ни үзгәртә кеше, бичара?!

Көрәшләрдән — мәгънә, максат алып,
Яшәүләр шул сирәк эләгә.
Тотам диеп үрелгәндә генә
Һаман кача бәхет-күләгә.

Күпме еллар үтте, нидер көтеп,
Язмыш-атта чаптык җилдереп.
Ярты гомер узды — нидер төзеп,
Ә яртысы — шуны җимереп.

Маңгайларга куна тора сырлар,
Җыерчыклар эзли яңа эз.
Килгән генә идек түгелме соң?
Китү якта инде күзебез...

* * *

Йөрәгемнең юлда арып-талып,
Егылуым болай беренче.
Син бит — Кояш!
Болыт арасыннан
Тик бер генә кабат күренче:
Елмаюың — миңа сихәт бирер,
Елмаюың — җанга сөенче.

Туң күңелнең бозлы сөңгеләре
Бер эрерләр әле, эрерләр.
Төн йокымны алган серле төшләр
Бер заманны сиңа керерләр.
Төштә генә түгел, өнеңдә дә
Күңелеңне назлап йөрерләр.

Горурлыкта шактый алдырсак та,
Алҗуларым болай — беренче.
Син бит — Кояш!
Болыт арасыннан
Тик бер генә тагын күренче.
Яратуда булмый җиңелүче,
Яратуда булмый җиңүче.

* * *

Үкенәсеңме?
Мин үкенмим,
Йолдыздай атылганга.
Буй җитмәс чәчәкләргә дә
Ымсынып тартылганга.
Ратканыма үкенмим,
Әрнимен бүтәненә:
Абындым... киләчәгенә,
Абындым... үткәненә.
Үкенәмен хисләреңнең
Кадерен белмәгәнгә.
Сөю абынасы җиргә
Юрганнар җәймәгәнгә.
Ратканыма үкенмим,
Әрнимен бүтәненә:
Абындык бугай икәүләп
Кемнеңдер киләчәгенә,
Кемнеңдер үткәненә.

* * *

Атылды йолдыз. Күңелдә
Эзе калды моң булып.
«Соңардым», дип сулкылдады
Йөрәгемнең бар кылы.
Ни җитми соңгы сулышта
Йолдыздай атылырга?
Соңардым яшәп калырга,
Соңардым яратырга.
Соңардым — аһ, үкенечле,—
Күктән үрнәк алырга!
Көч җитми эзсез калырга,
Көч җитми югалырга...
Атылды йолдыз. Күңелдә
Эзе калды моң булып.
«Соңардым»,— дип сулкылдады
Йөрәгемнең бар кылы.

## Җәйге иртәдә

Иртәнге чык үләннәрнең
Битләрен юа.
Саф һавадан яшәү дәрте
Саркылып тора.
Томан баскан яр өсләрен,
Гүя ак җәймә.
Таңнары да тоташ хыял
Кояшлы җәйдә.

Чык кырларга. Табигатьнең
Гүзәл чоры бу.
Балачакның хыялларда
Йөзәр чоры бу.
Томан яткан болыннарда
Чык суы коеп,
Йөрисе бар балачакның
Рәхәтен тоеп.

**Булат Солтанбәк**

# СТАЛИННЫҢ БАКУДАГЫ ДУСТЫ



Сталинның шәхси архивында беренче карашка гаҗәп тоелучы документ бар. Ул юлбашчының революциягә чаклы биографиясенең серле һәм аулак почмаклары караңгылыгына яктылык сирпеп җибәрүе белән игътибарга лаек. Сүз юлбашчының яман-яшерен эшләрдә катнашуы һәм үз якыннары арасыннан куркыныч шаһит булуы ихтимал кешеләрдән үч алуы турында бармый. Бу тема мавыктыргыч, әлбәттә, һәм хәзер андый хәлләр укучыларга коточкыч фильмнардагыча сурәтләп җиткерелә. Ләкин әлеге вакыйгаларның чынбарлыкка ни дәрәҗәдә туры килүе мәсьәләсе дә бар бит әле. Хәер, юлбашчының холкы, шуңа охшаш хәлләр булырга мөмкин, дип фаразларга нигез бирә. Әмма нәкъ менә — мөмкин! Ә бу очракта сүз документта раслануы вакыйга турында бара. Әйе, сөйләнәчәк хәлләрдә геройларның серле рәвештә котылып калуы булыр. Әмма төп хикмәт монда түгел.

Сталин тормышының «Баку чоры»нда, гәрчә ул җентекле үк өйрәнелгән булса да, чишелмәгән табышмаклар хәтсез. Болар — Вышинский белән аралаша башлау, Иран сугыш чукмарлары белән очрашулар һәм башкалар[1]. Сүз җаеннан, татар большевигы белән беренче һәм бердәнбер очрашуның да Бакуда булуын әйтик. Бу хәлне революциядән соң Сталин язма рәвештә раслый[2]. Түбәндә без тикшерәчәк документ та шул чорга карый. Ул 1923 елның 16 сентябрендә язылган, машинкада ике бит. РКП(б) Үзәк Комитеты Генераль секретаре менә нәрсәләр бәян итә.

Гәрчә мондый документлар өчен хас булмаса да, аңа исем куелган: «Рәсулзадәнең реакцион брошюрасы уңаеннан Мусабәков, Мирзоян, Ахундов, Киров, Орахелашвили иптәшләргә минем киңәшем». Киров фамилиясеннән башкалары бүгенге укучыларга таныш булмавы да мөмкин, шуңа күрә бу кешеләр турында кыскача әйтергә тиешбез. Г. Мусабәков — Әзәрбайҗан совнаркомы рәисе, М. Орахелашвили — Кавказ арты федерациясе совнаркомы рәисе, Л. Мирзоян — Әрмәнстан компартиясе Үзәк Комитеты рәисе, Р. Ахундов — Әзәрбайҗан Үзәк Башкарма Комитеты рәисе. Ә Киров Әзәрбайҗан компартиясе ҮКы секретаре була. Арадан икесе — Киров һәм Орахелашвили — РКП(б) ҮКы әгъзалары. Югарыда телгә алынучыларның берсе дә өлкән яшькә җитми, 1934—1938 елларда юк ителәләр. Документ исемендә аталган кешеләр Мәскәүгә ҮК Пленумына килгән булганнар, күрәсең. Пленум 20 сентябрьгә билгеләнә, ләкин ул 23 сентябрьгә кичектерелә. Һәм, ниһаять, документ исемендә әйтелгән соңгы ке-

ше — Мәмәд-Әмин Рәсүлзадә, демократик Әзәрбайҗанның беренче Президенты. Китабы, реакцион брошюра, дип аталган бу кеше ул чакта елдан артык инде Төркиядә эмиграциядә була.

Әлеге брошюра күптән түгел генә СССРны оештыручылар булган төп Кавказ республикалары җитәкчеләренә пунктлап күрсәтмә бирергә Генераль секретарьны ни өчен мәҗбүр иткән соң? Сүз шул ук 1923 елда Истанбулда төрек телендә чыккан «Әзәрбайҗан җөмһүрияте» исемле китапчык турында бара. Рәсүлзадә анда бөек державаларның сүз куешуы нәтиҗәсендә җимерелгән бу дәүләтнең драматик тарихын хискә бирелеп, әмма дөрес итеп сурәтли. Әзәрбайҗан, мөселман регионнары арасында, Исламга нигезләп, югары демократик дәүләт төзүдә беренче булып уңышлы омтылыш ясый. Идел-Урал, Вәлидовның Башкортостан, Букейхановның Алаш-Орда республикалары халыклар күңелендә дәүләт структурасына үзенә күрә әзерлек сыйфатында гына калса, Әзәрбайҗан ике ел чамасы суверен дәүләт була, башка илләр белән тулы масштаблы дипломатик һәм икътисади мөнәсәбәттә яши. Аның Президенты Рәсүлзадә 1920 елда хөкүмәт сараеннан соңгы кеше булып, җөмһүрият байрагын тәненә яшереп урап чыга, байракны — дәүләт символын Бакуны «азат иткән» Кызыл Армия ганимәтенә әйләнүдән саклап кала...

Моңа чаклы ниләр булган иде соң?

Мәмәд-Әмин Рәсүлзадәнең (ул 1884 елда Бакуда туа) тормыш юлы бу төбәктәге зыялы мөселман гаиләләре балаларыныкына охшаш башлана. Аларга Европа мәдәнияте белән кызыксыну, мөселман кадимчелегеннән читләшү, «ширбәт ае»н кичерүче социализм идеяләре белән танышу һәм шул идеяләрнең җәмгыятьтәге кыен мәсьәләләрне чишү вәгъдәсенә ышану хас. Бакуның һәм аның тирәсендәге төбәкләрнең Россиядә промышленностьның куәтле үсеш юлына баскан беренче мөселман үзәге булуын да онытмыйк. XIX гасыр ахырындагы нефть ыгы-зыгысы феодаль дәүләтнең күптән түгел генә ярлы булган төбәген Россиянең үзенә күрә «алтын базы»на әверелдерә. Бу хәл йокымсыраган провинциянең кичәге кешеләрен промышленность үсешенең ялкынлы учагына алып керә. Бер якта сарай һәм нефть хуҗалары байлыгы, икенче тарафта нефть чыгаруда тәүлегенә унике-ундүрт сәгать эшләп интегүчеләрнең хәерчелеге сыйнфый көрәш идеяләре чәчү өчен уңдырышлы туфрак була. Моңа Бакуның Россиядәге башка губерналарның күпләгән вәкилләренең, шул исәптән Идел буеннан «акча сугарга» килүчеләрнең (аларның күбесе монда төпләнеп тә кала) туплану урыны булуын да өстәргә кирәк. Шушы хәлләр төбәкнең иҗтимагый-сәяси тормышын тиз үстерүгә һәм халыкның сәяси карашын нык чуарландыруга — монархистик һәм феодаль-патерналистик караштан башлап социалистик фикерләүгә тикле — китерә.

Егерменче гасыр башында ук Рәсүлзадә социалистик мәгънәдәге публицист булып таныла. Әзәрбайҗанда социаль-демократик хәрәкәтне башлаган, күп кенә большевистик лидерларга старт мәйданчыгы булган «һиммәт» оешмасын төзүчеләрнең берсе дә ул — Рәсүлзадә. Шул ук вакытта Нариман Нариманов, Мәҗид Әфәндиев, Мешади Азизбәков, Әсәдулла Ахундов һәм башкалар аның белән кулга-кул тотынышып көрәшәләр. Соңыннан бу шәхесләр «халык бәхете өчен» бөек көрәшчеләр исемлегенә керәләр, аларның истәлеге шәһәр, промышленность предприятиеләре, мәдәният учреждениеләре исемнәрендә мәңгеләштерелә, алар турында поэма-романнар языла. Бакуның шул чордагы сәяси офыгында, һичшиксез, иң зур һәм иң талантлы Рәсүлзадәнең язмышы исә бөтән тарафка борыла.

Ул, большевистик идеяләр белән вакытлыча мавыгуын ташлап, булачак җәмгыятьнең уртачыл-милли үрнәген яклауга күчә бара. Бу җәмгыятьне Рәсүлзадә Ислам гореф-гадәтләре белән катнаш асыл затлы җөмһүрият төсендә күз алдына китерә. Россия империясендә Әзәрбайҗанның тоткан урыны мәсьәләсе аңа әле бик аңлаешлы түгел, ул, күрәсең, мәдәни-милли автономия турында фикер йөрткәндер. Нәкъ шул чакта Рәсүлзадә Каспий буенда яшәүче, Кавказ артының сәяси күгендә «балкый башлаган йолдыз» — Иосиф Джугашвили-Сталин белән аралаша. Аларның дусларча мөнәсәбәтләре турында күп төрле юрамалар бар. 1956 елдан соң болар аеруча ишәйде. Язучы Манаф Сөләйманов китабы — мондый мәгълүматларның тулырак чыганагы. Анда язылганча, Рәсүлзадә Сталинны кулга алынудан берничә тапкыр коткара. Бәлки, болар «бөек юлбашчы»ның тормышын саклап калу да булгандыр[3]. Кайбер вакыйгаларны гына мисалга китерик.

Жандармнардан саклап, Рәсулзадә Сталинны әтисе Әликбәр муллалык иткән мәчет мөнбәрендә ике атна яшереп яшәтә, булачак юлбашчы мулла

Әликбәр дачасында да ике ай чамасы качып ята[4]. 1923 елгы документка нигезләнеп фикер йөрткәндә (без аңа түбәндә тулырак тукталырбыз), Сталин «реакцион брошюра» авторының сәяси биографиясен, чыннан да, яхшы белгән. Аларны сәяси эшләр генә түгел, ә бүтән хәлләр дә берләштергән, күрәсең.

Рәсүлзадәнең 1917 елга чаклы иҗтимагый-сәяси биографиясе җентекле үк билгеле. Мәгълүм булганнарга бер нәрсәне генә өстик. Рәсүлзадә Бакудагы рус телле басмаларда хезмәттәшлек итүче бер журналист белән шактый якын, хәтта ышанычлы мөнәсәбәттә була. Ул 1917 елның язында, Кавказдагы икенче күренекле эшлекле Әхмәдбәк Саликов һәм Гаяз Исхакый белән бергәләп, бу журналистка мөселман иҗтимагый-сәяси хәрәкәтендә һәм Россия башкаласының сәяси элитасында шактый күренекле кеше булып китәргә булыша. Журналистның фамилиясе — Солтангалиев, исеме — Мирсәет. М. Солтангалиевнең «өченче дөнья»да милли хәрәкәтнең иң күренекле теоретигы булачагын бу чакта берсе дә күз алдына китерми, әлбәттә.

Тиздән сәяси агымнар Солтангалиевне һәм Рәсүлзадәне капма-каршы ярларга бастыра. Большевикларча карашлы элекке социал-демократ Рәсүлзадә демократик Әзәрбайҗан төзүне житәкләгән «Мөсават» партиясен оештыручыларның берсе була, ә Солтангалиев 1917 елның җәендә большевик булып китә дә гражданнар сугышы елларында Ленин вариантындагы бөтендөнья революциясенең иң ялкынлы тарафдарларының берсе булып әверелә. Әмма 1917 елда Солтангалиев үзенең оппонентларының милли эшкә, дини мәсьәләгә хыянәт итүенә киная-үпкә белдерүләренә: «Минем карашларым турында Әхмәдбәктән һәм Мәмәд-Әминнән сорагыз!» — дип җавап бирә әле. Алар икесе дә — Мәмәд-Әмин һәм Әхмәдбәк — милли-мөселман хәрәкәтендә иң абруйлы кешеләр саналалар. Әмма бу хәл Солтангалиевкә Рәсүлзадәнең кайбер журналистлык алымнарына шактый тәнкыйть итеп карарга комачауламый. Кечкенә генә мисал. 1916 елда Солтангалиев аңа «Ачык сүз» газетасында (мөхәррире Рәсүлзадә) Садри Максуди мәкаләсен авторын күрсәтмичә күчереп бастыруын искәртә.

Гражданнар сугышы елларында Рәсүлзадәнең сәяси тормышы Әзәрбайҗан җәмгыятен әйдәп баручы «Мөсават» партиясе белән бәйле. Ул яшь мөселман демократиясенең башлангыч чорын шушы партия белән уза. Аңа өч ел буена диярлек төрле эчке һәм тышкы сәяси көчләр белән көрәшергә һәм вакытлы килешүдә булырга туры килә. Ә әлеге сәяси көчләрнең һәркайсы Каспий буендагы бик тә бай илнең киләчәген үзенчә күз алдына китерә. Төрекләр һәм инглизләр, немецлар һәм дашнаклар (әрмән милли буржуаз партиясе әгъзалары), акгвардиячеләр һәм большевиклар — барысы да Бакуда ныклап төпләнергә омтылалар. Аларга нефть «исе» тынгылык бирми. Властьлар һәм җәмгыятьтә үз урыныңны билгеләүләр өзлексез алышынып тора. Төркия, бу регионда иң йогынтылы хәрби һәм сәяси көчле ил булса да, Антантага каршы торуның катлаулы шартларында, Совет Россиясе тарафыннан яклау табу өчен, совет гаскәрләренә Әзәрбайҗанны алырга комачауламый[5].

Унберенче армия (аңа җирле большевиклар һәм аларны яклаучылар булыша) апрель ахырында Бакуны басып алгач, Әзәрбайҗан җөмһүрияте сәяси драмасының соңгы пәрдәсе тәмамлана. Шимаха янындагы Лагич поселогында качып ятучы Рәсүлзадәне 1920 елның июль башында кулга алалар һәм Бакудагы Баил төрмәсенең гомуми камерасына китереп ябалар.

Аның эшен җирле ЧК тикшерә. Экс-президентның исән калырга ышанычы аз булгандыр, күрәсең. Әмма котылу мөмкинлеге көтелмәгән-уйламаган тарафтан килеп туа. 1920 елның октябрендә Сталин Бакуга бара. Бу аның революцион карьерасы башланган урыннар буйлап үзенә күрә тикшерү сәфәре була. Әзәрбайҗан Гадәттән тыш Комиссиясенең (АзЧеК) Баил төрмәсендә ишерен эшләрне алып барган җаваплы хезмәткәрләреннән берсе соңыннан менә нәрсәләр сөйли:

**— Мине АзЧеК начальнигы урынбасарына чакырып керттеләр. Ул миңа, Мөхәммәд-Әмин Рәсүлзадәне вокзалга илтеп куй, анда аны Сталин салон-вагонда көтә, диде. Төрмәгә бардым. Рәсүлзадә камерасына кердем. Андагы хәлләр яман иде. Тынчу-эссе, һава начар, камера кысан. Тоткынның кыяфәте бик тә мескен — киемнәре сәләмә, сакал-мыек баскан. Ул үзен тыйнак, дәрәҗәсен белеп тотты, сөйләшмәде. Ике солдат ияртттем, тоткынны фаэтонга утырттым һәм шәһәргә илттем. Миңа бухгалтериядә акча бирделәр, Рәсүлзадәгә эчке киемнәр, костюм, туфли, эшләпә һәм башка әйберләр сатып алдым. Ул юынып-кырынып, яңа костюм киеп урамга чыккач, мин аны танымыйча тордым. Бөтенләй бүтән кеше кебек — мәһабәт кыяфәт, зур күзләрендә акыл балкышы, киң маңгай, йөзендә тәвәккәллек сизелә. Ул чын мәгънәсендә бөек булып күренде...**

Егерменче еллар азагында язылган бу әчкерсез хатирәдән авторның Рәсүлзадәне Сталин янына илтүе аңлашыла. Чекист шаһит булган сөйләшү дә кызыклы: «Сталин аның янына килде, кочаклап үпте. Аннары кинәт кенә: — Мөхәммәд-Әмин, ел ярымда сезнең власть халыкка нәрсә бирде? Сез нәрсәләр эшләргә өлгердегез? — дип сорады. Мөхәммәд-Әмин, бераз сүзсез торгач: — Без, Иосиф, күп эшләр майтарырга өлгермәдек. Хәлнең ничеклеген үзең беләсең... Әмма, уйлавымча, без төп нәрсәгә ирештек. Халыкка милли азатлык һәм бәйсезлек тәмен татыттык... Бер җилфердәгән байрак моннан ары төшерелмәячәк, — диде».

Автор истәлекләре ахырында тагын бер кызыклы нәрсә турында сөйли. Чекист тоткынны берничә сәгатьтән соң төрмәгә кайтарырга кирәклеген искәрткәч, Сталин, боерык язуын ала да, аңа болай дип язып куя: «Ябылуда тотылучы Мөхәммәд-Әмин Рәсүлзадәне Сталин кабул итеп алды».

Ләкин тәртип — тәртип инде, куркуга төшкән конвойчы, ул-бу була калса, дип, ЧКага кайтышлый фотографиягә керә, нарком һәм Политбюро әгъзасы Сталин язган кәгазьнең берничә копиясен алдыра, аларга солдатлардан шаһитлар буларак имза салдыра, язуны төрмә документлары арасына куя, бер копияне, ул-бу нитә калса, дип, үзендә калдыра. Әмма берсенди дә бәйләнү-нитүләр булмый — Сталинның кемлеген һәм аның власть кодрәтен бөтен илдә, бигрәк тә Кавказда, яхшы беләләр инде. Хәер, революцион романтика дигән нәмәкәй яшәгән, барлык нәрсә кырыс кагыйдәләр калыбына кысылмаган чак бит. Юлбашчылар инструкцияләрдә каралмаган төрле хикмәтләр кыла алалар, өстәвенә, инструкцияләре дә аз була әле. Моны, мәсәлән, башкорт гаскәрләренең элекке штаб начальнигы һәм хәрби шура башлыгы Ильяс Алкин раслый алыр иде. Ул, 1920 елның салкын декабрь кичендә Бутыр төрмәсеннән чыккач, камерадашы — Хуканд хөкүмәтенең элекке башлыгы Убайдулла Ходжаев белән туп-туры Кремльгә, Сталин фатирына юнәлә. Һәм Сталин аларны кире бормый, сыйлый, эш бирергә ышандыра, Милләтләр Комиссариатының Пречистенкодагы гомум торагына үз автомобилендә озаттыра. Ләкин бу хәл игелек күрүчеләрне, чиратлары житкәч, репрессия тегермәненә эләгүдән коткара алмый.

Мөхәммәд-Әминнең Совет Россиясендәге моннан соңгы тормышы берничә җөмләгә сыя. Сталин белән бергә Мәскәүгә килгәч, ул Шәрекъ нәшриятына эшкә урнаштырыла. Нәшрият, революцион әдәбият бастыру һәм колонияләрдә тарату буенча Коминтернның шәрекъ бүлеге филиалы кебек санала. Рәсүлзадә мөхәррирлек итә, берничә мәкалә бастыра. Төпченүле цензура урнаштыруны, үз мәкаләләрен төзәткәләүне ачуланып кире кага. «Жизнь национальностей» газетасындагы бер мәкаләсенә «Бөтендөньяда совет власте яшәсен!» дигән сүзләрне өстәп бастыргач, Милләтләр Комиссариаты коллегиясе әгъзасы, күптәнге дусты Солтангалиев янына шикаять белән килә. Ә Солтангалиев, кулларын җәеп, берни эшли алмавын, моның Үзәк Комитет күрсәтмәсе икәнлеген әйтә[6].

1922 елда Рәсүлзадә Финляндиягә барып чыга. Аның китүенең ике юрамасы бар. Беренчесе. Ул Хельсинкига эш белән — кәгазь сатып алу өчен барган. Һәм, килгәч тә, илчелеккә, монда каласын әйтеп һәм соңыннан, халык байлыгын урлап качты, дип язарга урын калмасын өчен, казна акчаларын тапшыруы кәгазе яздырып биргән. Икенчесе. Монысын Солтангалиев үзенә якын кешеләргә сөйләгән. Мөхәммәд-Әмингә чик аша чыгып качарга, Финляндиядәге татар оешмасы булышлыгында, Петроград мәчете имамы Муса Бигиев булыша. Шулай булуы бик ихтимал — моннан алда гына күренекле татар журналисты һәм җәмәгать эшлеклесе Бари Баттал да (ул 1920 елда Казан янындагы концлагерьдан кача) М. Бигиев ярдәмендә «фин коридоры»ннан үтә. Озак та узмастан, Рәсүлзадә Истанбулга килә, аннары Әнкарага бара, монда аны Кемал кабул итә.

Гражданнар сугышында күргәннәре Рәсүлзадәне кичекмәстән каләм тотарга мәҗбүр иткән, күрәсең. Бәлки моңа совет матбугатының һәм чит илләрдәге советча матбугатның Бакудагы вакыйгаларны берьяклы яктыртуы да сәбәп булгандыр. «Кремль власте коридорлары»нда ыгы-зыгы тудырган китап менә шул вакытта языла. Анда Кемал идарә иткән Төркиягә мөнәсәбәттә Совет хөкүмәтенең икейөзле сәясәт-уен алып баруы ачып салына. Бәлки нәкъ менә шуна күрә бу кечкенә китап Сталинның ачуын кабарткандыр. Китапка мөнәсәбәттә Генераль секретарьның киңәшләре ипсез фактларны кире кагу «технология»сен (моны ул соңыннан ил күләмендә һәм чит илләргә карата уңышлы файдалана) ышандырырлык итеп күрсәтә. Әлеге киңәшләр сирәк очрый торган тарихи әкәмәтләр генә түгел, аларны бүген дә кызыксынып укырга мөмкин.

Киңәшләрнең баш өлешендә Сталин катгый. «Рәсүлзадәгә каршы брошюраның гомуми тоны һөҗүмчән булырга тиеш. Акланырга һич тә ярамый», ә аны түбәндәге гөнаһларны кылуда гаепләп һөҗүм итәргә кирәк:

1. Ренегатлыкта. Ул большевик иде, ләкин большевикларга хыянәт итте.

2. Төрекләр интересына хыянәт итүдә. Ул үзе һәм аның «Мөсават» партиясе Кызыл Армиягә төрекләргә ярдәм итәргә комачауладылар, Бакуны алуга каршы тордылар.

3. Әзәрбайҗан халкына хыянәттә. Крестьяннарга җир бирүгә һәм бәкләрнең биләмәләрен юк итүгә каршы тордылар.

4. Шәрекънең барлык халыклары интересларына хыянәттә һәм Англиягә мөселманнар өстеннән колониаль хакимлекне сакларга булышуда.

5. Әрмән-татар кырышын-суешын оештыруда. (*Сталин шунда ук сыртны каезлый торган пропагандистик тәгъбир дә әйтә* — Б. С. «Әзәрбайҗан Пуришкевичы дигән исем тагарга»).

6. Шахмор җәберләү-талавын, үтерешен оештыруда гаепләргә — Әзәрбайҗан җәберләүчесе-талаучысы, үтерүчесе, дип атарга».

Аннары берничә юлда «фетнәче»нең идеологик байлыгына анализ ясала, бу анализ исә Рәсүлзадәне «урта гасыр дәрәҗәсендәге надан хыялый» дип атауга кайтып кала. Киңәшләрнең ахырында юлбашчыга хас тыйнаклык белән болай дип язылган: «Шушы тезислар искә алынса, брошюра бик тә канәгатьләнерлек булыр, дип уйлыйм. И. Сталин»[7]. Әлеге киңәшләр язылганчы, Сталин адресатлар (барысы белән булмаса да) белән әңгәмә корган, күрәсең. Аларга, «аргументларны һәм фактларны» онытып җибәрмәсеннәр яки бутамасыннар өчен (арадан Кировның гына бераз провинциональ репортерлык тәҗрибәсе була), сәяси дошманны фаш итү буенча шушы инструкция тапшырыла.

Документның соңгы битендә киңәшләрне тормышка ашыра башлау да чагыла: «Ип. Раттаузер, миңа, иптәш Сталин тезислары нигезендә брошюра язу өчен, революция музееннан материаллар бирүегезне сорыйм. Мусабәков». Моннан, «шобага» фаш итүче итеп Әзәрбайҗан совнаркомы рәисенә чыккан, дигән нәтиҗә ясарга мөмкин. Оста телле һәм оппонентын җиргә «сыларга» сәләтле Киров Рәсүлзадә белән бәхәскә керməүне хуп күрә. Мин Мусабәковның брошюрасын очратмадым[8]. Аның язганы, түбән дәрәҗәдә булуы сәбәпле (моны оппонентның үз файдасына каеруы ихтимал бит), яраксыз саналган булырга тиеш.

Югарыда китерелгән киңәшләр — сирәк очрый торган документ. Өстәвенә, анда гаҗәеп яңалык та бар — фактлар һәм аргументлар аз булган яки алар сәяси максатка каршы килгән очракта ничек эш кылырга кирәклеге революциядән соң беренче тапкыр ачыктан-ачык өйрәтелә. Ләкин мондый ысуллар һәм алымнар чит-ятлар өчен түгел. Сталин үз кешеләре даирәсендә һич тә кыенсынып тормый: «исем тагарга», «акланмаска», «һөҗүм итәргә» һәм, баш ватып тормасыннар өчен, сыртны каезлый торган атамаларны үзе үк әйтеп бирә[9]. Монысы әле 1923 елда иде. Озакламыйча мондый нигезләүнең һәм яманат чыгару алымының «куәт-кодрәт»ен Сталинның көрәштәшләре — башта Троцкий, аннары Зиновьев һәм Каменев — үз җилкәләрендә татыйлар, ә аларны тәп фаш итүче Бухарин әлегә еракта тора.

Шушы тарихта серле бер нәрсә күзгә ташлана. Аның турында минем үз юрамам бар. Әмма ул һич тә көтелмәгән юрама, шуңа күрә аны тәфсилләүдән хәзергә тыелам.

Көтмәгәндә, югарыда тасвирланган вакыйгалар вакытында ук диярлек, Мәскәүдә Галимҗан Ибраһимовның «Кара маяклар яки Ак әдәбиятлар» дигән китабы (1924) чыга. Ул татар эмиграциясен, иң башлап Г. Исхакыйны һәм З. Вәлидине фаш итүгә багышланган. Рәсүлзадә турында да бүлек бар. Аның карашларын һәм эшчәнлеген тәнкыйтьләүдәге күп кенә алымнар Сталинның Кавказ эшлеклеләренә биргән киңәшләренә охшаш. Ләкин Сталин һәм Ибраһимов гражданнар сугышы елларында шактый якыннар булсалар да, әлеге бүлекне, турыдан-туры инструктаж нәтиҗәсе, дип бәяләмим мин. Хәер, өйрәтү-кушу булса да, андый хәлләр документларга теркәлми, гадәттә «эзләр» сөртелә бит. Кировка һәм башкаларга киңәшләр — кагыйдәдән чыгарма.

Г. Ибраһимов биографиясен җентекле өйрәнгән академик М. Хәсәнов та Сталинның турыдан-туры «заказ»ы юрамасына шулай ук шик белдерә. Бәлки, бу шулайдыр да. Әмма эмиграцияне фаш итү идеясенең илләге иҗтимагый-сәяси хәлләргә төрлечә (шул исәптән басма сүз белән дә) һәм якыннан катнашуын да онытмыйк. Ул чакта инанган коммунист буларак, Г. Ибраһимов, хәзер без моңа бүтән мөнәсәбәттә торуыбызга карамастан, үз бурычын үтәгән һәм аны әйбәт башкарган, дип саный алабыз.

...Мөхәммәд-Әмин Рәсүлзадә чит илдә утыз ел — вафатына чаклы (1954 ел) яши. Ул Россия эмиграциясе тормышында якыннан катнаша. Китаплар һәм мәкаләләр яза, милли хәрәкәтләрне большевикларга ярдәм күрсәтүдә гаепләп

үчеләр белән бәхәсләр куерта. Аның егерменче еллар ахырындагы һәм утызынчы еллар башындагы мәкаләләре шундый бәхәсләрне чагылдыра. Бу еллар СССРда милли читкә тайпылу дип аталган хәрәкәткә каршы кискен көрәш чоры була. Кырымда Вәли Ибраһимов, Мәскәүдә һәм Идел буенда Солтангалиев сәяси процесслары һәм эшләре алып барыла. Әзәрбайҗанда мөсаватчеләрне күпләп кулга алулар тоталитар режимның милли хәрәкәтләргә каршы көрәшендә яңа этабын билгели. Мондый хәлләрне эмиграция игътибардан читтә калдырмый, күп санлы мәкаләләр басыла, китаплар чыгарыла. «Солтангалиевчелек» аеруча актив тикшерелә. Рәсми органнарның аны, бер яктан, империализм агентурасы, дип атавы да, ә икенче яктан, «Туран империясе» төзергә маташуы, дип күрсәтүе дә моңа сәбәп булып тора. Милли читкә тайпылу дошманнары — Сталиннан башлап Керенскийга хәтле — бераз вакытка сәер «берлек»кә оешып алалар. Архивлар ачыла барган саен без мантыйксыз һәм үзара сыешмый торган хәлләр турында күбрәк белсәк тә, Кремль һәм Лубянка Россиянең элекке премьерына куйган бурычлар турында сүз бармый, әлбәттә[10]. Аңлатуларга күчмәстән, берничә факт кына китерик.

1930 елда Керенский «Дни» газетасында ОГПУның СССРда милли читкә тайпылу группаларын фаш итүе уңаеннан мәкалә бастыра. Аның исеме үк — «Рус халкы өстеннән диктатура» — милли хәрәкәтләрне фаш итүдә ОГПУ линиясенең дөреслеген «раслаучы» кыйммәтле дәлил булып хезмәт итә. «Солтангалиевчеләр рус жирен элекке Россиянең «изелгән халыклар» дип аталганнар арасында бүлгәләргә телиләр»,— дигән фикер үзе генә ни тора!.. Нәкъ шулай — «дип аталганнар» диелгән. Керенский, котны очырырга тырышуын көчәйтеп, болай дип яза: солтангалиевчеләр менә нәрсәләр таләп итә — «Кавказ грузиннарга, тау халыкларына, әзәрбайҗаннарга биреләчәк. Кече Россия — украиннарга. Себер — якутларга һәм бурятларга һәм башка чит халыкларга». Ә иң куркынычын Керенский ахырга калдырган икән — «Идел аръягындагы бөтен Россия, Оренбургтан һәм Себердән башлап Төркестандагы Памирга хәтле, пантюркистларга, ягъни Казан татарлары белән кемалчылар берлегенә биреләчәк». Һәм бу бөтен дөньяга игълан ителә. Керенскийның шушы позициясен әрмән эмигрантлары яклап та чыга[11].

Рәсүлзадә бер цикл мәкаләләрендә («Пантуранизм һәм Кавказ проблемалары» исемлесе принципиальлеге белән бигрәк тә аерылып тора) рус эмиграциясе матбугатындагы кампанияне һәм беренче чиратта СССРда милли хәрәкәтләрнең абруен төшерү буенча язмаларны жентекләп тикшерә. Ул Керенскийның һәм аның тарафдарларының карашлары «бердәм бүленмәс» империя идеясен яшерергә маташу гына икәнлеген кызганыч төстә билгеләп үтә.

Туган туфрагыннан аерылырга мәжбүр ителүен һәм Әзәрбайҗанның бәйсезлеге теләге тормышка ашуын күрә алмавын исәпләмәгәндә, Рәсүлзадәнең чит илдәге калган тормышы кайгы-хәсрәтсез уза. Хәзер катлаулы чор кичерүче Әзәрбайҗан жөмһүриятендә Рәсүлзадәнең исеме халыкка кайтарылды. Баку университеты аның исеме белән аталды. Аны ачу турында 1918 елда ул бик хыялланган була. Бүген Әзәрбайҗанның һәр кешесе Мөхәммәд-Әмин Рәсүлзадәне искә алмыйча кала алмый — Әзәрбайҗан акчасына Рәсүлзадәнең рәсеме төшерелгән...

Сталинның Рәсүлзадәне юк итү өчен нинди дә булса гадәттән тыш чаралар күрү-күрмәве билгеле түгел. Бәлки ул, бер-беребезнең тормышын саклап калу белән үзара исәп өзелде, дип санагандыр. Аннары чит илләрдә Рәсүлзадәдән бик күпкә куркынычрак дошманнар да бар бит әле — Троцкий, Бажанов, качак совет дипломатлары, ОГПУ һәм НКВД генераллары. Сталинның һәм совет властеның төрле сәбәпләр аркасында каршы якка баскан усал дошманнары. Һәм аларга ак эмиграция эшлекләләрен дә өстик. Үч алмауның бүтән, әйтик, психологик сәбәбе дә булуы ихтимал. Сталинның, дошманын юк итеп яки коралсызландырып, аңа шәхсән ачу тотмау гадәте дә билгеле. Гомеренең соңгы елларында аның, тар даирәдә үткәннәр турында сөйләшкәндә, Николайны да, Алексейны да ачуын кабартмыйча искә алуы мәгълүм. Бухаринга һәм Рыковка шундый мөнәсәбәтен сиздерсә дә, Лев (Троцкий) турында тыныч кына сөйләмәгән ул...

Әзәрбайҗан комсомолы Үзәк Комитеты секретаре Гусейнов 1930 елда республика партия һәм комсомол Үзәк Комитетлары секретарьларын Сталин кабул итүе турында яза. Очрашу Сочи янында була. Гусейнов Сталинның алар белән әзәрбайҗанча сөйләшүен әйтә. Юлбашчы элек үзе белән бергә эшләгән кайбер большевиклар турында сораша. Алар рәтендә Рәсүлзадәне дә атый. Сталин әйтүенчә, ул элек тә аның иң якын дусларыннан берсе булган икән.

Гусейнов, комсомолларча дәртләнеп, мөртәтләргә мөнәсәбәттә килешмәүчән карашта торуы белән юлбашчыга ошарга тырышып, Мөхәммәд-Әмин — хәсис һәм хыянәтче, ди, үз сүзе белән әйтсәк, «дип ычкындыра». Сталинның җавабы бу сөйләшүне тыңлап торучыларны хәйран калдыра. Юлбашчы, йөзен чытып, акрын гына, әмма һәр сүзенә басым ясап, болай ди: «Сәфәр, үзең белмәгән кеше турында беркайчан да начар итеп сөйләмә. Әгәр кем беләндер безнең юлларыбыз бер түгел икән, бу хәл әле, ул — хәсис, дигән сүз түгел». Шуннан соң Сталин кунаклар белән бик коры гына саубуллаша[12].

Әлеге очрашу 1930 елда була. Моннан соң әле 1934, 1937 һәм аннан соңгы еллар киләсе бар, шул еллардагы хәлләр исә очрашуда яңгыраган сүзләргә һич тә туры килми.

Сталин һәм Рәсүлзадә арасындагы мөнәсәбәтләрнең үзенчәлеген тагын мондый факт та раслый. Рәсүлзадә эмиграциядән Сталинга озын хат яза, аңа ЧК зинданыннан коткаруы өчен рәхмәт әйтә. Ләкин СССРда киң җәелүче-таралучы империячел гадәтләр-тәртипләр белән һич тә килешмәвен белдерә. Сталин бу хатны, укыгач, саклау өчен, шәхси архивына тапшыра.

Ахырдан Рәсүлзадәнең утызынчы елларда әйткән ике фикерен укучыларыбыз игътибарына җиткерик.

**«Бүгенге дөньяның чын хәле һәм аның гасырлар буена кешеләр акылында һәм холкында беркетелгән шартлары һәм факторлары безгә сәясәттә хыялыйлар булып һич тә ярамый торган гөнаһ кылырга ирек куймый».**

**«Безнең инануыбызча, бердәнбер ачык аңлаешлы һәм дөрес сәясәт — милли сәясәт. Тарихның мәгънәсе шундый. Фән, акыл һәм мантыйк фәрманы шундый».**

Бу фикерләр турында безнең көннәрдә дә ныклап уйлану һич тә зыян итмәячәк. Хәер, акыллы фикерләр шушы мәл хаҗәте өчен генә әйтелеп калмый лабаса. Аларның кайберләренең асылына төшенү өчен, шактый вакытлар узуы кирәк...

## ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Баку революционерлары эшчәнлегеннән аз билгеле кайбер фактлар 1985 елда Оксфордта чыккан «О пантуранизме» исемле китапның Рәсүлзадә турындагы биографик белешмәсендә бирелә.

2. Татар большевигы Сибгать Гафуров турында сүз бара.

3. Маннаф Сөләйманов. Үткән көннәр... Баку, 1990, 335—338 б. б.

4. Сталинның рәсми биографиясендә язылганча, ул Бакуга беренче тапкыр 1903 елның июнендә социал-демократлар лидерларының берсе сыйфатында килә. И. В. Сталин. Әсәрләр. М., 1946. т. 1.

5. Әхмәдбәк Саликов бу сәер союз турында болай ди: «Большевиклар төрек кошы койрыгына утыртылган. Һәм кош аларны үзе белән йөртә. Кош кунган төштә большевистик паразитлар үзләренең күзәнәкләрен калдыралар». ГАРФ, ф. 5871, оп. 2, э. 889.

6. Бу 1921 елның 13 гыйнварында «Р-дә» псевдонимы белән басылган мәкаләдер, күрәсең.

7. РЦХИДНИ,— ф. 558, оп. 1, э. 4491.

8. Рәсүлзадәне «фаш иткән» беренче брошюралар 1926 елда чыга.

9. РЦХИДНИ,— ф. 558, оп. 1, э. 4451.

10. Сүз монда совет властеның чит илләрдәге кайбер усал дошманнарының ОГПУның түләүле агентлары булуы турында бармый. Андый мисаллар да күп күбен. Ә менә 1924 елда Политбюроның, бик тә яшерен карар нигезендә, эмиграциянең «Накануне» газетасын чыгару өчен 15 мең доллар акча бирүен ничек аңларга?..

11. 1936 елда НКВД провокацион «Идел-Урал» подполье группасы эше»н әвәли. Аннан күренгәнчә, бу группаны күп кенә татарлар һәм башкортлар яклаган, имеш. Керенскийның «ташка язганнары» шул чакта ярап куйгандыр, мөгаен.

12. Манаф Сөләйманов. Күрс. хезм., 339 б.



Габделбари Баттал

# КАЗАН ТӨРКИЛӘРЕ

## Икенче Екатерина заманы

Икенче Екатерина идарәлеге заманында, 1773—1774 елларда кабынган Пугачев фетнәсенә, мин бары тик аңа төньяк төркиләрнең һәм башка җирле халыкларның катнашуы ягыннан гына тукталып үтәчәкмен. Н. Дубровин исемле урыс авторы, югарыда сүз алып барылган 1755 ел баш күтәрүе турында озаклап сөйләгәннән соң, мондый фикер әйтә: «Урыслар, файдалы казылмаларга бай башкорт җирләрен басып алуны һәм анда төрле фабрикалар төзүләрен дәвам итәләр иде. Мәсәлән, бакыр һәм тимер учаклары хуҗасы Иван Твердышев, башкорт Юлайның җирләрен үзләштереп, шунда фабрикалар кора. Бу башкорт түрәсе соныннан Пугачевның актив бер көрәштәше була. Җирле халык мондый талауларга соң дәрәҗәдә дошманлык белән карый. Әмма ачыктан-ачык каршылык күрсәтә алмаганга, яхшы көннәр һәм уңайлы форсат көтәләр иде». Н. Фирсов исә, («Пугачев хәрәкәте») исемле хезмәтендә бу фетнәдән бераз вакыт элек Идел буе һәм Урал өлкәсендәге җирле халыкның хәл-торышына карата шул сүзләрне яза: «Идел буенда татарлар, чирмешләр һәм чувашлар бик начар көн күрә иде. Моны, аларның мәшһүр «Катерина комиссиясе»нә барган вәкилләренә биргән теләкләреннән дә аңлап була. Алар бу күрсәтмәләрендә хакимият башында торучыларның җәбер һәм золымнарыннан өзгәләнеп зарланалар. Җирле игенчеләргә ачыктан-ачык яманлык эшләүчеләр бары тик урыс морзалары гына булмыйча, урыс крестьяннары да алар эзеннән бара иде. Урыс крестьяннары җирле халыкның иген кырларын, болыннарын вә урманнарын тартып алалар һәм мондый хаксызлыклардан соң туган шикаятьләр нәтиҗәсез кала иде. Мондый талаулар нәтиҗәсендә кайбер «ясаклы» авылларындагы халык бөтенләй җирсез кала һәм ясак түли алмас хәлгә төшә иде. Җирле халыкның басу-җирләрен тартып алу, җирле халык арасында гидайлар барлыкка килүенә этәрә иде. Болар көн итү өчен авылларын ташлап, ерак җирләргә китәргә мәҗбүр булалар». Табигый ки, мондый хәлләр Идел һәм Урал өлкәсендәге урыс булмаган халыкларның ризасызлыгын китереп чыгара. Шул сәбәпле, изелүдән котылуны хәбәр иткән бу хәрәкәтне алар дәртләнеп яклый. Чынлап та, Пугачев пәйда булып, күптән көтелгән «уңайлы форсат» күренүгә, башкортлар Дон атаманының иң беренче ярдәмчесенә әйләнгәнлектән, бөтен башкорт җирен фетнә ялкыны чолгап ала. Кайбер тарихчыларның фикеренчә, әгәр башкортлар мондый җитдилек белән катнашмаган булса, Пугачев фетнәсе бу дәрәҗәдә киңәя алмас иде.

---

[1] Дәвамы. Башы 3 санда.

Пугачев башкортларга тулы бәйсезлек вәгъдә итә һәм башкорт җирләренә урнашкан барлык урысларны аннан куачагы турында сүз бирә. Ялган императорның (Пугачев үзен императрица Икенче Екатеринаның буып үтерелгән ире Петр III дип таныта) мондый кызыктыргыч вәгъдәләре белән канатланган башкортлар, изелгәннәрнең уртак эше булган фетнә уңышлы тәмамлансын өчен, бар көчләре белән тырыша. Казанлы төркиләр һәм Казан өлкәсенең урыс булмаган башка халыклары да Пугачев хәрәкәтенә зур теләк белән катнаша. 1774 елның җәендә, Пугачев Казанга якынлашкан вакытта, Казан төбәгендәге крестьяннарның да килеп кушылуы сәбәпле, аның зурагайганнан зурая барган «гаскәре» игътибарга лаек санга, ягъни егерме меңгә җитә.

Пугачев фетнәсе көннәрендә башкорт баш күтәрүчеләре белән идарә итүчеләр Юлай белән аның улы Салават батыр була. Юлайның улы атасыннан да артык батырлыклар күрсәтүе белән аерылып тора һәм шөһрәт казана, бу тарихи шәхес турында Р. Игнатьев исемле урыс авторының җитди тикшеренүеннән алып, биредә бераз тарихи мәгълүматлар бирергә телибез.

Салават Юлай углы, Пугачев көрәштәшләре буларак кына түгел, ә Оренбург губернасындагы башкортларның һәм башка мөселманнарның баш күтәрүендә җитәкчелек итүче буларак та XVIII гасырның күренекле шәхесләреннән саналырга тиеш. Башкортлар Салаватны шушы көнгә кадәр хәтерләрендә саклыйлар, аның көче, кыюлыгы, каһарманлыгы хакында бик күп хикәяләр һәм җырлар телдән-телгә күчеп йөри. Башкортларның әйтүенә караганда, Салават үзе дә җырлар иҗат иткән һәм башкарган. Пугачев фетнәсе башланганда Салаватка әле егерме яшьләр генә булса да, ул кыюлыгы, елдамлыгы һәм корал кулланудагы осталыгы, көче белән танылa. Атасы Юлай 1768 елда Шайтан-Көдәй төбәгенең аксакалы итеп (волость старшинасы) бертавыштан сайлап куела. Юлай, тугрылык күрсәткән булып кыланса да, урысларга каршы соң дәрәҗәдә дошманлык хисе йөртә һәм үч алырга сусап, бу хисне улы Салаватка да сеңдерә. Пугачев башкортлар җирендә хәрәкәт иткәндә, урыңдагы чиновниклар Салаватны бер төркем башкортларга башлык итеп билгеләп, фетнәчеләргә каршы тору өчен Оренбург ягына җибәрә. Әмма Салават, пугачевчылар белән очрашкач та, аларга каршы көрәшәсе урында тегеләргә кушылып, туп-туры Оренбург янындагы Бирде бистәсенә — Пугачевның штабына китә. Игнатьевның язуына караганда, Пугачев белән очрашуы вакытында Салават Дон атаманының башкорт җире һәм башкортлар турындагы бөтен уй-фикерләрен сорашып белә.

Салават шунда ук эшкә керешә, 1774 елның апрель урталарында аның кул астында ике меңнән артык сугышчы була. Шуннан соң ул аерым-аерым фетнәче төркемнәрне үз җитәкчелеге астында берләштерә һәм сафтан чыкканнар урынын яңа кешеләр белән тулыландырып тора. Ул берничә мәртәбә мәшһүр генерал Михельсон белән дә бәрелешә. Фетнәчеләр Юса кальгасын яулап алганнан соң соң Салават исеме бер ара Пугачев фетнәсе тарихыннан югалып тора.

Пугачев кулга алынганнан соң Салават башкорт җирендә яңадан пәйда була, аның исеме басып алучыларга дәһшәт бөркүен дәвам итә. Ләкин тиздән урыс гаскәрләре Салаватның отрядларын җиңеп, үзен качарга мәҗбүр итәләр.

1775 елда Мәскәүдә Пугачевны, гәүдәсен дүрткә ботарлап, җәзалап үтерәләр. (Хөкем ителгән кешенең ике аягын, ике кулын дүрт атка бәйләп, соңыннан атларны бик кызу куу юлы белән башкарыла ул. Мондый җәзалау рәвеше башлыча үтерүчеләргә карата Франциядә, Англиядә, Германиядә, Италиядә һәм Русиядә кулланылган. Мәсәлән, француз короле Дүртенче Генрихне үтерүче Раваиллаж да бу рәвешле җәзалап үтерелгән.) Шуннан соң Салават та тотыла, Казан шәһәрендә эшләүче Яшерен комиссия карамагына җибәрелә. Атасы Юлай да тотылып шунда китерелә. Ата белән улны бу комиссия бары җиде генә көн тикшерә дә, Мәскәүгә, «Яшерен экспедиция» дип аталган даирә карамагына җибәрә. Анда озак кына сорау алулардан соң, тикшерүләрне дәвам иттерү өчен, болар кире Оренбургка кайтарыла. Сорау алулар тәмамлангач, ата белән ул, «мәгълүм булган бөтен җинаятьләре өчен», җинаять эшләнелгән җирләрдә камчы белән суктырылырга тиеш табыла. Камчы саны түбәндәге тәртиптә бүленә: Юлайга — Сим (Эсем) заводы бистәсендә — 40, Катау-Иван заводы бистәсендә — 45, Катау Тамакта — 45, Орловка авылында — 45, җәмгысы 175 камчы сугылачак була. Салаватка исә Симда (Эсем) — 25, Юлай авылында — 25, Красноуфимскийда — 25, Көнгердә — 25, Юса елгасы ярындагы Йәлдәк авылында — 25, җәмгысы 125 камчы сугылачак була. Соңгы җәзалау урынында, димәк, Юлай агага Орловка авылында, Салаватка исә Йәлдәк авылында тәннәренә тамга сугылырга һәм борын канатлары ерылырга тиеш була. Шуннан соң кабат Уфага китерелергә, аннары инде гомерлек ишкәкчелек җәзасын үтәргә Балтыйк диңгезе буендагы

Рогервик портына жибәреләчәк булалар. Юлай белән улына бу камчы суккысында һичбер табиб ярдәме күрсәтелми. 1777 елның сентябрендә хөкемгә тартылган бу ике зат Уфаның өяз кәнсәсенә кайтарылалар. Шул вакыт аларның тәннәренә тамга сугылмаганлыгы һәм борын канатлары да ерылмаган булуы ачыклана. Бу эшләрне башкару йөкләтелгән Третьяков исемле чиновник чакырылып, моның сәбәбе соралгач, ул тамгаларның бетүен, ерыкларның ялгануын тамга тимере белән кисү коралының бик иске булуы белән аңлатыла. Шунда ук тегеләргә яңа тамгалар бастыралар һәм борын канатларын яңадан ералар. Третьяков та түрәлектән төшерелә.

Рәсәйнең асылда нимес булган «зыялы» императрицасы Икенче Екатерина хөкемдарлыгының беренче елларында да төньяк мөселман төркиләренең мәчет һәм мәдрәсәләре хокукый халәте һичбер үзгәреш кичерми, ягъни алар элеккедәге кебек, әлегә бернинди дә хокукка ия түгелләр иде. Икенче Екатерина хөкүмәте 1768 елда яманаты чыккан «Яңа чукынучылар конторасы»н яптыра. Ул Анна белән Елизавета патшаларның исламга каршы рәхимсез эзәрлекләү сәясәтеннән ваз кичсә дә, мөселманнарның дини ихтыяҗларына бик артык әһәмият бирми әле. Бу хатын хөкемдарның хөкүмәте мөселманнар белән аңлашу һәм килешү сәясәтен бары тик Пугачев фетнәсеннән соң ун ел чамасы үткәч кенә үткәрә башлый. Үткән көннәр тәҗрибәсе һәм вакыйгалары шуны күрсәтә ки, көньяк-көнчыгыш Европа төркиләрен бөтенләе белән урыслаштыру яки христианлаштыру мөмкин булмаячак. Шуңа күрә XVIII гасырның ахырларына таба мөселман дөньясына карата битарафлык күрсәтү сәясәтенең файдасызлыгы һәм хәтта зарарлылыгы көн кебек ачык иде. Ул заманның катлаулы сәяси-икътисади торышы да бу өлкәдә эшлекле һәм килешүчән политика үткәрергә мәҗбүр итә иде.

Үз заманында патша Беренче Петр баш тылмачы Алексей Тәфкилевкә: «Казакъ-кыргыз урдасы далада яшәгән һәм артык нык булмаган бер ил булса да, бөтен Азия өлкәләре һәм илләренең капкасы һәм ачкычы»,— дип, әгәр Тәфкилев бу Урданы Рәсәйгә буйсындыруны үз өстенә алса, бу эшне оештыру өчен аңа бер миллион сум акча бирәчәген әйтә. Менә шул «ачкыч» кинәт Рәсәй кулына күчә башлый. Мәсьәлә шуннан гыйбарәт: Кече җөз казакъларының ханы Әбелхәер, Җунгариядән күчкән калмыкларның яу чабып талауларыннан туйганга, урыс патшасы ярдәменә сыенырга мәҗбүр була. Ягъни 1730 елда императрица Аннага мөрәҗәгать итеп, үз Урдасын урыс ватандашлыгына кабул итүен үтенә. Әмма ул шул вакытта ике шарт куя: 1) Ханлык дәрәҗәсен Әбелхәер токымына багышлау; 2) Хан өчен кара көннәр килсә, Ор елгасы тамагында төзеләчәк калада сыену урыны бирү.

Казакъ ханының бу гозере сөенеп кабул ителә һәм аның теләге буенча ханлык дәрәҗәсенең Әбелхәер токымына тапшырылачагына нигез салына. Әмма ханнары тарафынан урыс патшасына сатылган Кече җөз казакълары бу яңа ватандашлыкны бөтенләй танырга теләмиләр һәм хәтта урысларның көньяк өлкәләргә таба хәрәкәт итүләренә каршы торырга тырышалар. Шулай да, алыш-бирешне җайлау, матди файданы тәэмин итү өчен Төркестан белән мөнәсәбәтләрне көйләү XVIII гасырның соңгы яртысында урыс сәясәтенең зур максатларыннан берсе иде. Алексей Левшин әлеге хәлләр турында болай ди: «1752 елда, димәк, Елизавета көннәрендә, Рәсәйнең Нургали (Әбелхәер хан улы) белән мөнәсәбәтләренең максаты, асылда казакъ-кыргыз эшләре булмыйча, Хива, Бохара, Ташкент мәмләкәтләренә һәм алар аша Урта Азиянең башка өлкәләренә, хәтта ул заманнарда һәртөрле байлыкларның чыганагы булып саналган Һиндстанга кадәр сәүдә кәрваннары җибәрү өчен юл ачу иде. Һиндстан казакъ далаларыннан никадәр еракта булса да, бу далалар кулга төшү белән ул ерак җирләргә таба беренче адым атланган булачак иде. Менә бу эштә казакъ-кыргыз ханының ярдәме урыслар өчен бик тә кирәк иде».

Икенче Екатерина үткәргән бу сәясәтнең максаты Төркестанга сәүдә кәрваннары оештыру һәм казакъ-кыргыз далаларын яшәрлек бер хәлгә китерү иде. Әмма, шулай тырышуларга карамастан, Төркестан иле белән алыш-биреш мөнәсәбәтләре утыз ел буена бик аз гына алга җибәрелә. Моның сәбәбе — казакъ далаларындагы «тынычсызлык». Буйсынмас дала балаларын урыс хакимиятенә корал көче белән баш идерү һәм Оренбургтан Конграт белән Хивага, аннан яңадан Оренбургка китәчәк урыс кәрваннарына юл күрсәтүче вә озатучы булуга мәҗбүр итү бер дә җиңел эш булмый. Менә шул сәбәпле Икенче Екатерина хөкүмәте XVIII гасырның 80 елларында казакъ-кыргызлар арасына тынычлык юлы белән керү чараларын эзли башлый.

1784 елда Оренбург крае губернаторлыгына асылы белән Лифлянд шведы барон Иглстром билгеләнә. Бу кешенең тәкъдиме буенча, Икенче Екатерина

хөкүмәте 1785 елдан башлап казакъ-кыргыз далалары чигендәге урыс калаларында казна хисабына мәчетләр төзергә керешә. Шул ук елда Оренбург һәм Троицк шәһәрләрендә мәчетләр ачыла. Бу мәчетләрнең ачылу хәбәрен алган патшабикә барон Игълстромга шул ук елның 14 сентябрендә җибәргән фәрманында түбәндәге сүзләрне яза: «6 августта язып җибәргән рапортыгыздан, Троицк һәм Оренбург калаларында төзелгән мәчетләрнең ачылу хәбәрен ишеткәч, һич кенә дә икеләнмичә әйтә алам: мондый гыйбадәтханәләр чикләребез тирәсендә яшәгән күчмә халыкларны да җәлеп итәчәк. Бу хәл исә аларны киләчәктә буйсынмас булудан ваз кичтерер өчен көчле чараларның да иң көчлесе булачак». Екатерина шул ук ярлыкта генерал-губернаторга: телгә алынган шәһәрләрдә «Казан мәдрәсәләре шәкелендә татар мәдрәсәләре» ачарга, мөселман сәүдәгәрләренең эшенә ярарлык кәрвансарайлар яки сәүдә йортлары төзергә, «мөселман гадәтләре буенча ничек тиеш икәнлеген татарлардан сорашып», мәчет тирәләрендә таш диварлар тотарга киңәш итә. Яңа мәчетләрнең халыкның килү-китүе өчен уңайлы булган җирләргә һәм мөмкин булган кадәр зур, хәтта биш мең кеше сыярлык дәрәҗәдә киң итеп төзелүенә игътибар итәргә боера. Патшабикә казакъ-кыргыз мәдрәсәләре өчен мөгаллимнәрне Казан төркиләреннән китерергә куша. Игълстром исеменә җибәргән башка бер фәрманында Икенче Екатерина: «... төрле кыргыз кабиләләренә муллалар җибәрү безнең эшләребез өчен бик файдалы булачак. Бу эшкә сез Казан татарларыннан ышанычлы муллаларны җәлеп итегез, аларны кыргызларда безгә карата тугрылык тәрбияләргә өйрәтегез. Бу муллаларга, җибәргән вакытта, бераз акча да бирә аласыз һәм безгә хезмәт итүдә өсләренә алган вазифаларын тырышлык һәм тугрылык белән башкарган тәкъдирдә, тагын да күбрәк бүләкләр биреләчәген вәгъдә итегез»,— ди.

Болардан күренгәнчә, Икенче Екатерина хөкүмәте дин һәм хәреф таныту дигән булып, мулла һәм мөгаллимнәрне урыс хөкүмәте мәнфәгатенә хезмәт итүче үгет-нәсихәтче һәм сәяси агентлар итеп кулланырга теләгән. Бу мулла-мөгаллимнәрнең Екатерина һәм Игълстром тапшырган вазифаларны ни дәрәҗәдә һәм ничек үтәүләрен белмәсәк тә, шунысы ачык мәгълүм: барон Игълстром, казакъ-кыргыз иле белән идарә итү рәвешен тамырдан үзгәртергә карар биреп, Нургали ханны Уфага сөрә. Әбелхәер хан уллары белән Сырым батыр арасында килеп чыккан гаугаларны бөтен көченә күпертә һәм казакъ-кыргызларны «акылга утырту» өчен ике-өч мәртәбә урыс гаскәрләрен җибәрә.

Болардан тыш, ул замандагы Рәсәйнең көньяк һәм көнбатыш тарафларда да бик мөһим һәм житди максатлары бар иде. Бу вакытка инде Икенче Екатерина Рәсәе Төркия дәүләте белән бер мәртәбә бәрелешкән һәм, Кече Кайнарҗада төзелгән тынычлык турындагы килешү буенча, Кырым белән Кубань «бәйсезлеген» саклаган итенде. Ләкин якын киләчәктә Төркия белән яңадан да бер бәрелеш булачагын Рәсәй хөкүмәте яхшы белә иде. Кырымның сүздәге бәйсезлеге аны Рәсәйгә кушуның бары башы гына иде. Чынлыкта, Кече Кайнарҗа килешүеннән соң, Рәсәй «азат» Кырымның эчке эшләренә оятсыз рәвештә тыкшына башлый һәм инде 1783 елда берьяклы карар белән Кырымның Рәсәй императорлыгына кушылуын игълан итә.

Икенче Екатерина Рәсәе көнбатышта Польша белән дә бик нык әвәрә килә. Мәгълүм ки, әби патша хөкүмәте системалы рәвештә Польшага күз кыздыра, бу омтылышында астыртынлыкны һәм хәйләне эшкә җигә. Максаты: бу мәмләкәтне бүлгәләү ахырына җиткерелсен дә Рәсәй «арыслан пае» эләктерсен.

Пугачев фетнәсеннән яхшы сабак алган Икенче Екатерина хөкүмәте, көньякта һәм көнбатышта мондый мөһим омтылышлары булганда, әлбәттә, дәүләтнең көнчыгыш өлкәләрендә тынычлык хөкем сөрүен тели иде. Императрица Висла һәм Кара диңгез ярларына таба кызу хәрәкәт иткән «җиңү арбасы»ның тәгәрмәчләренә таяк тыгачак берәр вакыйга килеп чыгуын бер дә теләми иде.

Менә шул мөһим сәяси һәм икътисади сәбәпләр әби патша хөкүмәтен мөселман төркиләргә карата дин өлкәсендә бераз килешүчәнлеккә барырга мәҗбүр итә. Икенче Екатеринаның мөселманнарга карата сәясәте үзеннән алдагы ике патшабикә (Анна белән Елизавета) сәясәтенә охшамаса да, асылында бу тарихта үз урыны булган халыкның мәнфәгатен кайгырту юнәлешендә түгел иде.

Рәсәйнең көньяк-көнчыгышында яшәгән мөселман төркиләрдән Икенче Екатерина хөкүмәтенең ни дәрәҗәдә куркуы, патшабикәнең барон Игълстромга 1787 елның сентябрендә, димәк, икенче төрек-урыс сугышы башлангач язган ярлыкларында ачык күренә. Фәрманнарының берсендә (10.IX) шул сүзләр дә бар: «Ватандашлыгыбызда булган һәм сез идарә иткән өлкәләрдә яшәгән яки шул тобәкләргә күчеп утырган халыкка карата бик сак мөгамәләдә булыгыз. Сак булыгыз, аларга җәбер салмагыз, басым ясамагыз. Ясалган тәкъдирдә, аларга канун буенча дөреслекне табарга рөхсәт ителсен!»

Шул ук көн исәбе куелган башка бер фәрманда исә мондый сүзләр дә язылган: «Шуны да өстәп әйтергә телибез: бу халык арасында диндәшләре яисә башка берәр начар ниятле кешеләр тарафыннан безнең өчен зарарлы үгетләүләр булмасын! Моңа бик игътибар итегез. Зарарлы үгет-нәсихәтне башланганда ук мөмкин кадәр йомшак чаралар белән туктатыгыз». 27 сентябрь даталы башка бер боерыкта, Кавказ губернаторына җибәрелгән бер фәрманның Иглстромга да җибәрләүе искәртелеп, болай диелә: «Мөселман динен тоткан халыкны бик игътибар белән күзәтү һәм алар арасындагы һәртөрле хәрәкәтләргә карата уяу булу турында Кавказ губернаторына җибәргән фәрманның бер нөсхәсен сезгә дә җибәреп, биредә язылган тәгълимат кушканча хәрәкәт итәргә әмер бирәбез».

Әби патшаның мөселманнарга карата булган «мәрхәмәте»н тулыландыру өчен, генерал-губернатор барон Иглстромның урынлы дип табуы буенча, икенче төрек-урыс сугышы тәмам кызган көннәрдә, ягъни 1788 елның 22 сентябрендә «муллаларны һәм башка мөселман дин әһелләрен билгеләү һәм Рәсәйдә яшәгән мөселман рухание вазифасын үтәүчеләр белән идарә итү өчен Уфа шәһәрендә бер дини назарият төзү турында» Иглстром исеменә фәрман җибәрә. Шул ук вакытта Рәсәй мөселманнары өчен мөфти билгеләү турында Сенатка боерык бирелә.

Дөрестән дә, 1789 елда Иглстром Уфа шәһәрендә «Оренбург мөселман дини нәзарәте»н оештыра.

Боларны оештырганда Икенче Екатерина, әлбәттә, үз сәяси планнарын күз уңында тоткан. Ул шуннан да ачык күренә: мөселманнар өчен ачылган бу дини оешмага башлык сайлауны мөселманнарның үзләренә тапшыру бер якта торып кала. Мөфти билгеләгәндә аларның фикере бөтенләй исәпкә алынмый. Хөкүмәт тарафыннан сайланып, Рәсәйнең сәяси максатларына хезмәт итүче бер мулла мөфти итеп куела. Бу Каргалы авылы мулласының күңел кайтаргыч «хезмәтләр» башкарганлыгы, урыс хәзинәсеннән айлык хезмәт хакы алганлыгы һәм әлеге «хезмәтләре» белән чин, дәрәҗә өмет иткән булуы Екатеринаның Иглстромга язган боерыкларыннан ачык аңлашыла дип уйлыйм. Императрица 1785 елның 7 апрелендә язган бер боерыгында болай ди: «Уфа вилаятендәге Каргалы (Сәет) авылы ахуны Мөхәммәтҗан Хөсәен углын, хезмәте буенча үзегезгә кулай күргән рәвештә, андагы чик эшләрендә һәм чит өлкәләргә карата хезмәтләрдә кулланыгыз. Үзенә елына 150 сум хезмәт хакы түләгез». 1786 елның 9 августында бирелгән ярлыкта исә болай диелә: «Сезнең кул астыгызда чик эшләрендә һәм башка хезмәтләрдә кулланып өчен тотылган ахун Мөхәммәтҗан Хөсәен углының тырышып хезмәт итүе турындагы шәһадәтегез буенча, аның хезмәт хакын 300 сум итеп күтәрергә боерабыз». Шул ук елның 2 нче ноябрендә бирелгән боерык буенча, бу ахунның, хезмәт хакына, тагын 200 сум өстәлә һәм үзенә «Оренбур краеның беренче ахуны» исеме бирелә.

Уфада диния нәзарәте ачылгач, менә шул ахун мөселманнарның дини рәисе итеп билгеләнә. Бу кеше мөфти булганнан соң да урыс хөкүмәтенә сәяси агент булып хезмәт иткәндер, күрәсең. Казанлы тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани шактый вакыйгаларны заманга һәм булган хәлләргә бәйләп, гадәтенчә ишарәләп кенә искә алып, «Мөстәфадел әхбәр...»нең беренче бүлегендә, казакъ-кыргыз ханнары турында сөйләгәндә, кайбер казакъларның Мөхәммәтҗан мөфтинең нәсихәтләре нәтиҗәсендә Рәсәй ватандашлыгына керүләрен бер-ике сүз белән генә искә алып китә. Бу мөфтинең 1797 елның августында, димәк, император Беренче Павел көннәрендә, Хобда суы ярларына китеп, Иглстром төзегән план буенча казакъ-кыргыз киңәшмәсе мәҗлесен ачуын һәм «казакъларның тәртип-хәрәкәтләрен күзәтү өчен» бераз вакыт шунда калуын А. Левшин яза.

Игътибарга лаек бер хәлдер ки: Икенче Екатерина хөкүмәте казакъ-кыргызлар өчен дала чикләрендә мәчет-мәдрәсәләр ачтырса да, бу мөселманнарны Уфа диния нәзарәте мохитының тышында калдыра. Хәтта соңрак Кече җөз белән Урта җөз казакъларының автономия идарәсе бөтенләй алынганлыктан, Җаек елгасының аргы ягы «тыш» булудан «эч» булуга күчкәч тә, урыс хөкүмәте казакъ-кыргызлар өчен аерым бер дини идарә оештырмый, аларны Оренбур диния нәзарәтенә дә кушмый. Чөнки хөкүмәт хисабына мәчет-мәдрәсәләр төзү, дини идарә оештыру — болар бары тик урыс буйсындыруына әлегә эләкмәгән мөселман төркиләрне аулау максатына хезмәт иткән «сәяси чаралар» гына иде. XVIII гасыр тәмамланганда инде мондый чараларга ихтыяҗ калмаган иде.

Мөселман төркиләр арасына «тынычлык юлы белән үтеп керү» максатын күз алдында тотып, Казанда 1758 елда (димәк, императрица Елизавета заманында) беренче урыс гимназиясе ачыла. Ә 1768 елның 12 маенда, ягъни мәктәпнең ачылуыннан 10 ел үткәч, Икенче Екатерина фәрманы буенча «татарчадан русчага һәм русчадан татарчага тәрҗемә итерлек оста тылмачлар әзерләү өчен» төрки

тел классы булдырыла. Биредә төрки тел укыту эшен озак еллар буе, буыннан-буынга күчеп, Хәлфә угыллары (Хәлфиннәр) башкара. Башта бу эшкә Сәет Хәлфин билгеләнә, аннан соң 1758 елда бу вазифа аның улы Исхак Хәлфингә күчә. 1812 елда бу хезмәт Исхакның улы Ибраһимга тапшырыла. Хәлфиннәр дәрес китаплары да язганнар. 1812 елда Ибраһим Хәлфин Казан университетына да төрки телләр укытучысы итеп билгеләнә һәм 1823 елда университетның Шәрекъ әдәбияты профессоры ярдәмчесе итеп сайлана.

## XIX гасырга кергәндә һәм аннан соң

Казанның беренче гимназиясендә Шәрекъ телләрен укыту Шәрекъ китапларын басуны да китереп чыгара. Моннан тыш, XVIII гасырның ахырларына таба Казан төркиләре хөкүмәткә мөрәҗәгать итеп, ислам дине һәм әхлагы буенча әдәбият басу өчен Казанда гарәп хәрефле басмаханәне дә эченә алган бер матбага ачуны сораганнар. Шушыларны искә алып, хөкүмәт Петербургтагы Азия матбагасының ике басу машинасыннан торган бер бүлеген Казанга, беренче гимназия идарәсенә җибәрә. Шулай итеп, Казанда гарәп хәрефләрендә беренче матбага 1801 елда, димәк, император беренче Александр заманында ачылган. Матбугат йорты гимназия идарәсендә булган. Ләкин 26 ел эчендә басылган гарәп хәрефле китапларның төре бик аз.

1829 елда Казан университетына күчерелгәч, бу матбага яңартыла һәм киңәйтелә. 1840 елда немец Людвиг Швец шәхси бер матбугат йорты ача. 1843 елда Казан татары Рәхимҗан Сәет углы бер матбага оештыра. Ул 1843—1862 елларда 30 мәртәбәдән артык «Коръән»не һәм «Һәфтияк»не («Коръән»нең җиделән бер өлеше) басып чыгара. Бу шәхси матбугат йортларында гарәп хәрефләре белән бик күп брошюра һәм листовкалар басыла. Боларның арзанлы кәгазьдә басылган китаплары, университет матбагасында басылганнарга карaганда күпкә арзанрак булганга, фәкыйрь халыкның сатып алуын җиңеләйткән. Ул елларда Казанда татарлардан Чукин һәм Яхья углының ташбасмаханәсе дә була. Анда 1860 елда Тәҗвид һәм 1861 елда Габделхәким Габдерәшит тарафыннан сызылган Европа һәм Азия картасы да басылган.

XVIII гасыр ахырларында ислам дине урыс хөкүмәте тарафыннан танылып, диния нәзарәте оештырылса да, болар хөкүмәтнең ислам дине һәм мөселманнар белән булган мөнәсәбәтләрен беркадәр генә юлга сала. Ләкин төрки мөселман өлкәләрендә исламиятне көчәйтү, уку-язуга өйрәтүне киңәйтү, тәртипкә салу барыбер мөмкин булмый. Әгәр Уфа диния нәзарәтенә мәктәпләр ачу, дәреслекләр язу хокукы һәм акча бирелгән булса, әлбәттә, әлеге эшләр дә алга киткән булыр иде. Хәлбуки, бу дини оешмага мәктәпләр ачу хокукы түгел, хәтта инде яшәп килгән уку йортлары белән идарә итү хокукы да бирелми. Аның хокуклары Рәсәй императорлыгы кануннары җыентыгында күрсәтелгән. Анда мәктәпләр белән идарә итү дигән нәрсәгә хәтта ишарә дә юк. Ә менә Кырым дини идарәсенә мәктәп һәм мәдрәсәләр белән идарә итү хокукы бирелгән. Уфа диния нәзарәтенә мәхәллә имамлыгына күрсәтелгән кешеләрне имтихан алып тикшерү хокукы бирелсә дә, югары белемле муллалар хәзерләү һәм халык арасында укый-яза белүчеләрне күбәйтү омтылышына хокукы юк иде. Хәер, нәзарәтнең мондый эшләргә омтылышы булганлыгы да мәгълүм түгел. Хөкүмәтнең бу эшкә бармак аша каравы аркасында гына яшәп килгән мәктәп-мәдрәсәләр һаман да белемнәре түбән муллалар кулында кала бирә һәм язма дини китаплар да бик аз була.

Менә шул вакытта Казанда ислам дине китаплары басыла башлый. Бурашов идарәсендәге матбагада басылган «Коръән», «Һәфтияк», «Иман шарты» һәм башка китаплар тиз һәм күп итеп тарала. Көн үткән саен басма китапларга ихтыяҗ да арта бара. Бу хәл басма китапларның еллык исәбеннән ачык күренә. Басма китаплар күбәйгәч, муллалар да шактый җанлана төшә, халыкта укый-яза белүчеләр саны да арта. Бу турыда профессор Карл Фукс шул сүзләрне яза: «Муллалар «Коръән» өйрәтүне шәһәрләрдә генә түгел, иң фәкыйрь авылларда да бик уңышлы җәелдерәләр. Һәр мулланың диярлек үз мәктәбе була, анда гарәп теле өйрәтелә, «Коръән» һәм шәригать кануннары аңлатыла».

1853 елдан 1859 елга кадәрге 7 ел эчендә Казанда басылган «Коръән», «Һәфтияк» һәм «Иман шарты»ның санын күрсәткән мәгълүмат Академия әгъзасы Дорнны да хәйран калдырган. Чөнки бу вакыт эчендә 82 300 нөсхә «Коръән», 165 900 нөсхә «Һәфтияк», һәм 77 500 нөсхә «Иман шарты» басылып таратылган. Профессор Карл Фойгет сүзләренә караганда, ул көннәрдә Казанда

басылган ислам дине китаплары Төркестан шәһәрләренә кадәр барып җиткән.

XIX гасырның беренче чирегендә Казан мөселман төркиләренең аң-фикер дәрәҗәсенең күтәрелүенә, Идел буе мөселманнары арасына дини китапларның тагын да ныграк таралуына янә дә бер этәргеч булган дигән фикер бар. Казандагы беренче гимназия матбагасы хакында К. Фукс шул сүзләрне яза: «Библия җәмгыятьләренең Рәсәйдәге эшчәнлеге вакытында мин Азия матбагасында аеруча күзгә ташланган хезмәт итүнең шаһите булдым. Ул заманнарда татарлар үз дини китапларын, нәкъ безнең кебек, зур бер тырышлык белән нәшер итәләр иде». Югарыда берничә тапкыр искә алынган священник Е. Малов исә болай дип яза: «Ул замандагы хәлләр мөселманнарны китап басуда аеруча житди һәм тырышып эшләргә этәрә иде. Мәгълүм булганча, XIX гасырның беренче ун елында Рәсәйдә Библия җәмгыятьләре оештырыла. Боларның кайберләре турыдан-туры мөселманнарга һәм башка диндәгеләргә карата миссионерлык максатларын күз уңында тота иде. Мәсәлән, 1815 елның 18 сентябрендә Әстерханда да бер Библия җәмгыяте оештырылган була. Әстерхандагы кебек бер Библия җәмгыяте 1818 елның 2 гыйнварендә Казанда да ачыла. Менә бу җәмгыятьләр христиан дини китапларын «агартылырга» тиешле халыкларның телләренә тәрҗемә итеп, басып тарата башлый. Бу урыс һәм инглиз Библия җәмгыятьләренең эшчәнлеген мөселманнар, әлбәттә, сизмичә калмый. Алар бу җәмгыятьләрнең кемнәргә каршы эш алып баруларын бик яхшы аңлап, бу дошман көчне юк итәргә һәм тегеләргә караганда да күбрәк эшләргә тырыштылар. Азия матбагасында басылып чыккан китаплар мөселманнар тарафыннан гына укылмыйча, христианлыкка күчкән татарлар арасында да җәелеп, аларның йөрәкләрендә элекке диннәренә кире кайту теләген уята иде. (Чыгышы белән Дагстандагы Дәрбәнт шәһәреннән булган хаҗи Касыйм Кәзимбәкнең улы Мөхәммәтгали, бик яхшы мәдрәсә белеме алган мирза, Шотландиянең Әстерхандагы Библия җәмгыятендә эшләгән миссионерлар белән аралашып, 1823 елның җәендә христианлыкны кабул иткән һәм Александр исемен алган. Александр Кәзимбәкнең Казан һәм Петербург университетларында төрки һәм фарсы телләре буенча укытучылык итүе, тарихка һәм телгә кагылышлы әсәрләр авторы булуы мәгълүм).

Басма дини китапларның күбәюе һәм ислам мәхәлләләренең янадан оешуы XIX гасырда, заманында көчләп христианлыкка аударылган төркиләр арасында көчле, яңа бер хәрәкәт барлыкка китерә. Бу — зур бер үҗәтлек белән кире исламга кайту хәрәкәте иде. Христианлыкка аударылган кардәшләреннән аеру максаты белән мөселман төркиләрне башка җирләргә күчерү эше XVIII гасырның ахырларына таба шактый йомшый. Ягъни, бер авылда христиан төркиләрнең саны авыл халкының уннан бер өлешеннән дә артык булмаганга, алар да, мөселман төркиләр дә башка җирләргә күчерелмиләр иде. Маловның фикеренчә, ислам дини китаплары күбәйгәч, мөселманнар чукынган кардәшләрен кире мөселманлыкка күчерү уена киләләр һәм XIX гасыр башларында кайбер мулла-абызлар «керәшен» дип аталган христиан төркиләрне исламга тарта башлыйлар. 1908 елда бу эшне күреп алган хөкүмәт «керәшеннәр»не христианлыкта тотып калу максаты белән кайбер омтылышлар ясый. Мәсәлән, Түбән Новгород епископы Веньямин заманында муллаларга «керәшеннәр»не котыртырга юл куймау турында хөкүмәтнең бер әмере чыга. Түбән Новгород өязендә башланган мөселманлыкка кире кайту хәрәкәте бераз вакыттан соң Казан өлкәсендә дә җәелә. Маловның раславынча, басма ислам китапларының күбәюе мөселманнар арасында исламга тартылу теләген китереп чыгара һәм моның нәтиҗәсендә мөселманлыкка кайту хәрәкәте көннән-көн арта һәм киңәя бара.

Хөкүмәт бу хәрәкәткә каршы бер чара итеп, яңадан исламга кайтырга теләгәннәрне үгетләү өчен төрле җирләргә священниклар җибәрергә боера. Бу арада Казан епискобы губернаторларга мөрәҗәгать итеп, үгетче священникларга дәүләт чиновниклары тарафыннан ярдәм күрсәтелүен сорый. 1827 елда рухани үгетчеләр «исправник»лар, «дворянский предводитель»ләр һәм жандарм комиссарлары белән берлектә исламга кайту теләге һәм омтылышы булган төркиләрне үгетли башлыйлар. Һәр приходта көчләп чиркәүгә тупланган халыкны бер яктан «рухани аталар» үгетлиләр, икенче яктан, дөньяви агалар яныйлар. Ул көннәрдә көчләп чукындырылган мөселманнар соң дәрәҗәдә ныклык белән каршы торалар һәм шуның аркасында күп, авыр михнәтләргә дучар булалар. Дәүләт чиновниклары да, үгетче священниклар да, үзәктән килгән әмер кушканча, исламга кайту омтылышының җитәкчеләренә бигрәк тә игътибар итәләр, аларны даими күзәтәләр, авылларында булмасалар, башка җирләрдән эзләтәләр, халык белән мөнәсәбәтләрен өзәргә тырышалар, кулга эләккән һәм «җинаяте» исбат ителгән

житәкчеләрне, «гыйбрәт булсын өчен», җәзаларга тарталар. Моннан тыш, житәкчеләрне һәм «хаталануларын» дәвам иткәннәрне ныклы һәм озакка сузылган «үгет» астында тоту максаты белән ерак монастырьларга китереп, айлар һәм хәтта еллар буе ябып тоталар.

Көчләп чукындырылганнарның яңадан исламга кайту хәрәкәтләре бөтен XIX гасыр буе искиткеч ныклык белән дәвам итә. Бу гасырның икенче яртысында исламга кайтырга теләгәннәрне үгетләү эшен идарә итүчеләр арасында, татарларга исеме һәм эшләре бик мәгълүм ориенталист профессор Николай Ильминский һәм хезмәтебездә исеме инде берничә тапкыр телгә алынган священник Е. Малов та була. Е. Малов 1866 елның сентябрендә Мамадыш төбәгендәге Елыш авылына «үгетләү» максаты белән үзе китә һәм бер ай шунда торып, бу «үгетләү» эшен күзәтүе турында жентекләп көндәлек яза.

Бу «үгетләү» эшләрендә һәрвакыт бер үк ысул кулланыла. Соңрак заманнардагы «үгетләү» эшчәнлегенә карата «мадам Чечерина» дигән берәү түбәндәге сүзләрне яза: «Кире исламга кайтырга теләгәннәр турында мәхәллә священнигы консисториягә хәбәр бирә. Тегесе исә, эшне анализлаганнан соң, шундый бер карар чыгара: 1) Мәхәллә хәле турында жандармерия үзәгенә хәбәр итәргә. Шунда ук үгетләү эшенә керешергә. Шулай итеп, жандармерия үзәге бу хәбәрне алыр-алмастан становой пристав, исправник, губернатор ярдәмчесе һәм хәтта губернатор үзе дә бик тиз хәрәкәткә киләләр. Шаһитлардан күрсәтмә алына, беркетмә языла һәм һәртөрле җәзалаулар башлана: кайчак болар бөтенесе төрмәгә ябу һәм ерак Себергә сөрү белән тәмамлана. Табигый ки, мондый хәлләрдә карарның икенче өлешен (ягъни үгетләү турындагысын) тормышка ашыру мөмкин булмый».

Менә хөкүмәтнең мондый «көчле» чаралары аркасында яна чукынганнарның бер өлеше XIX гасырда да мөселманлыкларын законлаштыра алмыйлар һәм элекке кебек тыштан православный, эчтән мөселман булган хәлдә XX гасырга керәләр. Боларның бер өлеше 1905—1906 елларда кыска гына дәвам иткән хөррият көннәрендә мөселманлыкка кире кайта алалар. 1917 ел революциясеннән соң исә, исламга кайтырга теләп тә кайта алмый калган «керәшен» артык калмаган булса кирәк. Аннан соң да исламга күчмәгән һәм үзләрен «керәшен» исеме белән атаган бер төркем татарлар исә яки исламнан бик ераклашкан, христианлыкка исламнан түгел, ә мәжүсилектән үк күчкән «иске керәшеннәр» булса кирәк. Бүген Татар һәм Башкорт Совет жөмһүриятләрендә яшәгән бу керәшеннәр үзләрен төркидән аерым бер милли азчылык итеп саныйлар икән. Боларның татарларның бер өлеше булып та, үзләрен чукынган мәгънәсенә туры килгән («крещенный» сүзеннән бозып ясалган) «керәшен» исеме белән атап йөртүләре милләттә диннең никадәр зур роль уйнавын күрсәтә түгелме? Бу христианнарның саны 1920 елларда бары тик 200 меңнән генә гыйбарәт иде.

Ислам безнең шактый рухи байлыкларыбызны оныттырган һәм юк иткән. Алар арасында мөселманлык өчен зарарсыз, милләт өчен бик кыйммәтле булганнары да бар. Казан илендә жаһил муллалар соңгы вакытларга кадәр төркиләрнең «сабан туе», «җыен» кебек милли халык бәйрәмнәренә каршы төшәләр һәм аларны дин һәм шәригать исеменә язык саныйлар иде. Шактый милли көйләребез, жырларыбыз һәм башка милли фольклор әсәрләре һәм кайбер гүзәл гореф-гадәтләребез һәм тәжрибәләребез, милли киемнәребез, надан муллаларның дини карашларына корбан булып киткән. Боларны эзли башласагыз, юлсыз, аяк басмаган бер чүлгә төшкән кеше кебек, аптырап калачаксыз. Менә бу сәбәпләрдән кайбер өйрәнүчеләр Идел буе татарларының милли үзенчәлекләрен һәм фольклор әсәрләрен мөселман булмаган керәшеннәр арасында эзлиләр.

Болардан тыш казанлы тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар...»ының беренче кисәгендә (31 б.): «Керәшен диелгән татарларның теле һәм ирләрнең киеме мөселманнардагы кебек булган хәлдә, хатыннарының киеме мөселман хатыннарының киеменә охшамавы нидән килә икән? Юкса, борынгы заманнарда мөселман төрки хатыннарның да киеме шундый ук шәкелдә булып, әкренләп үзгәргән һәм элеккеге шәкел бары тик керәшен хатыннарында калганмы?» дип, шактый кызыксыну уята торган бер мәсьәләгә кагылып үтә. Мин исә мөселман казакъ-кыргызлар арасында ишеткән: «Тия бирсен!» — сүзенең керәшеннәр арасында да кулланылуы турында бер китапта укып гаҗәпләнгән идем. Мөселман казакъ-кыргызларда бер мәрхүмне искә алып берәр нәрсә ашарга, йә эчәргә тотыналар икән, ашыйсы йә эчәсе ризыкны авызга якынлаштырганда «Тия бирсен!» дип дога кылу гадәте бар. Бу гадәтнең керәшеннәрдә дә булуын мәшһүр миссионер Остроумов «Татарча-русча сүзлек» исемле китабында яза.

һәрхәлдә, Идел буе татарлары арасында фольклор әсәрләре, иске гореф-гадәтләр, традицияләр һәм тәҗрибәләр буенча тикшерүләр алып барганда, бу христиан төркиләрне дә (керәшеннәрне) истән чыгармаска кирәк.

Югарыда мөмкин булганча җентекләп сүз алып барылган рәхимсез дини басымнар, сәяси эзәрлекләүләр һәм икътисадый талаулар нәтиҗәсендә Казан төркиләренең шактыйлары ата-баба йортын калдырып китәргә мәҗбүр булган. Шулай итеп, алар башкорт өлкәсенә, ар кавеме урманлыкларына, Идел елгасының түбән агымына, Урал тауларына һәм аръягына, Көнбатыш Себергә, казакъ-кыргыз далаларына һәм соңрак Төркестан һәм Җидесу өлкәләренә җәелгәннән җәелә барганнар. Казан-йортта урнашкан бу басымнар, изүләр һәм талаулар аркасында бары тик татарлар гына түгел, мөселман түгел чуваш төркиләре дә, фин кавемнәреннән чирмешләр, арлар һәм мордваларның да бер бүлеге үз нигезләреннән аерылырга мәҗбүр булганнар. Башкорт иленә сыенган татарлардан, ар һәм чирмешләрдән ул өлкәдә «типтәр» исемле яңа бер сыйныф барлыкка килә. Бу аларның этник булмаган җыйма исемнәре. Ар (вотяк) өлкәсенә качып киткән казанлыларның бер өлеше көчләп чукындырылудан анда да котыла алмыйлар. Бүген Вятка өлкәсе Глазов урынчылыгында яшәгән һәм ар телендә сөйләшкән «бисермән» дип йөртелгән кечкенә бер төркем анда көчләп православиегә күчерелгән качак казанлылар булырга тиеш дигән фикер бар. Хәтта бисерман сүзенең «басурман» сүзеннән, ә ул сүзнең исә «мөселман» дигәннән үзгәртелгән булуы ачык.

XVIII гасырда, заманыбыздагы Америкага һәм Австралиягә күчүләр кебек, билгеле бер план белән, хәтта хөкүмәт белән килешенеп күченүләр дә булган. Мәсәлән, бүгенге, Оренбург Каргалысына нигез салган Сәет ага Хаялинның 1750 елда Казан өлкәсеннән 200 гаилә күчерүе менә бу төргә карый. Бу 200 гаилә, императрица Елизавета заманында үзләренә киң җирләр бирелү, гаскәр хезмәтенә алынмау, диннәренә кагылмау кебек шартларны хөкүмәткә кабул иттергәннән соң, Оренбург янындагы Сакмар суы ярларына күчәргә риза булалар. Бу татарларны ул җирләргә мондый кулай шартларны кабул итеп күчерүендә хөкүмәтнең дә, әлбәттә, кайбер сәяси һәм икътисадый максатлары бар иде. Ягъни мәсәлән, хөкүмәт бу казанлыларның анда яхшы колонизатор булачакларын күз алдында тотып, казакъ-кыргыз далалары һәм Төркестан белән алыш-биреш эшләрендә файдалы арадашчы булачакларын да өмет итә иде. Дөрестән дә, эш хөкүмәт өмет иткәнчә барып чыга. Бөек урыс революциясенә кадәр ун мең халкы булган Каргалыга урысларны кабул итмәгәннәр, шуңа күрә анда аптека һәм хастаханә дә ачыла алмаган. Авыл Оренбургның төньягында, Сакмар елгасы ярында шәһәрдән 18 чакрым ераклыкта урнашкан. Авылның бер ягы Каргалы инешнең ярларына тоташканга, авыл да шул исемдә аталган. Урыс һәм Европа карталарында исә ул Сәет бистәсе дип йөртелә.

Каргалы мөһаҗирләре турында тарихчы Н. Фирсов шул сүзләрне яза: «Алар монда бу өлкәләр өчен бик кирәк булган тырышлыкны алып килделәр. Рәсәйнең Төркестан белән сәүдә мөнәсәбәтләрендә беренче дәрәҗәдәге оештыручылар булдылар; алар, бик җитди рәвештә алыш-биреш өлкәсендә шөгыльләнү белән бергә, үзләренә бирелгән җирләрне эшкәртүдә дә зур тырышлык күрсәттеләр. Хәтта мамык вә дөге игү тәҗрибәләре дә булды; халкының тырышлыгы аркасында бу яңа татар йорты баеды». 1796 елда Каргалыда булган сәяхәтче Паллас та аны мактап телгә ала һәм халкының бай булуы турында сөйли. Андагы өйләрнең һәрберсенең таш нигезгә корылган булуын, өйләрнең һәммәсендә икешәр яки күбрәк бүлмәләр булуын яза.

Әмма Каргалы мөһаҗирләренең муллык эчендә яшәүләренә капма-каршы буларак, аларның Идел буендагы — төп Казан төбәгендәге кардәшләре хәерчелектә көн итәләр иде. Моны Казан өлкәсендә яшәгән халыкның Пугачев фетнәсенә кадәрге аяныч хәлләре ачык күрсәтә. Туган җирләрендә фәкыйрьлек арткан саен, бу төркиләрнең үзәктән чит җирләргә таба агылуы һәм җәелүе дә арта. Пугачев фетнәсе бастырылган вакытларда да бик күп халык төрле җирләргә качып китә. Бу качакларның үз туган илләренә кире әйләнеп кайтулары бик сирәк хәл.

Икенче Екатерина көннәрендә, югарыда да әйтеп үтелгәнчә, казакъ далалары чикләрендәге яңа калаларда мәчетләр төзелеп, казакълар да бу кала-шәһәрләргә тартыла башлагач, гаскәри максатларда төзелгән калалар куркынычсыз сәүдә итү җирләренә әйләнгәч, бик күп казанлы бәхет эзләп бу яңа шәһәрләргә күчеп китә. Соңыннан Рәсәй тарафыннан янадан-яңа төркиләр яшәгән өлкәләр басып алынуы, туган җирләрендә кысу-изү астында булган казанлыларга сәүдә һәм үз промышленностен үстерү өчен киң мөмкинлекләр ача иде. Менә шундый

мәҗбүри һәм ихтыяри мөһаҗирлекләр казанлыларнын көньяк-көнчыгыш Европанын һәм төньяк-көнбатыш Азиянең бөтен кинлекләренә таралуларына китерә. Ул җирләрдәге яңа шәһәрләрдә сәүдә белән шөгыльләнгән казанлылардан башка, Урал тауларынын аръягында, казакъ далаларында, Себернең ерак почмакларында һәм Җидесу өлкәсендә авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнүгә күчкән Казан татарлары да юк түгел иде.

Менә бу сәбәпләр аркасында төп Казан йортында төрки халык шактый кими һәм сирәкләнә. Әмма эш бары тик географик таралыш белән генә бетмичә, илнең иҗтимагый эшләре дә какшый, икътисадый көчләре дә кими. Югарыда язылганнардан күренгәнчә, XVIII гасырның ахырларында да Идел төбәгендә тәртип урнашмаган иде. Урыс чиновниклары белән священникларынын дингә һәм дини оешмаларга рәхимсез һөҗүмнәре китереп чыгарган буталчыклыклардан тыш, Мәскәүнең начар идарә итүе нәтиҗәсендә дә бөтен мәмләкәттә хисапсыз талаучылар, разбойниклар барлыкка килә. Боларның иң күп тупланган җире дә Идел төбәге була. Боларның талауларыннан халык зар-интизар яши. Бер-бер артлы булып торган һәм, югарыда да әйтелгәнчә, Урта Идел төбәгенә нык бәйләнештәге башкорт фетнәләре һәм ике ел дәвам иткән Пугачев восстаниесе бөтен XVIII гасыр буенча Идел һәм Урал җирләрендәге тынычлыкның астын өскә китерә.

Тәртип булмаган җирдә халыкның тынычлыгын һәм муллыгын кайгыртучы эшләр эшләнә алмавы табигый. Мәгълүм ки, XVIII гасырда урыс хөкемдарлары әле сугышлар да алып баралар иде бит. Бу сугышлар аркасында да халык кырыла, икътисадый эшләр чыгырыннан чыга һәм халык саны кими иде. Шуның өстенә әле мөселманнар «иман ясагын» яки «мөселман булып калу түләвен» дә түләргә тиешләр иде. Халык җирен эшкәртә алмый, авыр ясаклар түли-түли, өстәмә хезмәтләр үти-үти тәмам хәерчеләнә. Халык мескенләнә, өметсезләнә. Бердәнбер кәҗәсенең ясак түләр өчен сатылу ихтималыннан куркып дерелдәгән, тормыш авырлыгы аркасында үз йортыннан бизгән бер халыкның уку-язу турында уйлавы, мәктәп-мәдрәсәләр тотуы, басма китаплар күбәйтүе мөмкин эшме? Менә шул кимчелекләр сәбәпле бу халык рухи караңгылыкка тала, озак еллар матди һәм рухи хәерчелек кичерә һәм хәтта үз тарихын да оныта башлый.

Шуны да искә алырга кирәк, Идел елгасының Каспий диңгезенә койган урыны һәм Җаек елгасы үзәннәре урыслар кулына күчкәч, төньяк мөселман төркиләре башка ислам өлкәләреннән бөтенләй аерылып калалар. Читтәге мөселманнар белән бәйләнештә тора алмыйлар, алардан дин һәм гыйлем куәте дә, ярдәм дә ала алмыйлар, аларга кайгыларын белдерә алмыйлар. Ислам авторларының яхшы һәм кыйммәтле китаплары бу мәмләкәткә килеп җитми, үткән заманнарда килгәннәре исә урыс вәхшилеге һәм священниклар басымы астында юк ителә. Шул сәбәпле муллаларның кулында яхшы, дөрес дини китаплар да булмый. Муллалар тиешле дини белем алыр өчен кирәкле дәрәҗәдә гарәп телен белмиләр иде һәм аны ул дәвердә, ул мәмләкәттә өйрәнергә мөмкинлек тә юк иде. Шул сәбәпле ул дәвер муллалары, башлыча, түбән белемле, тар фикерле иделәр. Ләкин аларда иман сау иде, үзләре батыр, нык кешеләр иде. Моннан тыш үзләрендә тугры юл күрсәтү осталыгы булганлыгы да аңлашыла. Кыскасы, ул чорда татарлар урыслар белән уратып алынган хәлдә, динен вә мохитын саклау һәм азат итү эшендә бары тик үз көчләре белән генә калган, һәм үз эчләрендә кайнарга хөкем ителгәннәр иде. Шулай итеп, бу халык бер ялгызы үз иман һәм намус көче белән рәхимсез урыс изүенә, священник-миссионер һөҗүмнәренә каршы ике йөз ел буе көрәшү авырлыгын күтәреп кала. Шул шәфкатьсез көрәш нәтиҗәсендә халык бөтенләй үк юк булмаса да, XIX гасырга соң дәрәҗәдә хәлсезләнгән, көчсезләнгән бер хәлдә керә.

XVIII гасырның ахырларына таба урыс хөкүмәтенең мөселман төркиләргә карата сәясәте бераз яхшыра һәм татарлар ике гасыр дәвам иткән җимергеч һәм каһәрләүче сәясәт төшергән хәлдән котылу чараларын эзли башлыйлар. Нәкъ шул вакытларда Идел һәм Урал өлкәсе белән Төркестан арасында сәүдә кәрваннары да еш йөрер иде.

Оренбург, Орск, Троицк кала-шәһәрләренә күчкән һәм хәтта Казанның үзендә дә яшәгән татарлар, XIX гасырның беренче чирегендә бу Төркестан белән сәүдә мөнәсәбәтләрендә җанлы һәм уңышлы эшчәнлек күрсәтәләр. Әледән-әле Казан өлкәсеннән шәкертләрне белем алу өчен Бохарага китерәләр иде. Ул дәвердә Бохарада чын мәгънәсендәге гыйлем һәм мәгърифәт хөкем сөргән дип раслый алмыйбыз. Шуның белән бергә, анда бер төркем зур мәдрәсәләр һәм шактый мөдәррис-хәлфәләр һәм, үзләре хәерче хәлдә булса да, бай китапханәләр бар иде. Ул көннәрдә сәяси һәм икътисади хәлләр шундый бер рәвештә иде ки,

казанлы татарлар өчен рухи һәм дини мәнфәгатьләрен канәгатьләндерүнең тик бер юлы кала. Ул да булса — Төркестанга мөрәҗәгать итү юлы иде. Казанлы шәкертләрнең белем алу өчен Бохарага сәяхәтләре XVIII гасырның соңгы яртысы урталарында — Икенче Екатерина дәверендә, Пугачев фетнәсе бастырылганнан соң башланган булырга тиеш. Шулай итеп, бу сәяхәт һәм сәфәрләрнең башлануы өчен бөтен Төркестанның урыслар тарафыннан басып алынуы да, Бохараның Рәсәйгә кушылуы да кирәк булмаган. (Пугачев фетнәсе 1775 елда бастырылган, Бохара әмирлеге исә 1868 елда Рәсәйнең вассалы булган.) Казанлы шәкертләрнең Бохара өлкәсенә белем эстәр өчен сәфәрләре бөтен XIX гасыр буенча дәвам иткән.

Шулай итеп, XVIII гасырның ахыры — XIX гасырның башы һәм аннан соңгы чорны Казан төркиләре өчен икътисадый һәм мәдәни күтәрелеш дәвере дип билгели алабыз. Чөнки бу дәвердә бик эшлекле сәүдәгәрләр барлыкка килә һәм болар урыс сәүдәгәрләре белән ярыша башлыйлар. Казакъ-кыргыз далалары һәм Төркестан белән булган сәүдә мөнәсәбәтләрендә казан татарлары, тел һәм юл белгәнлектән, гаять мөһим роль уйныйлар. XVIII гасырда ук инде Казан шәһәрендә татарларның шактый сабын, шәм һәм тире эшкәртү, кытат дип аталган тукыма һәм саржа туку фабрикалары барлыкка килә. Казан тирәсендәге зур авылларда һәм башкорт җирләрендә дә мондый эшханәләр ачыла. Шул ук гасырда Казан төркиләре арасында шактый зур байлыкка ия булган капитал хуҗалары күренә башлый. Икенче яктан, Бохарада еллар буе укып белем алган казанлы яшьләр үз мәмләкәтләренә кайталар. Боларның гыйлем һәм зирәклелек туплаганнары, әлеге бай сәүдәгәрләр арасында ышаныч казанып, шулар ярдәмендә мәдрәсәләр ача вә шәкертләр туплый, анда Бохара ысулы белән дәрес укыта башлыйлар. Казан һәм Урал өлкәсендә XIX гасыр буенча мондый мәдрәсәләр күбәйгәннән күбәя. Казан, Оренбург, Троицк, Каргалы кебек мөһим шәһәр һәм бистәләрдә берничә зур мәдрәсә ачыла. Кышкар, Мәчкәрә, Сатыш, Эстәрлебаш, Тымытык, Чакмак, Каран, Чәршеле кебек зур авыллардагы мәдрәсәләрнең шөһрәте дә әлеге шәһәр һәм бистә мәдрәсәләренекеннән ким булмый. Менә бу хәл Идел һәм Урал өлкәсендә бик алдынгы бер яңалык, хәтта бер төрле фикри күтәрелеш була. Чөнки иске «Шурут әс-Сәлах», «Устуваны», «Фәүзел нәҗат», «Төхвәтел-мөлүк...» һәм башкалардан ары китә алмаган, белемнәре түбән булган муллалар урынына бу чорда инде «Кәлам» (Мөселман дини тәгълимәтләре) һәм мантыйк укыган, фәлсәфә фәнен өйрәнгән, кайсыбер четерекле мәсьәләләрнең «кылын кырыкка ярган», табигатьтән өстен көчләр турында, рух дөньясы һәм теге дөнья хакында белем белән башларын тутырган, шактый гына назария (теория) һәм фаразиянең әле бер ягыннан, әле икенче ягыннан йолыккалаган һәм аларны әле бер төрле, әле икенче төрле аңлатырга тырышкан, кыскасы, Бохара «схоластикасы»ның бөтен нечкәлекләре белән миләрен чатнаткан, «тау кебек зур чалмалы, диңгез кебек киң дәгъвалы» дамеллалар күбәя. Бохарада белем алганнан соң Казан өлкәсенә кире кайткан кайбер «дамеллалар» (Шиһабетдин Мәрҗани, «Вафиятел-әсляф вә тәхиятел-әхлаф») күп җирләрдә мәдрәсәләр ачып, йөзләрчә яшьләрне озак еллар буе белем туплауга җәлеп итә. Шәкертләр үзара гына түгел, Бохарадан килгән укытучылар белән дә сүз көрәштерәләр һәм бәхәсләргә керәләр иде. Һәртөрле шәрехләрне, аңлатмаларны үзләренчә анализлау, чагыштырулар белән мәшгульләр.

Һәм кышкы озын кичләрдә, зәгыйфь шәм яктысында күп итеп китап укыйлар иде. Бер шәһәр яки бистә эчендәге бер мәдрәсәдән икенчесенә генә түгел, башка шәһәр һәм бистәләрдәге мәдрәсәләргә дә төркем-төркем тупланып сүз ярышларына баралар иде.

Мондый хәл Болгар ханлыгы дәверендә булганмы? Мөстәкыйль Казан дәверендә бар идеме? Әлбәттә. Ә Казан җимерелгәннән соң, XVII һәм XVIII гасырларда? Һич юк. Шул хәлдә мондый схоластика өлкәсендә булса да киң белемле хәлфә-укытучыларның күбәюе, хисапсыз санда мәдрәсәләрнең ачылуы һәм бу мәдрәсәләрдә меңнәрчә татар яшьләренең җыелып белем алу белән шөгыльләнүе Казан илендә ул көнгә кадәр күрелмәгән бер яңалык, үзгәреш һәм бертөрле фикер күтәрелеше булмыйча ни булсын? Дөресен әйткәндә, бу мәдрәсәләр тәэсирендә Казан төбәге җәмгыяте танымаслык дәрәҗәдә үзгәрә һәм җанлана: Идел буенда сүнеп барган ислам мәдәнияте шушы мәдрәсәләр йогынтысы астында терелә, халыкта укый-яза белүчеләр күбәя башлый һәм галимнәр сыйныфы, ягъни заманына күрә бер зыялылар катламы барлыкка килә.

Чын дөреслектә, XIX гасырда Казанда урысларның Европа тибындагы университеты булганда татар-төркиләрнең бары тик Бохара үрнәгендәге мәдрәсәләре генә бар иде әле. Урыс студенты Көнбатышның алга киткән фәннәрен өйрәнә,

безнекеләр исә схоластика белән метафизика тирәсендә маташалар иде. Бу аерма, әлбәттә, безнең файдага түгел иде. Әмма, бер яктан, ул чорда бөтен ислам дөньясының диярлек фикер хәяте якынча бер үк дәрәҗәдә булды: икенче яктан, хаким милләтнең XIX гасырдагы фикер хәяте белән чагыштырганда, безнең бу артталыгыбыз, матди һәм рухи хәерчелектә яшәвебез XVII һәм өлешчә XVIII гасырдагы хәлебез белән чагыштырганда зур бер алга китеш һәм үсеш булып санала ала иде. Моннан тыш, Бохара үрнәгендәге бу мәдрәсәләр дәвере, киләчәктә бәхәс темасы булачак «Ысулы җәдид дәвере» дип аталган яна чор өчен дә бер төрле әзерлек булган. Һәм бу дәвернең бөтен җәмгыять эшлеклеләре диярлек (укытучылар, әдипләр, газетачылар һ. б.) бу мәдрәсәләрдә белем алган кешеләр арасыннан чыккан.

Бу мәдрәсәләрнең шактый бай үз тарихлары бар һәм бу тарихның күп мәгълүматлары Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар...» китабының икенче кисәгендә бирелгән. Казый Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар» томнары исә Мәрҗани хезмәтенә кыйммәтле бер өстәмә булып тора. Болардан башка мөхәррир һәм мөгаллим Җамал Вәлидинең урысча «Татарларның укымышлылык һәм әдәбият тарихы очерклары» (Петроград, 1923) исемле әсәре белән Газиз Гобәйдулла һәм Гали Рәхимнең бергә язган «Татар әдәбияты тарихы» (Казан, 1923—1927) исемле хезмәтләрендә вә Габдрахман Сәгъдинең дә «Татар әдәбияты тарихы» (Казан, 1926) исемле бер томлык китабында моңа карата мәгълүматлар бар.

## X

### Яңа чор

XIX гасырның беренче яртысында, ниһаять, шәһәр һәм бистәләрдә татар буржуазиясе барлыкка килә, Бохара тибында гына булса да мәдрәсәләр күбәеп, фикер хәяте дә җанлана. Авыл халкы да дини эзәрлекләүләрдән һәм көчле икътисадый һөҗүмнәрдән азат була. Икътисадый тарлык һәм сәяси изү булса да, чынлыкта болар ул замандагы Рәсәйнең дәүләт режимыннан туган һәм бөтен рәсәйлеләр өчен дә уртак булган хәлләр иде.

Әмма шул ук вакытта, югарыда да күргәнебезчә, татарлар белем һәм фикер туплау максаты белән карашларын Көнбатышка түгел, Көнчыгышка таба борганнар иде. Бу хәл ислам традицияләренең бер дәвамы булып тору белән бергә, Идел һәм Урал буе өлкәләренең Көнбатыш дөньясыннан бик еракта булулары һәм арада бик калын бер «урыс дивары» барлыгына бәйле иде. Шул сәбәпле ул дөнья белән бәйләнешкә керү мөмкин түгел иде. Көнбатыш гыйлемен һәм фикерләрен төрки-татарлар бары тик урысларның арадашлыгы белән генә ала алалар иде. Ләкин, югарыда күрсәтелгән сәбәпләр аркасында, бу төркиләр урыслардан шулкадәр шикләнәләр иде ки, аңардан килгән һәр нәрсәгә шөбһә һәм курку күзе белән карыйлар иде. Шуңа күрә балаларын урысның заманча алдынгы мәктәпләренә бирү кая, хәтта, урыс гаиләләре белән аралашудан, шәһәр һәм бистәләрнең урыс мәхәлләләрендә яшәүдән, Европача өс киемнәре һәм баш киемнәре киюдән, өйләрдә яланбаш йөрүдән, ирләре озын чәч һәм мыек йортүдән, һәм хәтта урыс телен өйрәнүдән дә бик сакланалар иде. Күбесенчә, шәһәрләрдә мөселман төркиләрнең мәхәлләләре аерым булып, мәчетләр һәм мәдрәсәләр дә шунда урнашкан була иде. Шул сәбәпле сәүдәгәр белән һөнәрчеләр дә урысча бик начар сөйләшә. Урыс язуын кайбер яшьләр бары тик «адрес яза алырлык» кына өйрәнә иде. Сәүдәгәрләр күбрәк кәләпүш, калфак, сафьян читекләр, кәвешләр, башмаклар кебек «Азия» товарлары белән алыш-биреш итәләр иде. Төркестанда һәм башка ислам өлкәләрендәге кебек пәрәнҗә ябу гадәте булмаса да, хатын-кызларның ирләрдән йөз һәм тел яшерү кебек гадәтләре бар, әмма йорт-җирләре «хатын-кызлар ягы», «ирләр ягы» дип бүленми иде. Кыскасы, Казан төбәге мөселман төркиләре, XIX гасырның урталарына кадәр һәм хәтта аннан соң да урыс дөньясы эчендә аерым бер үзбаш «көнчыгыш кавем» буларак яшәүләрендә дәвам итәләр. Бу дәвердә урыслар да хөкүмәт тә моны шул рәвешле кабул итәләр иде. Рәсәй хөкүмәте ислам гыйбадәтханәләренә, көнчыгыш тибындагы мәдрәсәләргә бик канәгатьсез карый башлаган, аңа кадәрге урыс хөкүмәтләре кебек, мөселман төркиләрне иске ысуллар белән «агарту» омтылышларын ясамый иде, яңа, заманча ысуллар эзләп табу белән дә артык шөгыльләнми иде. Хәтта, әйтергә кирәк, аларның бу рәвешле «агартылу»ларын теләми дә иде. Бу хәл Николай Ильминский кебек миссионер һәм шул ук вакытта сәясәтче вә ориенталист телчеләрнең сүзләреннән дә аңлашыла. Бохара үрнәген-

дәге Казан мәдрәсәләреннән мөселман төркиләр өчен һичбер файда булмаячагын яхшы аңлаган Ильминский, татарлар караңгылык һәм артталыкта яшәүләрен дәвам итсеннәр өчен иске мәдрәсәләренә бәйле калулары кулайрак булуын, урысның заманча алдынгы мәктәпләрендә укуның исә, киресенчә, аларның аңнары уянуга, күзләре ачылуга ярдәм итәчәген әйтә, һәм, бу фикерен исбатлау өчен, бер-ике мисал да китерә.

Беренче мисал: Казанда чын Бохара үрнәге булган Күл буе мәдрәсәсендә күп еллар ислам гыйлеме өйрәнеп «икъмали нөсах» иткән Гәрәй Әхмәр углы, югарыда исеме бернича тапкыр телгә алынган миссионер священник Е. Малов белән әңгәмәләре нәтиҗәсендә православиегә күчеп, мөселман-төрки мохиттан аерылган. Икенче мисал: беренчесенә капма-каршы буларак, Рәсәй үзәгендәге Пенза шәһәрендә урыс гимназиясендә укыган Муса Акъегетзадәнең төрки милли хисе уянып, шул сәбәптән ул урыс мәктәбен бетерер-бетермәс үк Казанга, аннан соң Истанбулга күчеп киткән һәм анда төрки дөньяга һәм исламга хезмәт итә башлаган.

Чынлыкта бу мәдрәсәләрдә кешегә тормыш итүдә ярдәм кыла торган гуманитар гыйлемнәрнең эзе дә юк иде. Мәктәп баласының азмы-күпме этник асылын, килеп чыгышын, үз халкының тарихын өйрәнүенә хезмәт итәрдәй һичбер мәгълүмат бирелми иде. Һичбер тел, хәтта яхшы бер укытучы булыр өчен зарури булган гарәп теле дә адәм рәтле итеп укытылмый иде. Төрки телнең дәрес буларак укытылуы турында сүз дә алып барылмый. Югарыда кайбер уңай яклары да атап үтелгән бу мәдрәсәләрдә, чынлыкта, шәкертләр дөньяда кешегә яшәү теләген хис итеп белемгә омтылу урынына, бернинди максатсыз, бернигә дә исәп тотмыйча, заманасы күптән үткән, урта гасырлардан калган бер төркем кирәксез һәм мәгънәсез нәрсәләр белән башларын тутыра иделәр.

Татарлар ул дәвердә урыс теленә әһәмият бирми, урыс уку йортларына бармый, шуңа күрә араларында заманынча зыялылар юк дияр дәрәҗәдә аз иде. Урыс гимназиясендә укыганнан соң урыс югары уку йортларында белем алып, хокукчы (юрист), табиб, мөһәндис (инженер) һ. б. булып эшләгән берән-сәрән татар белгечләр башлыча борынгы аксөяк токымына караган морзалар сыйныфыннан иделәр. Алар киң төрки катламнан ераклашкан, милләттәшләренең иҗтимагый мәсьәләләре белән әллә ни бәйләнешләре булмаган, күбесенчә урыслар белән аралашып, гаилә эчендә урысча сөйләшкән бер төркем кешеләр иде. Милләттәшләре дә аларны бик өнәп бетермәс, алар белән бәйләнештә тормас иделәр һәм аларга, ничектер, юлдан язган, үз төркеменнән аерылып, чит төркемгә кушылган, адашкан бер месккенгә караган кебек карыйлар иде.

1804 елда, димәк, император Беренче Александр заманында, Казанда урыс университеты ачыла. Бу — Рәсәйдә, Мәскәү университетыннан соң, вакыт ягыннан икенче университет иде. Бу хәл ул замандагы урыс хөкүмәтенең Идел-Урал өлкәсенә никадәр әһәмият биргәнлеген күрсәтүе белән дә игътибарга лаек. Урыс чыганакларыннан аңлашылганча, ул вакытларда Казан мәгариф системасы Рәсәйнең көнчыгыш өлкәләргә булган ихтыяҗына җавап бирерлек, дөресрәге, «мөселманнар белән аңлашу һәм килешү» сәясәте зарурлыгына туры килерлек бер сурәттә оештырылган иде. Казан университеты да бу өлкәләрнең җирле халкы белән бергә килеп урнашкан чит кавем халкы, ягъни урыслар арасында бер «бәйләүче чара» вазифасын үтәячәк иде.

Университет башта кечерәк күләмдә, югарыда телгә алынган беренче гимназия бинасында ачыла. Беренче профессорларның күбесе чит илләрдән, төгәлрәк әйткәндә, алманнар иде. Болар арасында Бартельс, Фукс, Х. Фраен аерылып торалар. «Яңа сәясәт» таләп иткәнгә, 1836 елда Оренбург мөселман яшьләреннән 20 кешенең Казанда табиблык гыйлеменә өйрәтеләчәгенә карар бирелә. Ул вакытларда Казан университетында Шәрекъ телләрен укыту да кочәя. Болардан тыш, университет каршында Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте дә оеша. Аның кайбер әгъзалары Болгар һәм Казан (ханлыкларының) үткәне, борынгы истәлекләре, этнологиясе, этнографиясе белән дә шөгыльләнәләр. Бу җәһәттән Н. Фирсов, Шпилевский, Березин, Катановларны атарга мөмкин.

XIX гасыр башында ачылган Казан университетының гыйлем, мәдәният һәм фикер үсешендә уйнаган роле, һәрхәлдә, кечкенә булмаган. Университетның медицина, хокук, математика, тарих-филология факультетлары була. Башта биредә бер Шәрекъ телләре курсы да эшли. Әзәрбайҗан төркиләреннән Дәрбәнт шәһәреннән хаҗи Касыйм углы Мөхәммәтгали Кәзимбәк, 1823 елда христианлыкны кабул итеп Александр исемен алганнан соң, Казан университетында төрки һәм фарсы телләрен укыта һәм аның православиягә күчкән ир туганы Габдесаттар да биредә төрки телләр укытучысы булып эшли. Казанлы Ибраһим Хәлфә

углы (Хәлфин) исә 1812 елда ук бу университетка төрки телләр укытучысы итеп билгеләнгән була һәм алдагы елда Шәрекъ әдәбияты адьюнктлыгына сайланыла һәм әле генә исеме телгә алынган алман Фраен белән бергә эшли башлый. И. Хәлфин, студентларына бер дәреслек итеп, 1819 елда «Әхвале Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» исемле бер әсәр дә бастыра. Моннан тыш XX гасырның башларында бу университетта Себернең сагай төркиләреннән Катанов исемле бер төрки телләр профессоры бар иде ки, дине христиан иде һәм дә урыслашкан иде, тик кыяфәте белән алтайлы иде. (Беренче Бөтендөнья сугышы алдыннан Катановның бай китапханәсе Төркия хөкүмәте тарафыннан сатып алынды. Шул китап-журналлар Истанбул университеты «Төркият институты» китапханәсенең нигезен тәшкил иттеләр. Ул көннәрдә Истанбулда Мәгариф эшләре мөдире булган Наил бәй исемле бер кешенең һәм асылы белән безнең ватандашыбыз булган мәрхүм Гомәр Тереголның бу китапханәне сатып алу йомышы белән Казанга килүләрен хәтерлим.)

XIX гасырның урталарына кадәр университет мохитендәге гыйлем һәм фикер хәрәкәтләре бу өлкәдә Бохара (акыл) юнәлеше белән яшәгән Казан мөселман төркиләре арасына бик үтеп кермәгән. Университетта татар балаларыннан бик аз кеше укыган, аларның да күбесе асылы белән Казанлы түгел иде. Казан университеты 100 еллык хәятендә татар-төркиләрдән нибарысы 9—10 табиб, 3—4 хокукчы һәм телче чыгарган. Аларның да мөселман төрки иҗтимагый хәятендә теге яки бу төрле роль уйнаган булулары мәгълүм түгел.

Шуның белән бергә, XIX гасырның соңгы яртысында, ягъни университет оештырылып ярты гасыр үткәч, университет мохитендәге гыйльми һәм мәдәни хезмәтләр һәм фикер хәрәкәтләре Болак каналының аръягындагы «азияви» хәяттә яшәгән Казан төркиләре арасында да җинелчә генә булса да чагылыш таба. Бу чагылыш нәтиҗәсе буларак, «Болак аръягы» мохитендә тәрбияләнгән, Бохара үрнәгендәге мәдрәсәләрдә белем алган кайбер кешеләр урыс телен өйрәнә, төрле темаларга караган урысча әсәрләр укый. «Болак»ның мөселман мәхәлләсе тарафыннан караганда, аргы яктагы фикер хәрәкәтләре белән, гыйльми һәм мәдәни хәят белән бәйләнешкә керә башлыйлар. Акыл-ан юнәлеше үзгәрүдә моның зур тәэсире була. Мондый кешеләрнен иң танылганы — Каюм Насыйри. Шуңа күрә бу язучы һәм фикер иясе хакында бераз мәгълүмат бирү файдалы булачак.

Яңа дәвернең алдынгыларыннан, Казан төркиләренең фикер һәм мәдәни хәятендәге яңа дәвернең алдынгыларыннан берсе — һичшиксез, язучы һәм галим Каюм Насыйри.

Аңа алдынгы урын казандырган эш — язучылыгы һәм тарихи эзләнү-өйрәнү эшчәнлеге була. Урыс гыйлем һәм фикер иярәре мохите белән бәйләнеше нәтиҗәсендә яңача фикерләү, яңача уй йөртү, яңача тормыш итүгә ия. Яңа ысуллар кулланды, Казан татарлары телендә календарьләр, әсәрләр язып бастыра башлады. Казан төркичәсендә китап язу әле яп-яңа бер эш иде. Мондый эшкә керешү гаеп һәм гөнаһ санала иде. Мондый язучының милләттәшләре тарафыннан ниндидер бер хуплау һәм яклау табуы мөмкин түгел иде. «Урам теле»ндә язылган андый әсәрләрне бастыру да гаять тә авыр иде. Шуларга да карамастан, Каюм Насыйри искиткеч бер көч белән үз төрки телендә әсәрләр яза, соңгы сулышына кадәр зур кыюлык һәм түземлек белән юлын дәвам итә... Һәм үз акчасына бастыра тора. Укыган, хуп күргән кеше бармы, китаплар сатыламы? Ул боларга бөтенләй әһәмият бирми, баш күтәрмичә, ял итмичә, эссене-суыкны белмичә яза да яза. Чөнки аны «Аллаһ язар өчен яраткан иде»...

Урысчадан гына түгел, гарәпчәдән, госманлы төркичәдән дә әсәрләр тәрҗемә итте. Бу тәрҗемәләрнең кайберләренең халыкны татарча укуга тарту максаты белән эшләнүе дә мәгълүм һәм Насыйриның оригинальлеге бу гына да түгел. Ул... үзен бер вәкиле санаган Казан татарларының бары тик «мөселман» гына булмыйча, бер милләт тә булуына инана. Бу милләтнең үз кагыйдәләре, үзенчәлекләре, нечкәлекләре булган бер теле бар: бу халыкның халык әдәбияты, мифләре, фольклоры бар. Болардан тыш, бу төрки кавемнең тагын дөньядагы үзгәрешләрдән, яңа фәннәрдән һәм алдынгы фикерләрдән дә хәбәрдар булуы кирәк. Һәм, ниһаять, бу кавем дәүләтнең рәсми телен дә өйрәнергә тиеш. Янәшәсендә яшәгән урыс кавемен дә танып белергә, мәмләкәт хәлләреннән һәм дәүләтнең канунннарыннан хәбәрсез яшәмәскә тиеш... Казан төркичәсенең грамматикасын яза, дөрес язылыш һәм җөмлә төзелеше кагыйдәләрен билгеләргә тырыша ул, сүзлек төзи һәм боларны язганда төрки тамырга нигезләнеп атамалар уйлап таба: зур бер ихтыяр көче белән Казан татарларының фольклор әсәрләрен җыя һәм бастыра. Татарлар өчен урыс теле грамматикасын һәм

сүзлеген төзеп бастыра. Урыс тарихына караган, математика, табигать фәннәре, тарих, география, анатомия, физиология, педагогика, физик тәрбия, ботаника, хәтта аш-су сәнгате буенча да әсәрләр яза.

К. Насыйри төрки дөньяның иң күп язган һәм язганнарын бастырып таратуга ирешкән бер шәхесе. Басылган әсәрләренең саны гына да кырыктан артык булып (календарьләрен дә кертеп), боларның бит саны дүрт меңгә җитә.

К. Насыйри татар теле дигән Казан төркичәсенең мөстәкыйль бер тел булуын исбат итеп, әсәрләрен бу телдә язарга тырышса да, госманлы төрек вә чагатай китап телләренең тәэсиреннән дә котыла алмаган. Һәм татар язу теленең гарәп вә фарсы телләре ярдәменә мохтаҗ булуы белән килешкән...

«Кавагыйде китабәт» исемле әсәрендә дә шундый сүзләр яза: «Үз телендәге сүзләрне тикшерми торып, башка телдән сүз алу, кирәк сөйләмдә, кирәк язуда ялгыш бер эш санала».

Болардан аңлашылганча, Насыйриның татар теле турындагы фикерен кыскача гына шул рәвешле әйтергә мөмкин: 1) татарча — чагатай теленең бер тармагы һәм бу телгә бик күп хосуслардан туры килә. 2) Моның белән бергә, үзенә хас кагыйдәләре һәм ысуллары бар. 3) Сүзләргә бик бай булмаганга, гарәп һәм фарсы телләренең ярдәменә мохтаҗ бер хәлдә. 4) Сайрак урыннары бу телләрдән сүзләр һәм гыйбарәләр алып тутырылган очракта, татар теле башка телләрдән һич тә түбән түгел, хәтта кайбер хосусларда, бигрәк тә фигыльләр өлкәсендә, алар белән чагыштырганда өстенрәк тә. 5) Башка телләрдән бары тик татар теленең үзендә булмаган сүзләр генә алынырга тиеш.

Әмма биредә фикер ялгышлыгы ачык күренә. Беренчедән, татарча дип аталган халык сөйләм теле чагатай теленең бер тармагы була алмас, чөнки чагатай теле сөйләм теле булмыйча, бер ясалма язу теле, ягъни китап теле.

Без санаган бүлекләрнең өченчесенә килгәндә, бер тел хакында һичбер шартсыз фәкыйрь-ярлы дип, яисә бай дип хөкем йөртү дөрес түгел. Бер кавемнең теле мәдәнилек дәрәҗәсе белән бәйләнгән була. Мәдәнилек ягыннан артта калган кавемнең теле дә артта калган һәм ярлы була: мәдәниятта югары күтәрелсә һәм алга китсә, теле дә алга таба үсә һәм байый. Ягъни культура үскән саен яңа төшенчәләр күбәя һәм аларны әйтеп бирү өчен яңа сүзләргә ихтыяҗ туа. Менә бу яңа сүзләрне чит телләрдән алу, ягъни әзергә-хәзер тору мөмкин булган кебек, аларны үз теленнең тамырларыннан ясау, яңа сүзләр барлыкка китерү дә мөмкин. Беренче юлдан барганда телгә, бигрәк тә язу теленә башка телләрдән сүзләр кереп тула: икенче чарага мөрәҗәгать иткәндә исә тел, бигрәк тә әдәби тел, үз нигезендә ясалган яңа сүзләргә байый... К. Насыйри да үзе язган грамматика, математика һәм география китапларында төрки тамыр сүзләрдән яңа атамалар ясау тәҗрибәсенә омтылган. Татар теленә караган ике томлык «Ләһҗәи татари» әсәрен төзегән. Әмма Насыйриның бу сүзлегендә татар теленнән артык күп материал бирелмәгән. Ул Әхмәт Вәфик пашаның «Ләһҗәи госмани» үрнәгендә ашыгып язылган бер әсәргә охшаган һәм ул бер татар сөйләме сүзлеге булудан бигрәк, уйлап чыгарылган, эшкәртелгән бер «Казан китап теле сүзлеге» дип атала ала.

К. Насыйри... әсәрләрендә татарчаны кулланырга тырышса да, Җамал Вәлиди дә билгеләп үткәнчә, кирәк сүзлек ягыннан, кирәк стиль ягыннан булсын, чагатай һәм госманлы телләре тәэсиреннән котыла алмаган...

К. Насыйриның сүнмәс көч һәм какшамас ныклык белән туплаган татар фольклоры материаллары «Кырык бакча», зур күләмле «Фәвакиһелҗәләса» әсәрләре белән «Казан календаре» исемендәге елнамәләрендә урнашкан. Болардан фәкать «Фәвакиһелҗәләса» да гына да 28 табышмак, 118 җыр, «Сәламнамә», «Чәй бәете», «Унмаган килен» дип аталган өч бәет һәм 315 мәкаль бар.

К. Насыйриның татар фольклоры өлкәсендә эзләнү-өйрәнүләре, әлбәттә, университет гыйлем һәм фикер мохитында да чагылыш тапмый калмаган. Шулай итеп, Насыйри бу хезмәтләре буенча университет янындагы «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте» әгъзалыгына кабул ителгән һәм бу җәмгыять җыентыгында аның туплаган кайбер татар халык әдәбияты үрнәкләре басылган...

1880 елда «Урыс география җәмгыяте» җыентыгының этнография бүлегендә (6 т., 241—270 б.б.) Насыйриның «Казан татарларының халык ышанулары һәм гореф-гадәтләре» исемен йөрткән әһәмиятле бер әсәре дөнья күргән. Ул борынгы төркиләрнең табынуларын өйрәнүчеләр өчен мөһим бер материал булып тора.

Югарыда да искә алынганча, Насыйри календарьлар төзү белән шөгыльләнгән. 1871 елдан 1897 елга кадәр (өч елны исәпкә алмаганда) «Казан календаре» исеме белән елнамәләр чыгарган. Бу елнамәләр, һәр ел кабатланган гадәти календарь мәгълүматларыннан тыш, төрле әдәби, тарихи һәм иҗтимагый

язмаларны да колачлап, бер альманах яисә журнал рәвешен алган. Насыйри бу календарьларында кайбер милли, тарихи риваятьләрне, җырларны да нәшер итүе белән бергә, XVIII гасырга һәм XIX гасыр башларына караган милли тарих материалларын биреп, азмы-күпме тарихка да хезмәт иткән. Һәр өлкәдә каләм тибрәткән бу мөхәррир, кин халык массаларын укуга җәлеп итү һәм дөньяви хәбәрләрне халык арасына җәелдерү юлында да, асылы белән төркияле Әхмәт Мидхәт әфәнде кебек, бик зур хезмәт күрсәткән. К. Насыйри шул ук заманда бер тәрбияче-педагог та булган: үзе шәхсән укытучылык иткән, шактый күләмдә мәктәп дәреслекләре язган.

Шул ук дәвердә каләм тотып, кайбер әдәби һәм тәрҗемә әсәрләр чыгарган башка кайберәүләр дә бар иде. Бу вакытта календарьлар бастырган мулла Шиһап Рәхмәтулланы (Рәхмәтуллин), тәрҗемәләр белән шөгыльләнгән Фатих Халидине, Габдулла Фәезханны, Габдрахман Ильясины искә алу урынлы булыр. Болардан Г. Фәезхан «Татар теленә гыйльми сарыф» (1887) исемле кечкенә бер грамматика һәм Рәсәй төркиләренең иҗтимагый һәм икътисади хәлләренә багышланган «Мухаррикол әфкяр» («Фикерләр этәргече», 1893) исемле бер китап та бастырган. Ильяси исә татарлар арасында беренче тапкыр «Бичара кыз» исемле 4 пәрдәлек бер драма әсәре язган. Бу язучының антиподы булган Ф. Халиди «Рәдде бичара кыз» исемле бер пьеса бастырган.

К. Насыйри Казанда урыс гыйлем һәм фикер иясе кешеләре белән аралашып сөйләшүләре нәтиҗәсендә заманының алдынгы фикер агымнары белән һәм яңа гыйльми ысуллар белән танышлык булдырганда, нәкъ XIX гасыр уртасында (1849 елда) бер мулла Бохарадан Казанга дини ислахчы һәм милли тарихчы сыйфатында кайта һәм бу өлкәгә яңа рух, яңа фикерләр китерә. Бу мулла — Шиһабетдин Мәрҗани. Бохарада укыган башка Казанлы муллаларга охшамаган, чөнки ул бу шәһәрнең мәдрәсәләрендә өйрәнелүе гадәткә кергән дәресләрне тыңлау һәм саны бик чикләнгән дини тәгълимат вә мантыйк китапларын уку белән генә канәгатьләнмичә, ислам гыйлемен төп чыганаклардан өйрәнү юлын тапкан. Бохара мәдрәсәләрендә укытылмаган һәм андагы мөгаллимнәр тарафыннан онытылган дөньяви фән тармаклары белән дә шөгыльләнгән, аеруча тарих гыйлеменә әһәмият биргән. Әмма Мәрҗанинең дин һәм дин гыйлеме хакындагы карашының формалашуына һәм тарих белән шөгыльләнә башлавына Бохарадан соң ике ел Сәмаркандта калуы сәбәп була, чөнки бу шәһәрдә бер дин галиме вә фикерле казый Әбү Сәетнең файдалы дәресләрен алуда дәвам итә һәм аның китапханәсендәге кыйммәтле әсәрләрне төп чыганактан укый. Шуның нәтиҗәсендә тарихи һәм дини эзләнүләрнең дөрес юлын вә методологиясен таба.

Ш. Мәрҗани Бохарага 1838 елның 12 декабрендә барган. 1849 елда исә, шактый мөһим кульязма китаплар һәм букча-букча гыйльми язмалар белән төянеп, Казанга кайткан. Ул кайткан вакытта татар җәмгыяте шактый сизелерлек үзгәргән була — дини мәдрәсәләр барлыкка килгән, шәкертләр күбәйгән, төрле мәсьәләләр белән кызыксына торган, дөнья күргән әсәрләрне укып, аларга тегеяки бу шәкелдә бәя бирә алырлык бер катлам туган була. Ш. Мәрҗани Бохарадан кайтып эшкә тотынган вакытта Казан татарлары мохите XVII һәм өлешчә XVIII гасырдагы кебек караңгылыкта булса, мәдрәсәләр, мөгаллимнәр һәм шәкертләр булмаса, Мәрҗанинең гарәпчә язылган әсәрләренә бөтенләй җирлек тә табылмас иде. Һәм ул китаплар бу мәмләкәттә шул дәрәҗәдә шартлау китереп чыгара алмаслар иде. Чөнки аңлаучысы һәм кызыксынучысы табылмаган бер фикер һичбер вакыт шау-шуга, уянуга сәбәп була алмый. Һәрхәлдә, ул көннәрдә Казан илендә азмы-күпме яңача фикерләү хәрәкәтләре сизеләнә иде инде. Мәрҗани исә кайбер яңа дини һәм иҗтимагый фикерләре белән шушы хәрәкәткә яңа бер юнәлеш биргән һәм ул вакытка кадәр хөкем сөргән ялгыш карашларны төзәткән.

Табигыйдер ки, болар бөтенесе мәдрәсә шәкертләре арасында уяну һәм уйлануларга этәргеч булган. Мәрҗанинең гарәпчә язылган дини китапларындагы фикер хәрәкәтләре менә шушында.

Бохарадан яңа фикерләр алып кайткан Мәрҗани Казанда бары тик кайбер дини фәлсәфәгә кагылышлы бик җитди һәм әһәмиятле әсәрләрен язып кына калмый, зур бер тырышлык белән җирле тарих мәсьәләләре белән дә шөгыльләнә башлый. Аның гарәпчә язылган төрки Караханилар династиясенә караган «Горфәтел хәвакыйн ли-гарфәтил хавакыйн» әсәре Казанда 1864 елда басылган. Ә 1877 елда исә Болгар белән Казан чоры тарихына караган кечкенә бер төркичә хезмәте туа: «Гыйлалатез-заман фи тарихи Болгар вә Казан». Бу хезмәте урыс галимнәренең дә игътибарын җәлеп иткән, ул, беркадәр кыскартылып, мәшһүр тел галиме В. Радлов тарафыннан урысчага тәрҗемә ителгән һәм 1877 елда узган

Бөтенрусия археология, тарих вә этнография җәмгыятенең IV конгрессында укылган. Радловның бу тәрҗемәсе, татарча төп тексты белән бергә, «IV археология конгрессы хезмәтләре»нең I томында басылган.

Мәрҗанинең төп әһәмиятле тарихи хезмәте — «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» әсәренең Казан һәм Урал төркиләрендә милли тарихка ихтирам хисе уятудагы роле һәм тәэсире зур булган. Бу сүзебезне бераз аңлата төшик. Ике гасыр буе рәхимсез урыс изүенә дучар ителгән һәм урыс вәхшәте аркасында тарихи язма истәлекләрен югалткан татарлар XIX гасыр урталарына таба үткәннәрен оныта башлыйлар. Әмма халык үз телен онытмый, Идел Болгарларына һәм мөстәкыйль Казан ханлыгы чорына караган төрле риваятьләрне, хикәятләрне саклый иде. Тик шанлы бәйсезлек чоры һәм бабаларның каһарманлыклары турында тарихи мәгълүматлардан хәтта алдынгы карашлы муллалар да хәбәрдар түгелләр иде. Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар»ының I кисәге менә шундый бер чорда дөнья күрә. Ул беренче мәртәбә Казанда 1885 елда, икенче тапкыр исә 1897 елда басылган. Автор әсәренең бу өлешендә Идел болгарлары һәм мөстәкыйль Казан дәүләте тарихы турында сүз алып бара. Урта Азия, Алтын Урда һәм Чыңгыз хан династиясе турында да тарихи мәгълүматлар бирә. (Нәҗип Асым бәй 1914 елда Истанбулда басылган «Төрек тарихы» исемле хезмәтендә, искәрмәдә Мәрҗанинең Идел болгарларына һәм хазар төркиләренә караган мәгълүматның бөтенесен дә диярлек — китапның 65 битен сүзгә-сүз күчереп биргән.) Китапның икенче бүлеге исә казанлыларның урыс буйсындыруы астындагы дәверенә караган материалларны эченә алган. Хезмәтнең бу өлешендә без танылган имам һәм мөгаллимнәрнең, мәшһүр казанлы шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләрен укыйбыз; XIX гасырда Идел буенда эшләп килгән мәдрәсәләрнең тарихына караган мәгълүматлар табабыз («Мөстәфадел-әхбар...»ның икенче кисәге авторның үлеменнән соң, 1900 елда басылган). Мәрҗани бу хезмәтенең I кисәгендә Идел болгарларының төрки ыруына караганлыкларын тирән белеменә таянып исбат итә, болгарлар белән хазарларның бер үк кавем булуларын раслый. «Бу кыпчак һәм хазарның төрки булуларына асылда шөбхә юк» һәм «бу кыпчак һәм хазарлар хәзерге халык булмаса, алар кебек көчле һәм кыю, күп санлы халык кая китеп беткән соң?» — ди. Ягъни тарихчы галим Мәрҗани бүгенге Идел буе татарларның тарихта кайчак болгар, кайчак кыпчак (коман), кайчак хазар дип йөртелә торган кавемнең дәвамы, дигән фикерне алга сөрә, бу ил халкына «татар» исеме тагылуның, кайбер Төркестан төркиләренә «үзбәк» исеменең тагылуы кебек мәгънәсез һәм нигезсез бер күренеш булуына ишарә ясый.

Иске Бохарадан яңа фикерләр китергән тарихчы һәм фикер иясе Шиһабетдин Мәрҗани 1889 елның 18 нче апрелендә 72 яшендә Казанда үлә.

## XI

## Яңа әдәбият

Идел буенда борынгы заманнарда, әйтик, Идел болгарлары дәверендә, киң мәгънәсендә әдәбият (язма әсәрләр) бар идеме? Бу сорауга кистереп «юк» дип җавап биреп булмый. Тик шулай да бүгенгә кадәр кайбер кабер ташларында бик кыска һәм артык зур әһәмияте булмаган язмалардан башка, Болгар дәвереннән калган язулы бер әсәр дә табылганы юк.

Мөстәкыйль Казан ханлыгы чорында язма әсәрләр булганлыгына ишарә итүче кайбер нәрсәләр турында хезмәтебезнең Казан ханлыгы чорына багышланган бүлегендә әйтеп үткән идек. Тик бу дәвердән «әдәбият» дип атарлык әһәмиятле язмалар калмаган, ахрысы. Булганнары исә елъязма кисәкләреннән һәм югарыда телгә алынган Сәхибгәрәй хан ярлыгыннан гыйбарәт бугай.

Урыс басып алуыннан соң, XVII—XIX гасырларда Идел-Урал төркиләрендә язма әдәби әсәрләр булганмы? Казан төркиләренең әдәбияты тарихын өйрәнү белән җитди шөгыльләнгән казанлы ике галим (Газиз Гобәйдуллин белән Гали Рәхим) бу өч гасыр эчендә халыкта киң таралган бер төркем әсәрләрне санныйлар. Болар арасында бары өчесе генә азмы-күпме әһәмияткә ия. Бу ике авторның «Татар әдәбияты тарихы» исемле әсәрендә, «Иске әдәбият» исеме астында алынып, тиешле дәрәҗәдә анализланган һәм тәнкыйть ителгән бу өч әсәр түбәндәгеләр: 1) Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария»се. 2) Мәшһүр Рәшидетдиннең «Җамигыт тәварих» әсәреннән файдаланып, Җәлаирлы Кадыйргали би тарафыннан асылы белән татар булган Мәскәү патшасы Борис Годуновка багышлап Касыйм шәһәрендә язылган әсәр. Бу әсәрнең исеме исә хәзер генә иско

алынган ике автор тарафыннан да һәм урыс галиме Березинның «Шәрекъ тарихчылары китапханәсе» исемле әсәрендә дә ачыкланмаган. 3) Хезмәтебездә Казан ханлыгы турында сүз барганда искә алынган һәм 1819 елда Ибраһим Хәлфин тарафыннан бастырылган «Әхвәле Чыңгызхан вә Аксак Тимер» исемле әсәр.

Тарихи характердагы бу өч әсәрнең беренче һәм өченчесенең тарихи кыйммәтләре юк дәрәҗәсендә булса да, боларның тел тарихы өчен әһәмитле булулары инкяр ителә алмас.

Моннан тыш, XVIII—XIX гасырларда Идел буенда кульязма рәвешендә таралган, XIX гасыр башында Казанда гарәп хәрефләрендә дә басучы бер матбага ачылгач, басылып таратылган дини-мистик эчтәлектә булган берничә китап бар. Боларның чынлыкта дини караштан да әллә ни зур кыйммәте юк. Мондый «әдәби» әсәрләргә караганнан соң, Идел буе татарларында XVIII гасыр ахырларына кадәр фикер үсешенең бик зәгыйфь булуы һәм бу җәһәттән теге яки бу фикер агымының чагылышы дип әйтерлек әдәбиятның да булмавы аңлашыла. Күренгәнчә, бу дәвердәге язма әсәрләрнең күбесе (бәлки бөтенеседер дә) ярым-ярты «тарихи әдәбият», яки җитдилектән мәхрүм «дини әдәбият». Матур әдәбиятка карата исә бары тик XVIII—XIX гасырларда яшәгән кайбер назымчы шагыйрьләрнең генә шигъри әсәрләрен атый алабыз. Бу әсәрләр турында Г. Газиз һәм Г. Рәхим хезмәтендә «Борынгы шагыйрьләр» дигән баш астында сүз алып барыла. Бу назымнарның күбесе мәрсия, мәдхия, касыйдә, мөнәҗәт шәкелендә булып, араларында кайбер газәлләр, хәтта мәхәббәт шигырьләре дә бар. Бөтен бу «борынгы әдәбият» ның чәчмә һәм шигъри әсәрләрендә кулланылган тел, һич тә оригиналь бер тел булмыйча, чагатай, госманлы төрек китап телләре белән берникадәр Казан төбәге халык сөйләм сүзләре катышкан авыр һәм корама бер тел иде. Мондый язу теле XIX гасырның соңгы яртысында иҗат иткән Ш. Мәрҗани тарафыннан да дәвам иттерелгән. Әмма галимнең язмаларында Казан төрки теле чагылуның шактый артканлыгы күзгә ташлана. Шул ук вакытта Казан төркиләренең яңа әдәбияты һәм ул әдәбиятның яңа теле, һичшиксез, Каюм Насыйридан башланган дисәк, ялгыш булмас. Дөрес, Насыйрины да чагатай һәм госманлы әдәби телләре тәэсиреннән бөтенләй азат дип әйтеп булмый. Шулай да, моннан соңгы язу теленең Казан төрки теленә нигезләнергә тиешлеге турындагы фикерне бөтен җитдилеге белән ул алга сөрә. Насыйриның яңа язу теле хакындагы фикерләрен һәм ул телне барлыкка китерүдәге хезмәте турында югарыда сүз булды. Төньяк төркиләренең ике ислахчысының берсе — Ш. Мәрҗани тарихи әсәрләр иҗат иткән, икенчесе — К. Насыйри күбрәк телгә багышланган әсәрләр язган. Алардан соң Казан өлкәсендә әдәби әсәрләр дә барлыкка килә башлый. Мәсәлән, әле бу ике ислахчының исәнендә, ягъни 1885 елда, Пенза урыс гимназиясендә укыган Муса Акъегетзадәнең «Хисаметдин менла» исемле, яңа заманны чагылдырган бер әсәре басылып чыга. Бу әсәр тел ягыннан яңалык китермәсә дә, яңа заман хикәяләре стилендә язылуы белән Казан татар әдәбиятында яңа бер юнәлеш ачкан. Язучы бу әсәрендә Казан татарлары иҗтимагый тормышыннан алып, әдәбият сәхнәсенә яңа образлар чыгара. Болар шул заманның татар җәмгыятендә хөкем сөргән тәртипләрдән риза түгеллекләре хакында сөйлиләр, халыкның аң-белем дәрәҗәсен күтәрү һәм иҗтимагый тормышка беркадәр хөррият рухын җәелдерү теләкләрен белдерәләр. Бөтен бу мажараларның каһарманы — бер яшь укымышлы. Әсәр шул зыялының исеме белән аталган.

Акъегетзадә бу әсәреннән соң башка хикәя һәм роман рәвешендә һичбер әсәр язмаса да, аның эзеннән барып, мәйданга яңа язучылар һәм әдипләр килә. Акъегетзадәнең бу әсәре чыгып, ике ел үткәч, 1887 елда Заһир Биги исемле бер авторның «Гүзәл кыз Хәдичә» исемле повесте басылып чыккан. Бераз соңрак шул ук авторның, темасы Казан татар эшкуарлары һәм мәдрәсә шәкертенең тормышыннан алынган әсәре — «Зур гөнаһлар» исемле зур хикәясе нәшер ителгән. З. Биги бу әсәрендә дә теге яки бу сәбәп белән гаепләнеп, судтан судка йөртелүче кешеләр тормышын ала. Бу Казанлы язучының әсәрләрен анализлаган ориенталист Николай Ашмарин болай ди: «Мөгаен, бу әдип Эмиль Габорио кебек француз язучыларының әсәрләре белән таныш булган һәм мондый әсәрләр аның иҗатына бераз тәэсир иткән, ахры».

Заһир Биги 1870 елда туган һәм Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укыган. Көньяк Русиядә — Ростов шәһәрендә имамлык иткәндә, 1902 елда үлгән. Мәгълүм дин галиме Муса Ярулла Бигинең бертуган абыйсы, Заһир Бигинең Төркестанга сәяхәт язмалары соңыннан, энесе Муса Биги тарафыннан тулыландырылып, яхшы бер китап итеп, 1908 елда «Мавәраэннәһердә сәяхәт» исеме белән Казанда бастырылган. Бу язучы Акъегетзадәнең теле белән чагыштырып та булмаслык дәрәҗәдә Казан төбәге сөйләменә якын бер тел белән язган.

Акъегетзадә белән З. Бигидән соң, XX гасырның башларында, хикәяче-язучы булу һәвәсе белән каләмгә тотынган ике яшь егет күзгә чалына. Икесенең дә югарыда телгә алынган укытучылар мәктәбендә укып, урысчалары шомарган һәм фикерләре дә киңәйгән була.

Болар — Садрый Максуди белән Гаяз Исхакый иде. Беренчесе Казан сәүдәгәрләре тормышыннан алып язган «Мәгыйшәт» исемле озын хикәясен укытучылар мәктәбендә укыганда, 1900 елда бастырган (С. Максуди бу мәктәпне 1901 елда тәмамлаган). Автор үзе моның «саф Казан теле белән язылган беренче милли хикәя булуын» әйтә һәм 1914 елда чыккан икенче басманың кереш сүзендә болай дип яза: «Мәгыйшәт» реализм стилендә язылган булса да, асылында билгеле бер фикерне җәелдерү һәм укучыларда максат уяту уе белән язылган бер әсәр. Бер яшь язучының милләте арасында җәелдерергә теләгән максатлары нидән гыйбарәт була ала? Моны аерым тукталып язуның кирәге дә юктыр. Хикәяне укыган һәркемгә бу ачык аңлашылачак. Хикәянең каһарманы Фатих кече улы Рәшитнең галим, дини, тугрылыклы, барлыклы һәм милли бер кеше булып җитешүен, сүзе-эше һәм малы белән милләткә һәм дингә файдалы булуын тәңредән сорый. 19 яшьлек яшь язучының милләт шәхесләре арасында җәелдерергә теләгән фикерләре менә шуннан гыйбарәт. Бу исә «Мәгыйшәт» авторына бүген дә бөек бер идеалдыр». С. Максуди шул хикәясеннән соң башка бер әдәби әсәр дә язмаган.

Моңа капма-каршы буларак, «Тәгаллемдә сәгадәт» («Белем алуда бәхет») исемле гаять зәгыйфь бер хикәячек белән иҗат мәйданына килеп кергән егет — С. Максудиның мәктәп дусты Гаяз Исхакый. Ул дәвамлы һәм уңышлы хикәяләр, драма әсәрләре язучы әдип булып җитешә. Бу язучының беренчесенә караганда реальрәк, төзегрәк булган икенче хикәясе «Кәләпүшче кыз» 1900 елда, димәк, «Мәгыйшәт» белән бер үк вакытта басылган. Аның беренче драма әсәре «Өч хатын белән тормыш» пьесасы да шул ук елны нәшер ителгән. Ә инде «Бай углы» исемле өченче хикәясе 1903 елда басылганнан соң, бу язучының хикәяләре һәм сәхнә әсәрләре бер-бер артлы чыга башлый. Инде XX гасырга керсәк, ул вакытларда Исхакый хикәяләр, сәхнә әсәрләре язу белән бергә, югарыда сүз алып барылган «Ысулы җәдит» мәктәпләрендә укытучылык итү һәм бу «Җәдитчелек» хәрәкәтенең җәелүенә үз өлешен кертү белән дә шөгыльләнә. Г. Исхакый беренче әсәрләрендә саф бер мәгърифәтче һәм сентименталист булса да, урыс реалист язучыларын укый-укый (ул вакытларда әле Исхакый башка чит тел белми иде), үз мәсләген тапкан, ахры, соңгы әсәрләрендә чын реалист язучы булуы күренә. Язучы саф татар теле белән яза һәм темаларын да Казан сәүдәгәрләре, мәдрәсә шәкертләре, хәлфәләр һәм авыл кешеләре тормышыннан ала. Исхакый асылында мулла улы булганга һәм мәдрәсә тәрбиясе алганга күрә, шәкертләр һәм хәзрәтләр тормышын, йола-тәртипләрне, гореф-гадәтләрне бик яхшы белә иде. Шуңа күрә боларны тасвирлауда аның тиңе юк. Бер мәдрәсә шәкертенең көндәлек дәфтәре рәвешендә язылган «Тормышмы бу?» исемле әсәрендә шәкертләрнең озакка сузылган мәдрәсәдә уку елларының максатсызлыгын, мәгънәсезлеген һәм заяга үтүен бик оста чаралар белән сурәтли. «Мулла бабай» романында язучы Казан өлкәсендәге мәдрәсәләр тарихын роман рәвешендә яза башлаган булса да, бу эшен төгәлли алмый. Илдәге соңгы көннәрнең баш әйләндергеч вакыйгалары аны ахырына житкерүгә киртә була. «Бай углы», «Кәләпүшче кыз» хикәяләрендә, «Теләнче кыз» романында, «Өч хатын белән тормыш» исемле сәхнә әсәрендә язучы Казан байларының әхлаксызлыгын, ярлыларның аяныч язмышын тасвирлый. Соңрак язган драма әсәрләрендә дә, уртага чыгарган образлары аша искергән һәм заманы үткән иҗтимагый корылышларны, яшәеш кануннарына туры килмәгән гадәт һәм әхлакны рәхимсез чыбыркылый.

XX гасырга кергәч, Казанда гына түгел, башка шәһәрләрдә дә, мәсәлән, Оренбург һәм Уфада, яңа заманга туры китереп хикәяләр иҗат итүче язучылар әдәбият мәйданына киләләр. Истанбулда белем алган Фатих Кәриминең «Җиһангир мәхдүм» исемле кечкенә хикәясе 1900 елда дөнья күрә. Уфа Диния нәзарәте әгъзаларыннан булган Ризаэтдин бине Фәхретдиннең «Гафвил бине Абдуллаһ псевдонимы белән язган) «Сәлимә» исемле озын хикәясе 1899 елда басылган. Ф. Кәрими беренче хикәясендә, «ысулы җәдит» мәктәпләрен вә яңача укыту ысулларын яклау һәм иске ысулларны инкяр итү максаты белән булса кирәк, иске авыл мәктәпләрендә (фәләка мәктәпләре) укыту-тәрбия ысулларының яраксызлыгын бер авыл имамының улы — Җиһангир исемле малайның шәхесендә ачып сала. Шул рәвешле, Ф. Кәрими сурәтләгән вакыйгалар көлкеле дә, кызганыч та. Ризаэтдин әфәнденең «Сәлимә» хикәясе исә, тәрбия һәм дидактик максаттан чыгып иҗат ителгән бер сәяхәт хикәясе, заманында зур кызыксыну белән укылган әсәрләрнең берсе була.

Ниһаять, 1905 ел революциясе алды. Бу вакытларда Казанда матур әдәбият чын үсеш юлына керә. Г. Исхакыйның 1903 елда «Бай углы» хикәясе, шул ук елда «Ике гашыйк» пьесасы, 1904 елда «Ике йөз елдан соң инкыйраз» исемле фантастик повесте, 1903 елда Ризаэтдин әфәндене «Әсма» исемле икенче озын хикәясе, шул ук елда Ф. Кәриминең «Шәкерт белән студент» исемле хикәясе, 1902 елда Галиәсгар Камалның «Өч бәдбәхет» исемле 3 пәрдәлек сәхнә әсәре басылып чыгалар. Шуның белән бергә, күбесенчә «ысулы кадим»челәр белән «ысулы җәдит»челәрнең тартышларын тасвир иткән Закир Һадиның да кайбер хикәяләре 1905 ел революциясенә кадәр нәшер ителгән.

XX гасырның беренче елларында Казан татарларында матур әдәбият кына түгел, әдәби иҗатның башка тармаклары да үсә башлый. Мәсәлән, әле генә телгә алынган Ризаэтдин әфәнде, Идел буе һәм Урал төбәге төркиләренең тарихына караган материаллар туплап, шуларны «Асар» («Эзләр») исеме белән 1900 елда бастыра башлый һәм 1904 елга кадәр бу кыйммәтле әсәрнең 8 чыгарылышы дөнья күргән. Бу авторның «Мәшһүр хатыннар» исемле күләмле һәм зур әһәмияткә ия әсәре дә 1905 ел революциясе алдыннан басылган булса кирәк.

Казан татарларының яңа әдәбияты нигездә 1905 ел революциясе тудырган мөмкинлекләр нәтиҗәсендә тиешле дәрәҗәдә үсә һәм киңәя башлый. Бу беренче урыс революциясеннән алып 1917 ел революциясенә кадәрге бер дистә ел эчендә Русия төрки сәяси нәшрияте зур кризис кичерде, шуңа да карамастан, киң мәгънәсендәге әдәбият күзгә ташланырлык дәрәҗәдә җанланды һәм алга китте. Мәсәлән, матур әдәбиятны алыйк.

XIX гасырның ахырларында каләмгә тотынган Фатих Кәрими, Гаяз Исхакый, Галиәсгар Камал кебек танылган язучылар 1905 ел революциясеннән соң да хикәяләр һәм сәхнә әсәрләре язуларын дәвам иттерәләр. Шуның белән бергә, бу чорда Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал, Кәрим Тинчура, М. Гали кебек яшь хикәячеләр; Габдулла Тукай, Мәҗит Гафури, Дәрдемәнд (Закир Рәми), Нәҗип Думави, Сагыйть Сүнчәләй, Гыйффәт Туташ, Газиз Укмасый, Шәехзадә Бабич, Нәкый Исәнбәт һ. б. кебек яшь шагыйрьләр иҗат мәйданына килә. Биредә бу әдип һәм шагыйрьләрнең әдәби көчләре дәрәҗәсен үлчәү белән дә, темаларын, тел һәм язу ысулларын анализлау һәм тәнкыйть итү белән дә шөгыльләнмәячәкбез. Бары тик аларның берничәсе хакында бер-ике сүз әйтү һәм кайбер әсәрләрен санап китү белән генә чикләнәчәкбез.

Мәсәлән, Казан имамнарыннан булган Зариф мулланың улы Фатих Әмирхан 1907 елда Казанда «Әл-ислах» газетасын чыгара башлый. Бу ислахатчы (реформачы) тәрәккый һәм яңалык тарафдары — мәдрәсә шәкертләренең алдынгыларыннан булып, бу газетаның юнәлешен билгеләүче дә иде. Хикәяләр язуы бу газета бастырган «Гарәфә кич төшемдә» исемле кечкенә бер фантастик әсәре белән башланган иде. Ф. Әмирхан ялкынлы милләтче, искергән, таушалган көнчыгыш алымнарының рәхимсез дошманы, көнбатыш мәдәниятенең һәм ул мәдәният тудырган яңа ысул һәм системаларның гашыйгы иде. Шуңа күрә «Кадерле минутлар», «Танышлык», «Хәят», «Урталыкта» кебек чәчмә әсәрләрендә, «Яшьләр», «Тигезсезләр» кебек пьесаларында яңа һәм алдынгы тормышка сусаган төрки-татар яшьләрен күтәренке пафоста сурәтли. Язучы шул ук вакытта үткен телле сатирик та иде. Сатиралар кайбер вакыт сарказмга якыная һәм шуның сәбәпле бик үтемле бер рәвеш ала иде. Аның сатира һәм юморлары, күбесенчә, иске фикерле, надан һәм фанатик муллаларга һәм аларны тоткан байларга карата юнәтелгән була иде. («Ташмөхәммәт» псевдонимы белән язган сатира әсәрләреннән «Фәтхулла хәзрәт», «Хәзрәт үгетләргә килде», «Габделбасыйр гыйшкы», «Салихҗан кари», «Сәмигулла абзый» исемле әсәрләрен күрсәтә алабыз.)

Ныклы һәм шул ук вакытта йөгерек бер стильдә иҗат иткән Ф. Әмирхан, әйтергә кирәк, яңа Казан әдәби теленең эшләнүендә, баюында һәм төзекләнүендә алдынгы урын тоткан бер әдип...

Уфа якларындагы бер авыл имамының улы булган Галимҗан Ибраһимовка килсәк, аның «Бер шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» исемле беренче хикәясе дә 1907 елда «Әл-ислах» газетасында басылган иде. Димәк, бу «урам малаен» матбугат дөньясына беренче мәртәбә чыгарган кеше Фатих Әмирхан була. «Әл-ислах»ның яшь баш мөхәррире, әле ул вакытта ук зирәк акыллылыгы белән бу яшь егеттә сәләт ялгысы сизеп алган, ахры. Чынлыкта бу яшь егет соңыннан төзек стиль белән бик күп һәм шактый кыйммәтле әсәрләр язган бер әдип булды. Төрки-татар авыл кешеләренең тормыш итү өчен көрәшен, эш һәм хезмәт рәвешләрен, иске заманнарга караган кайбер яшәү девизларын, аталар белән балалар арасында барган фикер каршылыкларын тасвирлаган бер төркем кеч-

кенә хикәяләреннән башка, бу язучының татарча язылган беренче зур роман булган «Яшь йөрәкләр» дип аталган бер хезмәте дә чыкты (1912 ел). Бу язучы Совет дәверендә дә, бигрәк тә эчке сугышларда «аклар»ның җиңелүеннән соң, хикәяләр язуын дәвам иткән, яки элек үк язылып та, басарга мөмкинлек булмаган кайбер әсәрләрен нәшер иттергән. Элек язылып, бу чорда басылган әсәрләреннән «Безнең көннәр» вә «Казакъ кызы» романнарын һәм яңа язылганнардан «Алмачуар», «Кызыл чәчәкләр», «Адәмнәр» исемле хикәяләрен һәм «Яңа кешеләр» дип аталган пьесасын искә ала алабыз. Әмма боларның күбесе, мәшһүр урыс язучысы Максим Горькийның Совет дәверендә язган әсәрләре кебек, әдәби-эстетик әсәрләр булудан бигрәк, хикәя яки роман тышчасына төренгән, фәкать режимны яклау яки режимга ярарга тырышу максатын күздә тоткан «сәяси» әйберләр иде.

Шәриф Камал мишәр сөйләшенең үзенчәлекләрен дә эченә алган, үзенә хас бер төрле алдынгы «Стиль белән эшчеләр, бигрәк тә руда учаклары һәм балыкчы промыселлары» эшчеләре тормышыннан алып, берничә хикәя язган иде. Аның бу кыска хикәяләре, әле минем дә язучылар арасында булган вакытларымда, бер «буржуаз» газета булган Оренбургтагы «Вакыт»та даими басыла башлаганнар иде. Бу язучы да Совет дәверендә дә язуын дәвам иттерүчеләрнең берсе.

Кәрим Тинчура асылында Казанның «Сәйяр» труппасының дәрәҗәле авторы һәм шул ук вакытта Казандагы «Аң» журналында кечкенә хикәяләр язып, каләм дә тибрәткән кеше. Соңыннан Казан татарлары кече буржуазия, һөнәрче һәм кайбер авыл кешеләре тормышыннан алып гүзәл пьесалар да язган һәм болар Казан сәхнәләрендә яратып тамаша ителгәннәр иде. Артист-язучы Совет дәверендә дә иҗатын дәвам иттерә, шактый санда пьесалар һәм хикәяләр яза.

1905 ел революциясе белән бергә мәйданга чыккан Казан шагыйрьләренә килсәк, иң тиз кабынган йолдыз, аз вакыт эчендә киң халык массалары арасында шөһрәт казанганы һәм чагыштырмача иң күп шигырь иҗат иткәне — Габдулла Тукай иде...

1906 ел революциясе көннәрендә шигърият мәйданына килеп керә, Казан татар шагыйрьләрен күләгәдә калдыра һәм үскәннән-үсә бара. Тик ул көннәрдәге Казан, «Печән базары»ның яңа мохите... шагыйрь тормышына һәм саулыгына бик начар тәэсир итә... «Печән базары»ның сасы номерларында яшәве һәм саулыгының тәмам какшавы, әлбәттә, аның китаплар укуына, белемен арттыруына да комачау итми калмыйлар. Ул инде бары тик Җаек мәдрәсәсендә өйрәнгән һәм урыс әдәбиятыннан алган кайбер белемнәренә таянып кына иҗат итә иде. Шуңа күрә шигырь өлкәсендә дә бик югары үрли алмый, уңышлы әсәрләр дә бирә алмый иде. Черек үпкәсен туберкулез таякчыклары рәхимсез кимергәндә, ул сәламәтлегенә бөтенләй әһәмият бирми, табибларның киңәшенә колак салмый...

Җаек каласы чорындагы иҗатында Тукай бөтен дөнья мөселманнарын күз алдында тотып, мөселман дөньясы өчен уртак булган кимчелекләргә, артталыкка каршы көрәш алып бара. Ә 1907 елдан башлап Тукай миллиятчелек юлында алга хәрәкәт итә. Шигырьләрендә башлыча үзенең туган халкына мәрхәмәт итә, аның тәрәккъый итүен, үсүен тели. Әмма Тукай миллиятче булу белән бергә социалистлыкка тартым бер халыкчы-демократ та иде. Ул күпкән корсаклы, калын инсәле байларны яратмый. Профессор Фуад Күпрүле уйлаганча, «мохтаҗлыкны күп күргәне өчен» түгел, капитал дошманы булганга күрә «алтын»га ләгънәт укый («Алтынга каршы» шигыре). Тукай беренче шигырьләрендә «мәчетләрне базар хәленә төшереп, дин белән сәүдә иткән» чалмалыларны фаш итсә, 1908 елда һәм аннан соң язган шигырьләрендә ялган миллиятчеләргә, байлыкка сатылган яшьләргә каршы рәхимсез көрәш ача («Милләтчеләр», «Яшьләр», «Өзелгән өмет» шигырьләре).

Балачагы ата-ананы назы һәм шәфкате күрмичә, гаилә җылысыннан мәхрүм ятимлектә үтсә дә, яшьлегендә дә зур мохтаҗлыклар, кимсетүләр күргән, зәгыйфь һәм авыру булуына да карамастан, Тукай асылында шат күңелле һәм, бер шагыйрь-мөхәррир әйткәнчә, «бала табигатьле» бер кеше иде. Астыртын көлү үзенчәлеге белән бергә, зәгыйфь гәүдәсе тирәнлекләрендә изге уйлар һәм бөек кешелек максатлары йөрткән, хисле һәм ватанпәрвәр бер төрки шагыйрь иде. Дөрес, Тукай элегиягә охшаган шигырьләр дә язган, әмма боларда да күзгә бәрелерлек өметсезлек, пессимизм сизелми. Күңел төшенкелеге булса да, бу бары тик үзенең шәхси тормышына бәйләнешле булып, милләтнең язмышына һәм киләчәгенә кагылышлы түгел иде.

Шагыйрь үз халкының иҗтимагый һәм мәдәни хәяте белән, хәтта аның көндәлек феноменнары белән дә кызыксына. Боларның күбесе шунда ук йә көлкеле, яисә җитди бер яңа шигырьдә чагылыш таба. Профессор Фуад Күпрүле:

«Аның шигырьләрендә баштан ахырга кадәр көрәш, бәхәс, хәрәкәт һәм тормыш бар»,— дию белән һич тә ялгышмый. Әмма, «көчле хислелектән һәм иҗат фантазиясеннән мәхрүм Г. Тукаевның шигырьләрендә темалар, һичшиксез, практик файданы гына күз алдында тоталар. Күңелнең самими һәм бер сәбәпсез дулкынланулары, табигать гүзәллекләре аның әсәрләрендә һич тә урын таба алмаган» — дип әйтүе белән ялгыша. Шунысы аңлашыла: хөрмәтле тәнкыйтьче ул вакытларда, мөгаен, Тукайның соңгы чор шигырьләрен әле күреп өлгермәгән, яисә аларны тиешле дәрәҗәдә нечкәләп өйрәнү форсатын таба алмагандыр. Югыйсә, мәсәлән, шагыйрьнең 1910—1912 елларда язылган һәм шагыйрь Фәтхи Бурнаш тарафыннан «Өзелгән өмет» яки «Соңгы зарлар» исеме астында тупланган әчкерсез лирик шигырьләрендә нинди «гамәли файда» була алсын?..

Күпрүленең: «Тукай чын иҗат фантазиясеннән һәм көчле хислелектән мәхрүм»,— диюенә капма-каршы фикерне әдәбият тарихчысы Г. Сәгъди әйтә: «Тукайның фантазиясе бай: хисе, фикере кебек үк уйнак, житез: ул тиз сизүчән һәм нечкә хисле шагыйрь»... Ике урыс революциясе арасында мәйданга чыккан Казан татар шагыйрьләреннән тагын икесен атау белән матур әдәбият бүлеген тәмамлыйбыз. Боларның берсе — Оренбурда «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем алган, 1905 ел революциясенең беренче дәверендә Казанда социалист кыяфәте чыгарып йөрүче Гаяз Исхакый, Фуад Туктарлар төркеменә кушылган, «Таңчылар» арасында хезмәт иткән мөгаллим Сәгыйть Рәми. Шигырьләре шул революция бастырылганнан соң, рәхимсез реакция көннәрендә пәйда булалар... Бу шагыйрь гаять кискен бер ысул белән язган шигырьләрендә анархист һәм бунтарь булып күренә. С. Рәминең бу баш күтәрү, бунтарьлык һәм көрәш чагылдырган шигырьләре шагыйрьлегенең беренче дәверенә, бәлки дә үзен-үзе түбән күрү тойгысы кичерүгә дучар ителгән чорга карыйдыр. Соңыннан «Аң» журналында чыккан шигырьләрендә исә, ниһаять, бунтарь С. Рәми юкка чыга, кабат «Аллаһы»га, дингә сыгынган, ягъни, фикеребезчә, асылына кире кайткан йомшак табигатьле С. Рәми пәйда була...

Дәрдемәнд бу «көннең мәсьәләләре» белән шөгыльләнмәгән һәм шигырьләреннән «гамәли бер файда» көтмәгән, уйларына һәм хыялларына кешелек һәм гомуми фәлсәфи мәгънәләр бирергә тырышкан, романтик, пессимистик вә лирик бер шагыйрь. Ул гомум кешелек тормышының дулкынлы агышын һәм жиһанның бер «билгесезлек»кә таба баруын күреп (күзәтеп) уйга тала һәм бу уйлардан туган тойгыларын тасвирлап шигырьләренә сала. Дәрдемәнд, мәгънә ягыннан фикерче бер шагыйрь булган кебек, шигырь төзелешендә тиешенчә хәбәрдар, мәгънәләргә туры килә торган сүзләр сайлап алуда оста, аһәңгә, рифмага һәм вәзенгә бик игътибарлы. Һәм, бәлки, бу яктан караганда Казан төрки шагыйрьләре арасында иң өстен шагыйрьләрнең берседер. Иске төрки әдәбияты белән дә житди шөгыльләнгән, Нәваи, Лотфи, Бабыр кебек чагатай шагыйрьләренең җыентыкларын игътибар белән укыган булуы да ачык билгеле. Шуңа күрә Дәрдемәнд шагыйрьләр арасында иң белемлесе булып саналырга тиеш... Ике революция арасында Казан татарларында нәфис әдәбият кына түгел, башка тармаклары да үсә башлый. Тарихи әдәбиятны алсак, бу чорда казый Ризаэтдин бин Фәхретдин төрки-татар тарихына караган әсәрләрен бастыруын дәвам итә. Бу тарихчы «Асар» сериясен дәвам иттерү белән бергә, мәшһүр кешеләрнең биографияләрен язып бастыру белән дә шактый шөгыльләнә. Ибне Рөшд, имам Газәли, Мәгарри, Мөхетдин ибне Гарәби, ибне Тәймия, Котбү Ситтә һәм Әхмәт Мидхәт әфәнде, Әхмәт бәй шул исәптәндер. Болардан башка, бу галим «Шура» журналында «Олуг хәдисләр һәм мәшһүр кешеләр» исемендә әһәмиятле язмалар һәм бәйсезлек елларындагы вә урыс басып алуыннан соңгы Идел һәм Урал төбәге төркиләре тарихына караган бик кыйммәтле мәгълүматлар биргән.

1913 елда Әхмәт Зәки Вәлиди «Төрек вә татар тарихы»н бастыра. Һади Атласиның «Казан ханлыгы», «Сөенбикә», «Себер тарихы» исемле әсәрләре, казый Хәсәнгата Габәшинең «Тарихы кауми төрки»се басылып чыгалар. Ә мәктәпләр өчен язылган тарих китапларыннан шуларны күрсәтә алабыз: Зәки Вәлиди, Г. Баттал, Ф. һәм К. Туйкәләрнең төрки-татарлар тарихына караган әсәрләре; Харис Фәйзи белән Фатих Кәриминең гомум тарих дәресләкләре, Ф. Кәриминең «Ислам тарихы», У. Газизнең (Випперлән файдаланып язылган) диннәр тарихы. Нургали Нәдиевнең «Русия тарихы» h. б. Казанлы тарихчы Гайнетдин Әхмәр исә, Казан университеты каршындагы Археология җәмгыяте әгъзасы сыйфатында, Казан төркиләре тарихын язу буенча зур хезмәт куя. Бу җәмгыятьнең җыентыгында төрле вакытларда аның берничә әһәмиятле тарихи һәм этнографик әсәре басыла. Мәсәлән, «Типтәрләр һәм аларның асылы» (23 нче том), «Мишәр теле һәм халкы хакында» (19 нчы том), «Казан татарларының туй

йоласы» (23 нче том) һ. б. Моннан тыш, аның татарча «Болгар тарихы» һәм «Казан тарихы» исемле әсәрләре дә дөнья күрәләр.

Югарыда да ишарәт итүебез буенча, кирәк 1905 ел революциясенә кадәр, кирәк бу революция булганнан соң, кайбер Казанлы яшьләр каләмгә тотынган көннәрдә, норма һәм кагыйдәләр кысасына кергән бер яңа язу теле булмый. Чагатай язу теле инде искереп һәм онытылып бара. Әйе, еракта булса да, яшәп яткан әдәбияты һәм матбугаты булган госманлы теле бар әле. Кырымда чыгучы «Тәрҗеман» газетасының хуҗасы Исмәгыйль Гаспралы купшы, кояз госманлы телен бик ошатып бетермәсә дә, аның камилләшкән бер шәкелдә, бөтен дөнья төркиләре өчен гомуми бер язу теле буларак кабул ителүен алга сөрә. Чынлыкта, кайбер казанлы мөхәррирләр дә башта кайбер әсәрләрен госманлычарак язарга тырышалар, әмма, Гаспралының бу фикере сәяси, икътисади һәм географик сәбәпләр аркасында Рәсәй төркиләре арасында кабул ителеп һәм кулланышка кереп китә алмый. Югарыда да искә алганыбызча, 1905 ел революциясеннән соң төрле тәбәкләр арасында тел аерымлыгы барлыкка килә, һәр өлкә үз шивәсендә яза башлый. Казан татарлары арасында Каюм Насыйриның гамәлгә куйган принципы буенча, татарчаның мөстәкыйль бер тел булуы кабул ителгәч, әлбәттә, бу телнең эшләнүе, баетылуы кирәк була. Шуңа күрә ике революция арасында газетачылар, әдип һәм шагыйрьләр татарча төзек һәм бай бер «әдәби тел» барлыкка китерергә тырышканда, кайсыбер мөгаллим һәм мөхәррирләр бу телнең кагыйдәләрен, ысул һәм теориясен төзү белән, вә башка кайберәүләр исә телнең баюына һәм киңәюенә ярдәм итәчәк халык авыз иҗатын җыю, өйрәнү, анализлау белән, башка бер төркем исә бу тел нигезендә төрле гыйлем өлкәсендә мәктәп-мәдрәсә дәреслекләре язу белән шөгыльләнәләр.

Менә шундый хезмәтләр һәм тырышулар нәтиҗәсендә чынлап та бертөрле «газета теле» барлыкка килгән кебек, «яңа әдәби тел»нең орфография, морфология һәм синтаксис кагыйдәләренә караган хезмәтләр: тарих, география, математика, табигать, тәрбия (педагогия) һәм өйрәтү ысулларына (методика) караган аерым дәрес китаплары дөнья күрә. Мондый китаплар язылганда, шөбһәсез, һәртөрле фән атамалары да эшләнә һәм ул вакытларда әле Казан татарлары арасында фән терминнарын төрки тамырлардан эшләү өстенлек алган була.

Фольклор үрнәкләрен җыю эшенең Каюм Насыйридан башланган булуын югарыда күрдек. Соңыннан бу эш белән Габделгаллэм Фәезхан («Әмсал вә мәкаләт», шагыйрь Г. Тукай, мөгаллим Хуҗа Бәдигый (мәкальләр, табышмаклар), Фазыл Туйкә һәм башкалар шөгыльләнәләр.

Әдәбият тарихы буенча исә ике революция арасындагы ун ел эчендә өстәнөстән генә китап шәкелендә язылган бер генә хезмәт басыла, ул да булса Җамал Вәлидинең «Татар әдәбиятының барышы» исемле 122 битлек кечкенә бер язмасы (Оренбург, 1912. «Вакыт» басмасы).

XIII

## XX гасыр башында

XIX гасыр ахырларында төрки культура вә мәгариф өлкәсендә бер агым кебек барлыкка килгән башлангыч мәктәпләр ислахы хәрәкәтенә Казан татарлары да катнаша. Ысулы җәдит хәрәкәтенең җитәкчесе кырымлы Исмәгыйль бәй Гаспралы иде. Казан төркиләренең бер төркем фикер ияләре тарафыннан да бу эш бик тиз арада үзләштерелә һәм тарала башлый. Әлеге тирәлектә Гаспралы үзенә ныклы таяныч таба. Казан татарлары дигәндә, тарихи Казан өлкәсендә яшәгән төрки халык кына аңлашылырга тиеш түгел. Инкяр ителмәслек бер чынбарлык ки: Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, тарихта билгеле булган сәяси, икътисади сәбәпләр аркасында, Казан татарлары бик күп җирләргә тарала. Шуңа күрә, кайсы җирдә генә яшәсәләр дә, тарихи Казан өлкәсеннән күчкән, Урта Идел татар телендә сөйләшкән һәм Казан гореф-гадәтләрен, йолаларын онытмыйча яшәткән бөтен төрки-татарлар, безнең фикеребезчә, Казан татарлары була.

Шунысы да мәгълүм: ысулы җәдиткә матди ярдәм күрсәткәннәрнең күбесе төп Казан-йортта яшәгән халык арасыннан булмыйча, Казаннан еракларда яшәгән эш кешеләре арасыннан чыккан. Чынлыкта, Истанбул халкы кебек үк борынгы йолаларга бик нык бәйле булган һәм соң дәрәҗәдә дәгъвалы Казан халкы бер төркем искелеккә табынучы хаҗи, хафиз һәм муллаларның тәэсире астында ысулы җәдиткә каршы торырга маташсалар да, Казанның университетлы шәһәр булуы сәбәпле һәм һавасында көнбатыш мәдәнияте җилләре искәнгә, яңа фикер

идеологлары нәкъ менә монда барлыкка килә. Милли уянуның беренче хәбәрчеләре булган Ш. Мәржани, К. Насыйри, Хөсәен Фәезхан, Ибраһим Хәлфиннәр бу шәһәрдә күтәреләләр. Ысулы җәдит фикерчеләре дә авазларын Казанда ишеттерә башлыйлар. Бу авазлар ерак тарафларга яңгырап тарала. Яңа мәктәпләр өчен дәрес китаплары язган Әхмәтһади Максуди, Шакирҗан Таһирилар, шул исәптән, яңа мәктәпләр өчен укытучылар хәзерләгән Г. Баруди, болар белән генә чикләнеп калмыйча, үзгәртеп корылган мәдрәсәсе каршында бер үрнәк башлангыч мәктәп тә ача һәм дәреслекләр язып бастыру белән дә шөгыльләнә.

Нәрсә ул «ысулы җәдит?» Төрки балаларга әлифбаны ул вакытларда көнбатыш өчен инде күптән искергән, ә безнең өчен җәдит (ягъни яңа) саналган ысул белән укыту дәгъвасыннан башланып киткән бу хәрәкәт, соңыннан төрле елларда урыс һөҗүменә дучар булган һәм патшаларның җәһаләтне яклаган идарәләре астында озак дәверләр гыйлем яктысы күрмичә гомер иткән төркиләрнең мәгариф һәм мәдәният дәгъвасына әверелә.

XIX гасыр ахырларына кадәр бу төркиләрнең шәһәрләрендә күп очракта рәтле-башлы башлангыч мәктәп булмаганга, кечкенәләр дә зур шәкертләр укый торган мәдрәсәләрдә укыйлар. Авылларда исә әллекке заманнардан бирле бер мәчет янында бер мәктәпнең булганлыгы чит ил сәяхәтчеләре тарафыннан да раслануына карамастан, соңгы заманнарда «мәптек» диелгән бу башлангыч мәктәпләрдә өйрәтү ысуллары «ысулсызлык» дәрәҗәсендә искергән, бозылган була. Бу «таяк мәктәпләре»нең укытучылары исә мәхәллә имамнары була. Мондый мәктәпләр дә бары тик малайлар өчен генә ачылып, кыз балалар өчен мондый мәктәпләр бөтенләй булмый. Аларны мәхәллә имамының хатыны үз өенә җыеп, өзек-төтек кенә укыта торган була. Малайлар мәктәбендә дә күбесенчә уку күнекмәсе бирелеп, язу һөнәренә өйрәтүгә артык зур әһәмият куелмый. Бигрәк тә кыз балаларга язу өйрәтү каттый тыела. Мәктәп дәреслеге диярдәй бернәрсә дә булмый һәм укучылар сыйныфларга да бүленми. Дөньяви фәннәр укытылмый. Ә «ысулы җәдит» буенча исә: 1) мәктәп мәдрәсәдән аерылачак иде; 2) башлангыч мәктәпләр өчен махсус укытучылар булачак иде; 3) укытучы «сәдака» түгел, айлык хезмәт хакы алачак иде; 4) уку-язуга өйрәтү элеккеге кебек ысулсыз «иҗекләү» алымы белән түгел, яңа әлифба китапларында күрсәтелгән «ысулы саутия» (аваз методы) яки «ысулы мәддия» (сузык аваз методы) белән башланып, шактый җиңел уку ысулы белән дәвам ителәчәк иде; 6) кыз балалар өчен дә аерым башлангыч мәктәпләр булачак һәм аларга да язу өйрәтеләчәк иде; 7) укыту махсус программа буенча барачак, яшь үзенчәлекләренә карап, дәрес китаплары да төрле булачак иде.

Болар безгә бүген бик әһәмиятсез һәм бик беркатлы нәрсәләр булып күренә. Әмма моннан 70—80 ел элек булган хәлләрне күз алдына китереп, уйлап карасак, бу «әһәмиятсез» һәм «беркатлы» шөгыльләрнең кайчандыр бер дә урынсыз булмыйча, җәмгыять тормышы һәм киләчәгебез өчен гаять мөһим һәм файдалы бер адым булганлыгын аңлау кыен түгел дип саныйм.

«Ысулы җәдит» дәгъвасын үткәрү җиңел булмый. Билгеле ки, һәрбер ният-тә, һәрбер максатта булган кебек, бу дәгъваның да ике ягы бар иде: 1) матди ягы, 2) фикер һәм тәрбия ягы. Ул заман хөкүмәте яңа төр мәктәпләр ачылуга каршы түгел иде, әмма шул ук вакытта аларны рәсми яктан танымый да иде. Бары тик аларның барлыгын белә һәм түзеп тора иде. Шуңа күрә бу мәктәпләргә матди ярдәм күрсәтелү турында сүз булуы да мөмкин түгел.

Кайбер хосусларда билгеле бер мохтариятка ия булган һәм ара-тирә мәгариф эшләре белән дә шөгыльләнгән «Земство» дип аталучы мәхәллә идарәләреннән дә, ул замандагы корылыш (структура) үзенчәлекләре сәбәпле, бу мәктәпләргә матди ярдәм көтелә алмый иде. Шуның өстенә хөкүмәт теге яки бу сылтау белән әлеге мәктәпләрне теләсә кайсы вакытта яптыра ала иде. Шуңа күрә аларга, хөкүмәт каршысында: «Киртә генә ясама, башка рәхим-шәфкать өмет итмим»,— дип яшәүдән башка чара калмый иде.

Бу рәсми кыенлыклардан тыш, мөселманнарның үз араларында калкып чыккан кайбер искелек тарафдарларының көчле каршы торуы да бар иде. Болар, дәүләт өчен куркыныч, зарарлы кешеләр, дип яла ягып, җәдитчеләр өстеннән хөкүмәткә шикаять итүдән дә хәтта тайчанмыйлар. Шундый яла ягу аркасында югарыда искә алынган мөдәррис Галимҗан Баруди төньяктагы Вологда өлкәсенә сөргенгә дә сөрелә. Моңа охшаш башка күңел кайтаргыч вакыйгалар да булмый калмаган. Казанда ул дәвердә бу каршы көчләр басылыр өчен реакцион газеталар булмый, шуңа күрә болар «ысулы җәдит»не юкка чыгару максаты белән, «Әл нусулу хәдидә фи хилафи усулу җәдидә» (Ысулы җәдиткә каршы тимер уклар) дигән гарәпчә исем белән аталган памфлетлар басып тараталар.

Димәк, бер яктан, хөкүмәтнең Дамокл кылычыннан саклану чараларын эзләү белән шөгыльләнгәндә, икенче яктан, үз арабыздан кара көчләрнең «тимер очлы укларына» каршы тору авырлыгы да бар иде. Кавказда, бигрәк тә бүген Әзәрбайҗан дип йөртелгән Көньяк Кавказда, төркиләр арасында ысулы җәдит мәктәпләренә каршы нинди ялгыш һәм кара уйлар яшәгәнен әзәрбайҗан шагыйре, сатира остасы мәшһүр Сабирның «Дәрси ысулы җәдид» исемле шигыре бик ачык чагылдыра.

Бөтен бу каршылыкларга да карамастан, «ысулы җәдит» хәрәкәте зур тизлек белән җәелә бара. Ягъни 1884 һәм 1905 еллар арасында Бакчасарайдагы үрнәк мәктәптә, төрле өлкәләрдән килеп, сиксәнгә якын укытучы ысулы җәдитне өйрәнә, биш меңләп яңа мәктәп ачыла, искеләре үзгәртеп корыла.

Яңа мәктәпләргә укытучылар әзерләү максаты белән электән яшәп килгән мәдрәсәләрнең бер өлеше заман таләпләреннән чыгып үзгәртелә һәм яңалары да ачыла башлый. Боларның үзгәртеп корылганнары да, яңадан ачылганнары да үзенә күрә бертөрле укытучылар әзерләү мәктәбенә әверелә. Электән яшәп килгән һәм үзгәртелгән мәктәп-мәдрәсәләр — Казанда Г. Баруди идарә иткән «Мөхәммәдия», Оренбургтагы Хөсәеновларның матди ярдәменә яшәгән «Хөсәения», Уфа шәһәрендәге «Госмания» мәдрәсәләре, яңа ачылганнардан Уфада зыялы мулла Зыятдин Камалинең «Галия», Гобәйдулла һәм Габдулла Бубилар ачкан Буби авылы мәктәбе бу төр мәктәпләрнең иң әһәмиятләреннән. Кавказда мондый мәктәпләр оештырылганда бик күп Төркия педагогларының белем һәм тәҗрибәләреннән файдаланганнар. Төркестанлыларга исә бу хосуста кавказлылар белән казанлының ярдәме тигән.

Ысулы җәдит мәктәпләренең ачылуы, киңәюе һәм дәвамлылыгы өчен киң күңеллелек белән матди ярдәм күрсәтеп торучылар: әзәрбайҗанлы Хаҗи Зәйнелгабидин Такый, Шәмси Әсәдулла; казанлылардан — Әхмәт, Гани һәм Мәхмүт Хөсәеновлар, троицкилы Яушевлар, Буби авылыннан Хаҗи Мөхәммәтҗан әфәнде; себер татары хаҗи Нигъмәтулла Карамышларның исемнәре хөрмәт һәм рәхмәт белән искә алынырга лаеклы кешеләр.

## Беренче урыс революциясе (1905)

Календарьлар чыгара башлаган көннәрендә (1870—1871 еллар) Каюм Насыйриның уенда бер газета чыгару фикере дә булуы беренче басылган календарендәге бер игъланнан аңлашыла. Бу игъланда болай диелгән: «Бу календарь 72 нче елда да чыгар, мөгаен, шаять тәңре әҗәлгә мөһләт бирсә (кичектереп торса), моңа охшаш бер татарча газета чыгару ниятебез дә бар. Ләкин халык теләрме? Укырга кызыксынып, абунә язылганнар булса, хәзерлекне тәмамлаганнан соң газетаның чыгуы турында халыкка белдерелер иде». Насыйриның газета чыгару уе турында шул игъланнан башка бер мәгълүмат та юк. Бу «эш» бары тик ният булып кына калдымы, әллә бу юлда бер омтылыш булып та, хөкүмәттән рөхсәт алына алмадымы? Билгеле түгел. Ни булса да, XX гасырга кергәндә татарча ни бер газета, ни бер журнал чыгарылсын? Хәлбуки, татарлар арасында фикер һәм мәдәният хәрәкәтләре киңәйгән һәм алга киткән саен, вакытлы матбугат ихтыяҗы үзен бик көчле сиздерә башлый. Икенче яктан, ул вакытларда Казан зыялылары арасында газета һәм журналларда язышачак, кулы каләм тотар кешеләрнең дә күбәюе күзгә ташлана. Мәсәлән, 1903 елда Тифлиста Мөхәммәт ага Шахтантинский тарафыннан чыгарыла башлаган «Шәркый Рус» газетасының гадәттә һәр нөсхәсендә шактый казанлы язучыларның төрле темаларга караган мәкаләләре чыгуы да моны ачык күрсәтә.

Ул вакытларда тегә яки бу кешенең татарча газета чыгару омтылышында булуы хакында белмәсәк тә, мондый бер омтылыш була калса урыс хөкүмәтенең «отказ сугачагы», ягъни кире кагачагы ап-ачык иде. Шул сәбәпле кайбер кешеләр газета яисә журнал урынына серияле рисаләләр (брошюралар) бастырып таратырга керешәләр. Мәсәлән, 1902—1903 елларда казый Габдерәшит Ибраһим әфәнде тарафыннан Петербургта нәшер ителгән «Миръат» (Көзге) исемендә серияле рисаләләр бу төр «күз буяучы вакытлы матбугат» иде. «Миръат»ның саннары бик еш чыкканга, К. Насыйриның «Календарь»ләренә караганда да күбрәк максатка ярашлы була.

Русиянең Ерак Көнчыгышта, Манчжурия тигезлекләрендә японнарга җиңелүе нәтиҗәсендә, 1905 елда кабынып киткән Беренче урыс революциясе, бөтен Русия императорлыгында шактый зур тетрәү барлыкка китерә һәм шул сәбәпле һәр өлкәдә азмы-күпме үзгәреш-яңарышлар беленә башлый. Бу революция

табигый ки, ул вакытта Русиядә яшәгән төркиләрнең һәм, шул исәптән, татарларның тормышында да шактый эз калдырмый калмаган.

Русиядә яшәгән төркиләр өчен 1905 ел революциясенең мөһим һәм уңай нәтиҗәләреннән берсе — төрки телдә вакытлы матбугатның мәйданга килүенә мөмкинлекләр ачылу иде. Югарыда да искә алганыбызча, беренче урыс революциясе кабынган көннәрдә иркен урыс илендә тик бер данә төркичә газета чыга иде, ул да Русиянең бер читендәге Кырымда нәшер ителгән «Тәрҗемән» иде. (Русиядә 1905 ел революциясенә кадәр «Тәрҗеман»нан башка төркичә газеталар да чыккалый иде, әмма болар Бакчасарай газетасы кебек озын гомерле булмыйлар. Әле 1875 нче елда ук, димәк, «Тәрҗеман»нан 8 ел элек Хәсән бәк Зәрбаби Бакыда «Игенче» исемле бер газета чыгара башлаган, тик бу газета хөкүмәт тарафыннан тиз ябтырылган. 1878 елда Үнсизадә хаҗи Сәет әфәнде Тифлиста «Зыяи Кавказия» исемле газета чыгара башлый. 1882 елда Үнсизадә Җәлал әфәнде шулай ук Тифлиста «Кешкул» газетасын нәшер итә. Боларның икесе дә үзләре чыгудан туктый һәм мөхәррирләре Төркиягә күчеп китә. Югарыда искә алынган «Шәркый Рус» газетасы да 1905 ел революциясенә кадәр генә чыккан һәм ябылган).

Революция кузгалган 1905 елда беренче булып чыга башлаган төрки газета Бакудагы «Хәят» була, аны исемнәре һәм эшләре Төркия төрекләренә дә мәгълүм булган Әхмәт Ага углы белән Гали Хөсәензадә бастыра. Тик ул 16 сентябрьдә үк үзеннән-үзе ябыла. 1905 елда чыга башлаган икенче төрки газета «Нур» була, моны Петербург ахуны Гатаулла Баязит чыгара. Беренче саны 15 нче сентябрьдә дөнья күрә. Казан татарчасында чыккан беренче газета булса да, мөхәррире, милли максатлар һәм мәнфәгатьләр ягыннан караганда, ышанычлы кеше булмаганлыктан һәм ул заманда кулы каләм тоткан язучылардан беркемне дә җәлеп итә алмаганлыктан, эчендә һичбер төрле җанлы фикер, житди сәяси мәгълүматлар, файдалы хәбәрләр, яңалыклар нәшер ителмәгәнлектән, бу газета татарлар арасында бөтенләй таяныч таба алмый һәм матбугат тарихында татарча нәшер ителгән беренче милли газета булып саналмый. 1905 елда чыккан өченче төркичә газета — «Казан мөхбире», аның беренче саны Казанда 11 ноябрьдә басылган. Мин моны татарча чыккан беренче милли газета дип санау чынбарлыкка туры килә. (Газетаның иясе адвокат Сәеттәрәй Алкин булса да, төп рух «өрүчесе» һәм төп язучысы Йосыф Акчура иде.) 1905 елда чыга башлаган дүртенче төрки газета — беренче нөсхәсе Петербургта 24 нче декабрьдә басылган «Өлфәт». Мәшһүр зыялы вә сәяхәтче Габдерәшит Ибраһимов әфәнде тарафыннан чыгарылган бу басма, катнаш бер телдә язылса да, татар газетасы булып санала ала. Бу газетадан соң, шул ук 1905 елда, бишенче буларак, Бакуда Әхмәт Ага углы тарафыннан «Иршад» исемендә газета чыгарыла башлаган, аның беренче нөсхәсе 30 декабрьдә басылган. Күренә ки, русиялеләргә хөррият һәм конституция режимын вәгъдә иткән «17 октябрь манифест»ы игълан кылынган 1905 елда ук биш данә төрки сәяси газета чыга башлый һәм болардан өчесе татар телендә языла («Нур», «Казан мөхбире», «Өлфәт»). Алдагы ел (1906) исә бу өлкәдә иң уңышлысы була, чөнки бу ел эчендә төрки телдә тәгәл 14 данә сәяси яңа газета чыга башлый, боларның сигезе Казан татарлары телендә языла һәм болардан бишесе Казан шәһәренә туры килә...

1907 елда да яңадан-яңа сәяси газеталар чыгуларын дәвам итә. Бу ел эчендә чыга башлаган газеталарның саны унике, болардан җидесе Казан татарлары телендә басыла...

Бу газеталарның зур бер өлеше икътисади сәбәпләрдән, берничәсе исә сәяси сәбәпләр аркасында ябыла, 1907 елның ахырларына таба болардан («Тәрҗеман»ны санамыйча) бары 14 данәсе кала. Казанда «Йолдыз», «Казан мөхбире», әмма ул вакытларда инде элекке «Казан мөхбире» булмыйча, сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Сәйдәшев хуҗалык иткән һәм Гали Саенов идарәсендәге рухы сүнек һәм зәгыйфь бер кәгазь кисәге: «Бәянелхак»; «Әл-ислах»; «Әхбәр»; Әстерханда «Борһани тәрәкъкый» һәм «Идел», Оренбургта «Вакыт»; Петербургта «Нур»; Бакуда «Таза хәят» һәм «Иршад»; Кырымда (Карасубазар) «Ватан хадиме»; Ташкентта «Түҗҗар» һәм «Шөһрәт».

Беренче бөтендөнья сугышы башланган вакытта исә элеккеге газеталардан Казанда бары бер «Йолдыз» кала. «Кояш» исә соңыннан, 1912 елда («Йолдыз»ның зәгыйфь яктысын юкка чыгару өчен булса кирәк) чыга башлаган бер газета. Моның наширләре зур сәүдәгәрләр, бертуган Кәримовлар булып, җаваплы мөхәррире Зәкәрия Садретдин, секретаре һәм баш язучысы танылган хикәяче Фатих Әмирхан иде. Оренбургта да «искеләр»дән бер «Вакыт» кына бар иде. Әстерханда «Идел» газетасы бик авырлык белән генә чыга иде. Уфада ул вакытта

бер газета басыла, әмма ул элеккегесе булмыйча, 1913 елда нәшере башланган яңа «Тормыш» иде. Бу газетага Уфада шактый шикле һәм караңгы «эш»ләр белән танылган Вәгыйз Нәүрузи тарафыннан нигез салына, тик соңыннан аны сәүдәгәр Гыйбадулла Госманов үз кулына ала һәм баш язучылыкны да зыялы мөгаллим Закир Кадыйрига йөкли. Болай да артык ялтырамаган «Нур» күптән сүнгән, «Дума» исә, таратылган I һәм II Думалар белән бергә югалган була. Бакыда да иске газеталарның берсе дә калмый. Төркестанда да ул вакытларда беренче революция дәвереннән калган һичбер милли газета булмый. Кырымда да XIX гасырның ахырларында ук чыга башлаган «Тәрҗеман» гына яши иде.

Күренә ки, югарыда исемнәре саналган газеталарның бер өлеше йә сәяси, яисә икътисади сәбәпләр аркасында ябылырга мәҗбүр булсалар да, байтагы әле даны чыккан Столыпин хөкүмәтенең «революцияне бастыруы»ннан соң да эшен дәвам итә. Ә бераздан исә ябылганнары урынына төрле шәһәрләрдә яңадан-яңа газета һәм журналлар барлыкка килә башлый.

Казанлылар 1916 елда, сугыш вакытына туры килгәнгә бик үк тантаналы итеп булмаса да, көндәлек матбугат тууының 10 еллыгын билгеләп үтәләр.

Казанны мәскәүлеләр басып алганнан соң һәм кораллы бәрелешләр, сугышлар» тынганнан соң, Идел һәм Урал татарлары сәясәт белән шөгыльләнделәрме соң? Моңа мөнәсәбәтле рәвештә бер-ике тарихи вакыйганы искә төшерик.

XVII гасырның башларында, ягъни 1601 елдан 1613 елга кадәр дәвам иткән һәм Русия тарихында «болганчык заман» исемен алган дәвер үтеп киткәннән соң, 1613 елда яңа патша сайлау өчен (Романовлар династиясенең беренчесе булган Михаил Федоровичны тәхеткә утырту) Мәскәүдә җыелган «Земский Собор»га Идел һәм Урал буе татарлары вәкилләре дә катнаша. Болар, шөбһәсез, «аксөякләр вәкилләре булганнардыр. Элеккеге байларның калдыклары булган вә хан, мирза, бәк исемнәрен йөрткән һәм бераз өстенлекләргә дә ия булган бу төркемнең бер өлеше шул «буталчык» көннәрдә хөкүмәт яклы булып, баш күтәрүчеләргә каршы сугышта да катнашканнарына күрә, дәүләткә яңа хөкемдар сайларга тиеш булган зур «корылтай»га аларның вәкилләрен дә катнаштыру ул замандагы Мәскәү сәясәтенең ихтыяҗы булган. Ягъни болар, төрки-татар халкының вәкилләре булудан бигрәк, бер өстен катламның вәкилләре иделәр...

XVIII гасырга килсәк, Казан һәм Урал төркиләренең алдынгы кешеләре арасында Русиядән аерылып, мөстәкыйль бер мөселман дәүләте төзү фикере бу гасырда да яңадан җанланып дәвам итә. Казанның алдынгы кешеләре бу максатларына ирешү өчен башкорт баш күтәрүләреннән файдаланырга теләгәннәр. Бу баш күтәрүләргә, югарыда да әйтеп киткәнебезчә, Казан өлкәсеннән качып киткән кайбер кешеләр катнашканнар һәм бу фетнәләрнең максаты белән Кавказ, Кырым, Казакъ иле һәм хәтта Төркия кебек төрки өлкәләрне дә кызыксындыруны планлаштырганнар. Русиядән аерылган мөселман төркиләрне берләштереп, зур бер мөселман дәүләте төзергә уйлаганнар. Әмма бу баш күтәрүләрнең уңышсызлык белән тәмамлануын беләбез. Менә болар XVIII гасырда җәелгән һәм корал көче белән дә ныгытылган, бөек максатлар куйган мөһим бер сәяси хәрәкәт иде...

Моннан тыш, XVIII гасырның ахырына таба (1767 елда) Мәскәүдә Икенче Екатерина тарафыннан җыелган «Яңа кануннар проектын төзү комиссиясе»нә Казан төркиләреннән 27 кеше сайлана. Боларның күбесе мирзалар һәм «йомышлылар» (хөкүмәт хезмәтен башкаручылар) булып, бары тик ике-өчесе генә сәүдәгәр һәм «ясаклы»лардан сайланган. Димәк, бу комиссиядә дә төркиләрдән гади халык түгел, башлыча югары катлау вәкиллек итә. Боларның комиссиягә китергән «наказ»ларында бөтен халык өчен уртак бер теләк булса, ул дин ирегә һәм хаҗга барырга рөхсәт алу иде. Моннан башка сәүдә ирегә һәм салымнарның, мәҗбүри хезмәтләрнең азайтылуы, гаскәри хезмәтнең җиңеләйтелүе кебек теләкләр дә алга куела. Шулай ук мирзалар тарафыннан «төрки аксөякләрнең» рус дворяннары белән тигез хокукта булу мәсьәләсе дә уртага чыгарыла.

Европада югары бер сәясәт дәгъвасы дип йөртелгән миллият мәсьәләсенең иң соңгы чиккә җиткән һәм урыслар арасында да сәяси хәрәкәтләр шактый беленә башлаган XIX гасырда һәм хәтта XX гасырга кергәндә дә, Русия төркиләре (шул исәптән, Казан татарлары) арасында азмы-күпме әһәмияткә ия булган бер сәяси хәрәкәт тә күрмибез. Аларның XIX гасырның ахырларында булган хәрәкәтләре дә күбрәк мәдәни, тәрбияви һәм икътисади мәсьәләләрне күтәрү вә яңару хәрәкәтләреннән гыйбарәт иде. Чынлыкта, сәяси хәрәкәтләр бары тик 1905 революциясе кабынгач, сәяси газеталар чыга башлаган вакытларда гына беленә башлый.

Югарыда, «икътисади һәм фикри күтәрелеш дәвере» башы астында язганнарыбыздан да аңлашылганча, Казан татарлары арасында да XVIII гасырның соңгы яртысында эшлекле бер ижтимагый катлам һәм сыйныф пәйдә була, ул — сәүдәгәр сыйныфы иде. Бу сәүдәгәрләр катламы, югарыда күргәнебезчә, вакытында Казан өлкәсендә Бохара тибындагы мәдрәсәләр тота, мулла һәм мөдәррисләргә матди ярдәм күрсәтә, соңрак халык арасында җәелгән бер мәдәният һәм мәгариф хәрәкәтеннән гыйбарәт булган «ысулы җәдит» хәрәкәтенә дә матди яктан булыша. 1905 ел революциясе кабынганнан соң белеңә башлаган татар сәяси хәрәкәтенең дә бары тик бу сәүдәгәр сыйныфның матди ярдәме белән генә дәвам итәчәге шөбһәсез иде. Чынлап та, Бакуда, Казанда һәм Оренбургта бер төркем сәяси газеталар шул сәүдәгәрләр ярдәменә таянып ачыла һәм кайбер сәяси оешмалар да аларның ярдәме белән оеша. Ул көннәрдә Русиядә татарлар арасында көнбатыштагы мәгънәсендәге буржуазия сыйныфы булмаса да, мөмкин кадәр дөнья үсешеннән хәбәрдар, үз катламы яки сыйныфы мәнфәгатьләрен дөрес аңлаучы һәм үз халкының җәмгыять эшләре белән дә кызыксынучы кешеләр аз түгел иде.

Элек бу сәүдәгәрләр янындагы назариятчы (теоретик) һәм фикриятче муллалар, ә соңрак тәрәккыйпәрвәр мөгаллимнәр һәм мөхәррирләр булса, XX гасыр башланганда исә алар урынына күбесенчә урыс һәм заманча Европа мәктәпләрендә белем алган хокукчылар, сәясәтче һәм гәзитчеләр булды. (Мондый зыялылар арасында мәшһүр «Тәрҗеман» хуҗасы, кырымлы Исмәгыйль Гаспралы, Кавказдан адвокат Галимәрдән Тупчыбаш, казанлылардан адвокатлар Сәетгәрәй Алкин, Йосыф Акчура, Садрый Максуди, мөхәррир Фатих Кәрими, элекке офицерлардан һәм җир хуҗалары — алпавытлардан Котлыкай мирза Тәфкилев, Шаһхәйдәр Сыртланов, Сәлимгәрәй Җантурин, тәрәккый яклы муллалардан казый Рәшит Ибраһим, Муса Ярулла Бигичев, Галимҗан Баруди, Габдулла Апанай һ. б. аерылып чыгалар.) Чөнки инде заман үзгәргән һәм яңа заман таләпләренә җавап бирә алырлык фикер ияләре вә җитәкчеләр кирәк иде. Менә шулай итеп, заманның буржуазиясе булырга маташкан төрки сәүдәгәрләр белән аларның акыл ияләре булган зыялылар 1905 елның 29 августында Нижний Новгородта, Ока елгасындагы бер пароход палубасында җыелган корылтайда, «Мөселман мәшрути (конституцияле) халык партиясе» төзергә карар бирәләр һәм шундый карарлар чыгаралар.

*Ахыры киләсе санда.*

# РУХЫ СЫНМАГАН КӨРӘШЧЕ



Алтмышынчы-җитмешенче елларда Татарстан Язучылар берлегенең Г. Тукай исемендәге клубында төрле җыелышларга, кичәләргә юантык гәүдәле, озынча йөзле, күзлекле, һәрвакыт елмаерга әзер шат күңелле бер карт килеп йөри иде. Аны күреп алуга, М. Әмир, И. Гази, Ш. Маннур, Ә. Еники кебек танылган өлкән яшьтәге язучылар да сикереп торып:

— Килегез, кил, Мәхмүт абый, менә монда утырыгыз! — дип үз урыннарын тәкъдим итә иде. Ә бу карт:

— Рәхмәт, мин 26 ел утырдым инде, хәзер бераз басып торып ял итим әле,— дип шаярта.

Нинди Мәхмүт бу, нигә шундый мәшһүр каләм ияләре дә ихлас олылыклый аны? Сораша торгач, ниһаять, яшьләргә дә аның кайбер өстәмә кушаматлары мәгълүм булды — «Мәхмүт Бөдәйли», «Кигәвен», «Мәхмүт Һади» дигән исемнәргә берьюлы ия зат икән бу. Бу исемнәр дә әле серне ачып бетермәгәч, төшендерделәр: 1912 елдан бирле татар матбугатына язышучы, Татарстанда һәм Төркестанда Совет хакимиятен урнаштыруда актив катнашучы, «Чаян» журналына нигез салышучы, җырчы, шагыйрь, әдип, җәмәгать эшлеклесе, халык комиссары ул. Әмма иң хәтәре — милләтче, солтангалиевче булуы, шуның өчен 26 елын төрмә-сөргеннәрдә, шул исәптән, ике елын бер кешелек таш капчыкта үткәрүе икән. Табигый ки, ул дәвердә һәм аннан соң да бик озак аның исеме матбугатта күренмәде, үзе әле исән булса да, нәкъ ике буын аны белми үсте!

Мәхмүт Кәшфелһади улы Бөдәйли 1895 елның 3 апрелендә Казан губернасының Мамадыш өязе Иске Мәксим (хәзерге Татарстанның Ямаш) авылында туа. Яшьли ятим калып, үз тырышлыгы белән көн күреп, Троицк мәдрәсәләренең берсендә белем ала, Беренче Дөнья сугышында катнаша, шунда революцион-милли хәрәкәткә тартыла. В. И. Ленинга кадәр барып җитеп, Татарстан җөмһүрияте төзүне куәтли, Төркестанда милли мәсьәләне гадел хәл итүгә көчен сала, Бохара Халык Җөмһүриятендә РКП(б) ҮК инструкторы һәм Матбугат халык комиссары, Хәрәзем Җөмһүриятендә Рәсәй илчесенең урынбасары һәм башка җаваплы вазифаларны ихлас күңелдән башкара. 1922 елда Татарстанга кайткач, сәламәтлек саклау, гаделия (юстиция) халык комиссарлары урынбасары, «Резинтрест» идарәчесе, төрле гәзитләрнең редколлегияләре әгъзасы, өлкә партия конференцияләре, Республика Советы җыйналышлары вәкиле сыйфатында киң эшчәнлек җәелдерә. Шушы дәвердә аның сәясәткә, сәламәтлек саклауга, хуҗалык тармакларын җанландыруга багышланган аерым тәрҗемә хезмәтләре һәм асыл үз китаплары басылып чыга, «Замана көлкеләре» (1927), «Тормыш төпчекләре» (1928) дигән сатира-юмор җыентыклары дөнья күрә. Бу елларда ул вакытлы матбугатта, төрле җыйналышларда, кичәләрдә ялкынлы нотыклар сөйли, шигырьләрен һәм мәзәкләрен укый, татар, башкорт, казакъ җырларын җырлап, күп санлы тамашачыларның мәхәббәтен казана. Аның бу кайнар эшчәнлегендә төп урынны гасырлар буе изелгән туган халкына ирек, хөррият даулау, Татарстанның чын милли җөмһүрият булуы өчен гайрәтле көрәш тота. Менә шушы тырышлыклары аны тиздән милләтчелектә, солтангалиевчелектә гаепләргә сылтау була — Мәхмүт Бөдәйли белеме

тирәнәеп, тормыш тәҗрибәсе баеп, иҗади һәм оештыру сәләте, дәрте һәм дәрманы киң колач ала барганда зинданга илтеп ташлана.

1955 елда ирекка чыгарылса да, Компартия сафына кайтарылмаганлыктан (1918 елда кергән), ул гомеренен ахырына кадәр (1975) тоталитар режим эзәрлекләвеннән тәмам котыла алмый — ана бик озак эш тә, торак та бирелми, язган әсәрләрен чыгару юлына да гел киртәләр куела. Әмма иманыннан иң газаплы шартларда да баш тартмаган, гаделлекнең барыбер җинәсенә өметләнгән Мәхмүт Бөдәйли өлкән яшьтә дә төшенкелеккә бирелми, әдәбиятыбыз тарихындагы кушаматларны (псевдонимнарны) өйрәнә, «Юмор һәм сатира» антологиясен төзи (Таткитнәшер 1966 елда аның чирегe чамасын бастырып чыгара!), күренекле замандашлары хакында истәлекләр яза. Аның давыллы вакыйгалар эчендә яшьнәп үзган эшчәнлеге, нахак җәзаларны бик мул татыган фаҗигале тормышы махсус өйрәнүгә, мәгънәле һәм кызыклы иҗаты укучыларга киң һәм тулы танытылуга лаек. Түбәндә «Тормыш төпчекләре» җыентыгыннан алып тәкъдим ителә торган өзекләр дә шушы фикернең дөреслеген раслар дип ышанабыз.

## Мәхмүт Бөдәйли

# ТОРМЫШ ТӨПЧЕКЛӘРЕ

### Тәрбиям шулай

— Мәхдүм, син әле партиягә кергән идеңмени?
— Әйе, кергән идем.
— Кайчан чыгасың билгеле түгелме?
— Әти мине кергән җирдән кумыйча чыкмаска, дип тәрбияләгән. Куып чыгарганчы торам әле, ни булыр?!..

### Яңа кагыйдә

— Иптәшеңне кызартасың килмәсә, чит кешеләр алдында хатыны турында сорашма.
— Нигә?
— Кайсы хатынын сораганыңны белми аптырап торуы бар...

### Урламаган...

Х а к и м: — Бу әйберне син урладыңмы?
К а р а к: — Гомердә урлаганым юк.
Х а к и м: — Менә бу егет урлаганыңны үз күзе белән күргән ич.
К а р а к: — Ул алдаша. Мин аннан әйбер алганда бер кеше дә юк иде бит...

### Тиз икән...

— Бу хулиганлык кайчан бетәр икән?
— Хулиганнар беткәч.
— Ә хулиганнар кайчан бетәр икән?
— Бөтен көзгеләр ватылып беткәч.

— Көзгенең монда ни катнашы бар?
— Барып кара, шунда күрерсең...

## Матур мәхәббәт

— Җаным! Син мине яратасыңмы?
— Бик яратам.
— Бигрәк тә нинди чагымны яратасың?
— Киенеп өйдән чыгып киткән чагыңны!

## «Яхшы торалар»?!

— Нихәл, хатының белән әйбәт торасызмы?
— Бик әйбәт.
— Кычкырышмыйсызмы соң?
— Кайда кычкырышу, бер атнадан бирле сөйләшкәнебез дә юк.

## Куркырсың да шул...

— Шушы урамга чыккач, автомобиль гөрләп килә башласа, котларым чыга.
— Нигә алай куркасың?
— Бер көн шушы урамнан үтеп барганда автомобильгә салып хатынымны алып качтылар...
— Качсалар качканнар инде, аның нәрсәсеннән куркасың эш беткәч?
— Автомобиль гөрелдәп килә башласа, тагын шуны кире кайтара торганнардыр, дип куркам мин.

## Менә ничек аерыла ул...

— Сездә хатын-кыз оеклары бармы?
— Бар.
— Күрсәтегез әле?
— Сезгә нindиләрне күрсәтик, хатыныгыз өченме? Әллә яхшыракларынмы?

## Матәм тота

— Ирең үлгәнгә ай тулды, син әле һаман елап утырасың. Җитәр инде, үлгәнне алып кире кайтара алмассың.
— Мин аңар еламыйм, аның белән үткән ун елым әрәмгә үткәнен яңа гына белдем, шуңар елыйм.

## Сәбәбе бар...

— Нигә син күп сөйли башладың?
— Сәбәбе бар.
— Нинди сәбәп ул тагын?
— Шаулама, зур урынга керергә исәп бар. Күп сөйләгәч, актив дип зур урынга куймаслармы дим.

## Мәгънәсе

— Нигә теге учреждениедә «Күрешкәндә кул бирмәгез!» — дип язып куйганнар?
— Кул ришвәт булмаганга күрә.

## Тыңлаган

— Күзләрең нигә болай бик кызарган, яңа гына йокыдан тордыңмы әллә?
— Юк, яңа гына җыелышта доклад тыңлап чыккан идем.

## Менә «Билясем» нишләтә ул!..

Дөресен әйтим, егетләр, яратмыйм шул эшсез йөргән халыкны... Эшсез кешенең башы — шәйтаннарның кантуры, дип татар бер дә белми әйтмәгән. Килә дә ул сиңа йә бер нәрсә, йә икенче нәрсә турында «суган сатып», вакытыңны алып тик утыра. Зарлана, офтана. Әлләниләр кыланып, кәефеңне җибәреп, эшеңә комачаулап тик йөри.

Үзе гаять тиз рәнҗүчән, үпкәләүчән була тагы ул халык. Бер сүз әйтергә ярамый, хәзер кәкрәергә генә тора. Соң үзең уйлап кара: дөньяда үз күңелеңне табасыңмы, әллә алар хәтерен саклап утырасыңмы? Шуның өчен яратмыйм мин аларны. Минем хатын да туеп беткән инде алардан...

— Яратмыйм шул кашын-күзен җимереп, мунчасы янган урыс шикелле бөкшәеп йөри торган Гапкарыңны,— ди ул.— Юкка гына шулар белән вaксынып йөрисең. Шундый бетле халык белән демократлашкан булып азаплануыңа төкерер идем,— ди. Аның килгәнен тәрәзәдән күреп калса да: — Тагын берәр әйбер теләнергә килә торгандыр әле, хәерчнең йөреше юньлегә булмас,— ди.

Шулаен да шулай шул. Ул халык әле сиңа килеп зарланып туйдыруы җитмәгән, синнән урын сорап, фәлән итеп теңкәгә тия бит. Бурычка, кәтәргә, дигән булып акча да сораштыргалый. Һәрвакыт сорамаса да... андый кеше килеп кергәндә кызык түгел инде. Барыбер сорар төсле булып тора. Үзенә читен. Кайчан чыгып китәр икән, дип кыткылдап утырасың. Һәркемнең үзенә пар иш табуы яхшырак инде. «Ишмөхәммәт ише, Бикмөхәммәт бикәче белән булган яхшы», дигән китапта.

Менә безнең Гапкарны гына алыйк инде. Ярый, ул безнең якын дус кеше дә инде. Үзе әйбәт тә кеше. Теге вакытларда күп кенә файдасы тигән чаклары да булды. Кулыннан килгәнне, кулында барын аямый торган кеше. Ләкин, коданың кихмәте, эшсез калганнан бирле, әлләни күңелем чит күрә шуны, яратмыйм ук. Ничәмә айлар бит инде чикерткә кебек... сызгырып тик йөри. Урын таба алмый имеш... Рәтле генә кеше кебек иде. Ужым бозавы икән.

Үзе болай тырышып та йөри кебек. Сәбәбенә дә керешеп карый, кана. Ул йөрмәгән, ул кермәгән учреждение дә калмады инде, хезмәт биржасына барып язылуына да сигез ай үтте, югыйсә. «Татар телен эшкә ашыру комиссиясе»сеннән алмаган кәгазен, рекомендациясен дә калдырмады, югыйсә. Юк та юк. Һаман урынсыз. Гаҗәп җебегән малай булып чыкты.

Килмәсә, йөрмәсә тагын бер хәл иде әле. Теләсә нишләсен иде шунда. Юк бит, ул сиңа килә, утыра, зарлана. Әллә ни сорамаса да эчне пошыра. Сорамый ул соравын, сораганы да юк. Шулай да бүген сорамаса, иртәгә сорар, дип уйлыйсың. Яхшы түгел, ахры. Дус кеше, якын кеше бит. Шулай түгелме?..

Әнә, алланың гына каһәре төшкән икән бу Габкаһарга, тагын килә бит шул чукынган нәрсәкәй. «Өйдә юк», дип әйттерсәң, тәрәзәдән күреп калды. Инде нишләргә?! Тагын эшне бүләргә туры килә инде. Шулар белән бер юл язуны да юньләп яза алма инде, йә. Каләмне тагын ташларга туры килә шул. Нишлисең, язмышың шул. Булмас инде барыбер, соңыннан язармын...

* * *

Сезне бераз көттерергә туры килде бугай, укучым, ярый. Кичерерсез инде. Монда эшләр бик шәпкә әйләнеп китте әле. Дустым Габделкаһһар иптәш Чытлыкетдинев килгән иде дә, шуның белән сайрашып утыра торгач, бөтен нәрсә онытылган. Бик уңган, шаян егет ул. Аның белән бер утыруы ни тора. Аерыла алмый аптырадык. Үзе белән әз генә «пирәшләп» тә алдык. Ярамый, бик якын, бик иске дус кеше бит ул минем. Хатын да бик якын итә үзен. Өстәвенә зур гына урынга да кергән. Зур урыннарда үз кеше булу үзе ни тора ул. Бер дә булмаса бер файдасы тия аның. Ни булса да дус кешенең мәртәбә иясе булуына күңел бик куана инде.

Ну хәйләкәр, уңган да егет инде үзе. Ахыры урнашкан бит. Вәт, ичмасам, баш дисәң баш эшли!

Дөресен әйтсәм, мин аны шаяртыбрак каршы алган идем алуын.

— Нихәл, лудыр, ялкау, кайлардан болай себерелеп йөрисең,— дим. Егетем егетнең асылы шул. Ачулану юк, нитү юк:

— Ялкауларны эшсез дип гаепләгән булалар, тик торуны уен дип беләләр микәнни,— ди. Җитәр, ул газаптан котылдык инде. Тәбрик ит хәзер мине, мин фәләндәй учреждениедә секретарь булырмын хәзер, әфәндем,— ди.

Күзләрем тоздай булды. Ни дияргә дә белмим. Аптырап каттым да калдым. Калырсың да шул. Уен түгел ул секретарь!

Аның урнаша алуына һичберебезнең дә ышанычы калмаган иде инде. Әйтәм бит, һич бармаган җирен, күрмәгән кешесен, алмаган кәгазен калдырмаган иде.

Ахыры түзә алмадым, шөбһәмне белдердем.

— Чынлап ук урнаша алдың мәллә?— дим.

Теге миңа бер хәйләле карап алды да башына бармагы белән төртеп:

— Менә монда булса, урнашасың икән аны,— ди.— Сигез ай эшсез йөрү каен җиләге түгел, өйрәтә икән ул,— ди. Безнең «тартарализатсия» яшәсен, ул булганда урнашып була икән ул,— ди.

Мин тагы аптырадым. Һаман аңлап җиткерә алмадым.

— Рәтләп сөйлә әле,— дим.— Ничек булды соң ул? Әллә теге «тел кәмиссиәсе» үзе белән хисаплаштыра торганрак иттереп, эшне корырак тота башлаганмы?— дим.

— Тот капчыгыңны, тотар корырак. Көт әле ул вакытны, йөрерсең көпәкөндез йолдыз санап,— ди.

Мине бик озак ялындыргач, озаклап үзенең урнашу тарихын сөйләп китте:

— Мине бер урыс өйрәтте,— ди. Ул өйрәтү буенча, мин читкә киткән бер урыс иптәшемнең документларын алдым да, хезмәт биржасына барып, өр-яңадан «Матвей Данилыч Маслов» булып язылдым,— ди.— Һәм нинди генә һөнәрдән кеше кирәк булса да, үземне күрсәтергә булдым,— ди.

— Элек мин слесарь булып язылган идем. Хәзер секретарь кирәк дигәч, «мин» дип килеп чыктым да, күп җирләрдә секретарь булып эшләгәнемне сөйләп ышандырдым. Кәнсәләрдә эшне бетерделәр. Җибәрергә генә торалар иде, заведующий Фома Кузмич чакырып алды да:

— Иптәш Маслов,— дип әйтә ди.— Синең үзеңнең болай һәр ягың килгән икән. Син инде һәр хәлдә неграмотный татарин түгел, сине ул эшкә бик җибәрәсебез килә инде безнең. Ләкин бер правила бар бит. «Тартарализация»не белү шарт дип әйткән булалар бит, аңар нишлибез?— дип әйтә ди.

Мин эчемнән шатлансам да, тыштан бер дә артык белдерми генә:

— Булса бик әйбәт. Мин мала-мала беләм,— дип әйттем ди. Үзем һаман урысча сөйләшәм ди.

— Белгәч, бик шәп алай булгач,— дип заведующий Фома Кузмич куанганын белдерде дә ди:— Формальность өчен шулай кирәк. Сез инде мине гафу итегез, мин сезне татарча бераз имтихан кылырга мәҗбүрмен, дип әйтте ди.

— Мин: «пажалста», дигәч Фома Кузмич татарча сорый да башлады.

— Минеке татартча билясем?— дип әйтте ди.

Ул «минеке» дигәч, миңа «синеке» дип әйтергә кирәктер инде дип уйлап алдым да ди:

— Синеке татарча билям,— дип әйттем ди.

Тегенең башында «вак» бетте булырга кирәк, бераз уйланып торгач, тәмәкесен чыгарды да ди:

— Ширпа бар?— дип әйтте ди.

— Бар,— дип әйттем дә шырпы яндырып бирдем, ди.

— Рахмит,— дип әйтте, ди.

— Турми,— дип әйттем, ди.

— Как, как, «Турми»? Что значит «турми»?— дип әйтте ди.

— Не стоит, диган сүз була дип әйттем ди. Аны бик куанып язып алып:

— Син яхшы беләсең икән,— дип әйтте ди.— Язарга билиасем?

— Билиасем,— дип әйттем ди. Бик эре генә бер кәгазь алып, ниндидер шайтан ботлары сызгалап бирдем, ди. Аннан соң шул кәгазьне күрсәтеп:

— Это будет Маслов,— дип күрсәткән идем, заведующием шаккатты, ди. Шундук миңа назначение дә бирделәр. Хәзер мин, әфәндем, «тартарализация» аркасында «билиасем» белән секретарь булдым. Эшләр рәтләнә,— ди.

Нишләтәсең аны, егет шул, булган!..

Менә баш дисәң баш ичмасам безнең Гапкаһарда.

*16 сентябрь, 1927 ел.*

А Л У — коммерческий директорлардан сорагыз, ничек «алганнарын» әйтерләр.

Кайбер властьта утыручыларга да бик таныш сүз. Үзен һәркем ярата.

А Ш А У — хужалык органнарында эшләүчеләр өчен махсус лөгат. Ике төрле ашау бар: элекке халыклар башта үтереп, аннан соң «утыралар».

А Р П А — элек басуда үсә торган иде. Хәзер пакьлыкка кайгыртмау итмәүчеләрнең күзләрендә үсә. Бик уңышлы ашлык.

А П Т Е К А — үз саулыгының кадерен үзе белмичә штраф илтеп түли торган бер җир.

А К Ч А — элек товарларга үзе бәһа куя торган нәрсә иде. Хәзер бәһа артыннан үзе уҗым бозавы кебек ияреп йөри торган бер юаш мәхлук. Шунда да хезмәт хакын арттырганда, күзен акайтып югартын караучан.

А Б Ы Й — карт кызлар үзләрен яшь күрсәтер өчен уникe яшьлек малайларны шулай дип йөртәләр. Кырык яшьлек сәүдәгәрләр дә үзләренә файда итәрдәй яшьләргә шулай дәшәләр. Бик төче тәгъбир.

Б А Р — борынгы заман сүзе. Хәзер күп кулланылмый. Аның урынына юк сүзе йөртелә. Мәсәлән:

— Атың бармы?

— Юк.

— Хатының бармы?

— Юк.

— Телең бармы?

— Юк.

— Мәдәниятең бармы?

— Юк.

— Хәрефең бармы?

— Юк.

— Акылың бармы?

— Юк! вә башкалар...

Б А Ш — ул элекке замандагы бабаларыбызның ми белән тулган уйлау аппараты булган. Хәзер кешеләр муен белән генә йөрергә гадәтләнү аркасында, артык кирәге калмаган бер «әсәре гатика» (борынгы нәрсә).

Б А Р А Б А Н — эче буш була. Үзе бик шалтырый. Хәзерге язучыларга бик охшаган бер нәрсә шунда. Кайбер студентлар да көзгегә караганда шуны күреп торалар.

Б О Р Ы Н — һәр кешенең бит уртасында ындыр табагына төшеп калган тукмак шикелле, тумпаеп тора торган бизәк. Кич белән Пралумныйда сонгарак калып «пайдум» бикәләр артыннан искәнеп йөрүчеләрнеке көннән-көн кечерәя баручан була.

Әгәр керделе-чыктылы халыктан берәрсе нарком-фәлән була калса, аларныкы көннән-көн үсә, зурая һәм шешә бара.

Әгәр аның берәр докладны да иттифакый гына удачный да чыгып куйса, борын үсә-үсә һава көймәсе шарына әверелеп, наркомны күккә күтәреп китә дә югары салкын температурага җиткәч, сабын куыгы төсле шартлап, борын сәхибе метеор тизлеге белән «очып» төшә.

Андый төшү бәласенә грифтар булган кешеләр, күбрәк, шундый мәгънәсез «очу»ларның һич сәбәбен ахмаклыкларыннан икәнлеген аңламыйчан, уку-белем юклыктан икәннән уйлап, грамота өйрәтә торган мәфтеккә керергә йөрүчән булалар.

Бабайлар алар турында: «Ана сөте белән кермәгән тана сөте белән кермәгәй», диерләр.

Икенче бер риваятьтә:

«Ахмак булыр өчен тәһарәт алырга да, укып чуалырга да хаҗәт юк», димешләр. «Валлаһи игълам бишшибиш».

Т А Т А Р — бу Идел, Агыйдел, Чулман, Нократ, Болак дәрьялары буенда яшәүче бер халыкның исеме. Үзе бик дәрәҗә сөючән, пүртәфил яратучан, байлык теләүчән, галимлек эстәүчән кешеләрне күп җитештерә торган бер милләт булып, соңгыларның сөймәгән нәрсәсе: шуларның сәбәбенә керешү һәм иң дә яратмаган, күрә алмаган нәрсәләре — татардыр.

Бу халыкның зурлары һәр нәрсәнең җиңел булуын тели. Алар укымыйча галим, тырышмыйча түрә, эшләмичә бай, латин хәрефе өйрәнеп доктор булуны хыялланып йөри торган бер хөрәсән ялкаудырлар.

Төркемсез тора алмый, икенче төркемнәрне күрә алмыйлар. Боларның кәсепләре сату, сатылу һәм башка татарлар өстеннән донос язып торудыр.

ТАТАРСТАН — моны мөхәррирләрчә иттереп шәҗәрәләп, озынрак иттереп язарга уйлыйбыз. Ул минем хатынның кайнатасының улы белән бертуган абзасының кодачасы белән бертуган тумасының олы малае Сәхиб Гәрәй абзыйның балдызына кайниш тиешле кешенең хатыныннан туган бер яшь бала. Зур мөхәррирләр кебек озын-озак җөмләләр белән язсак, баланың хәле менә болай: Авыл рәисе кәгенкерәп йөрү белән мәшгуль булу сәбәпле, авылга көздән үгез китерми калу сәбәпле, сыерларыбыз кысыр калу сәбәпле, ашарга катык-сөт булмау сәбәпле, шуның нәтиҗәсендә ачыгырга туры килү аркасында, бу бала да ачыгу аркасында, кыскасы, шундый бик күп сәбәпләр сәбәпле, бала шактай арык булуга карамый, үзе бик уйнарга, көләргә ярата. Ләкин үзе бигаять сакау. Төрле кәмиссияләр телен чыгарырга бик азаплансалар да, шуның өчен күп кенә аппаратлар куеп карасалар да, әле дә булса теле чыкмый. Үзен укытырга инде бик вакыт җиткән булса, да,— бердән, «крахиздат» әлеппи бирми. Уку китабы юк. Икенчедән, наркомфинның параграф читлегеннән чыгып качкан аюлары юлдагы бөтен мәктәпләрне җимереп йөрү сәбәпле, «мәфтәк» юк. Өченчедән, бик күпләр:

— Әле монда бюджет каймагы телләләргә дә җитми, дип йөргәнгә күрә, «телсез»не кайгырткан кеше дә юк.

ТАРАКАН — моның карасы да була, кызылы да була. Һавасы бик үк саф булмаган җепшегрәк җирләрдә була торган бер җәнлек. Үзе кайбер җаваплы эшчеләр кебек җылы урыннарны, унайлы почмакларны яратучан була. Итәкҗиңнәрен җыеп, сакланып йөри белми торган халыкларның ашларына төшүчән була.

ҖҮНЛЕ — җүнле кеше дә, җүнле бер әйбер дә калмагач, хәзер кулланудан чыккан сүз. Җүнсезләр генә калды.

# ЯЗМЫШ ҺӘМ ИҖАТ

«Халык үткәннәрне тарихчы кулыннан түгел, шагыйрь кулыннан кабул итеп алырга тели»,— дип язды Һенрих Һейне. Шушы хакыйкатьне торган саен тирәнрәк аңлап, татар әдипләре дә тарихның төрле-төрле чорлары белән тагын да ныграк кызыксына һәм үткәннәрнең моңа кадәр күләгәдә калдырылган яки күрсәтергә ярамаган якларын яктырта башлады.

Сталинизм белән бәйле чорның шундый якларына татар әдәбиятында беренчеләрдән булып Ибраһим Салахов мөрәҗәгать итте. Бу бер дә очраклы хәл түгел. Чөнки И. Салахов — шәхес культы чорындагы гаделсезлекләрне үз җилкәсендә татыган әдип. Ул «Колыма хикәяләре», «Утсакал», «Намаз», «Сагыну» һәм үзе әйтмешли, «тәрәзә капкачларын ябып, пәрдәне төшереп, ишекне бикләп» язган башка әсәрләрендә шәхес культы елларының фаҗигасен бөтен тулылыгы белән күрсәтә алды.

Сталинизм дәверен яктырткан әсәрләр, һичшиксез, катлаулы чор турында һәм геройларның эчке кичерешләре, каршылыклар белән тулы әсәрләр алар. Чөнки сталинизм — Сталин шәхесе генә түгел бит. (Әлбәттә, бу очракта безгә «бөек ата»ның ролен тарайтырга ярамый, ул үз вакытында гаять зур роль уйнаган.) Шул ук вакытта, Сталинизм — Сталин тирәсендә «укмашкан» икейөзле кешеләр җыелмасы һәм шәхес культы гына да түгел. Ул — бөтен ил күләмендә үтелгән юл, тарихи дәвер. Әмма, чиста битлек астындагы канлы йөз кебек, вәхшилек һәм астыртын эшләр, әләк ташкыны хөкем сөргән дәвер ул. Тарихта шундый бер мисал билгеле: 1934 елның 8 июнендә чыккан закон буенча, донос ясамаган өчен дә җәзага тартканнар (А. Литвин «Кемнәр алар, корткычлар» Татарстан коммунисты, 1990 ел, 11 сан, 62 б.) Әлбәттә, шундый катлаулы заманны үз вакытында ук аңлау, бәяләү бик авыр булган. Ә бүген исә бу тарихи дәверне бөтен ваклыклары белән яшь буынга аңлатып бирергә кирәк. Әнә атаклы шагыйребез Гамил Афзал да бит:

Тарихын белмәгән халык,

белгәннәрнең колы була,— дип язды. Нәкъ менә шуңа күрә, язучыларыбыз бу юнәлештә эшләп, матбугатта үзләренең әсәрләрен әледән-әле бастыра торалар.

Соңгы елларда дөнья күргән китаплардан Р. Мөхәммәдиевнең «Сират күпере», А. Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога», Г. Тавлинның «Афәт», Л. Бадыйкшанның «Мөртәт», Ф. Бәйрәмованың «Кыңгырау» әсәрләре шәхес культы елларын аңларга ярдәм итә. Гаепсезгә хөкем ителгән күренекле затларның тормышларын ачып бирә алар. Шушы чорны һәм дәүләт вәкилләренең чын йөзләрен, эчке системаны, сүз белән эш, чынбарлык һәм матур бизәкләр арасындагы аерманы, сталинизм системасы тудырган «яңа кеше» образларын күрәбез без анда. Үткән тарихыбызның «заман көчленеке» дигән девиз астындагы яшәеше белән очрашабыз. Бу чор — тарихыбызның «ак табы». Ә әсәрләрдә — фаҗига. Аерым шәхес фаҗигасе генә түгел, бу әсәрләрдә бөтен бер халык — татар халкының, аның күренекле улларының фаҗигасе.

Өлкән язучыбыз һәм шәхес культы елларының беренче дулкыны корбаны Ибраһим Салахов та үз әсәрләре белән бүген чаң суга:

«Укыгыз, белегез, гыйбрәт алыгыз, мондый хәлләр тагын кабатлана күрмәсен»,— ди ул.

Әдип белән үзара әңгәмә вакытында мин, кызыксынып:

— Ибраһим ага! Язучыларда бик күп вакыт әсәрләрен яңадан карап чыгу, кайбер бүлекләрен үзгәртү теләге туа. «Колыма хикәяләре» роман-фаҗигасенә карата Сездә дә андый уй туганы юкмы?,— дип сорадым.

— Юк. Әсәрдәге бер генә нәрсәне дә үзгәртеп булмый. Чөнки бит әсәр — чынбарлыктан алып язылган. Анда телгә алынган һәрбер вакыйга, һәрбер кешенең исеме, фамилиясе — барысы да тормыштан. Уйдырма юк. Шуна күрә бернәрсәне дә үзгәртеп булмый. Әсәргә кертелми калган төрле вакыйга, хәлләр белән романны тулыландырырга мөмкин. Ә язылганнарын арттырып та, киметеп тә булмый. Мин хәзер күңелгә уелып калган, «Колыма хикәяләре»нә кертелмәгән вакыйгаларны аерым истәлекләр рәвешендә язам. Тиздән менә, боерган булса, «Аргамак» журналында «Намаз» исемле истәлек басылырга тиеш.

Әлеге истәлегендә Ибраһим ага Тубыл төрмәсендә, ялгыз камерада утырган вакытларын сурәтләп бирә.

— Мине «одиночка»га яптылар. Сөйләшергә бер кеше юк, укырга ярамый. Кысан гына бүлмәдә ут-лампа гына янып тора, тәрәзә юк. Көнне-төнне дә, күпме утырасын да белмисең. Гел бер нәрсә турында уйлау — искиткеч авыр халәт. Ул акылдан шаштырырга мөмкин. Бу хәлдән котылу өчен мин намаз укый башладым. Тәүлегенә биш тапкыр намаз, догалар укыйм. Укыган вакытта сәҗдә китәсең. Ходага һитап (мөрәҗәгать) итәсең, күңел рәхәтләнә, онытыласың. Төрмәдә булуыңны да онытасың. Мин хәзер уйлыйм: мөгаен шушы намаз укулар ул вакытта ярдәм иткәндер. Намаз уку нәтиҗәсендә генә мин ялгызлыкны, күңелсез уйларны, шул вакыттагы авырлыкларны җиңә алганмындыр.

Кешенең рухын сындыру, буйсындыру, мескенләндерүнең тагын бер ысулы. Арада сыгылучылар, егылучылар да күп булган... Әмма үзләренең тоткан кыйблаларыннан, юлларыннан ваз кичмәгән, сынатмаган затлар да күп очраган.

Мисалга язучының «Идел» журналында (1989 ел, 6 сан) басылып чыккан «Утсакал» хикәясе. Хикәядәге вакыйга 1941 елның маенда, Колыманың Ягодный приискасында бара.

Төп герой — Мифодий Кириллович. Ул унҗиде ел буе төрмә-лагерьларда михнәт чигә, әмма үзенең «ут кебек янып торган» сакалын алдырмый. Шуның өчен аны карцерларга ябалар, кыйныйлар, паеклардан мәхрүм итәләр. Әмма ул үз сүзендә нык тора.

— Без, староверлар төркеменнән, кыйблабыз — протопоп Аввакум,— ди ул.

— Кешеләр сугышырга түгел, туганлашырга, бер гаиләдәй тату яшәргә тиеш. Шуның өчен без солдат хезмәтеннән баш тартабыз. Чөнки солдат — кеше үтерүче. Шимбә көннәре фани дөнья мәшәкатен ташлап, безне бар иткән аллаһе тәгаләгә генә гыйбадәт кылырга кирәк. Менә шуның өчен Советлар хөкүмәте дә безне ят күрә һәм эзәрлекли.

Ә «Инҗил»нең әүвәлге, төзәтелмәгән аяте исә сакал-мыек кыруны тыя икән. Нәкъ менә шуңа, үз диненә тугъры калып, «мөртәтлек»кә барырга теләми ул. Үз диненә бирелгәнлеге, үз кыйбласы булу — образга карата соклану тудыра. Әмма, М. Кириллович кебек нык ихтыярлы кешеләр төрмә башлыкларына ошамый, әлбәттә. Һәм шуңа, аның тормышы да аянычлы тәмамлана: тоткыннарның «алла»лары аны фаҗигале үлемгә хөкем итә. Ялангач калдырылган М. Кириллович көне буе кояш астында, озынборыннарның ябырылып талавына түзә алмый үлә.

— Анда күргән газапларны сөйләп бетерә торган гына түгел,— ди Ибраһим Салахов.— Ләкин мин ышандым, өметләнгәнемә барып җитәрмен кебек иде... Роберт Пэринең бер китабын укыган идем (Ялгышмасам, китапның исеме «Төньяк полюс» дип атала.) Ул полюсны ачу өчен тугыз тапкыр экспедиция ясый. Гел каршылыклар, көтелмәгән хәлләр килеп чыга — экспедиция уңышсыз тәмамлана. Ә менә унынчы юлы ул уңа, полюсны ача. Авыр вакытта мин шушы китаптан хәтеремә кереп калган сүзләрне кабатладым. «Судьба благославляет того человека, который не оставляет свои стремления до гробовой доски».

Кулымда Ибраһим Салаховның «Сагыну» истәлеге.

Аңа эпиграф итеп Х. Туфан шигыре алынган:

Беренче кат куллар бирешкәч үк
Таныдың син безне, таныдың.
Ярты сүздән аңладың син, Себер,
Бездә керсез йөрәк барлыгын.

Истәлегендә И. Салахов үзенең якын дуслары Хәсән Туфан һәм Сөббүх Рафиковны юксына. «1956 ел. Көз. Казан. Кар аралаш яңгыр ява. Шыксыз көннәр. Әмма нәкъ менә шушы шыксыз-күңелсез көннәр безнең язмышта иң шатлыклы-якты көннәрнең берсе булды». (И. Салахов. «Сагыну».)

...Менә ниһаять — аклану кәгазе. 19 ел буена көтеп, инде бу көннең килеренә ышанмый да башлаган язучы, үзенең реабилитацияләнүе турында Верховный суд

карарын кулына ала. Шунын өстенә тагын бер шатлык: ул Татар опера һәм балет театры бинасы ачылу тантанасына чакырыла. Көтмәгәндә бу хәл Ибраһим аганы сискәндереп җибәрә һәм әдип узган юлын яңадан күз алдына китерә.

1937 елда Казан педагогия институтының өченче курсында укыган егет, бу мәһабәт бинаның нигезен салуда катнашкан икән бит. Студент вакытлар һәм «бакыр бабай» бакчасындагы өмәләр әдип күңелендә кабат яңара.

Ә шулай да безнең өчен иң әһәмиятле вакыйга — әдипнең Хәсән Туфан һәм Сөббух Рафиков белән очрашуы. Бергә хөкем ителеп, «халык дошманы» дигән ярлык белән берсе — Котласка, икенчесе — Норильскига, өченчесе — Колымага сөрелгән өч дус, 19 елдан соң очраша.



Рәсемдә: Сөббух Рафиков, Хәсән Туфан һәм Ибраһим Салахов.

Еллар аларны үзгәрткән. Маңгайлар җыерчыкланган, күзләрдә моң, чәчләр сирәгәйгән. Ә Ибраһим ага лагерь юлларында аягын югалткан...

Бу истәлек Х. Туфан һәм С. Рафиков шәхесен тагын да ачыбрак бирә. Шуңа күрә ул тарихи яктан да әһәмиятле.

«Сагыну» әсәре, «Колыма хикәяләре»нең дәвамы булып яңгырый. «Колыма хикәяләре»ндә без, «халык дошманы» дип гаеп тагылганнан соң язучы күңелендәге авыр уйлар, узган юллар белән очрашсак, яңасында исә, акланганнан соңгы бәхетле көннәре белән очрашабыз.

Авыр еллар... Иң якын кешеңә, дустыңа сереңне ачарга, ышанып сөйләшергә курыккан заманнар. Шушындый вакытта, Октябрьнең егерме еллыгын каршылау алдыннан, 1 Май демонстрациясенә әзерләнеп йөргән көннәрдә, И. Салахов К. Нәҗми белән Г. Ибраһимов арасында «контрреволюцион йомышларны үтәп йөрүче булган» дип кулга алына, хөкем ителә. Яшь язучы тормышындагы кискен бу борылыш, әләк язучы Фазыл исеме белән бәйле.

Фазыл — сталинизм чорының «өлгергән» җимеше. Өлгергән, чөнки ул үз планын тормышка ашыру өчен түбәнлекләргә төшүдән дә чирканмый. «Биофак мадоннасы» Зәйтүнәне үзенә карату өчен, Ибраһимны юлдан алып ташларга кирәк. Нишләргә? Иң җиңел юл — донос язу. Үч алу өчен моннан да уңай чор, җиңел юл юк. Дөрес фикерләгән Фазыл: каршылык җиңел генә юк ителә. Зәйтүнә аның кулында, планнар тормышка ашкан.

Ә мин мондый юл белән табылган бәхет озакка барырга тиеш түгел дигән ышаныч белән, Ибраһим абыйдан Фазылның алдагы тормышы белән кызыксынам. Чыннан да, Фазыл кырыгынчы елларда ук үпкә авыруыннан вафат... Ә Башкортстанның ямьле Агыйдел буендагы Бөре шәһәрендә туып-үскән Зәйтүнә, 1955 елда, кырык яшендә вафат булган.

И. Салаховның тормыш юлы белән танышканда һәм язучының үзе белән әңгәмә корган вакытта кызык кына күренешкә (закончалык дип атаргамы аны) тап булырга туры килде. Ибраһим агага зыян салган бер генә кеше дә бәхетле була алмаган икән. Ирексездән сорау туа: ничек алай? Очраклылык дип аңлатасы килми, «заманына күрә» дип кенә аңлату да канәгатьләндерми. Татар халкында «кешенең иясе, өрәге бар» дигән ышану да яши бит әле... Гомумән, ничек кенә булмасын, явызлык җәзасыз калырга тиеш түгел. Безгә шунысы ачык.

Әсәрдә шундый бер вакыйга бар: чиркәүгә ябылгач, староста кушуы буенча И. Салахов көн саен тоткыннарга әкият сөйли. Студент вакытында укыган

«Әбугалисина кыйссасы», «Шаһнамә», «Салсал», «Кырык вәзир кыйссасы» һ. б. әкиятләрне сөйләп ул тоткыннар арасында дәрәҗә казана. Әмма бу эшнең азагы аянычлы тәмамлана — аны көтмәгәндә икенче төрмәгә күчерәләр һәм мондый гаепләү акты языла:

«Сез җинаятьчеләрне төрмәдән качарга өндәгәнсез һәм, шул явыз ниятегезне тормышка ашырыр өчен, төркем туплагансыз, чиркәү идәне астыннан подкоп ясарга әзерләнгәнсез».

Әсәрдәге «Алла йортында» дип аталган бу бүлекне укыганда ирексездән елмаеп куясың. Эш гади генә бит: әкият сөйләгән вакытта И. Салахов, тыңлаучыларга кызыграк булсын өчен, пиратлар турында, аларның ныгытмалардан, замоклардан качулары турында җентекләп сөйли. Ә шул сүз хәзер, «подкоп»ка кадәр күпертелгән. Һәм И. Салахов «качарга җыенган» төркемне табып бирергә тиеш була.

Уйлап карасаң, бу хәлләр үзләре әкият. Тоткыннарның аз гына бәхетенә — әкият тыңлап юануларына да шул чор, система вәкилләре тыныч кына карый алмаганнар. Шул әкият сөйләүдән бер сәяси эш, «дело» оештырып чыгарганнар. Хәер, аларның бит максатлары шул — шуның өчен эшләгәннәр, акча алганнар. Никадәр күбрәк «җинаять» ачылса, шуның кадәр дәрәҗә үсә, план арттырып үтәлә. Димәк, сизгер дәүләт вәкиле «халык дошманын» тиз танып алган, вакытында чарасын да күргән.

«Линкольн приискасында» дип аталган бүлектә, күңелгә кереп калырдай тагын бер вакыйга бар. Тоткыннар ярдәме белән Алексей Николаевич лагерьда кардан хайваннар аллеясе ясый. Зур түземлелек, тырышлык нәтиҗәсендә зонада, 1940 нчы елның 31 декабренә төньяк хайваннарының сыннары пәйда була. Бу сыннар тоткыннарның инде сүнеп барган тормышларын җанландырып җибәрә. Алар, «салкын, әмма күңелгә бик җылы сыннарга» карап соклана, ирektәге тормышның матур мизгелләрен исләренә төшереп юана, хыяллана торган булып китәләр.

«Бу аллея лагеребызны җылытып, яктыртып җибәрде.

...Мин үзем ешрак болан алдына килеп туктыйм. Аның белән сөйләшәм, иң яшерен, изге серләремне бүлешәм. Уйга, хыялга батам... Менә шушы боланга атланып ирекка, туган җирләргә очсаң иде... Оч, алып оч мине, толпарым, туган якларга!» Әмма тоткыннарның бу бәхете дә озакка бармый. Магаданнан килгән «өлкән бер түрә» аллеяны юкка чыгарырга әмер бирә.

«— Җитәр — калтыранган тавышны калын бас таш булып басты. — Монда нәрсә, тоткыннар лагереме, әллә ял йортымы?!... Лагерь кешеләр өчен, хайваннар өчен түгел»... Күзләремне йомдым.

Шарт-шорт, шарт-шорт. Әйтерсең лә башыма сугалар, иеләп-иеләп китәм».

Шушы өзектә генә никадәр вәхшилек!

Әсәрдә күрсәтелгән аянычлы тагын бер хәл:

Камераларда, суларга һава житмәгәнлектән, тоткыннар тарафыннан пыялалары ватылган рәшәткәле тәрәзәләр... Ә тәрәзә артыннан, ерактан, Лебедев-Кумачның «Нинди иркен минем туган илем» җыры яңгырый:

> Я другой такой страны не знаю,
> Где так вольно дышит человек...

Тормыш һәм аны ялтыравыклы бизәкләргә төреп алган ялган тышча... Сүзләрдә — бар да яхшы. «Совет иле — бәхет иле». Анда бар эштә дә гаделлек хөкем сөрә. Хәтта девизлар да: «Һәркемнән — сәләтенчә, һәркемгә — хезмәтенчә», «кем эшләми — шул ашамый».

Ә чынбарлык... ул — караңгы төрмәләр, көнне-төнгә ялгап эшләсәләр дә ярымач, иркенләп һава суларга да тилмергән, зур эшләр башкарырдай, гаепсез тоткыннар: галимнәр, язучылар, дәүләт эшлеклеләре.

Шулар өстенә, кеше шәхесен кимсетү, көн саен кыйнау, мыскыллау — болар шул чор совет лагере, төрмәләре өчен гадәти күренеш.

Шушындый җәһәннәмнән ничек исән чыга алган соң язучы?

— Исән калуым — күктән төшкән бәхет түгел, — диде И. Салахов әңгәмә вакытында. Кеше киртәләрне җимереп үз максатына, теләгенә омтылырга тиеш. Кара көч авыр хәлдә калдыра икән, үзең юл эзлә. Авыр тормышка бирешергә ярамый. Миннән үрнәк алыгыз. 1937—1956 нчы еллардагы газаплар: нахак сүз, төрмә, лагерь, әти-әни белән тора алмау — нинди генә очракта да мин кеше булып кала алдым, бирешмәдем. Җинел генә бер нәрсә дә бирелми. Тар сукмактан — өскә күтәрелергә кирәк. Әмма максатың изге булсын! Үзең өчен генә түгел әлбәттә, кешеләр өчен! Кешенең үзендә тагын өмет булырга тиеш. Өмет булмаса,

шәхес үз-үзен югалта, хәлсезләнә, бәлагә очрый. Мин өметемне югалтмадым. Аннан соң, эшләргә тырыштым, бригадир идем. Эшләсәң ачтан үлмисең. Бик күпләр эштән баш тартты. Бу — акылсызлык. Шуның өчен мине өмет һәм хезмәт саклап калды дип уйлыйм... Ә күпләр өметсезлеккә бирелде, берeште — ялгыштылар.

Мисал өчен безгә көн саен 400 грамм ипи бирәләр иде. Кемнәрдер шушы ипине нечкә телемнәргә бүлеп, тозга алмаштыра, калган ипиенә тоз сибеп ашый. Аннан соң су эчәсең дә, ашыйсы килү басыла. Әмма бу вакытлы гына, эшнең азагы аянычлы — ул авыруга һәм үлемгә китерә. Кайберәүләр икмәкне тәмәкегә алмаштыра. Ә мин барына канәгать идем. Булганын ашадым, күпкә өмет итмәдем.

«Иптәш Сталин күрсәтмәләре» — диләр. Ай-һай, иптәш Сталин бер гаепсез кешеләрне газапларга кушар микән? Булмас! Монда ниндидер өер үзләренең явыз ниятләренә юл салмакчы буладыр».

«Бәлкем иптәш Сталин Яңа ел котлавында «Безнең илдә нахакка төрмәдә утыручылар булырга тиеш түгел! Тикшерегез — дияр».

«Иптәш Сталин бу башбаштаклыкка юл куймас, тикшерер».

Гөнаһсыз төрмәләргә ябылган кешеләр шулай уйлый. Кемнәр соң алар? Әдипләр, галим, укытучы, өлкә, шәһәр партия оешмалары житәкчеләре, карт большевиклар... «Халык дошманнары», «Каян килеп?» Үзләре дә белми, сорау җавапсыз.

Әсәрдә Сталин үзе күренми. Ә тоткыннар аның исемен әнә шулай зур өмет белән телгә алалар. Бу чорның каршылыгы, хатасы да шунда: «Сталин безне бу хәлдә калдырмас, ярдәм итәр». Әмма ярдәм күренми...

Ә «Колыма хикәяләре»н язган И. Салаховның үзенең Сталинга мөнәсәбәте нинди соң?

— Бу сорауга төгәл генә җавап биреп булмый. Әлбәттә, Сталинда минминлек һәм властьны үзенә генә алырга теләү көчле иде. Ул беркемнән, хәтта киләчәк буыннан да курыкмады.

Тагын Ибраһим ага болай дип өсти:

— Татар халкында бик матур мәкаль бар бит: «Яхшылык эшлә дә суга ташла, халык белмәсә, балык белер», — дигән. Нинди генә очракта да кешегә ярдәм итәргә кирәк, яхшылык җирдә калмый ул. Мисалга мин үзем ун ел буена блатнойлар арасында яшәдем. Авыр сүз әйтүче, сугучы булмады. Хәтта мин сүгенергә дә өйрәнмәдем. Кеше үзе нинди, язмышы да шундый буладыр, күрәсең.

— Ибраһим ага! Сез бүгенге көнегездән ризамы? Үзегезне борчыган берәр мәсьәләгә тукталсагыз иде.

— Мин тормыштан риза, гомумән, зарланырга яратмыйм. Ашарга-эчәргә бар, аллага шөкер, «тегендә» бит әле ач та яшәдек. Мине иң рәнҗеткән нәрсә — ул татар халкының сибелгән, таралган, имгәтелгән булуы. Мин Күкчәтау татарлары турында яза башладым, тарихта, мөгаен, ул кирәкле сүз булып калыр. Чөнки тарихны, булганны, дөреслекне бары тик без үзебез генә кире кайтара алабыз. Татарстан китап нәшриятына мин «Канәфер гөле чәчәк атканда» исемле китабымны да тапшырган идем. Ул Себер татарлары турында. Уңлап шәхескә караган истәлек бар анда. Ул революционерларны онытырга ярамый. Алар бит изге юлдан барырга тырышканнар.

Шулай итеп, И. Салахов үзенең әсәрләрендә дистә еллар буена үзе күргәннәрне, кичергәннәрне сурәтләп бирә. Әсәрләренең төп идеясе — репрессияләнгән «халык дошманнары»ның фаҗигасен күрсәтү. Шулардан чыгып Сталинга, чор тудырган тоталитар системага нәфрәт уяту.

Мәкаләне И. Салаховның үз сүзләре белән тәмамлыйсым килә. «Минем «Колыма хикәяләре» романы төрек, инглиз телләрендә дә басылып чыкса әйбәт булыр иде. Чөнки китапта бит минем язмышым гына түгел. Анда тарихта, әдәбиятыбызда эз калдырган зыялыларның язмышы да. Татар нигә ауды, егылды, рәнҗетелде — менә шулар турында әсәр. Аны безнең яшьләр белергә тиеш. Гомумән, әлеге язмаларымны мин, киләчәк буыннар без кичергәннәрдән сабак алсыннар өчен язам», — ди ул.

**Ләйлә ӘХМӘДИЕВА,**
**педагогия университеты укытучысы.**

# Якты һәм җылы бөркелә...

МӘҖИТ РАФИКОВНЫҢ ТУУЫНА 70 ЕЛ

Бу әдипнең исемен әйтү белән минем күз алдына якты, кояшлы җәй көннәре — Аккош күлендәге иҗат йортында аның белән бергә, янәшә яшәлгән бик тә матур көннәр килеп баса... Һәм ул шәхес үзе дә хәтердә әнә шундый кояшлы җәйге көн кебек булып сакланып калган.

Әйе, Мәҗит ага Рафиков — чын-чыннан зыялы зат, югары тәрбияле һәм бик тә укымышлы шәхес иде. Аның белән икәү генә калганда ул сине үзенә дә сиздермичә генә тормыштагы, табигатьтәге, әдәбияттагы гүзәллекнең иң нечкә хасиятләре хакында гаҗәеп мәгънәле әңгәмәләргә алып кереп китә. Андый чакларда синең әңгәмәдәшең булган бу кешенең дөньяны һәм матурлыкны шундый да нечкә тою, шундый да тирәннән аңлау талантына сокланасың. Аның белән бергә үзең дә матурлыкның яңа үрләренә күңелеңнән генә өр-яңа сукмаклар саласың...

Менә ул татарның иң затлы шагыйрьләре язган әсәрләрне сөйли. Алардагы эстетик байлыкка, фикри тирәнлеккә ушы китеп, дөньясын онытып тора... Менә ул урысчага күчеп, Иван Бунин шигырьләрен яттан укый. Афанасий Фет әсәрләреннән күпләп-күпләп өзекләр китерә... Шулай ук чит илләр әдәбиятын да бик яхшы белә иде мәрхүм Мәҗит ага.

Аның үз әсәрләре дә дөнья әдәбиятының бөек әсәрләренә хас булган әнә шул кыйммәтле сыйфатларга ия иделәр. Аларда да кеше җанының, кеше рухының югары яшәеше гаҗәеп табигый булып һәм тәэсирле чагылды. Мәҗит Рафиковның күләм ягыннан әллә ни зур булмаган әсәрләре кеше күңеленең кадерле һәм изге мизгелләре хакында укучы белән ихлас әңгәмә алып баралар.

Мәҗит Рафиковның 1966 елда «Илһам авазы» дигән хикәяләр җыентыгы, 1973 елда «Төлке улы Хәйләпүш» дигән шигырь китабы, 1975 елда «Су башы» исемле повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы дөнья күрде.

Бу әдип бердәй осталык белән урыс телендә дә иҗат итте. Аның урысча басылган «Родник Хабира-Соловья» (1972), «Ишкильды» (1975) һәм «Школа на взгорке» (1981) китаплары бар.

Әдипнең «Шарлама», «Синә ничә яшь?» һ. б. әсәрләре чит илләрдә дә басылып чыкты, «Безнең авыл мәктәбе» повесте исә 1977 елда «Волга» журналында дөнья күреп, иң яхшы әсәрләргә бирелә торган бүләккә лаек булды.

Ул бик тә шигъри җанлы әдип иде. Проза әсәрләре язып бетереп «хәл җыйган» арада үзе дә байтак кына һәм әйбәт шигырьләр язды. Алар 1985 елда «Гүзәл мизгелләр» дигән исем белән Татарстан китап нәшриятында басылып та чыктылар, матбугатта яхшы бәя алдылар.

Сүзгә гаять сизгерлеге Мәҗит Рафиковның тәрҗемә эшчәнлегендә дә күренде. Аның тәрҗемәсендә Г. Тукайның прозасы, Ш. Камал, Н. Дәүли, М. Әмир, М. Гази, Г. Әпсәләмов, Ә. Еники, Р. Төхфәтуллин, Х. Сарьян һ. б. татар язучыларының күп кенә хикәяләре урысча дөнья күрде. Гомеренең соңгы елларында ул бик тә бирелеп һәм ихлас күңелдән мавыгып Тукайның чәчмә әсәрләрен урыс теленә тәрҗемә итте. Ул бөек шагыйребез язган һәр сүзнең тулы мәгънәсе, бөтен тирәнлеге, саллылыгы урыс укучысына һәм бу тел аша дөнья халкына аңлашылсын дип тырышты. Бу эшкә үзенең поэтик һәм фәлсәфи көчен салды, кызганмады. Мәҗит Рафиковның вафатыннан соң дөнья күргән китап, минемчә, көчнең юкка сарыф ителмәгәнлеген раслый.

Әйе, Мәҗит Рафиков дөньяны, тормышны киң колачлап һәм киң күңел белән яшәүче әдип иде. Әнә шуңа күрә аның әсәрләрендә безгә Олы Хакыйкать юлдаш булып бара, Бөек Матурлык күңелләрне җылытып тора. Аның иҗаты турында язган тәнкыйтьчеләр дә бер дә юкка гына менә мондый сүзләр кулланмаганнардыр: «Фәлсәфи калыптагы әдип» (И. Ахунҗанов), «Матурлык эзләүче» (Ф. Миңнуллин) һ. б.

Мәжит Рафиков — Бөек Ватан сугышында катнашкан һәм авыр яраланган кеше иде. Әнә шул яра соңгы елларда бигрәк тә үзен сиздерде, аның хәрәкәтләнүенә нык комачаулады.

Әдип Сталин системасының җәзаларын бик иртә татый — аны студент чагында ук кулга алалар һәм Себергә сөргенгә сөрәләр. М. Рафиков 1950—55 елларда Иркутск өлкәсендә, Тайшет-Братск тимер юлы төзелешендә эшли.

Совет концлагерьларын кичергән кеше булса да, аннан үзенең кешелеклелеген, нечкә күңеллелеген җуймый кайткан, саф йөрәкле зат иде ул. Матурлык һәм гаделлек ахырга кадәр аның төп таянычы булды.

...Җәйнең ямьле, матур, кояшлы көннәре «Аккош күле»ндә хәзер дә була... Һәм гаять моңсулатып, җаннарны серле билгесезлеккә төреп, андый ямьле көннәрнең эңгере дә килеп җитә... Әнә шундый кичләрдә, Мәжит ага белән икәү яшәгән өйнең кояш баешына караган верандасына чыгып утырам да — дөньяның, дөньялыкның, тормышның Олы Хакыйкатен, Олы Матурлыгын тоеп һәм күреп яшәгән, әнә шуларга йөз тотып яшәгән олы җаннарны чын-чыннан сагына башлыйм... Һәм кичке эңгердә утырып үз эчемнән, үз күңелемнән генә алар белән башланган әңгәмәләрне дәвам итәм...

**Мансур ВӘЛИ.**

## Әбрар Сәгыйдинең тууына 100 ел

Шагыйрь Әбрар Сәгыйди (Әбрар Закир улы Сәгыйтев) — егерменче еллар татар шигыре мәйданында шактый ук танылган, билгеле исем. Әүвәл ул 1914 елда «Кояш» газетасында күренә, аннары шактый шигырьләре һәм поэмалары («Кыр әбие», «Абыем хатлары») «Шура», «Сөембикә», «Ак юл» журналларында басылып чыга, «Йолдыз» һәм «Тормыш» (Уфа) газеталарында дөнья күрә.

1895 елның 14 апрелендә хәзерге Апас районы Кече Кошман авылында туган Әбрар Сәгыйдинең тормыш һәм иҗат юлы замандашлары — шул чор шагыйрьләре Ш. Бабич, З. Ярмәки, Гыйффәт туташ һ. б. юлыннан аерылгысыз. Шул ук — гасыр башы татар авылы, аннан Казанда «Мәрҗания» мәдрәсәсе, учительская семинариядә белем алу, милләт турында янып сыкрану, өметләр. Ә Октябрь фетнәсеннән соң инде — журналистика хезмәте, редакцияләрдә («Эшче» һәм «Татарстан хәбәрләре» газеталарында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире) эшләү, публицист һәм шагыйрь буларак танылу. Әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә көчен сыный шагыйрь: Уолт Уитмен, Р. Тагор, Д. Бедный шигырьләрен татарчалаштырып бастыра. Егерменче елларда ул сәхнә әсәрләре дә яза. («Сахра кызы», «Ишан улы», «Кызыл Тау», һ. б.) «Сахра кызы» драмасы Татар дәүләт академия театрында уйналып (1928), аннары Мәскәү үзәк эшче театрында да куела.

1925—1927 елларда Ә. Сәгыйди Зөя кантоны Башкарма комитетында консультант-тәрҗемәче булып эшли, аннары татар телен гамәлгә кую буенча инспектор вазифасын башкара; ә 1927 елдан инде мәгариф системасына күчә: Норлат район бүлегендә инспектор була, Зөя, Ослан, Кошман, Карауҗа һәм Кайбыч мәктәпләрендә укыта. Ул, каты авырудан соң 1939 елның 1 апрелендә туган авылы Кече Кошманда вафат була.

Басылып чыккан «Ирек азаны», «Сугыштан абыем хатлары» (1917), «Яшьләр иле» (1921) кебек шигырь һәм балалар өчен «Умарта бакчасы», «Эш курае» (1930) исемле китаплары бар.

# ИНКЫЙРАЗ КӨЗГЕСЕ

Юаныч

Соңгы дәвердә республикабызда татар тормышы милли яктан шактый жанланып китте. Радио-телевидениебездә татарча тапшырулар бирәр сәгать чамасы артты. Яңа театрларыбыз барлыкка килде. Мәгариф челтәрендә туган телдә укыту киңәя башлады. Җәмәгать транспортында, урамнарда татарча сөйләшүләр ешрак ишетелә. Туган телебез хәтта, Африканың Ботсвана, Бурунди мәмләкәтләре парламентлары шикелле, татар телен дистә еллар буе бар дип тә белмәгән жиргә — республикабыз Югары Советына да үтеп керде — берничә депутатыбыз ана телендә чыгыш ясарга гайрәтләнде.

Милли җәмгыятьләр, хәтта Милли бәйсезлек фиркасе дә барлыкка килде. Ахырда Татарстанның дәүләт бәйсезлеге игълан ителде, аның Төп законы, дәүләти билгеләре кабул кылынды, татар теле хокукый яктан дәүләт теле дәрәҗәсендә танылды. Күңелебезне күтәргән казанышларны әле тагын да санарга мөмкин. Шуларның янә бер сөенечлесе — милли матбугатыбыз сафы икеләтә-өчләтә арту иде.

Милли хөррият ачылуга бик озак, бик газаплы чорларны кичеп килгәнлектән, бу казанышларның кадере, әлбәттә, югары. Ниһаять, үткәнебезгә борылып карарга, рухи тамырларыбызны барларга, җаныбызга яңа сулыш өрергә форсат таптык. Утыз көн уразадан соң көндез су эчү дә бәйрәм саналган шикелле, без бүген фәлән район үзәгендәге балалар бакчасында бер татар төркеме оештырылуга да, фәлән авылда нәни генә мәчет корылып, анда биш-алты карт-корының намазга йөри башлавына да бинһая сөенәбез: иншалла, әнә шулай динебез әүвәлге хәленә кайтыр, иншалла, әнә шулай туган телебез тернәкләнер, янәсе! Өметләребез шулкадәр зур ки, без хәзер инде күп нәрсәгә алсу күзлек аша гына карарга күнегеп барабыз, милли хәятебездәге кайбер тискәре күренешләрне, нигезебезне какшата торган дәһшәтле аскы агымнарны абайлап йөрәкне бозмас өчен, күңел юаткыч уңай нәрсәләр хакында гына сөйләшергә тырышабыз. Гәзит-журналларыбызның тиражы кимиме? Басмаларыбызның саны арту аркасында ул! Яшьләребез һаман туган телендә укымыймы?

Республикабызда атна саен ике-өч мәчет ачыла, алар каршында гарәп хәрефен, төрек телен өйрәтү курслары оештырыла, тиздән шуларның уңай тәэсире татар телен үзләштерүгә дә җәелми калмас... Милләтебез мәнфәгатен кайгыртучы берничә галимебез, сәясәтчебез даими чаң кагып тора, алар хәтта митинглар җыеп та шушы хакта сөйли. Социализмда булган хәлмени бу? Юк! Димәк, эш бара...

Менә шулай юанабыз, тынычланабыз, хәтта татарлыгыбыз ныгый барган сыман да тоела. Ни әйтсәң дә, замана болганган чакта шактый нәрсәгә ирешелде ләбаса. Илдә икътисадый күчеш чоры, Рәсәй матди байлык җитештерүдә түбән тәгәри, кайбер төбәкләрдә, гомумән, мәхшәр — фәләненче Ватан сугышы бара. Ә бездә — тыныч, шәһәрләрдәге шифаханә, кибет, даруханәләрдә татарча эндәшкән өчен сүкмиләр, сукраналар гына. Урыс мәктәпләрендә татар теле укытучылары хәзер балаларны дәресләренә ялынып җыеп йөрми — алар хәзер йә класс белән кереп утыра, йә класс белән өйләренә кайтып китә! Анда укучы татар балалары үзара татарча аралашмый икән, бу аларның менталитетлары, ягъни гадәт-күнекмәләре үзгәрүдән. Ул менталитетны үзгәртү өчен үзенә күрә бер революция ясарга кирәк. Халык исә революцияләрдән гарык, бик ашыкмыйк, җәмәгать, килер бер көн...

## Матбугат — барометр

Китаплар чыгару кими, вакытлы матбугатның тиражы азая. Моның табигый сәбәпләре күбебезгә мәгълүм: икътисадны үзгәртеп кору, бер системадан икенчегә күчү ансат кына бара алмый. Җитештерү кими, тормыш дәрәҗәсе түбәнәя, халыкның зур өлеше җан саклау кайгысына баткан. Шунлыктан, элекке СССР халыкларының һәммәсе китап, вакытлы матбугат алуны күпкә киметте. Әгәр Татарстанда 1990 елда 40699 данә таралган «Казан утлары» журналы быел 6978 гә генә калган икән, «табигый» дип тынычланырга да мөмкин. Татар телендә яңа калын әдәби журналларыбыз да чыга башлавын искә алсак, бигрәк тә!

Әмма мәсьәләнең төбенә төшә башлагач, тынычлану дигән нәрсә үзеннән-үзе юкка чыга. Чөнки яңа калын әдәби журналларыбыз «Аргамак», «Идел», «Мирас» быел республикабызда гыйнвар аенда тулаем 9032 (2149 + 3859 + 3024) данә алдырыла. Аларны «Казан утлары» тиражына кушсак, 16010 саны пәйда була. Әмма шушы сан да 1990 елгы «Казан утлары»н тарату күрсәткеченнән 2,5 мәртәбә кимрәк икән.

«Казан утлары» Татарстанда иң күп таралган чагында (1990) мең татарга 23,1 данә туры килде. Бу санны укымышлырак халыкның, әйтик, эстоннарның шундыйрак журналы («Лооминг») күрсәткече белән чагыштырсак, аларда мең кешедән 33 әү язылган. Бу дәвердә эстоннар — 24, татарлар 7 журнал бастыра иде. Быел «Казан утлары» Татарстанда мең татарга 3,9 данә туры килә, димәк, аны һәр 67 татар гаиләсенең берсе генә алдыра. Калган 66 гаилә туган әдәбиятының төп көзгесе белән кызыксынмый икән. Биш ел дәвамында бу журналны алдыру Татарстанда 5,8 мәртәбә кимүен ачыклагач, күңеленә шом оялавы, мангаена яңа җыерчыклар кунуы бер дә гаҗәп булмас.

«Казан утлары» таралышы туган әдәбиятыбызга мәхәббәтнең ни дәрәҗәдә икәнлеген аныклаганлыктан, кайбер районнарда мең татарга язылу буенча ничә журнал туры килүен дә күрсәтик: Кама Тамагында — 12,7; Яңа Чишмәдә — 10,2; Апаста — 8,7; Балтачта — 7,6; Мөслимдә — 7,2; Сабада — 7,1; Актанышта — 6,9; Болгарда — 6,8; Әлкидә — 6,2; Ютазыда — 6,1; Сарманда — 6,0; Теләче белән Әгерҗедә — 5,9 ар; Кукмара, Мамадыш, Чирмешәндә — 5,7 шәр; Минзәләдә — 5,6; Азнакайда — 5,3; Аксубай, Балык Бистәсе, Октябрьда — 5,2 шәр; Арчада — 5,1.

Төп әдәби журналыбызны иң аз укучылар — казанлылар, монда ул мең татарга язылу буенча 1,1 туры килә. Аннары — Яр Чаллы (1,2), Менделеев (1,3), Түбән Кама (1,5), Зеленодол (1,9), Алабуга (2,2), Бөгелмә (2,4) «мактана» ала. Шәһәрләрдә милли әдәби журналга игътибарның бик нык кимүе андагы халыкның матди фәкыйрьләнүе турында гына түгел, ә бәлки аларда татарның милләт буларак йотыла баруы хакында сөйли. Әгәр мәсьәлә тормыш дәрәҗәсенә генә кайтып калса, «Казан утлары»на язылу күрсәткече буенча исәпләсәк, Кама Тамагы районы халкының Казанныкыннан уртача 11,5 тапкыр баерак яшәвен белер идек.

Шулай итеп без, милли үсешебезгә сөенеп, шатлыктан исереп йөргәндә, астыртын агымнар нигезебезне тәмам ишеп, юкка чыгарып ята икән ләбаса. Барометр һава торышын бик төгәл күрсәткән сыман, милли матбугат таралышы да милләтнең хәл-әхвәлен шактый дөрес һәм тулы чагылдыра, аңа игътибар бирмәү һәм аннан дөрес нәтиҗәләр ясамау үтә үкенечле акылсызлык булыр иде.

## Читтәге афәт

Һәр дүрт татарның өчесе Татарстаннан тышта яшәвен беләбез. Мондый шартта милли матбугатыбыз таралышын республикабыз эчендә генә ачыклау чамадан тыш чикләнгәнлек булыр иде.

Без болай да читтә яшәүче милләттәшләребез хәлен начар күзаллыйбыз. Билгеле, Татарстан үзеннән тыштагы татар дөньясыннан аерылып яшәгән заман артта калды. Радио-телевидениебезгә, матбугатыбызга хәзер ерак-ераклардан да шактый хәбәр килә, алар тыңлаучыларыбызга, тамашачыларыбызга һәм

укучыларыбызга да җиткерелә. Ләкин бу хәбәрләр, нигездә, «фәлән шәһәрдә мондый кичә уздырылды», «фәлән авылда шундый мәчет корылды», кеякты буяуларга манылып таратыла, сирәгрәк очракта гына андагы мәдәният-мәгариф учакларында милли белгечләр, дәреслекләр һәм тулаем татар китабы житешмәве телгә алына. Бөтен татар милләте ихтыяжларын кайгыртырга теләгән Милли Мәҗлес эшчәнлеге дә хәзер сүлпәнәйде — ул хәтта милләтебезнең бүгенге торышын, минемчә, төгәл анализлап сурәтли дә алмады. Сәяси үсешнең мәгълүм бер баскычында Милли Мәҗлеснең үзенә нинди дәрәҗәдә көндәш булу ихтималыннан хәвефләнгән республикабыз җитәкчелеге, бердән, үз йогынтысын киңәйтүне, икенчедән, милли хәрәкәтне үзе тарафыннан идарә ителә торган кысага кертүне күздә тотып, Бөтендөнья татар конгрессын җыйды һәм тантаналы-купшы утырышларда аның Башкарма Комитетын да сайлады. Төп максаты Милли Мәҗлесне зәгыйфьләндерү, аны сәяси мәйданнан кысрыклап чыгару гына булганлыктан, шул максатына ирешкәч, безнең тәҗрибәле партократлар Башкарма Комитеты тынычланды һәм... үзенең гадәти эшенә — Татарстан җирлегендәге идарә мәшәкатьләренә кереп чумды.

Ә Татарстаннан тыштагы милләттәшләребез бүген нинди хәлдә — бу аларны артык борчымый. Чөнки мона «рәсми вәкаләтләре юк», күпмилләтле Татарстан халкын гына кайгыртырга хакы булган, милли хисләр куерган шартта гына бераз «милләтпәрвәр» ролен уйнап, үзенә өстәмә очколар җыеп калуны кайгырткан бәндәгә әллә кайдагы татарлар нәрсәгә ул? Алла сакласын!

Менә шушындый хәлдә Татарстаннан тышта милли матбугат таралышын өйрәнү шактый нәрсәне ачыкларга мөмкинлек бирә. Әйтик, туган әдәбиятыбыз белән кызыксыну кайда ниндирәк күләмдә? Туган телнең сакланышы ни дәрәҗәдә? Милли мәгариф челтәре кайларда сакланган, кайсы елларда юкка чыккан? Милли аң сүнүен төбәкләп бизмәнләү мөмкинме? Милләтне терелтү һәм саклау эшен кайда, нәрсәдән башларга мөмкин?..

Элекке СССР күләмендә карасак, «Казан утлары» журналы мең татарга 1976 елда — 15,0 данә; 1986 да — 9,5; 1990 да — 12,5 һәм быел — 1,7 данә тарала. Быел, 1986 ел белән чагыштырганда, «Казан утлары»н алдыручылар исәбеннән утызлап өлкә-республика бөтенләй төшеп калды, шул өлкә-республикаларда яшәүче милләттәшләребезнең рәсми саны бер миллионга якын, югыйсә! Быел Кыргызстандагы 72 мең татар — 3 данә (1976 да — 767), Украинадагы 91 мең милләттәшебез — шулай ук 3 (1976 да — 419), Казагыстандагы 328 мең татар 24 данә (1976 да — 4274) журналыбызны алдыра. Мең татарга исәпләгәндә, Пенза, Өркет, Әстерхан, Сарытау өлкәләренә 0,3 әр, Чиләбе, Кемерово, Мәскәү, Красноярск өлкәләренә һәм Якутстанга 0,4 әр журнал туры килә. Бу күрсәткеч Свердловск өлкәсендә — 0,5, Удмуртстан, Коми республикаларында һәм Омск өлкәсендә — 0,6 шар, Курган өлкәсендә — 0,7, Төмән өлкәсендә — 0,9, Ульяновск, Киров өлкәләрендә — берәр данә. Бу саннарны 1976 елгы күрсәткечләр белән чагыштырып карау гына да җанны өшетерлек — кимү нәкъ ун мәртәбә дип әйтерлек. Билгеле, бу кимүдә халыкның ярлылануы, почта-экспедиция хезмәтенең журналыбызны мөштәриләргә илтеп тапшыруда җинаятьчел дәрәҗәдә өзеклек китереп чыгаруы да зур роль уйнады. Мисалга, Мәскәү өлкәсендәге әбүнәчеләребез (мөштәриләребез), милли хисләре тернәкләнеп, «Казан утлары»н 1976 елда — 372, 1986 да — 409, 1990 елда 805 данә алдырырга керешкән иде. Шуннан соң аңлашылмый торган могҗизаи бәлаләр җәелде: әле аңа бүтән яздырмаска тырыштылар, әле өстәмә бәяләр куштылар, әле язылучыларга аның 12 санынннан яртысын яки бөтенесен китереп бирмәүне гадәткә керттеләр. Нәтиҗәдә, «Казан утлары»на быел Мәскәү өлкәсендә нибары 74 кеше генә язылды.

1976 ел белән чагыштырганда, быел «Казан утлары» Чиләбе өлкәсендә — 18 тапкыр, Удмуртстанда — 23, Свердловск өлкәсендә — 25, Кемерово өлкәсендә — 30, Коми республикасында 34 тапкыр кимрәк тарала. Икеләнмичә расларга мөмкин, бу — зур шәһәрләрдә яшәүче милләттәшләребезнең кызу тизлектә йотылуы, татар мәктәпләрен тәмамлаган буынның картаюы һәм юкка чыга баруына бәйләнгән. Ә менә авылда яшәүче милләттәшләребез күп өлкәләрдә, бигрәк тә мәктәпләрендә татар теле-әдәбияты дәресе сакланган якларда бу азаю бермә-бер кимрәк. Әйтик, Түбән Новгород өлкәсендә — 4 мәртәбә, Самара ягында — 5, Ульяновск өлкәсендә — 7, Пенза, Сарытау, Киров, Оренбург өлкәләрендә һәм Чувашстанда — 8 мәртәбә кимрәк. Башлыча шәһәр татарлары күбрәк өлкәләрдән Омск, Курган, Пермь, Красноярск якларында кимү дәрәҗәсе — 10-14 мәртәбә арасында.

Дистә еллар бу «халыклар дуслыгы, милли культуралар чәчәк аткан» өлкә-республикалардагы татарның язмышы менә шундый мөшкел хәлдә хәзер: бүген туган телендә уку мөмкинлеге томалана барса, иртәгә аны милли сыйфатларын һәм милли анын тәмам югалтып бетерү кәсафәте көтеп тора. Бу хакыйкатьне татарның бүтән басмалары таралышы да раслый. Әгәр ул мәгълүматларны «Казан утлары» — 104 мең, «Азат хатын» — 430 мең таралган дәвер күрсәткечләре белән чагыштырсак, хәлнең аянычлыгы бигрәк тә шик уятмас.

Туган телебездә чыгарыла торган алты журналның — «Казан утлары», «Сөембикә» («Азат хатын»), «Чаян», «Ялкын», «Татарстан» («Татарстан коммунисты»), «Мәгариф» («Совет мәктәбе»)нең тулаем тиражы (меңнәрдә) үсешенә игътибар итик: 1976 елда — 644, 1986 да — 634, 1991 дә — 383, 1994 тә — 163, 1995 тә — 87 мең.

Соңгы вакытта дөнья күрә башлаган 6 яңа журналның — «Аргамак», «Идел», «Казан», «Мирас», «Сабыйга», «Салават күпере»нең тулаем тиражы былтыр 52 мең булса, быел 31 мең тәшкил итте. Хәтта шушы 12 журналның тиражын бергә кушсак та, ул 1994 елда 215 мең тәшкил итсә, быел 118 меңнән артмады. Тагын шунысы да аяныч: әле кайчан гына «Казан утлары», «Сөембикә»нең һәр өчтән ике данәсе Татарстаннан читтә таралса, хәзер бу өлеш өч мәртәбә чамасы кимеде. Яңа басмаларыбыз исә, гомумән, ерактагы милләттәшләребезгә таныш түгел диярлек.

Менә шушы хәлләр ачыклангач, безгә инде милли хәрәкәткә тартылган санаулы гына өлкән яшьтәге затларыбызга ышанып, Татарстан хәбәрләндерү чаралары тараткан иплe, әмма хакыйкатьне тиешенчә ачудан ерак торган мәгълүматларга алданып, пошынмыйча гына яшәү ярамыйдыр, җәмәгать.

Мәгълүматыбыз тулырак булсын өчен, 1976 ел белән чагыштырганда, быел кайсы басманың тиражы ничә мәртәбә кимүен дә карап үтик: «Ялкын» — 7, «Казан утлары» — 8, «Сөембикә» — 10, «Татарстан» — 17, «Чаян» — 18 мәртәбә кимрәк тарала хәзер. Бары «Мәгариф» журналы гына яңадан күтәрелә башлады — аның тиражы хәзер 1976 ел күрсәткеченә якынлашты.

Соңгы дәвердә туган телебездә чыгарыла торган республика гәзитләребез саны артуы мәгълүм. Ә менә аларның таралышы ничегрәк соң? «Ватаным Татарстан», «Мәгърифәт», «Сабантуй», «Татар иле», «Татарстан хәбәрләре», «Татарстан яшьләре», «Шәһри Казан», «Юлдаш»ның тулаем тиражы былтыр 438 мең булса, быел бу күрсәткеч 357 меңгә төште. Алар арасында бердәнбер хосусый гәзит булган «Юлдаш» кына тиражын 15 меңгә арттыра алды.

Татарстаннан тыштa милли матбугатыбыз сафы үсү соңгы елларның аеруча күңелле бер вакыйгасы булды. Алар арасында «Өмет» (Ульяновск), «Бердәмлек» (Самара), «Яңарыш» (Төмән), «Туган як» (Түбән Новгород), «Дуслык» (Киров) гәзитләре даими һәм тәртипле чыгулары, эчтәлекләре яхшыру белән укучыларга танылды инде. «Өмет» (Алмата), «Халык чишмәсе» (Пермь), «Яна вакыт» (Ырынбур), «Яңарыш» (Ижау), «Дуслык» (Чиләбе), «Вакыт» (Уфа), «Җидегән» (Уфа), «Алтын Урда» (Чаллы), «Нур» (Чаллы) һәм бүтән гәзитләр дә дөньяга килде. Уфада исә былтыр «Тулпар» әдәби журналына нигез салынды. Әстерхан, Санкт-Петербург, Мәскәү һәм тагын кайбер шәһәрләрдә милли рухлы татар гәзитләре урыс телендә басылгалап тора. Аларның барлыкка килүе, кайбер өлкә-республикаларда туган телебездә радио-телевидение тапшырулары башлану да халкыбызның яшәргә омтылышын гәүдәләндерә. Ләкин күренеп тора: татарны татар итеп саклау һәм үстерү өчен болар гына җитми! Милләтебезнең йотылуына Татарстанда беркадәр киртәләр куелды — урыслашу күләме һәм тизлеге азайды, әмма тулысынча туктатылмады. Республикабыздан тыштa исә бу эш бик зәгыйфь алып барыла әле — моны югарыда китерелгән мәгълүматлар да ап-ачык раслый шикелле.

## Матбугат — җан азыгы

Уку дөньяга карашны киңәйтә, чынбарлыкны танып-белүне тирәнәйтә, фикер йөртүне җанландыра.

Китап чыгару бермә-бер кимегән дәвердә без вакытлы матбугат белән аеруча тыгызрак дуслашырга мәҗбүр. Ул безгә әдәбият-сәнгать җәүһәрләрен дә тәкъдим итә, сәяси, икътисадый белемнәр, агымдагы бүтән мәгълүмат белән дә зиһенебезне баета. Ул безне төрле халыклар, төрле заманнар тәҗрибәсе белән сугарып, алар тормышыннан гыйбрәт биреп, яшәешебезне мәгънәлерәк оештырырга булыша. Вакытлы матбугат заман сулышын үткенрәк

тоярга, замандашларыбыз белән бер сафта атларга ярдәм итә. Шуның өстенә, милли матбугат — тарихи хәтерне уята, гореф-гадәтләрне, туган телне яшәтә торган кодрәтле чара, милли рухны дөрләтеп, меңләгән-миллионлаган җаннарның бер тамырдан килгән уртаклыгын саклый һәм ныгыта торган куәтле көч тә. Аның татар кебек сибелгән-таралган милләтне берләштереп, цементлап тоту үзенчәлеге бигрәк тә әһәмиятле. Шуңа күрә аны кайгырту, аның йогынты даирәсен киңәйтү безнең исебездән бер генә минутка да чыкмаска тиеш.

Бу мәкаләдә матбугатыбызның эчтәлеген баету, телен сафландыру һәм тагын шундый махсус профессиональ мәсьәләләргә, гәрчә алар бик әһәмиятле булса да, тукталып тормыйбыз. Төп игътибарны милли матбугат таралышы ачкан хәвефле нәрсәләргә юнәлтәсе килә.

Халкыбызның күпчелек өлеше хәзер шәһәрләрдә яши. Кызганыч ки, тарихи язмышы аны монда, хәтта Татарстанда да, азчылык хәлендә калдырган. Туган телендәге мәгариф челтәре имгәтелгәч, ул шәһәрләрдә милли мохитебез тулаем югалды. Хәтта мәдәният учакларында милли рух белән сугарылудан мәхрүм ителгәч, шәһәрләргә дулкын-дулкын килеп урнашкан милләттәшләребез урыс теле, гореф-гадәтләре, культурасы тегермәне аша узарга мәҗбүр булганлыктан, безнең милли иммунитетыбыз тәмам изеп-сытып ташланды. Бу хәл Татарстаннан тышта аеруча фаҗигале дәрәҗәгә житкерелде. Йотылу тизлеге көчәя барганда, без хәзер элекке СССРның бөтен тарафларына сибелгән милләттәшләребезне тарихи ватаннарыннан читтә коткарып калуны хыяллана да алмыйбыз. Еракта йотыла барган төркемнәр исә Татарстандагы милләттәшләренә дә һәлакәтле йогынты ясый. Шуңа күрә безнең алда торган иң зарур бурыч — милләттәшләребезне тарихи ватанга туплау һәм шунда милли мәгариф челтәрен аякка бастырып, яшь буынны асыл нигезенә, мохитенә кайтару өчен көрәш җәелдерү. Милләттәшләребезне тарихи ватанында төпләндерү безгә якын киләчәктә Казанда һәм тагын кайбер бүтән шәһәрләрдә күпчелек тәшкил итәргә дә булышырга тиеш. Шуннан башка татар теленең һәм милләтенең тарихта сакланып калуына өметләнү бик читен.

Татарның тарихи ватаны Татарстан белән генә чикләнми. Республикабыз күршесендәге ата-бабаларыбыз җирендә дә милләттәшләребез хәле җиңел түгелләгән беләбез. Анда милли мәгариф, мәдәният челтәрен яңарту Рәсәй белән Татарстан арасында яңа килешүләр төзелгәндә, Рәсәйнең шул максатта бюджет бүлеп бирүе нәтиҗәсендә генә ышанычлы хәл кылына ала. Бу мәсьәләне тиз һәм уңай хәл итү — икенче әһәмиятле бурычыбыз.

Өченче әһәмиятле эшебез — Казанны бөтен татар галәме өчен туган телебездә югары белемле кадрлар әзерли торган үзәккә әйләндерү. Милли рух кайнап торган үзәктә генә татарны упкыннан коткарырлык шәхесләр тәрбияләргә мөмкин. Социаль шартлау хәвефеннән өркеп, бөтен көчен һәм сәләтен республикабызда матди тормыш минимумын кайгыртуга гына биргән һәм башлыча матди житештерү мәсьәләләре белән генә шөгыльләнгән Татарстан җитәкчелегенә эшчәнлек юнәлешенә үзгәрешләр кертү хаҗәт. Тәүлек буе татарча тапшырулар алып бара торган кыска дулкынлы радио, татарча тапшырулары ун сәгатьтән ким булмаган милли телевидение каналын булдыру ни өчен һаман хәл ителми? Матди байлык житештерү күләме буенча Татарстаннан 3—4 мәртәбә калышкан республикалар моңа күптән ирешкән. Татар кешесе, кайда гына яшәмәсен, эфирда үзе теләгән вакытта туган теле, җыры белән азыклана алырга тиеш. Татарстаннан тыштагы милләттәшләребезнең мәдәни автономиясе республикабыз ярдәменнән тыш тормышка ашырыла алмый, ансыз милләтнең йотылып бетүенә генә исәп итәргә мөмкин.

1989 елгы җан исәбе алу буенча элекке СССРда 2036 мең алман (немец) яши иде. Соңгы елларда шуларның 500—600 меңе Алманиягә күчеп китте. Хәзер «Азатлык» радиосы хезмәткәрләре һәм кайбер белгечләр элекке СССР җирләрендә 7 миллион алманның калуы турында сүз алып бара. Чөнки рәсми статистика халыкның милли составын дөрес күрсәтә алмаган, имеш.

Алманнар саны 3—4 мәртәбә киметеп саналган шартта татар исәбе ничек алынган икән? Рәсми статистика 1989 елгы милләттәшләребез санын 6646 мең дип күрсәтте. Бу һәм бүтән еллардагы саннарның өлкәләргә бүленешен анализлаганда, татар исәбенең дөрес алынуына да шөбһә уяна. Фикер йөртергә азык булсын өчен, СССР җан исәбе алу мәгълүматларына таянып, кайбер өлкәләрдәге татар үсешенә күз салыйк:

| Өлкәләр | 1989 | 1979 | 1970 | 1959 | 1970—1989 |
|---|---|---|---|---|---|
| | меннәрдә | үсеш | | | проценты |
| Чиләбе | 225 | 220 | 217 | 190 | 103,7 |
| Мәскәү | 186 | 184 | 158 | 133 | 117,7 |
| Свердловск | 184 | 179 | 176 | 158 | 104,5 |
| Пермь | 150 | 158 | 169 | 166 | 88,8 |
| Пенза | 81 | 78 | 75 | 62 | 108,0 |
| Әстерхан | 72 | 71 | 67 | 57 | 107,5 |
| Кемерово | 63 | 65 | 69 | 67 | 91,3 |
| Т. Новгород | 59 | 69 | 72 | 67 | 81,9 |
| Мордовия | 47 | 46 | 45 | 39 | 104,4 |
| Киров | 46 | 45 | 45 | 41 | 102,2 |
| Өркет | 40 | 41 | 42 | 39 | 95,2 |
| Новосибирск | 29 | 29 | 29 | 25 | 100,0 |
| Волгоград | 26 | 26 | 24 | 18 | 108,3 |
| Курган | 23 | 24 | 24 | 20 | 95,8 |
| Хабаровск | 17 | 17 | 15 | 14 | 113,3 |
| Бөтен татар | 6646 | 6317 | 5931 | 4968 | 112,1 |

Югарыдагы таблицада күренә ки, Пермь, Кемерово, Өркет, Курган өлкәләрендә яшәүче татарларның 29 ел эчендә артмавын миграция (күчеп китү) белән генә аңлатып булмый. Новосибирск, Чиләбе, Свердловск, Әстерхан, Волгоград өлкәләрендә яшәгән милләттәшләребезнең дә 19 ел дәвамында бик аз артуын ышанып фәһемләү читен. Түбән Новгород, Пенза өлкәләре, Мордовия Республикасы татарларының күпләп Мәскәү шәһәренә барып урнашуларын беләбез, әмма Мәскәүдәге татарларның үсеш дәрәҗәсе, бигрәк тә 1979—1989 еллардагы күрсәткечләр әлеге агымның өсталүен тиешенчә чагылдырмый. Кара исәп белән дә шундый нәтиҗәгә генә киләсең: әйе, татар милләтенең йотыла баруы күз алдында. Аның сәбәпләре күп төрле: катнаш никахка керү, ят тирәлектә телне һәм милли аңны җую, ят тирәлек басымы астында җан исәбен алганда милләтен яшерү һ. б. Ләкин бу кадәр кыска вакыт аралыгында йотылу болай ук зур күләмдә барырга тиеш түгел иде. Димәк, рәсми статистика татар исәбен дөрес күрсәтеп бетерми.

Чынлыкта без хәзер ничәү икән? 17 яки 27 миллионмы? Һәрхәлдә, 7 миллион гына түгелдер. Ә бит без татар матбугаты таралышын мең кешегә бүлгәндә рәсми статистика мәгълүматларына таяндык. Димәк, алар хакыйкатькә якынча гына туры килә, чынлыкта татарча укучыларыбыз күбрәк, ул укучыларның җан исәбенә туры килгән матбугатыбыз саны тагын да азрак.

Милли вакытлы матбугатыбызның таралышын өйрәнү чынбарлыкның әнә шундый күләгәле якларын җәмәгатьчелеккә дә күрсәтергә форсат бирә. Җаны бар татар, халкы бәлагә тарыганда, һәлакәтне күрмәмешкә салышып яшәмәс, үз язмышын башкалар ихтыярына тапшырмас, бәлки. Күз куркак, кул батыр, дигәндәй, бездә әле дәрт тә, дәрман да житәрлек, тарих мәйданында үзең булып калу өчен гамәл кыла башларга гына кирәк. Милли матбугатны тиешле дәрәҗәдә үстерү һәм тарату шул бөек көрәшнең әһәмиятле бер өлеше булырга тиеш.

Таблица № 1

**«Казан утлары» таралышы**

| Республика, өлкәләр | 1976, барысы | № 6 мең татарга | 1986, барысы | № 1 мең татарга | 1990, барысы | № 4 мең татарга | 1995, барысы | № 1 мең татарга |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан | 36784 | 22,4 | 28237 | 16,4 | 40699 | 23,1 | 6978 | 3,9 |
| Башкортстан | 25890 | 20,9 | 16212 | 11,6 | 18348 | 12,9 | 2743 | 2,4 |
| Үзбәгестан | 4440 | 11,1 | 2323 | 3,3 | 2471 | 5,3 | — | — |
| Казагыстан | 4273 | 13,6 | 2308 | 7,1 | 2320 | 7,1 | 24 | 0,07 |
| Пермь | 2320 | 12,2 | 1138 | 7,5 | 1811 | 10,1 | 157 | 1,0 |
| Свердловск | 2236 | 12,5 | 1385 | 7,6 | 1528 | 8,3 | 85 | 0,5 |
| Ырынбур | 2006 | 13,3 | 1674 | 10,7 | 2168 | 13,6 | 254 | 1,6 |
| Чиләбе | 1578 | 7,2 | 976 | 4,4 | 1167 | 5,2 | 97 | 0,4 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Удмуртстан | 1352 | 13,7 | 609 | 5,7 | 892 | 8,1 | 61 | 0,6 |
| Төмән | 1294 | 9,4 | 1229 | 6,1 | 1694 | 7,5 | 212 | 0,9 |
| Ульяновск | 979 | 7,2 | 664 | 4,4 | 1290 | 8,1 | 162 | 1,0 |
| Кемерово | 773 | 11,9 | 407 | 6,7 | 417 | 6,6 | 27 | 0,4 |
| Кыргызстан | 767 | 10,7 | 257 | 3,6 | 367 | 5,2 | 3 | 0,04 |
| Самара (Куйб.) | 658 | 6,3 | 673 | 6,0 | 1068 | 9,3 | 149 | 1,3 |
| Чувашстан | 512 | 13,5 | 310 | 8,6 | 348 | 9,7 | 58 | 1,6 |
| Тажигыстан | 451 | 5,6 | 326 | 4,0 | 399 | 5,5 | — | — |
| Украина | 419 | 4,6 | 289 | 3,3 | 337 | 3,9 | 3 | 0,03 |
| Төрекмәнстан | 412 | 10,3 | 183 | 4,6 | 182 | 4,7 | — | — |
| Киров | 373 | 8,3 | 271 | 5,9 | 430 | 9,3 | 47 | 1,0 |
| Мәскәү | 372 | 2,0 | 409 | 2,2 | 805 | 4,3 | 74 | 0,4 |
| Коми | 364 | 20,2 | 349 | 14,5 | 298 | 11,5 | 16 | 0,6 |
| Түб. Новгород | 345 | 5,0 | 297 | 4,8 | 629 | 10,7 | 75 | 1,3 |
| Омск | 294 | 6,3 | 167 | 3,3 | 218 | 4,4 | 29 | 0,6 |
| Красноярск | 285 | 5,7 | 211 | 4,0 | 224 | 4,1 | 24 | 0,4 |
| Курган | 198 | 8,2 | 102 | 4,4 | 161 | 7,0 | 15 | 0,7 |
| Пенза | 179 | 2,3 | 145 | 1,8 | 285 | 3,5 | 23 | 0,3 |
| Өркет | 173 | 4,2 | 102 | 2,5 | 115 | 2,9 | 110 | ,3 |
| Әстерхан | 156 | 2,2 | 110 | 1,5 | 227 | 3,2 | 23 | 0,3 |
| Магадан | 119 | 17,0 | 66 | 9,4 | 57 | 8,1 | — | — |
| Сарытау | 113 | 2,4 | 77 | 1,6 | 162 | 3,3 | 14 | 0,3 |
| Якутстан | 113 | 10,3 | 115 | 7,2 | 111 | 6,5 | 6 | 0,4 |
| Бүтән җирдә | 1149 | | 858 | | 1341 | | 152 | |
| Мәҗбүри данә | 44 | | 49 | | 44 | | 44 | |
| РСФСР | 80991 | 16,2 | 56766 | 10,3 | 76734 | 13,9 | 11526 | 2,0 |
| Экспорт | 65 | | 50 | | 60 | | 20 | |
| Барысы | 91944 | 15,0 | 62549 | 9,5 | 83044 | 12,5 | 11576 | 1,7 |

Таблица № 2

## «Казан утлары»ның Татарстанда таралышы

| Казанда һәм районнарда | 1989, № 2 | 1995, № 1 | мең татарга 1989 | мең татарга 1995 |
|---|---|---|---|---|
| Арча | 2015 | 224 | 34,4 | 5,1 |
| Әтнә | | 48 | | 3,7 |
| Азнакай | 1706 | 266 | 34,5 | 5,3 |
| Әлмәт | 1552 | 270 | 18,5 | 3,0 |
| Саба | 1516 | 198 | 38,1 | 7,1 |
| Теләче | | 71 | | 5,9 |
| Кукмара | 1331 | 217 | 35,0 | 5,7 |
| Балтач | 1318 | 183 | 56,3 | 7,6 |
| Актаныш | 1207 | 214 | 36,0 | 6,9 |
| Сарман | 1198 | 179 | 39,1 | 6,0 |
| Мамадыш | 1168 | 210 | 31,7 | 5,7 |
| Мөслим | 1147 | 151 | 54,4 | 7,2 |
| Апас | 1047 | 156 | 30,4 | 8,7 |
| Кайбыч | | 43 | | 3,3 |
| Түбән Кама | 991 | 156 | 10,0 | 1,5 |
| Октябрь | 928 | 125 | 37,7 | 5,2 |
| Буа | 868 | 127 | 27,0 | 4,4 |
| Әгерҗе | 728 | 136 | 30,0 | 5,9 |
| Лениногорск | 716 | 110 | 18,1 | 2,7 |
| Чистай | 716 | 133 | 24,2 | 4,2 |
| Тукай | 713 | 84 | 36,0 | 4,0 |
| Баулы | 693 | 69 | 18,0 | 3,0 |
| Ютазы | | 85 | | 6,1 |
| Зеленодол | 670 | 105 | 13,0 | 1,9 |
| Балык Бистәсе | 651 | 124 | 25,8 | 5,2 |
| Биектау | 622 | 85 | 23,6 | 2,9 |
| Зәй | 622 | 137 | 20,7 | 4,6 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Минзәлә | 554 | 107 | 24,7 | 5,6 |
| Әлки | 540 | 87 | 35,3 | 6,2 |
| Питрәч | 517 | 65 | 35,2 | 4,3 |
| Бөгелмә | 410 | 85 | 12,3 | 2,4 |
| Чирмешән | 382 | 63 | 31,8 | 5,7 |
| Кама Тамагы | 380 | 114 | 38,8 | 12,7 |
| Яңа Чишмә | 347 | 61 | 51,0 | 10,2 |
| Аксубай | 331 | 62 | 22,8 | 5,2 |
| Чүпрәле | 326 | 54 | 16,5 | 3,0 |
| Лаеш | 281 | 33 | 23,4 | 2,5 |
| Болгар | 226 | 48 | 28,6 | 6,8 |
| Алабуга | 224 | 50 | 13,8 | 2,2 |
| Тәтеш | 216 | 31 | 23,7 | 3,4 |
| Алексеев | 182 | 32 | 26,4 | 4,6 |
| Менделеев | 188 | 18 | 15,9 | 1,3 |
| Югары Ослан | 64 | 19 | 17,3 | 3,2 |
| Яр Чаллы | 2411 | 254 | 16,9 | 1,2 |
| Казан | 4860 | 474 | 11,7 | 1,1 |
| Ваклап сату | | 1421 | | |
| Барысы | 36582 | 6978 | 22,1 | 3,9 |

Таблица № 3

## Кайбер татарча басмаларның таралышы *(меңнәрдә)*:

| Исемнәре | 1976 | 1986 | 1991 | 1994 | 1995 |
|---|---|---|---|---|---|
| Сөембикә (Азат хатын) | 362 | 406 | 260 | 83 | 37 |
| Казан утлары | 92 | 63 | 40 | 23 | 12 |
| Ялкын | 77 | 59 | 36 | 21 | 11 |
| Чаян | 72 | 70 | 25 | 12 | 4 |
| Мәгариф (Совет мәктәбе) | 24 | 20 | 17 | 22 | 23 |
| Татарстан (Татарстан коммунисты) | 17 | 16 | 5 | 2 | 1 |
| Идел | | | 66 | 13 | 5 |
| Салават күпере | | | | 17 | 14 |
| Мирас | | | | 10 | 4 |
| Аргамак | | | | 8 | 3 |
| Сабыйга | | | | 3 | 4 |
| Казан | | | | 1 | 1 |
| Татарстан яшьләре | | | | 200 | 134 |
| Юлдаш | | | | 95 | 110 |
| Ватаным Татарстан | | | | 61 | 58 |
| Сабантуй | | | | 24 | 14 |
| Мәгърифәт | | | | 20 | 15 |
| Шәһри Казан | | | | 18 | 14 |
| Татарстан хәбәрләре | | | | 15 | 7 |
| Татар иле | | | | 5 | 5 |

**Тәүфикъ ӘЙДИ**

## ТАТАРСТАННЫҢ ЯҢА ПАРЛАМЕНТЫ

5 һәм 18 март көннәрендә — ике турда үткәрелгән сайлаулар нәтиҗәсендә, административ-территориаль һәм территориаль округлардан Татарстан Дәүләт Советына 130 депутатның 124 е сайланды. 6 сайлау округында кабат тавыш бирү 28 апрельгә билгеләнде.

Яңа Парламент составында 5 хатын-кыз бар. Административ-территориаль округлардан күбрәк районнарның хакимият башлыклары депутат итеп сайланды. Башлангыч мәгълүматларга караганда, 114 депутат (92 процент) — нинди дә булса сәяси партиядә тормый. Республика парламентына Жириновский партиясе һәм «Тигезлек һәм законлылык» блогы бер вәкилен дә үткәрә алмады.

Татарстан язучыларыннан 5 кеше — «Сабантуй» газетасының баш мөхәррире Роберт Миңнуллин (111 нче Биләр округы), «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире Ренат Харис (117 нче Зөя арьягы округы), җөмһүриятебезнең милли китапханәсе директоры Разил Вәлиев (119 нчы Васильево округы), драматург Туфан Миңнуллин (120 нче Тәмте округы), ТР Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев (123 нче Нократ округы), әлеге сайлауларда җиңеп чыгып, яңа парламентка сайландылар.

## ТР ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ ПЛЕНАР СЕССИЯСЕ

30 мартта Татарстан Республикасы Дәүләт Советының беренче пленар сессиясе булды.

Депутатлар җөмһүриятебезнең Вице-президенты булып эшләгән В. Лихачевны, ул вазифаларыннан азат итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе итеп сайладылар. Дәүләт Советы Рәисе урынбасарлары итеп Р. Харисов, З. Вәлиева, ТР Дәүләт Советы Секретаре итеп Н. Әбдерәшитова сайланды.

Сессиядә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы һәм ТР Дәүләт Советының Парламент контроле комитеты да сайланды. Сессия Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре төзү турында карар кабул итте.

Сессия эшендә ТР Президенты М. Шәймиев катнашты һәм доклад ясады.

Утырышны ТР Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев алып барды.

## ЮНЕСКО БЕЗНЕ ТЫҢЛЫЙ

Дөнья җәмәгатьчелеге һәм халыкара оешмалар Татарстан турындагы мәгълүматларны беренче чыганаклардан алуны кулайрак күрәләр. Шуңа күрә ЮНЕСКОның Мәскәүдә Европа илләре һәм Россия вәкилләре катнашында уздырылган күчмә утырышына әлеге абруйлы оешманың мәдәният һәм мәгълүмат буенча халыкара эксперты, язучы Разил Вәлиев та чакырылган иде. Ул республикабызның үткәне, бүгенгесе, сәяси һәм икътисади яңарышы турында сөйләде.

## СӨЕНЕЧЛЕ ХӘБӘР

Төркиядән Татарстан Язучылар берлегенә җибәрелгән телеграммада шатлыклы хәбәр килде. Төрки дөнья әдәбиятына керткән зур хезмәте өчен язучы Ринат Мөхәммәдиев Төркиянең әдәбият, сәнгать өлкәсендәге мәртәбәле премиясенә лаек дип табылган.

Шунысы гыйбрәтле: 1995 ел өчен ике премия билгеләнсә, аның икенчесе Лондонда яшәүче Кипр шагыйре, Нобель премиясе лауреаты Осман Туркайга бирелгән.

Бүләкләр тантаналы рәвештә шушы елның 29 апрелендә Әнкарада тапшырылачак.

## ШИГЪРИЯТ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

30 мартта язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында шигъри ел йомгакларына багышланган җыен булды. Аны, кыскача кереш сүз белән, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Р. Мөхәммәдиев ачты. Аннары шигъриятнең аерым юнәлешләре буенча Т. Галиуллин, Р. Мостафин, С. Малышев, Р. Кукушкин, Ә. Рәшитов, Н. Гамбәров, Р. Зәйдулла, М. Вәлиев докладлары тыңланды, фикер алышулар булды.

Җыелышта күп кенә язучыларга Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы таныклыклары тапшырылды.

## ФАТИХ КӘРИМИГӘ — 125 ЕЛ

4 апрельдә Татарстан Фәннәр Академиясе һәм аның Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты, күренекле җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, язучы һәм журналист Фатих Кәриминең тууына 125 ел тулуга багышлап, фәнни конференция үткәрде.

Конференциядә Татарстан Фәннәр академиясе президенты, академик М. Хәсәнов, профессорлардан Ф. Мусин, Я. Абдуллин, Р. Ганиева, доцентлардан Ф. Солтанбәков, М. Гайнетдинов, Ш. Садретдинов, М. Йосыпов, Э. Галиев, өлкән фәнни хезмәткәрләрдән М. Әхмәтҗанов, И. Бәширова, М. Гайнетдинов, өлкән укытучы Җ. Миңнуллин, фәнни хезмәткәр Ф. Гаффарова һ. б. чыгыш ясады.

## БАКЫЙ УРМАНЧЕ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Халкыбызның горурлыгы — атаклы рәссам-сынчы Бакый ага Урманченың тууына 95 ел тулу уңаеннан, башкалабызның сынлы сәнгать музеенда әдәби-музыкаль кичә булып узды. Мәдәният әһелләреннән бик күпләр — рәссамнар, язучылар, композиторлар, галимнәр, артистлар килгән иде.

Әлеге истәлекле кичәдә Татарстан рәссамнар берлеге идарәсе рәисе А. Абзгильдин, мәдәният министры урынбасары М. Низамиев, рәссам-сынчы турындагы монография авторы А. Новицкий, академик А. Кәримуллин, шагыйрь Р. Харис, сәнгать белгече Д. Вәлиева, Б. Урманченың хәләл җефете Флора ханым һ. б. чыгыш ясадылар, онытылмас хатирәләре белән уртаклаштылар.

Соңыннан зур концерт булды.

## К. НАСЫЙРИГА БАГЫШЛАП

Казан педагогия университетында «Каюм Насыйри һәм хәзерге педагогика» дигән темага укулар булып узды. Ул күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйриның тууына 170 ел тулуга багышланган иде.

Бер төркем галимнәр Зеленодолда, аның иҗатына багышланган дәүләт музееның филиалында да булдылар.

## САРА АПА БӘЙРӘМНӘРЕ

Сөекле композиторыбыз Сара ханым Садыйкованың якты истәлегенә багышлап, 22 февральдә Казан шәһәренең Азино бистәсендәге 144 нче мәктәбендә әдәби-музыкаль кичә уздырылды. Анда «Сара ханым фонды» җитәкчесе Ә. Хөсәенов, язучыларыбыздан Г. Зәйнашева, Л. Ихсанова, Р. Харис, Ш. Маннап, яшьрәк каләмдәшләребездән Н. Сәйяр, Ф. Тарханова, җырчы Р. Җаббаров, концертмейстр К. Сатиев катнашты.

* * *

С. Садыйковага багышланган шундый ук кичә 11 мартта Мәскәүдә, Татар зыялылары клубында да булып узды. Очрашуга Казаннан Татарстан җөмһүриятенең Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреатлары — язучы Г. Зәйнашева белән җырчы Х. Бигичев, Татарстанның халык артистлары — җырчы З. Сәхәбиева белән биюче Р. Габдрахманов, шулай ук концертмейстр Г. Максимов килгән иде.

Кичәне зыялылар клубы директоры — язучы Н. Кәримова алып барды.

## КАЛӘМДӘШЕБЕЗ РУХЫНА

Г. Тукай исемендәге Дәүләт музеенда шагыйрь — «Казан утлары» журналында эшләгән мөхәррирләрнең берсе, Г. Исхакый премиясе лауреаты Рәшит Әхмәтҗановны искә алу кичәсе булып үтте. Анда язучылардан М. Хуҗин, К. Тимбикова, Ә. Рәшитов, Ф. Яхин, Ш. Мостафин, артист И. Әхмәтҗанов, җырчылардан К. Хәйретдинова, Р. Дәминов, концертмейстр Г. Сәйфуллин, музыка белгече К. Таҗиева һ. б. катнаштылар.

## «ЗАМАН» ЛАУРЕАТЛАРЫ

Халыкара иҗтимагый-сәяси «Заман — Татарстан» газите 1994 елның иң яхшы язучысы, шагыйре, журналисты исеменә конкурс игълан иткән иде. Быелның март азагында аңа йомгак ясалды. Редакциягә килгән укучы хатларын тикшереп-анализлаганнан соң, 30 процент балл җыеп, язучы Фәнис Яруллин, шагыйрь Шамил Маннап (24 балл) һәм журналист Айдар Хәлим (22 балл) конкурста җиңеп чыгучылар дип табылды. Лауреатларның һәркайсына акчалата премия һәм дипломнар тапшырылды.

## «ХӘТЕР ҖЫЕНЫ»

15 февральдә — герой-шагыйрь М. Җәлил туган көндә — Кукмара районының Түбән Өскебаш авылында җәлилчеләрнең 1 республика-зона «Хәтер җыены» булып узды. Бергә — атаклы җәлилчеләрдән Әхәт Атнашев белән Рушад Хисаметдиновны биргән изге җиргә — ерак Үзбәкстаннан Мусаның якын көрәштәш дусларыннан берсе саналган Фәрит ага Солтанбәков һәм аның улы — Казан дәүләт университеты галиме Фоат әфәнде, «Казан утлары» журналыннан язучы-эзтабар Ш. Әхмәтсафа (Мостафин), «Ватаным Татарстан» газетасыннан өлкән фотохәбәрче М. Шакирҗанов, «Идел-Урал» легионерлары, Франциянең партизан отрядларында көрәшкән макизарлар, район җитәкчеләре, күп кенә мәктәпләрнең татар теле-әдәбияты һәм тарих укытучылары килгән иде.


Бу көнне Түбән Өскебаш урта мәктәбендә «Җәлилчеләр музее» ачылды.

Әлеге җыен Кукмара район хакимияте (җитәкчесе — М. Гатиятуллин) һәм «Таң» күмәк хуҗалыгы (рәисе — Р. Газизуллин) инициативасы белән оештырылды.

## ЕРАК КӨНЧЫГЫШТАГЫ «ТУГАН ТЕЛ»

Рәсәйнең, БДБ илләренең төрле төбәкләрендә татар милли мәдәни үзәкләре елдан-ел арта, үзләренең эшчәнлекләрен яхшырта бара. Приморье краенда оешкан татар мәдәни үзәге «Туган тел»гә дә бик күпләр тартыла. Анда тупланган милләттәшләребез бергәләшеп туган телебез нечкәлекләрен өйрәнәләр, халкыбыз тарихына тагын да тирәнрәк үтеп керергә, гореф-гадәтләребезгә, йолаларыбызга тугрылыклы булырга омтылалар. Бирелә һәр елны Сабантуйлар гөрләп уза, сәхнәдән милли моңнар яңгырый, балалар татарча сөйләшә... Менә шушы эшләрнең һәммәсенең уртасында кайнап, безнең милләтпәрвәрләр — Приморье краеның Надеждинский районы башлыгы урынбасары Җәүдәт Гыйззәтуллин («Туган тел» рәисе), контр-адмирал Әнәс Нуретдинов, хәрби журналист — «Красное знамя» газетасының баш мөхәррире урынбасары Дмитрий Латыйпов һ. б. халкыбызга тугры хезмәт итәләр.

■ ■ ■



# ГАЛӘМГӘ ҮРЕЛГӘН УЧАК УТЫ

Илдар Ханов иҗаты һәрчак бәхәсле булды. Аның әсәрләренә карата мөнәсәбәт берьяклы гына түгел. Берәүләр — икеләнмичә кабул итә, икенчеләр исә берсүзсез инкарь итә. Әмма Илдар Ханов — бүгенге көннең танылган скульпторы, рәссамы, бернигә дә карамыйча үзенең иҗат дөньясын торган саен баета бара. Рәссамның һәр әсәре биниһая киң колачлылыгы белән көчле тәэсир уята. Төсләр эченә алынган вакыйгалар көнкүрештән өстен югарылыкта, тирән гомумиләштерүгә, мәгънәле символга әверелә. Рәссам аерым шәхес тормышы һәм язмышына гына төбәлмичә, бөтен кешелек галәмен колачлап алырга омтыла. Әмма аның чиксез җиһанында минем дә, синең дә, ягъни аерым бер кеше язмышы да чагылыш таба. Уйлап багыйк әле: 1945 елдагы дөнья тарихында күрелмәгән Хиросима фаҗигасе безнең йөрәкләргә кагылмыймы? Нәкъ ярты гасырдан соң шушыңа тиң дәһшәт Чечняда кабатланмадымы?..

Рәссамның «Гасырның тууы» дигән картинасында — шушы дәвер балалары, фаҗигале язмышка дучар булган буыннар, коточкыч дәһшәт, инәлү, өметсезлек, моңа кадәр кичерелмәгән афәт сулышы бәреп тора. Аның «Хатын-кызның ялваруы» картинасыннан гасабилы күзләрен төбәп, галәм тирәнлегеннән кулын сузган образ безнең чоргамы, киләчәк дәверләргәме кисәтеп дәшә?..

Әлбәттә, күпләребез гадәти чынбарлыкны тасвирлаган иҗатчыларны якынрак кабул итәргә күнеккән. Рәссамнар һәм сәнгать белгечләре реализм яхшыракмы, әллә инде ирреализм кирәкме дип бәхәсләшергә яраталар. Болар икесе дә янәшә яшәргә хаклыдыр, мөгаен. Шулай булганда гына сәнгать дөньясы камил бөтенлеккә ирешә аладыр.

Илдар Хановка, кешелек язмышы битләрен сурәтләүче буларак, сәнгатьнең символик алымы якынрак. Аның «Кешелек учагы» дигән әсәрендә без, учак ялкыны булып күккә төбәлгән кешеләр дуенын күрәбез. Кем белә, галәм биеклегеннән караганда, без бәлки нәкъ шулай күренәбездер дә?..

«Апокалипсис»та кеше вөҗүденең боҗраланган хәрәкәте — убылып килгән афәтән котылып каласы килү кодрәте чагыла.

Илдар Хановның иҗади табигате һәркемгә ачык. Ул — киң урамнар, мәйданнар буйсындыра ала торган рәссам, скульптор. Ул Казан кремленең эчен, Казан университетын үзгәртеп коруны проектлаштыра (болар әле гамәлгә ашмаган). Скульпторның киңлеккә омтылган хыялына җирлек чын мәгънәсендә Чаллыда ачылды. Рәссам анда символик скульптура ансамбльләреннән, бассейн һәм фонтаннардан торган Энтузиастлар проспектын җанландырды. Святослав Рерих аңа бөек рәссам булган әтисенең хикмәтле сүзләрен ирештерә. Имеш, киләчәктә Кама аланы, ягъни, Чаллы дөньяның рухи чистарыну зонасы булачак икән. Олуг акыл иясенең шушы фикерен истә тотып, Илдар Ханов Галәми храм проектын эшли, бу төзелеш эше башланып та китә... Ләкин бүгенге икътисад заманында тукталып кала.

Һәр рәссамның иҗаты, һичшиксез, милли үзенчәлекләрне чагылдырырга тиеш. Милли калорит — иҗат әһеленең таяну ноктасы, рухи тамыры. Әмма җәмгыятьләрнең билгеле бер үсеш югарылыгында, өчмененче гасыр-эпоханың бусагасында торганда кешелек каршында моңа кадәр күрелмәгән мөмкинлекләр ачыла бара. Иҗат кешесенә, бәлки, гомумкешелек төшенчәләре белән эш итү, яңа алымнар, яңа төсләр-мәгънәләргә ирешүдә киң офыкларга чыгу юлы ачылырга мөмкин.

Илдар Ханов — купкырлы талант иясе. Ул иҗат эшенең тәмен табып, нәгышле сәнгатьтә һәм скульптура өлкәсендә татар галәмен дөнья аренасына алып чыгардай мәртәбәле әсәрләр тудырачак әле.

**Динә ВӘЛИЕВА,**
сәнгать белгече.

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Илдар Хановның «Кешелек учагы» картинасыннан фоторепродукция.


**Тышлыкның дүртенче битендә:** әдәбият галиме, танылган тәрҗемәче Рәис Даутов.

# ЯҢА КИТАПЛАР




**Илһам:** *(Жырчы турында китап)* Коллектив.— Казан: Татарстан китап нәшрияты, 1995.— 126 бит. Тиражы — 15000.

Бу китапка татар халкының гасырлар буена жыйналып килгән моң-зарын, тарихын чагылдырган жырларын бөтен матурлыгы белән бүгенге буыннарга житкерүче мәшһүр жырчыбыз Илһам Шакировка татар әдипләре багышлаган язмалар кертелгән. Авторлар арасында Н. Исәнбәт, С. Хәким, С. Баттал, Н. Нәжми, Н. Арслан, И. Юзиев, Т. Миңнуллин, Г. Ахунов, Ш. Галиев кебек халыкка киң мәгълүм исемнәр бар. Китапта жырчының тормыш юлын чагылдырган фоторепродукцияләр урнаштырылган. Сувенир-бүләк рәвешендә полиграфик яктан затлы итеп эшләнгән бу китапның төзүчесе — шагыйрь Разил Вәлиев.




Гарипова Фирдәвес. **Исемнәрдә — ил тарихы.** *(Югары һәм урта уку йортлары өчен кулланма).* Казан: Татарстан китап нәшрияты. 1994.— 264 б. Тиражы — 10000 данә.

Тел белемендә ономастика, топонимика, гидронимика дигән төшенчәләр бар. Гидронимика дигәне — барлык төр су чыганакларының — елга, инеш, күл, сазлык, чишмә, күпер һ. б. атамаларын өйрәнә торган фән. Ә безнең республикабыз елга-күлләргә, чишмә-суларга ифрат бай. Бу китап мәктәп укучылары, студентлар, укытучылар, галимнәр һәм гомумән халкыбызның теле, тарихы, ономастикасы белән кызынсынган һәр кеше өчен үзенә күрә бер юл күрсәткеч. Китап Татарстан Президенты каршындагы Мәдәният үсешенә ярдәм итү фондының матди булышлыгы белән чыгарылган.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог